ISSN 0206—418

# Казан утлары

10.1988



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

1988

10

(792)

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

Х. КАМАЛОВ. **Үлгәннән соң яздым.** *Роман* 3
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. **Хатасыз яз, язмыш.** *Шигырьләр* 62
З. ХӨСНИЯР. **Көзнең соңгы көннәре.** *Хикәя* 69
В. КАСЫЙМОВА. **Ачы умач.** *Хикәя.* 79
Э. МӨЭМИНОВА. **Нәрсәдер югалтам сыман.** *Шигырьләр* 86
Г. САДӘ. **Хәтер җебе.** *Шигырьләр* 88
АКЪЕГЕТ. **Җир хуҗасы булсак.** *Шигырьләр* 91

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

С. ЧАВАЙН. **Мәхәббәт имән...** *Шигырьләр* 94

Р. МОСТАФИН. **Кабан күле серләре.** *Тарихи-документаль повесть* 96

ӘДӘБИ МИРАС

**Мәҗмугы-л-хикәят** 130

БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

М. ВӘЛИЕВ. **Ни өчен борчылабыз?** 155
Р. МИҢНУЛЛИН. **Нәрсә булды безгә?** 166

БИБЛИОГРАФИЯ

Ф. ХАТИПОВ. **Фикер катламнары** 170

**Бер сорауга — бер җавап** 173

УФАДА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Х. ГОБӘЙДУЛЛИН, Җ. МИҢНУЛЛИН. **«Госмания» мәдрәсәсе** *(А. Тимергалина рәсеме)* 174

БОРЫНГЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ

Ф. ГАРИПОВА. **Тәтеш** 176

Укучы сүзе 178
Ф. ШӘФИКОВ. Безне дә онытмагыз 183

ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ-ЯЗУ

Җ. МИҢНУЛЛИН, Р. КАДЫЙРОВ. Икенче дәрес 185

Татар әдәбияты чит илләрдә 188

Котлыйбыз 189

Культура тормышы көндәлеге 190

Тышлыктагы сурәтләр 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(баш редактор урынбасары)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-65,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Окончание романа Х. КАМАЛОВА «Написал после смерти». Историко-документальная повесть Р. МУСТАФИНА «Тайны озера Кабан». Рассказы З. ХУСНИЯРА «Последние дни осени» и В. КАСИМОВОЙ «Горький хлеб». Стихи Раш. АХМЕТЗЯНОВА, Э. МУЭМИНОВОЙ, Г. САДЭ, АКЪЕГЕТ.
В рубрике «Дружба народов — дружба литератур» публикуются стихи классика марийской литературы С. ЧАВАЙНА.
«Литературное наследие» — образцы татарской народной прозы XVIII века.
«Литературная критика». Продолжение дискуссии «Время и поэзия»: статьи М. ВАЛИЕВА, Р. МИННУЛЛИНА.
В рубрике «Библиография» рецензируется книга Ш. Галиева «Илһамым — мәхәббәтем» («Мое вдохновение — моя любовь»).
«Памятники татарской культуры в Уфе» — медресе «Усмания».
«Города древней Булгарии» — статья Ф. ГАРИПОВОЙ «Тетюши».
Слово читателя.
Навыки чтения и письма на основе арабской графики. Занятие 2-е.
Татарская литература за рубежом.
В номере отмечаются юбилеи Н. Фаттаха и С. Гараевой.
Дневник культурной жизни.
На наших обложках: интерьер старинного татарского дома. Татарское книжное издательство.

Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*
Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Т. Сибгатуллина. Г. Салихҗанова.*

Производствога бирелде 02.08.1988 ел. Басарга кул куелды 23.09.1988 ел. ПФ 11286. Офсет ысулы белән басылд.
Кагазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 64549. Заказ А-301. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1988 ел.

# ПРОЗА

## Хисам Камалов

# ҮЛГӘННӘН СОҢ ЯЗДЫМ

РОМАН

### Өченче бүлек

### I



Энвәр исән аягын караватыннан идәнгә салындырып утырды. Әмма яра шул чаклы нык сулкылдарга тотынды, хәтта тынны бетерә иде. Чыдарга тырышып, тешен кысты, учларын йомарлады. Авыртуга түзә алмыйча аякны тагы элекке торышына кайтарсаң — беттең, бернигә ирешә алмыйсың. Исән аякны шулай кыймылдаткан саен яра бик каты сулкылдаячак инде. Нишләргә? Күсәк булып ятаргамы? Менә хәзер туйганчы сулкылдасын, Әнвәр чигенмәячәк... Авырту тән буенча менеп баш миенә чүкеч белән суккан кебек итә иде. Маңгаеннан салкын тир борчак-борчак булып сикерде.

Берничә көн рәттән шулай итте. Аннары бер артсыз урындык алды, шуңа тотынып аякка басты. Югары киткән баш кинәт әйләнергә тотынды, палатаның асты өскә килде, Әнвәр караватбашына шатырдап ябышты, аумады. Эчтән ниндидер дулкын башына килеп менде, күз алдында ак бөтерчекләр уйнаклады. Ул күзләрен йомды, баш әйләнүе туктады. Куллары белән урындыкны ныклап тотып, аны бер адым алга күчерде, аннары шуңа таянып аягын атлады. Бер адым алга китте ул. Шул хәрәкәтен тагы кабатлады. Янә бер адым... Аннары үҗәтлек керде. Бәдрәфкә барып житкәндә бөтен тәне шабыр су иде, күлмәге тәненә ябышкан. Ул шулай урындыгын алга күчерә-күчерә кайтты. Бик нык арыса да, үзендә канәгатьлек рәхәтлеге сизде.

Һәр адым хәзер аңа шулай бик авырлык белән генә бирелә икән. Үз хәлеңне аңламыйча, аңа жайлашмыйча һич чара юк. Әнвәр үз хәлен нык кичереп борчыла иде, үзен хәзерге хәленә туры китерү өчен күп көч куярга кирәклеген тагы ничәнче кат аңлагандай булды.

Әйе, тере килеш кабергә кереп булмый. Эчеңдә жаның бар икән, син нәрсәдер эшләргә, ниндидер эш башкарырга тиешсең. Әнә Турганов ничек тырыша! Балансста дебет белән кредитны туры китерә алмыйча изалана. Дебет белән кредит бервакытта да бер-берсенә тәңгәл килә алмыйлар икән. Турганов дәрестән кайтышлый Әнвәр янына тукты. Балансны үзенчә аңлатмакчы була:

— Тормышта һәр нәрсә дә ике яклы. Әнә тәңкә акча. Бер ягы күн,

---

Ахыры. Башы 8, 9 саннарда.

бер ягы иләк. Бер ягында герб, икенче ягында сан. Таяк та ике башлы... Әйдә син дә укы, ятудан файда юк,— дип куя да китеп бара.

Әйе, ятудан файда юк, күп ятты инде. Иң элек култык таягына иялә-нергә кирәк әле. Укымыйча булмас, дип уйлый Әнвәр, ләкин бар белгән-нәре онытылып беткән. Контузияләр, аң җуеп ятулар хәтер тартмасын ватып, челпәрәмә иткән, фикерне, уйны бер ноктага җыеп булмый. Тарт-мага туплап булмый. Шулай да бик укыйсы килә. Ансыз, тутыккан калай кебек, бернигә дә ярамыйсың. Әнә әнисе дә: «Улым, авылга кайтма,— дип яза.— Монда сиңа бик авыр булыр. Җизни дә кулсыз кайткан икән. Тормышы авыр: апаңа гына көч килә. Мин дә авырыйм, улым, кара са-ры, диләр. Авылга кайта күрмә. Капчык ямап, мич башында фураж кип-тереп бераз эш көне төшерәм. Апаң килеп булышкалап китә. Балалары күп аның да».

Апасының хаты да шундыйрак иде. «Ник аягыңны кисәргә бирдең, акылсыз! Ник уйламадың әзрәк? Әнә җизнәң әйтә: кулны кисмәсәләр, гарипләнеп булса да төзәлә иде, ди. Синең дә төзәлгән булыр иде әле. Акылсыз! Хәзер ничек итеп яшәрсең? Әнинең дә хәле әйбәтләрдән түгел. Синең уйлап җиткермичә эшли торган гадәтең бар иде. Кул-аякларын кистермәгән кешеләрнең төзәлүен җизнәң дә үз күзе белән күргән. Врач-ларга кисәргә генә булсын, ди. Үзең дә инде уйсыз. Аяк тиклем аякны...»

Бу хатка Әнвәр башта кимсенде, йөзенә мендәрен каплап, яшерен генә елап алды. Аннары аңлады. Әнисе дә, апасы да аны бөтен җаннары белән кызганып, хәленә кереп язалар иде. Үз тормышлары кушканча уй йөртәләр. Аны үз өсләренә ала алмыйлар. Моның нәрсәсенә кимсенергә? Аягыңны ник кистердең, дип әйтүләре генә бераз гадел түгел. Гангрена дигән нәрсәне аларга ничек аңлатырга? Аягын кисәселәрен ул белмәде, бер аңын җуеп, бер аңга килеп яткан чагы булгандыр. Сөякне пычкы бе-лән шатыр-шытыр китереп кисеп ятканда гына аңына килде ул һәм хәтәр авыртудан кычкыра башлады. Аягы хакында уйламады, авыртуны гына белде, шуңа кычкырды. Аңа тизрәк укол кададылар һәм ул тагы аңын җуйган кебек булып калды. Аягы киселгәнен шактый вакыт үткәч кенә белде... Әнвәр көннән-көн бер ачы хакыйкатьне төшенә бара: аңа беркем дә ярдәм итә алмаячак.

Урындык күчерә-күчерә йөреп, буыннары бераз ныгыгач, Әнвәр кул-ларына култык таягын алды. Һәм шактый ансат йөреп тә китте. Гел тәпи йөрергә өйрәнә торган бала инде. Йөргән саен йөрисе килеп тора иде. Караватлар араларыннан үтә-сүтә йөри. Кемдер яткан җирдән аңа әмер би-рә: «Один татарин, в два шеренга становись!»— ди. Көлешәләр. Әнвәргә дә рәхәт булып китә. Болай йөри алу бер бәхет булып тоела аңа.

Кайчак аның янына ике аяксыз Әзимов үзенең подшипниклы арбасы белән шуып килә. Куллары белән үрмәләп караватына менә. Беркем бе-лән аралашмый, сөйләшми ул. Тик яткан көе көне-төне китап укый. Иске гарәп хәрефе белән язылган китаплар. Әнвәр берсенең соңгы битен кара-ган иде, рус хәрефләре белән «Ак юл» дип язылган. Каян ала икән бу ки-тапларны? «Нянкалар аша базардан алдырам», диде Әзимов. Аннары ул сугыштан бер тартма машина энәләре алып кайткан. Шуны әз-әзләп са-та икән. Энә өчен әллә нинди китаплар табып китерәләр, ди. Күзләре та-лып, кызарып беткәч, Әнвәр янына хәл җыярга килә.

— Сиңа укырга кирәк,— ди Әзимов.— Сиңа әле мыек та чыкмаган икән. Әллә кырынганың да юкмы?

— Юк,— ди Әнвәр нигәдер сәерсенеп.

Аны күргән бер кеше: «Син бик яшь, ничек фронтка эләктең?»— ди. Ә Әнвәр исә үзенә бик карт шикелле тоела. Нинди генә газаплар чикмәде ул? Ике тапкыр авыр яраланды, контужен булды. Алгы сызыкта күргән газаплары әллә ничә кешегә җитәрлек. Әгәр гомер, күргән газап-лары буенча исәпләнсә, ул бик карттыр инде.

— Чукынмыйча карга, укымыйча мулла булалмассың, дигәннәр.— Әзимов әйтә моны. Әнвәр уйлары белән читкә китеп торган икән.

— Яралар бик сызлый шул.

— Укыганда онытыла ул. Мин шуның белән генә юанып яшим.

— Белмим шул, укыйсы иде дә.

— Үзең дә күрәсең, хәзер бер төрле дару да алмыйм. Син гарәп танымыйсың шул, кызык китаплар бирер идем.

— Күптәнме монда, Әзимов абый?

— Күптән. Мин Риганы алганда яраландым. Риганың яртысы бездә, яртысы аларда булып торды. Күперне җимерткән иде. Дингез култыгыннан эсменецлар атып җанга тиде. Минә кайда тәмуг булды. Аларның снарядлары тонналы диме? Сиңа укырга кирәк, әнә бухгалтерлар курсы ачканнар.

— Куркам, баш тумәр кебек түнеп тора.

— Ачыла ул. Бүредән куркып урманга бармый тормыйлар.

— Әллә син укып чыктыңмы инде?

— Юк, мин карт инде. «Нәрсәгә?» дип тә уйлыйм, чөнки йөрәк бик начар минем. Бер ягына кан бик әз төшә икән, насосы тузган, ди врач. Минә минем иреннәрнең зәңгәрсуланып торганын чамалыйсыңмы? Юкса, минем белән яткан күпләр курсларда укып, кеше булып чыгып киттеләр. Әнә ике аяксыз Ефимов белән бергә яткан идек. Хәзер тәэминат министрлыгында эшли ди. Инспектор булып. Инвалидларга ярдәм биреп тора икән. Йөри торган егетләр аның янына баргалый. Берсен дә буш җибәрми. Ун-унбиш тәңкә булса да бирә, ди. Эшкә казна машинасы алып килә, кайтарып куя, ди.

— Казанныкыдыр ул?

— Әйе. Хатыны, баласы бар икән.

— Квартира яклары бик начар, ди, монда.

— Анысына танышлык кирәк.

— Шул танышлык дигән нәрсә кайчан бетәр икән?

— Коммунизмда бетәр, диләр. Минем янда яткан Чапбаев дигән егет, беләсеңме, ничек итте? Синеке кебек төптән бер аягы юк. Курста укып, документ алды. Эшкә урнашты. Кайдадыр хисапчы булып. Ләкин торырга урыны юк. Нишләргә? Эшләгән җирендә моңа акыл өйрәтәләр. Кайда квартирадан күченәләр, шуны чамала, диләр. Күршеләр белән таныш та җайла. Акча төртәсеңме, ничек?.. Чапбаев шулай фатирлы булды. Хәзер рәхәтләнеп эшләп ята.

— Мин алай итә алмыйм шул, Әзимов абый,— диде Әнвәр авыр сулап.

— Дөнья әрсез-ертлачларныкы, энем.

— Ә ничек ертлач-әрсез булырга соң?

— Анысына грамотым җитми, әмма әрсезләр бәхетле була икәнен беләм.

— Ничек инде?

— Минемчә, аның сере болай булса кирәк: менә сиңа, әйтик, тормышта бер әйбәт җай туры килде, ди. Шуны син кулдан ычкындырмаска тиеш, тешең-тырнагың белән шул җайга тотынырга. Үзләштерергә. Әрсезләр нәкъ шулай эшли дә. Алар тормышта очраган бер җайны кулдан ычкындырмый. Намусны-нине уйлап тормый. Намуссынып торсаң, булмый ул. Менә ни өчен әрсезләр күп уңышка ирешәләр.

— Миннән булмый шул,— диде Әнвәр.

— Әй, энем, бик күп булдыра алмыйм дигән эшләр эшләргә туры килер сиңа, башың яшь! Ат бер аяк та басмам дигән җиренә йөз кабат басарга мәҗбүр була, ди. Тәртәгә җигелгәч кирәгеңне бираләр инде... Хәрби тормышта ансат ул. Боерык бирәләр, шуны үтисең. Бурычың өстеңнән төшә. Тагы боерык көтеп йөрисең. Баш ватып торасы юк үзеңә. Мин моны дөрес эшлимме, ялгышмы дип тә ми сарыф итәсе түгел. Көч бары әмерне үтәргә генә чыга. Ә тыныч тормышта бары да үзеңә, үз башыңа төшә. Ялгышың өчен дә үзең түлисең. Гаскәрдә бары да әзер. Иртәге өчен ишәк кайгырган. Нәрсә киярмен, нәрсә ашармын дип үеңа

да кереп чыкмый. Ә монда энәсенә хәтле үзең эшләп табарга, үзеңә борчылырга. Көч күп кирәк, нервы нык кирәк.

— Безнең нервылар тузган, тузган...— дип Әнвәр үзен карт итеп тоюы хакында уйлап алды.

— Ә барыбер яшәргә кирәк,— диде Әзимов һәм резинадай зәңгәрсу иреннәре белән әз генә елмайган итеп үзенең арбасына төшеп утыра башлады.

Әзимов янына малайлары килгәләп йөри иде. Кайдадыр Паратскида гына торалар, заводта эшлиләр. Инде өйләнеп башлы-күзле булырга да өлгергәннәр. Икесе дә ФЗӨдә һөнәр алган икән. Әзимов алар белән дә ничектер аз сөйләшә. Тыңлап кына утыра, ә малайлары туктаусыз сөйли иде. Әллә шулар белән сөйләшүдән туган фикерләре тәэсирендә, әллә болай, Әзимов Әнвәр караватына килеп утыргач, әйтеп куя:

— Иман кирәк ул, аннан башка булмый,— ди. Әнвәр иман сүзен дини мәгънәдә генә аңлый. Әзимов дингә ышана торган кеше түгел, шуңа күрә күзләрен чет-чет йомып, карап тора. Ни дип әйтергә дә белми.

— Намус хакында әйтәм, намус,— диде Әзимов Әнвәрнең аңламый торуын күреп, сүзенә ачыклык кертте.— Намус гаделлек белән генә кеше күңеленә керә, гаделлек белән генә ныгый. Ясалма, күргәзмә намус ул намус түгел!— Ул моны бик кайгырып, пошынып әйтә. Уфылдап көрсенә.

Ул Әнвәрнең чамасын тартып карый шикелле, уй йөртә аламы бу малай, юкмы? Мондый уйлар белән сөйләшүне күтәрерлекме, юкмы? Башы бушмы, әллә уйлымы? Әнвәр андый тирән уйлы сөйләшүләргә кушыла алмый әле. Дикъкате аның бүтән нәрсәләрдә. Ярасы бик сызлый, шул сызлау уйларга комачау итә. Ләкин Әнвәр тыңларга бик ярата. Әзимовны тыңлавы бик рәхәт аңа. Аның сөйләгәннәрен куәтли алмавына эчтән генә үртәлә, гарьләнә. Үзеңнең буш баш икәнен аңлавы бик авыр бит. Әзимов янында томана булуың бик ачык күренә. Әнвәр үзенең томаналыгын белгертмәс өчен сүзгә кушылмый, бары гаепле елмаеп, ияк каккан булып утыра. Әзимов сөйләгәннәргә ул кушыламы, каршы киләме — моны чамаларга һич мөмкин түгел.

Әнвәр, тәвәккәллеген җыеп, Әзимовның «укы, укы», дип тукып торуыннан да уңайсызланып, бухгалтерлар курсына керде. Укый башлады. Алай ук куркыныч түгел икән ләбаса. Дәрестә сөйләгән нәрсәләрне аңлый кебек ул. Өйгә биргән эшләрне дә аңлап, үтәп куя... Болай булгач, бар нәрсә дә югалып бетмәгән икән әле. Бөтен юллар да ябылып бетмәгән икән. Җан биргәнгә юнь биргән... Әнвәр үзенең шулай дәресләрне аңлый алуына эчтән генә сөенә иде. Эш белән мәшгуль булгач, яра сызлавы да онытылган кебек тоела. Башны, дикъкатьне ниндидер шөгыль белән биләп тотарга кирәк икән. Ул, үзенең русча белү-белмәвен, аңлау-аңламавын сынар өчен, китапханәдән китаплар алып кайтты.

Дәресләр бер кечерәк бүлмәдә үткәрелә. Анда парталар куелган, кара такта бар. Нәкъ мәктәп классы. Егермеләп аяксыз, кулсызлар укый. Укытучы Михаил Аркадьевич, үзе дә инвалид, тумыштан. Казанныкы. Аяклары чалыш үскән, керпе чәчле, елмаеп кына сөйләшә. Мөлаем кеше. Дәресне бик тәфсилләп аңлата. Хуҗалык эше, аны исәпләү-бәяләү, теркәү. Бик катлаулы нәрсә икән. Четерекле.

Михаил Аркадьевич, папирос көйрәтеп алгач, калькуляция турында аңлата башлый. Ул ни сәбәптәндер калькуляцияне бик яратып сөйли иде. Шул хакта сөйләргә сүз сөреше дә туры килеп тора. Калькуляциянең бер мәгънәсе болай: мәсәлән, ашханәгә ит китерәләр, бәрәңге, токмач һәм тагы бик күп нәрсәләр, тәмләткечләр. Ашчы аш пешерә, гуляш йә биточки ясый. Азык-төлек кичтән килә, ә иртәнгә калькулятор-бухгалтер бер тәлинкә ашның күпме бәя торганын менюга язарга тиеш. Икенче тәгамнең дә төгәл бәясе чыгарыла. Бик нечкә эш бу. Ашка бер дәфнә яфрагы салынса, шуның да хакы әлеге бәядә чагылырга тиеш. Яки өстәлгә горчица куела. Аның да бәясе беренче, икенче ашлар бәясенә кушыла. Азык бәяләре төрлечә. Ит кенә дә өч-дүрт төрле бәя белән йөри.

Токмачка он бирелә, ә ипи пешергәндә он кырык процент артым бирә, токмачка салгәнда артым буламы, юкмы?

Бухгалтер исәбе буенча Татьяна Владимировна укыта. Алсурак озынча йөзле, киң маңгайлы, калынрак иренле, бик ягымлы хатын. Ленинградтан эвакуацияләнгән икән. Баланс төрләрен аңлата.

— Төрле типтагы баланслар бар. Менә рус балансы, менә ике системалы итальян балансы, менә американныкы. Бездә колхоз эшендә күбрәк итальян балансы гамәлгә алынды.

— Буржуаз баланс колхозга зыян итмиме соң?— диде бер аяксыз әллә шаярып, әллә чынлап.

— Юк, зыян итми,— дип Татьяна Владимировна шул балансның уңай яклары хакында сөйләргә керешге. Кечкенә колхозлар өчен бу баланс бигрәк тә уңай икән. Ә промышленностьта американныкы кулланыла. Бу катлаулы, шулай да төгәллек өчен шушы система белән эш итү җайлы. Ләкин баланслар тормыш кебек һаман үзгәреп тора. Болар һәммәсе дә цифрларда чагыла. Шуның өчен цифрларны иң күләмле һәм иң матур фикер туплаган сүзләр дип йөртәләр. Бер сүз язмышны хәл иткән кебек, бер бичара хөрти генә цифр да язмышны теге яки бу якка борып җибәрә ала.

— Сүзнең әһәмияте кими төшәменн?— диде тагы кайсыдыр.

— Бәлки шулайдыр. Исәп-хисап заманы җитте.

— Ул доклад сөйләүчеләр нишләр хәзер?

— Докладларына күбрәк цифр тутырырлар.

— Әйе, сүзләр ышандырмый башлады...

Тәнәфес ясап алгач, әллә яралыларның арыган йөзләрен күреп, әллә сүз уңаеннан, Татьяна Владимировна Ленинград турында сөйләп китте. Ул һаман туган шәһәрен телгә алмый үтми иде.

* * *

Турганов бухгалтерлар курсын тәмамлады, тик һаман эшкә урнаша алмый әле. Аның госпитальдән чыгып йөрергә рөхсәте бар. Вакытны әрәм уздырмас өчен, папирос сәүдәсенә керешеп китте. Эше тиз, акчасы да тиз керә. Папиросны базарда шундук алып бетерәләр. Юньле эшкә кайчан урнашып була әле? Эш күп, ләкин Турганов квартиралы эш эзли иде. Бу мәсьәлә бик кыен хәзер. Әзимов аңа киңәш биреп кенә тора, берәр фатирлы хатынга өйлән, ди. Ягъни, йортка кер, дигән сүзе инде. Тургановның бер дә йортка керәсе килми. Алай, ди, хатынга буйсынып яшәргәме? Аяк атлаган саен, ни әйтер икән, дип күзенә карап торыргамы? Һәй, дип, Әзимов аның бу сүзләреннән көлә генә, син бер дә хатынкыз затын белмисең икән, ди. Аның бит синең күзеңә генә карап тора торган әйбәтләре дә була. Хатын-кыз бер яратса үзеңне, ул сине үзенә патша итеп куя. Син теләгәнчә генә яши. Каян табасың аның шундый әйбәт тәрбия алганын? Әнә синең малайларыңа туры килгән хатыннар кебек булса, нишлисең? Мин алай чыдап яши белмим бит...

— Татарлыгыңа барасың, Турганов,— ди Әзимов.— Куй шул кадим фигылеңне! Фатирлы әйбәт хатынны тап та шуңа берек! Болай юкка көчеңне түгеп бетерәсең.

— Әнинең сукырлыгын да әйтмәскәме башта?

— Юк, анысын әйт.

— Әйтсәң, миңа кем генә карар? Үзе аяксыз, әнисе сукыр. Хәзер хатын-кызда исәп көчле.

— Юк, хатын кирәк безнең ише кешегә. Минем хатын кырык дүрттә үлгән. Малайлар өйне сатып, акчасын бүлешкәннәр. Хатыным исән булса, мине алмас идемени ул? Килен янына, билгеле, сыеп булмый...— Әзимов күңелсезләнеп китте.

— Һәркемнең үз балансы шул,— диде Турганов ничектер укымышлы кеше кебек итеп. Әзимов зиһенле, аны тиз аңлады.

— Бер кешенең дебет, кредиты икенче кешенекенә туры килми, төрес әйтәсең.

— Хатын-кыз белән бер баланска кереп китсәң... Амортизацияне бишләтә түләтә инде ул. Ликвид хәленә төшүеңне сизми дә калырсың...

— Әй, Турганов, хатын-кыздан куркасың син, алай ярамый. Әллә кыюсызмы үзең? Андыйлар хатын-кыздан курка.

— Кыюсызлык бар шул, Әзимов абый, бар.

— Әйбәт сыйфат түгел, кешене өлешсез калдыра торган нәрсә ул. Җиңәргә тырыш син аны. Күбрәк кешеләр белән аралаш, вакчыл булма. Вак-төяккә акчаңны жәлләмә. Беләсең, авылда үскән малайлар бер тиеннәрен исәпләүчән була. Алай булма. Аның белән тернәкләнә алмассың. Иптәшсез, дуссыз калырсың. Өйләнсәң дә ул гадәтеңне оныт! Вакчыллык бик начар микроб. Әйбәт мөнәсәбәтне, дуслыкны боза... Затлы әйберне көя тишкәләгән кебек...

Бу Әзимов әллә ниләр белә, ахрысы. Кешеләрне сынап, күзәтеп кенә ята, хәйләкәр төлке кебек. Тургановның да ниндирәк кеше булуын чамалаган булса кирәк. Чөнки каршы бер сүз әйтә алмады. Бераз вакчылрак булуын танырга уңайсызлана сыман. Турганов авыз эченнән нидер мыгырданды да, ашыгыч эше бар шикелле, палатадан чыгып китте. Бу хакта сүз озайтасы килмәгәне беленеп тора иде.

Турганов әйтә: без, ди, кредит бүлегендә инде, ди. Чөнки без җәмгыятькә хәзергесе көндә бер файда китермибез, аңа зыян гына итеп ятабыз, ди. Дебет бүлегенә чыгар өчен безгә күп тырышырга кирәк, эшкә яраклы булырга... Кредит бүлегеннән дебеткә кайту теге дөньядан бу дөньяга кайту кебегрәк ул.

Турганов папирос кәсебен ташлады. Дебеты бик әз, диде. Шикәр белән сату-алу эшенә керешеп китте. Яралыларга көн дә иртән шикәр бирелә. Күп кенә кешеләр өлешләрен саталар. Бер өлеше биш-алты сум. Турганов ак ситсыдан бер капчык текте, аңа элмәк тасма такты. Протез тасмасы мач булды. Иртән врачлар кергәнче палаталардан шикәр өлешләре җыя... Капчыгын тутыра. Врачлар аягы тынгачрак капчыгын асып базарга китә. Ләкин капкадан үткәрмиләр. Госпиталь биек койма белән әйләндереп алынган. Хуҗалык корылмалары артында такта койма биек биегән, ләкин тырмашып менәргә җепсәләре бар. Турганов коймадан чыгу өчен булышырга Әнвәрне алып килә. Ул җепсәгә култык таягын куеп торып, Тургановка өскә үрмәләргә ярдәм итә. Теге коймага менеп атлана, аннары шатыр-шотыр килеп теге якка шуып төшә. Әнвәр шикәр тулы капчыкны койманың теге ягына ыргыта, Турганов җиргә төшермичә тотып ала... Турганов барын да алдан исәпләгән. Көннәр җылы чагында ул шикәр белән базарга икешәр бара иде. Бер ай дигәндә үзенә гади генә булса да чалбар, ботинка юнәтте. Бер көнне сырма да күтәреп кайтты. Хөрти генә бүрек тә алды.

Кыш җитеп суыклар башлангач, беркем чыгып йөри алмый. Турганов йөри. Хәзер шикәр өлешен ул җыеп маташмый, аяксызлар үзләре китереп бирә.

— Ничек соң дебет, кредит?— дип кызыксына кайчак Әзимов.

— Дефицит сизелә, сальдо бар,— дип көлә Турганов.

— Ягъни дебет бар?

— Әмма тир түгәргә туры килә инде.

— Җайлырак бер эш юкмы соң?

— Менә эзлим. Замполит телефоннан бер эш белешкән, иртәгә шунда барып карыйм.

Турганов ике-өч көн кайтмады. Замполит рөхсәте булгач, иркенләргә уйлагандыр. Шикәр өлешләрен сатучылар:

— «Дебет-Кредит» кайда?— дип сорап керәләр. Тургановны хәзер шулай атап йөртәләр иде... Ояларына үтеп кереп, фрицларны «җылы килеш» алып кайта торган разведчик менә нинди хәлгә калды.

Әнвәр укуга бик бирелеп китте. Баланс хикмәтләрен төшенергә каз-

гана иде. Дөнья барышы шушы балансгагы кебек хәлләргә корылган. Кая гына барсаң да шул: керем, чыгым... Кешенең тормыш белән булган мөнәсәбәте дә шундый — дебет, кредит. Тормышка син көчеңне, мускулыңны яки ми эшчәнлегеңне бирсәң генә, ул да сиңа көн күрерлек әйберләр, ягъни исраф ителгән көчеңне кайтарырлык ризык бирә икән.

## 2

Михаил Аркадьевич дәрестә саннан процент табарга өйрәтә. Мисаллары һаман ризык әйберләреннән генә була. Ипи пешерү цехына йөз килограмм он китерелгән. Он кырык процент артым бирә. Күпме икмәк пешерелгән? Яралылар мышный-мышный мәсьәлә чишә. Кайсы бик тиз эшләп ташлый, кайсының мие бик үшән, булдыра алмыйча азаплана. Мәсьәләне чыгаргач, гаҗәпкә калалар: йөз кило оннан йөз кырык кило икмәк чыга икән. Бик күп бит бу, нигә алайса бездә ипи житешми?— диләр. Бәхәскә кереп киткәннәрен тоймый да калалар.

— Корылык булды бит,— ди Михаил Аркадьевич.

— Аның өчен түгел,— дип кайсыдыр белдекләләнә.— Германиягә биргәннәр...

— Ник? Менә әкәмәт!

— Көнчыгыш секторда ач калганнар, нишләтәсең инде аларны?!

— Алсыннар үзләренең немец туганнарыннан! Хәерчеләр күп булыр ул?

— Шөребең бушаган. Бел: кем ипиен ашасаң, шуның җырын җырлыйсың.

— Икмәк биреп, җырлатырга? Их, егетләр!

— Ник шаккаттың? Бушка сыер да мышнамый хәзер. Черчилль әнә нинди сәясәт алып барган: немецлар белән руслар бер-берсен ныграк кырып бетерсеннәр...

Сүз икенче юлга борылды. Хыялга бирелделәр. Тормыш өзегрәк булган саен хыял үткенрәк, хаҗәтлерәк була, ахрысы.

— Коммунизмда ипи мәсьәләсе ничек булыр икән?

— Күпме телисең, шул чаклы,— диде Михаил Аркадьевич.

— Капчык тутырып алырга да булачакмы?

— Рәхим ит, үлчәү булмаячак.

— Үлчәү булмаса, ашамсаклар күбәеп китәр бит?

— Артыгын ашап булмый. Беркемнең дә ике корсагы юк бит.

— Күп ашап, эз эшләүче комагайлар булыр. Коммунизмда хәйләкәрләр күбәеп китмәсме?

— Җаен табарлар, башта коммунизмга житик әле,— диде Михаил Аркадьевич һәм өйгә эш әйтеп яздыра башлады...

Көннәр жылыткач, китүчеләр күбәя башлады. Жылы вакытта кая булса да урнашып калырга кирәк. Маринкин тешләрен куйдырып бетерде. Йөзендә тонык көмеш елмаю иде, теш куючы хатын янына күчте. Үз хатыны янына кайтырга йөрәге житмәде, жилегенә үтәрлек итеп теңкәсенә тигән булган. Китәсе көннәрдә ул, «Крокодил» журналында чыккан бер рәсемне күрсәтеп, көлдереп йөрде. Рәсемдә сырлы-сырлы тешле пычкы сурәте ясалган һәм астына «хатыным портреты» дип язып куелган иде. Самохин да кыш буе протез белән йөрергә өйрәнде, еш кына шәһәргә чыга иде. Ул замполит белән дус, бер-берсенә «фәлән фәләнич» дип кенә дәшәләр. Замполит аңа киемнәр бирдерде. Самохин кайчандыр Казанда «Гуж» артелендә эшләгән, аннары Казанны өнәмичә кайдыр язылып киткән. Хәзер элеккеге танышларын эзли, бәлки бередә төпләнеп булыр диган нияте дә бар иде шикелле. Ләкин шәһәрдән йөзе чытылып кайта иде. Ул бер төпле иптәш тә, дус та таба алмады. Үзбәкләр белән Ташкентка китәргә карар итте. Анда жылы, тормыш жинелрәк, дип әйтәләр. Энварне дә шунда китәргә өндәп маташты. Юлга кәгазь алгач.

мин сиңа хат язармын, килерсең, җылы безнең ише чирле чебеш өчен мөһим нәрсә ул, диде. Ләкин киткәненә инде ике айдан ашып узды, берниндн хат-мазар юк. Чынлыкта Әнвәр хат-хәбәр дә көтми. Ничә кеше мәңге дус булырга антлар биреп, катлы-катлы вәгъдәләр әйтеп китеп барды. Берсе бер ичмаса хат та язып карамады. Әнвәр шунда аңлады: вәгъдәләр, антлар бирүе нинди ансат, ә аларны үтәве нинди авыр. Сүз белән эш икесе ике нәрсә икән шул. Аңа, беркатлы кешегә, бу да бер сабак иде. Бер көн палатада булган бәхәс тә аны уйга төшерде. Дөнья турында тел чәкәләштерәләр иде.

— Ул намуслы, аңа ышанырга була,— диләр кем турындадыр.

— Намуслы кеше, димәк, непрактичный кеше! Непрактичныйга ышаныч бәләкәй инде.

— Булдыклылык өстенрәк алайса?

— Уңганлык, әрсезлек үзеңә файда, намуслылык кешегә файда, дип әйткән бер акыл иясе!

— Нигә, намус белән яшәп булмас дисеңмени?

— Язмыш безне екты, төшерде, кешеләр дә түбәнсетәчәкләр. Ул нәрсә кешенең психологиясендә бар. Күпме генә әхлакый сүзләр сөйләмә, күпме генә өйрәтмә, кеше дигәнең үз психологиясе буенча эшли ул. Адәм баласы үзенә файдалыны гына таный. Файдасызны санга сукмый ул!

Яралыларның пошаманга төшеп, үзара сөйләшүләрен тыңлап яткannан соң, Әнвәр дә кайгылы уйларга чорнала. Бу килеш нишләр ул? Ярты гәүдәсе юк, башы да һаман авыртып кына тора. Ничек яшәргә, ни әмәл табарга? Сиңа беркем дә ярдәм кулы сузмаячак. Әнә Турганов ни әрсез, таш астыннан чыккан кеше, кайчаннан бирле рәтле эш таба алмый. Замполит та аңа эш эзләп әллә кайларга барып беткән. Көн дә телефоннан шалтыратып, белешеп тора. Барыбер юньле эш юк. Дөрес, Турганов хөрти генә булса да бүлмә-почмак бирә торган эш карый. Аңарда әрсезлек тә, тәвәккәллек тә бар. Ә миндә берни дә юк. Элеккеге кыюсызлык, юашлык өстенә бу аяксызлык мине тәмам бетереп ташлады. Мин еш кына үземне тирән бер чокыр төбендә ятам кебек хис итәм. Ничек чыгармын мин бу чокырдан? Болайга барсам да стена, тегеләйгә төртелсәм дә — шул ук мәрхәмәтсез стена! Әллә берни дә уйламаскамы? Ни булса, шул булыр? Юк, мондый принцип белән эш майтару мөмкин түгел. Гомер бит бер генә, бүтән булмаячак ул! Әнә Самохин гел әйтә иде: үзеңне корбан итеп сизәргә ярамый, алай итсәң, чокырдан тырмашып чыга алмыйсың, ә үзеңне тулы кеше итеп тояргa һәм шулай хәрәкәт итәргә! Шунда гына безгә котылу...

Әнвәр бу сүзләрнең асыл мәгънәсен аңлап та бетерми, шулай да күңеле моның бик кирәкле сүзләр икәнен тоя иде.

* * *

Коридордан култык таякларын идәнгә шак-шок бәреп, аяксыз ике яралы бер-берсенә таба килә иде. Йөзгә-йөз очрап аяк кагып исәнләштеләр дә узып киттеләр. Инвалидлар арасында таныш булмаган кеше белән дә шулай исәнләшү бар иде. Ләкин берничә адым киткәч, икесе дә туктап, артларына борылды. Бер-берсенә текәлеп тордылар.

— Фазлыев?— дип дәште өлкәнрәк күренгәне ышанычсызрак тавыш белән. Әнвәр мөлдерәгән күзләрен чекрәйтеп карап тора иде, түшеннән чамалап, Ваһаповны танып алды. Шулай да, икеләнеп калды, элеккеге таза замполитны бер аяксыз көе күрүе сәер, тиз генә ышанырлык түгел иде.

— Иптәш замполит?!— Әнвәр ялгышмады. Шул мәл замполитны соңгы мәртәбә күргәне, аның каршына килеп ярдәм сораганы исенә төште.

Ваһапов, ни әйтергә белмичә, аптыраган төстә торды. бик яшь килеш бәхетсезлеккә дучар булган үз солдатын күрү аңа да авыр тәэсир иткән иде. Ул, юатырга теләгән шикелле, Әнвәрнең иңенә учын куйды һәм сыпыргалап алды.

— Теге вакытта мин кирәкле жиргә чылтыраткан идем,— диде Әнвәрне тизрәк тынычландырырга итеп.— Соңыннан тикшереп белдем. Сөенчалин барысы да тәртиптә, дип әйтте.

— Рәхмәт, иптәш замполит!— диде Әнвәр, күзләрен учы белән корытып алып.

Ваһапов палатасына кереп сөйләшеп утырдылар. Палата бик чиста һәм тыныч иде. Өч-дүрт кенә яралы караватларында китап-газета укып ята. Бер-берсе белән бик итагатьле генә сөйләшәләр. Офицерлар икәне әллә кайдан сизелеп тора. Ваһапов үзенең Әнвәрдән соң булган хезмәт урыннарын әйтеп чыкты. Махсус ротада замполит вазифасында алгы сызыкта булуын, Курляндиядә бер бик каһәрле биеклекне алганда яраланганлыгын сөйләде. Әнвәр дә шул тирәдә, кечкенә бер шәһәр янында яраланган булуын әйтте. Аларның икесен дә алгы сызыктан Митава шәһәрендәге бер үк госпитальгә китергәннәр булып чыкты. Ә Митавадан Әнвәрне бирегә шактый элек озатканнар. Икесе бер үк госпитальдә ятсалар да, күрешү-очрашу мөмкинлеге хакында уйга да китереп булмый. Икесе дә бик авыр хәлдә: аңнарын җуеп, ничектер үлеп китмичә, көч-хәл исләренә килеп ятканнар. Ваһаповта да гангрена булган икән. Гомере кыл өстендә генә калган. Шәфкать туташлары, врачлар бик әйбәт булдылар, юкса беткән идем, дип ниндидер горурлык белән әйтте Ваһапов. Ася исемле сестра мине бик карады, хәлем бик начар вакытта үзенең канын биреп, коткарып калды...

Ася дигән исемне ишеткәч, Әнвәрнең колаклары торды, дикъкате шуңа тупланды. Сүзнең азагын көтте. Баш миенә кайнар елдырымнар каяндыр йөгереп менгәнен, канның шулай таба куылганын тойды.

— Нинди Ася?— дип түземсез төстә сорады Әнвәр һәм нигәдер бите кайнарланып киткәнен сизде. Ул йотылып Ваһапов йөзенә текәлде. Әллә мине караган Ася турында әйтәме, дигән уй килгән иде аңа башта, аннары бүтән бер сестра хакында, ахрысы, дигән шик ымсынуын тыйгандай итте. Әмма Ваһапов Әнвәр белгән шул сестра — Мишина Ася турында сөйли булып чыкты. Әнвәрне бик нык караган, тәрбияләгән, үлемнән коткарган Ася! Алар икесе дә Асяның куллары аша үткән икән. Менә нинди тәңгәллек! Кара син моны! Асяга соклану, аны алиһә итү Ваһаповның бөтен чыраена нур булып калыккан. Әнвәр үзе Асяның ничек каравы турында тыйнак кына сөйләп алды. Ваһаповның әчкерсез шатлануына, Асяны аллалаштыруына шәүлә төшермим дип курыкты. Ләкин эчтән шатланды. Асяның үз-үзен аямавын, риясызлыгын онытмауларының өчен чын күңелдән сөенде. Асяның тырышлыклары, яралыларны терелтергә янып-көеп йөрүләре бушка китмәгән. Шулай булгач, мең шөкер. Чын күңелдән салган хезмәтнең онытылмавы һәм Асяга мең-мең яралылар күңеленнән рәхмәт явып торуы бик зур гаделлек!

Авыр яралыларны карауның барча мәшәкате, кара эше шәфкать туташлары җилкәсенә төшә. Бик четерекле, каһәрле хезмәт бу. Асяга да күпне кичерергә туры килгәндер. Әнвәр күз алдында да кызыкайны түбәнсетә торган хәлләр булды. Бер бәлачел яралы ята иде. Өске теш казнасы, ирене һәм ярты борыны юк. Күзләре күрми. Яшь бизләрен ярчык өзгәләп бетергән. Операция ясап, селәгәй бизләрендәге сыекчаны күзләренә ага торган иттергәннәр. Бу күрә башлады, күзләре нормаль хәлгә килде. Ләкин шуңа бәйләнгән икенче нәрсә: ашаганда авызында селәгәй беткән. Тора-бара булыр, диләр. Организм әле үзенә авыз эчендә селәгәй бизләре эшләргә өлгермәгән. Шунлыктан яралы каты ризыкны ашый алмый, авыз эче кан булып бетә, йотарга мөмкин түгел. Яралы бары сыек аш кына кабул итә иде. Аңа бик майлы шулпа бирәләр. Ә бер көнне моңа кәтлит белән ботка куйганнар. Селәгәй бизләрен

тизрәк үстерү өчен врач аңа шуны язган, бу да кирәк икән. Аш исеннән яралының күз яше бик каты ага башлый. Билгеле инде, селәгәй бизләрен күзгә ялгагач... Моның бик каты ачуы килде. Ул сөйләшә алмый, бар хисләрен кулы, хәрәкәтләре белән белдерә иде. Бу юлы исә, эмаль поднос белән дарулар алып керүче Асяны күрде дә үзен ярсытып торган азыкны тотып аның өстенә ыргытты. Ася мескен бер сүз әйтмәде, бары йөзенә кызыллык йөгерде. Халатын сөрткәләгән итте дә яралы янына килде, гозерен тыңларга кереште. Ул үзен бик уңайсыз сизә иде. Нишлисең, түзәргә туры килә. Шундый түбәнсетүләрне дә күтәрергә мәҗбүр буласың. Мондый хәлләрне йөрәгең белән генә күтәрәсең, дип сөйли иде Ася. Әнвәр ярасы сызлаудан төннәрен йоклый алмый борсалана иде. Ася шул чакларда Әнвәр янына килеп утыра да пышылдап үз башыннан кичкән хәлләрне сөйләп алгалый иде.

Әнвәр, ничектер оялчанлыгын да онытып, Ася турында сораштырды. Барын да беләсе килде. Ул бит һаман Ася хакында уйлап ята иде, йөрәгенә аннан да якын кеше юк. Шундый затны ничек беләсе килмәсен, ди!

— Ася белән юлда уникe көн бергә булдык. Бер-беребезне белеп бетердек...— Ваһапов гадәтенчә бик салмак кына сөйли. Әнвәрнең йөрәге дөп-дөп тибә. Ваһаповка ишетелә күрмәсен... Ася турында болай салкын гына сөйләү кәефен җибәргән кебек итә иде.

— Ә аннары Митавага кайтып киттеме?

— Юк, биредә эшкә калды.

— Ничек?! Ул бу якныкы түгел бит?

— Гаеп миндә,— диде Ваһапов ниндидер эчке горурлык белән елмаеп.— Шул ике атна эчендә без аның белән бер-беребезне сүзсез аңлый башладык...— Ваһаповның бер дә эчке дөньясы беленми торган чыраенда нурлар тагы күбәйде, җетеләнде. Күз кырыендагы җыерчык сызыкларына яктылык тулды.

Әнвәр ни әйтергә белмәде. Әһә, менә ничек икән! Эшләр тирәнгә киткән икән... Бу хәлне баш мие үзенә кабул итеп, әйләндергәләргә кереште. Ләкин миенең көче әз, бу фикерне һич тә сеңдерә алмый азапланды.

Шәфкать туташы кереп, Ваһаповка процедурага барырга кушты. Культясына кайнар парафин ябалар икән. Палатадан бергә чыктылар.

Әнвәр Ася хакында гына уйлады. Бу уй аңа тансык иде. Асяның беркемдә дә булмаган йомшак ягымлылыгы, нурлы мөлаемлелеге, һәр кешегә игелек итәргә генә торуы, һәрчак балкып торган йөзебите, ак көмәч кебек ак куллары... Ярый болары тышкы матурлык булсын, ди. Аның эчке матурлыгын авыр яралылар күбрәк белә. Кешелекле булуына тиңнәр табылыр микән? Күпме яралыларның гомерен саклап калды ул?! Әнә шундый кызга Ваһапов ничегрәк булыр соң? Әнвәр Асяга таза, киң җилкәле, мәһабәт бер офицер юраган иде. Шуның белән бәхетле гомер кичерсен дип эчтән генә теләп, рәхмәтен дога кебек укып яткан иде. Юраганы юш килмәде, әллә шуңа күңеленең бер почмагында Асяны җәлләү хисе калкып, эчен пошырып куйды. Аяксыз инвалид белән көйсезрәк булыр бит. Әнвәр инвалидларның төрлесен күрде. Бик түземсез халык. Дөрес, Ваһапов сабыр кеше анысы. Шулай да бөтен кеше түгел. Асяга авыр булыр бит? Ася, мөгаен, Ваһаповны җәлләгәндер? Үзен тагы корбан иткән ул, бер дә бүтән түгел!? Ася моңа соңыннан үкенмәсме? Бу холкындагы артык риясызлыктандыр инде. Бәлки үзенә әйбәтрәк пар чыкканын көтәргә кирәк булгандыр. Күңел аның ялгышмавын, бик бәхетле булуын тели. Бик өмет итә. Хәер, Ваһапов әйбәт кеше, әйтәсе дә түгел. Хөрмәткә лаек, яратуга да торырлык булырга тиеш (Әзимов әйтә: кайбер ир-ат, ди, яратуга торырлык түгел, чөнки яратырлык дәрәҗәгә барып җитмәгән, имеш. Шулай булса да хатын-кызлар ахмакланып аларны ярата һәм гомерләрен харап итә, ди. Китаптан укып әйтәдер инде, шуңа Әнвәр аның

сүзләрен аңлап та бетерми.) Ася, бәлки, тагы шуны да уйлагандыр. Ваһаповка госпитальдән подполковник дәрәҗәсе биреп чыгаралар. Комсоставта шундый тәртип. Пенсиясе дә әйбәт булачак аның. Кая барса да, подполковник дигән дәрәҗәсе булыр. Дәрәҗә алдан йөри торган нәрсә. Нинди генә шәһәргә барып төшмәсен, аңа квартира тәэмин ителгән. Юк, Ася бик үк алданмаган шикелле. Холык-фигыльләре дә капма-каршы түгел, бер чамадарак. Ваһапов рус телен яхшы белә, яхшы сөйләшә. Монысы да уңай як. Югыйсә, Митавадагы госпитальдә бер рус сөйләгән иде: бер сүз русча белмәүче латыш кызына яшьлеге белән өйләнеп ташлаган. Бик авыр булды, ди. Синең көлеп шаярасың килә, шукланып, көлкеле сүз әйтәсең, ә ул синең күзләреңә карап тик тора. Чөнки теле юк. Башта телсез хатын белән торган кебек яшәдем. Ул телне белә башлаганда яшь чак үткән иде. Шунлыктан өйләнү елларым, бәйрәм заманым бер эзсез узды да китте, ди... Асяның ул яктан начар булмас кебек. Ләкин Ваһапов «элеккеге контузиям» дип сөйләнеп маташты бит? Мәкерле нәрсә ул контузия. Кешене әчтән җимерә икән. Тыштан кеше янып торган битле, таза җилкәле, һич уйламассың, шул бер мизгелдә ава да төшә. Авызыннан күбек килә башлый, аңын югалта. Әнвәр андыйларны күп күрде. Тышкы тазалыкка ышанып җитмичә карый ул. Юк, Ваһапов андый булмас. Күзләре бик җете, очкынлы, эчке контузиясе булган кешенең күзләре бүтәнчәрәк, тонык карый, диләр.

* * *

...Палатага яңа яралы салдылар. Әллә нинди йомык кеше. Култык таяклары белән бик җитез йөри. Беркемгә бер сүз катмый. Йөзгә карамый, күзләрен читкә ала. Бу нинди адәм икән дип Әнвәрнең уйлап алганы бар иде. Бер көнне шуның белән яра бәйләтүдә бергә туры килде. Шәфкать туташы Лениза иң элек аның культясын чисте. Врач Луиза Георгиевна пинцетына спиртлы мамык алып яраны юарга тора иде, ярасын күргәч, коты алынгандай булды, матур күзләре зурайды, иреннәре кысылды.

— Саянов, тагы хатыннар янына йөргәнсең?! Соң күпме әйтергә мөмкин, ә? Сөйләшкән идек бит!

— Юк, Луиза Георгиевна, сез нәрсә!

— Мәнә бит яраң әйтеп тора. Ялганлама! — Луиза Георгиевна культя ярасын өйрәнә иде, томпонын тигерергә ашыкмый.— Болай яраң төзәлмәячәк! Әнә тагын начарланган. Тыела алмыйсыңмыни соң?!

— Булмаганны, юк, Луиза Георгиевна!

— Ичмаса ялганлама, Саянов. Ачуны китермә. Мин ир-атны белмимме? Аһ, бу хатыннарны әйтер идем, кешенең бөтен сутын суырып бетерәләр! Мондый яраңны бүтән күрмим, аңлыйсыңмы? — Ул яраны юа, эшкәртә башлады.

— Тиздән китәм, Луиза Георгиевна...

— Һе, киттең ди бу шешенке яра белән! Ходабәндә, нишләп сине хатыннар шул чаклы ярата, ә? Эштән чыгаралар бит үзеңне!

— Төзәлә ул...

— Хатыннар янына юлыңны өзмичә, төзәлми, Саянов! Башыңны ахмаклыкка салма! Соңыннан начар булыр.

— Чын мәнә, Луиза Георгиевна, бер гөнаһым юк,— диде Саянов, йөзендә бер тамырын да селкетмичә.

— Саянов, бүгеннән мин сине чыгып йөрүдән тыям! Яхшылык белән килешик! Начарга җибәрмик! Ачуга китсә, сине аңлы рәвештә симуляция эшли дип караячаклар. Моның ни белән бетәсен үзең чамалыйсыңдыр? Сөйләштекме? Яхшылык беләнме, Саянов?

— Яхшылык белән, Луиза Георгиевна...

— Димәк, яратуларыңны онытып торасың. Өч айга! Бар!

Луиза аның культясына бинт урап бетергән иде инде. Саянов авыр гына күрсенде, врачтан карашын читкә алды. Йөзе һич тә үзгәрмәгән, әйтерсең, аның белән катгый сөйләшү дә, аны оялту да, битәрләү дә булмаган шикелле иде. Ай-һай калын тиреле, берни белән дә «тишеп» булмый торган кеше икән, дип уйлады Әнвәр. Луиза инде аның бинтларын сүтә башлады...

* * *

Әнвәр офицерлар палатасына, Ваһапов янына кереп утыргалый. Дәрәҗәле кешеләр, сөйләшүләре дә дәрәҗәлерәк, югарырак. Ваһапов белән янәшә караватта — капитан, ул үзен бик иркен тота, сискәндерә торган сүзләр дә әйтә иде.

— Танклар белән сыттырып Ламаншка хәтле барырга кирәк иде! — дип кызгану белгертә. Берлинда яраланган, сугыш беткәч, Гитлерюнг каршы як урамнан аткан. Термитлы пуля белән. Гангренаны туктатыр өчен аягын кискәннәр. Үзе Казанныкы икән. Бирегә самолет белән кайтарганнар.

— Юк, ярамый,— дип аңа каршы төшәләр.— Сталин белә ул, зирәк баш! Алай итсәң, атомны безгә ташларлар иде.

— Кая! Сталиннан алар куркып торалар. Ташлый алмыйлар! Сталин булганда... Ә хәзер ничек инде — ике Германия ике дәүләт буламы? Бу бит тагы дары мичкәсе инде...

— Сталин җаен табар. Ул трубкасы белән бер генә ым кага... Атом аларда, билгеле, ләкин бездә дә бардыр ул. Сталин аны сер итеп кенә тотадыр...

— Безнең танклар Ламаншка чыгып у-у-ух, ә! Черчильнең асты юешләнер иде, мөгаен.

— Атом ул бик хәтәр нәрсә икән. Хәтәрлеге шунда: тирә-юньне кыздырып шартлый һәм һавадагы атомнарны да шартлата икән. Күз алдыңа китер, бөтен һава коточкыч рәвештә шартлый, ди. Бөтен нәрсә җимерелә, тере җан иясе минут эчендә көлгә әйләнә дә кала, ди. Менә ничек. Атом хәтәр нәрсә.

— Сталин атомнан курыкмаган, союзникларның ышанычын югалтудан уңайсызланган. Ышаныч зур нәрсә.

— Сталин белә, билгеле.

— Берлинны дүрт зонага бүләләр,— диде капитан.

— Берлинны безнең гаскәрләр генә алды. Күпме кан коеп! Нигә аны союзникларга бирергә инде?

— Потсдамда шулай хәл иткәннәр, ди. Сталин белмичә эшләмәс. Башкача чара булмагандыр.

— Шулай да анда безнең генә кан коелды бит!

— Рус характеры, киң күңелле. Беркатлы...

— Беркатлылык караклыктан яман диләр...

— Сталин барын да алдан исәпләп эшли, аны алдый алмыйсың...

Тынып калдылар. Тирәнгә китеп булмый. Моны барысы да эчтән сизә һәм белә иде.

— Ул нигәдер үзенә Иосиф Виссарионович дип дәшкәнне яратмый икән, иптәш Сталин дигәнне генә өни икән. Һәр сүздә үзенең корыч икәнен искәртү өчен микән?

Капитанның бу фикерен ишетмәмешкә салыштылар. Ул артык күп белә иде. Кайсы, урыныннан кузгалып, палатадан чыга башлады. Ваһаповта да ишетмәгән кеше чырае иде. Ул Әнвәргә үзләренең элекке булган хәлләрен сөйләргә тотынды, Фира Касыймовнаны телгә алды. Теге вакыттан бирле элемтәне өзмәдек, хәбәрләшеп тордык, диде. Фира Касыймовнаның бу сугышта күргәннәре — сөйләсәң, кеше ышанмас. Адәм баласы чыдый икән, исән китәр. Броня туза, җимерелә, ә кеше чыдый, яши. Гаҗәп!

— Ә үзе бер дә үзгәрмәгән.

— Син аны күрдеңмени? — Ваһаповның соры күзләрендә, күз кырые җыерчыкларында гаҗәпсенү иде. Әнвәр Фира Касыймовнаны изоляторда ятканда күрүен, анда еш кереп йөрүен сөйләп бирде.

— Мина карап-карап ала иде, әмма танымады,— диде.

— Шул хәтле хәсрәт кичерүдән туган анаң да онытылыр,— диде Ваһапов.

— Тавил исемле егет операциядән соң начарланган абыйсын саклый иде. Абыйсы үлде. Фира Касыймовнаның ерак туганы булган, имеш.

— Ә-ә,— дип сузды Ваһапов нәрсәнеңдер серенә хәзер генә төшенгәндәй.— Шул кеше белән яши ул хәзер...

— Бик якын булып сөйләшәләр иде, җирле.— Әнвәрнең Ася турында нәрсәләрдер беләсе килә, ләкин сорарга кыймый. Ася хәзер әнә кияле кеше, шуңа уңайсызлана. Офицерларның эш әйбәт, алар аяксыз булсалар да үзләренә теләсә кемне карата алалар. Йолдызлар һаман йолдыз булып кала...

Ваһапов тумбочкасыннан хатлар алды. Ул часть белән элемтәне өзмәгән икән. Хатлар алып тора. Аңа Кытай җиреннән язалар икән. Курляндиядә чакта частьне көнчыгышка җибәрәселәр дип бик еш сөйләнәләр иде. Моңа зур өмет баглыйлар иде. Менә шушы һөҗүмдә генә булып чыгабыз да, менә шушы фриц төркемен әзрәк кенә чигендерәбез дә, аннары... Моны үлемнән котылып тору, исән калу өмете белән куерталар иде. Бу тәмугтан ычкына алсак бер... Ләкин шундый ышаныч белән янган күпләр ул өметләренә ирешмәделәр. Бруствердан дошман траншеяларына хәтле ара барып җитеп булмаслык дәрәҗәдә ерак иде. Бу ара кылдан нечкә, кылычтан үткен сират күпере иде. Күперне бик әзләр генә үтеп чыга алды. Сугышта өмет белән гамәл арасы бик озын. Кем башта ук төшеп кала, кем уртада, кем соңгы адымнарда. Шуларның төшеп калуы хисабына бәхетле берәү, барча үлемнәр аша, өметенә барып җитә.

— Японнарның фанатиклары бар бит. Шулар бик каты каршылык күрсәтеп маташкан,— диде Ваһапов.— Патша белән солдат шундый килешү төзи икән: кирәк чакта солдат дошман танкысына гранат белән ташлана һәм шунда бетә... Патша исә килешү буенча тегенең гаиләсенә яшәү бәһасен түли. Үлемгә баручы очучылары күп булган японның. Самурайлар...

— Юк, немец чаклы әшәке бүтән булмас...— диде Әнвәр. «немец» сүзен әйткәндә аның, үзе дә сизмәстән, теле кысыла һәм йодрыгы йомарлана иде.

— Фриц мәкерле булды, әйтәсе дә түгел. Тик барыбер бетте! Бүтән баш калкыта алмас ул. Бу соңгы сугыш булгандыр. Дөньяның ресурслары бетеп бара.— Ваһапов ике учы белән колагын томалады, күзләре дә эчендә нидер авыртудан йомылып торды.

— Баш чыңлый,— диде ул, учларын алып.— Калайга суккандай, башта чың тарала... Операция кирәк, диләр. Контузиядә кан тамырларына зыян килгән. Нәзберек операция таләп итела. Ася операциягә бик каршы. Безнең әле бәхәс бара. Фира Касыймовна аны яклый. Мигә бер кыл гына тиеп китсә дә, бик хәтәр була икән. Шәхес бөтенләй икенчеләнеп калуы мөмкин...

— Медиклар белмичә әйтмәсләр, иптәш майор...— Әнвәр Ваһапов янында ниндидер горурлык тоя. Шулай булмый ни, кемгә тия болай фронттагы замполитыңны очрату һәм шушы килеш булса да аның белән үткәннәрне искә төшереп утыру. Ул икесе дә белгән кайбер таныш сугышчы, командирларны сорашып чыкты. Күбесе шул каһәр Курляндиядән ары китә алмаган... Әнвәр февраль азагында яраланган иде, шуннан соң аяусыз каты сугышлар булган. Немецлар алгы сызыкны турылар өчен ике-өч тапкыр бер йодрык булып төйнәлеп һөҗүм башла-

ганнар. Самоходкалары ыжгырып килгән. Ун көн буе тоташ дәвам иткән сугышта гаскәр бик нык өтелеп беткән. Шуннан соң кайбер полкларга алгы сызыктан күчәргә һәм поездларга төяләргә боерык килгән... Ләкин күпләр якты өметләре белән бергә Курляндиядә мәңгегә ятып калган.

Командирлар аяксыз-кулсыз калса да, һаман командирларча. Аерым чыныгу алган кешеләр. Борын салындыру ише нәрсә бөтенләй сизелми. Һәрберсенең тумбочкасында гәзит-журнал өелеп ята. Элек укырга өлгермәгәнне хәзер куып баралар. Бер дә бирешәселәре килми. Рухи нык булу зур нәрсә шул. Болар нинди очракта да җебеп төшә торган түгел. Боларда үзәк нык, иман нык! Ничек алар кебек булырга дип кызыга Әнвәр. Әллә күп укырга кирәкме? Акыл тупларга? Укып кына акыл күбәя микән соң? Әзимов әйтә, акыл күп кирәк түгел, булдыклылык, эшлеклелек кирәк, ди. Бирeдә шундыйлар.

Әнвәр замполитыннан киңәш сорый: нишләргә, кая барырга аңа? Укырга кирәк, ди Ваһапов. Мин курсларны бетер дә тагы укырга кер. Урта мәктәпне тәмамла. Аннан күзең ачылыр, ары нишләргә икәнен тормыш үзе күрсәтер. Мин дә Ленинградтагы партшколага керергә ниятлим. Ася нәрсә әйтер тагы. Ул Митава диебрәк сөйләнә.

— Мин дә шунда китим микән әллә? — Әнвәр Латвияне бик яраткан иде, үзе булган җирләрне хәзер дә сагынып искә төшерә. Әллә анда күп газаплар кичергәнгә, туфракка каны акканга, ул җирләр якын аңа. Туган ягы кебек. Өтелгән килеш үз авылына кайтасы да килми. Ничектер уңайсыз. Авылдашларыңның өметен акламагансың кебек тоела. Авылга батыр булып кына кайту яхшы. Җиңел. Юкса, жәлләү китә, күзләрдән суган суы чыгару була. Тере килеш кызгану уята торган бичарага әйләнәсең. Авыр бу...

— Укы, уку үзе юл ача ул! — диде Ваһапов нык итеп.

Палатага Фира Касыймовна килеп керде.

— Рәүф, хәлең ничек? — Русча гына сөйләшәләр. Әнвәр үзен артык санап бөрешеп калды.

— Зарарсыз,— диде Ваһапов. Фира Касыймовнаның матурлыгы бөтен гәүдәсенә таралган. Куллары, тулы нәфис гәүдәсе дә ниндидер ягымлылык бөркеп тора. Тавышы да ничектер күңелгә ятышлы иде.

— Ася төнге сменага калам дип чылтыратты.

— Алай икән... Алайса...— Ваһаповның сүзе өзелде. Бераздан ялганды: — Рәхмәт!

— Протезың иплеме? — Фира Касыймовна караватъ башында миномет көпшәсе кебек торган агач аякка ымлады.

— Әйбәт шикелле. Өченче көн ике сәгать йөрдем...— Ваһапов кулы белән протезына кагылып алды. Аннары Әнвәрне күрсәтеп әйтте: — Менә Алексейда телефончы булып йөргән егет.

Фира Касыймовнаның озын керфекләре леперләде, ул Әнвәргә төбәлгән иде. Әнвәр уңайсызланып кызарды. Хатын исә аны һаман хәтеренә төшерә алмады. Алексей исеме уйланырга, игътибарлы булырга мәҗбүр итә иде кебек.

— Кайсы вакытта?

— Шул син анда булган чакта. Ул сине яхшы белә...— Ваһапов нигәдер аңлатыбрак әйтми. Фира Касыймовнаның йөзендә һаман таный алмау иде.

— Шулаймы? Ничектер хәтерли алмыйм...— Ул бер кулын иреннәренә китерде, эчтән уен йөртә иде.— Юк! Аның үлгәнен күрмәдеңме?

Әнвәр сүзнең болай борыласын көтмәгән иде, хәтерен тиз-тиз эшләтте.

— Күрдем,— диде ул әкрен генә.— Комбат блиндаждан тамбурга чыккан иде, «Элемтә өзелде!» — дип миңа кулын изәде. Берничә адым атладым гына, шунда ординарецның «Комбат! Комбат!»— дип ачы итеп кычкыруы туктатты. Өч-дүрт метрда гына снаряд шартлаган иде...

Әнвәр үзен танымаганга кимсенмәде. Ул кешеләрне бераз белә башлаган иде инде. Кайберәүләрнең хәтере әйбәт, кайберәүләрнең — начар. Анныры кайбер кеше таныса да танымый, күрсә дә күрми. Дөнья бу! Белсә дә белми, аңласа да аңламый... Ләкин Фира Касыймовна андый түгел. Ул Алексей хакында тирәнгә керергә курыкты, тагы берәр деталь ишетеп йөрәгем бозылыр, дип тизрәк чыгып китте.

* * *

Турганов, кыш буе госпитальдә шикәр җыеп, аны шәһәрдә сатып йөрде. Квартирлы эш эзләде. Юк та юк. Шулай да бер көнне ул сөенечле чырай белән кайтты. Авылдашын очраткан икән. Ул исә квартир ягын җайларга ышандырган. Иң элек үзенә пропискага яздырырга булган. Үзе «Кызыл Шәрык»та эшли һәм шул завод ишегалдына салынган баракта яши икән.

Ләкин прописка ансат кына булмады. Тургановка күп йөрергә туры килде. Райсобес юлын да байтак таптады. Алардан кәгазь алды. Бар төштә дә кәгазь генә кирәк иде. Кәгазьсез син бер тиен дә тормыйсың. Милиция бүлегенә госпиталь замполиты белән бардылар. Эш уңай хәл ителде. Прописка булгач, Тургановны авылдашы «Кызыл Шәрык»ка эшкә урнаштырды. Башта өйрәнчекләр эшли торган цехка шешә санап кертә һәм, сыра тутырылгач, санап кире кабул итеп ала. Әмма шунда тагы бер мөһим тоткарлык туды. Авылдашының бүлмәсе кечкенә, анда Тургановка урын юк икән. Бүлмәдә бер карават та бер өстәл, бүтән нәрсә сыймый. Хуҗалар балаларын караватка салалар, үзләре идәндә... Турганов тагы замполитка барды. Ярый әле ул, игелекле, миңа тагы бер йолдыз өстәлерме, юкмы дип калтыранып тормый иде. Тургановка госпитальдә яшәп эшкә йөрергә рөхсәт итте. Ризыктан да төшермәде. Шулай да палатадан күчәргә кирәк булды. Госпиталь йортының ярымподвал бер бүлмәсендә яралыларны итек тегәргә өйрәтү остаханәсе бар иде. Ул буш, бер курс тәмамланган, икенчесе әле җыелмаган. Турганов шунда торып эшкә йөри башлады. Ризыкны тумбочкасына кертеп куялар. Әнвәр кич белән аның янына төшкәли. Турганов кайчак бер шешә сыра кыстырып кайта. Үзем алмадым, бирделәр, ди. Башкаларның алганын күрмәсен дип шулай эшлиләр икән. Күз йомдыру өчен. Сыраны стаканнарга салып, әкрен генә чөмерәләр, икесенең дә иреннәренә «ак мыек» — сыра күбеге ябыша. Сөйләшәләр, хыял итәләр. Кешенең мөмкинлекләре никадәр аз булса, ул шул чаклы хыялга бай була. Боларның да сыра пары белән хыяллары уйнаклый, оча. Тургановның карары нык: пар белән җылытыла торган бүлмә булса гына алачак. Бүтәнгә риза түгел. Ничек ул утын кисеп, ташып йөрсен? Ул моны Әнвәргә дә акыл булсын дип сөйли иде. Сыра заводының торак ягы бик хөрти икән, өмет юк, ди. Шулай да Тургановның гаризасын алып калганнар.

Авылдашы аны һаман өметләндерә иде. Имеш, бараклан бер-ике гаилә яңа салынган йортка күчә. Ул йортлар Павлюхинда. Әсир немецләр төзегән. Алар хәзер дә шунда эшлиләр. Әнвәр култык таягы белән йөрергә өйрәнгәч, Ботан бакчасына бер барганда, әчкәрәк кереп китеп, аларны карап торган иде. Барысы да таза-көр кыяфәттә. Димәк, ярыйсы ашаталар. Киемнәре дә әйбәт, ямаулы мундирлысы бер дә юк. Үзләренең зәңгәрсу киемнәре. Ләкин бик әкрен кыймылдыйлар. Озак кына итеп кирпечкә үреләләр, аны озак кына итеп алалар. Бер дә ватылмыйлар. Тагы шунысы гаҗәп, эшли торган җирләре тәбәнәк кенә койма белән әйләндереп алынган. Бернинди чәнечкеле тимерчыбык юк. Боларга үзләрендәге лагерьларны күрсәтеп карыйсы иде. Әнвәргә Даугавадагы немец лагерен карарга туры килде. Кабахәтләр әсирләрне, мунчага керәсез, дип чишендереп, бер герметик бүлмәгә туплыйлар һәм өстәге тишектән һавада кислородны бетерә торган порошок сибәләр

икән. Егерме минут эчендә бүлмә һавасындагы кислород бетә, кешеләрдә агония башлана. Тәмугтагы үлем газабын противогаз кигән немец кечкенә тәрәзәдән күзәтеп тора. Бер сәгатьтән бер партия әсир гәүдәсе мичтә яндырырга әзер була... Шуны күрсәтергә иде боларга. Әмма Турганов күңелләнеп кайткан.

— Кичә теге баракларны карап торучы комендантны абый белән икәү ресторанга алып бардык,— дип сөйли.— Майламыйча таба купмый дигәнне беләсеңме? Ә кубарырга кирәк. Сыйлау шул инде. Берикене салгач, абый сүз кушты. Күптәнге белгән кешесе. Бушыйсы бүлмә хакында кылын тартып карый. Теге әйтә: «Завком бүлмәне конторда эшләүчегә бирергә дип карар итте», ди. «Нинди кеше соң ул? Частныйдан күчәме, әллә квартирын яхшырту өчен генәме?» Бу кадәресен комендант тәгәл генә белми икән. Ярар. Тагы әзрәк кайнарлана төшкәч, абый мине күрсәтеп: «Менә энекәш өчен шул бүлмәне кулга төшереп булмас микән?» дип чынын ярып салды комендантка. Теге көлеп җибәрде, шаярталар, дип уйлады. Абый шаярмавын белгертеп, кул артын буш итмәбез, дип өстәде. Комендантның йөзендәге сызыклар тигезләнде, ул тынып башын эшләтә башлады. Аннары өметле елмаеп, ым какты. Абый аңа үзләренең планын сөйли башлады. «Күченүче бүлмәдән әйберләрен алып чыгып бетергәндә ике-өч инвалид култык таяклары белән шалтыр-шолтыр килеп бүлмәгә килеп керерләр. Шалтыр-шолтыр идәнгә аварлар һәм кузгалмаслар. Аларны җилкәләп чыгарырга беркемнең дә кулы бармас. Ә син, комендант, белмәмешкә салышасың. Изге миссиян шул гына, ә?..» Комендант тагы бераз эндәшми генә утырды. Үзе дә инвалид. Бер кулы иңбашына таккан таяк кебек асылынып тора. Бармаклары җәнлек тырнаклары кебек, кәкрәеп каткан. Кулының тиресе, йомырка кабыгы кебек, кубып тора. Кан йөрмәгәннән шулай икән. Күзләрен, мәче кебек, калын кашлары астына яшереп утыра. Менә кашлар өскә күтәрелде, яшькелт күзләре елтырап китте. «Ярар, сезнеңчә булсын, күрмәмен», дип куйды. Нишләптер бик җиңел ризалашты. Абый бераз икеләнеп калып әйтте: «Син практик кеше буларак әйт, бу эш өметлеме, әллә өметсезме?» «Әйтә алмыйм, минем практикада мондый очрак булганы булмады,— диде комендант.— Дәгъвачылар, милиция алып килер, миңа чыгарырга кушарлар». Абый: «Ә син нәрсә эшләрсең?»— диде. Комендант: «Яралылар белән сугыша алмыйм, теләсәгез үзегез җилкәләп карагыз!» диярмен диде. Абый: «Күченүче нинди ирәк адәм?»— диде. Комендант: «Якыннан белмим, каядыр бер арадаш идарәдә эшли кебек. Һәрчак чиста киенгән, галстуктан, тыштан болай культурный күренә, сәлам бирә, сәламне ала, ләкин эче ничектер», диде.

— Кешенең эче, тышы бер түгел,— диде Әнвәр балаларчарак.

— Кыскасы, безнең лейтенант әйтмешли, доннер-ваттер, ягъни яшен һәм күкрәү булырга тора,— дип Турганов Әнвәрнең җилкәсенә учын куйды: — Син беренче номер әзерлек белән тор. Сигнал булуга, доннер-ваттер.

Әнвәр фатир мәсьәләсенең бик хәтәр булуын аңлады һәм пошаманга төште. Шәһәрдә калып булмас микәнни? Бу башны кая гына куярга соң инде? Тургановка, ичмаса, әнә авылдашы ярдәм итә, ә минем бер этем дә юк...

Көн җылы иде. Быел карлар да бик тиз эреп бетте. Трамвайда «тагын яздан ук кояш кыздыра, ходаем, нәрсә булыр инде», дип хатын-кызлар кайгырыша. Әмма Турганов берни ишетми, берни күрми бара иде. Әнвәр аңа сүз катарга базмый. Ул эчке уйларына чумган, йөзе дәһшәтле, кашы-күзе тартылган. Яңакларына эчтән дулкынлану кызыллыклары типкән.

Завод ишегалдына керделәр. Склад платформасы янына олаулар килеп туктаган иде. Алдагы таза, шәп атлы арбага платформадан сыра тутырылган зур агач мичкәләрне тәгәрәтеп китерәләр дә өч-дүрт кеше

«ай-һай» дип бергә әйтеп, күтәреп салалар иде. Әнвәр белән Турганов арырак үттеләр. Кабан буендагы баракка таба титакладылар. Шунда, диде Турганов ияге белән ымлап. Бер-ике күтәрмә баскычтан менеп, коридорга килеп керделәр. Коридор озын һәм ярым караңгы иде. Һәр ишек төбендә әрҗә, шуның өстенә вак-төяк әйберләр өйгәннәр. Ничектер бер кеше дә күренми, бала-чага да чыр-чу килми. Тышта җылы, шунда уйныйлардыр. Бераз баргач, әллә каян гына озын буйлы бер кеше каршыга килеп чыкты. Турганов белән сүзсез генә күрештеләр, теге ялт китеп тә барды. Шулай да артына борылып кулы белән изәде, үзе белән тагы нәрсәдер әйтте. Турганов аңлады, күз карашлары яктырып китте:

— Комендант бу,— диде шыпырт кына.— Күченәләр, монда калгыныпйөрмәскә кушты...

Култык таяклары белән ишек төбенә куелган әрҗәләргә бәреләбәреләчыктылар. Барак артына аулаккарак үтеп, пычкы чүбе тутырып такта белән тышлаган нигезгә утырдылар. Ләкин Тургановның йөрәге урынында түгел иде, тик кенә тора алмый ул, түземлеге төкәнә. Аңа нәрсә беләндер бу киеренкелекне тутырып торырга кирәк иде. Ул ишегалды аша эшләгән җиренә кереп китте.

— Цехтагы тәрәзәдән күзәтеп торырмын,— диде. Әнвәр көндәм иде, шунда гына көтеп торырга булды. Ишек төбенә олаулар килеп туктаганы аңа ишетелде, ләкин ул поскан җиреннән башын сузып та карамады. Эшне тиз тотарлар, Күченүченең әйберләре күп булмаска тиеш, чөнки бүлмәсе тугыз квадрат метр гына икән... Менә әйберкара арбаларга төялеп бетте, күрәсең, олаучыларның атларын кузгатыр өчен чөңгерүләре ишетелде... Шулчак барак артына Турганов килеп житте. Чынлап та сагалап кына торган икән. Ул Әнвәргә башы белән генә ымлады. Алар шыпырт булырга тырышып, сак кына хәрәкәт иттеләр. Менә ул изге ишек. Турганов кесәсеннән ачкыч чыгарды, комендант аны тегендә биргән булган икән. Ишекне ачканда Тургановның чырае зур батырлык эшләгән кеше йөзе кебек канәгатьлек, эрелек белән тулган иде. Кергәч, ачкычын алып, тиз-тиз генә ишекне эчтән бикләп куйды. Сулышы капкан икән, Турганов күкрәген тотып, иркенләп уфылдады, эчтән һавасын чыгарды. Башын як-якка чайкады. Әнвәр бүлмәгә соклана иде. Җыйнак кына, бер тәрәзәсе бар, тәрәзә астында сырлысырлы батарея тезелгән.

— Доннер-ваттер! — диде Турганов, сырмасын салып идәнгә атты да шуның өстенә ауды. Кесәләреннән ике шешә тартып чыгарды. Әнвәр дә аның янына җайланды. Сыраны шешә авызыннан гына йоткалый башладылар.

— Менә күрдеңме? — дип Турганов кыяфәтенә җиңгәнлек, укганлык билгеләре чыгарды.— Үткен егетләр шулай итә. Мин исән чакта өйрәнеп кал! — Ул шаярып әйтми иде. Әнвәр елмайды, мактарга сүз таба алмады. Нәрсәгәдер ышанып җитми иде әле. Шулай бик ансат бүлмә алып була микәнни дип эчтән аптырый иде. Тик иптәшенә белгертми. Турганов инде хуҗаларча тавыш белән сөйләшә:

— Иртәгә Сорочидан бер карават, өстәл, урындык алып кайтам. Керосинка сабын кибетендә бар бугай... Доннер-ваттер, тормыш шулай башлана, диләрме? — Тугановның кәефе бик шәп иде, каядыр күккә менеп киткәндәй. Сүзләрен дә аңлап бетереп булмый башлады. Бу ансатлык аны һич шөбһәләми кебек иде.

— Күчүче күренмәде, ахры? — дип Әнвәр эшнең серенә үтеп кермәкче булды. Комендант белән шухыр-мухыр китергәннәрдер дигән уй аны кымырҗыта иде.

— Күчүче-печүче без, бетте! Бусагадан бер эт тә керә алмаячак! Сталинградта кан койганмы — койган. Гомерне Сталин өчен биргәнме — биргән!

— Ярый ла аңласалар, хисаплашсалар?

— Упшым, үзеңне куя белергә кирәк! Кәлҗемә булмаска!

— Эх, миңа да шундый бер почмак? — Әнвәр эчендәге яшерен теләген чыгарды.

— Минем исәнлекне телә, гөмбә! Сиңа тагы да шәбрәкне табарбыз! — Турганов күптән шушы җиңүле мизгелне көткән, шуңа хәзер кинәнә дә кинәнә. Шуны җаны тансыклаган. «Күрдегезме, менә мин кем?»— дип үзен күрсәтәсе килеп йөдәгән кебек иде.

— Комендант нишләп күренми? — диде Әнвәр, Тургановның хәйләсен ачарга теләп. Ләкин теге һаман югарыдан сөйләште, җиргә төшмәде.

— Үзең яшә, бүтәннәргә дә яшәргә ирек бир, диләр. Комендант эшне белә. Тешенә «суккан»ны онытмый.— Турганов тамак төбенә бармаклары белән чирткәләп алды. Бу халыкара ым һәркемгә аңлашыла иде.

— Күп түктеңме?

— Дүртне бирмичә бишне алып булмый, диләр! Өйрән! Чутың бармы соң?

— Кая! Җайлы эш булсын иде?

— Муен булгач, камыт табылыр. Миндә яшәп торырсың. Ике тәкә сөзешмәбез. Кухняга су кергән, паровой...

— Пропискага язарлармы?

— Бу ведомственный. Ну сәмән булса, һи-и! — Турганов бармакларын бер-берсенә ышкып, акча санаган кебек итеп торды.

— Ул нәрсә бездән ерак йөри шул...

— Шундый бул, акча үзе сине тапсын, гөмбә! — Тургановның бу бүлмәне ачып кергәч кинәт үзгәрүенең хикмәтен сизәргә тырышып, Әнвәр аңа карап-карап ала иде. Юк, тыштан артык берни беленми. Тик аның күзләре генә ныграк очкынлана. Шешә тоткан бармаклары дерелдәгәне күзгә чалынып калды.

Кәефле генә сөйләшеп ятканда ишекне тыштан бик каты тарттылар, каты-каты суккаладылар. Болар шым булып торды. Аннары нәрсәдер сүгенә-сүгенә китеп бардылар. Турганов белән Әнвәр, бер-берсенә карап, мәгънәле генә ымлаштылар. Янәсе, күрдеңме, эшләр башлана хәзер. Ләкин бүтән килүче, ишек шакучы да булмады. Кич булып килә иде инде. Алар шулай озак яттылар. Караңгы төшеп, утлар алгач, бераз тынычланган кебек булдылар. Турганов лампочканы кабызды.

— Бәлки ут яндырмаскадыр? — диде Әнвәр сагаеп.

— Куян булдың чисти.— Турганов эре генә, хуҗаларча әйтте. Ул бүлмәне җентекләп караштырды, кай төшкә нәрсә урнаштырасын планлаштыра иде шикелле. Аның хыяллары канатланып оча. Йөзендә нур катламы. Кыяфәтендә яшәргә омтылыш, үз-үзеннән канәгатьлек иде. «Комендант белән эшне пешергән икән бу»,— дип уйлады Әнвәр һәм тәмам ышанып, тынычланды. Турганов, җалт кенә кузгалып, капкаларга берәр нәрсә алып керим, дип чыгып китте. Бүлмәне тыштан бикләргә дә онытмады. Әнвәр идәнгә сузылган көе ничектер изрәде. Киеренкелек аны шактый арыткан иде.

Ишек ачылган тавышка ул күзләрен ачты. Ишектән таза гына бер хатын һәм аның артыннан алты-җиде яшьлек малай кереп киләләр иде. Малайның иңендә карага буялган агач автомат иде, ул Әнвәр янына йөгереп килде дә:

— Һенде һоһ! — дип кычкырып җибәрде. Әнвәр аптырады да калды. Нәрсә бу? Әллә күзенә күренәме? Малай тагы аның йөзенә үк автоматын терәп: «Һенде һоһ!»— дип кабатлый иде. Нинди уен бу? Кем шулай шаярта? Ниһаять, ул торып басты һәм хатынга төбәлде.

— Гражданка, сез нишләп кеше квартирына керәсез? — диде көчкә генә.

— Син үзең нишләп монда? Әллә күчеп киткәннең берәр кешесеме син? — Хатын аңа сыный карап тора, үзе бик тыныч. Алып килгән

әйберләрен чишеп алгалый иде.

— Бүлмәне безгә бирделәр, госпитальдә ятучы инвалид Тургановка, ягъни минем иптәшкә. Ул хәзер кайтыр...

— Ничек бирсеннәр? Ордер бит минем кулда. Ә сезнең кәгазегез кая?

— Хәзер ул комендантны алып килә, чыгып торыгыз! — диде Әнвәр каты гына һәм култык таяклары белән хатынга таба атлады. Малай аңа аркылы төшеп, автоматын аңа төбәп: «Руки! Руки!»— дип кычкыра. Малай үз уеныннан аерыла алмый иде.

— Син үзең чык! Кәгазең кая?! — дип хатын нәрсәдер сизенгән кебек тавышын күтәрде.— Әһә, сез бүлмәне басып алмакчы булгансыз икән! Әһә, сволочьлар! — Ул әйберләрен куйды да Әнвәр өстенә килде һәм аны ишеккә таба төртеп җибәрде. Әнвәр, билгеле, идәнгә шалтырап барып төште, кулыннан ычкынган таяклары төрле якка атылды. Ул торгалаганчы хатын аның таякларын алды да коридорга чыгарып ыргытты. Аннары торырга азапланган Әнвәрне ике кулыннан эләктереп өстерәргә кереште. Әнвәр сыңар аягы белән тибенгән булды.

— Хулиганка! Нишлисең, җен хатыны! — диде. Хатын аны коридорга шудырып чыгарып идәнгә сузылдырды. Сырманы аның өстенә ыргытты һәм ишекне шартлатып бикләп алды. Эчтән малайның шатлыклы: «Руки!» «Руки!» — дигән ачу китергеч тавышы яңгырый иде. Коридорның урта өлешендә шактый еракта бер генә лампочка янганга күрә, бирედә ярым караңгы иде. Әнвәр көчкә генә торып басты. Хатын аның касыгына ботинкасы белән дә орынгалаган, ахры, янбаш өсте әрнеп авырта иде. Аяк бетү белән безнең ишенең бар көче дә беткән икән, дип ачынып уйланды Әнвәр, шушы хатыннан җиңелгәнгә хурланып. Юкка чыгылган икән, бернигә яраксыз булып калынган, авызын корт чаккыры! Бармак белән төрткәнгә дә егылып китәсең. Шулмы булды кеше? Юк, кеше кыйпылчыгы, бернигә тормый торган калдык-постык!

Әнвәр, ирененда юешлек тоеп, кулъяулыгын борынына куеп алды һәм кан таплары күрде. Борыны да каный икән. Ул башын чалкан җибәреп, канны туктатырга итә иде. Кабалана-кабалана Турганов килеп житте. Кесәләре бүлтәйгән. Әнвәр бер-ике сүз белән хәлне аңлатты. Борын канавы да аның сүзләрен куәтли иде. Турганов җан ачуы белән ишекне шакырга, тарткаларга тотынды. Хатынны сүкте. Хулиганны хәзер куып чыгарам, дип янады. Әмма теге яктан бары малайның «һенде һоһ! һенде һоһ!» дигән сүзләре генә ишетелгәли иде. Тургановның тәмам ачуы ташыды. Ул урамга чыгып, каршы яктагы сырахانәдән бер милиция алып керде. Озын гына гәүдәле егет. Иплап кенә үзенең кем икәнен әйтте, ишекне ачарга кушты. Ләкин хатын бик тәмле тел белән аңлатты:

— Аларның ордерлары юк, минем бар,— диде.— Ишекне ачмыйм, иртәгә килерсез... Алар үзләре бүлмәне басып алмакчы булганнар, иптәш милиционер...

Хатынның сүзләре ышанычлы яңгырый иде. Милиционер боларга таба борылды.

— Ордерыгызны күрсәтегез? — диде ул Тургановка төбәлеп.

— Ордер комендантта,— дип ышанычлы итеп әйтте теге.

— Комендант кайда?

— Белмим. Сезгә барырдан элек аңа сугылган идем, өендә юк.

— Ордерны ник аңа бирдегез?

— Ул үзе алды...— Тургановның сүзләрендә ныксызлык сизелде. Милиционер әллә шуны эчтән тоеп алды, әллә болай, уйга калып торды да әйтте:

— Иртәгә барын да ачыкларбыз, бүгенгә кайтып торыгыз.— дип, ул хәрбиләрчә уң кулын чигәсенә күтәреп төшерде. Һәм шул минутта боларга битараф кыяфәттә китеп тә барды.

Әнвәр һаман башын муен артына ташлап борын канавын туктатмакчы була иде. Тургановның кыяфәтендә нишләргә белмәү, аптырау иде. Ләкин чигенәсе, Әнвәр алдында үзен төшерәсе килми иде. Ул үҗәтләнеп:

— Иртәгә мин моны барыбер куып чыгарам,— дип каударланды.— Син кайт, мин комендантка барам...

Турганов ике көннән соң гына кайтты. Суырылган, ябыккан. Яңакларында каты төкләр тырпайган. Әнвәр белән сөйләшәсе килмәгән кебек иде. Ләкин кемнедер гаепләмичә, акланмыйча булмый. Үзең өчен генә булса да, үз каршыңда гына булса да.

— Комендант бүген кич кенә пәйда булды,— диде Турганов.— Күрүгә, мине тиргәргә тотынды. «Ник бүлмәдән чыктың, гөмбә баш, фәлән-фәсмәтән. Хатынның ордеры бу бүлмәгә түгел, ә монда кучәргә тиешле кеше фатирына язылган... Түмәр булып шунда ятырга кирәк иде», имеш. Бар гаепне миңа аударды да куйды.

-- Шалман ул, жулик! — диде Әнвәр, ачуы ташып.— Башта ук әйтергә тиеш иде...

— Ну бу мокытлыкны, ну бу ышанучанлыкны,— дип Турганов йодрыклары белән мендәренә боксер кебек төрткәли, нишләргә белми иде. Ахырда Әнвәргә тотынды: — Син бөтен эшне боздың, бигрәк пешмәгән!

— Сине төп башына утыртканнар, әле дә аңламыйсыңмы? Һи-и!

— Шул хатынга да бирешеп торгач... Кит әле...

— Үзең булсаң нишләр идең? Үзең соң? Ничек алдаганнар, сизмисеңмени? Каз тизәге кебек йомшак...

— Син аныкы миннән дә сыеграк сыер тизәге!

Әнвәр кычкырышып китүдән тыелды. Турганов тагы:

— Ну бу беркатлылыкны, ну бу ышанучанлыкны! — дип, еламсырап, мендәрен төйгечләргә тотынды.

— Бу сиңа разведкага барып «тел» алып кайту түгел,— дип үртәлде Әнвәр.

— Разведчик селтәнүләре монда ярамый икән,— диде Турганов, бик кайгыга калып.

Әнвәр шуны аңлады: ерткычланып берәр нәрсә кулга төшерергә, йөз ертырга алар икесе дә сәләтсез икән. Сүздә мөмкин булган нәрсәләр күп вакыт гамәлдә мөмкин түгел. Сүз бер, эш бөтенләй икенче төрле килеп чыга. Сүзләр белән генә барлыкка китерелгән хәлләргә сукырларча ышану ярап бетми икән.

## 3

Госпитальдән чыгар вакыт якынлашкан саен ныграк уйландыра. Нишләргә, кая барырга? Нинди эшкә тотынырга? Көн-төн шул кайгы борчып тора, сөлек кебек җанны суыра, йөрәкне сызып-сызып авырттырып үтә. Тормыш бик авыр. Моны ул няняләр, шәфкать туташлары, врачлар йөзенә карап та сизә. Бер кирпеч ипи өч йөз сум тора, ди. Быел тагы коры ел булды, игеннәр уңмаган. Хөкүмәт чит илдән икмәк сатып алу турында сөйләшүләр алып бара. Ә капиталистлар җелегеңне суыра. Әйе, авыр ел. Без госпитальдә сәхрәдә ятып, кайбер нәрсәләргә җиңел карарга өйрәндек шикелле. Нәзберекләндек, мәми авызга әйләндек. Гражданкада тормыш безгә тагы да авыр булачак... Протез заводына үлчәтергә барганда икмәк кибетендәге чиратны күреп, Ваһапов янә пошаманга төште. Андагы кычкырыш-талаш, якалаштан эченә салкын йөгергәндәй булды. Бу гарип-гораба көе нишләрмен? Үзем гаилә турында хыялланам. Гаиләне асрар өчен ныклы эш урының, саллы айлыгың булырга тиеш! Асяга исәп тотып, аңа ышыкланыргамы? Аның химаясына керергәме? Шәфкать туташының нәрсәсе булсын?! Юк,

мин ир кеше, үзем аның яклаучысы булырга тиешле. Мин әле ирлек бурычымны онытмадым...

Ася, терелеп, яңа гына эшли башлаган чак. Ул Митавага кайтып китә алмады. Һаман намуссынды. Мира аны шул гарнизон госпиталенә эшкә урнаштырган иде. Фира Касыймовна исә үзләре күршесендә бер кечкенә бүлмә табып бирде. Туганы төньякта очучы иде, яртышар елга бүлмәсен Фира карамагына калдырып китә. Ася өчен бик әйбәт булды ул.

Кичен Фира Касыймовна Ваһаповны үзләренә алып кайтты. Ася өйдә иде, чакырып алып керде. Бу вагонда аерылышудан соң беренче очрашу иде. Ваһапов, Асяны күргәч, әсселе-суыклы булып китте. Асяның җете гүзәллегенә таң калды ул. Элек болай аяктан егарлык түгел иде кебек. Аксыл тулы түгәрәк бит уртасында нур бөркеп торган чокырчыклар. Тагы да тулыланып киткән калку күкрәкләр. Хәрби киемнәрнең бик килешеп торуы аны ача, тагы да мөлаем итә.

Алар берсен-берсе бүлә-бүлә сөйләштеләр. Фира чәй әзерләде. Чәйне дә хуҗабикәнең күңеле булсын өчен генә эчтеләр. Асяның сөйләшүендә ниндидер горурлык, үз бәясен үзе белү сизелде. Җирдә нык басып торучанлык, арка терәге барлык та чагыла иде. Ул күбрәк үзенә шушы яхшылыкларны эшләгән дус кызы Мира Лучинская турында сөйләде. Аның белән горурланды. Ваһаповның хәл-әхвәлен сорашса да, госпитальдән чыккач нишләргә, кая барырга ниятләве хакында бер сүз дә катмады. Ә Ваһапов аның хәзер нинди план белән яшәвен сорагач, белмим әле, тормыш үзе күрсәтер, дип, кулын селтәп куйды. Бу хакта сүз озайтасы килми иде. Ваһапов, аның һәр күз карашыннан башын муенына тартып, бөрешкәндәй була, чөнки шушы чаклы матур хатын-кыз янында утырганы юк иде. Күркәмлек ничектер электр кыры кебек тәэсир итә икән. Бу гүзәллек янында Ваһапов үзен хәчтерүш бер зат итеп сизде. Асядагы элеккеге гадилек беткән шикелле иде. Ул үзен куя белә. Шуңа бәрабәр аның уйлары, хафалары да үзгәргән булырга охшый.

Инде соң иде. Фира аларга күрше бүлмәдә кунарга урын әзерли башлады. Үзе шаяртып сөйләп алды:

— Татарларда егет белән кыз йөргәндә, бергә куналар, кочаклашып йоклыйлар. Ләкин бернинди кыҗыр-мыҗыр эшләмиләр. Шундый йола бар,— диде. Асяга карап-карап алды, көлде, шаяруга борды. Ася да аңа кушылып көлде, бу йоланы өнәмичә, баш чайкады. Ачыклык кертте:

— Без әле аңа чаклы өлгереп җитмәгән,— дип куйды.

— Күпме үсәргә мөмкин?— дип шаяртты Фира Касыймовна, әле Асяга, әле дәшми, көлемсерәп утырган Ваһаповка карап. Бәлки Ася аның инициативасын көткәндер? Ваһапов исә гипнозланган кебек булып калган. Тәмам зиһене чуалып беткән, таркауланган төс белән утыра. Үзе белән Ася арасында шундый зур физик аерма булуы аның миенә китереп суккан иде. Ничек ул элегрәк бу хакта уйлый белмәде? Нинди реалист кеше үзе, нинди сукырлык күрсәткән?!

Фира һаман бергә кунарга кыстый иде. Ася, көлә-көлә, аның тәкъдимен кире кага:

— Без аңа әзер түгел, димәк, артхәзерлек житешмәгән. Йөрәккә артхәзерлек кирәк, тәнгә кирәк түгел, ә йөрәк шунсыз андый нәрсәгә бара алмый...

— Юк,— дип, үзенекен каера Фира Касыймовна,— мондый чакта тәвәккәллек кенә кирәк. Бергә яткач, житмәгән нәрсәләр бик тиз өлгереп житә ул...

Ася үз бүлмәсенә чыгып китте, Ваһапов монда калды. Фира Касыймовна аны хөрмәт белән генә шелтәләп алды:

— Син нәрсә, хатын-кыз янында җебеп торасың,— диде.— Хатын-кыз җебегәнне өнәми, үзен табыш итеп алганны ярата. Нигә ике кул-

лап аңа ябышмадың? Беләсеңме, кеше үзенең табышына ничек омтыла? Үлгәнен дә белми ыргыла, тизрәк эләктерергә тырыша. Йөрәккә әзерлек кирәк, дип ул болай гына әйтә. Тыйнак буласы килгәннән. Сизеп торам мин. Үзе эчтән генә синең ныклы беләкләрең көч белән кысканны көтеп тора...

Ваһапов үзен мокытлыкта гаепләп сөйләнде:

— Хатын-кыз четерекле бит, аны белеп буламыни,— диде.

— Бернинди четереклеге-метереклеге юк, бары тәвәккәллек һәм каты куллылык кына кирәк,— дип, Фира һаман Ваһаповны өйрәтте.

* * *

Нишләргә? Һәр көнне шул сорау Ваһаповны газаплый. Үз язмышын бернечә вариантта уйлап карый. Берсенең дә очына чыга алмый. Иң элек миңа яраклы әйбәт эш табарга кирәк, дигән нәтиҗәгә килә. Эшкә урнашкач, гаилә кору хәстәренә керешергә мөмкин. Ә эшне сиңа әзерләп куймаганнар. Алда билгесезлек, караңгылык.

Әмма җан биргәнгә юнь биргән дигән кебек, шул караңгылыктан аңа бер якты чаткы сузылды. Хикмәт шунда, шәһәр янына урнашкан хәрби частьтән махсус бүлек кешесе Ваһапов янына кайбер нәрсәләр белешү өчен килеп йөри иде. Аны алгы сызыкта килеп туа торган ситуацияләр бик кызыксындыра. Үзе сугышта булмаган, ә алгы сызык аша үткән кешеләр белән эш итәргә туры килә.

— Ул эштә сезнең практика бик зур, һәр киңәшегез файдага,— дип, салам кыстыра. Аның сүзләрен «саф тәңкә» итеп кабул итмәсә дә, үзен белүләре, менә каян килеп табулары белән горурланып куя Ваһапов. Яхшы эшчене бәялиләр бит, югалтмыйлар, нинди икәнеңне чамалыйлар. Бу эштә ул зур мәктәп узды. Чиста эш түгел иде, әмма кемгәдер аны эшләргә кирәк бит! Дошманны җиңү, үз хәләл җирләребезне азат итү өчен, ниләргә генә барылмады, нинди генә чаралар кулланылмады! Немецлар берни белән хисаплашып тормады, без дә кырыс, хәтта соңгы чараларга барырга мәҗбүр булдык. Шунсыз канлы дошманны тез чүктерү мөмкин булмас иде. Ә кайбер кешеләр ил мәнфәгатен әз кайгырта, үз тиреләрен саклау белән шөгыльләнә. Кеше психологиясендә ак таплар бик күп әле. Адәм заты үзен-үзе белеп җиткерми һәм шуның аркасында аянычлы хаталар да эшләп ташлый. Аларга үз хаталарын төзәтергә ярдәм итү зарури бер эшкә, дәүләт эшенә әйләнә. Тере кешене җәмгыятьтән сызып ташлый алмыйсың. Шуңа күрә алар белән эшләү кирәк тә. Ваһапов кулы һәм күңеле аша күпме шундый язмышлы кешеләр узды! Бернечә кешегә чын коммунистларча ярдәм итеп, аларны бәладән дә коткарды. Моны ул үз җаваплылыгына алып эшләде. Ваһаповка ышаналар иде... Әнә бит ул ышаныч югалмаган, фронттан монда чаклы килеп җиткән. Бу эшнең кеше психологиясе һәм холык-фигыле белән бәйләнгән бик четерекле яклары бар. Кай кешегә ышанасың, әмма ул синең ышанычыңны акламый. Сине төп башына утырта. Кешенең эчен чамалар өчен бик нечкәлек һәм үткен интуиция таләп ителә.

Махсус бүлек кешесе кысыграк күзле, кыска борынлы, калынчарак тигез иренле бик мөлаем зат күренә иде. Кешеләргә хәерхаһ каравы аеруча ошады. Андый эштә утырган кешегә шундый сыйфат бик кирәк. Ул Ваһаповка да хәлен аңлап карый иде. Ничектер аңа бер-бер игелек итәсе килгән кебек. Менә ул соңгы килүендә сөйләде:

— Син безгә кирәкле кеше,— диде.— Бездә әйбәт эш бар сиңа, тик квартира ягы кисә. Үзең квартира юнәтә алмассыңмы? Юкмы? Әйе, авыр хәл!— дип тынып калды. Аннары Казан шәһәрендә тормыш-көнкүреш авырлыклары турында зарланды:— Элек-электән ярлы шәһәр. Чөнки тирә-ягында җирләр бик начар, ком да кызыл балчык, бернәрсә дә уңмый. Туфракның нинди булуы хәлиткеч нәрсә шул әле. Әнә Бөгел-

мә якларында булганда күрдем, бәрәңгеләре куш йодрык чаклы, ә бездә — чебеш йомыркасы шикелле генә. Тукта, Бөгелмә дигәннән искә төште. Балтик буеннан кайткан бер мехкорпус машиналары Бөгелмәгә туплана. Әмер бар. Зислар, студебеккерлардан ике авторота төзелә. Стройбат профилендә. Анда зур эшләр башланачак. Нефть ачканнар. Хәзергә сер итеп тоталар. Оборона министрлыгы үзләштерергә керешә. Армеецлар асфальт юллар салачак. Беркадәр машиналар колхозларга икмәк чыгаруда булышачак, ди. Карточканы бетерергә дигән бурыч куелган. Аннары барча техника нефть эшенә җигеләчәк. Менә шунда эшләргә, ә?

Ул кызыксынучан итеп Вәһаповка карады. Вәһапов исә мондый тәкъдимгә бик үк әзер түгел иде, шулай да аны кайгырткан кеше алдында мәнсез булып күренәсе килмәде һәм йөзенә сөенечле чаткылар чыгарды.

— Әйе, уйларлык эш бу,— дип тәкъдимне хуплады һәм тәгаенрәк итеп сораштырды. Теге, урта бармагын югары күтәреп, Бөгелмә шәһәрен мактады.

— Бай шәһәр,— диде.— Әллә ничә тегермән генә гүләп эшләп тора. Зур бойнясы бар. Ашханәгә керсәң, эч-баш турап пешерелгән тәмле шулпа белән туеп чыгасың. Квартир ягы да җайлы. Солдатлар өчен бараклар төзегәннәр инде, ә комсоставка — ике, өч гаиләлек фин йортлары...

Бу бик кызыктыргыч иде. Күңелдә теләк, дәрт кузгатты. Баш казанын «кайнатыр» өчен Вәһаповка шул җитә калды. Күңелендәге ниндидер өметкә җан өргән кебек хис итте. Ул өмет киләчәк караңгылыгына үзеннән якты чаткылар сузды. Юк, бөтенләй беткән баш түгел икәнмен әле, дип, тәшвишле җанына тамчы хәтле генә канәгатьлек килде. Их, Ася белән киңәшергә, нәрсә әйтер иде икән? Юк, бу мөмкин түгел инде. Ул, мөгаен, туган җире Ленинградка кайтырга йөридер. Сөйләгән иде, аларның йорты бүрәнәдән салынган булган, блокада вакытында аны сүтеп утынга ягып бетергәннәр. Аның да кайтып сыеныр почмагы юк. Әмма бушап калган квартираларга урнаштыралар, ди. Шәһәр кешеләре генә миллионга якын һәлак булган. Аларның урыннарын кемнәр беләндер тутырырга тиешләр инде. Юк. Ася белән борчак пешереп булмас. Ул бик затлы булып киткән. Аның затлылыгы бәлки электән үк киләдер, мин генә күреп-сизеп җиткермәгәнмендер. Ә мин балта белән генә чапкалап эшләнгән мужик. Безнең нинди уртак нәрсәбез булуы мөмкин? Минем хисләр чын да бит, аның хисләре ихтыяр көче белән генә булыр. Гарип кешегә ниндидер хәер кебек. Хәер хисләр... Хәер белән озак барып буламы? Аннары, хатынны тәэмин итәрлек эшкә урнашмый торып, мин гаилә корырга ыргылам. Хатын-кыз көченә исәп тоту, аңа ышыкланып яшәү миннән булмый. Гаиләгә җитәрлек эшли алмыйм икән, иң яхшысы, ялгыз калам. Хатынына салынып ятучы адәмне, инвалид булса да, мин ир-атка санамыйм. Бәйле булу мин-минлеккә тия, минем холыкка һич ятмый торган нәрсә! Әз генә бәйле булу да жанга бик авыр. Нидән бу? Элек алай ук түгел иде кебек? Нервылар беткән, ахрысы. Сизәм, юк кына нәрсәгә дә ачу килеп тора. Бу нервыларның бик нык тузуы билгесе. Вак, пүчтәк нәрсәләрне күрәм, шуларга әһәмият итәм һәм борчыла башлыйм. Паникага биреләм. Үз-үземә, үз көчемә ышаныч кимүдән була торган халәтме бу?!

Шуны аңлыйм да кебек. Ләкин берни эшли алмыйм. Организм бик нык үзгәргән, кире сыйфатларның калкып чыгуы шулардандыр? Артык нык үзанализга бирелү һәм үзеңнең бәянне кечерәйтү шулай ук әйбәт түгел. Теге якка да китмәгән, бу якка да тайпылмаган алтын урталыкны табарга кирәк. Шул алтын урталыктан барырга... Әйе, миңа уку, белемемне күтәрү иң зарури нәрсә хәзер! Кичектергесез эш! Ә хатын-кыз белән бәйләнсәң, укып булмый инде, шушы тутыккан тимер кисәге булып калыначак. Беренче чиратта — белем, икенче чиратта — гаилә.

Моны Асяга әйтергә микән? Ул да укырга омтыла иде шикелле. Шулай булмый ни, ул бер нәрсәне дә ярты юлда калдырмый. Мөгаен, ул миннән: «Ася, син укырга кер», дигән сүз көтәдер? Ул хәзер уку исәбе белән генә яшидер?

Шундый каршылыклы уйлар эчендә ятканда, Ваһапов янына Ася килеп керде. Хәлеңне врачлардан сорашып чыгыйм, дидем, ди. Кулында Ваһаповның «Авыру тарихы» иде. Врачлар белән сөйләшкән, ахрысы. «Авыру тарихы»н актаргалап карый да Ваһаповтан хәл-әхвәлен сораша. Ә палатадагы яралыларның карашы Асяга төбәлгән. Карамаска итсәләр дә, башлары үзләреннән-үзләре Асяга таба борыла. Асяның аксыл түгәрәк йөзеннән, кулларыннан нур бөркелә иде. Аңардагы садәлек, табигый нәфислек һәм ясалмасызлык зиһенне үзенә тарта да тора. Гөлнең чәчәк аткан чоры була бит әле, Асяның, мөгаен, шундый вакытыдыр. Аңа сокланмыйча мөмкин түгел иде. Юк, бу каршы хисне уятмый торган матур. Киресенчә, әйбәт буласы килүне уята торган нәфислек. Әйбәт янында әйбәт буласың, диләр. Ваһапов үзе дә шундый хисләр кичереп утырды. Ничектер әйтергә әзерләп куйган сүзләрен дә онытып җибәрде. Ася аңа протезыңны киеп йөр әле, дип әйткәч, нигәдер каушаган кебек булды. Тизрәк баш тартырга ашыкты:

— Протез төзек түгел, культяны кыра,— диде.— Иртәгә төзәтеп китерәчәкләр,— дип, кулын селтәде. Ася:

— Болай хәлең әйбәтләнеп бара икән, тик чыгарга ашыкма әле,— дип тә өстәде. Аннары китәргә кузгалды.

Асяны озатып кергәч, палатадагылар, күзләрен очкынландырып, Ваһаповка ябырылдылар:

— Кем ул? Кайдан? Ничек?

— Мине дәвалаган врач,— диде Ваһапов.

— Таныштыр әле, исеме ничек, тагы кайчан килә?

Асяның нәфис мөлаемлеге тәэсиреннән әсәрешкәннәр. Күзләрендә ниндидер чаткы яна. Кара инде боларны! Аяксыз капитанның тәмам дәрте кузгалган, Ваһапов караватына утырган да Ася турында төпченә. «Ул кияле!» дигәнне дә аңламый, «минем танышларда кичә оештырабыз, шунда Асяны да чакырыйк», дип, конкрет тәкъдим әйтә.

Гаҗәп бу ир-ат халкы, матур хатын-кыз өчен үлә, гарип калса да, гүзәлгә үрелә. Гариплекләрен уйламый. Ахры, табигатьтән шулай килә. «Тиң түгеллеген дә белә, өзелеп сөя яшь күңел». Соңы ни белән бетәсен уйламый, чибәрләргә ташлана, шуны яуламакчы була. Хатын-кыз нәфислеге зур көчкә ия шул. Ләкин чибәрләр акыллы булмый, дигән сүз дә бар. Бу бөтенләй үк нигезсез түгелдер. Әмма Асяга карата аны әйтеп булмый.

Мин үземне Ася янына куеп карыйм: йа, хода, нинди зур аерымлылык! Янәшә китерергә дә мөмкин түгел. Янәшә китерсәң, бик зур гаделсезлек килеп чыга. Асяга карата гаделсезлек! Мондый җирәбә аңа чыгарга тиеш түгел. Сугыш тураган күпме яралыларны үлемнән алып калган ул! Риясызлыгы, фидакарьлеге, үз-үзен җәлләмәве белән! Ул бик бәхетле язмышка хаклы! Мин аның язмышына сарылып, барын да харап итәрмен. Ул өмет иткән тормышны төзи алмам, көткән бәхетне бирә алмам. Шуңа аның юлыннан кая булса да таярга! Шик юк, Ася үзенә тиң, таза кеше белән язмышын бәйләргә телидер. Кеше табигате шулай ул. Моңа Асяны гаепләп булмый.

Тукта, яраткан кеше шулай уйлый аламы? Әллә минем болай аек уй йөртә алуымда хис катнашмыймы? Әйе, сизәм, миндә ташып торган сукыр хисләр юк кебек. Алгы сызыкта күп булу, гарип булып калу да эзсез үтмәгән. Аерым исәптәге солдатлар белән эшләү дә, күп төрле фаҗигаләр күрү дә җаныма үзенең мөһерен суккан. Мин элек тә әкрен табигатьле, озак кузгала торган кеше идем түгелме соң? Тагы шул: авырлыклар, югалтулар кичергәндә кешенең хисләре сарыф ителеп бетә, ахрысы. Ул салкын исәп-хисапчан булып кала сыман. Ни генә булса

да, бер фикер: Ася үзенә лаек кеше тапсын, аның бәхетенә комачауларга мин җөрьәт итә алмыйм. Үз-үзеңне әзрәк белү тиеш! Үз мөмкинлекләреңне төгәл исәпләргә һәм шуңа карап эш итәргә. Үзеңә артык ышану бәлагә генә китерә. Мөмкинлегеңнән узып, нәфескә бирелү һәрчак фаҗига белән тәмамлана. Шундый язмышлы кешеләр белән күпме очрашырга туры килмәде...

Казан дигән бу шәһәрдә калырга бернинди әмәл юк. Ни җайлы эше, ни квартиры. Баш төртер почмак таптың да ди, ә тамакка карточкадан тыш берни юнәтү мөмкин булмаячак. Шундый хәлдә күзле-башлы бул, гаилә кор, имеш! Моннан да мәгънәсезрәк берәр нәрсә табылырмы? Ничек мин элегрәк шул хакта уйламаганмын? Яралану, операцияләр акылны алган булган. Аякны кискәндә, акыл да әзрәк киселгән, ахрысы. Шуның аркасында балалыкка төшелгән, кырыс реальлекне исәпкә алмыйча, җиңел, беркатлы уй йөртелгән...

Палатага кайсыдыр кайтып керде дә:

— Клубка кино китерделәр, урын алырга ашыгыгыз,— дип кычкырды. Кайсы халатын киеп, ашыга-ашыга китте, кайсы протезы белән мәшәләнә башлады. Протезны, атны арбага җиккән кебек, үзеңә җайлау шактый читен. Ваһапов та кузгалып протезына тотынды. Аңа чалбар кигезү бик читен. Протез тимерләре чалбарны ерта да чыгара.

Бу зур бина элек мәктәп булган, шуңа аның әйбәт кенә клубы да бар иде. Бик зурдан булмаса да, җыйнак, утыргычлары тар креслолар рәвешендә эшләнгән. Бер башында сәхнә бар, анда пианино тора. Сәхнәгә ак җәймә эләләр дә, янәшә бүлмәгә аппарат куеп, кино күрсәтәләр. Артистлар килгәндә исә, сәхнәгә калын гына яшькелт төстәге пәрдә элenә.

Ваһапов килгәндә залда бер буш урын да калмаган иде. Госпитальдә миңа якын яралы, диләр. Шуңа күрә бу хәл бер дә гаҗәп түгел. Аннары яралылар киноны бик көтеп ала. Чөнки кино әз генә булса да сызлау, сыкрауларны оныттыра. Көне-төне ах-вах килеп караватта аунаган яралы өчен бер юаныч. Начар гына картина булса да, анда күрсәтелгән икенче бер тормыш эчтә җыелган караңгы уйларны таратып җибәргәндәй итә. Кызыктыра, үрти, йә ачуны китерә. Гадәттә, трофей фильмнар күрсәтәләр. Без чит илдәге тормышны белмибез, хәбәрдар да түгел, шуңа кызыксынып карыйбыз. Йөри алмаган яралылар да кинодан калмый. Аларны носилкалары белән сәхнә алдындагы буш урынга китереп тезәләр. Бүген дә носилкалар шактый күп. Ваһапов та бер носилка башына барып чүмәште. Зал гөж килә, култык таяклары бәрелгән тавышлар ишетелеп тора.

Сәхнәдә бер өстәл, берничә урындык тора. Димәк, замполит нәрсәдер сөйләячәк, йә берәр лектордан халыкара хәл турында сөйләтәчәк. Ул бер киноны да болай гына уздырмый, алдыннан берәр төрле нәрсә өештыра. Юкса лекция-фәләнгә дип чакырып, яралыларны клубка китереп булмый. Кызыл сүз сөйләгәнне өнәмиләр, чөнки сүзгә түгел, булган нәрсәгә, фактка гына ышаналар. Сугышта өтелеп бетеп, бик нык какланган халык. Арада кайнар башлы, тәртибе шактый какшаганнары да бар. Замполит алар белән аерым сөйләшә. Үгетли:

— Аяксыз калсаң да, барыбер кешеләр арасында яшәргә туры килә. Үз сыныгыңны эшләп ашарлык бул. Бүтәннәр җилкәсен кимерергә өмет итмә. Әрәмтамаклыктан да түбән нәрсә юк дөньяда. Шуның өчен берәр һөнәргә өйрәнергә кирәк...

Нәкъ әнә шуңа замполит бик тырышып госпитальдә итек тегәргә һәм баянда уйнарга өйрәтү, бухгалтерлык курслары ачтырды.

Ян бүлмәдән замполит Френкель сәхнәгә килеп чыкты, аңа врач Луиза Георгиевна һәм таякка таянган, ничектер үкчәсенә басып авырлык белән атлаучы, погонсыз яңа гимнастеркадан, урта буйлы яралы ияргән. Юк, яралының аяклары протез түгел шикелле... Атлавыннан шулай сизелә. Әллә лектормы ул? Алай дисәң кулында берни дә юк. Менә алар

врач белән өстәл янындагы урындыкларга утырдылар. Замполит баскан көе залга карады, тынычлануны үтенә иде. Теге яралыга Ваһаповның нигәдер күзе төште, һәм дикъкате шунда тукталыбрак калды, чөнки ул кешедә нindидер таныш чалымнар күргән кебек булды. Кем булыр бу? Юк, таный алмый. Күзләр алдыйлар, ахрысы...

Халык тынычлангач, замполит сөйләргә тотынды. Бернинди кереш сүзсез башлады.

— Иптәшләр, сез беләсез инде, алгы сызыкта кайчак бик кискен, аяныслы хәлләр туа. Шулвакыт югалып калмаган, кискенлекне үз файдасына бора алган батырлар була. Алар куркуны, үлемне онытып, дошманга каршы ташлана, аны чигенергә мәҗбүр итә. Шундый чын геройларның берсе безнең арада да бар. Ул — иптәш Туфайлов. Безгә чираттагы яралылар белән бер ай элек килгән иде. Алгы сызыкта һөҗүм алып баручы ротада санитар булган. Рота санитары. Күп яралыларны үлем кырыннан алып чыккан. Шул ук вакытта дошман танклары, безнең сафларны өзеп, ротага ташланган бер мәлдә, Туфайлов, траншеяда торган килеш, гранаталар белән дүрт «Тигр»ны сафтан чыгара һәм экипажларын да бетерә. Хәлиткеч мизгелдә позицияне саклап кала. Шушы батырлыклары өчен күптән түгел Туфайловка Советлар Союзы Герое дигән исем бирү турында указ чыкты...

Замполит шул урында сүзен бүлеп, аңа таба борылды. Залдагылар геройны күреп, белеп алдылар һәм дәррәү кул чабарга тотындылар. Туфайлов, күзен аска төбәп, бераз каушаган елмаю белән, нишләргә белми, кулларын уа иде.

Ваһапов сәхнә баскычы янында иде, ничек торганын, ничек сәхнәгә чыга торган ишеккә килгәнен сизми дә калды. Ян ишекне ачты да, бер-ике адым атлап:

— Туфайлов!— дип кычкырды.

Кул чапкан тавыш көчле булса да, Туфайлов ишетте һәм аңа таба башын борып карады. Ләкин тиз генә таный алмады шикелле. (Аерылганга биш ай үтте микән.) Ваһапов аңа тагы дәште. Тик шуннан соң гына Туфайловның икеләнүле йөзе кинәт яктырып китте. Урыныннан торды, замполитка карады һәм Ваһаповка таба атлады. Ваһапов та бер-ике адым килергә өлгерде. Сәхнә кырыендарак алар очрашып, бер-берсенең иңнәренә сарылдылар.

— Иптәш замполит!— дип, йөрәк белән әйтте Туфайлов һәм күзләреннән яшь атылып чыкканын тоймый калды. Ваһаповның да тамагына кайнар төер килде. Ул арада кемдер өстәлне шалтыратып кыңгырау чыңлатты, залда ут сүнде. Механик ашыктыра иде. Эленгән ак җәймәгә ут көлтәсе төште. Болар ян бүлмәгә чыктылар.

Ваһапов белән Туфайлов озак сөйләшеп утырдылар. Туфайлов үзен замполит каршында бурычлы итеп сизә иде. Аңа зур исемне бирер алдыннан бик күп кәгазь-документлар җыялар, тутыралар. Рота замполитының язуыннан башка беркем берни эшли алмый. Моны Туфайлов яхшы аңлый иде.

Үзләре сугышкан позицияне кәгазьгә сыза-сыза аңлаштылар. Кайда нинди траншеялар, блиндажлар булганын, анда кем, ничек хәрәкәт иткәнен, нәрсә эшләгәнен тәгаенләделәр. Кем кайда, ничек яраланган? Шуны ачыкладылар. Ваһапов ярты тәүлек чамасы элегрәк яраланган икән. Ул позициядән киткәч, нинди кискен бәрелешләр булганын Туфайлов сөйләп бирде. Мамакны еш телгә алдылар. Ул булмаса, эш харап иде, дигән уртак фикер аларны тагы да якынайтты. Мамакны икесе дә курку белмәс чын батыр дип таныйлар иде. Һөҗүмне эшлекле итеп оештыру һәм эшлекле җитәкчелек итү көчле дошманны чигенергә мәҗбүр итте.

— Ике як та соңгы көченә хәтле тартышты,— диде Туфайлов.— Бар җегәрен чыгарып бетерде. Немецлар техника белән алдырмакчы булдылар. Әмма бездә дә техника бар бит...

— Танкларны җимерүең хакында мин санбатта ишеттем,— диде Ваһапов.— Комбатның ярдәмчесе килгән иде. Реляция язарга куша. Температура. Кая анда! Үзе язып килгән икән, шуңа кул куйдым... Ә армия госпиталенә күчергәч, Мамакны күрдем. Кулы яраланган иде. Синең хакта сөйләде. «Мондый батырлык эшләгән сугышчылар булды,— диде,— ләкин берсенә дә герой исеме бирү турында эш кузгатмадылар. Орден, медальгә генә куйдылар...» Мамак шулай әйтте. Ә сине — герой-га! Димәк, артында начар нәрсәләр булмаган?

— Белмим инде, белмим,— диде Туфайлов үзенең ак тешләре белән елмаеп.

— Тагы бер мөһим нәрсә,— дип Ваһапов фикерен дәвам итте.— Шул танклар килгән мизгелдә андагы хәлләрне стереотруба аша комбат үзе, полк замполиты майор Жиздринский күзәтеп, күреп торганнар. Бернәрсәне дә күздән ычкындырмаганнар. Дивизиядән дә аерым күзәтүчеләр булган, бәхетең шунда, алар күзәткән чакта танклар килгән һәм синең траншея буенча йөгерә-йөгерә, гранаталар ыргытуыңны карап торганнар. Туктап калган танкларны күргәннәр, ике танктан төтен дә күтәрелгән. Шулаймы? Һөҗүмнең борылыш мизгелен шушы нәрсә хәл иткән. Немецлар чигенү ягына борылган. Үзләре күз алдында булган факт. Фактны яшереп калу бик кыен ул. Чара юк, геройны бирергә кирәк, дигәннәр.

Ваһапов бер күзәнәкле адәм түгел, ул катлаулы кеше. Билгеле, Туфайловка герой исеме биргәндә бераз көнчелеге килгән иде. Шуңа күрә моның бәхетле бер очрак икәнен аңа кат-кат сөйли һәм шуңа үзен дә ышандырмакчы була. Әйе, Туфайловка хәлләр җайлы килеп кенә торган.

— Һаман да ышанып җитмим әле,— дип көлеп куйды Туфайлов.— Замполит уртәлә күрмәсен, дип үзе эчтән борчылды. Бу бәхет аңа тикмәгә генә килмәгәнен белгертер өчен, яралары турында сөйләп алды. Ике аягының балтыр сеңерләрен мина ярчыклары өзгәләп бетергән икән. Чалбар балакларын сыерып күрсәтте: балтырларда бернинди ит юк, нечкә таяк шикелле генә булып калганнар. Аяк бармаклары да беткән, ярчыклар фарш ясаган булган.— Эвакогоспитальдә әлек бергә эшләгән врачка туры килдем, саклап кала алмады. Тизрәк Каунаска озатты...

— Әһә,— диде Ваһапов нидер белеп алган кебек,— сине, яралангач, Литва ягыннан безнең участокка килгән яңа частьлар җыеп алган икән. Шуңа ул якка эләккәнсең.

Алар, еш очрашып, алгы сызыкта булган теге яки бу хәлне, кешеләрне хәтерләренә төшерә, нәрсәдер ачыклый, тәгаенлиләр иде. Берсендә Туфайлов:

— Крынкин дигән сары чәчле, олырак чырайлы рус хәтереңдәме?— дип сорап куйды. Ваһапов исенә төшерә алмады. Туфайлов тагы сурәтләп күрсәтте. Ваһапов баш селеккәч, сөйләп китте.— Шул кеше бер дә курыкмый, каушамый торган булып чыкты. Танклар килгәнен, траншеяга сыланып, тыныч кына күзәтеп тора. Гүя бер гади, өйрәнгән, күнеккән нәрсә кебек итеп. Валлаһи! Нервы да булса була икән! Танк якынлаша башлагач, миңа запал куйган граната суза. «Мә, иптәш Туфайлов, әнә ул траншея борылышыннан теге гробка томыр», ди. Битараф кына итеп әйтә. Тыңламыйча һич булдыра алмыйсың. Аның үзен тыныч тотуы миңа да күчте. Ул биргән гранатаны алам да чабам траншеядан танк каршына. Шул чапкан көчкә гранатаны якында гына ыргыган танкка томырам. Үзем траншея төбенә авам. Шартлау якын бит. Өч гранатам танк астында шартлады. Юк, сиңа чынын әйтми ярамый. Крынкин булмаса, мин әллә ни майтара алмаган булыр идем. Хәлне хәзер анализлап ятам, шул ук фикергә киләм. Крынкиннан башка, бәлки, бер танкка граната ыргыткан булыр идем, җимертер идемме, юкмы, белмим... Ул, гранаталар әзерләп биреп, кайда, ничек ыргытырга күрсәтеп торды, ә мин башкарып бардым... Үзе ыргыта алмый, уң кулы-

ның бармаклары яраланган...

— Ә-ә-ә, искә төште,— диде Ваһапов чәчен учы белән сыпырып.— Крынкин лейтенант булган, ниндидер бер ахмак командирның мәгънәсез боерыгын үтәмәгән өчен гаепләнгән.

— Булыр, булыр! Ай-яй! Танклар җирне дерелдәтеп ыжгырып өскә килә, ә ул төген дә селкетми шуны карап тора! Просто таң калдым мин аңа!

— Куркыныч хәлдә кай кеше яңадан тугандай үзгәрә, минем дә күргәнем бар,— дип Ваһапов бер вакыйганы сөйләде.— Орудие командиры сержант Щерба бар иде. Үткен телле, бер сүз белән сине кисә дә сала. Командирларны да аямый. Штабта эшләгән, шул пычак теле өчен алгы сызыкка җибәргәннәр бугай. Бер һөҗүм вакытында расчеты беткән, үзе генә калган. Танклар һаман шуыша. Яраланган, шул көе ике танкны яндырган, үзе дә һәлак булган. Шул егетне без орденга куйдык. Ләкин штабта реляцияне кабул итмиләр. Анда тегенең пычак теле тигән кешеләр утыра. Медаль дә биреп булмады. Ә синең бик бәхетле килеп чыккан...

Алар хәзер нишләргә, ничек тормышка җайлашырга, ни кылырга дип, кайгырышып, уфтанып та утырдылар. Хәрби танышлык, бербереңә булышулар шунда бетә, ары юллар аерыла: алар икесе ике төрле кеше, язмышлары бер-берсенә охшамаган. Тормыш дәрьясын аерым гына кичәргә туры килә. Ул шаулап аккан тормыш дәрьясы нишләтер аларны? Бара алырлармы дәрья дулкыннары белән көрәшә-көрәшә? Әллә өерелеп өскә килгән дулкыннарга каршы торырга көчләре җитмичә, төпкә китәрләрме? Тормыш дулкыннары, гарипме син, әллә тазамы, аерып тормый бит! Китереп суга да аяктан ега һәм төпкә алып төшеп китә. Ватан өчен каныңны койдың, гарипләнеп калдың, дип, сиңа йомшаклык күрсәтмәс ул. Аңа өмет тотма! Син шул дулкыннар белән бергә-бер! Көчең җитсә, нәрсәгәдер ирешә алырсың, җитмәсә — юк!

Икесе дә кайчандыр замполит булган кешеләр, тормышның чыгырларын яхшы белә, аңардан аяу көтми иде. Гарип көе тормышта үз сукмагыңны ерып бару бик авыр булачак. Алар моны бик ачык таный һәм үзләрен шул кырыслыкка әзерли кебек иде. Икесе ике палатага кайтып, үз караватларына яткач, һәрберсе үз язмышын ничек эзгә салып җибәрү турында уйларга тотынды. Һәр кешенең үз кайгысы, үз хәстәре. Синең кайгыңны бүтәннәр белми, син исә бүтәннәрнекеннән хәбәрсез.

Ася белән ничектер авырттырмый гына аерылырга кирәк, дип уйлый Ваһапов.

Шул ук вакытта никтер Асяны тагы бер күрәсе килә. Күңел шуны сорап, көтеп тора кебек. Нәрсәдән бу, нигә бу? Аерылу ачырак, әрнүлерәк булсын өченме? Әллә яшерен бер өмет чаткысы бармы? Нинди өмет? Йа хода, бу өмет резина кебек, тузмый да, бетми дә, сузыла да сузыла...

Теге махсус бүлек капитаны кәгазь-документларны алып, анкеталар тутырып киткән иде. Бүген сөенечле хәбәр белән килде:

— Шул урынга бер тоткарлыксыз сине үткәрделәр,— диде. Ул Ваһапов өчен шатланган иде, ә Ваһапов исә дымык кына елмайды. Теге аны дәртләндерергә теләгәндәй, иңенә учы белән чәбәкләп:

— Курыкма, үкенмәссең!— дип әйтергә кирәк тапты.— Госпитальдән чыгуың турында бухгалтериягә әйтеп куй, шушы айның азагында диген...

Капитан, һаман канәгать елмайган килеш, тез башларын учы белән чәбәкләп алды да китәргә кузгалды.

Димәк, артка юл юк, дип уфтанды Ваһапов ул ишекне япкач. Ниндидер ачы ут эчне пошыра башлады. Нәрсәдер өзелеп кала, нәрсәдер бик җәл. Берничек тә кире кайтарып алып булмый торган. Менә шулай йөрәкне учка кысып тотып китәргә туры килә.

Китүне Фира Касыймовнага да белгертмәскә кирәк. Ә ул палатага

теләсә кайчан килеп керә. Шуңа күрә сестра-хозяйка белән сөйләшеп, юл капчыгын аның бүлмәсендә генә тотты, палатада бөтенләй күрсәтмәде. Аның китүен палатадагылар киткән мәлдә генә белсеннәр. Берни сиздерергә ярамый.

— Иптәш замполит, нишләргә, кая барырга?— дип Әнвәр ах-ух килә.— Тегеләйгә барсам да — стена, болайга барсам да! Сезнең берәр танышыгыз юкмы, ичмаса?— ди-ди өзгәләнә. Ваһаповның кәефе начар, зиһене таралган чак иде. Ныклы гына итеп әйтте:

— Беркемнең дә ярдәменә, булышлыгына исәп тотма, үзең тырыштырмаш,— диде.— Тормыш, күрәсеңме, нинди авыр, һәркем үзен генә кайгыртырга мәҗбүр. Кемнең дә булса булышуын өмет иткән уйларыңны башыңнан чыгарып ат! Үзең казган, үзең иреш, тир түк, көч сарыф ит! Бүтәннәргә исәп тотма, үзеңнең башыңа һәм йөрәгеңә генә таян!

Әнвәр башын ике учына алып уйга калды. Ваһапов аның әле бик яшь икәнен күреп:

— Сиңа укырга кирәк,— диде.— Менә мин дә унынчы класс өчен имтихан тапшырырга уйлыйм. Үзеңне-үзең агартмасаң, беркем дә килеп агартмас.

— Сез тиздән чыга торгансыздыр?— дип кызыксынды Әнвәр.

— Культя бик сызлый әле,— диде Ваһапов, чыраен сытып. Культясын ике учына кысып алды да, басып-басып уарга, изәргә тотынды.

## 4

Курс тәмамланып килә иде. Укучы яралылар нинди дәрт белән көне буе чарт-чорт чут салып утыра. Имтиханга баланс әзерлиләр. Тизрәк кулга кәгазь алырга да җылы вакытта туган өйләргә кайтып өлгерергә кирәк. Кулында бер таныклык булу таяныч ул. Бигрәк тә бер «таянычын» җуйган кешеләргә. Кая барсаң да иң элек кәгазь сорыйлар. Турганов: «Бер кәгазьсез син мәгънәсез», дип җибәрә. Ул тормышның үзе татып белә башлады. Теге «операция» барып чыкмагач, Тукай урамында нинди кеше почмагы табып, шунда кучте. Әшендә дә бер гөрләвек шикелле үзенә юл ерып, җай алган сыман күренә.

Әнвәр дә баланс белән утыра. Бер тиенгә генә хата китсә дә, баланс тигез килеп чыкмый иде. Ә аны болай гына төзәтеп куеп булмый. Бер тиенне эзләргә, табарга кирәк. Эшнең башлангычына кире кайтып. Дебеттамы ялгыш, кредиттамы? Бу кай ягы беләндер кешенең язмыш тактасына язылып бара торган савап, гөнаһны хәтерләтә. Дебет — саваплы эшләрең, кредит — начарлыкларың. Үткәндә кылган кырын эшләреңне, кире кайтып, төзәтеп булмый. Кешедә андый кодрәт юк. Ул элеккеге ялгышлары өчен хәзергесе белән түли генә ала. Үз балансын кеше шулай гына тигезләп бара. Ничек кенә булмасын, кеше тормышында күзгә күренми торган баланс яши.

Шимбә көн кич булып килгәндә Әнвәр янына Ваһапов килеп керде. Үзен танырлык та түгел: протез кигән, чын аяклы кеше кебек. Тулы хәрби формадан. Майор погоны да өр-яңа, елкылдап тора. Мундиры да яңа, яшькелт габардиннан. Хром итекләр дә көзге кебек.

— Әйдә Фира Касыймовналарга барып киләбез. Ася да шунда булачак!— диде ул кинәттән генә.

Әнвәр аңа томырылып карады һәм аңлады. Тыңламасаң, Ваһаповның кәефе кырылачак иде. Әнвәр тиз генә үзенең простойдан тегелгән киемнәрен киде. Майорга ияргәч, аны капкада да тоткарламадылар. Эчтән генә Асяны күрәчәгенә сөенә иде. Хәзер ничек икән ул? Мине танырмы икән? Аңа иң элек нинди сүз белән дәшергә? Кулын кысканда, мин сиңа мәңге бурычлымын, Ася!— дияргәме? Син коткарып калмасаң, мин күптән җир астында булган булыр идем, рәхмәт, дип такылдаргамы? Мондый сүзләрне ул бик күп ишеткәндер. Аңа берәр бүләк

бирсәң иде, ләкин Әнвәрнең коры сүзләрдән һәм Асяны апасы кебек итеп яраткан йөрәгеннән башка бернәрсәсе дә юк шул! Аннары Ася бит хәзер кеше кешесе булган инде, аңарда бүтән, яңа исәпләр, яңа мәшәкатьләрдер? Апаң кияүгә чыкса, син аңа нәрсә генә сөйли аласың? Элеккеге дуслык ни беләндер алышынган, апаң чикнең теге ягында, ә син бу ягында. Чикне үтеп чыгып булмый... Мин үземне хәзер ничек тотарга тиеш соң? Мин тупас, чапмаган-юнмаган авыл тумасы, уңайсызланып кызара гына алам. Авызымнан сүзләрне этеп чыгарырга ихтыярым җитсә ярый әле. Анысы да икеле. Каушап сүзләремне онытырмын да күзле бүкән булып калырмын? Киркәкле сүзне әйтә алмаганыма үлә-үлә үкенермен. Мин бары үкенергә генә оста...

Горняктан икенче трамвайга эләгеп киттеләр. Трамвай кольцодан университетка таба сөзәк таудан бик авырлык белән күтәрелде. Ак колонналарны узганда гына тизләтте. Цирк тукталышында төшкәч, Черек күл буеннан атладылар. Күлдә әле язгы су җәйрәп ята, шактый тирән күренә иде. Малай-шалай суга таш атып шаяра. Ваһапов протезда әйбәт кенә йөри икән. Культясы озын, тез тиңентен, шуңа шактый кыю адымлый. Әнвәр исә култык таягы белән булса да, җиңел гәүдәле командирдан калышмаска тырыша. Ул аның йөзенә карап-карап ала, ләкин берни дә күрми. Ваһаповның йөзе бер нәрсә дә әйтми. Ни өчен ул аны Ася янына бүген генә алып барырга булды әле? Ася үзе сорады микән? Ася безнең санитар эшелонының Казанга кайтасын белеп калган иде. Үзе кызыксынганмы? Исәнме икән, үлде микән, дигәндер. Ул минем исән калуыма ышанмагандыр, тыштан белгертмәсә дә, эчтән уена шундый фикер килгәндер. Мин бик начар идем бит. Мин үлмәдем, Ася, дияргәме? Хәзер Ася алдында мин ихтыярсыздан елап җибәрермен шикелле. Ә ничек түзәргә, ничек ташка әйләнергә? Җебегәнлекне күрсәтмәскә иде, ичмаса.

Зур Кызыл урамы белән баргач, уң яктагы өч катлы таш йорт ишегалдына килеп керделәр. Икесе дә шабыр тиргә баткан иде. Хәл алып торырга туры килде.

Киң баскыч икенче катка алып менде. Баскычның ике ягында озын коридор буенча як-якта бүлмә ишекләре. Кайсы капчык-киндер белән тышланган. Кайсы иске киемнәр белән, кайсында шома дермантин җиз башлы кадаклары белән ялтырый. Ишегенә карап, кемнең ничек яшәгәнен чамаларга була. Әмма кайберәүләр тыштан ялтырырга ярата. Арырак үткәндә уртак кухня күзгә чалынды. Кечкенә өстәлләр тезелгән, һәр өстәлдә примус. Бер су краны бар икән. Әнвәр дә Турганов тәэсирендә мондый нәрсәләргә игътибар итә башлады.

Ваһапов бер ишекне тартып карады, бикле иде. Ул бераз торды да кухняга китте. Ася шунда пешеренеп маташмыймы? Ваһапов, гаепле көлемсерәгән килеш, протезы белән идәнгә дең-дең басып, кире килде. Шул мәл каршы яктагы дермантин ишектән Фира Касыймовна килеп чыкты. Әнвәр ни уйларга белмичә торганда, ул Ваһаповны күрүенә сөенеп, елмая иде.

— Рәүф, Ася шалтыратты,— диде мамык тавыш белән.— Өчдүрт сәгатьсез кайта алмый, ашыгыч операциягә калдырганнар...

— Әй,— дип куйды Ваһапов, Ася белән горурлангандай,— аның шул инде, бер дә баш тарта белмәс...

— Медиклар шулай, Рәүф, әйдәгез, безгә керегез. Тавил дә өйдә...— Фира Касыймовна ишекне ачты, Ваһапов Әнвәргә күз сирпеп алды, әйдә, дигән сүзе иде. Керделәр. Зур тәрәзәле якты бүлмә. Анда тагы бер бүлмә бар бугай. Ишегендә яшькелт бәрхет чаршаулар. Аларны уртадагы чәчәкле клеенка җәйгән өстәл артына утырттылар. Тегендәрәк күн тышлы диван һәм кара чия төсенә буялган нәкыш бизәкле, пыялалы шкафлар. Берсенә чынаяк-савыт тезеп куелган.

— Хәзер чәй эчәрбез,— дип Фира Касыймовна тиз-тиз йөренә башлады. Ул шоколад төсле күлмәктән, алкалары кечкенә бер ут төене кебек

чаткыланып янып тора. Шунда теге як бүлмәдән чәчен тарак белән тигезли-тигезли хуҗа чыкты. Ак күлмәктән, галстуктан. Уртачадан биеграк буйлы, озынча йөзле, таза муенлы. Бу кыю кыяфәтле кеше иде. Йөзеннән шул сизелә. Әнвәр аны изоляторда ятканда еш күрде. Ул хәл эчендәге абыйсын саклап төн куна иде. Үзенекен итә торган ир-егет. Әнә Фира Касыймовнаны да эләктергән. Төеп тутыргандай тыгыз гәүдәсенә караганда, аның каршылыгын тиз сындыргандыр. Ләкин ул Алексей Егорычны алыштыра алды микән? Ничектер комбат өчен Әнвәрнең йөрәге сулкылдап куйды. Фира Касыймовна аны искә алгалый микән? Юк, бөтенләй онытa алмас ул, әнә бит күз төпләренә ниндидер моңсулык яткан. Юкка гына түгел ул.

Хуҗа шкафтан кызыл балык алып озынча металл тәлинкаләргә турап куйды. Фужерлар алып тезде. Хуҗабикә ике коштабакка өеп тутырылган йөзе килгән кызгылт пәрәмәчләр кертте. Аңа бер кыз да булышып йөри иде, ул графин белән саргылт төстәге сыра китерде. Яшел чәйнек белән чәй һәм чынаяклар да килеп утырды. Кемгә сыра, кемгә чәй салдылар. Кунакларны кыстадылар. Бигрәк тә Фира Касыймовна кыстый иде. Әнвәр аның фронтта, Алексей Егорыч янында булган чагын исенә төшерде. Анда да ул шулай кунакчыл иде. Бер нәрсәсен дә кызганмый торган иде. Тик Алексей Егорыч тегендә бетте, ә без монда исәннәр. Ниндидер гаделсезлек бар. Өстә гаеп тора шикелле. Дөнья тигез түгел шул! Ә бит Алексей Егорыч алтын кеше иде! Әх, мәнә ни эшли аласың!?

Пәрәмәч, эчәге-үпкәдән булса да, бик тәмле иде. Чәй белән әйбәт үтте. Әнвәр башы авыртканга сыра эчмәде. Хуҗабикә аны кыстады, теге кыз да тәлинкәсенә пәрәмәчләр өстәп торды.

Табында русча гына сөйләшәләр иде. Фира Касыймовна татарчаны начар белә кебек. Бәлки, шулай күнеккәндер. Тавилнең сөйләшүендә татар акценты сизелә. Шулай да шома сукалый. Сүз нишләптер тимер юлда поездлар йөреше хакында барды. Әллә хуҗа кеше Тавил шунда эшлиме? Бәлки шулайдыр? Пассажир составлары йөри башлаган диләр. Билет мәсьәләсе авыр икән әле. Немец талап, яндырып бетереп киткән җирләргә эшелон-эшелон ат, сыер җибәрәләр. Ул яктан тимер-томыр кайта, ә бу яктан мал-туар китә. Юл турындагы сүзләр Ваһаповка карап сөйләнә иде. Ул кая булса да сәфәр чыгарга җыена шикелле аңлашыла иде. Әнвәр моңа игътибар итте. Аннары кәефе күтәренке Тавил яңарак чыккан мәзәк сөйләде. Үзе сөйләгәненнән үзе пырх-пырх көлә иде. Имеш, яшь кенә хатын ирен ачулана: «Сиңа чыкканчы бер шайтанга чыксам, йөз мәртәбә әйбәтрәк булган булыр иде»,— ди. «Юк шул,— ди ире,— булмый, якын туганнарның бер-берсе белән никахлашуы закон буенча тыела. Шайтанга чыга алмас идең, чөнки...»

Теге саргылт чәчле кыз пырхылдап көлеп җибәрде. Аның көлүе ничектер хуҗаларга ошарга тырышудан кебек иде. Бәлки мәзәкнең мәгънәсе аңа кызык тоелгандыр? Тавил барысыннан да ныграк көлә иде. Фира Касыймовна ирен очлары белән генә елмайды. Ваһаповның да йөзенә җылылык нурлары чыкты, эчтән яктырды. Нәрсәдер исенә төшергән сыман иде. Ул да нәрсәдер сөйләр дип көттеләр. Ләкин Ваһапов тиз генә кузгала торган түгел. Хуҗа тагы сүз алды. Имеш, бер хатын врачка каралырга барган. Башы еш авырткалый икән. Врач аның хәлен бәйнәбәйнә сорашып бетергәч, сорап куйган: «Сез ирегезне алдаштырмыйсызмы?» — дигән. Хатын уйлап тормастан: «Әлбәттә, алдаштырам инде, иң якын кешем шул бит»,— дип әйтеп алган, ди. Монысында көлүче дә булмады, мәгънәсе барып җитмәде, әмма Тавил үзе көлеп рәхәтләнде. Ул кунакларга күңелле булсын дип тә көлгәндер инде.

Теге якта телефон шылтырады, хуҗа тиз генә торып, шунда атылды. Аннан нигәдер җитдиләнеп килде. Фира Касыймовна сәгатенә карап алды. Матур кашлары маңгаенарак менде.

— Альфредларга соңга калмыйк, ул шылтыраттымы? — дип кузгала башлады. Үзе Ваһаповка караган иде. Тавил дә майорга төбәлде.

— Бигайбә, зинһар, иптәш майор,— диде һәм көзге алдында торган хуҗабикәгә ымлады.— Бармасаң, үпкәли башлыйлар...

Теге якка таба атлады. Фира Касыймовна Ваһапов янына килде.

— Ася кайтканчы торып торыгыз, Рәүф, ә?

— Кайтыр микән соң?— Ваһапов мөлаемләнеп китте. Асяга кагылышлы сүз, эш булганда ул ничектер үзгәреп, йомыклыгыннан чыгып ала иде.

Фира Касыймовна көзге алдында чәчләрен рәтли-рәтли, теге кызга эшләр куша иде.

— Зәлия, кунакларны скучать иттермә, яме. Без соңга калмабыз. Әнә патефонны куеп җибәр. Яңа пластинкалар бар. Альбомны карарга мөмкин...— Ул кечкенә түгәрәк көзге алып, битенә нәрсәләрдер сөртте, ышкыды. Тавил теге яктан хром пальто, велюр эшләпә киеп чыкты. Кулында хуҗабикәнең күгелҗем төстәге габардин пальтосы иде. Нинди дер горурлык, рәхәтлек белән ул аны Фирага кигерде. Хуҗабикә ашыга-ашыга ридикюлен кулына алды һәм ишеккә атлады. Алар чыгып киткәч, Әнвәр Ваһаповка карады. Әүвәлгечә йөзеннән берни дә чамалай алмады. Ася кайтырмы икән соң? Зәлия табынны җыеп бетерә иде. Ваһапов протезын шыгырдатып урыныннан торды. Озак кына аны җайлап маташты. Аның җыенуын күреп, Әнвәр дә таягына тотынды.

— Син, Фазлыев, утырып тор,— диде Ваһапов гадәтенчә ипле тавыш белән.— Мин Ася янына барам. Бәлки алып та кайтырмын.

Аның сүзләрен хуҗа урынына калган кыз да ишетте, шулай да берни әйтмәде. Әнвәр дә аптырап тора иде. Монда калыргамы аңа, юкмы? Ваһапов кулын түбәнгә селтәде, янәсе, кымшанма. Әмергә өйрәнгән солдат шунда ук тынып калды. Ваһапов протезлы аягын алып сала-сала чыгып китте. Әнвәр уңайсызлык кичерә иде. Шунда Тургановның сүзләре исенә килде: «Син ашыгучан, шуның белән оттырасың кебек, чыдам булырга өйрән»,— диган иде ул. Әнвәр сабыр гына дәшми утырды. Асяны күрмичә китәсе дә килми иде.

Зәлия патефон алып чыкты. Капкачын ачып, «колагын» борды. Түгәрәге өстендә пластинкасы бар иде, әйләнә башлагач, инәсен кырый эзгә куйды. Гаҗәп матур авазлар агыла башлады. Бу бик танылган «Өч шаһит» дигән көй иде... Без очрашканда өч шаһит булды. Куакта сандугач сайрады, ак каен шәм кебек якты сипте, чишмә чылтырап-чылтырап акты... Сугыш килде дә барысын бетереп ташлады... Аннары татарча пластинкалар китте. Гөлсем Сөләйманова «Кәккүк»не җырлый иде.

— Гөлсем апа моннан ерак түгел генә тора,— дип куйды Зәлия, теге җырлап бетергәч, мөһим нәрсә хакында әйткәндәй. Атаклы кешене күргән булуы белән ничектер горурлана кебек иде.Әнвәр шәһәр кешесенең сәер бер сыйфатын белде: ул күренекле бер затны белүе белән мактанып, масаеп сөйләүчән. Ерактан гына күреп калса да, без аның белән бер мәҗлестә утырдык, фәлән-төгән дип шыпырынырга ярата. Шунда ук озын колактан ишеткән теге күренекле зат хакындагы гайбәтне дә үзе күргән, үзенең күз алдында булган хәл итеп сиптерә генә. Моны авылдан килеп шәһәрдә калган кешеләрдә күзәтергә була. Шәһәр кешесе дигән исемне алу өчен әллә бу кирәкле шартмы? Бу кызны да шул хис тырыштырамы?

Әнвәр кызлардан курка иде. Хәзер дә ул тотлыгырмын дип бер сүз әйтергә кыймый утыра. Ә Зәлия болай ягымлы гына, тәбәнәгрәк тыгыз гәүдәле, коңгырт чәчле, эре җепселле чәчләре агып төшеп битен яртылаш каплаган. Бу аңа аеруча килешеп тора шикелле. Кызның тагы әйтеп биреп булмый торган күркәмлеге бар. Әнвәр тәмам югалып кала язды. Ул үзенең кимчелеген хатын-кызлар янында ныграк тоя, шуның ачысын күбрәк кичерә. Яшь чакта үзеңнең тиң түгеллегеңне тоюдан да әрнүлерәк нәрсә бармы икән? Кызлар белән аның арасында тирән чокыр. Син чокырның бу ягында, ә ул теге ягында. Кызлар егетләрдә таяныч-терәк эзли. Әнвәр хәзер кемгә нинди таяныч була алсын инде? Юк, бу хакта

уйламаска, уйламаска кирәк! Барыбер берни дә үзгәрми бит, нигә юкка баш ватарга? Ник үзеңне-үзең кайнарга? Әнвәр күңелсез уйларны үзеннән куып җибәрде һәм кыз пластинка алыштырганда күтәрелеп карады.

— Син әллә Фира Касыймовнаның туганымы?

Шуннан сүз ялганып китте. Зәлия моннан ел ярым элек кенә авылдан килгән икән. Вербовка белән. Төзелешкә. Соцгородта завод корпусы салу эшендә эшләгән. Үзе шушы коридордагы бер карчыкта яшәгән. Ләкин кайтып-килеп йөрү бик кыен булган. Зәлия караңгыдан курка икән. Икенче сменадан кайтканда караңгыда исерек егетләр бәйләнгәләгән. Берсендә тәмам харап итә язганда, кешеләр килеп чыгып, коткарган. Шуннан Фира Касыймовна аны Островский урамындагы тегү остаханәсенә урнаштырган икән... Кыз, горурланыбрак, эти колхозда келәтче булып тора, дип куйды.

— Келәтче?— диде Әнвәр кызны үсендергән тавыш белән.— Алайса ышанычлы кеше икән?

— Ничек ышанычлы?— Зәлиянең кашлары матур бөгелгәләде.

— Колхозның ышанычлы кешесе икән дим.— Әнвәр: бай кешесе, дип әйтмәкче булган иде, сүзләре шулай чыкты.

— Нигә, кешеләр ышанычсыз да буламыни?

— Колхоз келәтен теләсә кемгә тапшырып булмый, билгеле.

— Тик минем әти бик аз сөйләшә. Көненә бер-ике сүз әйтә микән?

— Аз сүзле кеше ышанычлы була,— дип раслагандай әйтте Әнвәр. Үзенең бик үк төшеп калган түгел икәнен белгертәсе килгәнгә охшый иде.

— Ничек алай? Ул әни белән дә юньләп сөйләшми. «Кабып» кайтса гына өч-дүрт сүз әйтә. Синең этиең ышанычлы түгелмени?

— Юк,— диде Әнвәр.— Ул күп сөйләргә ярата иде.

— Күп сөйләшкән ышанычсыз буламыни? Аңлашылмый.

— Күп сөйләүче кирәкмәгән сүзләр ычкындыра.

— Ә-ә,— диде Зәлия, битенә сибелгән чәчләрен артка этәреп.— Ул яктан әйтәсең икән...

— Ышанычка лаек кеше булу бәхет ул,— дип көрсенде Әнвәр.

— Ә синең этиең ник шулай түгел?

— Әйтәм бит, лыгырдарга ярата иде дип.

— Шул гадәтен бетерә алмадымы?— Зәлиянең тавышында беркатлылык чагылып китә иде. Әллә шулай булып кылана гынамы ул? Ничектер маңгай астыннан гына күзен кысып карап алуында әчке бер хәйлә бар сыман тоелып кала.

— Гадәтне ничек бетерәсең? Без авыл кешеләре. Ул аны аңламагандыр да әле.

— Үзенең күп сөйләүче икәненме?

— Әйе. Начар гадәте барын. Аңласаң да гадәтне бетереп булмыйдыр?

— Нигә бетереп булмасын?

— Менә бетереп кара берәр начар гадәтеңне!— Әнвәрнең болай катгый әйтүенә кыз тиз генә җавап таба алмады. Һәм шуның өчен елмайды.

Әнвәр үзеннән ярыйсы гына сүзләр чыкканга бераз иркенәебрәк китте. Чирканчык алган шикелләрәк булды. Кызның да йомыклыгы языла төште кебек. Патефонның ак көмеш «колагын» борганда хәрәкәте дә кыюрак була бара иде.

Пластинкалар уйналып беткәч, Зәлия ике кулын өскә күтәреп, чәчләрен рәтләштереп алды. Сүзсез тору уңайсыз иде. Шул уңайсызлыктан чыгу өчен генә:

— Сезнең елгылар сугышка кермәделәр түгелме соң?— дип куйды. Йөнтәс керфекле күзләрен Әнвәргә сирпеп алды.— Безнең авылдан киткән егерме алтынчылар берсе дә сугышка элəкмәде.

— Бездән дә эләкмәүчеләр булды,— диде Әнвәр.

— Нигә алай соң ул?

— Белмим. Язмыштыр инде. Дөнья бер кешене үз итә, икенчене үги итә.

— Ә сине язмыш үз итәме, үги итәме?

— Әйтә алмыйм, ничектер. Моңарчы үз итә иде кебек.

— Үз итсен инде, үги итсә начар...

Теге якта телефон шылтырады, Зәлия шунда ашыкты. Әнвәр, уйланып торгач, кузгалды. Вакыт шактый булгандыр инде. Ваһапов белән Ася кайта алмадылар, ахрысы. Операция ул тиз генә бетәмени? Зәлия әйләнеп кергәндә ул ишек төбендә иде.

— Китәсеңмени?— диде кыз һәм кыстап бер сүз дә әйтмәде.

— Отбойга соңга калмагаем.

— Тагы кил,— диде кыз күңел өчен генә. Аның әдәп саклап әйтүе тавышының төссезлегеннән беленеп калды. Шулай да Әнвәр үзенең хәлен аңлап, кимсенмәде, рәнҗемәде. Тагы да әрсезрәк булырга кирәк дигән нәтиҗәгә килде. Әмма Асяны күреп булмавына эчтән үртәлде. Кемгәдер ачуы килде. Үз язмышын каргады, бәгыре телгәләнде. Кайтып яткач та йоклый алмады, төне буе талауланып чыкты.

Шулай да эш арасында теге кыз Әнвәрнең уйларына килеп чорналгалый башлады. Нилектән? Күңеленең шулай уйлыйсы килә, ахрысы? Әмма бер өмет чаткысы да юк бит. Бары ниндидер өметсез теләк кенә бар. Теләк бар, ә мөмкинлекләрең юк. Теләк белән генә яшәп булмый. Хатынкыз бит ул иң элек мөмкинлекләреңә карый һәм дөрес итә дә. Аларга дебет кирәк. Ә синең дебетың юк дәрәҗәсендә. Теләгең дә шул реаль хәлеңнән чыгарга тиеш. Таза-сау, нормаль кыз аяксыздан ояла ул, аның үзен кимсетәсе килми. Үзен түбән төшерергә һич тә теләмәс. Моның өчен аны тамчы да гаепләп булмый. Димәк, үзең кебек түбәнрәк дәрәҗәлене карарга туры килә инде?

Әнвәр яздан бирле госпиталь бакчасындагы зур каен башына оялаган каргаларны күзәтә. Монда ана карга баш икән. Ата каргага эш кушып кына тора. «Бар, ояга чыбык-чабык ташы!» Башына берне чукып ала. «Бар, оя төбенә җәяргә йон-мамык ише нәрсә табып китер». Башына томшыгы белән чүки! «Күкәйләргә җил тимәсен! Бар...» Тагы башына тук! Балалары чыккач та ата каргага бер минут вакыт бирми, азык ташырга куып кына тора. «Бар, бар! Кар! Кар!» Ата карга шундый тыңлаучан икән, гаҗәпкә калырлык. Ана карганың бөтен боерыкларын бер тайпылышсыз үтәп торган көне. Гыйбрәтле хәл...

Нинди генә өтелеп беткән булсаң да, йөрәк ашкынып яшәргә омтыла. Таза, бөтен чагыңдагы кебек. Бу үз хәлеңне аңлап җитмәүдәнме? Әллә күкрәгеңдә калган яшәү көчеңнәнме? Һаман югарыга таба күз төбисең, бер дә түбәнгә карарга теләмисең. Дөнья шундый матур ымсындыргыч булып тоела. Врачлар, шәфкать туташлары, нянялар... Нинди әйбәтләр алар! Бер риясызлар, ихлас күңелләләр! Һәр кеше, аның холкы кызыклы! Күз карашы, сөйләшүе, елмаюы — бүләк! Шуңа күрәдер инде, «Кеше җирдә иң кыйммәтле капитал,— дип сөйли Михаил Аркадьевич.— һәрбер кеше кояш кебек,— ди.— Һәр адәм баласында кояш сыйфатлары бар икән. Ул синең тормышың өчен үзенең җылысын кызганмый, көчен-куәтен җәлләми бирә. Син аңа һәрчак рәхмәтле булырга тиеш. Дөньяда кешедән дә әйбәтрәк, акыллырак, миһербанлырак бернәрсә дә юк», ди. Шулаймы икән соң? дип уйга кала Әнвәр. Алайса кешеләр нигә бер-берләрен үтерә? Моңа аларны ни мәҗбүр итә? Нигә кешеләр бер-берсенә әшәкелек кыла? Юк, кешеләр бик катлаулы, четерекле затлар. Үзләре теләмәгән нәрсәләрне дә эшлиләр.

Булачак бухгалтерларны укытучылары Татьяна Владимировна арифмометр дигән прибор белән эшләргә өйрәтү өчен уку комбинатына алып килде. Комбинат Арча кырындагы паркка каршы салынган элеккеге бер зур бинада иде. Шушы ук бинада республиканың партия мәктәбе

дә урнашкан икән. Бакчасында райком тирәсендә күрергә мөмкин булган күе зәңгәр китель һәм галифе чалбар кигән курсантлар җиңел кулдан эшләнгән өстәлләрдә укып-язып утыра иде. Офицер киеменнән булганнары да күзгә чалына. Болар әле генә сугыштан кайткан кешеләр, ахры.

Калын чуен баскычтан күтәрелделәр. Зур гына бер бүлмә. Парта кебек тар өстәлләр тезелгән, аларга арифмометрлар куелган. Тышкы яктан әзрәк тегү машинасын хәтерләтә, ләкин аңардан кечерәк прибор. Татьяна Владимировна арифмометрның төзелешен бер-ике сүз белән аңлата. Тимер калпак эченә саннар язылган дисклар һәм барабаннар куелган. Шуларны берничә рычаг ярдәмендә дөрес хәрәкәт иттерсәң, үзеңә кирәкле исәп-хисапны эшләтергә мөмкин. Кушу, алу, тапкырлау, бүлү.

— Прибор төгәл эшли, ялгышмый,— ди Татьяна Владимировна.

— Кеше ялгышырга мөмкин, ә машина кечкенә булса да ялгышмый. Димәк, машина кешедән акыллырак?— дип сорый укытучының хатасын тотарга яраткан яралы.

— Әйе, акыллырак!— ди Татьяна Владимировна бер дә исе китмичә. Арифмометр белән ничек эш итәргә кирәклеген үзе күрсәтеп бетергәч, яралыларга мәсьәләләр биреп чыкты. Бер мәсьәлә,ике, өч... Яралылар тырт-тырт итеп приборның рычагларын күчерделәр, барабанын әйләндерделәр. Кушарга, алырга, процент чыгарырга өйрәнделәр. Бик ансат һәм тиз эшләнә. Чут салып азапланасы түгел. Мәсьәләләрне дөрес чишкән укучыларны Татьяна Владимировна кайтарып җибәрә торды. Әнвәр дә, эшен төгәл үтәп, шулар белән бергә чыкты.

Ул, иптәшләреннән калып, бакчада берәз утырып торырга уйлады. Башы бик авырайган иде. Җайлырак эскәмия эзләп агачлар арасына китте. Кырыйдагы сукмактан кемдер килә иде, аны күреп, туктап калды. Әнвәргә төбәлгән иде. Шул карашны тоеп, Әнвәр дә туктады.

— Фазлыев дисәм... ммм?— дип сузды теге кеше. Зәңгәрсу төстәге кительдән, галифе чалбардан, мөлаем йөзле. Ләкин Әнвәр аны танымады, ялгышадыр дип уйлады һәм үзенең фамилиясен ишеткәнгә күрә генә, «әйе» диде.

— Мине танымыйсыңмы?— Теге аңа таба якыная иде.

— Кайдадыр күргән кук булам...

— Сезнең колхозда даими вәкил Хәлдәмовны оныттыңмыни?

— Ә-ә, әйе, хәтерләдем, Хәлдәмов абый!— диде Әнвәр нәрсәгәдер сөенгәндәй. Ләкин үзе һаман текәлеп тора иде әле. Вәкил бик үзгәргән икән. Кул бирешеп күрештеләр. Эскәмиягә утырдылар. Хәлдәмов аңа бер ригая белән караган шикелле иде. Күңелендә Әнвәргә карата хәерхаһлык тойгысы уянганга охшый.

— Партшколада укыйм.— Ул бинага ымлады һәм ничектер уңайсызланыбрак Әнвәрнең култык таякларын күздән кичерде. Әнвәр аңлыйм дигәндәй ияк какты, партия эшендә эшләгән кешене биредә очрату бер дә гаҗәп түгел иде.

— Без дә практикага килгән идек.— Әнвәрнең тавышы сүренке иде һәм ул үзенең госпитальдә ятуын, анда бухгалтерлар курсында укып маташуын бер-ике сүз белән әйтеп бирде.

— Шулай диген, һе.— Хәлдәмовка Әнвәр белән сөйләшү ничектер кыен иде кебек. Ул үзе фронтта булмаганга уңайсызлык сизә булыр. «Кайсы фронтта булдың, ничек?»— дип тә сорашмады.

— Укыйм диген? Молодец!— диде ул сөйләргә сүз тапканына сөенгәндәй.— Хәтерлим. Син колхозда да бик тырыш идең. Ну эшләп карадың! Көндез сабанда, төнлә көлтә ташуда. Синең кебек числыклы егетләр күп түгел. Бер дә хәрәмләшмәдең. Исеңдәме, ашлык суккан кыр сташында бер кыш буе көшел саклап каравыл тордың һәм бер бөртек тә алмадың. Ичмаса тавыкка бөртекле кибәк тә алып кайтмадың. Ә ат куучы Тәкый бүреге эченә тутырып чәлә иде. Барганда бүрегеннән бите дә күренми, кайтканда бүреге түбәсендә биек булып утыра иде, колакчын-

нарын өстәмә җеп белән тарттырып бәйли. Өендә кул тегермәне бар. Эре генә он чыгара. Катламага ярый. Балалары күп иде, шуңа аны күрмәдек. Югыйсә сизгерлектә бик тырышучылар булды. Теге ябык атлар белән булган эшең исеңдәдер. Сәвәләев зурга җибәрмәкче иде, минкирәкмәс дидем. Ә фронтка киткәндә сине җыелышта ике пот бодай оны һәм биш кило бал белән бүләкләдек, хәтерлисеңдер?

— Рәхмәт инде, хәтерлим, хәтерлим,— дип Әнвәр аңа чын күңелдән яктырып карады.

— Әйе, хәлләр,— дип үкенүле итеп әйтте Хәлдәмов сөйләр сүзе беткәндәй.— Мин фронтка китәргә әллә ничә гариза яздым, җибәрмәделәр.

— Җибәрмәүләре әйбәт булган!— Әнвәр аның күңеленә ятышлы сүз әйтергә тели иде.

— Бер яктан әйбәт кебек, ләкин икенче яктан,— ул йөрәк турына учын куеп алды.— Менә монда әйбәт түгел! Намус үртәлә. Бу инде эш узгач борчылу анысы.

Хәлдәмов тынып калды. Карашын читкәрәк алды. Әнвәрнең дә сүзе юк иде. Аңардан берни дә сорашмады, сүзләр ничектер күңелсез хәлләргә китереп чыгарыр дип курыккан кебек иде. Икесе берьюлы кузгалдылар. Һәркем үз сукмагы белән китәргә тиеш иде.

— Менә укыйсың икән, бу да икмәк, молодец!— дип ул һаман Әнвәрнең күңелен күтәрәсе килеп сөйләнде.— Югалып калма. Яшәү кызык ул! Әгәр берәр гозерең-фәләнең булса, минем янга кил.

Кайтканда Әнвәр теге атлар белән булган хәлне исенә төшерде. Ул язны аңа сабанга иң бетәшкән атларны биргәннәр иде. Бөтенесе баш тарткан атларны. Сыртлары кылыч кебек булып тора, янбаш сөякләренә әйбер элеп куярлык. Сабанны өстерәтеп басуга килеп җиткәч, тагы да аянычрак хәл беленде: атлар икесе дә буразнадан йөри белми иде. Төпкә җиккән ат буразнадан йөрергә тиеш, юкса җир сөреп булмый. Аны буразнадан йөртергә өйрәтү өчен каты чыбыркы хаҗәт. Ул гына җитми, атка җәлләми сугарга да кирәк. Әнвәрнең өйрәткәнне күргәне бар: «Буразна!»— дип бик каты кычкырасың һәм каеш чыбыркы белән бик нык итеп атка сугасың. Өч-дүрт көн шулай кыйнап өйрәтергә туры килә. Кайбер акыллы атлар шул өч-дүрт көн эчендә өйрәнә, чыбыркы ашамый башлый. Акыллы ат белән җайлы. Менә болар кебек ахмак атларны һич тә өйрәтеп булмый инде. Әнвәр аңлады: мондый эш аның кулыннан килми. Иң мөһиме шунда: ул атларга суга алмый иде. Чыбыркысы әйбәт булса да, бу коры сөякләрне кыйнарга аның кулы күтәрелми инде, юк. Әнвәр дүрт көн газапланды. Нишләргә белмичә сабанына утыра иде дә, еларга җитешеп, кайгыра иде. Бригадир килә дә, «норма үтәмисең» дип ачулана. Нишләргә? Бишенче көнне иртән Әнвәр сабанга барудан баш тартты. Бүтән атлар бирсәгез генә барам, диде. Шуны гына көтеп торгандай, аны элеп кенә алдылар. Башта бригадир, аннан — агитатор. Бу укытучы хатын усал ачы телле иде, каты тотынды: «Син колхозны яратмыйсың!»— дип йөрәккә тиярлек сүз әйтте. «Ул атлар белән үзең сөр, аларны үзең кыйна!»— диде Әнвәр ни дип җавап бирергә белмәгәч. Хатын тагы: «Синең әтиең теге сугышта немецларга болай гына плен төшмәгән!?»— дип ычкындырды. Әнвәр рәнҗеде: «Син лыгырдап йөргәнче үзең эшләп кара колхозда, үзең чиләп!» Ул арада «вәкил чакырта» дип идарәдән бер куштан менде... Идарә йортының клуб белән тоташкан өлешендә эчкәрге бүлмә бар иде. Куштан Әнвәрне шунда алып керде. Ишекне ачып бик каты эчкәре төртеп җибәрде. Әнвәр урындыкка тезе белән килеп бәрелде. Авырту ачысыннан күзләре юешләнгән иде. Шкаф артыннан Хәлдәмов килеп чыкты. «Менә колхозны яратмаучы саботажник!»— диде куштан. Хәлдәмов тыныч кына карап тора иде. Куштан өстәл артына утырып, кәгазь-каләм алды. «Ник эшкә чыкмыйсың?»— дип дәште Хәлдәмов. Әнвәр өзек-төтек сөйләп бирде. «Атларны кыйный алмыйм, нишлим?»— дип сүзен бетерде. «Алдыйсың!»— дип кычкырды куштан. Нәрсәдер язмакчы булды. Ләкин Хәлдәмов тыныч кына

аңа чыгып торырга кушты. Минут эчендә теге ишек артында шым булды. Хәлдәмов иплән кенә бер-ике сүз белән хәлне аңлатты да кайтарып җибәрде. Икенче көнне аңа ярыйсы гына атлар бирделәр. Әнвәр карусыз эшләде. Хәлдәмовның яхшылыгын соңыннан гына аңлады ул. Түбән колхозда шундый ук хәл өчен бер егетне ерак сәфәргә җибәргәч кенә. Ләкин язмышны алдан белеп булмый шул. Соңыннан ни буласын белергә язмаган. Теге егет ерак сәфәрдә фронтка эләкми калган. Тап-таза Әнвәр әнә ничек булып бетте? Тик ул үзенең хәлен тегенекеннән өстенрәк саный. Чөнки биографиясе берни белән дә тапланмаган. Сәламәтлеге беткән, әмма пычранмаган. Шушы чисталык аңа ничектер кыйбатрак тоела иде...

Имтиханны укыту комбинатыннан килгән комиссия алды. Таләп шактый каты иде. Шулай да төшеп калучылар икәү генә булды. Унсигез кеше имтиханны тапшырып чыгуга ирештe. Госпиталь җитәкчеләре бар көчләре белән яралыларны сафка кайтарырга тырышалар иде. Курсны тәмамлаучыларга чыгарыш кичәсе оештырдылар.

Класс бүлмәсендә өстәлләрне тезеп, табын әзерләнгән иде. Саранланмаганнар, һәр кеше алдына котлет белән ботка, кызыл балык, селедкалар торап куелган. Икмәк телемләп уртага өелгән. Яралылар кереп утырдылар да өстәлдә ни җитешмәгәнне шәйләделәр. Менә ишектә замполит Френкль, Татьяна Владимировна, Михаил Аркадьевич һәм тагы врач, шәфкать туташлары күренде. Ин азактан ике кулына ике сумка күтәреп Фира Касыймовна килеп керде. Аңа ике кыз булышырга тотынды. Булачак рәхәтне алдан тойган мизгелдә кеше тынып кала. Стакан тотып өстәл башында замполит торып басты. Шунда Фира Касыймовна да Әнвәр янындагы буш урынга килеп утырды.

— Иптәш Сталин яралыларга карата зур кайгырту күрсәтә,— диде замполит.— Кайда гына булсак та, без моны онытырга тиеш түгелбез. Нинди генә авыр хәлләр безне сынаса да, совет солдаты исеменә тап төшермик! Юлбашчыбыз саулыгы өчен!

— Һәм үзебезнең тазалыкка!— дип кемдер өстәде. Әнвәрнең күңеле күтәрелде, үзен бер карыш үсеп киткәндәй сизде. Табында сөйләшү, шатлыклы тавышлар көчәя төшкән иде. Шуңардан файдаланып, Фира Касыймовна Әнвәргә таба иелде.

— Мин сине хәтерләдем,— диде.— Сине батареяда «малайка» дип йөртәләр иде, әйеме? Син чыннан да Алексейның үлгәнен күрдеңмени?

— Күрдем,— дип кыяк какты Әнвәр.— Күмгәндә була алмадым, санбатка алып киттеләр, яраланган идем.

Бер яралы ашханәдән менгән чибәркәй белән сүз куерта иде.

— Тол хатын — сөрелмәгән җир ул,— диде майлы битле хатын.

— Сөрүче бер дә булмадымыни?— дип кызыксынды аяксыз.

— Булмады шул, нишлисең.

— Сөрелмәгән җирдә әрем, билчән үсә.

— Үсә инде, үсә.

— Син теге чирәм җир кебек инде алайса?

— Нәкъ, нәкъ,— дип кеткелдәде хатын.— Күтәрелмәгән чирәм.

— Рәсәйдә чирәм җир күбәеп китте. Сиңа да бер тәрән табылыр анысы, әнә күпме төрәннәр ята.

— Һәрберсенең үз кишәрлеге бардыр шул.— Хатын калын җилкәләрен селкетеп кеткелдәде.

Сөйләшү, шау-шу, көлүләр торган саен күбәйде. Инде эчтә йә сер, йә шик кебек урнашкан сүзләр дә атылып чыга башлады. Сафаров дигән аяксызның ярасы төзәлми иде. Врачлар ниләр генә эшләтмәде, һаман чимә-чи булып тора. Үлекләми дә. Үлеге булса төзәтер иде. Юк, зәңгәрсуланып чиләнә дә чиләнә. Берсе шуңа тотынды.

— Синең яраң ни өчен төзәлми? Беләсеңме?

— Ни өчен?

— Күңелеңдә синең гөнаһың бар, намусың чиста түгел, шуның өчен!

— Нинди гөнаһ, нәрсә такылдыйсың?— дип кызмакчы була Сафаров.

— Син ул гөнаһыңны үзең оныткансыңдыр да, ә күңел онытмый. Җан истә тота. Син бераресен сатканеыңдыр да, үзеңне көчләп, онытканеыңдыр. Җан эчтә барын да исәпләп бара. Әнә шул синең яраңны төзәттерми!— Яралы ихластан сөйли иде. Сафаров берни әйтә алмый, моны чын дип кабул итмәгән төс чыгарып елмая. Никтер, үз эченә йотылып, тынып кала.

Яшьрәк һәм елдам бер аяксыз егет шәфкать туташы белән уртак тел табар өчен разведка алып бара шикелле. Ниндидер кызык сөйләп, аны көлдерә дә көлдерә иде. Ул инде чибәркәенең иңенә кулын куеп торырлык ышанычка кергән һәм аның битенә авызын якын ук китереп сөйләнә. Каршы яктан кемдер шаяртып аларга: «Әче!»— дип кычкырып куйды. Дәррәү көлеш күтәрелде. Яралы аның саен дәртләнеп шәфкать туташы иңендәге учын күчергәли иде. Теге шаян тагы: «Әче!»— дип ярып салды. Көлеш тавышы түшәмне күтәрә язды. Татьяна Владимировна җыр башлады. Яралылар, шәфкать туташлары аңа кушылдылар. Бу бик моңлы җыр иде.

Кичә җыр белән шаян сүз сибү, шуклану, көлүләр белән әйбәт кенә барды. Тик Әнвәр генә чыдамады. Башы чатнап авырта иде. Ул иплән кенә торды да бүлмәдән чыгып китте. Бакчага төште. Госпитальнең таш койма белән уратып алынган карт бакчасы бар иде. Юан-юан юкә агачлары инде ямь-яшел яфракка төренгән. Каенга оялаган каргалар тынып калган. Тын, рәхәт. Сулыш алуы иркен. Төн караңгы түгел иде. Кичәдә җырлаган тавышлар ишетелеп китә. Бераздан бакчага кемнеңдер чыгып килгәне күренде. Ак халаттан иде. Шәфкать туташыдыр дип уйлады Әнвәр. Тик бу Фира Касыймовна булып чыкты. Туры Әнвәр янына килде.

Әнвәр ни әйтергә дә белми тынып калды. Ул Фира Касыймовна янында ничектер каушый иде. Врач үзе сөйләргә тотынды. Комбатны һаман оныта алмый икән.

— Аның белән булган чаклар матур төш кебек кенә булып калды. Алексей кебек кеше юк инде ул, юк! Ул дөньяда бер генә булган, ахрысы. И әрәмнәр булды инде, үзе турында бер дә уйлый белмәде шул!— Врач тирән итеп уфтанды, үзенең эчке уйларын тыңлагандай тынып торды. Шактый шулай утырганнан соң, тагы үзе сөйләп китте.

— Минем беренче ирем дә әйбәт иде. Тик бичара бик бәхетсез булып чыкты. Немецларга әсир эләккән. Анда аны ниләр генә эшләтеп бетермәгәннәр. Палач-врачлар аның өстендә тәҗрибә ясаганнар. Арка миендә ниндидер даруларын сынап караганнар. Умыртка баганасына шприц энәсе кертеп, арка миен алганнар. Шунда дару җибәргәннәр. Мескен, тәмам бетеп кайткан. Күзләре шардай зурайган, бөтен битен алып тора. Күз агы белән генә карый. Куркыныч хәтта. Пункциядән күз шулай була. Уф! Аны җәлләүдән йөрәгем бозылып бетә язды. Аңы да бераз тегеләйрәк булып калган. Элекке таза кеше урынына тере мәет. И шул чакта кичергәннәрем! Яхшылыгын шуннан бел, минем янга кайтмады, үз хәлен чамалап, анасына кайтып егылган. Мине шунда чакыртты. Башта аны танымадым. Сүзләреннән генә шәйләдем. Барысы өчен дә үзен гаепле саный иде бичара. «Мин,— ди,— тормыш корып яшәрлек хәлдә түгелмен, зинһар, яшь гомереңне заяга уздырма, үз җаеңны кара». Шулай диде дә караватына капланып ятты, бүтән бер сүз дә эндәшмәде. Мин еладым, бүтән берни кулымнан килми иде. Апа белән икәү елыйбыз. Йөрәгем телгәләнде инде, телгәләнде. Мин аны ташламаска булдым. Аңа ярдәм итәргә кирәк иде. Әйбәт дарулар таптым, азык-төлек юнәттем дә бер-ике көннән соң сумкамны тотырып аларга бардым. Ләкин соңга калганмын, аны психбольницага алып киткәннәр. Кухняда бер ир кешегә ябышкан да буа башлаган.

— Бәлки, терелер әле?— диде Әнвәр, теге бичараны җәлләп.

— Юк, кирегә юл беткән инде аңа.— Фира Касыймовнаның тавы-

шында да кызгану иде. Ул тирән итеп көрсенде. Ә бакча ишегеннән аны чакырган тавыш ишетелде. Шәфкать туташы дәшә иде. Кичә инде тәмамланган, җыештыру, әйберләрне урнаштыру болар өстендә булуы аңлашыла иде.

Әнвәр кулына «бухгалтер итеп файдаланырга ярый» дигән кәгазь алу көнен көтте. Шул кәгазьне Ваһаповка күрсәтергә, әгәр хәерхаһлыгы нык сизелсә, бирәр җайлы эшкә урнаштыруда булышлыгын сорарга уй төйнәп, офицерлар палатасына килеп керде. Ләкин Ваһапов караватында бүтән берәү ята иде. Әнвәр сәерсенеп, нәүмизләнеп калды. Аның кинәт боегуын, шәлперәюен күреп, Ваһаповның элеккеге күршесе: «Аны иптәшләре Саратовка алып киттеләр. Ул анда сугышка чаклы укыган булган икән. Җайлы эш бар ди, квартир да юнәтербез дип вәгъдә иткәннәр... Бик тиз генә җыендылар да китеп тә бардылар»,— диде.

Әнвәр үзен нәрсәсендер югалткан шикелле хис итте. Җанына урын таба алмады. Бүтән палатадагы сабакташлары янына кереп карады. Әзимов белән сөйләшеп утырды. Юаныч булмады. Асяны күрми калу бигрәк күңелен телгәли иде. Барасына да шул кыюсызлыгы, мокытлыгы гаепле. Ул бит Ася янына Ваһаповтан башка да бара алган булыр иде? Әгәр башын эшләтсә, зиһенен катырак җигеп уйласа? Нәрсәсе уңайсыз иде соң? Ничек бетерергә бу кыюсызлыкны, ничек җиңәргә? Ася белән бу инде мәңгегә аерылу, бүтән бервакытта да очрашып булмас!? Тормышның кануннары кырыс, катгый. Ул һәркемне үзенең көчле агымына суырып ала һәм вак-төяк нәрсәләргә бернинди вакыт калдырмый. Мин үземә бирелгән вакыттан файдалана белмим. Үземә тигән өлешне ала алмый калам. Менә, билгеле, беркем дә гаепле түгел инде. Ә күңеленең моны кемгәдер сылтыйсы килә, барысын да аның өстенә өеп калдырмакчы була. Бер уңышсызлыкка тарысаң, шулай була, сәбәпне читтән эзли башлыйсың. Ә уйлап карасаң, иң гаепле зат үзең, үзеңнең пешмәгәнлегең. Тик үзеңне хөкем итәргә көчең генә җитми!..

Ул Турганов фатирына килеп кергәндә, теге яңа гына эштән кайткан, протезын салып, культясын ял иттереп, киез шикелле нәрсәдә ятып тора иде. Бу кечкенә бер бүлмә икән. Ничектер җыйнаклык, чисталык сизелә, хуҗалар уңган кешеләр, ахрысы. Турганов исә Әнвәр килүгә бик сөенде, әйтерсең, аны көтеп кенә торган. Тиз-тиз торып өстәл тумбочкасыннан бер шешә сыра чыгарды, сынар балыкны урталай кисеп куйды.

— Эш поша, парин,— диде Әнвәр уфылдап. Турганов диагнозны тиз куйды:

— Сиңа кызлар кирәк, күңел юаткычы,— диде, күзен дә йоммыйча. Әнвәр мондый сүз көтмәгәнгә, ни әйтергә белми торды. Ул эч пошуының сәбәбен нидән икәнен белми иде. Турганов нәрсәдер белә, ахрысы? Шунысы бар: килгән саен Тургановның үткенәя, чарлана төшкәнен сизә Әнвәр. Кешеләр арасында булу, ахрысы, аны чарлый, ботак-чатакларыннан арындыра. Пөрән таш шомара, диләр. Турганов күзгә күренеп гаярьләнә иде. Ул үзенең шомарганлыгы белән бераз һаваланырга да күп сорамый. Әнвәр эндәшмәгәч, сыраны стаканнарга агызды: «әйдә, тот», дип ияге белән ымлап, укра чәчә башлады:

— Син кызлардан куркасың, әйеме? Кыюсызлык чире!

Әнвәр аптырады, каян белә ул аның кызлардан курыкканын? Әллә маңгаена язылганмы?

— Юк, аяксызлык галәмәте,— дип аның фикерен ялганга чыгармакчы булды.

— Төкер барысына да! Тәвәккәлләргә кирәк!

— Син миңа эш тап,— диде Әнвәр сыра чөмереп.— Үзең янында.

— Юк,— дип кул селтәде Турганов ничектер җавабы алдан ук әзер булган кебек.— Син анда батмыйсың.

— Ник? Әллә анда могезләләр эшлиме?

— Син бик юка тиреле бит! Пычтак өчен дә кайгырасың. Күңне ку-

рәсең! Алай үзеңә генә авыр.
— Тәртипсезлек күрсәм, йөрәк сызлый шул.
— Төкер! Кемгә файдасы бар ул сызлавыңнан? Кем ишетә аны?
— Беркемгә дә файдасы юк. Беләм. Ләкин җан көя бит.
— Җаныңа баш бул! Чи яра белән яшәп булмый! Яшәргә өйрән.
— Өйрәт мине, дус кеше, өйрәт!
— Ну, синең үз кырыгың кырык бит, тыңламыйсың.
— Тыңлыйм, өйрәт кенә.
— Әйдәме, хәзер кызлар янына киттек? Ике шешә сыра бар. Балык та эләктерербез, ә?
— Тукта, алай кинәт кенә.
— Әйттем бит, тыңламыйсың дип. Тыныч бул, үзләре чакырды.
— Сине чакырганнардыр, ә мине?
— Какрас кына, ике кыз янында берүзем — ике инәгә бер җеп.
— Килешер микән соң?
— Күзеңне йом да ыргыл! Юкса, үз өлешеңнән колак кагып калырсың.

Трамвайга утырып Пеләтәнгә хәтле килделәр. Төштеләр. Пеләтән мунчасы турыннан баралар. Тротуарда бер аяксыз утыра иде. Сәләмә бүрек кигән, кара күзлек элгән. Кешеләр үткәндә кычкыра: «Сталинград сугышында яраландым, контужен...» Хәер җыеп утыра икән. Тургановның аны күргә йөзе үзгәреп китте, иреннәре калтырый, беләкләре тырпая башлады. Ул протезы белән тиз-тиз атлап янына килде һәм кинәт тегенең башыннан бүреген алып ташлады. Бүрек белән бергә күзлеге дә ычкынды.

— Янтиев, суккин сын!— дип акырып җибәрде Турганов, хәтәр зәһәрләнеп. Аны ачудан танырлык түгел иде.— Ник Сталинградны хур итәсең?! Авызыңны корт чаккыры! Ник Сталинград белән сату итәсең? Тор! Хәзер эт урынына...— һәм ул таза аягы белән тегеңә типмәкче булып кизәнде, ләкин теге ялт кына торып басты. Күзе дә таза, үзе дә бетәшкән түгел иде.

— Ник ирәясең ул тиклем!— диде мөгрәп. Тургановны белә һәм аңардан шүрли дә, күрәсең.

— Сталинградны буяма! Пычратма изге нәрсәне! Паразит! Синең пенсияң әйбәт бит!

Теге малайларча артына карый-карый титаклады гына.

Турганов Әнвәргә:

— Госпитальдә бергә яткан идек,— диде.— Шундый бер тиен өчен чукына торган адәм. Зеленодольскида тора. Үз йорты, сыеры бар. Бирегә килеп нишләп йөри, кабахәт! Тегендә аның хәлле икәнен беләләр. Сталинград белән сату итә бит, гад!

Сабанчы урамына борылгач та ике катлы бер агач йортка керделәр. Кирәкле квартира икенче катта икән. Керүгә кухня иде, керогаз, табак-савыт шкафы. Аларның тавышын ишетепме, арыдагы бүлмәдән... Зәлия килеп чыкты. Әнвәр күземә күренә, ахрысы, дип күзләрен угалады, юк, бу шул Зәлия иде. Аны күрмәгәнгә бер айлап вакыт узгандыр. Шулай да гаҗәпләнмичә мөмкин түгел иде. Ул арада таза күкрәкле, түгәрәк йөзле, өлкәнрәк кыяфәтле мөлаем икенче кыз килеп алар белән күрешә башлады. Ул кунаклар килүгә бик шат иде. Турганов Әнвәрне кызларга тәкъдим итте. Болай ук төче кирәкми иде, Әнвәр кызарды. Түгәрәк битле кызның исемен көчкә ишетеп калды. Нифа исемле икән. Зәлия аңа апа дип дәшә иде. Биредә шушы Нифа баш булуы сизелде. Ул Зәлиягә, тегене эшлә, моны кара, дип кушып кына тора иде. Зәлия, әллә апасыннан уңайсызланып, Әнвәр белән таныш булуын белгертмәде. Әнвәр исә аңардан узып дәшәргә кыенсынды. Чынлап та, бәлки ул аның туган апасыдыр. Зәлияне шәһәрдә карап, күз-колак булып тору аңа йөкләтелгәндер? Тар гына бүлмәгә узып, бер кырыйдагы өстәл янына

утырыштылар. Зәлия генә утырмады. Нифа аңа карашы белән ниндидер эш кушып өлгергән иде бугай. Ә Нифа белән Турганов күптәнге якын танышлар кебек сөйләшә башладылар. Кыз аңардан бер дә тартынмый, егетне үзе белән тигез күрә иде. Бер-берсенә булган мөнәсәбәтләрен күз карашларыннан, ихлас әйтелгән сүзләреннән чамаларга була иде. Борчаклары пешә булырга охшый. Кыз төпле фикер йөртә, үзенең мөстәкыйльлеге дә шактый сизелә иде. Тургановның сүзләрен аста калдыра, теге исә шуның белән килешергә мәҗбүр була һәм горурлана иде.

Зәлия өстәлгә табада кыздырган бәрәңге һәм чәй китергәч, тегеләрнең сүзләре өзелде. Турганов бирелә үз кеше булырак, шаяртып сөйләнергә кереште. Беренче ятсынуны бетерер өчен бу кирәк иде. Мондый чакта юк-бар сүз дә ярап куя.

— Без Кәҗә белән Сарык, сезгә кунакка килдек,— диде үзе бер дә көлмичә, елмаймыйча.— Сез көткәнне белдек, бакчагызга кердек. Хуҗа безне куды, сыртны шактый уды. Кәҗә әйтә: «Белмәдем, бер яфрак та күрмәдем».

Нифа чын күңелдән көлә иде. Зәлия дә дымык кына көлгән итте. Әнвәр дә Тургановка төбәлеп әйтте:

— Кәҗә, кәҗә-мәкәрҗә, кермә минем бакчага, кысылырсың, үләрсең, тәңкә ярым түләрсең.

Турганов ары дәвам итте:

— Әй, Сарык, ахмак Сарык, китер зуррак бүре башын табып?! диде һәм кесәсеннән бер сыраны алып өстәлгә дыңк итеп куйды. Әнвәр дә кесәсеннән икенче сыра шешәсе чыгарды. Кызлар көлделәр дә көлделәр. Табадагы ризыктан җитешкәч, Турганов тагы әллә каян гына алып бирәр вобла бирен чыкты. Запаслы кеше икән. Үзгәргән ул, шактый нык үзгәргән. Сүз арасында Әнвәр һаман Зәлияне күзәтә иде. Ничектер ихтыярыннан тыш эшләнә бу. Зәлияне очраткач, аның караңгы күңелендә ниндидер бер күз ачылган кебек булды. Шул күз үзенә иш эзләгән кебек тоелды. Зәлия төскә ямьсезрәк, беленер-беленмәс шадрасы аның йөзендәге нурны каплап тора сыман иде. Аның нуры эчтә. Мондый кызлар аек фикер йөртүчән була. Борынны артык нык чөймиләр бугай. Әмма үзе нәрсә уйлый ул? Хәер, монда аның ни уйлавы түгел, апасы Нифаның Әнвәр хакында ничек уйлавы мөһим. Апасы ничек әйтсә, Зәлиянең дә фикере шулай булачак. Монда аның апасына ошарга кирәк. Зәлиягә юл апасы аша гына. Моны Әнвәр аңлап алды инде.

Шаян сүзгә бер шаян сүз ялгады:

— Бездә Әмҗәт исемле карт бар иде. Бик туры сүзле, чистыклы бабай. Узып барганда: «Исәнме, Әмҗәт бабай?»— дисең. Ә ул сәламне алганчы: «Син кем малае әле?»— дип сорап куя. «Фәлән малае», дисең. «Ә-ә,— ди Әмҗәт бабай кулын селкеп,— сезнең кәҗәгез бакчага керде, исән түгел, исән түгел!»— ди-ди сәламне алмый китә дә бара.

Шул мәл бүлмә дерт итте, тышкы ишек каты ябылганы ишетелде. Нифа сикереп торды:

— Хуҗа кайтты, шылыгыз!— дип пышылдады. Үзе өстәлдәге шешәләрне шкаф артына озата иде. Иң элек Әнвәрне шыпырт кына озаттылар. Аның артыннан Турганов чыкты.

Әнвәр ул төнне йоклый алмады. Барча ару-талу, сызлаулары юкка чыккан кебек иде. Тәне җиңел, әгъзалары җиңел. Кулы очкын каурый кебек авырлыгын җуйгандай. Аягы да җиңел, башы да җиңел. Баш та үзенең авырлыгын каядыр куйган бугай? Болай бит аны җил очыртып кына алып китәчәк? Бөтен нәрсә җиңел булып калган төсле. Дөнья да бик җиңел, тормыш та шундый рәхәт, җиңел! Бер җыр исенә килә: «Әнә килә автомобиль, тәгәрәннәр барабан. Бу дөньяны авыр, диләр, кем күтәреп караган?» Күпме кайгы, борчулар мәче кебек эчен гел тырнап торалар иде. Алар да әллә кая очканнар. Авырлыкны җуюга чыдый алмаганнармы? Кайгылар, таштай булып, җанны басып тора

торган иде. Ташлар да юкка чыкканмы? Җиңел, яңа туган кебек җиңел, рәхәт! Күкрәгендә йөрәге сулыгып-сулыгып рәхәтләнеп типкәне колагына ишетелеп китә. Башында, ми тартмасында ниндидер моңсулык, нурлы зәңгәрлек. Ул ниндидер моңсу рәхәтлек эчендә йөзә кебек. Төн караңгы, ә аның күз алды ял-якты. Ул караңгылык пәрдәсе аша бар нәрсәне үтәли күрә сыман. Нишләп караңгыда да минем күз алдым якты икән дип гаҗәпсенә Әнвәр. Әллә мин тагы чирли башладыммы? Юк, чирләгәндә болай җиңел, рәхәт булмый. Күз алдының көндезгедәй якты булуы нәрсәдән, күңелдә әллә тагы бер күз ачылганмы? Зиһенем ачылганмы? Күңел күзе дип юкка гына сөйләнмиләрдер? Андый нәрсә чынлап та бар, ахрысы? Кешеләрдә шундый күңел күзе ачылу ише нәрсәләр була, ахрысы?

Палата төрле авазлар чыгара-чыгара йоклый. Ә Әнвәрнең күзләре ачык. Аңа бик җиңел, бик рәхәт иде.

## 5

Алар фанер стена белән генә бүленгән тар бер бүлмәдә эшләп утыра. Икесенә ике кечкенә өстәл. Михаил Кузьмич хисапчы, Әнвәр аңа ярдәмче. Бирегә Әнвәрне госпиталь замполиты урнаштырган иде. Курсны тәмамлауның икенче көнендә үк Әнвәр паспорт алырга булды. Моңа рөхсәт кирәк иде. Замполит янына төште. Әнвәрнең эшләргә теләвен замполит бик хуплады, иртәгәдән үк әзерлән, җайлы эш бар, диде. Һәм сүзендә торды да. Кәнсәгә үзе ияртеп алып барды. Әнвәрне шунда ук эшкә куйдылар. Паспорты да юк иде әле. Дәрәҗәле кешенең сүзе үтә шул. Аннары замполит Әнвәрне госпиталь ризыгыннан да төшерттермәде. Тик палатадан Турганов яшәп чыккан астагы бүлмәгә күчәргә туры килде. Шулай да аның өчен болар бик зур ташлама иде. Әнвәр моны аңлый һәм замполитка, бүтән игелекле кешеләргә эчтән генә рәхмәт укып йөри иде.

Менә айдан артык инде ул эштә. Яңа шартка ияләнү җиңел булмады. Һәркөнне алтыдан торып эшкә китү авыр иде. Госпитальдә озак ятып, иркәләнеп бетелгән. Әмма бергә эшли торган кешеләр әйбәт иде, аңа ярдәм иттеләр. Башта эшне дә күп өймәделәр. Якыннан бер почмак табып бирәбез дип тә өметләндерәләр иде. Эш катлаулы түгел. Баш бухгалтер ярдәмчесе Нина Ахуновна дигән хатын катыргы тышлы калын-калын амбар кенәгәләрен Михаил Кузьмичка кертеп бирә. Шулардагы җиңелрәк башкарыла торган эшне Михаил Кузьмич Әнвәргә тапшыра. Бу гадәттә бер кенәгәдәге кайбер сан-цифрларны икенче кенәгәдәге графаларга күчереп кую кебек эшләр була. Техник эш шикелле генә. Әнвәр бик тырышып эшли. Кайчак бирелгән эшне шактый тиз үтәп ташлый. Андый чакта Михаил Кузьмич, үзенең кәгазьләренә караган килеш кенә: «Ашыкма, кая ашыгасың?»— дип әйтеп куя. Бу аның көне буена әйтелгән бердәнбер җөмләсе. Ул бөтенләй диярлек сөйләшми торган, үз эченә йомылган кеше. Йөзе, кояш ашаган кәгазьдәй, саргылт, чәче озын, яңакларын атнага бер генә кыра бугай. Күлмәк якалары да керләнеп беткән. Ул ялгызы гына яши икән. Гайбәттерме, чындырмы, аны хатыны калдырып киткән, түбән төшүенә шул сәбәпче булган, имеш. Күпне кичкән, катлаулы язмышлы кеше, ахрысы, ул. Өзмәс тәмәке тартып тора. Бер дә елмаймас, көлә белмәс. Нина Ахуновна белән дә юньләп сөйләшми иде. Тегесе буянып, ясанып йөри торган хатын. Күлмәкләрен дә тәненә сыландырып, бар чыгынтылы, керентеле төшләрен тыгызлатып, тышка төртеп тора торган итеп кия иде. Килеп керүгә чынлы тавышы белән сайрарга тотына.

— Әй, Михаил Кузьмич, яратам ла шушы тәмәке исеңне,— дип тезә башлый. Аның янындагы урындыкка утыра, кенәгәләрен өстәлгә куя, көрсенә, җилкәләре түбән төшкәндәй була. Михаил Кузьмичка те-

кәлеп, тегенең керле якасын күрә дә, чын кайгыртучан кыяфәт белән аны йомшак кына шелтәләгән итә.

— Мунчага бара алмадыңмыни? Йа хода! Нишләргә инде?— Битенә кайгы-хәсрәт сөмсере чыга. Бу шелтәләү-кайгырту аның үзенә бик тә ошый шикелле. Әмма Михаил Кузьмич бер сүз дә эндәшми, үзенең кәгазьдәге графаларына текәлгән дә тәмәкесен суыра бирә. Нина Ахуновнаның кайгырту дәрте һаман арта бара, шул чак Кузьмич аны бүлдерә.

— Йә, башлыйк, Нина?— дип, кырыйдагы калын кенәгәне алып, ачып куя. Алар ниндидер фактураларны чагыштырып чыгарга тиешләр. Хатын шуның өчен кергән. Ләкин эштә әллә ни гаме юк.

— Гимнастерканны гына юып китерим, Михаил Кузьмич! ди ул, таза җилкәләрен хәрәкәтләндереп күрсәнә. Кузьмич кенәгәдән укып әйтә башлый. Нина аны ишетми дә. Алар ничектер бер-берсен ишетмиләр.

— Чи тире-илтер егерме биш мең, даланыкы,— диде Кузьмич башын күтәрми генә. Нина ул әйткәнне кире тибәргәндәй кулын селтәде.

— Ялгыз яшәү авыр ул, Михаил Кузьмич! Үземнән беләм. Ир-атка бигрәк тә. Ялгыз ир-ат кыргыйлана башлый диләр.

— Миронос сарык тиресе утыз мең...

— Синнән миңа берни кирәк түгел, Михаил Кузьмич! Билләһи! Син уйлыйсыңдыр теге ни дип. Юк, минем кемне булса да тәрбиялисем килә. Кемне булса да карау мәшәкате кирәк миңа. Билләһи! Кем өчен булса да кайгырырга, борчылырга телим мин. Шул гына, Михаил Кузьмич!

—-Озын йонлы саратовский чи тире биш йөз данә.

— Мин үзем өчен түгел, кеше өчен яратылган. Үземә булмасын, бүтәнгә булсын. Үзем өчен тырышмыйм мин.

Нина Ахуновна зур кенәгәне ачты. Әле Кузьмич әйткән саннарны табып, күздән кичерде. Уң кул учын шул биткә куеп, сөйләвендә булды.

— Иртәгә үк мунчага барган бул, күлмәк-ыштаннарыңны әнә кара сумкага салырсың, беркем дә күрмәс. Алып кайтып юармын. Миңа эш кирәк, Михаил Кузьмич!

— Гурьев сорты ни өчен бу графага теркәлгән? Ялгыш түгелме бу? Аларның йоны югары сортлы, шуңа тиреләре дүртенче категория белән йөри ич?

— Бәлки, бәлки,— дип йомшак кына әйтә Нина.— Кырыйга сорау куеп торам, ачыклармын.

Алар кенәгәдәге фактураларны чагыштырып озак кына утыралар. Нина Ахуновна һаман үзенең кайгыртуын белдерүдән туктамый. Михаил Кузьмич бик сабыр кеше икән. Каршы да, уңайга да бер ым билгертми. Шулай ук бу нәрсәнең туйдырып бетерүен дә сиздерми. Әллә Нина Ахуновнаның шулай үзе өчен өзелүен күреп тору һәм шуңа битарафлык күрсәтү аңа рәхәт кенәме?

Эш тәгәлләнгәч, Нина Ахуновна авыр гына кузгала. Күрсәнә, Михаил Кузьмичка керләрен кара сумкага салырга куша. Боерыгы тегенә барып җиттеме-юкмы дип бер карап ала да муен артына өеп куйган чәчләрен рәтли-рәтли чыгып китә. Кенәгәләрен алырга юри онытта ул. Тагы керергә сәбәп булсын өчен.

Ул чыккач, Кузьмич берни булмаган кебек, һаман элеккечә утыра бирә, тик мөштегенә яңа папирос кигезә. Ул аңа күнегеп беткән, ахрысы. Ә нигә бер дә эндәшми, сөйләшми икән? Әнвәргә бу бик гаҗәп тоела. Аның Кузьмич белән сөйләшәсе килә. Менә күпме вакыттан бирле ул аңа ачкыч таба алмый. Нина Ахуновна шикелле. Кайчан, нинди хәлдә теле ачыла икән моның дип аптырый ул. Нәрсә ярата икән Михаил Кузьмич? Кешенең телен яраткан нәрсәсе белән ачалар дип Әзимовтан ишеткәне бар иде. Әллә салдырып карыйсымы моңа? Баш тартмасмы?

Ләкин бер очрак ярдәм итте. Госпитальнең өстәге катларына ремонт керү сәбәпле, яралыларны аскы бүлмәләргә күчерделәр. Әнвәр янына да бер кешене куйганнар иде. Кайтса — шул, яңа күрше. Татар агай. Ике

аягы да төптән үк юк икән. Үзенең йөзе ягымлы гына. Сөйләшергә ярата кебек. Әмма бик авыру. Аңа иртә-кич укол кадап кына торалар. «Инә тимәгән бер төшем дә калмады инде,— дип көлә үзе.— Мин тишкәләнеп, иләк кебек булып беттем, хәерле булсын»,— ди. Уколдан соң шактый кызып сөйләнә дә аннары нигәдер тынып кала. Бик оптимист кеше. Грамотасы бик шәп. Яшьтән үк русча укыган, күп белә. Әнвәрне русча дөрес язарга өйрәткәли. Ләкин бик тиз арый бичара, маңгаеннан салкын тир тама башлый, кәгазь битен юешләп бетерә. Кара белән язган сүзләр җәелеп танымаслык була. Әнвәр аны туктата, ярар, җитеп торыр, ди. Гамәшев (аның фамилиясе шулай) кискен түмәр кебек булып калган ярты гәүдәсе белән караватына ава. Кулларын баш астына куеп озак кына ятканнан соң, тагы торып утыра. Рәсемчеләрнекенә охшаган тартмасын ача, йөзе бердән яктырып, илһамланып китә. Анда вак-вак кораллар. Мөһер ясый торган. Ул фронтта мөһер ясаучы булып эшләгән. Бик оста булган. Ләкин бер урман буенда торганда җиләк җыярга дип эчкәрәк кергән икән, минага эләккән. Һич көтмәгәндә шулай харап булган. Ул врачларның һәрберсенә диярлек имзалары факсимилесен ясап бирде. Әнвәр аңа үзенең хәлен, эштәге кешеләрне сөйләштереп ала иде. Гамәшев бик кызыксынды. Ул кешеләр белән бик кызыксына. Аларның имзаларына карап характерларын фараз итәргә ярата. Шуңа Михаил Кузьмич белән Нина Ахуновнаның имзаларын алып кайтырга кушты. Менә ул имзалар аның алдында ята.

— Михаил Кузьмич имзасы танылмый, ләкин бик киң итеп селтәнгән сызыкларга карап әйтергә була: үз имзасын ярата бу. Эчендә минминлеге бастырылып ята шикелле...

— Ничек ул?— диде Әнвәр аңламыйча.

— Һәр кешенең эчендә мин-минлеге бар. Кайбер кеше: «Мин, мин», дип йөрергә ярата. Эчендәге шул ертлач «мин»ен йөгәнлли алмый, теләми. Әмма кеше шул «мин белән генә кеше. Шул «мин»е бетсә, ул инде сынган кеше. Кешенең үз «мин»е булырга тиеш. Авыр язмышка дучарларның «мин»е үз башына төшкән дөнья авырлыгыннан бастырыла, рәнҗетелә. Кеше үзенең эчке дөньясына йомыла һәм «мин»ен дә яшерә. Ул «мин» бик сирәк очракта гына үзен күрсәтеп куйгалый. Мәсәлән, имзада...

Гамәшев сөйли дә сөйли. Әнвәр аның сүзләрен аңлап җиткерми. Шулай да тыңларга кызык. Аңламавын белгертәсе дә килми. Гамәшев аның мокытлыгын болай да сизә, ахры. Кайчак әйтә:

— Синең миеңдә сырлар әзрәк әле, әнә шул сырлар күбәйгәч аңларсың,— дип куя һәм рәхәтләнеп, башын артка ташлап көлә. Ләкин көлгәндә хәле бетә дә тагы түмәр кебек ятагына авып тәгәри. Бераз яткач, торып, сәгатьченеке кебек зурайтып күрсәтә торган күзлеген кия.

— Нина Ахуновна,— дип шәрехләргә керешә.— Имзасы танылa. Әйбәт күңелле кеше булырга охшый. Мин-минлеге кечкенә. Шуңа күрә дөньяга таләпләре дә зур түгел. Әз таләпле зат. Ә син Әнвәр нинди таләпле, азмы, күпме?

— Белмим.

— Син күп таләпле. Ләкин көчең аз. Физик һәм акыл көчең. Таләбеңне шуларга яраштыр. Юкса, авыр булыр, матри!

— Мин аңламыйм, Гамәшев абый?

— Киләчәктә аңларсың, күңелеңә салып бар. Тормыш сине төрле хәлләргә төшерер. Шул чак минем сүзләр исеңә килер. Адәм баласы үзе татымыйча күп нәрсәне аңламый. Әйткән сүз керми аңа.— Ул сөйләнәсөйләнә эшли иде. Эшләгәндә үзгәреп китә икән. Битендәге җыерчыклары әзәя, эчтән нindидер нур бөркелгәне сизелеп тора. Йөзе тагы да яктыра, аңа көч-куәт өстәлгән сыман була.

Икенче көнне ике имзаның да факсимилесе әзер иде. Юка гына резинага имза төгәл итеп кисеп төшерелгән һәм кечкенә шакмакка ябыштырылган. Чын пичәттән берничек тә аерырлык түгел.

Әнвәр, Михаил Кузьмич биргән эшне язып бетерде дә, кенәгәләрне

аңа сузды. Үзе торып басты, оеган әгъзаларын язу өчен буыннарын шыгырдатып киерелде. Аннары кесәсеннән теге мөһерләрне чыгарып, ак кәгазь өстенә шап-шап китереп алды. Шул имза төшкән кәгазьне Михаил Кузьмич алдына куйды. Теге, кинәт куркып киткәндәй, зур башын күтәрде, Әнвәргә сәерсенеп карады.

— Нәрсә бу? Ничек?— диде бик тиз телгә килеп. Саргылт маңгаенда җыерчыклар җыелды, чал керә башлаган калын кашлары селкенгәли иде. Аның өркеп калуын күреп, Әнвәр тизрәк аңлатырга тотынды. Шуннан соң гына, Кузьмич бераз тынычланып, мөштегенә папирос кигезде. Тәмәкесен тәмләп суыра-суыра имзаларыннан күзен ала алмый иде. Үз имзасын гаҗәп ярата икән.

— Оста эшләгән, шайтан! Аерырлык түгел,— дип сокланды ул. Ләкин эчендәге куркуы бетмәгән икән:

— Моның белән мине төп башына утыртулары мөмкин ич?— диде җитдиләнеп.

— Ничек инде?— дип көлде Әнвәр.

— Бер документка шушы имзаны куйды — бетте! Утыз менне кесәсенә сала. Мине — тегендә!

— Шундый жуликлар да буламыни?

— Әй, энем, син әле кешеләрне белмисең.

— Шулай да...

— Минем бу кешене күрәсем килә,— диде Михаил Кузьмич.— Ниндирәк адәм ул?

— Күпне күргән кешегә охшый. Бик күп белә. Теләсә нинди әйберне сора, ул аңа җавап бирә. Нык укыган, ахрысы.

— Тегенди кеше түгелме?— Кузьмич үзенең имзаларын күзләре белән иркәли, сөя иде. Шулардан аерыла алмый. Бар эшләрен онытты. Күз кырыйларында кинәнү нуры. Күптән инде аның мондый куаныч кичергәне булмаган шикелле иде.

Нина Ахуновна да, үзенең мөһердәге имзасын күргәч, бик нык шатланды. Саескан кебек чыт-чыт килеп сөйләнде. Соклanудан күзләрен ала алмады. Ул да үз имзасын ярата икән. Әнвәр факсимиле-мөһерне аңа бирде. Нина Ахуновна әйбәт күңелле хатын иде:

— Бу яхшылыкка мин дә бер яхшылык эшләрмен әле сиңа,— диде.— Мин сине бер домком белән таныштырырмын.

Һәм сүзендә торды. Эштән соң Әнвәрне домкомга алып китте. Пеләтән урамы буйлап бардылар. Ниндидер чатлардан борылдылар. Урамнар бик пычрак иде. Һавада сабын заводыннан чыккан әллә нинди начар ис.

— Мин сине, энем, бик җәллим,— диде Нина Ахуновна.— Менә йөрәгемне бирер идем.— Ул биек күкрәге турында йодрыгын йомарлап читкә таба сузып алды.— Беләсеңме, домком Фатыйха апа бик үткен хатын. Шәхси йортларның башы ул. Теләсә, сине фатирлы итә ала. Мәсәлән, үз йорты белән яшәүче ялгыз карчык була. Гомере дә озак калмагандыр. Сине шуңа пропискага яза. Син карчыкны опекага аласың. Бераз вакыттан карчык аллаһе әкбәр! Йорт сиңа кала. Ләкин Фатыйха апага ошасаң гына...

— Ничек ошарга соң аңа?

— Хатын-кыз җебегәнне яратмый. Бәрек бул. Күзенә кер. Хатын-кызга ни кирәк? Таяныч!

— Миннән таяныч чыкмас шул?

— Чыга, энем, чыга. Холыгың гына булсын.

— Анысы ничек тагы?

— Акча белән торылмый, сабырлык белән торыла, диләр. Дөрес ул, энем...— Нинада ачы тормыштан килә торган хикмәт сизелә иде. Әнвәр әле бу ваклыкларны аңлап җиткерми. Шуңа күрә дәшмәде. Тыңлап кына барды. Бу хатыннан күп нәрсәгә өйрәнергә буладыр.

Бата-чума шактый гына баргач, бер алты почмаклы таза йорт

каршында туктадылар. Шушы икән. Капкасы рәшәткәле, җиңел иде. Аны ачуга эт өрә башлады. Ул арада верандадан иңенә оренбург шәле салган бер хатын чыкты. Әткә кычкырды:

— Карзун! Карзун!

Теге тынгач, боларга борылды. Нина Ахуновнаны күрүгә, чын шатланып эндәште. Әнвәр исә, Карзун дигән исемне кайда ишеткәнем бар иде соң, дип, хәтерләргә маташты. Юан хуҗа хатын өйгә дәшә иде. Нина Ахуновна белән хәл-әхвәл сөйләшә-сөйләшә өйгә керделәр. Өйнең бер ягы такта белән бүлеп алынган. Шушы домком икән. Нина Ахуновна сөйләп килде: Фатыйха Диндарованы сугыш вакытында мөдир итеп куйганнар. Телгә-сүзгә үткен булганы өчен. Үзенең грамотасы юк. Кул куярга кызлары кулыннан тотып өйрәткәннәр. Әмма герблы мөһере булгач — түрә. Аннардан башка берни эшли алмыйсың. Бөтен кешенең юлында ул тора. Паспорт ала алмыйсың, прописка да булмый. Үзенең бу форсатыннан оста файдалана, ахры, мөдир, дип уйлады Әнвәр. Теге як бүлмәдә пианино уйный башладылар. Димәк, шактый әйбәт яши.

Керүгә, Нина Ахуновна:

— Фатыйха апа, җан-ным,— дип тотынды.— Менә бу егет бездә эшли. Үсмер генә, ә немец-варварлар үзен тураклап бетергәннәр! Бик җәллим үзен, Фатыйха апа, йөрәгем өзелеп төшә! Шул балага бер почмак табып бирә алмассыңмы, ә?— Ул текә күкрәге турында йодрыгын йомарлап куйган, күзләре юешләнә башлаган иде. Әнвәр курыкты, елап җибәрмәсен тагы. Нина Ахуновна — игелекле кеше. Бу аның бер дә ясалмалануы түгел. Чын күңелдән шулай. Әнвәр Диндаровага карап тора. Хатын бик сак күренә. Ул Нина Ахуновнаның сүзләрен күңеленә алып тыңламый шикелле, эчкә үткәрми кебек. Менә ул сүзләр аның иңнәренә, кулларына орынып идәнгә борчактай коелдылар сыман. Мондый очракта әдәплелек алга чыга, юату, тынычландыру сүзләре. Билгеле инде, эш батмады. Мондыйларны бу хатын күп күргән. Аның кире кагу сүзләре дә әзер. Шомартылган.

— Нина, кадерлем!— дип башлады.— Без бит кечкенә кешеләр, безнең мөмкинлекләр юк,— диде. Мәгънәле киңәшләр әйтергә тотынды. Әнвәрне җәлләвен кат-кат белдерде. Сүзләре төче һәм җиңел иде. Һавада очып йөри торган сүзләр. Әнвәр шәһәр халкының бик төче сөйләшүенә игътибар итте. Авылда алай түгел. Анда тупас тел, әмма һәр сүзе чын. Бер тамчы ялган юк. Кайда төче, тәмле сүз, шунда ялган, шомарту булыр. Ни әйтергә белмәгәч, Нина Ахуновна, җиз тимерле кара ридикюленнән фиксимилесен алды да өстәлдә яткан кәгазьгә баскалап, Диндаровага күрсәтте.

— Кирәк түгелме?— диде пышылдап. Теге исә обой артында кыштырдаган тавышка сагайган мәчедәй кинәт тынып, саклыгын арттырды.

— Ә-ә,— дигән булды шаярткан тавыш белән һәм шул рәвешле бу нәрсәнең бәясен, әһәмиятен бер дә калдырмыйча.— Булса зыян итмәс иде!— Ул бу эшнең бик пүчтәк нәрсә икәнен искәртте, аны тәмам юкка чыгарды.

— Әнә егет коя да куя!— диде Нина серлерәк пышылдап.

— Имзагызны бирегез,— дип Әнвәр Нинаның сүзен куәтләде. Фатыйханың маңгаенда җыерчыклар җыелып өскә менде, аннан язылып бетте. Ул ышанып җитми иде. Шулай да боларның күңеле булсын өчен генә сүз тыңлавын белгертте.

— Ике данә булсын иде,— дип куйды. Читкә карап тора башлады. Әнвәр аның имзалары булган кәгазьне алып кесәсенә салды.

Ә Гамәшев заказга бик шат иде. Ул, Диндарованың имзасын озак өйрәнеп, карап торды. Бу аның үз кулы түгел бугай дип аптырады. Әллә шәхесе юк кешеме? Башын селкеп торганнан соң, Гамәшев моноклен күзенә киде һәм коралын кулына алды. Эш аның өчен дару кебек иде. Шундый чакта йөзендәге авырту җыерчыклары язылып китә аның.

Ничектер шулай көйләнеп кителде: шимбә көнне Әнвәр эштән Турганов янына кайта. Шунда куна. Иртән сыра алып, кабарга тегене-моны кыстырып, кызлар янына баралар. Нифа белән Зәлия алар килүгә шат. Тыштан гына түгел кебек. Бигрәк тә Нифа киң күңелле, юктан гына да шатлык табып көлә, шаян сүзләр сибә. Көлүе белән бүлмәне шатлыкка тутыра. Биредә үзеңнең аяксыз икәнеңне дә онытып торасың. Алар белән үзеңне тигез, тиң итеп күрә башлыйсың. Шул ягы рәхәт иде. Кызлар чәй куялар. Табын түгәрәкләнә. Кечкенә бер нәрсәдән дә көлә-көлә сөйләшеп утыралар. Сүз арасында беленә: Нифа егерме өченче елгы икән, биредә иң өлкәне. Ә иң кечесе Әнвәр. Сүз сөрешен Нифа алып бара, ул узаман биредә. Конкрет уйлый белә, аек фикер йөрткәне сизелеп тора. Ниндидер чаялыгы, зирәклеге бар аның. Эштә дә алдынгы икән. Меховой гәзитенә мактап язып чыгарганнар. Гәзитне яшергән җирдән Зәлия алып күрсәтте. Нифа әз генә кызарып куйды. Кызыллыгы тиз үк бетте, сүзне икенчегә борыр өчен тырыша иде.

— Ганс тәре,— дип төртте ул егеткә шаяртып. Ярата башлаган икән. Кыз егеткә көлеп сукты исә, димәк, ярата, бер дә шикләнмәскә мөмкин.— Өйләнгәч син үзгәрмәссеңме? Икенчеләнмәссеңме, ә? Әни гел әйтә иде: әтиең егет чагында бик әйбәт иде, өйләнгәч, икенче төрле булды да куйды, дип. Син дә шулай булмассыңмы?— Үзе шырык-шырык көлә, матур, килешле күкрәкләре селкенеп тора. Ул бер уен да эчендә саклап тотмый, ахрысы, шушы минутта башына ни килә, шуны әйтә дә сала...

— Курыкма, Нифа, мине үзеңчә калыпларсың,— дип Турганов та көлде. Аның кыяфәтендә үзен хатын-кыз кулына бирәсе килү чагылды. Шуны әйбәт нәрсәгә санау, горурлану да беленә иде. Моның ниндидер бер рәхәтлеге бар сыман. Әнвәр эчтән бер нәрсәне тойды: аның да үзен Зәлия ирегенә тапшырасы килә иде. Турганов исә Нифага сокланып карый. Нифа белән бераз масая да кебек. Ирлекме бу, әллә түгелме?

— Калыпларсың сине, син үзсүзле татардыр әле?

— Син дигәндә, Нифа, башым иДәндә.— Турганов сары чәчләрен бармаклары белән тараштыра, бераз үсенеп киткәндәй була. Нифа шаяруын дәвам итә. Әнвәргә төбәлә.

— Син, мыштым малай, үзгәрмәссеңме, ә?— дип шаркылдый.— Бер хатын әйтә икән: егетләр барысы да әйбәтләр, ә начар ирләр каян була соң?— дип.

Әнвәр кызара, ничектер уңайсыз аңа, ни дип әйтергә сүз таба алмый.

— Белмим,— диде Әнвәр.— Алдагыны алла белә, диләр картлар.

— Алла каян белсен, үзең белергә тиеш.

— Алдан ничек әйтә аласың? Болай эшләрмен дип, бер эшне уйлыйсың, уйлаганың барып чыкмый...

— Ә син барып чыгарлык ит, менә булырсың егет!— дип Турганов кыюланды. Нифа алдында аның бераз үзен күрсәтәсе килә иде.— Менә бaрактан «паровой»лы бүлмә алырга өметләнәм. Һәм шуңа барыбер ирешәчәкмен!

— Каты булу кирәк анысы...— дип Әнвәр сүзен әйтеп бетермәде. Үзендә Зәлия карашын тоеп кызарды, керфекләре түбән төште.

— Җебегәннәрне яратмыйлар,— диде Нифа, Әнвәргә төрттереп, ниндидер акыл әйтергә теләгәндәй. Бу юлы ул шаркылдамады. Барысы да җитдиләнеп калдылар. Тормышның уен түгеллеген, кешене кырыкка төрләндерә, бөгә икәнен ничектер ерактан гына булса да сизәләр, шуннан куркалар иде кебек.

— Кешене дөнья алты килештә төрләндерә,— диде Әнвәр Зәлия алдында үзен белдекле итеп күрсәтәсе килеп.— Баш килеш, иялек килеш...

— Кара, мыштым,— дип ияк какты Нифа сүзнең аскы мәгънәсен аңлап.— Әллә сиңа акыл теше чыгамы, малай?

— Юк, ул көне-төне китап укып ята. Бөтен китапханәне укып бетерде инде...— Турганов дустын мактыйсы һәм хуплыйсы килеп әйтә иде. Нифа Әнвәргә күз сирпеп куйды. Ахрысы, киштәсе буш түгел бу мыштымның, дип уйлады кебек.

— Башым төшсез кабак, бик күп кирәк сабак,— дип Әнвәр җорланган булды, учы белән чәчләрен сыпыргалады.

— Укып нәрсә?!—дип Турганов тавышын күтәрде.— Яшәргә кирәк! Әниең сырхап ята, шуны кайгырт ичмаса!?— Аның сүзләрендә Әнвәрнең укуга омтылуыннан көнләү сыман нәрсә бар иде. Юкса, Әнвәрнең авыру әнисен телгә алып тормас иде.

— Юк, укысын, кеше булсын!— Нифа саф күңелле ичмаса, һәркемгә хәерхаһ кына карый.

— Ул болай да кеше.— Турганов үзенекен куалады.— Укып эреләнеп китәр дип куркам!— Шаяртып күз кысты.

— Безнең авылда шундый җыр бар,— диде Әнвәр.— Болай: Кулымдагы йөзегемнең исемнәре сөйкемле. Эреләнмә, вакланырсың, вак акчалар шикелле...

— Ә бездә мондый,— дип Нифа да җыр әйтте.— Кулымдагы йөзегемнең исемнәре игерик. Ятлар безне таптамакчы, ә без таптатмый йөрик.

— Бу-шәп! Ятларга хут бирергә ярамый.— Турганов сәгатенә караштыра башлады. Уннар тирәсе булгандыр. Нифа өстәл артыннан кинәт кенә торды да коридорга чыгып керде. Кунаклар кузгалалар иде. Нифа иреннәренә бармагын куеп, шыпырт кына әйтте:

— Мин хуҗаны җайладым.

Бу — теләкләргә бик туры килә торган сүз иде. Аңлашылды. Кунарга калырга була. Нифа барысын да эчке бер зирәклек белән эшли. Ул рәтли алмаган эш булмас. Әнә кырыс хуҗага да ачкыч тапкан. Нифа лабораториядә эшли икән. Эш өчен аларга спирт бирелә, ди. Шул кайчакта артып кала. Әлбәттә, аны әрәм итмиләр. Кечкенә одеколон шешәсенә салып чыгалар. Ә абзыйга бик ярап куя икән. Әйе, хәзер эчемлек бик күп нәрсәләргә ачкыч урынына йөри башлады.

Нифа белән Турганов караватка урнашты. Иданнең аргы почмагына Зәлия киез һәм иске-москылар җәйде. Утны сүндергәч, Нифа шаяртып сөйләнде:

— Ганс, син минем белән татарча көрәш башлама,— диде.—Мин аның тәртибен белмим, типтем очырдым булыр.— Үзе яратып көлде. Шулай сөйләнү аңа рәхәт кебек иде. Ул тагы нидер сөйләнә башлаган иде, Турганов аның авызын үзенеке белән япты, сүзе бүленеп калды. Нифа шуннан тынды...

Әнвәр дә Зәлия янында утын пүләне кебек тик кенә ята алмады. Алай ятса, кыз аңа рәнҗер, отыры аңардан бизәр иде. Ул Зәлияне кочарга, кысарга тотынды. Үбә белми иде. Ә Зәлия аны үпте дә үпте. Әнвәр кочарга гына белә иде. Ләкин Зәлия эчтән әллә нинди кием кигән. Бөтен җире кыштырдау тавышы чыгара торган нәрсә белән төрелгән. Бу плащпалаткадан тегелгән нәрсә булырга тиеш. Плащпалатка бик хутта иде. Зәлиянең биленнән кысып алсаң, кыштырдау тавышы бөтен бүлмәне тутыра. Теге бүлмәгә дә ишетелми микән әле? Кызлар шулай киенергә тиеш микәнни, дип уйлый Әнвәр. Нифа белән Туpгановтан бер дә кыштырдаган тавыш чыкмый кебек. Зәлия нигә болай киенде икән? Миннән курыкты микәнни? Тагы шунысы да бар: кызның биленә орынсаң, бер төрле кыштырдау тавышы чыга, күкрәгенә үрелсәң — икенче төрлерәк, билдән түбән тагы бүтәнчә тавыш килә иде. Кулыңның кай төштә йөргәненә чаклы ишетелеп, беленеп тора. Әнвәрнең моңарчы кызлар белән кунганы юк иде. Авылда туры килмәде. Бүтән егетләр кызлар янында кунып кайткач сөйләгәнне ишеткәне булды, ләкин бер дә болай ефәк кузысы кебек «броня»га төренгән кыз хакында колагына

кермәде. Зәлия усал, ертлач егетләргә туры килгәндер дә шулай саклану чарасы уйлап тапкандыр, дип уйлады Әнвәр. Кулын тик кенә тотты, бер төшкә үрелмәде, сузылмады. Ә Зәлия аны үпте, иреннәрен озак итеп тигереп тора иде. Әнвәрнең шуңа күңеле бик хуш булды. Үзендә уянган тойгыларга ниндидер җавап иде бу. Зәлия дә аңа битараф кына карамый икән. Үзенә тиң күрә икән. Таза-сау кыз кешегә аягы булмаган егетне иш итү бик авырдыр, оят тадыр. Зәлия әнә шуңа да карамастан, аны ничек якын итә! Үзенә күрә бер батырлык бу, тәвәккәллек. Әнвәр шуларны уйлап, тик кенә ятты, күзләрен йомды. Әмма бер як белән озак ята алмый, ярасы авырта башлый иде. Шулай да чалканга җайланып, йокларга итеп маташты. Шактый вакыт узгандыр инде. Башы томан эчендә йөри иде. Нәрсәдер шап итеп идәнгә төшкән тавышка күзләрен ачты. Караңгыда Тургановны шәйләп алды. Аның протезы шапылдаган икән. Тиз генә киенделәр, шыпырт кына, песи адымнары белән коридор аша узып, чыгып киттеләр.

Тургановның фатиры моннан ерак түгел иде. Шунда кайтып, калган йокыны дәвам иттерделәр. Икенче көнне соң гына торып, хуҗа үзенең запас сырасын чыгарды. Авыз чылата-чылата фикер алышалар.

— Нифа ничегрәк тоела сиңа?

Тургановның ул кызны Әнвәрдән мактатасы килә. Әнвәр шуны сизеп алгач, Нифаның уңай сыйфатларын әйтә. Чөнки Нифа хакында болай да яман нәрсә уйга килми иде. Аның уңганлыгы күзгә бәрелеп тора. Тик Әнвәрнең мактау сүзләре бик ярлы. Фантазиясез. Ансыз мактау нәрсә ул! Бернинди тәэсирсез. Тургановка ялкынлы булсын. Нифа белән горурлана ул. Күзләрендә нурлар чаткыланып китте, йөзенә мөлаемлык өстәлде.

— Мин чисталыкны яратам,— дип сөйләнде.— Нифаның чисталыгы шәп! Күрдеңме, идәнгә түгәрәк-түгәрәк паласлар җәйгән. Салават күпере кебек матурланып торалар. Аның кул эше! Ул бит зур кешедә өй җыештыручы-караучы булып торган. Шулар аңа паспорт алып биргәннәр, авылга бүтән кайтмаган. Җайлы эшкә урнаштырганнар.

— Әйтәм, аңарда ниндидер затлылык сизелә, — дип куйды Әнвәр. Турганов исә бер карыш үсеп киткәндәй булды.

— Менә шул-шул!

— Ничек таныштың син аның белән?

— Госпитальнең шефлары иде. Беләсең ич, бәйрәм саен килеп, мәҗлес уздыралар иде. Октябрьнең егерме сигезенче еллыгына да килделәр. Нифа оештырып йөрүче иде бугай. Мин табынга иң соңыннан утырдым. Урыным Нифа янына туры килде. Су кушкан спиртны Нифа авызына да алмады. Үз өлешен миңа биреп барды. Ә минем «чүмәлә»гә тиз менде. «Чүмәлә» эчендә уйлар җиңеләйде һәм шундый тизләнделәр, мин һавада очып йөри башладым. Оҗмахта. Рәхәт. Кулга, билгеле, шулай ук тизлек өстәлгән, кызга таба сузыла. Кыюланган. Кыз исә кулны этәрми, кулга сукмый. Кыздан ниндидер дулкын кебек нәрсә миңа килеп бәрелгән шикелле була, кәефне күтәрә. Синең шулай булганы бармы?

— Юк.

— Син әле яшел икәнсең. Шуннан сөйләшеп киттек. Ә ул сүзне кабул итә, йөз чөерми.

— Ә Зәлия белән каян таныш алар?

— Дөбъяз районы, күрше авыллар. Зәлия ничектер Нифага чыбык очы кардәш тә икән.

— Карале, ә?

— Әх, Әнвәр, белсәң, Нифа нинди затлы, әйбәт кыз! Миңа чыкса, ирәм булмасмы ул? Мин кем? Үзем аяксыз, әнием сукыр.

— Кайнананың сукыр булуы килен өчен шәп кенә була, ди бит?! — дип Әнвәр юатмакчы булды.

— Шаяртасың, ә мин Нифаны жәллим, жәллим...— Аның тавышы

кинәт калтыранды, ул күзләрен учы белән каплады. Тармаклы-тармаклы зәңгәрсу кул тамырлары хөрмәт уяталар иде. Әнвәр бераз аптырап калды. Тургановны беләм дип йөри иде. Ә ул исә нечкә күңелле дә икән.

Аның күзләре мөлдерәмә яшь иде.

— Мин сине аңламыйм әле, Ганс...

— Юк, аңлыйсың! Әнинең сукыр булуын аңа ничек әйтергә? Ул миннән бөтенләй өркеп качмасмы?

Гансның чыраенда зур кайгы иде. Әнвәр ничек кирәк алай юата башлады. Турганов ятимлек-кимлек кичереп үскән. Шулай да бәгыре катыланмаган икән. Әллә Нифа белән йөри башлагач, эчтәге яралары кинәт үзләрен белгерткәнме? Торкарланып яткан-яткан да хәзер тишеләп чыккан. Тойгыларның кайда, кайчан безне нәрсә эшләтүен алдан һич белеп булмый шул.

* * *

Бүлмәдә Зәлия үзе генә иде. Хәзер Нифа күбрәк Ганс янында була. Аларның аралары якынайганнан якыная бара. Ә Зәлия белән ничек борчак пешерергә? Бүген Зәлиянең йөзендә таркаулык иде. Колагын каплап, ярты битендә дугайланып тора торган матур чәчләре дә чәбәләнгән. Йөзенә күңелсезлек пәрдәсе эленгән. «Нәрсәдән булыр бу?»— дип пошынды Әнвәр. Кыз аның йөрәгенә якын, кадерле була башлаган икән! Берәр кайгысы бар микән әллә? Ничек белергә, ничек күңелен күтәрергә? Зәлия сөйләшәсе килмичә генә сүзләрен әйтә. Әнвәр өстәл артына аның кырына килеп утырды һәм кулларын хәрәкәткә җибәрде. Кочмакчы булды. Кыз аның омтылышларын кире кага иде.

— Кара, сине тәрбияләргә кирәк икән! — дип шелтәләгән итте. Бу Нифага охшарга тырышу иде. Зәлия өлгене шуңардан ала. Үзе исә кочаклаганга бик үк каршы да түгел төсле.

— Йә, тәрбиялә! — Әнвәр Зәлия сөйләшкәнгә шатланды.

— Синең авыл гадәтләреңне юнып ташларга кирәк.

— Ышкың бармы соң? — Әнвәр көчәнеп кенә көлә. Зәлиянең кәефен күтәрәсе килә.

— Аңа чаклы балта белән юнасы булыр!

— Кара син, бигрәк!

— Сине төзәтеп булырмы соң? Синең үз тугызың тугыздыр әле? — Зәлиянең тавышы көррәк чыкты, уенны кабул күрде шикелле.

— Әйе, андый чатаклык бар бугай миндә!

— Менә! — Зәлия үзенең фаразы дөрес чыгуына сөенгәндәй иде. Бары күңеле генә күтәрелсен, әллә нинди кимчелекләрне өстенә алырга риза Әнвәр. Бераз тын гына утырганнан соң, күңел төбендә яткан сүзне әйтте:

— Зәлия, әйдә укырга керәбез, ә? — Әнвәр аңа туры карады, кыз исә карашын читкәрәк алды. Озак дәшми торды, эчтән үзен тыңлый иде. Әнвәр бер көн эшеннән сорап китеп, Кремльгә, министрлыкка барып белеште. Укырга кая керергә мөмкин? Ак чәчле бер бик мөлаем хатын аңа төгәл мәгълүмат бирде. Әнвәрнең хәлен күреп, ярдәм итәргә теләп. Әйе, тизрәк бер һөнәр алып чыгу өчен иң уңае — педучилище икән. Өч елдан син укытучы. Аннары белемне читтән торып күтәрергә мөмкин. «Сиңа иң җайлысы Бөгелмә педучилищесы булыр,— диде ягымлы хатын.— Аның директоры бик әйбәт, үз ашханәсе бар, бер тапкыр ашаталар». Соңгысы бик мөһим иде, хатын шуны кат-кат искәртте. Әнвәр, ничек булса да укырга, дигән карарга килеп кайтты. Чөнки эшенә күңеле ятып бетми, сан-цифрлардан сару кайнарга тотына иде.

— Миңа укырга соң инде,— диде Зәлия, чикләвек төсле көрән күзләрен челт-челт йомгалап.

Юк, соң түгел! Син әле егермедә генә, өч елдан — укытучы.

— Әйем, минем укыйсым килми.

— Ник?

— Мин мәктәптә, кайчан шушы җәзадан котылырмын, дип хыяллана идем...— Зәлия кулын гына селкеде. Әнвәр тотлыкты, чөнки һич тә болай укудан бизгәнне ишеткәне юк иде. Аның өчен укудан да рәхәт нәрсә булуы мөмкин түгел. Зәлиянең йөзенә бераз уңайсызлану да чыкты. Әмма укырга теләмәве белән горурлана да кебек иде. Шуны акларга иткәндәй әйтә куйды:

— Бер авыз көлгән чакта, икенче авыз елый,— диде. Әнвәр моның мәгънәсен аңлады. Бер кешедә шатлык булганда, икенче кешедә кайгы була. Бер кеше болай фикер йөртә, икенче кешедә бөтенләй бүтән төрле уй-исәп. Зәлиянең берәр кайгысы-фәләне юктыр бит? Әйтергә генә теләмиме? Юк, ахрысы, булса сизелер иде. Үзе сиздермәсә дә, Нифа аша беленер иде...

Әнвәр театрга билет алган иде, шуны бирде дә чыгып китте.

Кичен шунда очраштылар. Нифа бик сөенгән иде. Әнвәргә рәхмәтен белгертте. Зәлия исә үзен аңа барыбер сыман итеп тота иде. Бәлки, чынлап та барыбердер? Шулай да матур киенеп килгән. Тик биек үкчәле туфли генә кимәгән. Нифа исә биек үкчәле туфлидән йөри, ул бер карыш үсеп киткәндәй. Биле дә сыгылмаланып тора. Биек үкчә хатын-кызны матурайта, оча торган хикмәтле нәрсә, ахрысы. Аны шәһәрчә итә дә куя. Нифаның бөтен җире шәһәрчә, хәрәкәтләре, сүзләре дә, үз-үзен иркен тотуы да. Зәлиядә әле авыл кыюсызлыгы һаман утыра кебек. Әнвәр хәзер һәр төштә сизә: авыл белән шәһәрдә шактый аерымлык бар икән. Авылда кеше бөтен авыл күз алдында, бер нәрсәсен дә яшерә алмый, барысын күреп, белеп торалар. Шуңа үзен бик кысада тотып кына яши. Сүзе белән эше бер була. Әгәр ялганласа, ул бик тиз тотыла. Чынын гына сөйләргә өйрәнә. Шәһәрдә ялганлаганны тиз генә тотып булмый. Әхлак кысалары да киңрәк, иркенрәк.

Театрда тоташ хатын-кыз гына булыр, дип уйлаган иде Әнвәр, ләкин алай булып чыкмады. Ир-ат халкы да күп иде. Галифедән, гимнастерка өстеннән кара пинжәк киеп җибәргән, ак яка теккән. Кайберләре әле хәрби киемнәрен дә алыштырмаган, медаль-орденнарын күкрәгенә таккан, чылтыратып йөри. Погоннары гына юк. Шәһәрдә иратның әзлеге артык күзгә ташланмый икән.

«Тормыш җыры» спектакле иде. Сәхнәгә өстән яктылык тасмасы сузылып төште. Шул нур тасмасында әллә каян чыккан көя күбәләкләре очкалаганы күренеп китте. Көчле музыка яңгырады, көн башланды. Малай ролен Зифа Басыйрова башкара иде. Җырны да ул җырлый. Бик моңлы җыр. Спектакльгә шул җырны ишетер өчен генә дә йөриләр икән. Әнвәр сугыш вакытында колхозда эшләде, бу тормышны белә. Биредә ул бик җиңеләйтелеп күрсәтелә. Анысы шулай кирәктер инде. Сәхнәдә дә кыен тормыш күрсәтелсә, нәрсә була ул! Юк, тиеш түгел! Әмма булган кыенлыкны да җыр үзенең моңы белән күмә, җиңеләйтә дә куя иде. Моң тылсымлы. Күңелләргә үтеп керә, айкый. Җанда утырган, авырайтып торган юшкыннарны юып чыгара. Моң күзгә яшь китерсә дә, кайгыны көчәйтми, ә җиңеләйтә. Күз яше кайнарлыгы белән җандагы ташлар эри шикелле. Күкрәккә иркен, сулыш алырга әйбәтрәк булып китә иде.

Тик галеркада кычкырып утыручылар да бар иде. Болар Яңа Бистә егетләре, имеш. Бераз төшереп алганнар күренә. Артистларга нишләргә кирәген кычкыралар: «Тот та үп, шуннан карышуы бетә аның»,— дигән урынсыз сүзләр ишетелгәләде. Артистлар әйбәт, берни булмаган кебек үзләренчә уйныйлар.

Әнвәр менә ел ярым диярлек Казанда. Ишетеп тә, күреп тә шуны белде: Яңа Бистә ничектер караңгырак, тәртипсезрәк төбәк саналып йөртелә икән. Бәлки бу сүз генәдер. Яманатың бер чыкса, аны берни

белән дә бетереп булмый инде. Һәрхәлдә алар бик эшчән, гаярь халык булырга тиеш. Зур-зур завод, фабрикаларда эшлиләр, ә квартира мәсьәләсе бик кыен. Завод-фабрика үзенә бик күп эшчеләр җыя, ә квартира белән тәэмин итеп житкерә алмый әле. Кайсы сугыштан кайткан, кайсы авылдан ычкынган. Шәһәрдә өйләнә. Семья барлыкка килә. Кеше өстендә яшәве бик авыр. Семья башлыгы үтә кыю карарга килә. Үзенә йорт салып чыкмакчы була. Якыннан урын бирмиләр. Шулай да өйлек материал җыя. Такта, бүрәнә, кирпеч әзерли. Рамнарны эштә ясап алып кайта. Бары тупланып беткәч, үзе белән эшли торган егетләргә әйтә. Алар сүзсез дә аңлыйлар. Унлап дастуен егет җыела. Төн эчендә өйне салып өлгертергә кирәк. Поселокта булачак күрше үз кеше, цехташ. Алдан сөйләшенеп, өйлек барча материал аның ишегалдына ташып куелган. Эшне бүлешәләр. Тотыналар. Егетләр ут уйнаталар. Көзге төн жылы әле, үзе озын. Кем нигезгә бүкән утырта, кем такта кага, арага пычкы чүбе тыгызлый, кем шунда ук морҗа чыгара. Сөйләшмичә тын гына эшлиләр. Тиз, тиз, тиз! Төн яктыргач, иртән торып чыккан кешеләр күрәләр: күршедә генә ак такта йорт пәйда булган. Өч тәрәзәле. Тәрәзәләргә ак пәрдә эленгән. Морҗасыннан төтен күтәрелә. Алай икән, хәерле булсын. Сәгать уннарда планшетын бот турына ук салындырган милиционер килә. Йорт янында беркем дә юк, ишек бикле. Тәрәзәдән карый. Мичтә учак яна, мич алдында бәләкәй генә бер малай ду күчеп уйнап йөри. Милиционер бер сүз дә әйтми, кайтып китә. Соңыннан яңа хуҗа йортка домовой кенәгә алыр өчен йөри башлый. Анысын инде рөхсәтсез салынган йорт дип бераз сузалар. Барыбер бирәләр. Шул рәвешле Яңа бистә ягында зур гына поселок үсеп чыккан, ди.

Нифа белән Турганов бер-берсенә ныграк ияләнә баралар иде. Егет үзенең «кысуын» бик йомшак итеп, сизелмәслек рәвештә алып бара. Үзе Нифа әйткәнчә генә булырга тырыша. Күзенә генә карап тора. Шулай да Нифа кайчак аңа:

— Ә син үзгәрмисеңме соң? — дип әйтеп куя. Тургановның эчемлек белән дуслашып китү ихтималыннан бик шүрли икән. Әтисе шуңа хирыс булган, бер дә юньле көн күрсәтмәгән. Адәм баласы шул шәйтан белән бер мөнәсәбәткә кердеме, һич тә ычкына алмый, үзе дә шәйтанга әйләнеп харап була. Ганс хәзер тәмам куркуга төшеп, сыра да эчми башлаган иде. Нифага ярау өчен ул барысын да эшләргә риза. Монда ул ниндидер егетлек күрә иде. Шуны зур эш саный иде. Чын ир булу өчен сөйгән кызына үзеңне бөтенләйгә тапшыру бик кирәкле шарт. Шунсыз ир дигән зур исемгә лаек була алмыйсың. Үзеңә кайчак читен булса да, кызыңның кәефенә ярар өчен барысын да җиңәргә кирәк. Бу зыялылык, затлылык. Ганс моны шулай аңлый һәм бик теләп эшли иде. Ул бары Нифа дигәнчә генә торыр, яшәр. Әнвәр шуны күрә дә, үзен уйлый. Ул да аның кебек тулысы белән үзен Зәлия ирегенә куярга ризамы? Әнвәр дәлилләр эзли: әгәр акыллы, уңган булса — нигә үзеңне хатын-кыз ирегенә бирмәскә?! Әмма бу, ахрысы, уйларга гына ансат. Уйларга ансат нәрсә гамәлдә бик авыр булып чыга.

Турганов та шәһәрдә яшәүнең сәер якларын сөйләп куя.

— Биредә, парин, авылдагы кебек түгел икән. Бөтенләй икенче төрле. Әйтик, авылда бер ялгыз хатынга утын, йә салам кайтарасың. Ул сиңа рәхмәт укый. Тегесенә тагы бер нәрсә эшлисең. Ул да игелекне аңлый. Синең абруй үсә. Игелек итәсең килеп кенә тора. Яхшылык итүдән дә рәхәт нәрсә бар! Сиңа бөтенләй зур кеше итеп карыйлар. Җан кинәнә. Күңелең яктырганын сизеп йөрисең. Ә шәһәрдә... Бер кешегә цехтан барда бирдергән идем. Берни алмадым-нитмәдем. Игелек итәсе килеп. Ләкин шул нәрсә профкомга ошамады. Кемгә игелек итәргә белмисең, ди. Миңа бик каты ачуланды. Квартир исемлегеннән чигерде.

Үземә начар булып төште минем игелек! Менә ничек!

— Әйе, монда бизмән башкачарак, ахры? Шуңа күрә минем укыйсым килә.

— Шәһәргә ияләшү авыр. Ялгыз бигрәк тә! Бер иптәш тапмыйча һич тә ярамый!

— Нифа риза түгел мәллә?

— Риза да кебек, тик әнисеннән курка. Әле ял алып, әнисенең кылын тартып карарга кайтып китте.

— Нифа барын да булдырыр.

— Ут йотып ятам менә. Нәрсә әйтер? Шәһәрдә ялгыз авыр, малай.

Ниһаять, берникадәр вакыттан соң алар язылышты. Шул җәһәттән кечкенә генә табын да әзерләнгән иде. Ләкин Нифа да, Ганс та ничектер үзгәреп киткәннәр. Борыннары салынган. Нифаның кечкенә нәрсәдән дә кызык табып көлүе бөтенләй калмаган. Әнвәр аларны котлап тост әйткән булды, бәхет, игелек теләде. Әмма тостны күтәреп алмадылар. Стаканнарны күтәрделәр дә эчмичә кире куйдылар. Әнвәр дә бер генә уртлап алды. Нифа, уңайсызланып, коридорга чыгып китте. Әнвәрнең сораулы карашы Ганска төртелде. Тегесе, шулай ук күнелсез көе, җилкәләрен генә җыерып торды. Бер сүз дә әйтмәде. Нифа керде, күзләре кызарган иде. Анда елаган икән. Хәзер аңа берәр сүз кушсаң, кычкырып елап җибәрәчәк иде. Әнвәр тыелды. Шаяртып Залияне уртәргә тотынды. Ул да табынны җанландыра алмады. Нәрсә булган Нифага? Кияүгә чыкканына үкенәме? Аяксыз кешегә туры килдем дип эчтән рәнҗиме? Ул, билгеле, таза, бөтен җире килгән егеткә лаеклы кыз! Алайса нигә бу адымны ясады икән? Бик җаваплы, авыр адым. Ул хәзер икенче төрле тормышка адым атлады. Бу — биек җирдән сикергән кебек. Куркыныч. Хәзер кире чигенеп булмый инде. Нифа җаваплылыкны тоеп, уйга калганмы? Өлешенә тигән көмешнең ул хыял йөрткәнчә булмавыннан күңеле кимсенгәнме? Моның өчен кемгә үпкәләргә? Бары каһәр сугышка гына үпкәли аласың?

Нифа бераз утыра да тагы коридорга чыгып китә. Тагы күзләре кызарып керә. Залия аңа ярарга тырышып бөтерелә. Нифа серен аңа да әйтми. Төпченә башласа: «Юк, берни дә булмады!» — дип бетерә иде. Ахырда квартир хуҗасын алып керделәр. Ганс аңа мәҗлеснең сәбәбен дә әйтеп тормады, бары стаканны тутырып алдына куйды. Тегеңә шуннан башка нәрсә кирәк тә түгел иде. Берни сорашмады, кызыксынмады. Икенче стаканнан соң сөйләнә башлады. Һәр сүзен:

— Мин иске режим кешесе,— дип башлап китә. Үзенең картлыгына ишарә итәме? Хәзерге тормышның элеккегедән үзгәлегенәме? Белмәссең. Авызында тешләре юк.

— Сез яшьләр — яңалар, без картлар — искеләр. Менә яңа костюм, менә иске әйбер. Алар арасында аерма бик зур. Мин Казанның иске чагын беләм. Атлы мичкә белән су ташыйлар. Мичкә белән пычрак су түгәләр. Урам буйлап «Кемгә күмер кирәк?» — дип арба белән сатып йөриләр иде. Агач күмере, самавырга. Урам тулы атлы. Кыш көне бик яман иде. Кар басып китә. Өйләр суык була иде...

Чаманы белә торган кеше икән. Үзенә житкәнен сизде дә, рәхмәт әйтеп, чыгып китте. Аннан соң Әнвәр белән Залия табынга җан кертергә итеп, шаян сүз башлаганнар иде. Бу чара да ярдәм итмәде. Сүрәнлек бетмәде. Нифа үз уена батып утырудан арына алмады. Ганс аңа сүз әйтергә, хәтта юатырга да кыймый иде. Нифа юатканны һич яратмый. Әйтә-аңлата башласаң, сиңа шундый итеп кулын селки, шып буласың. Кул селтәве: «Ялганлама!» — дигән мәгънәдә иде. Сәгать уннарда алар Турганов фатирына кайтып киттеләр.

Әнвәрне бер уй борчып торды. Залиядән сорады:

— Нифага нәрсә булган?

— Белмим. Әйтми.

— Ни булса да сизенгәнсеңдер бит?

— Юк. «Үзең белерсең әле», ди.

Караватка яттылар. Әнвәрнең каны кызуланган иде, Зәлияне нык-нык кысып кочты. Зәлия аны үпте дә үпте. Әнвәр кыюланып китеп, кулын хәрәкәтләндерде, әмма Зәлия тагы плащпалаткадан теккән «калканына» төренгән иде. Әнвәр кулын елгыррак йөртә башлагач, Зәлия:

— Шаярма! — диде һәм тагы бер сүз пышылдады. Әнвәр кинәт айнып киткән кебек булды. Кулларын җыйды, юаш песигә әйләнде. Бу яңа сүз иде, ул Әнвәрнең миенә китереп сукты. Әллә Зәлиянең язылышырга исәбе бармы, шаярып кына әйтәме? Бер яктан, язылышуны Әнвәр бик зур эш дип саный. Аңа ул әле әзер түгел шикелле. Шуңа, ахры, бу сүз бик сәер тоелды аңа. Икенче яктан, Зәлия белән рәхәт аңа. Зәлияне күрәсе килеп кенә тора. Хыялында Зәлиягә иш булырга теләү, аның белән бергә буласы килү өмете көйри иде. Ләкин ул риза булмас дип, хыялын гел куып җибәрә иде. Әнә шул сүзендә риза булуы ишетелеп китте түгелме соң? Моңа сөенеп, тизрәк шул сүзне куәтләргә, ачыкларга кирәк. Үзеңнең дә ризалыгыңны белгертергә кирәк. Әмма Әнвәр нигәдер алай итми. Кызның сүзенә сөенүен белгертсә, бу ниндидер әлегә күрмәгән хәлгә бер адым атлау булыр иде. Ул бит шуны бик тели иде. Зәлия белән бергә булыр өчен әллә ниләр бирердәй чаклары бар иде. Шул ихтимал теләк тормышка ашып эзгә төшә башлагач, хыял ачык булып алдына килеп баскач, нишләптер куркып калды. Аның бу яңа хәлгә таба адым атлыйсы килми. Ул хәл гаять җаваплылык таләп итәдер, ул таләпне үтәп булмас кебек тоела иде.

— Ә-ә, шүрләдеңме? — дип үчекләде Зәлия.

— Юк, шүрләмәдем,— диде Әнвәр, эчендәге яшерергә тырышып.

— Кинәт тәһарәтең сынган кебек булды?

— Юк ла инде, нәрсә син!

— Үзең урлашырга каршы түгел, ә?

— Кәҗә янында кәбестә торсын да, ул аны капмасын.

— Шундук айныдың.— Кыз һаман үчекли иде.

— Ярар, усал шаяртма!

Әнвәрнең бу сүзеннән соң Зәлия тынып калды.

— Кызларга алтын тавы вәгъдә итәргә кирәк,— диде Әнвәр, уйчанланып.— Алар вәгъдәне ярата.

— Белмисең, кызлар дәрәҗәне ярата! Аларның хыялы — йолдыз.

— Мин — пешкән шалкан, төшкән калган, ә?

— Сиңа чыксам, әни мине үтерә! — Зәлия көрсенде һәм әйләнеп ятты. Әнвәр күпме генә тырышса да бүтән сөйләшмәде.

Госпитальдә дә хәлләрне ашыктыралар иде. Госпиталь бинасы әлек мәктәп булган. Хәзер аны тизрәк бушату таләп ителә иде. Ярасы төзәлгән, протез алган яралыларны өйләренә озату ягын тизләтәләр. Озак дәва таләп ителә торганнарны икенче урынга күчерәләр икән, дип сөйлиләр. Бу хәбәрләр Әнвәрне дә нык кына борчый иде. Аңа хәзер икенең берсен сайлар вакыт җитте: йә өйләнергә, йә кая булса да укырга керергә?! Икенең берсе, башка чара юк шикелле. Әнвәр үзе янындагы Гамәшевтән киңәш сорап карады.

— Өйләнсәң, ахмак булырсың! — диде Гамәшев гыжылдаган көчсез тавыш белән. Аның хәле һаман артка тәгәри бара иде. Үпкәсендә ниндидер чир көчәеп киткән диләр икән.

— Иң элек аякка басарга кирәк, энекәш! Семья бит ул бик авыр йөк! Бер җигелсәң, тугарып ташлый алмыйсың. Җигелдең — тормыш арбаңны рикша кебек тартырга кирәк! Укуың яна!

— Өйләнәм һәм укырга керәм.

— Юк, ике куянны берьюлы тотып булмый ул!

— Мин ул кызны әллә яратам микән, дим...

— Ярату юк нәрсә. Ул ир белән хатын булгач кына була, балалар булгач кына.— Гамәшев хәле бетеп, мендәре өстенә түмәрдәй ауды.

Әнвәр төне буе йоклый алмады. Хәер, болай да шәфкать туташ-



*А. Тимергалина рәсеме*

лары Гамәшевкә укол салырга еш кереп торалар иде. Иртән ул авыр баш белән эшкә барды. Кәефе юк иде. Гамәшев эшләгән Диндарова мөһерен дә үзе илтергә теләмәде, Нина Ахуновнага биреп җибәрде.

Әнвәр Зәлия янында ешрак була башлады. Эштән туры шунда кайта, кайчак куныл та калгалый иде. Ләкин үзе өчен һаман бер мәсьәләне хәл итеп бетерә алмый: өйләнеп, тормыш арбасына җигелергәме, юкмы? Зәлия дә беркөн ычкындырган сүзенә эчтән үкенгән кебек йөри. Әлбәттә, аңа бик авыр инде. Аяксыз кеше белән тормышны бәйләү гаять зур тәвәккәллек сорый. Әти-әни сүзен тыңламый да мөмкин түгел иде. Әнвәр үз-үзенең куркаклыгыннан көлә. Ул хәзер, теге мәзәктәге кебек, әйткәнне тыңлый, кушканны үти торган егетмени? Мөстәкыйль рәвештә, үзе белеп, бер эш тә эшли алмыймы? Колхозда, аннан соң фронтта боерык үтәргә генә өйрәнеп бетелгән, ахры.

Хәлләр дә һаман кыса иде, аннары үзенең сыеклыгына Әнвәрнең бик ачуы килде. Күзле-башлы булырга, дип үз-үзенә үчекте ул. Шул карарын Зәлиягә туры гына әйтеп бирде.

— Язылышабыз, мин укырга керәм,— диде.— Педучилищега.

— Әни мине каргаса? — дип бөреште Зәлия.— Нишләрмен?

— Үз баласын каргарга күңеле җитәрме?

— Җитәр. Усал ул.— Зәлия бер ноктага төбәлеп, ничектер моннан китеп торган кебек утыра иде. Аның әзрәк шадрасы беленеп торган йөзендә тирән гаҗизлек. Әнвәргә шушы каршылык кына кирәк булган кебек, аңарда үҗәтле зиһен уянды. Һәм ул үзенең төшеп калган кеше түгеллеген, өч елдан укытучы булачагын, фатир алыр өчен көн-төн чабачагын тасвирлап сөйләп ташлады. Аракыны авызына да алмаячак ул! Әнә аягы-кулы бар, ләкин алкаш, аңардан ни мәгънә? Бәлки әниең сиңа шундый ир телидер?

Барганда Зәлия алдан, Әнвәр дүрт-биш адым арттан атлый иде. Зәлия шулай теләде. Ул ояла иде. Бу бик аңлашыла. Гарип кеше белән янәшә барса, танышлар очрар дип курка иде. Кремльгә илтә торган Чернышевский урамындагы ишегендә «Шәһәр архивы» дип язылган йорт янына килделәр. Зәлия башта разведка ясап чыкты. Урамның каршы ягында басып торган Әнвәргә сигнал бирде. Язылышучылар аз иде. Эшне тиз тоттылар. Гаризага бер чибәр генә ханым ризалыгын сырлады һәм кара тушь белән зур кенәгәгә язды. Аннары паспортларга мөһер сукты, шул тушь белән число һәм имзалар куйды. Торып басты да, тәбрик итәм, дип боларның кулларын кысты. Һәм икенче язылышучыларның гаризаларына сузылды.

— Син кайта тор,— диде Зәлия, шыпырт кына ишектән чыкканда ничектер читкәрәк карап. Һәм кызгылт сумкасын кысыбрак тотып, каядыр китеп барды. Табынга берәр нәрсә юнәтергәдер, дип тынычланды Әнвәр. Менә бик зур эш эшләнде. Күңелдә нинди дер борчылу-курку дулкын-дулкын булып калкына иде. Авыр сызыкны атлап чыкты. Сызыкның бу ягында бөтенләй икенче тормыш. Ваемсызлык юкка чыкты. Күңелдә нинди дер икеле-микеле тойгы. Ул сөенергә тиеш шикелле. Әмма ничектер җанында күтәренкелек тоймый. Нәрсәдән икән? Аны моңарчы беленмәгән борчулар биләп алды. Эчен нидер авырттырып тырный иде.

Әнвәр киеренке уйлар эчендә кайтып керде. Әмма Нифа барысын йолача кыландыра. Ишектән кергәндә аңа калак белән бал каптырды. Үзе шырык-шырык көлә. Ганс та шат. Аларга теге әүвәлге шатлыклы халәтләре кире кайткан иде. Кияүгә ишектән беренче кергәндә бал каптыру йоласы бар, ди.

— Зәлия кая? Нигә бергә кайтмадыгыз?

— Хәзер кайта,— дип Әнвәр плащын салды.

Ләкин Зәлия кайтмады. Кичтән дә, иртән дә, икенче көнне дә, өченче көнне дә. Әллә бер-бер хәл булганмы? Нифа Зәлиянең эшләгән җиренә барып кайтты. Зәлия бүген генә, икенче эшкә күчәм, дип

хезмәт кенәгәсен алып киткән, ди. Димәк, бернинди дә ул-бу хәл булмаган, Зәлия исән-сау. Алайса нидән бу тамаша?

Нифа һаман Зәлияне эзләде, үзен Әнвәр каршында гаепле санаган кебек иде. Чәченнән өстерәп алып кайтыр идем, дип янап чыгып китә, ләкин һич тә таба алмый кайта. Зәлия суга төшкән кебек булды. Эзне оста яшерә белә икән. Бер көнне хуҗа карт өйдә юк чакта әнисе килеп Зәлиянең әйберләрен алып киткән. Шул әни кеше кызының юлын кисмәдеме икән? Эзләүдә Әнвәр артык активлык күрсәтмәде. Зәлияне эзләп табуның хәзер бернинди мәгънәсе дә калмаганлыгын сизә иде. Аңа үпкәли дә алмый ул, чөнки таза, тиң кеше түгел. Берәү гарипкә иш булудан кача икән, батырчылыгы җитми икән, ничек аны гаепләргә мөмкин? Әнвәр шулай уйлады, һәм бу хәлнең соңы әйбәт булыр әле, дигән өмет күңелендә һаман бетмәде. Менә кинәт кенә бер көнне Зәлия кайткан булыр, гаепле генә елмаеп торыр. Ләкин аны квартир хуҗасы — карт кына каршы ала иде. Аңа Нифа барын да әйткән шикелле. Әмма картның бер нәрсәгә исе китми, ул дөньяви хәлләр белән гомумән кызыксынмый төсле. Шулай да ул нәрсәдер белә, әйтми генәдер, дигән шик Әнвәр башына килә иде.

Әнвәр госпитальгә кайтты. Гамәшев юк иде. Аның урынында икенче яралы ята. Ничек бу болай? Бик гади, нигә исең китте? — дигән кебек карады аңа шәфкать туташы. Гамәшев өченче көн төнлә үлгән, кичә аны җирләп тә куйганнар.

Эштә тагы да ныграк гаҗәпкә калырлык нәрсә көткән. Аны милициягә чакырып повестка килгән иде. Бу уйландырды. Башына кырык төрле уй килде. Ни өчен аны милициягә чакыралар? Зәлия белән бәйләнгән бер-бер хәл булганмы? Әллә шул милициягә барып җиткәнме? Нишләптер Зәлиянең бу эшенә чынлап торып ачуы килмәде аның.

Сержант башта аның белән йомшаграк сөйләште. Торган саен тавышы катылана барды. Ул өстәл тартмасыннан киндидер кечкенә шакмак сыман нәрсә чыгарды да үз алдына куйды һәм Әнвәргә карады.

— Моны син ясадыңмы? — Кыяфәте гаять дәрәҗәдә мөһим һәм җаваплы иде. Әнвәр, әллә каушаудан, теге шакмак кебек нәрсәнең ни икәнен күзе белән күреп тә, фикерен эшләтеп тә белә алмады. Зиһене тәмам чуалып беткән иде.

— Нәрсә соң ул? — диде тотып карарга рөхсәт сораган төс белән. Ләкин сержант рөхсәт итмәде, билгесезлек белән нидер белмәкче була иде кебек. Ул, ручка алып, Әнвәрнең җавабын язарга әзерләнде.

— Кыланма, үзең беләсең!

— Юк, чынлап та?

— Бергаланмыйча гына! Синең эшеңме?

— Туктагыз әле, нәрсә соң ул?

— Пичәт! Син ясадыңмы?

— Минем пичәт эшләгәнем юк!

— Чыгымчылама! Син рецидивист түгел! — Сержант ачулы хәрәкәт белән теге шакмакны чеметеп кенә тотты да чиста кәгазь битенә шапшоп сугып алды. Кәгазьне Әнвәргә сузды. Анда: «Ф. Диндарова» — дигән исем басылган иде. Моны күргә, Әнвәрнең эченә җылы йөгерде һәм ул иркен сулап елмаеп куйды.

— Ә-ә, бу бит пичәт түгел, факсимиле! — диде җиңеләеп киткәндәй.

— Хикмәт исемдәмени?

— Сез ни телисез соң?

— Син нәрсә белмәгәнгә салышасың?! Ярдәм итмәс! Туры танысаң, үзеңә җиңел булыр?! Факт. Ә пичәтне син ясадыңмы?

— Юк!

— Ә кем? Бу тагы да интереснырак! — Сержант Әнвәрдән кызык мәгълүмат чыгара алуына кәефләнеп китте. Әнвәр уйга калды.

— Әһә, кумакләпме? 107 нче статьяның «а» пункты! Кем белән эшләдегез? — Сержант яза башлады.

— Моны Гамәшев эшләде! — диде Әнвәр, тагы каушап.
— Кем ул? Тәк, тәк?
— Яралы. Ике аяксыз. Бик оста иде!
— Адресы?
— Белмим...— Әнвәр сержантка карады. Бу кешенең үз эшен шундый яратып үтәве аңарга хөрмәт уята иде. Сержант Әнвәргә ачу белән төбәлде. Ул ышанмаска тиеш иде һәм шулай булды да.
— Йә, боргаланма! — Сержантның йөзе чытылды. Бер кашы өскә менде, икенчесе төште.
— Ул моннан дүрт көн элек үлде,— диде Әнвәр, сүзен нык итеп. Сержант ручкасын куйды да үйланып алды. Шунда ук бер карарга килүе йөзенә чыкты. Ул, билгеле, Әнвәр сүзенә һич тә ышанмады.
— Ярар, ачыкларбыз,— диде коры гына һәм Әнвәргә кул куярга бер кәгазь сузды. Бу беркетмә иде бугай, Әнвәр имзасын селтәде.
— Кайтып тор! — сержант, урыныннан торып, Әнвәрне ишектән чыгарып җибәрде...

Бер-бер артлы китереп суккан бәла дулкыннарыннан Әнвәр тәмам хәлдән тайды. Кайгылар да кешене физик какшата, вата ала икән. Ул иртән ятагыннан тора алмады. Уң касыгы бик каты авырта иде. Ә күзләренә бар нәрсә сары булып күренә. Нәрсәдән бу?
Шулай да эчендәге өмет чаткысы аны өстерәп дигәндәй Зәлия яшәгән фатирга илтте. Инде менә ничәнче мәртәбә. Һаман ышанычы бетмәгән иде. Ни генә булса да, яхшылык көтәсең, шуны телисең, ә начарны күңел һич тә кабул итәргә теләми.
Баскыч башында хуҗа карт басып тора иде, йөзендә таркаулык, карарсызлык. Димәк, бернинди өметле нәрсә юк? Ләкин картның күзләрендә астыртын чаткылар пәйда булды һәм ул бер сүз дә дәшми генә, кул ымы белән Әнвәрне эчке бүлмәгә алып керде. Әллә Зәлия кайткан-мы? — дигән уй Әнвәрнең тамырларына йөгерде.
Өстәл янында тулы битле, әйбәт киенгән бер хатын елап утыра иде. Елаган тавышны ул ишекне ачканчы ук ишетте. Әнвәрне күргәч, хатын тагы да кычкырыбрак еларга тотынды. Борынын тарта-тарта тирән уфтанып, ачыргаланган, рәнҗегән сүзләр әйтә;
— Күпме газаплар кичерә-кичерә без аны кадерләп үстердек. Ул киселмәгән ефәк кебек кыз. Күпме көч салып, үлемнәрдән алып калып, без аны гарип өчен үстердекмени? Болай да безне язмыш һаман рәнҗетеп килде. Әнә энем бер кулын калдырып кайтты. Инде бусы тагы. Гел безгә генә дигәнмени? Безнең кай төшебез ким? Ый-ый-ый...— Хатын елау тойгысына буылып тагы да ярсып ачыргалана иде. Чәчләре күз яше белән юешләнгән битенә ябышкалап, чуалып беткән, ул бик кызганыч кыяфәттә иде. Әнвәр исә елаучының Зәлия әнисе булуын бик тиз белде, ни әйтергә аптырап, агарып каткан көе, ишек төбендә култык таякларына таянып басып торды. Зиһене бөтенләй таралып китте. Маңгаеннан салкын тир тамчылары тама иде. Шундый күп тамалар, ботинка йөзен чылатып бетерделәр. Әйе, ул шактый авырый, ахрысы. Хуҗа карт әллә, биредә берни дә эшли алмыйсың инде дигәнне белдереп, әллә Әнвәрнең хәлен чамалап алып, аңа башы белән ым какты һәм ишекне төртеп ачты. Әнвәр һаман зиһенен туплап өлгерә алмаган иде әле, нишләргә икән, дип икеләнеп торды да аңа иярергә мәҗбүр булды.
Карттан нидер белергә теләп, Әнвәр сүз кушкан иде, теге сөйләшәсе килмичә, кулын өметсез селтәде һәм читкә борылды. Бераз салмыйча ул бер сүз дә әйтми иде.
Ул госпитальгә кайтып врачка күренде. Температурасы да күтәрелгән иде. Карадылар да «сары» дигән диагноз куйдылар һәм изоляторга күчереп яткырдылар. Көн саен шикәр тутырган сөтле аш бирәләр, уколлар кадыйлар, шулай да күз алды сап-сары булып тора. Тәр-

бия, дәва әйбәт булгангамы, ул бирешмәде. Югалту, әрнүләре күпме генә йөрәген телгәләмәсен, аек акылын җуймады. Күп уйлый торгач, аңа укырга китүдән бүтән юл калмаганлыгына төшенде.

Судья булып эшләгән бер абзый, аяксыз калгач, алар палатасына кабат операция ясатыр өчен яткан иде. Әнвәр шуның белән киңәште. Ул тәҗрибәле кеше иде, бүген үк Бөгелмә педучилищесына гариза җибәрергә кушты. Үзе әйтеп торып яздырды.

Берничә көннән Турганов шундый хәбәр китерде: Зәлияне үзе эшләгән җирдә Ивановога торф эшенә җибәрмәкче булганнар. Ул исә, мөһерле паспортны китереп күрсәткән дә котылып калган. Шулай да бу урыннан китқән, кая урнашуы хәзергә билгесез.

Ни генә булса да, Әнвәр Зәлияне гаепли алмый иде. Бар гаеп үзендә икәнен, Зәлиягә берничек тә тиң була алмавын ул әлек тә белә, аңлый иде. Яшьлек алдануына бирелеп кителгән, юләр!

Озак та үтми Әнвәр училищедан уңай җавап алды. Һәм моңа чаклы булган алданулар, югалтулар бараәбәренә аңа шатлык елмайды. Ун югалтуга бер шатлык, унга бер, шайтан алгыры, дип, хисапчыларча уйлады ул. Бу исәп белән яшәп булырмы? Ә бит өмет зур! Күңел һаман яхшыны көтә, шуңа омтыла.

Әнвәр киләчәк гомеренең дә шул унга бер нисбәте белән барачагын белми иде әле.

# ПОЭЗИЯ

## Рәшит Әхмәтҗанов

### Хатасыз яз, язмыш

Очла, язмыш, каурый каләмеңне,
Яза барыйк кайбер уйларны:
...чиксез дөньянымы?— Күптән инде
Күлмәк итеп кидем мин аны.

Башта гына ипле-иркен булды,
Башланасы көннәрдә генә.
Башларымның ниләр күрәчәген
Сорамадым кемнәрдән генә.

Бер сорадым — яфраклары очты,
Бер сорадым — кошлар кузгалды.
Бер сорадым — балкып кояш батты,
Бер сорадым — офык кызарды...

Барлык сорауларны шәфәкъ уты
Күз алдымда тотып яндырды.
Барын уйлый-уйлый, уем мине
Менә шушы көнгә калдырды.

Тимергә һәм миңа тигез сукты
Мизгелләре «мәңге» дигәннең.
Элек сиздермәде. Аңлыйм хәзер:
Җиргә вакытлыча килгәнмен.

Бар булырга, юк булырга мөмкин,—
Эшле кеше моны төшенгән.
Заман әле һаман, ким дигәндә,
Башын сорый батыр кешедән.

Үзен яклый алмый әле җирдә
Һәр изгелек, һәрбер яхшылык.
Шул хәлендә ничек кешеләргә
Мин аларны китим тапшырып.

Арып аудым бүген яклый-яклый,
Авыр көрәш булыр иртәгә.

---

Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ *(1941)— шагыйрь, «Хыялларым үзем белән», «Ак канатлар», «Җан яктысы» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Алар мәңге азат булса гына,
Җирдән мөмкин тыныч китәргә...

Йөрәгемнән,
Күлмәгемнән башка
Мин үземә берни сорамам.
Көчем дә шул минем — җир өстендә
Кеше булып кына торалам.

Мин өзелмим — яфраклары оча,
Мин китмимен — кошлар кузгала.
Мин батмыймын — балкып кояш бата,
Мин яралы — офык кызара.

Кат-кат очлап канлы каләмеңне,
Хатасыз яз, язмыш, шул хакта.

...Күлмәгемнән алда йөрәк туза,
Җыры гына кала китапта.

## Рәхмәт кенә әйтәсе идем...

*Татарское, дремучее,*
*Пришло из никуда,*
*К любой беде липучее,*
*Само оно — беда.*

«Имя». Анна Ахматова.

Нәкъ шуларның, менә, мин исәне —
Шуннан киләм авыр йөк тартып.
Чорлар яткан үрләр аша узам,
Илбасарлар гүрен таптатып.

Ниләр генә төялмәгән анда —
Тартып барам язмыш арбасын.
Тарта-тарта, йөз урадым сыман
Оҗмах белән тәмуг арасын.

Мин — шуларның тере мәхәббәте,
Киләчәккә таба барганы.
Идел бурлагыдай тартып киләм
Тарихларым яткан арбаны...

Иген чәчтек — эшләп ашадык без,
Сәүдә итсәк — коллар сатмадык.
Иске төрмә ишекләрен түгел,
Иген кешелләрен сакладык.

Үз җиренә иелгән дә татар
Иген чәчкән, урган... урачак!
Илбасарлар белгән: ул турайса —
Урагы бит кылыч булачак.

Көлләреннән кат-кат күтәрелде
Килмешәкләр ваткан йортыбыз.
Җанны гына бары җылыта ул,
Кул җылытмый — истә тотыгыз.

Җирдән икмәк алган өчен хәзер
Кыйнамыйлар инде халыкны.
Иманеннән таяк алып халык,
Корычыннан кылыч алып халык,
Чорлар упкынынннан калыкты...

Кайдан килеп, ниләр китергәнне
Нигә сөйләмәскә дөньяга!—
Кайсы гына чордан кычкырсак та,
Мәхәббәтнең сүзе өр-яңа.

Тик дәшмиләр.
Юкса беркемгә дә
Үпкә белдерәсем юк минем.
Иң гүзәл зат — кеше булган өчен
Рәхмәт кенә әйтәсе идем.

Бер-берсеннән рәхмәт ишетергә
Кыйтгалар бит күптән зарыккан...
Рәхмәт кенә әйтәселәр идек
Борынгы бер бөек халыктан.

## Норма Аби Хәсәннең[1] соңгы монологы

Туган илдә туган өчен
Каныктылар каныма.
Каным сеңгән байрагымны
Каныкканнар алдына
Тотып барам, туганнарым
Үлгән кырлар аркылы.
Көрәшләрнең иң авыры
Безгә калган ахры?!

Туган илдә тумыйча соң,
Миңа кайда туарга?
Мин туганмын — туган илдән
Илбасарны куарга.

Биектәге куркакларга
Дәшмим — төшмәячәкләр;
Иректәге коллар... алар
Тыныч яшәячәкләр.

Алар кала — кузгалырлык
Хәлләре юк куркудан.
Мин халкымның үче булып,
Туганнарым йортыннан
Чыктым бүген. Соңгы чиккә —
Чигенмәскә барамын.
Илбасарны таптаганда,
Канга батсын табаным!

Раслап үтим, туганнарым
Үлгән кырлар аркылы:
Куркакның юк биеклеге,
Ирекнең булмый колы.

Кол булмасак — кырык тапкыр
Тереләчәк калганы...
Дошманнарым минем канның
Ни икәнен аңлады.

Һәр тамчы кан өчен алар
Үлем белән түләде.—
Бары шулай шартлаячак
Һәр ватанчы йөрәге!

---

[1] Шартлаткычлар куелган машинада Израиль илбасарлары колоннасына ташланган яшь Ливан кызы. Автор.

## Китмим моннан

Көнчыгыштан көнбатышка таба
Сөю мине кая алып бара?
Бергә очкан тузан бөртегеннән
Сорап куям:
— Калды күпме ара?

Юлда чакта юкка чыга яздым
Төшеп сәйяр йолдыз учагына.
Очам гына... Исән калдым бары
Туры килеп синең кочагыңа.

Хәтереңнән генә узыйм дисәм,
Сөйгән ярың итеп тудырдың син;
Безне күрердәйнең бөтенесен
Сихер белән читкә кудырдың син.

Утлы иреннәрем
узып киткән
Гасырларның сәламнәрен әйтте.
Чәчләреңне җилләр аралады:
Мин күмелдем, индем таңга хәтле.

Галәм йоклаганда,
Кочагыңда
Узган гасырларны кабатладым.
Алма төше хәтле каргыш алдым,
Алма кебек изге булып калдым.
(Бу изгелек белән нишлим хәзер?—
Алласына бирсәң — алмас аны.
Минекедәй гөнаһлары өчен
Юктыр әле аның каргалганы.)

Сизелми дә узды айлар, еллар.
Каргыш күрмәгәннәр — йокладылар.
Каргалганнар керфек какмадылар:
Мәхәббәтне илдә сакладылар...

Узганнарны уздык.
Инде бүген
Киләчәктән киләм мин каршыңа.
Үзең тудырганны үтерә күрмә,—
Елмай миндәй тугры юлдашыңа.

Киләчәкне сиңа китерәсем
Бар бит әле. Юк, юк, китмим моннан,—
Ник дауламый шунда көнчыгышның
Барып мине кояш баешыннан —
Китмим моннан!..

*

Ташлап китсәм әгәр
Туган-үскән илне,—

Медаль белән кемдер
Бүләкләргә мине

Әзер тора. Ләкин
Мин алдан ук беләм:
Китсәм — бергә үләм
Мәхәббәтем белән.

Миннән калган көлне,
Алып үзләренә,
Җилләр кайтып сибәр
Әнкәм күзләренә...

Ташла, кирәк түгел
Безне бүләкләргә,—
Сөю җитеп тора
Ярсу йөрәкләргә!

Юк, интекмә, безнең
Килүләрне көтмә!
Тапшыр медалеңне
Алдан килгән эткә.

## Акка кызыл ачык булып төшәр

*Сез дә, минем йөрәк язмаларым,*
*Юлда төшеп калган хат кебек...*

Х. Туфан

Илгә күченепләр булмасмы, дип,
Кулларына конверт алгандыр,
Үз җанының шунда бер кисәген
Яшерен хат итеп салгандыр.

Эзли күңел, җилләр арасыннан,
Җилләр арбасыннан актара.
Имляны җил таный алмаса да,
Хәбәр итеп тора: хат бара.

Котылганнар, димәк... палачлары
Көн дә капшап торган төрмәдән.
Җил кулыннан алар һаман әле
Ил кулына килеп кермәгән...

Озатыгыз мине, дөньяның дип,
Сагыш саргайтмаган ягына,—
Шагыйрь җаны һаман уйларымда
Яралы кош кебек кагына.

Дәвам итә алмыйм шигыремне,
Мин кәгазьнең җәйдем ап-агын:
Акка кызыл ачык булып төшәр,
Яралы кош... язар калганын.

*

Күңел сабый һаман: һәр кешене
Үзем кебек диеп ялгышам.
Качып булмый шушы ялгышлардан —
Кара сакал булып ябышкан.

Сакал кисү иң зур җәза булган
Чорларга кит, Рәшит, дисәләр,
Китәр идем... Ләкин анда да шул
Миндәйләрнең башын кисәләр.

*

Килгән болыт моннан китми иде,
Тамган тамчылары кипми иде.

Бүген бар да ташлап киттеләр,
Кош кунмаслык бер тал иттеләр.

Хәсрәтләрем тиздән кимер әле,
Барысы да кабат килер әле.

Мәхәббәттән алар качмасын,—
Буйсындырам әле барчасын!

## Фаҗига

Кош баласын читлектән азат иттем.
Гүя үзем ирекка очып киттем.

Башымны борган арада бер читкә,—
Кош баласы кайтып кергән читлеккә.

## Ишми ишанның Тукайны соңгы юлга озатканда әйткән тәкбире

Барчабызда җитәрлектер язык,—
Тукай гына түгел, без дә яздык.

Без дә кердек шигырь бакчасына,
Зина кылдык донос акчасына.

Күзәтмәгән булсак без аларны —
Афәт басар иде дөньяларны...

Ник тудырдың, тәңрем, ни карадың —
Күзен йомдырмадың шул баланың.

Ятим булгач, аксын иде шунда —
Еракларга Идел бозларында.

Үзең саклагансың аны, Аллам,—
Үз башыңа җитә язды балаң.

Кабул италмадык без аларны —
Ник тудырдың андый балаларны.

Баш бирмичә яши башкалары,—
Тукайларын алар ташламады.

Әләммени — өскә күтәргәннәр...
Каләмемә тотынсаммы әгәр,—
Ул кяферләр әле дарга менәр!

Бер серемне әле әйтми калам,—
Йә йөрәгең ярылыр, кичер, Аллам...

## Чәчәсе бар

Ниләр тере — барысын да кояш
Үзенәрәк дәшә — якынга.
Гөлләр китми. Чәчәк ата-ата,
Сүз кузгата йөрәк хакында.

Кат-кат кабатлыйлар: йөрәгеңне
Афәтләрдән генә арала,—

Матурлыклар арткан саен артыр,
Ямьсез кеше калмас арада.

Кайсы йолдыз тузанында, туган,
Очрашырбыз, диләр, соңыннан?
И, гөлләрем, һәр түтәлне кабат
Чәчәсе бар. Китмим мин моннан.

Иген чәчкән кебек чәчәсе бар
Сулышларда, җанда ни барын:
Мәхәббәтнең хәле җиңеләйсен,
Күрсен кояш күңел кырларын.

Башлар исән чакта,
Бүген башлыйк:
Батырлыкны чәчик моң-зарга.
Уңышлары кирәк баш имичә
Заманалар аша узарга.

Шатлыкларны — хәсрәтләргә чәчик.
Бүген башлыйк — вакыт калмады.
Кырларыгыз кысыр сезнең, диеп,
Ятлар безне күпме алдады.

Болай яшәп булмый: кыргыйланды,
Гөл кабере булды түтәлләр.
Ул түтәлләр бездән соңгы кабат
Рәхим-шәфкать өмет итәләр...

Чакыралар. Әллә бу чәчәкләр
Киләчәкнең күзләре микән?
Әллә түтәлләргә су китергән
Сабыйларның үзләре микән?

Түтәлләргә сулар китергәннең
Ялгыш тия күрмә рухына,—
Күкрәп уңган сагышлары белән
Сугуы да мөмкин ул сиңа.

Яшәү яклы, гөлләр яклы булсаң,
Афәтләрдән аны арала,—
Матурлыклар арткан саен артыр,
Ямьсез кеше калмас арада.

*1986—1987.*

## ПРОЗА

Зиннур Хөснияр

# КӨЗНЕҢ СОҢГЫ КӨННӘРЕ

хикәя



Тәрәзә каршындагы карт юкәнең менә-менә өзеләм дип торган кызгылт сары яфраклары, көзге вак яңгыр белән ни хакындадыр сөйләшкәндәй, шыбыр-шыбыр киләләр. Аннары күп тә үтми, капка төбендәге ут баганасының ялангач чыбыклары шыксыз, нечкә тавыш чыгарып сызгыра да, шуның артыннан ук җил тәрәзә пыялаларына юкә яфракларын ябыштырып куя.

Түрдәге диванда аякларын бөкләп утырган Гажбикамал карчык, һәммәгез дә тыңларга әзерме дигәндәй, өй эчендәгеләргә тагын бер мәртәбә күз йөртеп чыга да, башындагы ак яулыгын маңгаена табарак тартып, карчыкларча йомшак кына итеп тамак кырып алганнан соң, утырган урынында җай гына тирбәлә-тирбәлә укырга керешә:

Бисмилляһи-р-рәхмани-әр-рәхим...

Бу сүзләрне ул ни өчендер ике тапкыр кабатлый, икенчесендә инде тавышы ишетелми дә диярлек, аның ни әйткәнен бары тик бертуктаусыз кыймылдаган ирен хәрәкәтләреннән генә чамалап була.

Өй эчендә тынлык, бер-берсе белән сүз алышу түгел, хәтта тамак кырырга да кыенсынып утыралар. Кухня якта йөргән карт мәченең аяк буыннары черт-черт иткән тавышка да өй эчендәгеләрнең ачулары киләдер сыман.

Мактау, шөкер һәм дан булсын бер аллага,
Мөлке даим, үзе мәңге ул мәүлягa,
Мөлкәтенең эчендә юк шәрик аңа,—
Аны бакый һәм олуг дип белдек имди...

Гажбикамал карчыкның кулында «Йосыф китабы». Гарәп хәрефләре белән басылган бу китап кулдан-кулга йөргәнлектән, тузып, кыршылып беткән, аннары аны яшел чүпрәк белән бик пөхтәләп тышлаганнар. Китапның кайбер битләре өрәңге яфрагы кебек кенә калган, карчыкның сулышыннан да җилфер-җилфер килә. Ул китапны мөнәҗәт кебек көйләп, сузып укый. Өй эчендәгеләрне, бердән, андагы вакыйгалар, Йосыфның язмышы, Зөләйханың әчкерсез хисләре һәм газаплы мәхәббәт утында януы җәлеп итсә, икенчедән, Гажбикамал карчыкның көйле, моңлы тавышы әсәрләндерә.

Китап укыла башлагач, инде бер-береңә сүз катсаң да ярый.

— Һай, бу пәйгамбәрләрнең язмышлары да җиңел булмаган икән,— ди Маһирә.

— Кара эчле залимнәр, малга кызыгучылар әлек тә булган ла ул,— дип куя аның янәшәсендә утырган Маһишәкәр.

— Әй, дөньясы тигез түгел лә аның,— дип көрсенә тол хатын Сафия.

— Әйе шул, шулай шул, шулай,— дип, сүзләрен җөпли хуҗа хатын.

«Без гөнаһлыларыңны үзең сакла инде, раббем! Без гаепле түгел, дөньясы шундый аның...»— дип, эченнән генә уфтана Әбелкәрим һәм булмадагы хатыннарга бер-бер артлы күз салып чыга. «Изге китап янында нигә үзегезнең гөнаһларыгызны яшерәсез? Пакь кенә түгел бит берегез дә. Син, Маһирә, суфиланып утырасың. Теге елларны оныттыңмыни? Ә син, Маһишәкәр, син дә оныттыңмы, яккан ялаң аркасында кеше чак кына гүргә керми калды. Син дә күзләреңне яшьләндереп утырган булма, Сафия килен, иреңнең бәддогасы сиңа да төшми калмас...»Күз карашы хатыны һәм диванда аякларын бөкләп утырган бертуган апасы турысыннан узганда гына берни уйламый Әбелкәрим. Хәер, иренә каршы авыз ачып бер сүз әйтергә дә кыймаган хатыны һәм шәһәрдән кунакка кайткан апасы турында ни дип уйласын да, нәрсә дип әйтә алсын инде?

Әбелкәрим бу юлы апасын шәһәрдән үзе махсус барып алып кайтты. Соңгы елларда күңеле бер дә тыныч түгел. Апасы кайткач, һәр кич күрше-күлән җыелып керә аларга. Укымышлы карчыкның хәлен белергә, олы кеше белән сөйләшеп утырырга, тагын бер кат изге китап сүзләрен ишетергә. Пәйгамбәрләрнең катлаулы язмышын тыңлап, алар өчен борчылып, күз яше түгеп утырсаң, җаның рәхәтләнеп киткәндәй була, җиңеләеп китәсең, сафланып-пакьланып каласың, дип фикер йөртә өй эчендәгеләр.

Инде Йосыфны Мисыр патшасы иттеләр. Бу урында бераз күз яшьләрен тыя төшеп, җиңел сулап, сүз куертып җибәрсәң дә ярый. Гаҗбикамал карчык та, китабын итәгенә салып, башын күтәрә. Ләкин өй эчендә һаман да тынлык әле, сүз кушарга кыючы күренми. Гаҗбикамал карчык беренче булып үзе:

— Мотыйгулланың хәле ничек икән?— дип сорады. Аның бу сүзләре оеп, үз эченә йомылып утырган Әбелкәримне сискәндереп куйды. Ул, өй эчендәгеләр әлеге сорауга ни рәвешле җавап бирерләр икән, дип колакларын торгызды. Менә Маһишәкәр әби утырган урынында җайсыз гына селкенеп алды да:

— Һаман шул бер килеш ди, урын өстендә икән,— диде.

— Монда үләргә генә кайткан икән,— дип, аңа тол хатын Сафия кушылды.

— Үзенең гомер иткән туфрагына кайткандыр инде,— дип авыр сулап куйды Маһирә карчык. Әбелкәримнең хатыны да сүзгә кушылырга кирәк санады бугай:

— Әле кайчан гына типсә тимер өзәрлек пәһлевандай кеше иде бит. Уза гомерләр, аккан сулар кебек уза. Сизми дә каласың...

Гаҗбикамал карчык итәгендә яткан китабын бер читкәрәк этеп куйды.

— Ни булса да начар даны таралган кеше түгел. Авылдан киткәненә ничә еллап булыр икән әле?

Әмма бу турыда башка берәүнең дә сөйләшәсе килмәде, ахрысы.

— Йә, ахирәт, китабыңны нигә этеп куйдың? Тыңлап бетерик,— дип, Маһишәкәр әби әңгәмәне икенчегә борды. Соравына җавап ала алмаса да, Гаҗбикамал карчык карышмады, яшел тышлы саргайган китабын янә кулына алып, тагын бер мәртәбә:

— Бисмилләһи-р-рәхмәни әр-рәхим,— дигәннән соң калган урыныннан көйләп укый башлады.

Әбелкәрим башка тыңламады, аны үз уйлары бөтереп алды. Югыйсә, тыңларга кирәк иде, апасы әйтмешли, әлеге кыйссаны тыңлап, андагы пәйгамбәрләр өчен кайгырып утыру, моңа хәтле сүзнең ни турында барганын яттан белсәң дә, тагын бер кат колак салу үзе бер савап. Әмма үз уйлары көчлерәк иде Әбелкәрим картның.

Моңа кадәр бер җайга гына аккан тормышының көе китте, бозылды, чуалды, әллә нишләде шунда. Боларның барысының да сәбәпчесе элеккеге авылдашының, Мотыйгулланың ничә еллардан соң, күпме сулар аккач, кире Урман-Тауга әйләнеп кайтуы иде. Бу хәбәрне аңа моннан нәкъ бер атна элек хатыны кайтып әйтте. Ул кибеттә ишеткән иде. Хатыны тагын нәрсәләрдер сөйләде — Әбелкәримгә ишеткән кадәрлесе дә бик җитте, ул аны тыңлап бетермәде, көтүдән кайткан танасын бәйләп маташа иде, арканы кулыннан ычкынып китте. «Кайткан?! Ник кайткан? Нәрсәгә?! Монда тамыры бер өзелгән бит инде. Әллә картайган көнендә булса да теге чактагы үчләрен алырга, исәп-хисапларын өзәргә кайтканмы?!»

Мөгезенә бәйләгән бауның йомшаруын сизгән тана, башын гаярь генә чайкап алды да, лапас капкасы янында торган хуҗа хатынын бер якка селтәп, ишегалдына чыгып чапты һәм, кабат ирекkә чыгуына сөенгән кебек, сикерә-сикерә ишегалды буйлап чаба башлады. Тояк астыннан чәчрәгән пычрак хуҗа

хатынның өс-башын буяды, Әбелкәримнең йөзенә тиде. Болай да кәефе кырылган хуҗа, тананың бу кыланышына ачуы килеп, утын әрдәнәсе өстендә яткан арканны суырып алды да: «Аһ, мур кыргыры, аһ, денсез хайван»,— дип мыгырдана-мыгырдана тана артыннан йөгерде. Шулчак яртылаш ачык капканы мөгезе белән төртеп, мышный-мышный сыер кайтып керде. Тана һаман ишегалды буенча чаба иде әле. Сыер туктап, нишләвең бу, дигән кыяфәттә аңа карап торды да үз яныннан чабып узып барган танага мөгез очы белән төртеп алды. Мондый һөҗүмне көтмәгән тана, сөрлегеп, ишегалдына түшәлгән ташка тезләнде. Аннары кызулыгы белән кабат сикереп торды да, бу юлы аксый-аксый лапаска таба китте. Әлеге хәлләр шундый тиз булды ки, Әбелкәрим үзе дә, хатыны Сәмига да берни абайламый калдылар. Шул арада тананың аягы сынып өлгергән иде. «Хәерлегә түгел бу, хәерлегә түгел!»— дип сукранды Әбелкәрим. Әмма Мотыйгулла кайткан, инде аны кире җибәреп булмый, инде бернишләп тә булмый иде.

* * *

...Ул вакытта да көз көне, ул чакта да пыскып яңгыр сибәли иде. Аяк асты пычрак, көн күңелсез, ямьсез, шыксыз иде. Әбелкәрим, хатынына мунча ягарга кушты да, үзе ишегалдында яңгыр астында яткан утыннарны лапаска ташып, ярырга кереште. Шулчак капкадан өстенә чабулары җирдән сөйрәлгән озын соры кожан кигән, кулына кыска каеш чыбыркы тоткан Мотыйгулла күренде. Ул Урман-Тау авылында күптән түгел генә бригадир итеп сайланган иде. Туры сүзле, кырыс холыклы булуын кайберәүләр өнәп бетермәсә дә, күпчелек аны ярата, хөрмәт итә. Әбелкәрим исә аны өнәмәү өстенә, бераз шүрли дә. Ни өчен курка, нигә, нәрсәгә — моны үзе дә аңламады ул. Һәм нәкъ менә шуның өчен дә өнәми иде бугай.

Бригадир, Әбелкәримнең утын ярганын күреп, туп-туры лапаска таба китте.

— Бу эшең яхшы түгел, Әбү, нигә атыңны туардың? Ул икмәкне кем ташып бетерер дип беләсең?— диде бригадир килә-килешкә.

— Ни бит... күпме йөрергә була инде бу яңгыр астында?— дип мыгырданды аңа каршы Әбелкәрим.

— Яңгыр асты имеш, тоз түгел, эремәссең!

Әбелкәрим кулындагы балтасын бүкәнгә кадап куйды.

— Бүген бер юл илткән бит инде,— диде ул.

Сүз колхоз эше турында барганда бригадирның тәмле тел белән генә сөйләшмәячәген белә иде егет. Шулай да, әлеге сүзләренә өстәп, әйтеп куйды:

— Арыдды бит, аг та хәлдән тайды.

— Тфү! Аңлыны корт чаккан нәмәстә! Чери бит, күзгә күренеп амбар тулы ашлык яңгыр астында күгәреп ята! Берне генә түгел, көненә уны илтерсең! Аңладыңмы? Төне буе ташырсың, кирәк булса!

Бригадирдан бераз шүрләвен шүрләсә дә, Әбелкәрим үзе дә җебегәннәрдән түгел иде.

— Ник минем әнигә кагыласың? Бар, бар, үзең ташы!— дип кычкырды. Бригадирга каршы җыелып килгән ачуының кайчан булса да бер тышка чыгачагын сизә иде ул. Менә бүген ташыды. Бүген нәкъ вакыты. Көне буе яңгыр астында йөрү туйдырган иде, тәмам җелеккә төшкән иде. Җитмәсә, инде мунчага керәм, ял итәм, дип кенә торганда...

Бригадирның холкын яхшы белә Әбелкәрим. Канына тоз салсаң, бигрәк тә колхозга кагылышлы эшкә каршы берәр кыек сүз әйтсәң, чыбыркысын уйнатып алырга да күп сорамас. Әбелкәрим кулын бүкәнгә кадалган балта сабына куйды. Бригадир кешеләр белән әрләшеп туеп беткән идеме, әллә башка берәр сәбәп булдымы:

— Их, син йомран баласы!— диде дә, капылт кына борылып, күн итеге белән суына, пычрагына карап тормыйча чап-чоп баса-баса капкага таба китте. Аннары артына борылып:

— Атка бүтән якын киләсе булма! Бүгеннән ул атны син җикмисең!— дип кычкырды.

Әбелкәрим моңысын көтмәгән иде. Аттан колак кагасы килми иде аның. Авылда төп көч — атлар. Утыны да, печәне дә ел саен кирәк хуҗалыкка. Һәммәсе дә ат белән кайта торган нәрсәләр. «Ул дуамалга ышан син! Атсыз калдыруы да бар!»— дип уйлады Әбелкәрим.

Мотыйгуллага булган ачуы төер булып күңелендә укмашып калды. Тик хәзер тагын икмәк төяп яңгыр астында юлга чыгып китмичә ярамый иде.

Аларның Урман-Тау авылындагы ашлык амбары инде күптән ныклы сиплəүне көтə. Икмəк яңгыр астында күксеп, күгəреп ятмасын өчен, аны Караяр станциясенə ташыталар. Караярның амбарлары зур, яхшы. Айлар буе яңгыр койса да, икмəккə зыян килерлек түгел.

Мəһирə, əле яңа гына өч йөк төятеп, ишеклəрне биклəп маташа иде. Амбар каршына килеп туктаган Əбелкəримне күргəч:

— Ник килдең инде тагы? Бүтəн бармыйм дип əтəчлəнгəн идең бит!— дип кычкырды.

Əбелкəрим арбасыннан сикереп төште дə, дилбегəсен җыеп, ат өстенə ыргытты. Бу əче телле хатынга җавап бирмəкче иде, əмма кулай сүзлəр тапмады. Бары тик:

— Бармый кара. Теге чулак авылдан кудыртыр,— дип мыгырданып кына куйды һəм амбар алдына менде.

— Йə, күпме төйисең?— диде Мəһирə, биклəргə җыенган ишеклəрен кире ачып.

— Күпме бирсəң, шулчаклы.

— Миңа димəгəе... Ник һəммəсен дə алып китмисең шунда. Хəлеңнəн килсə, дим инде.

— Килер, килер, кайгырма. Их, түлке мунча əрəм кала. Арка да кычытып тора иде.

Амбарга кереп барган Мəһирə, туктап, артына борылып карады.

— Өлгерерсең əле мунчаңа! Сезнең хатыннарга гына ирлəр аркасын юарга димəгəн. Көтсен əле ул да бераз,— дип төрттереп алды.

Мəһирə — тол хатын. Ире сугыштан əйлəнеп кайтмады. Ул чакта Əбелкəрим малай гына иде əле. Яшь хатынның ике тапкыр җир тырный-тырный үксегəнен күрде ул. Берсе ирен сугышка озатканда, икенче мəртəбə хат ташучы кайгылы хəбəр китергəч. Ул вакытта да Əбелкəрим малай гына иде əле.

— Менə шушыларны төярсең!

Мəһирə амбарның караңгы почмагында өелеп торган капчыкларга төртеп күрсəтте дə үлчəүне көйлəргə кереште. Əбелкəрим иң өстəге бер капчыкны үлчəүгə салды һəм икенчесенə дип китте. Баядан бирле Мəһирəгə берəр сүз əйтергə теле кычытып тора иде. Əмма тамагына утырган төер ирек бирмəде. Менə ул икенче капчыкны күтəреп алды да үлчəүгə таба атлый-атлый:

— Кеше хатыннарыннан көнлəшмə син. Мунчаң бар бит, як та чакыр,— диде. Тик тавышы барыбер сизелерлек калтырый иде. Үлчəү янында басып торган Мəһирə көлеп җибəрде.

— Сезнең ул зобани хатыннарыгыз белəн судлашып йөрер хəлем юк əле. Бөтен тəрəзəңне кырып бетерерлəр.

Əбелкəрим үлчəүдəн соң капчыкларны арбасына чыгарып салды да, өслəрен япкач, кире амбарга керде.

— Йə, кая, кəгазьлəреңне бир дə.

Ул язып утырган Мəһирə янына килеп, аның җилкəсенə кулын салды, хатын бер сүз дə дəшмəгəч, кочып ук алды һəм:

— Синнəн арка юдырыр идем мин түлке!— дип пышылдады.

— Кит, җүлəр, кеше күрсə!— Мəһирə аны терсəклəре белəн төртеп җибəрде дə көлə-көлə:— Бүген ягам. Станцадан кайткач, кереп чык,— диде. Хатынның күзлəре ут кебек яна иде.

Урман-Таудан Караярга тиклем унике чакрым дилəр. Коры көнне җəяүле өчен ул ике сəгатьлек юл. Ат бераз тизрəк бара. Мондый лыздырдык пычракта исə, житмəсə, йөкле килеш бу араны үтү өч-дүрт сəгатькə сузыла. Юлның иң газаплы урыннары Алабута чокырын үтү һəм елга аша чыгу. Калган өлеше, бер-ике үрне исəплəмəгəндə, ярыйсы гына.

Əбелкəрим, кожанын киеп, йөк өстенə менеп утырды да, атын авыл башына таба борды.

Ул станциягə килеп житкəндə, бригадир күптəн шунда иде инде. Урман-Таудан килгəн йөклəрне үзе карап бушаттыра. Əбелкəримнəн алдагы өч ат ашлыкны поездга илтə киткəннəр. Зур, киң амбарның бер почмагында капчык-капчык Урман-Тау икмəге өелеп тора. Мотыйгулла Əбелкəримне каршы алды да, аның йөген бушатканнан соң, хисапчы малай белəн икесен каравылга куеп, үзе станциягə китте.

Əбелкəрим кожанын амбар ишегенə җəеп элде һəм тəмəкесен кабызып, капчык өстенə утырды. Шунда гына ул үзенең эт булып арыганын сизде, кулбашлары сулык-сулык килə, гəүдəсе кыйнап ташланган кебек. Хисапчы малай Мансур да Урман-Таунык иде.

— Кәрим абый, безнең әнигә кереп әйтерсең әле, тагын бер атнасыз да кайтып булмас монннан. Бүген Мотыйктан сораган идем, авыз да ачтырмый. Башта ипине озатып бетерик әле, ди.

Мансур быел гына җидееллык мәктәп тәмамлаган иде. Башы йомры дип, Урман-Тау бригадасына хисапчы итеп куйдылар. Әбелкәрим: «Ярый, әйтермен, энекәш», дигәндәй, башын селкеде дә, тәмәкесен аяк астына салып таптаганнан соң, артындагы капчыкка сөялде. Мансур:

— Кәрим абый, мин Мотыйк кайтканчы, тиз генә кибеткә барып килим әле,— дип урыныннан торды.

— Бар, энекәш, бар,— диде Әбелкәрим һәм итекләрен салып, аяк чолгауларын рәтләргә кереште. Малай китеп биш-ун минут та үтмәгәндер, Әбелкәрим янына күрше колхозның бер кешесе килде.

— Нихәл, агайне?— диде ул акрын гына.

— Әйбәт әле.

Әбелкәрим итекләрен аягына киде. Теге кеше аның янәшәсендәге капчык өстенә килеп утырды.

— Кайчан бетә инде бу газаплар...— дип көрсенде ул.— Ат урынына эшлисең, җигеләсең, ә өйдә авыз тутырып ашарлык ипи дә юк.

Әбелкәрим колгадай озын буйлы, чандыр гәүдәле бу кешене күреп белә иде. Күрше колхозның Чулпан авылыннан, аның кебек үк ат җигә бугай.

— Әйе шул,— дип куйды Әбелкәрим аңа каршы. Сөйләшеп киттеләр. Таныштылар: Сафиулла атлы икән. Әбелкәрим шикелле үк, Караярга икмәк китергән. Аңлаштылар. Килештеләр. Урман-Таудан килгән дүрт капчык амбарның икенче почмагындагы өемгә күчте. Икесе сиңа, икесе миңа. Сафиулла Әбелкәримне Алабута чокыры янында көтеп торачак.

Капчыкларны берәмтекләп санап карамаса, дүртесенең югалганын Мотыйгулла сизмәячәк иде. Озакламый Мансур кайтып җитте. Беркавымнан Мотыйк үзе дә күренде. Бригадир үз күзләре белән карап калды: Әбелкәрим борчак тәгәрәтерлек буш арбада утырып кайтып китте. Алабута чокыры янында аны Сафиулла көтеп тора иде инде. Алыш-биреш беткәч, син мине, мин сине күрмәдем, дип кул бирештеләр дә атларын икесе ике якка куаладылар.

Әбелкәрим авылга якынлашканда караңгы төшә башлаган иде. Ул атын бәрәңге бакчаларына таба борды һәм, үз йортының лапас капкасы янында туктап, капчыкларын печән астына яшерде. Аннан соң өйгә дә кереп тормады, атын кәнүшнигә илтеп туарды да бакча артыннан гына Маһирә йортына таба китте. Әбелкәрим шул кичне беренче мәртәбә Маһирә атлы тол хатынның ишеген какты...

Шул хәлләрдән соң ике көн үттеме икән, районнан килгән кешеләр бригадир Мотыйгулланың, хисапчы малайның һәм тагын берничә кешенең өен, каралты-курасын тентеп чыктылар. Аннары бригадирны да, хисапчы малайны да үзләре белән районга алып киттеләр. Өченче көнне Мансурның әнисе Маһишәкәр дә төенчеген алып районга йөгерде. Шул ук көнне малаен үзе белән ияртеп тә кайтты. Шул китүдән элеккеге бригадир чулак Мотыйгулла Урман-Тауга бөтән әйләнеп кайтмады. Аның турында авылда төрле хәбәрләр йөрде, имеш, колхоз икмәген саткан өчен, Мотыйкны ун елга хөкем иткәннәр икән, имеш, кырын эшен сизмәсәләр, ул бөтен авыл икмәген сатып җибәрәсе булган икән. Имеш... Бу хакта авылга Маһишәкәр кайтып сөйләде.

Мотыйгулланың каладагы малае ялгыз әнисен үз янына алдырды. Язгы бер көнне Мотыйгулланың караучысыз ялгызак йорты, ут чыгып, кара күмергә әйләнде. Урман-Тау авылында Мотыйгулла нәселенең тамыры төбеннән үк өзелде, корыды. Моны авыл халкы шулай дип сөйләде. Маһишәкәр авызыннан чыгып халык теленда йөргән имеш-мимешләренең ни дәрәҗәдә дөрес икәнен бары тик өч кеше генә белә иде. Аның берсе элеккеге бригадир Мотыйгулла үзе, Әбелкәрим һәм күрше Чулпан авылыннан Сафиулла атлы кеше. Мотыйгулланың ялгыз йортында ни сәбәпле ут чыгуын исә Урман-Тау авылында да, тирә-күрше авылларда да Әбелкәримнән башка белүче бер генә адәм заты да юк иде...

* * *

Җанлы мал — ярты мал, диләр. Тананың имгәнгән аягы әллә дөрес ялганмады инде — һаман да төзәлеп җитә алмады — ул аксак килеш калды.

Әле җиргә кар төшмичә көтү кермәсә дә, аны өйдә генә асрадылар —

аксак хайванны тинтерәтеп йөрү файдасыз иде. Хәер, тана кайгысы качты Әбелкәримнән. Мотыйгулла кайтуының өченче көнендә үк түшәк өстенә менгән дип сөйлиләр. Авыл халкы, каладан кунакка кайткан апасы Гажбикамал, хатыны Сәмига шулай ди.

Әбелкәрим апасын шәһәрдән чакыртканына кайчак үкенеп тә куя. Мотыйгулла белән яшьтәшләр булганлыктанмы, кергән-чыккан һәрбер кешедән аның хәлен сораша һәм, үзе дә белмичә, Әбелкәримнең күңеленә җәрәхәт өсти. Әйе, апасын шәһәрдән чакыртканына үкенә ул кайчакта...

Мотыйгулланың малае авыл кырыендагы буш йортны сатып алгач, шуннан атна да узмагандыр, бер аягы белән кабергә баскан карт үзе дә Урман-Тауга кайтып төшкәч, Маһишәкәр карчык Әбелкәримне урамда очратып:

— Гажбикамал ахирәт ел да туган нигезенә корьән чыгып китә торган иде. Аның янына кереп бер сөйләшеп утырсак, безнең дә күңелләр җиңеләеп китәр иде, пакьләнеп, сафланып кала идек. Быел никтер күренмәде,— диде. Аның тел төбен аңлаган Әбелкәрим икенче көнне үк калага чыгып китеп, апасын туган нигезенә кунакка чакырды.

Тормышның көе китте. Әбелкәримнең бик тә, бик тә Мотыйгулла карт янына барып сөйләшеп утырасы, җаен туры китереп, кылларын тарткалап карыйсы килде. Белмиме икән, сизмәгән микән соң ул үзенең кем аркасында бәлагә тарыганын?! Берәрсе әйтмәдеме икән?.. Ул көн саен Чулпан авылыннан килә торган юлны күзәтте. Юлчыларны мөмкин булганча, берәмтекләп карап, күзе белән тикшереп озатты. Юлчылар арасында бүгенге көнгә хәтле Сафиулла атлы кешегә охшаганы күренмәде. Югыйсә, Мотыйгулланың Урман-Тауга әйләнеп кайтканын Сафиулла да ишетергә, белергә тиеш иде. Әбелкәримнең ул кешене инде байтактан күргәне юк. Әлегрәк елларда сабантуйда күзенә чалынгалый иде. Анда да бер-берсенә якын килергә базмыйча, сизелер-сизелмәс кенә баш кагып уздылар.

Беркөнне Әбелкәрим иртүк торып, танасының мөгезенә бау салды да аны җитәкләп капкадан чыгып китте. Гадәттә, ул көн дә аксак хайванны тау башындагы чирәмлеккә алып менеп арканлый иде. Әле дә тау башына юл тотты. Шундагы саргая башлаган чирәмлеккә җитәм дигәндә генә Әбелкәримнең башына бер уй килде. «Әгәр бу хайванны корбан итеп чалсам! Корбан ашыннан бөтен авыл халкы авыз итәчәк. Үз кулларым белән Мотыйгуллага да илтермен. Күңеле булыр...»

Тик, гөнаһ шомлыгына каршы, аларның Урман-Тау авылында да, тирә-күрше авылларда да тана кадәр тананы берәүнең дә корбан итеп чалганы юк. Һәрхәлдә, фани дөньяда күпме гомер итеп, Әбелкәримнең мондый хәлне күргәне дә, бу хакта ишеткәне дә булмады. Әлеге изге ниятенең әнә шул ягын уйлап, карт бермәл аптырашта калды. Әгәр дә тананы корбан итеп чалса, аның бу кыланышы берәрсендә шик уятмасмы соң, картның әлеге изге гамәле телдән-телгә йөреп, күпертелеп, арттырылып, әллә ниләр өстәлеп, бәласе кире үзенә әйләнеп кайтмасмы, аның күңеленә таш булып атылмасмы соң? Әбелкәрим әнә шул хакта уйланды.

Әмма, курыкканга куш күренә, ди. Бәлки әле аның бу эшен авылдашлары хупларлар гына. Авыл инде таза, көр тормыш белән яшәсә дә, соңгы елларда сарык тәкәләрен корбан итеп чалучылар да кимегәннән-кими бара. Әллә нигә бер генә, сирәк-мирәк кенә була андый хәлләр хәзер. «Бер заман бу дөньядан китәсе барын онытабыз шул...— дип көрсенде Әбелкәрим.— Дөнья куабыз, мал җыябыз, ашыгабыз. Йа! Ул тананы теге дөньяга үзең белән барыбер алып китеп булмый бит! Гөнаһлардан арынып китәргә кирәк, гөнаһлардан. Анда адәм баласына башмак тана да, савым сыер да кирәкми. Бу ниятемне авылдашларым хуплар гына, рәхмәт кенә укырлар. Алайса шулай итим. Үзеңә корбан итеп алырсың хайванны, аллаһы тәгаләм!»

Әбелкәрим шундый карарга килде. Әмма шулчак аның тез буыннары йомшарды, ул, хәлсезләнеп, юеш чирәмгә утырды, үзе күңеленнән Мотыйгулла белән гәпләште: әле үзен акларга тырышты, әле үзенә-үзе үк каршы төште.

«Ничәмә ничә еллар буе җан газабыннан интегәм бит инде, Мотыйгулла, кичерә күр!»

«Синең җан газабы гына. Минем бөтен тормыш чәлпәрәмә килде, энекәш. Хәер, энекәш, дим, син дә картайгансың икән инде, бетерешкәнсең, бабай булгансың».

«Мин дә үз җәзамны алдым инде. Шул җитмәгәнмени?! Менә тананы да корбан итеп чалам әле».

«Мин киткәч, халык дошманының улы дип, малаемның да күзен ачыр-

маганнар, бер гаепсезгә ул изаланган. Юк, Әбү, моны онытып та, кичереп тә булмый».

«Вөждан газабы, күңел газабы бар нәрсәдән дә көчлерәк, ачырак. Шуның хакына гына булса да...»

«Сугыштан исән-имин кайткач, минем бик тә, бик тә яшисем, җир җимертеп эшлисем килә иде. Син мине нәкъ менә шундый чакта харап иттең!»

«Җан газабы барыбер ачырактыр, Мотыйгулла!..»

«Үзең сорап алдың...»

Ул, арканның кулыннан шуып чыгуын сизеп, сискәнеп китте. Тана, титаклый-титаклый, аннан ераклаша бара иде. «Бар, йөр, өйлә вакытында арканлармын әле»,— дип, Әбелкәрим аңа таба кулын селтәде дә акрын гына тау башыннан үз йортына атлады. «Ниемә дип кайткан инде ул монда?» Әбелкәрим сүгенеп җиргә төкерде. Аннары уйлап куйды: «Сафиулла дигән адәм беләме икән бу турыда?»

Чулпан юлында кеше-кара да, атлы да, машиналар да күренми иде.

Өенә кайткач, аксак хайванны корбан итеп чалу-чалмау хакында тагын бер тапкыр бик озак уйланды Әбелкәрим. «Һай! Үтерә лә икән ул. Һай, михнәтле дә икән ул җан сызлавы!.. Белсәгез иде, аңласагыз иде, берәрегезгә сөйләп булсын иде ичмаса. Һай!..»— дип, янә авыр итеп, газаплы итеп офтанды Әбелкәрим.

Тананы корбан итеп чалу-чалмау мәсьәләсе төштән соң үзеннән-үзе хәл ителде. Моны аксак хайван үзе хәл итте. Әбелкәрим аны кичкырын ужымнан табып алып кайтты. Һәрвакыттагыча тамагына тугры хайван ужым ашап күбенгән, күзләре иләсләнгән, борын тишекләре киңәйгән иде. Җитмәсә, басуда ашлама да ялаган, ахрысы, авызыннан бер туктаусыз ак күбек килә. Шулай итеп, тана корбан бәйрәменә дә, Әбелкәримнең үзенә дә насыйп булмаган икән. Кич белән ул гөрселдәп капка төбендәге пычракка ауды. Бәлки ярдәм итәр дип, Әбелкәрим аны йөртергә алып чыккан иде. Шуннан кайтып килешли җан тәслим кылды хайван, чалырга да өлгерми калдылар...

Шул кичне үк Әбелкәрим аны, күрше малаеның трактор арбасына салып, Алабута чокыры янындагы үләксә зыяратына илтеп күмде. Иртәгәсен иртүк торып, Әбелкәрим ишегалдына чыкты. Гадәттә, иң беренче эш итеп ул иртән капка бастырыгын тартып килә иде. Мотыйгулла кайтканнан бирле исә, капкадан башын тыгып, Чулпан ягына карарга күнегеп китте. Бүген дә өйалды баскычыннан ук шул тарафка күз атты: юлның тау битендәге өлеше ачык күренә иде. Анда хәрәкәт шәйләнмәгәч, күңеле бераз тынычланып, капка бастырыгына да орынып тормыйча, туп-туры лапаска таба китте.

Бүген төне буе керфек тә какмады ул. Йокы алмады. Картының әле бер якка, әле икенче якка борылуыннан, оя килештермәгән каз кебек, бертуктаусыз кыбырсынуыннан хатыны Сәмига да уянып, берничә мәртәбә:

— Оныт инде шул тананы. Безгә насыйп булмагандыр. Борчылма шуның өчен, йөрәгеңә кан савар, йокла!— дип шелтәләп алды.

«Их, күңелдәгеген хет сиңа гына булса да сөйләп алсам иде! Һай, карчык!.. Безгә насыйп булмаса булмас иде шунда. Менә корбан итеп тә чалып булмады. Аллаһы тәгалә дә аны миннән кабул итеп алырга теләмәде. Кылган гөнаһларым өчендер инде. Шуңа күрәдер... Бәлкем... иртәгә... не... иртәгә үк Мотыйгулланың үзе янына барыргадыр, ә? Әйтергәдер аңа, барысын, барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирергәдер? Ә?.. Бәлкем... кичерер? Узган эшкә салават, дияр, онытыйк, дияр. Кичермәсә? Кичермәсә кичерми инде. Язмыштыр. Аңа каршы барып булмый, ни язылган булса, шуны күрерсең. Аның каравы, җаның сызлавы басылыр!..» Әмма Әбелкәрим тиз генә берниндә дә карарга килә алмады. Мотыйгуллага барып сөйләсә, дөньяга кара даны таралыр, аны бар авыл халкы каргар, бармак төртеп күрсәтер кебек тоелды. Сөйләмәсә, моннан кырык ел элек булган хәлне берәү дә искә төшереп тормас, ул һаман да әүвәлге Әбелкәрим, балалары өчен яраткан әти, хатынына гомер иткән ир булып калыр. «Һай, үтерә лә икән ул, һай, михнәтле лә икән ул җан сызлавы! Белсәгез иде, аңласагыз иде, берәрегезгә сөйләп булсын иде ичмаса, һай!..»

Таң әтәчләре кычкыра башлаганда гына үзен-үзе җыя алды Әбелкәрим: көтүләр кугач, Мотыйгулла янына барырга катгый карар кылды. Мондый фикергә килү аның өчен гаять газаплы, авыр булса да, шуннан соң күңеле хәйран гына җиңеләеп, бушанып калгандай сыман иде.

Әбелкәрим лапас ишеген ачуга, анда чүпләнеп йөргән тавыклар, башта өреккәндәй иттеләр дә, аннары, хуҗаларын таныпмы, бер-берсен уздыра-уздыра, аның янына йөгерештеләр. Әбелкәрим: «Китегез әле, ачкүзләр!»— дип, аларга кулы белән селтәнде. Моннан «ачкүз» тавыклар түгел, бурабзарның

ишек тоткасына бәйләнгән бозау куркып, алдындагы тагарагын төртеп җибәрде дә утын әрдәнәсенә килеп сөялде.

— Йә, йә, мин сиңа түгел бит. Ник котың очты?— дип, Әбелкәрим бозаунын сыртыннан сыйпады.

Элек сыер белән тана торган урын лапасның икенче башында иде. Кичә үз куллары белән танасын үләксә зыяратына илтеп кайтса да, аны күрергә өметләнгәндәй, туп-туры шул почмакка таба атлады. Бурабзар стенасындагы тимер чөйдә элек тана бәйләгән бауның асылынып торганын күреп, хуҗа кеше, моның шулай икәнен алдан ук белсә дә, кинәт имәнеп киткәндәй булды. Киртәнең икенче ягында сыер гына күшәп тора. Моңсу, бик тә моңсу булып китте Әбелкәримгә. Беренче мәртәбә күргәндәй, бауга өнсез калып карап торды да, аннары кырт борылып, утын әрдәнәсенә сөялгән тимер көрәкне барып алды һәм танадан калган тизәкләрне җыештырырга кереште. Башын күтәреп ара-тирә сыер ягына таба да карап ала һәм авыз эченнән генә мыдыр-мыдыр сөйләнә иде: «Менә бит ничек килеп чыкты. Әле ярый, җәй көне үгез яраткан үзеңне. Киләсе язга бозаусыз калдырмассың инде, шәт...»

Әлеге эшен бетереп, сыер астын да җыештырам дип кенә торганда кемдер каты итеп капка дөбердәтте. Әбелкәрим, көрәген куярга да онытып, ишегалдына чыкты һәм:

— Хәзер, хәзер ачам,— ди-ди капкага таба атлады. Бастырыкны этеп капканы ачты да анда еш-еш тын алып торган түбәноч Гайнияне күрде.

— Ни булды, килен? Нәрсәгә шул хәтле әлсерәдең?

— Әбелкәрим абый, ни кая? Гаҗби әби тордымы инде? Анда ни... Мотыйгулла абзыйның хәле бик начар икән... үлә ди. Гаҗби әбине чакырдылар. Укырга дип, ясин чыгарга дип.

Әбелкәрим каушап төште.

— Әә? Кит! Булмаганны!..

Гайния анын тораташ кебек бер урында басып торганына ачуы килеп:

— Гаҗби әбине чакырдылар. Гаҗби әбине,— дип сөйләнә-сөйләнә кулы белән төртеп капканы ачты.

— Ә... хәзер, хәзер әйтәм.

Әбелкәрим сөртенә-сөртенә ишеккә таба йөгерде. Гаҗбикамал карчык йокысыннан торып, урын-җирен дә җыеп куйган иде инде. Әбелкәрим кереп әйтүгә, тиз-тиз генә юынды да өйдән чыгып китте.

Әбелкәрим байтак вакыт өнсез утырды. Аннары, нәрсәдер исенә төшкәндәй, җәһәт кенә урыныннан торды да капка төбенә чыкты, абына-сөртенә кибет янына кадәр барды һәм түбәночта, Мотыйгулла йорты янына ук җыелып торган кешеләрне күреп туктап калды.

Мотыйгулла үлгән, дигән хәбәр йөрәгенең бер читен умырып алгандай итте. «Үлгән!.. Аңа да сөйләмичә калдыммыни инде? Нигә суздым? Кичә үк, өченче көн үк барган булсамчы янына! Хәзер нишләргә инде? Бу якты дөньяда бер генә көн булса да, бер генә сәгать булса да җаным газаптан арынмас микәнни? Ник болай... Ник болай ашыгасы иттең соң, Мотыйгулла? Урының җәннәттә булгыры, ярабби!..»

Әбелкәрим беркавым шул рәвешле кибет артында басып торды да, Мотыйгулланың исемен телгә алып, аны кызгана-кызгана түбәночка ашыккан кешеләргә капма-каршы, бөтенләй икенче якка таба атлап китте. «Каберенә туфрак та сала алмам инде. Мотыйгулла, монысын гына булса да кичерерсең. Мин салган туфрак өстеңдә ташка әйләнер...»

Әбелкәрим карт, пычратына, суына карап тормыйча, атлады да атлады. Юка, аксыл иреннәре бертуктаусыз кыймылдадылар. «Менә син дә киттең. Ашыктың... Менә без калдык. Барыбыз да үләсе инде аның. Бүген менә яшибез әле, иртәгә, берсекөнгә... тагы... Бу янгырлар бер туктар. Аннары бераз кояшлы көннәр булып алыр. Аннары тундырып да җиргә кар төшәр. Гаҗбикамал апа, бер кайткач, кышка хәтле торып китәм әле, ди. Ул кичләрен үзенең изге китабын укыр, аны тыңларга күрше-күләм җыелышып керер. Пәйгамбәрләрне кызганып еларбыз, яшь түгәрбез. Аның савабы зур, ди. Инде яттан белсәк тә, тагы, тагы тыңларбыз без ул изге китапны...»

* * *

Иртәгәсен, авылның яше-карты җыелып, мәрхүмнең гәүдәсен җирләп кайттылар. Әбелкәрим зиратка бармады, ул көнне бөтенләй урамга да чыкмады: сырхаулыйм дип, түшәк өстенә менеп ятты.

Әмма ике төн рәттән керфек тә какмый чыкты. Йокысызлыктан алҗыса да, күзләрен йома алмады: күзләрен йомса, каршында мәет сурәте пәйда булды. Ак кәфенгә төренгән салкын күзле Мотыйгулла кыяфәтендәге кеше аны, күзен йомарга ишарәләп, үзенә таба чакырды, әле шаркылдап көлде ул, әле кинәт тынып калды, салкын күзләре тагын да суына төшеп, боз төймәләренә әйләнгән сыман булдылар. Ул кешенең гүя ана ниндидер әйтер сүзе бар, шуны Әбелкәримгә ишеттерергә теләп пышылдый, тавышы чыкмагач, аны үз янына әйди кебек иде.

Карт, аны җен-мазардыр дип уйлап, ачы итеп сүгенеп тә карады, белгәннәрен дә укып бакты, аптырагач, ул хакта уйламаска да тырышты — ярдәм итмәде. Күзен йомуга, каршында Мотыйгулла кыяфәтендәге шыксыз сурәт пәйда була да пышылдый, чакыра.

Әбелкәрим карт түзмәде, ике көннән соң зиратка китте. Мотыйгулланың каберен үз күзләре белән күреп кайтмаса, тынычлана алмас кебек тоелды.

Мәрхүмнең малае гаиләсе белән һаман авылда иде әле. Аталарының җидесе узгач кына китәчәкләр, ди. Алар күзенә чалынмас өчен, Әбелкәрим карт зиратка таңнан ук торып кузгалды.

Урман-Тауның зираты авыл читендә. Аның бер кырые авылның бәрәңге бакчаларына ук килеп терәлә, икенче ягыннан колхозның уҗым басулары башланып китә.

Авыл иртәнге йокысыннан уянып кына килә иде. Урамда кеше-кара күренмәде. Ул кызу-кызу зиратка таба атлый-атлый, үз алдына сөйләнеп барды: «Теге хәлне малаена булса да сөйләргә кирәктер. Белеп торсын. Мотыйгулланың үзенә әйтә алмадым, малаена әйтсәм, Мотыйгулланың үзен күреп сөйләшкән кебек булырмын. Аннары фаш итсә итсен. Соң булса да, бу каһәр суккан серне белсеннәр. Теләсәләр, йөземә төкерсеннәр. Җаным җиңеләеп китмәсме. Котылырмын, тынычланып калырмын. Әйтәм, малаена барып әйтәм. Бүген үк барам, зираттан кайткач ук!»

Ул зиратка килеп җитте. Әнә юеш уҗымнар өстеннән күтәрелгән сөтле чәй кебек аксыл буны эретеп иренеп кенә кояш чыгып килә.

Әбелкәрим карт капканы ачып кергәч тә, иң кырыйдагы ялгыз яңа каберне күреп, адымнарын акрынайткан иде. Җир куеныннан актарылып чыгарылган кызыл балчык өеменең җансыз, хәрәкәтсез икәненә инангач, тагы кызулый төште. Менә — кабер. Мотыйгулла мәрхүм ята монда. Әбелкәрим кабер янына ук килеп басты да, тынсыз калып, беркавым карап торды, аннан соң акрын гына иелеп, бер кулы белән кабер туфрагына орынды. Кулын башта тиз генә тартып алырга теләгән иде, туфракның салкынлыгын тоеп, бармакларын балчыкка тирәнрәк батырды һәм, ни булыр икән дигәндәй, сулышын кысып, үзен көч-хәл белән генә мәҗбүр итә-итә, бер ара көтеп торды. Юк, берни дә булмады. Мотыйгулла аны үз янына тартып алмады; кабер җансыз иде, аның эчендәге ләхеттә яткан Мотыйгулла да җансыз иде. Моның шулай икәнен акылы белән аңласа да, менә хәзер тагын шул турыда уйлап, куанып куйды: «Юк, юк бит! Үлгән, беткән бит инде! Юк ул, юк!»

Аннары ул сынын турайтты да, каерылып, тирә-якка күз салды. Якын тирәдә адәм әсәре күренми. Ә аның бар кешегә дә ишетелерлек итеп аваз саласы, «Мотыйгулла үлгән, ул юк бит инде бүтән!» дип, шатланып кычкырасы, әлеге сәер шатлыгын башкалар белән уртаклашасы килде.

Шуннан соң Әбелкәрим карт кырт кына борылып, аяк астындагы түмгәкләргә сөрлегә-сөрлегә, кайтыр юлга чыкты. Зират капкасы янында беркавым уйланып торды әле. Аннан, ниндидер катгый карарга килгәндәй, бәрәңге бакчаларына таба борылды. Бәрәңге җирләре күптән буш иде инде. Шуңа күрә ул, бураэна таптап йөрисе булмагач, турыдан гына Маһирә лапасына таба атлады.

Карчыкның лапас ишеге бикле иде. Әбелкәрим бермал уйланып басып торды да, лапасны әйләнеп үтеп, таныш юлдан — читән койма аша ишегалдына сикереп төште. Нәкъ шул чакта кулына җиз комган тотып өенә кереп барган Маһирә дә аны күреп алды һәм бу хәлне ни дияргә дә белмичә аптырап, баскан урынында аптырап калды.

Әбелкәримнең инде күптән, бик күптән аның ишегалдына аяк басканы юк иде. «Әллә бу карт шайтанның яшь чакларын исенә төшереп йөрүеме?» дип уйлап куйды карчык.

— Нишләп йөрүең бу, Әбелкәрим?

Әбелкәримнең аңа: «Мотыйгулла үлгән икән бит, каберен үз күзләрем белән күреп кайтып киләм»,— дип әйтәсе килгән иде, тик әйтә алмады, теле әйләнмәде, әйтсә дә, карчык барыбер аның күңелендәгесен аңлый алмас, бары: «Акы-

лыңнан яздыңмы әллә?» генә дияр иде. Шулай дисә дә, аңа үпкә юк. Әбелкәримнең бу газаплары аның үзенеке, фәкать үзенеке генә иде шул...

Шулай да ул карчыкның соравын җавапсыз калдырмады, тел очына килгән беренче сүзләрен әйтергә ашыкты:

— Лапас ишегеннән бозавыбыз чыгып качкан. Зират янындагы уҗымда йөрмиме икән, дип, шуннан карап кайтыш ие. Анда да күренми. Монда ни, әллә кайдан урап йөрисе килмәде, синең ишегалды аша турыдан гына чыгып булмасмы икән, дигәнием. Лапас капкаң бикле икән.

Хуҗабикә җанланып китте.

— Бәй, шулаймыни! Мин тагын әллә нәрсәләр уйлап бетергән ием.

Әбелкәрим зур-зур атлап капкага таба юнәлде. Ирен читләренә эленгән елмаюын карчык күрми калды, бары сүзләрен генә ишетте:

— Әй, кортка, әллә нәрсә уйлый торган чаклар узды шул инде, узды,— дип көрсенде ул чыгып барышлый.

Зиратта булып кайткач, Әбелкәрим картның Мотыйгулла малае янына бару теләге юкка чыкты.

Менә бүген дә аларга күрше-күлән җыелышып керер. Гажбикамал карчык үзенең изге китабын укыр.

> Бу кыйссаны укыр гаклы булган кеше,
> Тыңлаучының күңле эрер, агар яше.
> Юкка чыгар гөнаһларының һәммәсе,—
> Рахман аңа рәхим шәфкать кылыр имди.

Изге китап әнә шулай дияр. Маһирә дә бик бирелеп тыңлар аны. Маһишәкәр дә, тол хатын Сафия дә авызына су капкандай утырыр. Әбелкәрим дә дикъкать белән тыңлар. Тыңлый-тыңлый, пәйгамбәрләрнең ачы язмышларын күз алларына китереп, кайнар яшьләрен агызырлар. Бары тик Әбелкәримнең генә, бик теләсә дә, күзләренә яшь килмәс инде, күңелендә утырган төере ирек бирмәс аңа.

Бу изге китап каршында үзләрен бик кечкенә һәм түбән итеп тоярлар алар, һәммәсе дә шул яшел тышлы китапка өмет күзләре белән багарлар...



**Венера Касыймова**

# АЧЫ УМАЧ

**хикәя**



Ерак рейстан кайтып киләм. Юлымны җәяүле буран себерә. Урман эченнән узганда мин моны сизмим. Бу вакытта күңелне рәхәт тынычлык били. Көн дә җылыныбрак киткән кебек тоела. Күңел түрендә җыр тибрәлә:

Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым пар каен...

Аланлык турысыннан узып барам икән. Юл кырыендарак янәшә салынган печән кибәннәре күренә. Машина тавышыннан куркытырмы, кибән төбеннән ап-ак тере йомгак атылып чыга да бер читкә тәгәри башлый. Куян! Менә ул, артыннан чуар эзләр калдырып, каен урманына кереп күздән югала. Урманны яңгыратып, малай чактагы кебек: «Тот! Тот, һайт!»— дип кычкырасым килеп китә.

Буран көчәя төшкән, ахры. Пыялага кар сылана башлады. Агачлар сирәгәйгәнгә шулай икән ул. Озакламый кырга килеп чыгачакмын. Кырлар... Барыр юлым туган кырларым аша үтәчәк! Бу яклар миңа кечкенәдән таныш булганга, тирә-як авыл шоферлары гына йөри торган, үзем белгән туры юл белән киткән идем. Моны үземнең кайчандыр борчак ашап йөргән басу-кырларны, туган якларымны күрәсем килеп өзгәләнгән йөрәгемә буйсынып эшләдем. Бу кырларга кайчан да булса яңадан килергә тиеш идем мин. Андагы һәр ызан, һәр сукмак, һәр буразна әле дә күз алдымда минем. Авыл башындагы коймаларга терәлеп диярлек, түгәрәк талга кадәрге арада арыш басуы дулкынланып утыра торган иде. Түгәрәк тал дигәнем... Аны нигә шулай дип атаганнардыр инде? Олы юл кырыенда үсеп утыручы мәһабәт карт юкәне түгәрәк тал дип йөриләр иде. Ул авылыбызның барлык серен беләдер сыман. Һәммә кешесен таныйдыр кебек. Чөнки авылда булган барлык вакыйгалар, яңалыклар, фронттагы хәлләр карт юкә төбенә әбәткә җыелгач сөйләнә. Хатлар шуның күләгәсендә утырып укыла. Күз яшьләре шунда түгелә. Ә карт юкә башын иеп, әкрен генә тыңлый. Кешеләр белән бергә моңая кебек. Моңлыларны юатып, нәрсәдер әйтеп, яфраклары әкрен генә лепердәшә. Басуларда ашлыклар уңып, рәхәт, тыныч яшәгән елларда түгәрәк тал да яшьрәк, сылурак күренә иде. Сугыш елларында түгәрәк талның өч ягы корый, саргаеп килә башлады. Әйтерсең лә авылдашлары өчен кайгырудан шулай саргайган ул.

Әтиләр сугышка киткән елны басулар соңгы тапкыр күкрәп утырдылар. Без, малайлар, олылар күрмәгәндә арыш дулкыннарына чума-чума качып уйнарга ярата идек. Сугыш елларында исә арыш сабаклары арасына кереп качуның кызыгы калмады. Аннан соң рөхсәт тә итмиләр. Басуларга каравылчы куя башладылар. Бигрәк тә борчак җирен саклаучы Галимҗан картка ачуыбыз килә иде. Борчак кузаклана башлауга, җир өстенә шалаш корып куя. Шуның эчендә, борчакны безнең ише тынгысыз малайлардан саклап, көне-төне яшеренеп ята. «Галимҗан бабай авылга кайтып киткән икән»,— дип, җиргә аяк басуыбызга этен ияртеп шалаштан килеп тә чыга. Бар халебезчә кирегә, авылга йөгерәбез...

Әниләрнең уракка төшүен тагын да түземсезләнебрәк көтә торган идек. Чөнки шул көннән башлап иң тәмле, иң куе ашлар ашарга насыйп була иде.

Әниләр урак урганда, түгәрәк талның күләгәле ягына утырып, арыш башын ике учыбыз белән ныгытып уабыз. Кылчыкларның кулга кадалуында эш юк.

---

Венера КАСЫЙМОВА *(1938) — газета-журналларда, «Идел» альманахында чыккан повесть һәм хикәяләр авторы. Журналда проза әсәре белән беренче тапкыр катнаша. Казанда яши.*

Арыш башын уып, өзгәләп бетергәч, бөртекләре коелып, җиңеләеп кала. Бармакларны җәеп, теткәләнеп беткән буш башакны өреп очырабыз. Уч төбендә аксыл-сары бөртекләр тәгәрәшеп ята. Арада яшькелтрәкләре дә күренгәли. Авызыңны зур ачып, бөртекләрнең барысын берьюлы кабып йотасың. Юк, йотмыйсың, бу шулай әйтелә генә. Башта озаклап, рәхәтләнеп чәйнисең. Алардан май сыгылып чыга төсле.

Их! Мине гомерлек газапка салган шул арышлар! Эш көненә алып кайткан беренче авансы арышы! Их! Нигә дип бу кырлар аша үтәргә уйладым соң әле? Газапларымны яңарту өченме...

Тиздән ике юл чатына җитәм. Уңга киткәне безнең авылга илтә. Мине анда әнием көтеп торсын иде. Юк! Көтмәгәндә, сиздермичә кайтып төшсәң икән! Ә әни барыбер сизәр иде. Капка төбендә, кулын каш өстенә куйган килеш, текәлеп юлга карап торган көйгә каршылар иде ул мине.

— Исәнме, әни! Менә мин кайттым әле. Көтмәгән идеңме?

— Көттем, улым, көттем! Көтмәгән кая! Мин сине һәрвакыт көтәм. Кайтмасыңны белсәм дә көтәм!— дияр әни. Елмаюдан әниемнең озынча ябык йөзенә нур иңеп китәр иде.

Тик... хәзер бу мөмкин түгел шул. Әнием юк инде минем. Иң кызганычы: мич тутырып ипи сала алмый калды ул. Кершән төсле ак оннардан токмач җәя алмый калды әни. Гөбәдияләр пешереп, сыйланып, чәйләр эчеп утыра алмый калды әни. Оннар исәпсезгә әйләнгәнче, ни теләсәң шуны пешерә ала торган заманнарга кадәр яши алмады әни. Он-ярма мыскаллап исәпләнгән, стаканлап әҗәткә сорала торган заманнарда умачка да туймыйча җәфа чикте.

Бу каһәр суккан сугыш әтиемне дә, әниемне дә тартып алды. Әниемне?.. Юк! Әниемне... мин үзем...

Күзем юлда, ә каршымда әниемнең шул чактагы йөзе шәйләнә. Беркайчан да, беркая да кача алмыйм мин аның бу карашыннан. Күземне чытырдатып йомсам да күрәм мин аны! Әнә ул, капка төбенә чыгып баскан да, тегермәннән кайтып килгәнемне көтеп тора. Без капка төбенә килеп туктагач башта сөенечле, аннан соң аптыраулы, аннан борчулы карашы белән миңа төбәлеп, инәлепинәлеп сорый:

— Нишләп... моның гына кадәр?

Ничә еллар колагымда әниемнең шушы сүзләре яңгырый! «Нишләп моның гына кадәр?»

Әниемнең каш өстенә куйган куллары әкрен генә югары күтәрелә башлады...

Чү! Каршымда әни түгел, кулын югары күтәреп бер агай басып тора икән. Туктадым. Агай, кулларын угалап, кар сарган кабина тәрәзәсенә килде. Нәрсәдер әйтә. Тик көчле җил аның тавышын әллә кайларга бөтереп алып китә, миңа ишеттерми. Кабинаны ачам. Ургылып кергән җилдән йөземне читкә борам. Колак төбендә ялварулы сүзләр яңгырый:

— Табариш, памагай пажалысты!

Агай юл читендә туктап калган «Жигули»га төртеп күрсәтә.

Кабинадан сикереп төштем. Җилгә ян беләнрәк борылып, машинага таба атладык. Кайнар җил колакларны өтеп алырга да өлгерде.

— Нәрсә булды соң, абзый кеше?— дим.

— И-и, энекәш! Үз кешебез икәнсең әле! Бу тирә машинасы булмагач мин тагын...

Агайның тавышы миңа ничектер таныш тоелды. Бу авазларны минем кайдадыр ишеткәнем бар. Тик кайда?

Ихтыярсыздан агайга борылып карадым. Ә ул йөзен бүрек колакчыны, тун якасы белән каплап бетергән. Күзләре генә елтырый. Күзләр! Башымда бер генә уй: «Дуңгыз баласыныкы төсле керфексез, төссез ак күзләрне кайда күрдем соң мин?»

— Әле күптән түгел генә алганнарые. Кода да, мин дә гомеребез буе дилбегә тотып өйрәнгән. Бу нәмәстәкәй белән таныш түгел. Үзем тиле шул, кодаНың борын асты да кипмәгән малаена ышанып...

Әйе, безнең бу агай белән кайдадыр очрашканыбыз бар! Бу шөбһәсез. Тик кайда һәм кайчан икәне генә хәтеремә төшми.

Машина тирәсендә ике кеше кайнаша. Без килеп җиткәндә яшь егет, ачык капот эченә иелеп, моторда казына иде. Ә бабасы, үзенең ярдәм итә алмавына гаҗиз булып, борчылып аңа карап тора.

— Саумы, бабай!

— Шөкер әле, олан, шөкер. Үзебез исән-сау... Тик менә бу нәрсәбез генә

кәжәләнеп тора.

Егет тә гаепле кыяфәт белән миңа карады:

— Моторга әллә нәрсә булды. Үзеннән-үзе сүнде дә, кабынмый.

Машинаны туктарга мәҗбүр иткән гаепне эзләргә тотындым. Хикмәт ротор-да булып чыкты. Күпме чиләнсәң дә машиналары кабынмаячак! Буранда гына рәтләрлек түгел. Бабайлар, машиналарын минекенә тагып, кире кайтырга карар кылдылар. Утыргыч астыннан тимер аркан алып, «Жигули»ны буксирга тактым. Егет руль артына кереп утырды. Бабасы аның белән янәшә урнашты. Менә туктаткан агай гына нишләптер утырырга ашыкмый. Бер урында таптана. Бераздан ул минем янга килде.

— Энекәш, синең кабинкеңдә җылырак бугай. Матуры эшләмәгәч, безнең машина тәмам суынган. Синең янга утырсам, ачуланмассың бит?

— Утыр, абзый, утыр! Коданны да чакыра аласың, ул да туңгандыр бит. Икегез дә сыясыз.

Агай, кодасы ягына күз төшереп алды да, мыштым гына кабинага үрмәләде. Сак кына кузгалып киттек. Агай сүз башлады:

— Ерактан килешме?

— Ерактан,— дип, билгесезлек белән җавап бирдем.

— Капчыкларда он ахры?

— Әйе, он...

Он дигән сүз чыгуга, күз алдыма янадан әнием килеп басты.

...Әнә ул, эш көненә тигән арышны күтәреп, әвеслектән кайтып килә. Талчыккан йөзе яктырыбрак киткән. Әни капчыгын сап-сары итеп юган баскычка куйды.

— Улым...

Әни озак кына сүзен әйтми торды. Аның тавышындагы сөенечне күңелем белән тойдым. «Бу арышны тарткач, ипи салырмын да сине тәмле, җылы ипи белән сыйлармын!»— димәкче булгандыр ул, бәлки. Аннан соң:

— Менә, эш көненә авансы бирделәр,— дип кенә куйды.

Арышны бүлмәгә кертеп урнаштырдык.

— Әни, кара әле, никадәр күп!— дидем сөенеп.

— Бәрәкәте белән булсын. Ише янына кушы өсталсен. Менә тегермәнгә барып, тарттырып кайтырмын да...

— Әни, ипи пешерерсең әле? Күп итеп! Туйганчы ашарлык...

— Пешерермен, улым.

Тагын да батыраеп киттем:

— Әни, коймак та пешерерсеңме?

— Пешербез, улым...

Мин бөтенләй хыялга биреләдем:

— Әни, озын-озын токмачлар кисәрсең әле!

— Токмачлар да кисәрмен, гөбәдияләр дә пешерермен...

Миндәге хыял әнигә дә күчте бугай. Бераздан ул исенә килде, чынбарлыкка кире кайтты:

— Синең гөбәдияне ашап караганың да юк бит әле,— дип куйды.

— Әни, гөбәдия тәмлеме ул?

Әни бер сүз дә дәшмәде. Моңсу гына миңа карап алды да, кытыршы-йомшак кулы белән башымнан сыйпый башлады.

Минем күз алдында — әле генә мичтән чыккан өстәл тулы ипиләр, кызарып пешкән коймаклар. Тик гөбәдияне генә күз алдыма китерә алмыйм. Борынымны кетердәп пешкән ипинең тәмле исләре кытыклый. Тик гөбәдия исен генә аера алмыйм. Ул ис миңа таныш түгел.

— ...Он димәктән, безнең дә тегермәнгә барышыбыз иде әле.

Бу сүзләрдән соң әниемнең кытыршы куллары башымны сыйпаудан туктады.

— Үзебездә бик начар тарта. Күрше авылныкына барырга чыкканыек. Анда бик әйбәт тарта, кершән шикелле итә дигәннәрие...

«Кершән... Кершән шикелле!... Тукта! Әни дә шулай дигән иде бит!»

Моннан күп еллар элек булган вакыйгалар бер-бер артлы күз алдымнан үтә башлады... Ул көнне мин атылып кайтып кердем дә:

— Әни! Сәлихҗан белән мин дә тегермәнгә барыйм әле?— дидем.— Теге арышны үзем тартып кайтыйм!

Әни, ышанмыйча, «Чынлап әйтәме икән бу?»— дип, бер миңа, бер әле генә ишектән килеп кергән Сәлихҗанга карап алды.

— Үзем булышырмын. Икебезнекен дә безнең арбага салып барырбыз.

Мин күтәрә алам!— диде Сәлихҗан ышандырырлык итеп.

Әнигә файдам тиярлек булып үсеп җиткәнлегемне күрсәтәсем килә. Бик ялына торгач, әни ризалашты.

Икенче көнне төшке ялга кайткач, әни Сәлихҗаннар арбасына безнең дә арышны чыгарып салды. Капчыкларны ныгытып бәйләдек тә кузгалырга җыендык.

— Улым, анда кершән шикелле иттерә. Ә син тегермәнчегә әйт, безгә ипи пешерергә, эрерәк кирәк, диген. Көрпәсен очыртып бетермәсен.

Әни тагын нидер уйлап сүзсез калды.

— Әллә үзем генә барыймы икән? Эштән кайткач... Әрәм-шәрәм итеп бетермәссеңме соң? Булдыра алырсың микән? Бер умачлыгы да ни тора бит! Син икенче өләшкәч барыр идең...

Шундый шөбһәле уйлар белән әни безне озатып калды.

Арбабызны тартып, тегермәнгә китеп бардык...

Янәшәмдәге агай яңадан уйларымнан бүлдерде:

— Менә элгәрие ул тегермәннәр! Тартып карыйлары да соң? Кирәк булса кершән кук, туйга яраклы итә. Ипигә дисәң, эрерәк тарта. Теләсәң, ярма ярдыр. Су тегермәннәрне шул алар! Карадуганныкы тирә-якта атаклые! Гомер бакый, ата-бабалардан килгән тегермәнне сүтеп әрәм иттеләр!..

«Карадуган тегермәне! Карадуган!.. Без дә Карадуган тегермәненә барган идек бит инде!»

Ялт итеп агайга карадым. Әллә бу... шулмы?.. Шул ич! Тавышы! Күзләре! Әнә нигә таныш кебек тоелган ул тавыш миңа! Юк, ялгышмыйм бугай. Битен дә капламаган булса!

Тегермән ягыннан килгән көчле гүләү тавышын кабат ишеткән кук булам. Теләсәм-теләмәсәм дә, тегермәндәге вакыйгалар күз алдыма килә. Мин аларны хәтеремнән сызып ташлау өчен әллә ниләр бирер идем дә...

...Әнә, без инде Сәлихҗан белән Карадуган урамыннан барабыз. Биек, карт тирәкләр белән уратып алынган ниндидер йортларга таба борылдык. Шул тегермән икән инде. Сәлихҗан шулай диде. Ул яктан шомлы гөрелтәү ишетелә.

Тегермәнгә килеп ук җиттек. Бер абый артыннан чират алдык та, мин шунда ук тегермәнне карарга тотындым. Ә Сәлихҗанның күргәне бар икән.

Әнә нинди икән ул тегермән! Башта туйганчы эчен карап йөрдем. Зур-зур ташлар әйләнеп тора. Ике таш арасына әкрен генә коелып торучы арыш, онга әйләнеп, кечкенә улак буенча агып төшә. Сөт чишмәсе шикелле! Чүмечкә тутыр да эч! Сөт чишмәсенә кулны тыгып карыйсы килә. Яңа сауган сөт төсле җылыдыр ул. Тик кулны тыгарга ярамый, үзебезнеке ага башласын әле!

Бөтен нәрсә ап-ак. Түшәм дә, идән дә. Бүрәнә жекләренә дә бәс сарган төсле. Тәрәзәгә дә он тузаны кунган.

Югары каттан төшеп килүче тегермәнче күренде. Җен патшалыгының хуҗасы диярсең! Зур гәүдәле. Озын мыеклы. Мыегы белән йөнтәс кашы, керфекләренә кадәр ап-ак. Ул үзенең бүрәнә юанлыгы бармаклары белән угалап тараткалап, улактан аккан онның эрелеген-ваклыгын тикшерде бугай. Аннан соң алыптай адымнары белән кызу-кызу атлап, югары катка менеп китте. Мин дә аңа иярдем.

Онга әйләнсен өчен ашлыкны башта монда алып менеп бер яшьнеккә саласы икән. Ул яшьнек кызау дип атала. Кызау нәкъ бүрәнкә төсле. Түгәрәк түгел, шакмаклы бүрәнкә. Аскы өлешендә, ике таш арасына аз-азлап ашлык коелып торсын өчен, тишек тишелгән. Өске ягы зурая барып, берьюлы әллә ничә капчык ашлык сыешлы итеп ясалган.

Тегермәнче артыннан калмыйча ияреп йөрим. Ул әллә нәрсәләрне бора, көйли. Аңа ияреп ишек алдына чыктым. Монда ничектер шомлы. Суы дегет шикелле караеп торган буада әллә нинди аждаһалар яшидер кебек. Шуннан җен малайлары чыгып, тотып алырлар төсле. Башта куркыбрак торсам да, кызыксыну үзенекен итте. Карамаган бер генә почмагын да калдырмадым. Зур агач тәгәрмәчләргә килеп бәрелгән су тавышы белән әлеге тәгәрмәчләр чыгырдавы бергә кушылып, кук күкрәгән тавыш чыгара. Тагын күпме йөргән булыр идем, шулчак Сәлихҗанның:

— Кайда йөрисең инде шул гомер? Чират җитте ич!— дигәне ишетелде.

Йөгереп кердек тә икебез дә капчыкларыбызга тотындык. Капчыгымны урыныннан да кузгата алмыйм. Тегермәнченең: «Сез әзерме анда?»— дигән сүзеннән соң тагын да каушап киттем. Сәлихҗан үз капчыгын ычкындырды да минекенә килеп ябышты.

— Кая әле, капчыгыңның авызын чиш башта. Аннан соң җыеп тот та шуннан күтәр. Мин төбеннән күтәрәм. Тегермәнче әйтмичә капчык авызын ычкындыра күрмә!— дип, Сәлихҗан белгәннәрен миңа өйрәтә.

Кызау безнең буйлар өчен шактый биек булып чыкты. Безгә капчыкны кызау кырыена күтәреп куярга кирәк. Сәлихҗанның да көче минеке чамалы гына икән. Капчыкны җан көчләребез белән кызау кырыена күтәреп куюыбыз булды, капчык авызының бер чите кулымнан ычкынып та китте! Арышым кызау эченә ага да башлады. Котым чыгып капчык авызын кызу-кызу җыярга тырышам. Ул аның саен кулымнан ныграк ычкына гына бара. Моны Сәлихҗан да күреп тора. Тик ул капчыкны кызау эченә төшереп җибәрмәс өчен ике куллап ныгытып тотып торганлыктан, миңа булыша алмый. Яшен тигезлегендә нәрсәдер эшләргә кирәклекне аңлыйм. Ул нәрсәдернең кызау эченә иелеп, капчыкның арыш агып торган читен җыеп югары күтәрү икәнен дә беләм. Тик моңа минем буем җитмәячәк. Шуны аңлап тагын да каушый төштем. Сәлихҗанның: «Җый инде капчык авызын! Нәрсә карап торасың, арышыңны агызып бетерәсең ич!»— дип, кычкырып җибәрүеннән соң бөтенләй катып калдым.

Капчык күзгә күренеп кечерәя бара. Әйтерсең лә шикәр кебек эри. «Ә теге абый минем онны үз капчыгына тутыра булыр!» Бу уйдан хәлсезләнеп киттем. Тегермәнченең: «Салыгыз!»— дигән боерулы тавышы яңгырады. Кыл кыймылдый алмыйча басып торам. Сәлихҗан, әллә хәлемне аңлады, бер сүз дәшмичә, мине этеп җибәрде. Үзе, төшеп баручы капчыкны чак кына эләктереп өлгерде дә, кызау эченә кагып, миңа тоттырды.

«Әле соң түгел! Онны сорап алырга кирәк!» Шушы уйдан уянып киткән күк булдым. Буш капчыкны тоткан килеш, дөбер-шатыр түбән катка йөгердем.

Нәни улак буйлап агып торучы он җыела торган лар янына килдем. Бездән алда чиратта торган абый, ларга иелеп, соскычына он тутыра. Килгәндә тулартулмас булган капчыгы шыплап тутырылган.

— Абый! Тимә! Ул минем он!— дип кычкырып җибәрдем.

Ул иелгән килеш кенә миңа карады. Лардан, яңа дуңгыз баласыныкы төсле керфексез-нисез, төссез, ап-ак күзләр коточкыч усал чекерәеп карап торалар! Әйтерсең лә мине якын җибәрмәс өчен көйдерергә, этәргә җыеналар. Ул караштан куркып чигенеп куя яздым хәтта. Иң гаҗәбе... Ул күзләр турында шул секундта ук оныттым. Игътибарымны җәлеп иткән нәрсә — ямьсез җөйләр белән чуарланып, тиресе тартылып торган, чокыр кебек эчкә батып кергән яңагы! Йодрык сыярлык! Кош оя ясап кереп утырырлык! Сыңар яңак. Бичара! Читендер инде аңа. Килгәч тә ничек күрмәдем икән мин аны!

Кадакланган шикелле басып торам икән. Абый тураеп, капчыгының як-ягына баскалап, онын тыгызлый башлагач кына ни өчен килгәнлегем исемә төште. Күңелемдә туган кызгану хисеннән каты дәшәргә кыймадым, җайлап кына әйтергә тырыштым:

— Абый, анысына тимә инде, ул он минеке.

Абый күтәрелеп тә карамады, тутыруын белде.

— Абый дим, чынлап әйтәм! Анысы минеке! Капчык авызы ычкынып китте дә, арышым синеке өстенә акты. Тегермәнче салырга кушканчы бөтен арышым агып бетте диярлек. Әз генә, капчык төбендә генә калды. Безнең арыш ярты капчык иде...

Кызу-кызу сөйлим. Соңга калмагаем, бу кеше онны тутырып бетермәгәе дип куркам. Шушыларны әйткәч, онны бирер күк тоела.

Лардан кисәк кенә, ашарга торучы усал бүреneke шикелле, явыз йөз калыкты. Бу юлы аның ыржаеп торган яңагына күзем дә төшмәде. Күңелемдә уянган кызгану хисе әкренләп нәфрәткә әверелә бара. «Кызгансыннар өчен, явызлыгын яшерү өчен генә шундый яңаклыдыр ул!» Түзмәдем.

— Калганы минем он! Анысына тимә!— дип, бар көчемә чытырдатып соскычка килеп ябыштым.

— Нәрсә сөйлисең син, ахмак малай! Олак хәзер үк янымнан!— дип, ул мине бик каты этеп җибәрде.

Соскычка ябышкан кулларым ычкынып китте. Ә ул яңадан лардагы онны инде урыны калмаган капчыгына сыйдырырга азаплана башлады. Капчыгының як-ягына баскалап урын әзерли. Мин, мөлдерәп, сихерләнгән шикелле аңа карап торам. Соңгы тапкыр ялынып карамакчы булам. «Анысын алма инде, абый?! Капчыгың тулган бит. Миңа калсын. Ату мине әни орыша ич»,— димәкче булам. Әни исемә төшүгә, тамагыма кайнар төер килеп тыгылды. Каерылган тырнагымның авыртуы, капчык күтәрерлек көчем булмаганга ачыну, онымны бу явыздан ала алмавыма әрнү — барысы бергә кушылды да кайнар күз яшенә эн-

ләнеп ике битем буйлап ага да ага. Яшьләремне күрсәтмәс өчен нелеп, улактан яңа гына ага башлаган үз онымны капчыкка тутыра башладым. Ул арада теге кеше капчыгын чеметеп кенә бәйләп тә куйды. Лар почмагында шактый он өелеп калды. «Миңа калдырды! Кызганды булса кирәк!» Уйлап та бетермәдем, тегермәнче килеп үзенең чиләк кадәр соскычына калган онны тутыра да башлады.

— Ә син көрәк оны биреп тормассың,— диде ул миңа карап.

Ул арада минем арышымны талаган кеше китәргә җыена башлады. Капчык аның көчле иңнәренә менеп утырганчы миндә әле: «Бәлки, кире бирер»,— дигән өмет яши иде. Нигәдер ул мине сыный, куркытыр өчен генә бирми тора кебек тоелган иде. Мондый явызлыкны эшли алырына ышанмаган идем. Инде соңгы өметем дә сүнде. Карамаска тырышсам да булдыра алмадым. Әнә, капчык күтәргән хәрамша инде ишеккә җитте! Бусаганы атлап чыкты. Юк, болай булгач, кире кертми инде! Онымны алып китте...

Күз яшьләрем миңа буйсынмыйлар. Он өстенә тамалар да тамалар. Күрмәсеннәр дип йодрыкларым белән сөртеп тә карыйм. Он белән яшь, бергә кушылып, камырга әйләнә дә биткә сылана.

Әкрен генә улактан агып торучы сөт чишмәсе туктады. Битемне пешерүче яшь чишмәсе генә туктамый.

Лардан җыйган соңгы соскыч онымны капчыкка салдым. Килгәндә никадәр арыш иде! Күпме генә он булды! Капчык төбендә генә, мин күтәрерлек кенә ич бу!

Күз яшьләрем тагын да мулрак ага башлады.

— Җылама инде шул хәтле... Тукта инде. Әзрәк безнекеннән дә салырбыз,— дип, Сәлихҗан кыяр-кыймас кына җиңемнән тартты.

Бу мизгелдә минем өчен тирә-якта беркем, бернәрсә, хәтта кояш та юк иде кебек. Дөнья караңгыланып киткән төсле булды. Бары алдымдагы һәм теге явыз хәрамша капчыгында киткән он гына иде уемда. Сәлихҗанны да онытканмын!

— Синекен саласы бар ич әле! Әйдә, тизрәк,— дип, яшь пәрдәсе аша аңа карадым.

— Салдык инде, тегермәнче булышты,— диде ул.

Аның сүзен раслагандай, ипи исе аңкытып, улакта он күренде. Җир астыннан яңа гына бәреп чыккан шифалы чишмәдәй, он тагын да көчлерәк агарга тотынды. Сәлихҗан улак алдына соскыч куйды. Он чүмәлә булып өелде дә ишелеп төште. Сәлихҗан аны як-якка җәеп тигезли. Онга тагын урын була. Соскыч тулгач, Сәлихҗан бер мәл уйланып торды да, минем капчык авызын ачып, онны шунда сала башлады.

— Кирәкми! Сезнең үзегезнеке дә күп түгел ич. Әниең орышыр,— дип, соскычын читкә эттем.

Каршы килүемә дә карамастан, Сәлихҗан онны минем капчыкка салды. Бер тамчы җәлләмәде. Бәлки җәлләгәндер дә. Башта соскычка карап уйланып торды бит. Ә шулай да салды! Ә теге хәрамша, никадәр оны булуга карамастан, кычкыртып талап китте!

Юл буенча сөйләшми генә кайттык. Сәлихҗан да гаепле кеше шикелле аска гына карап бара. Минем аркада инде... Килгәндәге шикелле шаяра-шаяра рәхәтләнеп шатланып кайтасы урынга... Он кимеп, арба җиңеләеп калганнан бер җиңеллек тә юк икән. Киресенчә, әле күңелгә тагын да авыррак. Арба авыр булсын икән ул. Авыр арбаны тарту берни түгел икән.

Теге кеше, он белән бергә, безнең шатлык-сөенечләребезне дә капчыгына тутырып киткән кебек.

Аска гына карап барсам да, авыл зиратының һаман якыная барганын күрәм. Эх, ерак, бик ерак булсын иде әле ул! Бүген кайтып житмәслек! Әни белән очрашкач нәрсә диярмен? Ул нәрсә әйтер...

Әни безне капка төбендә каршылады. Ерактан ук аның сөенечтән балкыган йөзен күрдем. Без килеп туктагач, бу шатлык башта аптырауга, аннан соң борчуга әйләнде. Бер онга, бер миңа карап ул: «Нишләп... моның гына кадәр?»— дип, хәвефләнеп пышылдады. Аның ябык, борчулы йөзеннән: «Әй, бала, бала! Ач калдырдың бит! Ник кенә сине җибәрдем икән! Онны нишләттең соң?»— дигән сүзләрне укыйм. Күңелемә беренче килгән җавапны бирдем:

— Тегермәнче абый көрәк онына алды...— дидем дә аска карадым.

— Сабыйларны таламаса... Беткәнме аңа... Кеше өлешен, сабыйлар хакын ашаган өчен ходай орыр әле үзен. Тамагына тыгылыр. Ходай җәзаламый калмас. Кеше рәнҗүе төшми калмый ул...

Әни әрни-әрни тегермәнчене тирги. «Әни! Аңа кагылма, әрләмә! Ул алмады!

Хәрамшага җәза телә! Безнең онны шул явыз алды!»— диясем килә. Тик әйтергә батырлыгым җитми.

Әни әкрен генә, тавышсыз гына елый. Аның елаганын карап тору, минем аркада бер гаепсез кеше өстенә каргыш яудыруын ишетү — бермә-бер газап. Тегермәнчене түгел, мине орышсын иде ул ичмаса! Аңа кушылып, үксеп-үксеп елыйсым килә. Әнинең: «Рәнҗү төшмичә калмый ул! Ходай җәзаламый калмас!»— дигән сүзләре генә бераз юаныч бирә. Димәк, теге явыз җәзасын алачак!

Без ул оннан ипи пешермәдек. Әни аны умачка гына тотты. Тик ул умачларны авызга кабуга, теге хәлләр исемә төшә дә, умачның бер тәме калмый. Умачлар авызны өтәрдәй ачы тоела. Йота алмыйча азапланам. «Эх! Кайчан зур булырмын! Кайчан әнигә капчык тутырып хуш исле он алып кайтып бирермен!»— дип уйлыйм.

Тик ул бәхет миңа насыйп булмаган. Бер кило он да алып кайта алмадым мин әнигә. Тими калды ул бәхет миңа! Икенче тапкыр эш көненә ашлык өләшкәндә әнием юк иде инде. Врачлар: «Туйганчы ашамаганлыктан, организмы көчсезләнеп, хәлсезләнеп үлгән»,— диделәр. Теге чакта капчык авызын ычкындырмасам, арышны агызмасам, әнием хәлсезләнмәс иде. Үлмәс иде ул! Онны мин хәрамшага биреп кайттым. Ә үзем әни өлешенә кердем. Ул ашыйсы ризыкны ашадым! Әнине мин генә үтердем...

Бу уйдан мин гомерем буе газапланам. Бу уй көнелемә килгән саен үземне каһәрлим. Үкенүдән дә авыр, ачы газап бармы икән дөньяда! Иң бәхетсез кешеләр генә үкенү газабы кичерәдер!

...— Хи-хи-йхи-ихи! Ә ул вакытта өч йөз грамм өчен себер җибәрәләрне! Янымдагы бәндәнең буыла-буыла хихылдавыннан әнием турындагы татлы һәм газаплы уйларымнан бүлендем.

— Ә минем җавабым әзер! «Ындыр каравылчысын сынамакчы гына идем! Әнә ул ничек каравыллый икән, контр! Атарга кирәк аны!»— дип тетмәсен тетәм. Барыбер миңа ышаначаклар, ана түгел! Мин партияле. Аның өстенә тагын идарә члены да! Шулай, энекәш. Йоклап йөрмәскә, җай чыкканда умырып алырга кирәк. Хи-хи-хи...

«Чын намуслы партия членнарына да кара яга! Үзенең этлеген сөйләп мактана! Әшәке җан! Тибеп төшерергәме әллә!»

Ә хихылдаучы, минем дә хуплап көлүемне көттеме, «Бигрәк булган кеше икәнсең!»— дигән соклану билгеләре теләпме — комачаулап торган якасын төшереп миңа борылды. Җөйләр белән чуарланып беткән, эчкә батып кергән сыңар янак! Шул явыз хәрамша!

Моңарчы да аның кем икәнен чамалаган идем инде! Аның хихылдавында: «Олак хәзер үк янымнан, малай актыгы!»— дигән мәрхәмәтсез сүзләрне янадан ишеткән күк булган идем. Менә язмыш бер дә уйламаганда мине кем белән очраштырды! Теге чакта ук аның сәламәт яңагына тырнакларымны батырып, буразна-буразна итеп ермачлыйсым килгән иде. Ул чактагы нишләргә белмичә гаҗиз калган көчсез малай түгел мин хәзер! Бу минутта аның миннән күп көчсез булуы кулымны тота, ихтыярымны богаулый. Их! Хәзер менә көчләр тигез булсын иде дә, аның икенче яңагыннан черек бәрәнге калҗемәсе ясарга ярасын иде!

Бу эштән үземне чак-чак тыеп калдым. Арттагы машинаны кисәттем дә тормозга китереп бастым. Теге бәндәнең такыр басу кадәр шаксыз маңгае алдагы пыялага килеп бәрелде. Ул шундук хихылдавыннан туктады. Үрелеп, сыңар саңак утырган якның кабина ишеген ачтым.

— Яхшы чакта хәзер үк олак, тәмуг кисәве!— дип әйтергә теләгән ачулы сүзләрем бугазыма килеп бөялде. Бу халәтемдә нишләргә, нишләргә тиеш соң?

Кинәт каршымда әниемнең борчулы йөзе пәйда булды. «Кирәкмәс, үткәннәрдән үч алма, улым! Мондый начарлар аз ул! Җир йөзендә яхшы кешеләр күбрәк! Булдыра алган кадәр кешеләргә үзең дә яхшылык эшләргә тырыш. Юлдашларыңа нинди үрнәк күрсәтүеңне уйлыйсыңмы соң?! Алар да шулай кешеләрне бәлагә тарган килеш ташлап китсә? Дөрес хөкем итүчән бул, улым!»

Давыл булып күңелемдә уйлар кайный, капма-каршы фикерләр тарткалаша. Уйларымны тәртипкә саласы килеп, тәмәке кабызырга дигән сылтау белән кесәмнән шырпы эзлим, актарынам, кырысланам. Янәшәмдә аптыраулы кыяфәттә хәрамша утыра. Безнең арада — упкын, тиз генә аңлашып булмый торган гаҗизлек. Мин хәзер ике юлның берсен сайларга тиеш! Тик кайсысын, кайсысын?..

# ПОЭЗИЯ

## Энже Мөэминова

*

Нәрсәдер югалтам сыман,
Нәрсәдер табам сыман;
Кемнедер эзлим кебек мин
Юлдашлар арасыннан.

Нигә соң һаман юлда мин?
Нигә соң түгел ялда?
Кайда соң юлның азагы?
Ни көтә мине алда?

Юл башында, кулын изәп,
Бәхетем калмый микән?
Юл азагы бәхет, бәлки,—
Әллә шул алдый микән?

### Табышмак

Таң атуы сизми калынган,
Озак эшләп кичтән, арылган.
Таң йокысы җиңгән үземне:
Көн иде инде, ачсам күземне.

Сукмакларда — агач шәүләсе,
Күтәрелгән томан пәрдәсе.
Мин ашыктым диңгез янына.
Дулкын бәрә диңгез ярына.
Акчарлаклар канат кагына.
Нидер сөйли сыман, сулкылдап,
Гәрәбәдәй сары дулкыннар.
Сөйләр дә шул диңгез — сере бар,—
Күбекләрен чәчә ул шуңар.

...Ачмады ул серен, ачмады,
Агач тамыры китереп ташлады,
Бер чуерташ чыкты ияреп,
Йөзеп килде такта кисәге...
«Серем шунда!» — дигән шикелле
Дулкын ашыгып кире чигенде.
Өч табышмак миңа калдырды:
такта,
        таш һәм
                агач тамыры!
Ярга күмдем агач тамырын.
Ташын истәлеккә алырмын.
Калыр анда ялгыз тирбәлеп
Табышмаклы такта кисәге.

---

Энҗе МӨЭМИНОВА — *шагыйрә. «Ефәк яулыгым», «Синең өчен язам», «Исемдә» һ. б. шигырь китаплары авторы. Әлмәт районының Габдрахман авылында яши.*

Хокукым бар—
димәк, хакым бар!
Хакым бар, дип,
хокук даулар өчен
Хокук биргән
олы халкым бар.

## Исемләнгән байлык

*(Латыш шагыйрәсе М. Залитедән)*

Көмешебез — хәзинәбез:
Урман,
елга,
күл.
Һәм әнкәмнең көмешләнгән
Чигә чәче ул.
Исемләнгән көмеш байлык
Менә шул безнең.
Кеше аннан чәчәк түгел,
Яфрак та өзми.
Без үлсәк тә исән калыр

Күл,
елга,
урман.
Мирас булып күчәр алар
Килер буынга.
Хәзинәбез арта барыр
Еллардан елга.
Көмеш нурын юмарт сибәр
Күл,
урман,
елга.

Бирәү йөрәк рәсемен ясаган да
«Яратам!» дип язган ак комга.
Ярга дулкын килеп бәргән иде,
Агып китте ул сүз сулкылдап.

Шул ук сүзне, җылы хискә төреп,
Шагыйрь язган ихлас күңелдән.
Еллар түгел, инде гасыр үткән,
Ә сүз тора һаман җемелдәп.

Табигатьнең иң зур могҗизасы
Бу дөньяда кеше!
Кеше үзе — галәм киңлегендә
Сәяхәтче төсле.
Һәр кешенең гомер сукмагында
Өмет йолдызы бар.

Үзе өчен олы бәхет санап,
Омтыла ул шуңар.
Бәхет күген аның нурлап тора
Хыял белән өмет,
Кеше өчен алар — очар кошның
Пар канаты кебек.

*1987. Латвия.*

# Госман Садә

## Хәтер җебе

I

Тарих сыры катлам-катлам...
Хаклык кайда?
Кайда ялган?
Үткәннәргә күз төшерсәк,
Анык түгел хаклык һаман.

Кемгә хаҗәт, кемгә кулай
Хакыйкатьне инкарь итү?
Аннан өзеп, моннан кисеп,
Хәтер-җепкә учак төртү?

Янган җепкә мөмкинме соң
Дисбе итеп мәрҗән тезү?
Бер яндымы хәтер җебе —
Берни түгел илдән бизү.

Кадер белмәс хәтерсезгә
Тарих ни дә, иманың ни,
Туып үскән нигез ни дә,
Кардәш-ыру, туганың ни.

Тарих сыры катлам-катлам...
Хаклык кайда?
Кайда ялган?
Эзләү кирәк бүгенгене
Шул тарихи катламнардан.

II

Тарих сыры катлам-катлам...
Булган заман...
Нил ярыннан
Безнең якка килгән кәрван,
Кәрван башы — Ибн Фазлан.

Ялга туктап болынлыкта,
Эңгер төшеп кич житкәндә,
Арган дөя, атларына
Әтил суын эчерткәндә,

Гарәп углы Ибн Фазлан
Киңлекләрне хозур кыла.
Елга буйлап каек килә,
Әтил иңләп җыр агыла.

Җырлый аны болгар кызы:
*«Әтил суы ака торур,*
*Кыя төби кака торур...*
*Ака торур... кака торур...»*

Фазлан кебек тыңлыйм бүген
Болгар җырын, чулпы чыңын.
Укыйм аның китабыннан
Ядкарьләрен шушы чорның.

Болгарларның мәркәзе дә
Мәккә кебек мәртәбәле.
Хөр мәмләкәт шәһрәтенең
Рим-румнарга житкән мәле.

Ерак юлдан арып килсәң,
Юын мәрмәр мунчаларда.
Монда — аклык, монда — сафлык!
Карап йөри ул шуларга.

Кичләр житсә, саз моңнары —
Көмеш ефәк чатырларда.
Сарайларда — көтепханә,
Дастан теле — шагыйрьләрдә.

Һәммәсенә Әтил шаһит.
...Идел һаман ага тора.
Ни хәл итик:
Яманлыкны
Кемдер һаман тага тора.

Яманлыклар, яманатлар
Идел өчен күбек кенә.
Нишләп була — хакыйкатьне
Күбек белән күмеп кенә?

---

Госман САДӘ *(1949) — шагыйрь. «Мәхәббәт елы», «Җиләкле тәрәзәләр» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Тарих сыры катлам-катлам...
Булган заман...
Нил ярыннан
Безнең якка килгән кәрван,
Кәрван башы — Ибн Фазлан.

Ни ишеткән, нәрсә күргән,
Арттырмыйча, киметмичә,
Барсын-барсын теркәп барган,
Беркемне дә кимсетмичә.

Шул китапны укыйм бүген:
Тарих сыры катлам-катлам...
Сәяхәткә алып чыкты
Сәяхәтче Ибн Фазлан.

Заман җиле гел җилгәрә:
Кайда чыны...
Кайда чүбе...
Без булганда
чуалмас та
Утта янмас Хәтер җебе!

## Лев Толстой кабере янында булганнан соң язылган шигырь

### I

Иске Заказ урманында
Без дә көзен йөрдек бергә.
Ява иде пыскак яңгыр,
Охшап тыныч, тын шигырьгә.

Ә ул
шушы тын урманда,
Тыныч, аулак бер урында
Гүрдә ята,
тыңлап безнең
Сөйләшкәнне ни турында.

Көзге урман тынлыгында
Безнең сүзләр гади иде.
Ләкин хисләр
Бу урында
Булу белән гали иде.

Телгә килде көзге урман:
— Шулай булган ул элек тә,
Хәзер дә ул һаман шулай:
Галилекләр — гадилектә!

### II

Көзге яңгыр,
Көзге урман
Гадилекнең җыры сыман...
Кайткан чакта чәй эчтек без
Синең кытай термосыңнан.

Хисләр иде ашкынулы...
Шул хисләрдән ашыгумы?—
Азак беллек:
Төшеп калган
Синең алтын бал кашыгы.

Кайгырма, дус!
Югалтулар
Килә безгә ачыш белән;
Шунысын да ачык беләм:
Җыр язмыйлар кашык белән.

⁂

Күк читендә, офыкта
Ажаганмы, яшенме?
...Килеп кердең яшендәй —
Сорамадым яшеңне.

Әллә инде син үзең
Сеңлесеме яшеннең?

Күрсәтмичә йөзеңне
Чәч араңа яшердең.

Карашыңда чагылды
Бер чаткысы яшеннең.
Шуннан бирле, яшермим,
Яшен күтеп яшим мин.

## Сынау

Ай нурыдай йоп-йомшак
Назлы сүзләрен тезеп,
Учыңа учын куеп,
Әйтсә өздереп-өзеп:

«Мәңгегә мин синеке!»—
Дип әгәр дә сөйгәнең,
Йөрәгеңнең хисләрен
Йолдызларга сөйләрсең.

Йолдызлар киң күңелле,
Көнләшмиләр беркемнән.
Балкыйлар, якты алып
Гашыйклар йөрәгеннән.

Моңарчы да мәхәббәт
Сынау узган мең тапкыр.
Сынатмасаң, сөюдә
Яңа бер йолдыз калкыр.

⁂

...Ә Чилида
Менә бүген
Яшьле күздәй яшькелт шәфәкъ.

Неруда да,
Туфан кебек,
Яшел белән язган фәкать.

Яшел төскә иңәдер ул
Шагыйрьгә хас рәхим-шәфкать.

...Ә Чилида
Үги ана яфрагыдай
Бүген шәфәкъ.

⁂

Куера һаман болытлар...
Берсеннән-берсе гайрәтле...
Күк йөзе нурсыз, караңгы.
Карашы явыз, нәфрәтле...

Яралды кинәт болытта
Йөз чатлы яшен тармагы.

Йа хода! Җәйге чилләдә
Ишеп лә ишеп кар яуды.

Болыт та шундый халәткә —
Нәфрәткә бик тиз күчала.
Гөнаһны, ахры, күп кылдык —
Табигать бездән үч ала.

# Акъегет

## Җир хуҗасы булсак...

*Чәчәк әле чәчәк кенә түгел,*
*Шул ук чәчәк — әле орлык та...*

Хуҗа булып, кеше урман кисә...
Җир селкенә агач ауганга:
сизми чишмәләре кибәчәген,
калачагын шәрә яланга.

Дөньялыкта берни эзсез узмый,
гөманыңа җиңел карама:
көньякларда пальма ава икән,
төньякларда корый карама.

Әйе, Кеше хуҗа шушы Җиргә,
Җир язмышы Адәм кулында...
Хуҗа була белгән онытмасын —
Табигатьнең ул бит Улы да.

## Ул урамның иске йорты

Ул яшәгән иске йорт та
инде исемдә генә.
Колакта тора сүзләре:
«Өметем синдә генә...»

Бар иде ул адашулар
сыерчык буранында.
Ай нурларын күргән чак
кар көрте урынында.

Тәмәке кабызган мәлләр
йолдыздан гына гелән!
Тәрәзәләр ачылуы
бер сызгыруым белән.

Менә килдем ул җирләргә,
басып торам тын гына.
Торна тавышыдай сузылып
калган икән моң гына.

Ул урамның иске йорты
инде исемдә генә.
Әле дә ишетелә күк:
«Өметем синдә генә,
өметем синдә генә...»

## Су буйлары

Су буйларын кичке якта
таптадым мин, таптадым.
Тирә-юньдә ул тирәкне
тапмадым шул, тапмадым.

Ул тирәкне күңелем шулай
исән дип саклый бугай.
Баш очымнан оча бер кош,
оясын тапмый бугай.

Ай толымын назлый дулкын,
җилкән сорап җил исә.
Ул тирәк юк, таллар үскән
тирәкнең тирәсенә.

Башларын суга игәннәр,
бу — моңсулык билгесе...
Җирсү күңел, дөрли учак,
били туган як хисе...

---

**АКЪЕГЕТ** (Рөстәм ФӘЙЗУЛЛИН) — *1951 елда туган, «Ак болыт шәүләсе» исемле шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

## Ана ялваруы

«Адашып булса да,
кире кайт...»
Тәрәздән ага төн буе
ут яктысы юлларга.

«Адашып булса да,
кире кайт...»
Ялвару булып ага ут,
кушылып яңгырларга.

«Адашып булса да,
кире кайт...» —
Тәрәздән карый ана.
Юк, еламый,
яңгыр-тамчы
кунган тик пыялага...

## Мәҗүси шом

Йөрәкләрне убылдырып,
ни сагайтты күңелне?
Ялгыш тамган тамчымы,
ярдан ишелгән коммы,
сүзсез моңмы?..

Баш өстеннән очкан
төнге кош-байгыш
аңласа аңлый
сихерле һәм серле
мәҗүси бу шомны...

❀

Күкне кара болыт каплап,
кинәт кояш тотылды...
Җиргә инде караңгылык,
җиһан тын алмый торды...

Күз алдында — күрмәделәр,
тик сукыр сиземләде:
ут бөҗәге, төн дип уйлап,
кабынды — җемелдәде...

## Язгы кәләш

Зәңгәр күктән өлге кисә
яшь кәләшкә карлыгач.
Гөлгә түк яшең, яшь кәләш,
кайгыдан еламагач.

Ак күбеккә баткан шомырт,
шау чәчәктә алмагач.
Күз яшьләрен чык дип белеп,
гөлдән эчәр сандугач.

## Тәңгәллек тойгысы

Дулкыннарның йөгерүе,
кошның канат кагуы,
җилләрнең исеп куюы,
болытларның агуы...

Мәңгелек гармония бу,
бу — мәңгелек тәңгәллек:
Иделемә күкләр сыйган,
сеңеп беткән зәңгәрлек...

## Күңел тулы

Күңел — тулы,
күк — тирән.
Яп-якты
бөтен тирәм.
Пәрәвезләр җебе буйлап
мин сине эзләп киләм.

## Август төне

...Атыла йолдыз —
сораумы бу?
Алма коела —
җавапмы?
Өлгергән алма җилләре
өтеп алды яңакны...

## Көзгедән дә кара үзеңә

Гел «акыллы гына»
булып яшәү
акылсызлык бәлки үзе дә?!—
Гел көзгегә генә түгел, иптәш,
көзгедән дә кара үзеңә.

*

Ха! Ха!— дип аваз салдык,
башны күкләргә чөеп.
Сызланып торды кайтаваз:
Ах!— диеп тик, ах!— диеп.

Гел сүз генә тыңлап яшәү —
әсирлекнең бер төре.
Тәмам кулга ияләшкәч,
эт булып улый бүре.

*

Күл төбендә йоклыйдыр төн,
йолдызлар шунда төште.
Таң атты да — төнбоеклар
каплап куйды су өстен.

## Кайчак

Бәхетләне гафу ит син,
белмәгәнгә сагыш тәмен;
Кайчак
чәчәк бәйләменнән
кадерлерәк була әрем...

# МАРИ ӘДӘБИЯТЫ КЛАССИГЫ

СЕРГЕЙ ЧАВАЙННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Быелгы елның 6 октябрендә мари әдәбиятына нигез салучы әдип — шагыйрь, прозаик, драматург Сергей Григорьевич Чавайнның туууына 100 ел тулды. Аның исемен хаклы рәвештә Россия халыклары гаиләсендәге иң гали исемнәр — Г. Тукай, М. Гафури, К. Хетагуров, К. Иванов һ. б. лар белән бер рәттән атыйлар.

С. Чавайн — үз халкының мәдәният тарихында аерым бер дәвер тудырган һәм аның рухи дөньясында кабатланмас эз калдырган олы шәхес, олы талант. 1905 елдан алып утызынчы еллар уртасына кадәр вакыт эчендә язучы тарафыннан халыкчан рухлы һәм югары сәнгатьчә эшләнештәге күп санлы шигырьләр, поэмалар, пьесалар, хикәяләр, повестьлар, роман язылган һәм бу мирас мари әдәбиятының иң кыйммәтле сәхифәләреннән исәпләнә.

Царевококшайск өязе Себеусад волосте Кече Карамас авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган С. Чавайн (чын фамилиясе — Григорьев) башта үз авылындагы мәктәптә, аннан Казандагы учительская семинариядә белем ала; ул анда яшерен революцион түгәрәктә катнаша, марксистик әдәбият белән таныша, 1905 елгы рус революциясенең күтәрелеш чорында беренче әсәрләрен язып бастыра. Бу чорның иң алдынгы идеяләре белән канатланган егет үз халкының иң якты омтылышларын җырлаучы әдип булып үсә. «Чоткар батыр», «Баһадирлар», «Бабаларым» кебек шигъри әсәрләрен язып, шагыйрь мари халкының үз тарихы барлыгын, башка халыклар кебек үк, аның да үз мәдәниятын, әдәбиятын тудырырга хаклы, көчле булуын раслады. Ул олуг мәгърифәтче дә иде. Царизмның милли үзаңны үтереп, халыкларны бер-берсенә каршы куйган бер чорында С. Чавайн бөек рус әдәбиятын өйрәнергә чакырды, Пушкин, Рылеев, Лермонтов, Некрасов шигырьләрен тәрҗемә итте.

Бөек Октябрь революциясеннән соң әдипнең бөтен тормышы һәм иҗат юлы яңа тормыш, совет чынбарлыгы тантанасы белән аерылгысыз бәйләнгән; әйтик, «Революция» кебек шигырендә ул халкының яңа җәмгыять өчен көрәшкә килү юлларын ачык күзаллап язды.

С. Чавайн — мари милли театрына нигез салучыларның да берсе: аның «Умарталык» исемле музыкаль пьесасы, халык иҗатына нигезләнгән «Тере су», «Акча уты» һ. б. драма әсәрләре бүген дә сәхнәдән төшми уйнала. Шулай ук «Акпатыр» исемле героик драмасын, халык язмышын сурәтләгән зур полотноны «Элнет» романын С. Чавайн иҗатының иң калку нокталары дип билгеләп була.

С. Чавайнның гомер юлы 1937 елда фаҗигале рәвештә өзелә: ул — шәхес культы корбаннарының берсе.

Әсәрләре илебез һәм дөнья халыклары телләренә тәрҗемә ителгән (Мәсәлән, «Роща» исемле шигыре кырыктан артык телдә яңгырый.).

Укучыларыбызга бу санда мари әдәбияты классигы иҗатыннан яңа тәрҗемәләр тәкъдим итәбез.

## Сергей Чавайн

### Мәһабәт имән...

Кайчандыр безнең басуда
Мәһабәт бер имән үскән,
Колачлы ябалдашлары
Як-якка таралып төшкән.

...Яшәгән илдә бер кавем —
Илаһи буй, илаһи көч...
Урман аша егетләре
Юлга чыгып киткән, имеш,

Һәм шуларның иң кечесе
Атлап чыккан зур имәнне
Күккә башы тигән килеш,
Чикмәненең сул итәге
Аерылып калган, имеш...

Бабайлар сөйләгән хикмәт
Әкият булып калган бары,
Күр, имәннең эзе дә юк,
Яшен кыеп киткән аны.

Пәһлеван кавем турында
Сөйләнелә сирәк кенә...
...Бары давыл сызгән чакта,
Бәргәләнеп, йөрәк кенә
Шул имәнне хәтерләргә

Кушкан сыман дулап ала...
...Яшь егетнең зур адымы
Безгә үрнәк булып кала.

*1908.*

## Изге хисләр

И туган җир, и матур җир,
Онытылып тормый икән —
Сине сөю хисләреннән
Аерылып булмый икән!

Язмышым алып чөйсә дә
Әллә кая — еракка...
Иң якты сагышларым гел
Кайтара синең якка.

Сагыну-саргаюларым
Агыла күкрәгемнән.
Яңадан сиңа әйләнеп
Кайтырмын әле, бәләм!

Кытыклар аяк табанын
Хәтфә кебек чирәмең,
Яшел бөдрәләрең белән
Каршылар киңлекләрең.

Шунда мин сак кына атлап
Тыңлармын болын шавын.

Чәчәкләр беләң күмелеп
Иркәләнер кочагым.

Былбыллар моңы илена
Алып барыр сукмагым:
Сизми калып сабый чакның
Басуына чыкканын.

Һәм мин анда төнгә кадәр —
Бала чактагы сыман —
Иңемнән уракны алып,
Ызанга чаклы урам;

Көлтәләр ташыйм эвенгә,
Җан уйный әллә нигә:
Башаклардан сикереп төшә
Орлыклар берәм-берәм...

...И туган җир, и матур җир,
Китсәм дә бик еракка,
Сагыну-сагышларым белән
Кайтырмын синең хакка.

*1909.*

## Оч, акылым...

Еллары кара булса да,
Төннәрне ярып, бары
Үз тиңнәре киңлегенә
Оча акылым шоңкары.
Оча... Ә мин жырым сузам:
«Табигать-әнкәм миңа
Биргән канатлар,
Очсын дип
Беркетләр тарафына».
Йөрәк курыкмый, дөньясы
Булса да гел дөм-кара:
Ут янып торган күзләрем
Төннәрен ярып бара.
Төн вә көндез мин янамын,
Таң калып тора гавәм:

Мин жырлыйм. Жырның асылы
Бер генә... Үзгәрмәгән.
Акылның көчен беләм мин,
Шуңа да киң колачым:
Нәрсәләр булганын белгән
Белә нәрсә буласын.
Яктырак янмак булам мин,
Төн кара булган саен —
Халкыңа яктылык илтү
Шулай мөмкин, мөгаен.
...Күңел тели күк гөмбәзе
Киңлекләрен тик бары:
Үз тиңнәрең янына син
Оч, Акылым Шоңкары!

*1910.*

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ тәрҗемәләре.

## Рафаэль Мостафин

# КАБАН КҮЛЕ СЕРЛӘРЕ

**ТАРИХИ-ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ**

**9**

*«Казан каласындагы иң шәп су — төбендә чишмәләр тибеп торган Кабан күлләрендә. Ул тонычрак, әлбәттә, әмма ком белән күмер аша үздырсаң, бу суга яңадан табигый сафлыгы кайтачак».*

Р. Лангель, дәвалау управасы инспекторы, 1807 ел.

XIX гасырның җитмешенче елларынача, Казанда сууткәргеч төзелгәнгә кадәр, Кабан шәһәр өчен бердәнбер су чыганагы булып торган. Идел җиде километр читтән үтә. Өстәвенә, суын яратып та бетермиләр. Казан суын яр буенда яшәгәннәр дә эчәргә тотмый.

Шәһәрнең Кабан ягына таба үсә баруының бер сере әнә шул. Сан алу кенәгәләреннән күренгәнчә, XVI гасыр уртасында шәһәрнең төп капкасы (хәзерге Куйбышев мәйданы тирәсе) яныннан ук яшелчә бакчалары башланып киткән була. Казан баштарак әкрен үсә, болыннар, калкулыклар, әрәмәләрне ашыкмыйча гына йота. 1708 елда, гаять зур губерна үзәгенә әйләнгәч тә, анда нибары унбиш мең кеше генә яшәгән әле.

XVI гасыр уртасында барлыкка килгән Татар бистәсе белән бераз соңрак салына башлаган Яңа бистә чагыштырмача тизрәк үсәләр. XIX гасыр башланганда Якын Кабанның көньяк яры Пләтән авылынача шәһәр кочагына керә. Төньяк ярда «Суконный» һәм «Кирпичный» дигән рус бистәләре үсеп чыга. Бу бистәләр белән Архангельский авылы (хәзерге Архангельский зиратыннан ерак түгел) арасына чөй булып аерым мәхәллә хасил иткән берничә татар урамы килеп керә...

Аз-азлап Казанның көнчыгыш белән көнбатыш, Азия белән Европа оеткылары кушылудан килеп чыккан үзенә бер төрле кыяфәте төсмерләнә башлый. Күккә ашып торган кызгылт-көрән Сөембикә манарасы, алтын гөмбәзле чиркәүләр, нечкә-нәфис мәчет манаралары, тау башындагы ак, көяз шәһәр үзәге, уйсулыктагы агач йортлы бистәләр... Өч яктан су белән уратып алынган, эчендә күлләр көзге кебек ялтырап яткан Казан корабта йөзеп килгән сәяхәтчегә әкияти кала булып күренгән. Әмма шул ук су зур каза да — пычраклык-юешлек һәм төрле-төрле чирләр чыганагы да булган.

Ахыры. Башы 9 нчы санда.

XIX гасыр башында шәһәрнең югары, иң мәһабәт өлешендәге урамнарына букән түшәлә, алар буйлап тавыш-тынсыз гына пролеткалар җилдерә. Берничә урамга йомры таш җәяләр, алар буйлап дөбер-шатыр крестьян арбалары үтә, мичкә белән Кабан суы таратып йөргән йөк атларының дагалары чакы-чокы килә.

Урамнарның күпчелеге исә мәтегә батып ята бирә. Пычрак язын көзен тәгәрмәч букәненә җитә, тәгәрмәч эзе янындагы күлдәвекләр, юл чите канавындагы су җәен дә кипми. Тирес, чүп һәм нәҗес, язгы ташу алып китәр дигән өмет белән, башлыча Кабан ярларына түгелә. Бу исә йогышлы авырулар таралу өчен менә дигән шартлар тудыра.

XVII гасыр уртасында Казанга чакырылмаган дәһшәтле кунак — чума килә. Шәһәр халкының яртылабын алып китә бугай ул. Корбаннарның төгәл саны мәгълүм түгел. Безгә бары риваятьләр генә килеп җитте: көне-төне дөрләгән учаклар (чирнең таралуыннан шулар ярдәмендә котылып калмакчы булалар), шешенгән-күбенгән, кара көйгән мәетләр, кара киемле монахлар озатып барган исәпсез җеназалар... Ваба, тиф эпидемияләре дә онытмый. Хәерчелек һәм начар һава юлдашы булган туберкулез Октябрь революциясенә кадәр тынгы бирми. Үлүчеләр, түбән урнашкан кварталларда, хәтта туучылардан күбрәк тә була. Унтугызынчы гасырның башыннан азагынача Казан халкы бары читтән күчеп килүчеләр исәбенә генә үсә диярлек. XIX гасыр азагында статистиклардан берәү исәпләп чыгарган: үлү темпы шул килеш сакланса, 1960 елга Казанда... бер кеше дә калмаячак...

Хәер, бу яктан караганда, Казан башка провинциаль шәһәрләрдән әллә ни аерылып тормаган, зурлыгы һәм төзеклеге буенча күбесеннән арурак та булган әле. Әби-патша, мәсәлән, Казанга килеп киткәч, болай ди: «Һичшиксез, Рәсәйнең, Мәскәүдән кала, беренче шәһәре бу». Екатерина II тарафыннан Себергә сөрелгән, 1797 елның маенда Казан аша үткән Радищев исә көндәлегенә болай дип яза: «Шәһәр буйлап соклану хәлендә диярлек йөрдем». Әдип ул чагында әле мул сулы булган Болакны, Болактагы пристаньны, әрле-бирле йөзгән төрле-төрле корабларны тасвирлый. Бишбалтада төзелгән фрегатны суга төшерү турында яза.

Русның икенче бер бөек улы, Пермьгә сөрелгән А. И. Герцен болай дип язып калдырган: «Казан уңайлы урнашмаган, татарча исемен аклап, чыннан да казанда утыра; юеш-дымлы урыннары күп, эчәр суы аз. Бина-корылмалары болай ару гына, үзәк урамнар матур; алар шау-гөр килеп тора, төркем-төркем булып халык җыела, шаулашалар; таза-матур гәүдәле бурлаклар очрап тора; татарлар күп, яньчек борынлы, кысыграк күзле, хәйләкәр чырайлылар, читек, түбәтәй, халат саталар, кигәннәре дә — халат... Крайның үзәк шәһәре, сәүдә шәһәре бу, иң мөһиме, Европа һәм Азия рухын берләштергән үзенчәлекле шәһәр».

Болгар заманнарыннан ук Казанда күнчелек нык алга китә. Биредә эшләнгән йомшак күн (юфть) һәм сахтиян күнне Рәсәйдә, Урта Азиядә, Шәрык һәм Көнбатыш илләрендә кулдан йолкып алгандай алалар. Казан читекләрен рус боярлары яратып кия. Күнчеләр элек-электән Кабанның көньяк яр буенда, хәзерге Сафьян урамы тирәсендә тупланган булалар.

Казанга 1436-1452 еллар арасында килеп киткән Венеция сәяхәтчесе Йосифат Барбаро болай дип яза: «Бу — сәүдәгәрләр каласы, аннан Мәскәүгә, Польшага, Пруссиягә, Фландриягә бихисап мех китә».

Чыннан да, Казан Россиянең экономик, социаль һәм культура тормышында зур роль уйнаган санаулы шәһәрләрнең берсе була. Казанда Россиядәге беренче мәдрәсәләр, беренче провинциаль гимназия (1758 ел), өченче (Мәскәү һәм Тартуныкыннан соң) университет ачылу (1804), беренче провинциаль газета чыга башлау («Казанские известия», 1811 ел), беренчеләрдән булып провинциаль театр эшли башлау әнә шул турыда сөйли. Документлар, хатирәләр шәһәрдә культура тормышы кайнап торганлыгын, арада татар зыялылары да булган белем ияләренең күплеген күрсәтә.

Шәһәрнең экономикасы үсүгә, шактый дәрәҗәдә, табигый шартлар да йогынты ясый. Йомшак һәм чиста Кабан суы күп төрле һөнәрләр өчен алыштыргысыз сулык булып чыга. Ул постау җитештерүдә, кирпеч сугуда, сабын кайнатуда, шәм ясауда да кулланыла. XVIII гасырның беренче яртысында Кабан яры буенда 25 сабын кайнату, 40 күн остаханәсе урнашкан була. Аларның кайберләрендә дистәләрчә кеше эшли. Күлгә төрле яктан бу һөнәрдә кулланылган агулы сулар агып төшә...

Шәһәр үскән саен, Казандагы эчке сулыклар берәм-берәм юкка чыга бара: Гүзәй күле булган җирдә балык базары ачыла (хәзер Куйбышев мәйданы), Тихвин күле урынында Печән базары гөрли. 1820 елда шәһәр Думасы Черек күл белән Мунча күлен чистартырга шактый зур акча билгели. Күлләрне чүп-чардан арындыралар, ярларын турайтып кәс тезәләр, агач утырталар. Әмма күлләр барыбер саега, чөнки туендырып торучы чишмәләр, инешләр калмаган. Күпмедер вакыттан күлләрне күмәргә мәҗбүр булалар.

Тирән сулы Кабанга әлегә мондый язмыш янамый янавын, ләкин ул да XIX гасыр башларында саф сулы булмый инде. Шул елларда Мәскәү янындагы күлләрне тикшерүдән, кимендә, ярты гасыр алдан Кабанны фәнни яктан тикшерүләр башлана. Бу хәл үзе генә дә аның Казан өчен никадәр мөһим булуын күрсәтә.

Кабан турындагы беренче фәнни хезмәт — Р. Лангельның «Казан губернасына һәм губерна шәһәре Казанга кыска медик-физик һәм топографик күзәтү»е. Бу хезмәт 1807 елда Санкт-Петербургта «Медицина журналы»нда басылып чыга. Соңыннан ул ике мәртәбә (1817 һәм 1824 елларда) Казанда да басыла. Автор Лиль (яки Лилий) исемле аптекарьның безгә килеп җитмәгән хезмәтенә дә таянуын әйтә. Бу аптекарь XVIII гасыр азакларында ук күлләрнең зурлыгын, тирәнлеген үлчи, аларның режимын өйрәнә башлый.

Р. Лангель Кабан күлләренең физик-географик тасвирламасына аныклык кертә, шәһәрне су белән тәэмин итүдә аларның ролен күрсәтә. Гәрчә галим Якын Кабан суының сыйфатын, тулаем алганда, әйбәт дип бәяләсә дә, аның хезмәтендә инде яр буйлары пычратылуга, бернинди контроль-фәлән булмауга борчылу да сизелә. Авторны бигрәк тә «өч аршын ләм утырган» Болакның хәле борчый. Болакны тирәнәйтергә, ләм күмгән чишмәләрне арчырга, агымга юл ачарга кирәк, дип яза ул.

Статистик һәм тарихчы И. Ф. Яковкинның «Казанны Идел һәм Кабан суы белән тәэмин итү, аларның сыйфаты һәм Кабанны мул һәм агым сулы итү турында искәрмәләр, күзәтүләр һәм фикерләр» дигән зур мәкаләсендә («Заволжский муравей», 1833 ел, 16 сан), күлнең һаман пычрана баруы борчуга салса да, чагыштырма анализ ясагач, автор болай дип таба: «Идел суы Кабан суына караганда начаррак — катырак та, сәламәтлеккә тәэсире ягыннан да шиклерәк».

Дәвалау управасы директоры Тиле исә бу караш белән килешми. «Казанның сәламәтлек өчен кулай булмаган шәһәрләр исәбенә керү сәбәпләре турында» язмасында («Заволжский муравей», шул ук ел 19 — 20 саннар) ул төп өч факторны атый: 1. Шәһәрнең түбән урнашуы. 2. Пычраклык. 3. Суның яру булмавы. Инспектор Кабан күленнән (якыннан, билгеле) черек исе килүен, җәйге айларда яшелләнүен, суда балык аз булып та суалчан тулып ятуын, суның тәмлелеге дә чамалы гына булуын яза. «Суга килеп эләккән пычрак беркая да китмәгәнгә һәм дә күл шәһәрнең төп өлешеннән түбәнрәк урнашканга... аның суы пычрансын өчен бөтен шартлар да бар»,— дип, бик дөрес яза ул. Күлнең төбен кара ләм каплаганлыгын ачыклый. Әмма бу — шәһәр эчендә генә шулай. Шәһәр читендә исә төптә ком һәм үзле балчык була. Инспектор шундый нәтиҗә ясый: Кабан суы Идел суыннан начар, шуңа күрә, һичшиксез, Идел суын эчү хәерлерәк.

Бернича дистә елдан бәхәсне бөек химик профессор А. М. Бутлеров

хәл итә. Гаять оста үткәрелгән фәнни анализлардан соң ул Кабан суының табигый сыйфатлары белән Идел суыннан яхшырак, йомшаграк булуын әйтә. Әмма ул органик калдыклар белән шулкадәр пычратылган ки, аның сәламәтлеккә зыян китерүе бик мөмкин. Галим мондый тәҗрибә ясый: тирес суын 31 өлеш дистилляцияләнгән саф су белән катнаштыра, әнә шул сыеклык үзенең төсе, исе һәм органик матдәләр күләме буенча Кабан суына бәрабәр була.

Урта Кабанның суы исә төсе, исе, гомумән,— бөтен күрсәткечләр буенча да Идел суыннан әйбәтрәк була. Бутлеров, тиз арада суүткәргеч төзергә һәм суны Урта Кабаннан алырга кирәк, ди.

Болакның хәле тагын да авыр була. Җирле журналистлар аның турында: «Шәһәрне төзекләндерүнең иң нечкә җире», диләр. Шәһәр монда чүп-чарын түгә, пычрагын агыза... Ярына элеккечә мунчалар сырышкан була. Арада сәүдәгәр Меркулов, борынгы нәселдән булган Жуковский һәм Баратынскийларныкы кебек ике катлы зур таш мунчалар да бар.

Болак ул чагында да әле су юлы буларак әһәмиятен җуеп өлгермәгән була. Бу шуннан да күренә: XVII—XVIII гасырларда Болакта але ачылмалы күперләр тора. Аларның берсе — төзеткән сәүдәгәр исеме белән «Жарковский күпере» дип йөртелгәне — XIX гасыр башларына кадәр сакланып, бары 1815 елгы янгында гына харап була. Төнлә күперләрне ачып, Иделдән, Казан суыннан кергән судноларны яр буендагы складлар янына үткәрәләр. Язгы ташу вакытында кораблар Кабанның иң ерак почмакларына кадәр барып җитә. Коры елларда исә Болак тирәнлеге нибары ярты аршын (30 сантиметр) булган сасы ермакка әйләнеп кала. Күп гасырлар буена җыелып килгән пычракны язгы ташулар гына һичничек юып бетерә алмый.

Болакны чистарту, төзекләндерү проектлары шактый. Беренчеләрдән берсен 1807 елда инженер Шевякин эшләгән. Шевякин төпне чистартырга, яр кыегын ныгытырга, Болакны агымсулы итәргә тели. Шәһәр думасы проектны яхшы дип таба, әмма аны гамәлгә ашырырга акча җитми.

XIX гасырның егерменче елларында танылган архитектор П. Г. Пятницкийга (университет бинлары комплексы авторларыннан берсе) Болакны чистартуның яңа проектын төзү йөкләнә. Проект берничә мәртәбә ачыклана һәм (арзанайту максатында) үзгәртелә. Ниһаять, 1829-1830 елларда реконструкция үткәрелә. Болакны нык кына чистарталар, тирәнәйтә төшәләр, яр кыегына кәс түшиләр, күперләр салалар. Шул кыяфәтендә Болак безнең көннәргәчә килеп җитте.

Шәһәребезнең бөтен үткәне дә, бүгенгесе дә Кабанга, Болакка бәйле. Алар турында җырлар, шигырьләр, поэмалар язылган. Лондонны — Темзадан, Парижны — Сенадан, Мәскәүне Мәскәү елгасыннан башка күз алдына китереп булмаган кебек, Кабан белән Болактан башка Казан да — Казан түгел.

Болак тирәсендәге иң шау-шулы, ыгы-зыгылы урын — Печән базары. Монда исәпсез-хисапсыз кибетләр, амбарлар сузылып киткән була. Кем генә юк монда. Һөнәрчеләр, чуар шәлле сәүдәгәр хатыннары, крестьяннар, тар, кара бишмәтле шәкертләр, ул чалма-чапанлы руханилар, ялантәпиле бала-чагалар... Аршын һәм ачкыч бәйләме тоткан приказчиклар әрле-бирле йөренә. Кызыл мал, кырык тартма товары, сабын, чәй, аш тәмләткечләре белән кызу сәүдә бара. Шунда ук чәчтарашлар пәке кайрый, сакал-мыек төзәтә. Җәмигъ мәчетен, әнә, гарип-гораба, теләнчеләр сырып алган.

Болак буенда ел саен беренче майдан алып беренче июньгә кадәр язгы ярминкә үткәрелгән. Татарлар аны, Ташаяк ярминкәсе дип, руслар Биржа, дип атап йөрткәннәр. Балачагы, яшьлеге Казанда үткән С. Т. Аксаков (Казаннан 1806 елда китә) бу ярминкәләрнең матур тасвирламасын калдырган. Әдип язуынча, «җәйләрен сай, тонык вә сасы була торган» Болак язын үзгәрә. Идел суы ыргылып кереп, коргаксып

беткән ярларны мөлдерәмә тутыра. Форсаттан файдаланып, Кабан аша Иделдән Болакка көтүе-көтүе белән төрле вак товар төягән зур һәм бәләкәй көймәләр йөзеп керә, инешнең өстен тәмам каплап ала.

«Бердәнбер ярминкәләре була торган ошбу вакытны Казан халкы һәрвакыт түземсезләнеп көтеп алыр иде. «Көймәләр килде»,— дигән хәбәр минут эчендә бөтен шәһәрне аякка бастырыр иде. Болакның һәр ике ягында шау-шу, күңел ачулар башланып китә... Яр буйларын халык сырып ала. Төрледән-төрле товар әфлисун-лимон арасында фарфор, пыяла, эче-тышы яки эче генә яшел лакка буялган, кызыл балчыктан ясалган савыт-саба бихисап булыр иде. Савыт-саба берлә кызыл балчыктан яисә пыяладан ясалган үрдәк-каз, сыбызгы, су чәчрәткеч кеби уенчыклар алып киләләр иде. Ул көннәрдә сатып алынган өр-яңа уенчыклар тоткан өер-өер малайлар, кызыйлар нииндидер куанычлы вә кыргый бер дәрт илә бөтен Казанны бетереп чабышып-сикерешеп йөрерләр, сызгырырлар, чинашырлар, чәчрәткечләрдән төрле тарафка су аттырырлар, бер-берләрен һәм хәтта өлкәннәрне дә коендырырлар иде. Бу хәлләр бер ай буена шулай дәвам итәр иде. Халыкны, татар вә русны, кала вә сала киемнәре кушылмасын тамаша кылырга Казан аристократиясе дә килер иде. Мондый чын бер халык сәүдәсе вә уен-сафасы бик тә кызыклы вә күрекле булыр иде».

Ташаяк ярминкәсендә кайбер елларда миллион сумлык товар сатылган — заманы өчен бик тә зур сума инде бу. Монда таш складлар, исәпсез-хисапсыз агач кибетләр тезелеп киткән була. Аларның кайберләре безнең гасырның илленче елларына кадәр килеп җитеп, циркның яңа бинасын төзегәндә генә сүтелде. Сүз уңаеннан искәрик — безнең цирк нәкъ менә Ташаяк ярминкәсе вакытында да цирк балаганнары корыла торган, шамакайлар, аю биетүчеләр, курчак уйнатучылар тамаша күрсәткән урынга салынды.

Кабан белән Болак үзенә күрә шәһәрнең рус һәм татар өлешләрен аерып торган чик тә булган. Татарлар бары Октябрь революциясеннән соң гына Казанның биегрәк һәм, димәк, корырак та ягында нигез кору хокукы алганнар. Кремльгә керү юлында исә: «Татарларга һәм этләргә керү тыела» дигән язу торган. Кышларын рус һәм татарлар ике гаскәр кебек Кабан бозында йөзгә-йөз килә торган булган. Бу йодрык сугышларын ни дип бәялик? Милли дошманлык утын өреп дөрләтүче кыргый һәм рәхимсез яман гадәт дипме? Әллә үзенә күрә бер күңел ачу, көчкуәтеңне, егетлегеңне күрсәтергә мөмкинлек биргән хәтәр, әмма кызыклы күмәк уен дипме? Хаклык тегесендә дә, монысында да бардыр.

XIX гасыр урталарында, капитализмның бик тиз үсүе сәбәпле, кешенең табигатькә тәэсире дә көчәя. Шул вакыттан күлнең бик тиз пычрана һәм үлә бару чоры башлана.

Кабанны пычратуга иң зур «өлеш» кертүче, мөгаен, агалы-энеле Крестовниковларның Якын Кабан буена салынган һәм тора-бара үзенә күрә бер шәһәрчек хасил иткән сабын заводыдыр. Гасыр азагына ул, ел саен 150 мең пот шәм, 205 мең пот сабын ясап, алар белән ярты Рәсәйне тәэмин итеп тора. Шул заманда чыккан шәһәр белешмәлекләрендә Казан сабын патшалыгы дип атала. Крестовниковлар гәрчә агулы суны Кабанга түкмичә, агач улактан шәһәр читендәге сазлыкларга агызсалар да, заводның зарарлы тәэсире барыбер сизелми калмый. Һава бассейны пычрана. Яңгыр суы, кар суы завод ишек алдында җыелган сабын күбеген, май һәм пычракны Кабанга да юып төшерә тора.

XIX гасыр азагында Казанда инде, күп санлы остаханәләрдән тыш 92 завод һәм фабрика була. Аларда 5900 кеше эшли, ун миллион сумлык продукция җитештерелә. Шәһәр дә нык кына үсә: 25 квадрат километр мәйданда инде 140 мең кеше яши. Мең таш бина, тугыз мең агач бина була. Гади йортларга өстән унөч мәчет, кырык чиркәү манарасы бага. Халык биш йөздән артык коедан су ала. Тик күбесенең суы тәмсез, каты.

Хәзер ышануы да кыен: хәтта XX гасыр башларында да нәжеснең нибары уннан бер өлеше генә шәһәрдән читкә чыгарыла, калганы, жир асты суларын агулап, туфракка сеңә, яисә... Кабан буена яки күлнең үзенә үк түгелә. Кыш буена махсус йөкләр Кабан бозына «сасы алтын» ташый. Язгы ташуга өмет баглана. Ләкин ташу ел да күл суын яңартырлык дәрәжәдә көчле булмый.

1875 елда Казанда суүткәргеч төзелә. Моның алдыннан озак кына бәхәс бара: суны кайдан алырга? Башта Урта Кабанда су алу пункты төзү күздә тотыла. Тик, экономик яктан зур өстенлекләре булуга карамастан, бу вариант кире кагыла: күлнең пычрануы бар! Якын Кабанның язмышы шәһәр башлыклары өчен гыйбрәтле бер сабак була. Урта Кабан тирәләренең җәен меңнәрчә кешеләрнең ял итү урынына әйләнүе дә искә алына.

Суүткәргеч шәһәрдән унсигез чакрымдагы Пановка чишмәсеннән су кудыра башлый. (Бу линия әле дә эшли, ул Казанның югары өлешен тәэмин итеп тора). Су, әлбәттә, байгуралар, хәлле граждавнарның өйләренә генә керә. Ярлы-ябагай һәм Болак арьягы халкы Кабан суын эчәргә мәжбүр. Шул елларда тиф, дизентерия, ашказаны-эчәк авырулары белән чирләүчеләр күбәя. Бу хәл җәмәгатьчелекнең игътибарын янадан күлгә юнәлдерә.

XIX гасырның сиксәненче елларында врач Купидонов Якын һәм Урта Кабан суына бактериологик анализ үткәрә. Нәтиҗәләрен 1890 елда аерым китап итеп бастырып та чыгара. Китапның төп сөземтәсе шул: Якын Кабанның суы Пановка чишмәсеннән 150 мәртәбә пычраграк, ә Урта Кабан суы чишмә суыннан да чистарак икән. Купидонов төп пычрату чыганакларын да күрсәтә: яр буендагы чүплекләр-тиресләкләр, кер чайкау һәм коену урыннары, фабрикаларның агынтылары, бәдрәф һәм юынтык чокырлары.

Кабан суын бераз соңрак тикшергән профессор Глинский да асылда шундый ук нәтиҗәләргә килә. Әмма бу вакытта эпидемия куркынычы беркадәр кими төшеп, җәмәгатьчелекнең бу мәсьәләләргә игътибары кимегән була. Язгы ташулар да үзенең аруландыру миссиясен уңышлы үтәп килә. «Язгы ташкыннар да булмаса,— дип яза 1893 елда профессор А. Я. Щербаков,— Кабан суы гаять дәрәҗәдә пычраныр, күл — күл булмас, чын мәгънәсендә арт юлга әйләнер иде».

Күлне өйрәнүгә татар галимнәре, язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләре дә өлеш кертә. Хосусан, тарихчы һәм дин белгече Шиһабетдин Мәрҗани хезмәтләрендә күлнең тарихы турында кызыклы гына мәгълүматлар бар. Каюм Насыйри беренче булып Кабан турындагы легендаларны җыя һәм бастырып чыгара. Алдынгы карашлы күп кенә татар зыялылары Кабанны, Болакны һәм алар тирәсендәге кварталларны төзекләндерү өчен җан аталар. Менә бер мисал. 1907 елның 15 ноябрендә Яңа клубта татарлар өчен лекция була. Укытучы И. В. Терегулов җыелганнарга йогышлы авыруларның килеп чыгу сәбәпләрен аңлата, шәһәрдә суның чисталыгын саклау өчен зарур чаралар турында сөйли. («Казанский вечер» газетасы, 1907 ел, 16 ноябрь).

Безгә килеп җиткән фотографияләр һәм рәссамнарның әсәрләреннән Якын Кабанның яр буйлары XIX гасырда никадәр үзгәргәнлеген чамаларга була. Укытучылар семинариясенең ак кирпечтән салынган бинасы, Дүрт евангелист чиркәве, Мәрҗани, Юнысов мәчетләре һәм бигрәк тә Болгар дәүләтенең ислам динен кабул итүенә мең ел тулу уңае белән, инде тәмам тузган агач мәчет урынында салынган Иске таш мәчет (Һади Такташ урамында, хәзер анда балалар бакчасы) күлгә ямь өстиләр.

1868 елда Н. Свешников атлы кеше «Якын һәм Ерак (ягъни Урта) Кабан күлләре буйлап кеше ташу пароходчылыгы» оештыра. Шул вакыттан алып күлләр буйлап регуляр пароход хәрәкәте башлана. Якын Кабанның бер ярыннан икенчесенә паром да йөри.

Пристань, ягъни касса будкасы булган такта причал. Болак башланган урында, трамвай тукталышы янында корыла. Монда көпчәкле пароходлар — «Нептун», «Казанец», «Джигит», «Ласточка» һ. б. туктый. Пароходлар арасында хәтта «Бобчинский» белән «Добчинский» да була — аларның хуҗасы, сыра заводы тотучы Оскар Петцольд юморны яраткан, күрәсең.

Бу нәни пароходлар пассажирларны Казан юнкерлар училищесының Урта Кабандагы җәйге лагерьларына, Серебрянников, Андреевский кебек Казан байларының дачаларына ташый. Җитмешенче еллар азагында Урта Кабанда кымыз шифаханәсе эшли башлый. 1885 елда монда үтә зур тантана белән «Аркадия» бакчасын ачалар. Ямьле табигать кочагында, бәләкәйрәк урман эчендә зур заллы җәйге театр, ресторан, күңел ачу урыннары, кегельбан, бильярд бүлмәләре, «иң яңа тасмалары булган синематограф» һ. б. төзелә.

Ул чор газеталары болай яза: «Аллеяларда кеше мыж килә... Берьюлы берничә оркестр уйный... Бер генә буш өстәл, бер генә буш урындык та юк...» «Аркадия»дә татарның күп кенә культура эһелләре дә ял иткән. Монда Тукай хозурланып йөргән, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал озак-озак яшәп алган. Болар бар да «Теплоконтроль» берләшмәсенең гүләп-дуылдап торган иләмсез зур корпуслары, складлары урынында булганлыгын хәзер күз алдына китерүе дә кыен!

Гасыр азагында Болак тагын ләмгә бата, йогышлы чирләр чыганагына әйләнә. Үзенең атаклы белешмәлегендә («Спутник по Казани») профессор Н. П. Загоскин: «Болактан инде барына да күнеккән Казан кешесе дә чыдый алмаслык авыр ис бәреп тора»,— дип язган. Ул елларда Кабанны һәм Болакны савыктыруны максат иткән күп төрле «проектлар» эшләнә. Әйтик, махсус канал казып, мул сулы Мишәне Кабанга бору, яисә агым хасил итәр өчен, Идел белән Кабанны ике яклап тоташтыру күздә тотыла. Бу проектлардан иң шиклесе, әмма иң арзанлысы сайлап алына. Аның авторы Болак төбендә артезиан скважинасы бораууларга тәкъдим итә. Шуннан соң, янәсе, су үзе Болакка бәреп торачак һәм аны сафландырачак. Бораулыйлар. 44 метр тирәнлектә, чыннан да, чиста төче су табыла. Ләкин нигәдер бәреп чыгарга теләми ул — Болак төбенә менеп җитәргә бер сажин кала туктый.

## 10

«Беренче күкрәү» 1926-27 елларның кышына туры килә. Якын Кабанда балыкның күпләп үлүен җирле газеталар әнә шулай дип атыйлар. Кыен вакытлар булуга да карамастан, республика Совнаркомы Казан университеты профессоры В. В. Миславский җитәкчелегендә махсус комиссия төзи. Комиссия сүзен кистереп әйтә: «Кабан күле нык пычранган». Су һәм ләм анализлары шул турыда сөйли. Якын Кабанда туберкулез бациллалары, Урта Кабандагы белән чагыштырганда, утыз мәртәбә күбрәк булып чыга.

Комиссия фикеренчә, бу хәл күп төрле сәбәпләрдән туган. Беренчедән, Казан-Свердловск тимер юлын салганда Якын һәм Урта Кабаннарны тоташтырган элекке бугаз күмдерелә. Таш торба астыннан үтә торган яңа бугаз таррак та, саерак та була, күлләрнең иркен аралашуын тәэмин итә алмый. Икенчедән, Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышы, аннан соңгы авыр елларда шәһәр хуҗалыгы тәмам ташландык хәлгә килә. Чүп, тирес чыгару белән бөтенләй диярлек шөгыльләнмиләр, күл буендагы урамнарда шакшы су чокырлары чистартылмый. Һәм, ниһаять халык хуҗалыгы аякка басу белән, күлгә торган саен көчлерәк булып промышленность юынтыклары ага башлый.

Комиссия түбәндәгеләрне тәкъдим итә: чистартылмаган суларны күлгә агызуны кичекмәстән туктатырга, чүплекләрне күл тирәсеннән кү-

черергә, бозга нәҗес түгүне тыярга. Мондый саклык чараларының гына житмәвен аңлап, комиссия аеруча пычранган җирләрен генә булса да Кабан белән Болакны чистарту мәсьәләсен дә күтәрә.

Татарстан хөкүмәте беркадәр чаралар күрә. Нәҗесне сугарулы басуларга чыгаруны оештыра, күл буйларына чүп һәм тирес түгүне тыя, күлнең хәлен тикшереп торыр өчен санитар постлар булдыра. Әмма шәһәр промышленносте һаман үсә бара бит. Яңа йортлар салына, халык саны арта. Канализация челтәре исә бу үсештән нык калыша. Бу хәл иң гүзәл ниятләрне дә тар-мар итә. Рәхимсез, мәҗбүри экономия еллары иде бу.

Утызынчы елларда Казанда ул вакыт өчен иң зурлардан саналган машина төзү, металл эшкәртү, синтетик каучук, кинопленка, фотожелатин заводлары, мех комбинаты, киез итек-киез фабрикасы һ. б. сафка баса. Урта Кабан ярында республика энергетикасының беренче карлыгачы — куәтле Җылылык энергоүзәге (ТЭЦ) төзелә. 1940 елда башкалабыз промышленность продукциясен, революциягә кадәрге белән чагыштырганда, унике тапкыр күбрәк бирә. Әйләнә-тирә мохитка төшкән басым да, әлбәттә, шушы үсешкә тәңгәл була.

Кабан тирәсендә урнашкан завод-фабрикалар 1929 ел дәвамында күл суының унике процентын, 1935 елда — дүрттән берен, утызынчы еллар ахырына яртысыннан күбрәген файдалана. Бу елларда Кабан суына иң зур зыянны «Спартак» аяк киемнәре комбинаты ясый, заманында ул хакта матбугатта күп язылган. Комбинат тәүлек саен күлгә зәһәр кислота, көчле агулар, тире иләү калдыклары катнашкан дүрт йөз куб метр чамасы су агыза. Судагы катнашмаларның корылай авырлыгы гына да елга 27 тонна тәшкил итә.

Шул елларда чыккан газеталарны актарганда күлнең язмышы өчен борчылуның өзлексез арта барганын күрәсең. «Күлләрдә суның сыйфаты елдан-ел начарлана,— дип яза «Красная Татария» 1935 елның 16 мартында.— Ярым-йорты саклану чараларының файдасы шуның кадәр генә, алар фәкать җәмәгатьчелекнең уяулыгын гына киметә. Табигатькә китерелгән зыян барыбер, иртәме-соңмы, кешенең үзенә кире әйләнеп кайтачак, сәламәтлегендә, гомер озынлыгында чагылачак»... «Күп гасырлык нәҗес белән тулган Болак чир оясына әверелде»,— дип, Болакны да онытмыйлар.

Утызынчы еллар уртасында Дәүләт шәһәр проектлаштыру институты («Гипрогор») Болакны һәм Якын Кабанны савыктыру проектын эшли (авторы — инженер А. Доценко). Болак белән Кабанның төбен чистарту, Иделдән Болакка, Болак аша Кабанга чиста су кудырту һәм күлләр тезмәсендә суның агып торуын тәэмин итү — барлыгы өч миллион сумлык эш башкару күздә тотыла.

Архитектор Исхак Казаков проекты да кызыгырлык була. Анда Болакны кабат Кабан күле, Казан суы һәм Идел белән тоташтыручы суднолар йөрешле каналга әверелдерү карала. Шәһәр пристанен Болак тамагына, Казан Кремле янына ук, ягъни элекке тарихи урынына, күчерү күздә тотыла. Икенче бер канал Урта Кабанны Идел белән тоташтырырга тиеш була, ул чагында бөтен күлләр тезмәсендә су даими агып торыр, суднолар йөрүдән өзелмәс иде.

Акча җитмәү сәбәпле, И. Казаков проекты кире кагыла. А. Доценко проекты исә өлешчә генә тормышка ашырыла. 1938 елда Болак төбе шаплап чистартыла, тирәнәйтелә, ярларына таш түшәлә. Эшне ярты юлда сугыш туктата. Сугыш беткәннән соң махсус сусткәргеч төзелә. Болак белән Кабанга Идел суы кудырыла. Болак кабат җанлана, Кабан да күзгә күренеп тернәкләнә. Шул вакыттан башлап илленче елларның икенче яртысына кадәр Болакта (Кабан турында әйткән дә юк) бала-чага рәхәтләнеп су коена.

Күл суын тиешле тирәнлектә тотар өчен һәм язгы суларны җыеп калыр өчен Болакның ике башына су капкалары куела. Шулар ярдә-

мендә Якын һәм Урта Кабанда су дүрт метрга күтәртелә, күләме исә җиде миллион куб. метрга арта.

Бер үк вакытта архитектор Ү. Г. Алпаров проекты буенча Болак яр буйлары реконструкцияләнә: яңа биналар салына, череп беткән агач күперләр урынына яңа, нык күперләр төзелә. Болак буйлап милли орнаментлы чуен рәшәткә тотыла. Кабанны чистартыр өчен исә зуррак чыгымнар сорала, акча, әлбәттә, табылмый. Җитмәсә, күл ничек итсә итә, әлегә пычрактан үзе арына бара. Кабанда коеналар, кер чайкыйлар, көймәдә йөриләр, ишү ярышлары үткәрәләр, балык тоталар. Дөрес, 1927 елда балык күпләп кырылганнан соң Кабан балыкчыларны бик куандырмый. 1921 елгы ачлык вакытында күлнең меңләгән Казан кешесен үлемнән коткаруын инде әкият итеп кенә сөйләргә кала.

Ләкин галимнәр чаң сугудан туктамыйлар. 1940 елда географ В. Н. Сементовскийның күлләр тезмәсенең гидрология режимына багышланган фәнни хезмәте басылып чыга. Күлнең торган саен ныграк пычрана баруы бер хәл, аның инде үлү процессы башланган — бу хакта беренче булып нәкъ менә Сементовский сүз кузгата. Ни булган соң? Күл кислород җитмәүдән чын мәгънәсендә тончыга, күкертле водород белән агулана. Сементовский ашыгыч чаралар күрергә: күл тирәсендәге йортларга канализация үткәрергә, промышленность суларын агызуны туктатырга тәкъдим итә. Ул, пычрак суларны махсус коллекторларда җыеп, соңыннан канализация челтәренә кудырырга тәкъдим итә. Галимнең сүзенә бөтенләй үк колак салмыйлар дип әйтеп булмый. Ләкин гаять тиз үсә барган шәһәрнең мөһимрәк, ашыгычрак чыгымнары табыла тора. Сементовский тәкъдимнәренең нибары берсе генә тормышка ашырыла: күкертле водород белән агуланулар ешаю сәбәпле, кар базлары өчен Кабаннан боз алуны тыялар.

Сугыштан соңгы елларда республика промышленносте янә зур сикереш ясый. Куәтле компрессорлар, электрон-хисаплау машиналары, реактив һава лайнерлары, вертолетлар, суыткычлар, кондиционерлар, полиэтилен һәм халык хуҗалыгы өчен гаять мөһим тагын бик күп төрле продукция җитештерә торган уннарча яңа предприятие эшли башлый. Казан өчен традицион җиңел промышленность предприятиеләре — мех берләшмәсе, «Спартак» аяк киемнәре комбинаты, «Заря» конфет фабрикасы һ. б. ның куәте күп тапкырлар арта. Кабан тирәсендә биек йортлы, киң проспектлы яңа микрорайоннар үсеп чыга...

Илленче елларда төп эчү чыганагы ролен югалта барган Кабанга яңа вазифалар йөкләнде. Ул менә дигән ял итү урынына әйләнде. Студент чакларда, бераз гына буш вакыт чыктымы, Кабанга чаба торган идек. Анда һәрвакыт көймә алып була, туйганчы йөзәсең, кызынасың. Кабанда ГТО нормалары тапшырдык, күмәк йөзешләрдә катнаштык, курсташыбыз, ишү буенча РСФСР чемпионы Виктор Шадринга куәт өстәргә дә килә торган идек.

Казан тирәсендәге су мәйданы нинди генә киң булмасын, Идел дә, Казан елгасы да бу җәһәттән Кабанны алыштыра алмый. Күл җил-дулкыннан ышыкланган, анда башка сулыкларда була торган агым да юк. Җитмәсә, үзе — шәһәр уртасында. Спортчылар Кабанны тренировкалар үткәрү өчен идеаль урын дип саныйлар, Кабан булмаса, аны казырга кирәк булыр иде, дип әйтәләр. Күп санлы коену урыннары, көймә һәм спорт станцияләре, сикерү манаралары һ. б. корылмалары булган илленче еллардагы Кабан Россия Федерациясендә иң әйбәт су стадионы булып санала иде. Монда әледән-әле бөтенроссия һәм бөтенсоюз ярышлары үткәрелеп торды.

Илленче еллар урталарында күлнең яңа биографиясен ачып җибәргән вакыйга булды. Куйбышев ГЭСы Идел суының Казан тирәсендәге биеклеген 11,3 метрга күтәрде. Шәһәрнең түбән өлешен саклар өчен катлаулы инженерлык корылмалары — дамбалар, дренаж канаулары,

насос станцияләре төзергә кирәк иде. Урта һәм Якын Кабаннарда сусаклагыч өслеге биеклегеннән 1,5-2 метрга түбәнрәк. Кабанны элеккечә Болак аша Казан елгасы һәм Идел белән тоташкан килеш калдырганда, Идел суы, күлне тутырып, якын тирәдәге урамнарны басачак иде, шуңа күрә Болак тамагын күмеп, Казан суыннан дамба белән аердылар. Хәзер Болак Казан елгасына киңлеге ике ярым метрлы җир асты юлы аша, Иделгә исә аркылысы бер метр булган су юлы аша гына тоташкан. Хәер, тоташкан дип әйтү дөрес үк булмас, чөнки һәр ике юлның «капкалары» бар, алар, гадәттә, бикле хәлдә тора.

Шәһәрнең икенче башында, су ташыганда, Урта Кабан Идел белән ермак аша тоташкан җирдә дә дамба салынды. Шулай итеп, күлләр Иделдән киселеп калды, зарарлы матдәләр торган саен күбрәк туплана барган йомык экологик системага әйләнде.

Хәер, сусаклагычның гидростатик басымы тәэсирендә җир асты горизонтларыннан күлләргә берникадәр су кереп тора торуын. Яңгыр-кар сулары, промышленность сулары, канализация агынтылары да бар бит әле. Арткан суны суыртып чыгарыр өчен Болак тамагында һәм Урта Кабанның ерак читендә ике насос станциясе төзелде. Алар, артык суны Иделгә һәм Казан елгасына кудырып, күлне ел әйләнәсе бер биеклектә тоталар. Сусаклагычның су өсте биеклегенә һәм явым-төшемнең күпме булуына карап, кайбер елларда бер ярым яки хәтта ике Кабан күләмендә су суыртып чыгарыла.

Күл төбен ләм томалаган саен сусаклагычтан су саркып керү кими һәм, Н. М. Минһаҗева фикеренчә, бөтенләй туктауга бара. Шуңа бәйле рәвештә, арткан суны суыртып чыгару да кими, һәм, димәк, күлдәге алмашыну елдан-ел акрыная бара.

Тулаем алганда, Куйбышев сусаклагычы төзү шәһәрнең санитар хәленә уңай йогынты ясады. Гасырлар буена чүп түгү урыны, чир чыганагы булган баткак уйсулыклар, сазламыклар су астында калды. Элекке Ташаяк урамындагы баткак урын юкка чыкты, монда Үзәк стадион, цирк төзелде. Болак һәм Кабан буйларын төзекләндерүгә, дамбалар, комлык, күперләр, көймә станцияләре коруга дәүләт миллионлаган сум акча бирде.

Иң мөһиме әле бу да түгел. Куйбышев ГЭСы төзелгәнгә кадәр шәһәрне әледән-әле су баса торган иде. Ташу көчле булган елларда миллионнарча сумлык зыян күрә килдек, хәтта кеше гомерләре дә киселгәләде.

Әнием 1926 елгы туфан турында сөйләргә ярата. Ул чакта аңа егерме ике яшь булган. Су, гомер булмаганча, хәзерге Куйбышев сусаклагычының иң биек җиреннән дә өч метр биегрәк күтәрелгән. Болакта да су мөлдерәмә тора, тротуарларга ташый. Кабан төрле тарафларга җәелә. Яңа бистә, Архангельск һәм Кәҗә бистәләре, Казанның бөтен уйсу өлеше су астында кала. Халык өй түбәләренә кунаклаган, үзләре ясаган салларда йөзгән. Коткару катерлары һәм көймәләре әрле-бирле йөреп торган.

Кабанның бу ягында су Куйбышев мәйданы һәм Свердлов урамына килеп җитә. «Спартак» комбинатының ишегалды күлнең бер өлешенә әйләнә, анда чуртаннар йөзеп керә.

Бу кадәр үк катастрофик нәтиҗәләргә китермәсәләр дә, шундый су басулар 1929 һәм 1932 елларда да кабатлана. Шуннан соң су артык нык күтәрелми, ләкин су басуларга бары тик шәһәр инженерлык саклану линиясе генә чик куя.

1957-1958 елларда Кабанның төбен яхшы ук чистарттылар. Земснаряд ярдәмендә яр сызыгы буйлатып 15-20 метр киңлектә, 2-3 метр тирәнлектә ләм суыртылды. Бу эшкә өч миллион сумнан артык акча тотылды. Моның күл өчен сихәте зур булды.

Кабанның йомык экологик шартларда үзен ничек тотачагы мәгълүм түгел иде әле. Биолог В. В. Нечкина әнә шуны ачыкларга алынды.

Ул илленче еллар башында (ягъни Куйбышев сусаклагычы төзелгәнче) аннары илленче елларның икенче яртысында һәм 1964-1965 елларда (күлнең яңа режимы урнашып җиткәч) тулы өч тикшеренү циклы үткәрде. Галим ясаган төп нәтиҗә шундый: күп кенә уңай яклары булуга карамастан, Куйбышев сусаклагычын төзү, тулаем алганда, күлләргә начар тәэсир иткән. Идел белән бәйләнеш өзелү пычрануның тизләнүенә китергән. Суның катылыгы хәтта Идел суыныкын да узып киткән. Берничә ел эчендә углекислота микъдары 5-6 мәртәбә арткан, кислород микъдары исә шулкадәр дәрәҗәдә үк кимегән. Галимнең әйтүенчә, төп куркыныч табигый ләмнең һәм суның күкертле водород белән агулануыннан гыйбарәт. Нечкина, галимнәрдән беренче буларак, Якын Кабанда җан әсәре калмаган зур-зур «үле зоналар» барлыкка килүен искәрә. Иң әүвәл планктон (бик вак терек организм) зыян күрә, аның саны һәм төрләре нык кына кими. Ә бу инде — су үзенүзе чистарту сәләтен җуя, авыру тудыра торган бактерияләрне җыңа алмый дигән сүз. В. В. Нечкина үткәргән күп санлы анализлар Якын Кабанның куркынычлы инфекцияләр, кизүләр, ашказаны-эчәк авырулары һәм йогышлы мал чирләре чыганагына әверелә баруын күрсәтә. Якын Кабан суы эчәргә генә түгел, коену һәм спорт өчен дә яраксызга чыга бара. Элек хәле арурак булган Урта Кабан да, барлык күрсәткечләр буенча, Якын Кабанның «үкчәсенә басып» килә. Чөнки, миллионнарча сумнар сарыф ителеп тә, төп нәрсә эшләнмәгән Кабанга элеккечә промышленность сулары һәм хозфекаль агынтылар елга булып коеп тора. Моңарчы күлне язгы ташулар сафландырса, хәзер ул чын мәгънәсендә тончыга, буыла. Нечкина шәһәр властьларыннан барлык промышленность, көнкүреш һәм канализация агынтыларын туктатырга, яр буйларындагы чүплекләрне бетерергә, сазлыкларны киптерергә, Болак белән Кабанның төбен әледән-әле чистартып торырга тәкъдим итә, дөресрәге, моны таләп итә. «Шушы елларда радикаль сәламәтләндерү чаралары күрелмәсә, Кабан котылгысыз рәвештә, тиз арада гигант пычрак җыю урынына әйләнәчәк»,— дип яза.

Республикабыз 1979 елда промышленность продукциясен, 1913 ел белән чагыштырганда, 770 тапкыр күбрәк эшләп чыгара. Бу инде — завод-фабрикалар бер көндә генә дә элек ике елда эшләп чыгарылган кадәр, ә бер айда бөтен XIX гасырда җитештерелгәннән дә артыграк продукция биргән дигән сүз.

1954 елдан 1979 елга кадәр Казан халкы ике тапкыр артты һәм бер миллион чиген үтте. Шулай итеп, абсолют саннарда Казан халкы чирек гасыр эчендә элек сигез гасыр дәвамында артканнан да күбрәк арткан. Казанның беркайчан да болай үскәне булмаган. Шәһәр үзе дә, тирә-як ландшафты да үзгәрә, чиста су күбрәк тотыла, производство калдыклары исә геометрик прогрессиядә арта бара.

1975 елда Кабан суын сибү өчен дә файдаланмый башладылар — агачларны үстерми, үләннәрне корыта иде ул.

1976 елда Якын Кабанда балык юкка чыкты, акчарлаклар качты. Җәй урталарында Урта Кабаннан адашып килеп кергән балык була иде әле, ләкин язга анысы да җан тәслим кыла иде.

1978 елда санэпидстанция, бактериологик агулану булмасын дип, урамнарны Кабан суы белән юдыртуны тыйды. Күл төбендәге организмнар, суалчаннарга кадәр, үлеп бетте.

1980 елда Казан санэпидстанциясе шундый нәтиҗә ясады: «Күлгә агызылган пычрак сулар соңгы чик концентрациясен узу сәбәпле, Кабан торак массивлар атмосферасын агулый торган күкертле водород чыганагына әверелгән».

Гади телгә күчергәндә бу, боз ачылгач, Кабан тирәсендәге кварталларда тәрәзә-форточкаларны ябу-томалау гына җитми, кайбер предприятие, оешма, учреждениеләрне дә ябарга кирәк, дигән сүз иде. Моңа тагын хезмәт җитештерүчәнлеге кимү, больничныйларга түләү, күл буен-

да төзү эшләрен туктатудан күргән зыянны да өстәсәң, түгәрәк кенә сумма килеп чыга.

Шул 1980 елда Якын Кабан рәсми рәвештә үле күл дип табылды. Пычрану дәрәҗәсе ун баллы шкала белән үлчәнә. Бу төбәккә кеше аяк басканга кадәр әлеге күрсәткеч — нуль, XIX гасыр башында бердән бераз гына артык булса, 1980 елда 7,7 баллга җиткән. Тере организмнар яши ала торган чикне (биш балл чамасы) үтеп киткәч, күл инде канализация тондыргычларыннан берни белән дә аерылып тормый башлаган. Кабанның мең ел буена тула килгән сабыр савыты, ниһаять, тулып ташкан.



## 11

*Кабан — Казанның моңлы бер күзе...*

Рәвил Фәйзуллин

Бу эшкә рөхсәт алу җиңелдән булмады. Дөрес, берәү дә: «Ярамый!», «Мин каршы!» — дип сөрән салмый иде, тик, көне килеп җиткәч кенә, ...берсенең вакыты юк, икенчесе командировкада, өченчесе стажировкага китеп барган булып чыга. Азмыни ул санэпидстанция халкының эш-мәшәкатьләре! Бер тапкыр, инде, ниһаять, җыелышып беттек дигәндә, моторчы килмәде...

Менә бу юлы да инде тәмам көйләнгән эш шул моторчы аркасында өзелә язды. Инде кузгалабыз дигәндә генә: «Бензин юк»,— дип әйтмәсенме! Санэпидстанциянең баш врачы да, хәтта райбашкарма комитеты хезмәткәре дә ярдәм итә алмады. Әмма... баш врач югары инстанцияләргә шалтыратып маташкан арада, мин моторчыга бишлек тәкъдим иттем. Шундук табылды бензин.

...Менә без Кабан буенча йөзәбез. Без дигәнем — ике санитар врач гидрохимик лаборатория инженеры, лаборант кыз һәм без фәкыйрегез.

Күлнең иң хәтәр чагында, 1980 елның июнь аенда булды бу сәяхәт. Дегет кебек кап-кара су күбекләнеп-кабарып тора, әледән-әле шомлы гына пычтырдап та куя. Канализация исе аңкый. Төрле урыннардан су алып, яктыга куеп карыйбыз. Суда таркалып өлгермәгән нәҗес кисәкчәләре, корым-сөрем, кер юу порошогы бөртекләре йөзеп йөри. Лаборант кыз борынын җыера. Врачлар аңлаталар: кислород суның өстәге бик юка катламында гына табыла икән, калганы күкертле водород белән тәмам тончыккан. Димәк, су канализация суыннан бернәрсәсе белән дә аерылмый инде.

Менә пычрату чыганакларының берсе — «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсе тирәсеннән Кабанга коя торган агынты. Болай да җирәнгеч күл суы бу урында сары-җирән күбек боткасы булып шактый еракка сузылган.

Моторчы әллә көймәне артык кинәт борды, әллә тизлекне исәпләп җиткермәде инде, су алам, дип иелгән лаборант кызның битенә су чәчрәде. Кызый чырыйлап кычкырып җибәрде. Куркудан да бигрәк, җирәнүдән булса кирәк. Ярый әле бер бидон чиста суыбыз бар иде. Кыз юынды, ләкин бер күзе кызарып калды, күз кабагы да шешенкерәде.

— Саграк кыланырга кирәк! — дип әрләп куйды аны врач.— Күзсез калуың да бар.— Ничек юарга, нинди дарулар салырга кирәклеген аңлатып, ярга төшәргә тәкъдим итте. Әмма кызыбыз фидакарьләрчә баш тартты. Аннан башка йөрүебезнең бер мәгънәсе дә калмый иде шул. Кичкә таба шеше кайтты. Аның каравы, икенче күзе дә кызарып чыкты. Хәер, бу вакытта безнең бөтенебезнең дә күзләре йорт куяны күзенә охшап калган иде инде.

Әлеге вакыйгадан соң юлдашларым, үзара пышылдашып алдылар

да, канализация агынтылары белән маташмаячакларын әйттеләр.

— Ник алай? Алар күлне пычратмыймыни? Кайдан нәрсә күпме акканын төгәл белергә кирәк! — дим.

Күтәрелеп бәрелмичә генә түбәндәгеләрне аңлаттылар: иң катлаулысы — промышленность агынтылары, тулы бер көн эшләр өчен анысы да баштан ашкан. Хозфекаль агынтыларын анализларга махсус лаборатория җиһазлары соралмый — аларын бүтән вакытта да тикшереп була, янәсе. Мин ризалашырга мәҗбүр идем, чөнки аларга шундый күрсәтмә булганлыгын сиздем.

Рейдчылар промышленность агынтыларын тикшерүгә бәйле бөтен эшне төгәл иттереп, үз-үзләрен аямыйча башкардылар. Моторчы көймәне каршы ярга бора. Элекке сыра заводы янына йөзеп киләбез (хәзер алкогольсез эчемлекләр заводы). Тутыгып беткән торбадан черек арпа исе бөркеп торган болганчык су ага. Икенче бер ермакка завод ишегалдындагы юынтыклар төшә: чан юган су, барда һәм башка калдыклар... Шунда ук — янып-парланып яткан арпа өемнәре, алар эчендә симез-симез күселәр кайнаша. Ермакта файдаланылган кальций карбидының шомлы-дәһшәтле төстә парланып торган ак эретмәсе дә бар.

Акт төзибез. Әлбәттә инде, кул куяр кеше табылмый — администрация вәкилләрен җир йоткан диярсең. Цех башлыкларының берәрсеннән кул куйдырмакчы булабыз, әмма бездән ваба чирле кешедән курыккан кебек качалар: «Юк-юк, бернинди имза да салмыйбыз. Бары начальство рөхсәте белән генә». Дөресен әйтим, моңарчы мин санэпидстанция хезмәткәрләрен эшсезлектә гаепләбрәк йөри идем. Хәзер миңа алар хезмәтенең бөтен авырлыгы-катлаулылыгы ачыла башлады...

Без кайтуга, лаборант кыз беренчел анализны өлгерткән иде инде. Агынтыларда органик кушылмалар СЧКдән — соңгы чик концентрациядән йөзләрчә тапкыр күбрәк булып чыккан.

Мулланур Вахитов исемендәге химия комбинатының майланыпысланып беткән карасу-көрән корпусларына якынаябыз. Илленче елларда «Спартак» комбинаты агулы агынтысын туктаткач, химкомбинат Якын Кабанны иң нык пычратучы предприятие булып калган. Торбадан бәреп торган су күрер күзгә чип-чиста кебек. Тик рейдта катнашучыларны бу алдый алмый. Алар эшлекле кыяфәт белән иснәнәләр, суны яктыга тотып карыйлар, бармаклары белән угалыйлар, аннары реактивлар белән хикмәт кора башлыйлар. Кәгазьгә багана-багана саннар тезелә. Химик анализ суда төрле майлар, органик кислоталар һәм синтетик актив матдәләр булуын күрсәтә.

— Артык хафаланыр урын юк-югын,— дип аңлаттылар миңа.— Ләкин биредә әледән-әле авария агызулары булып тора. Бөтен күл өсте ак күбек белән каплана. Тәүлегенә меңәр тонна агызалар...

Күлгә хәлиткеч «һөҗүм»не нәкъ менә вахитовлылар ясый. Күлдәге соңгы балык алар юынтыгына тончыгып, өскә калкып чыга...

Эшне прокуратурага тапшыралар. Тикшерү берничә ай дәвам итә һәм, моңарчы каралган башка күп эшләр кебек үк, нәтиҗәсез тәгәлләнә. 1978 елның 20 ноябрендә Казан шәһәр Советы башкарма комитеты, химкомбинатка карата, Кабанга чистартылмаган су агызу тыела, дигән 1258 нче карар кабул итә. Әмма пычрак су ага да ага. Юк, үчлектән-дошманлыктан да түгел. Бердән, өстәмә канализация коллекторы тармагын сузучы төзелеш оешмасы инде ничәнче мәртәбә срокны өзә. Икенчедән, комбинатта авария очракларында, сабынлы су туплау өчен кирәкле махсус чокыр юк.

Ә бит югыйсә Кабанга агып торучы майлар һәм органик кислоталар — комбинат өчен кыйммәтле чимал. Тиешенчә чистартканда, барысын да яңадан файдаланырга, өстәмә табыш алырга мөмкин.

— Бу хәл озак дәвам итәчәкме соң?

Соравыма санэпидстанция хезмәткәрләре: «Чистарту корылмалары төзелгәнче»,— дип җавап бирделәр.




Кабан күлләре һәм аларның пычрану чыганаклары

— Комбинатта шуны аңласыннар өчен нәрсә эшләргә мөмкин соң?

— Күп тапкырлар кисәттек. Актлар да төзеп карадык, штрафка да тарттык. Инде бер генә чара калды — производствоны туктату турында кисәту.

Ярты айлардан мондый документ та төзелде. Күпләгән имзалар, мөһер-штамплар белән «ныгытылган» кәгазь миңа бик тәэсирле булып күренде. «Комбинат бер ай вакыт эчендә шәһәр Советы башкарма комитеты карарын үтәмәсә, Кабанга чистартылмаган су агызуга чик куймаса, производство туктатылачак, җиһазлар «бикләп куелачак». Кисәтүдә акка кара белән әнә шулай дип язылган иде.

Әлеге документның язмышы кызыклы. Анда күрсәтелгән вакыт узып китте, комбинат исә пычрак суны элеккечә агыза бирде. Шуннан соң «Советская Татария» газетасы хәбәрчесе Майя Канторович, комбинатның ул чактагы директоры Степанов янына кереп, әлеге кисәтү турында сүз башлаган. Хәбәрченең әйтүенә караганда, директор шактый вакыт... сүзнең нинди документ турында барганлыгын аңламыйча торган. Директор бу кодрәтле документка игътибар да итмәгән икән! Чыннан да, нинди дер бер күл аркасында кем инде йөзләрчә кешене — акчасыз, ә илне сабынсыз калдырсын ди!

Шулай да йөрүләребез бушка китмәде. Санэпидстанция актлары һәм «Советская Татария»да басылган мәкалә нигезендә, директорны эшеннән алдылар. Әмма пычрату дәвам итте. Тагын бер газета күлне яклап чыгыш ясады әле, бу юлы — «Вечерняя Казань» (1986, 19 июнь. «Үлчәү тәлинкәләре» дигән мәкалә.) Мәкалә уңаеннан, ТАССР Министрлар Советы Карар кабул итте. «Кабан күленә промышленность суларын агызуга юл куюы һәм чистарту җайланмаларын төзетмәве өчен М. Вахитов исемендәге химкомбинат директоры иптәш А. М. Рәхмәтуллинга шелтә белдерергә һәм, авария агызулары кабатланса, катырак җәза кулланылачагы турында кисәтергә».

...Вахитов күпере яныннан үтәбез. Бу турыда күлгә диаметрлары берәр колачлы ике торба төбәлгән. Икесеннән дә шаулап-гөрләп сасы сыеклык ага. Әмма бусы хозфекаль агынтылар булганга, тукталмыйча узып китәбез.

Урта Кабанда әлегә бәдрәф исе юк. Әмма күл бака ефәге белән капланган. Бу — пычрануның тизләнүе һәм күлнең үлеп бару билгесе. Сынау өчен алынган су метр ярым — ике метрдан башлап аска таба күкертле водород белән тулысынча агуланган «үле зона» ятуын күрсәтә. Кислород исә өске катламнарда да нормадагыдан шактыйга аз.

Менә берьюлы өч предприятиедән — беренче ТЭЦ, резина-техник әйберләр заводы һәм синтетик каучук заводыннан чыккан агынтыларны берләштерүче мул сулы каналга килеп җиттек.

— Каршы килмәсәгез, ТЭЦны калдырып торыйк! — ди гидрохимик лаборатория инженеры.— Үзенә бер көн кирәк аның.

Лаборант кыз синтетик каучук заводы суының беренчел анализын өлгерткәч, санэпидстанция хезмәткәрләре үз күзләренә ышанмыйча тордылар. Дүрт контроль пробада фенол (куркынычлы канцероген матдә) соңгы чик концентрациядән утыз ике мәртәбә артыграк булып, пробаларның берсендә бакыр кушылмалары әлеге чиктән 820 мәртәбә күбрәк иде! Ә бит авыр металларның тозы кешенең акылын зәгыйфьләндерергә, авыр чирләр китереп чыгарырга, киләчәк буыннарны гарипләргә һәм, гомумән, организмда алдан күреп бетереп булмаслык үзгәрешләр ясарга мөмкин.

— Эшне прокуратурага тапшырырга кирәк булыр,— дип үзара киңәшеп алдылар санэпидстанция хезмәткәрләре.

(Алар сүзләрендә тордылар. Өстәмә күп кенә анализлар һәм тикшерүләр үткәргәннән соң материаллар прокуратурага бирелде. Бу эш белән шәһәр прокуроры, өлкән юстиция советнигы К. Садриев шөгыльләнде. Анализ мәгълүматлары раслануга да карамастан, гаепле кеше-

ларне ачыклау мөмкин түгел икән. Прокуратура предприятие җитәкчелеген суны күлгә агызмыйча эшләүгә көчүне тизләтергә һәм алдагы бер-ике елда Кабанга чистартылмаган су коюны бөтенләй туктатырга мәҗбүр итүче аерым билгеләмә чыгарды. 1988 елга ул үтәлмәгән иде әле).

Резина-техник әйберләр берләшмәсе агыза торган су исә барлык параметрлар буенча да... күлнекеннән берничә тапкыр чистарак булып чыкты! Сәбәбе гади: завод артезиан коесыннан су ала һәм бер тапкыр файдалану белән күлгә агыза икән. «Димәк, алар күлне чистарталар булып чыга!»— дип шаярттым мин. Ләкин санэпидстанция хезмәткәрләре көләргә ашыкмадылар. Көләрлекме: Кабан суын шундый хәлгә китереп җиткергәнбез ки, хәзер промышленность агынтыларыннан да пычраграк булып калган.

Шуннан соң ниләр үзгәрде? Асылда бар да шул килеш калды. Дөрес, агызыла торган суның күләме, аерым анализларның күрсәткечләре беркадәр аерыла — нидер арта, нидер кими, әмма шакшы юынтыклар һаман ага бирә... ТАССР Министрлар Советының шул ук карарында болай дип әйтелә: «Казан резина-техник әйберләр берләшмәсе, беренче ТЭЦ, С. М. Киров исемендәге синтетик каучук заводы (директорлары Григорьев В. Д., Галиев И. Г., Сафин З. З. иптәшләр) су белән тәэмин итүнең йомык циклы системаларын төгәлләү өчен тизләткеч чаралар күрергә һәм аларны, Кабанга су коюны 1990 елга тулысынча туктату максатында, 1987 елда төзи башларга тиешләр».

Бу озын-озак һәм гаять авыр көн дәвамында (иртәнге уннан кичке җидегә кадәр) без предприятиеләрдән күлгә коючы җиде агынтыны ачыкладык һәм тикшердек. (ТЭЦка тагын бер көн кирәк булды). Аларның гомуми күләме тәүлеккә — ике йөз мең, елына 72 миллион куб метр тәшкил итә. Күл суларының гомуми күләме 12 миллион куб метр икәнен искә алсаң, промышленность предприятиеләренең ел дәвамында Кабанның бөтен суын үзләре аша алты мәртәбә үткәрүләрен исәплэп чыгаруы кыен түгел. Нинди күл моңа түзә алсын ди!

Санэпидстанция хезмәткәрләре — төпченүчән халык. Алар суның пычрану очраклары белән генә кызыксынып калмадылар, төркемнәргә бүленеп, цехларны да йөреп чыктылар. Аеруча агулы матдәләрнең күлгә эләгүе, күп очракта, җитәкчеләр аңлатканча, производство ихтыяҗы түгел, ә гап-гади мәнсезлек, битарафлык нәтиҗәсе икән.

Әйтик, резина-техник әйберләр берләшмәсе ишегалдында, агулы булганга, шәһәр чүплегенә кабул ителмәгән калдыклар табылды. Ни генә юк иде анда: кислоталар, селтеләр, зәһәр матдәләр сыланган савытлар. Болар бар да кар-янгыр сулары белән Кабанга агып төшә бит.

«Теплоконтроль» берләшмәсендә махсус нейтральләштерү цехы да бар, юкса. Тотылган электролит шуның аша үтәргә тиеш, тик аны канализациягә агызалар. «Сизмәсләр әле», янәсе. Чыннан да, еш кына сизми дә калалар. Табигатьне генә алдап булмый! Табигатькә кизәнеп, без үз яшәешебезгә балта белән чабабыз. Кызганычка каршы, күпләр моны аңламый.

Әлегә күл суының бер өлешен Иделгә суырту коткарып кала. Әмма Идел үзе дә илебезнең мөһим кан тамыры ич! Агулы суны Иделгә агызу шулай ук катгый тыелырга тиеш!

Кешенең көч-куәте, бигрәк тә техник куәте, чиксез арткан бу заманда табигатькә мөнәсәбәт яңача караш таләп итә. Әлегә исә әйләнә-тирә мохитне саклау өчен көрәш, асылда, кешеләрнең бер-берсен алдауларына кайтып кала.

Бер генә мисал. Кабан тирәсендәге предприятиеләрне туктаусыз тикшереп торып, актлар һәм штрафлар белән тенкәгә тия башлагач, күрсәткечләр кинәт яхшырды. Мондый кинәтлек шикле иде. Тиздән исә шул мәгълүм булды: атна буенча тупланып килгән иң агулы калдыкларны, контроль хезмәткәрләре ял иткәндә — шимбә һәм якшәмбе көн-

нәрне агызалар икән. Моны Казан химия технология институтының инициатив группасына кергән студентлар ачыклады. Әмма тагын эш йомылды: студент анализлары рәсми көчкә ия түгел.

«Кабан җиңелде». Абдулла Алиш язган очеркның исеме шундый. Әдип, яшь чакта, КазГРЭС төзелешендә десятник булып эшләгән. Язучы беренче бишьеллыкларның иң зур төзелешләреннән саналган бу мисалда дөнья моңарчы белмәгән хезмәт күтәренкелеген тасвирлый.

Язын Кабан суы, берничә метрга күтәрелеп, буаны ерып, котлованга ыргыла. Ташу суы белән көрәшергә алдынгы бригаданы куялар. Буаны кызыл балчык тутырган чыпта каплар белән томалыйлар. Тездән, кайчакта хәтта бил тиңентен бозлы суда торып эшләргә туры килә...

«Кабан! Ачулансаң да, котырсаң да, син җиңелдең. Удар бригадалар, корыч кешеләр сине барыбер авызлыклый алдылар...»— очерк әнә шулай тәгәлләнә.

Ул чорның әдәби документын укыганда бүген каршылыклы хисләр кичерәсең. Ата-бабаларның фидакарьлеге сокландыра, әлбәттә. Икенче яктан... табигатьне буйсындыру, елгаларны, күлләрне, хәтта диңгез кадәр диңгезне дә авызлыклау, «табигатьтән рәхимлекләр көтмәү, аны кеше ихтыярына буйсындыру» омтылышы шундый нәтиҗәләргә китерде ки, хәзер чәчне йолкырдай хәлгә җитәбез.

Электростанция салу өчен урын сайлаганда мәсьәләне Урта Кабанның суы саф кына түгел, йомшак та булырга тиешлеге хәл итә. Ул вакыттагы шкала буенча күл суының катылыгы биш градустан артмый. Казан суыныкы туксан градуска җитә. Станциянең казаннары өчен исә катылыгы ун градустан артмаган су кирәк.

Утызынчы еллар башында станция ел дәвамында күлнең уннан бер өлешен файдаланса, сугыштан соң аны тулаем «эчеп» бетереп, кире коя башлый. Ә хәзер Урта Кабан аның ут кайнап торган казаннары аша елына әллә ничә тапкыр үтә. Нәрсәгә китерә соң бу?

«Җылылык пычрануы»ның хикмәте зур түгел. Күрер күзгә су нәкъ шундый ук. Ләкин ул, беренчедән, кислородсыз кала. Икенчедән, анда балыкларга иң кирәкле булган планктон бетә бара. Әлеге иң нәни организмнарның һәлакәтеннән соң, күл үзен-үзе чистарту сәләтен җуя, анда зарарлы бактерияләр үрчи башлый. Чик-чама билмичә үрчегән бактерияләр кислородның төп өлешен йотып, күлдәге башка тереклек ияләренең үлемен тизләтәләр.

Менә су инспекциясе хезмәткәрләренең 1980 елның 14 маенда ясаган анализлары. Нефть продуктлары бер литрда — 54 миллиграмм. Рөхсәт ителгән иң соңгы чик — 0,3 миллиграмм. Балык сагы инспекциясе таләбе исә тагын да кырысрак — 0,03 миллиграмм. Эремәгән химик кисәкчәләр — 20 млг. урынына 1391 млг.

Чистарту корылмалары, ниһаять, эшкә җигелгәч, күрсәткечләр беркадәр яхшырды, әмма нефть продуктлары барыбер соңгы чиктән уннарча мәртәбә күбрәк.

Урта Кабанны күптән инде берәү дә Якты күл дип атамый. Суы көнкүреш яки хуҗалык хаҗәтләре өчен генә түгел, хәтта промышленностька да яраксыз. Табигый чисталыгын югалтып, каты елга суына якынаеп килә ул. Санэпидстанция хезмәткәрләре Кабан суына, яман ис беткәнче, дистилляцияләнгән саф су кушып карадылар. Моның өчен аны 250 тапкыр «сыегайтырга» туры килде.

Урта Кабанда вак-төяк балык йөзгәли әле. Бака тавышлары да ишетелгәли. Ялгыз акчарлаклар да очып үткәли. Ләкин үләксә эзләп бөтерелүче козгыннар күбрәк.

Күлне бу һәлакәттән коткару өчен нишли алабыз соң? Җавап күптән мәгълүм: судан файдалануның йомык циклын кертергә, чистарту корылмалары төзергә кирәк. Иң катгый карарлар да, штрафлар да, тантаналы вәгъдәләр дә бу үтә зарури, нәрсәләрне алыштыра алмаячак.

Шунысын ассызыклап әйтәсе килә: Кабан мәсьәләсе техник якка яки финанс мәсьәләләренә генә кайтып калмый. Бу — иң әүвәл, аңлылык, вөждан мәсьәләсенә кагыла.

...Балык сагы инспекторы, яшенә күрә артык житди егет — Володя Чекирин белән беренче җылылык энергоүзәгенең чистарту корылмаларын карап йөрибез. Менә нефть агып, кара әз сузган зур бер резервуар. Тирәсенә мазут күле җәелгән — түмгәктән түмгәккә, таштан ташка сикереп кенә якын килә алабыз. Суны чистартырга тиешле буфер савыт бу.

Володяның очлы күзе шунда ук житешсезлекне күреп алды: су монда берничә сәгать тонарга тиеш, әле исә ул бер торбадан агып керә дә икенчесеннән чыгып та китә. Житмәсә, өстәге майлы катламны агыза торган бүрәнкә дә тыгылган.

Ягулык-транспорт цехы начальнигы иптәш Охлопчиковны эзләп табабыз — чистарту корылмаларының эше өчен ул җавап бирә.

— Әйе шул,— дип килешә цех башлыгы.— Резервуар бәләкәйрәк булып чыкты. Проектчылар ялгышкан...

— Алай булгач, тагын берне куегыз,— дип очып куна Володя.— Бакларыгыз аз мәллә? Тондырганда гына да нефть продуктларының туксан процентлабын аерып алып була.

Флотатор дип аталган җайланманы карыйбыз. Монда судагы нефтьне махсус химик өстәмәләр — коагулянтлар аера. Әмма, Охлопчиков әйтүенчә, бу хикмәтле коагулянтларны күргәннәре дә юк икән — дефицит мал.

Өченче стадиядә су фильтрлар аша уза. Ләкин, баштагы ике стадия тиешенчә үтелмәгәч, нефть продуктларының соңгы калдыгына исәпләнгән фильтрлар бик тиз тыгыла, үзләренә йөкләнгән бурычны үтәми башлый. Менә шуннан соң инде Кабан суында аллы-гөлле таплар, хәтта мазут төерләреннән оешкан кара утраучыклар йөзеп йөрүгә гаҗәпләнәсе юк.

Кабан мисалында табигать тирәлегенең, бигрәк тә йомык экологик системаның үзенә бик тә сак мөнәсәбәт таләп итә торган нәфис-нечкә организм булуы күренә. Көчләүгә бер ел, ике ел, кайчакта хәтта уннарча еллар буена түзә ул. Әмма соңыннан аны элекке хәленә кайтару өчен дөньяның бөтен алтыны да житмәскә мөмкин...

## 12

Географик белешмәлекләр раславынча, Кабан күлләре тезмәсенең хәзер бер генә кушылдыгы да юк. Әмма дә ләкин 1980 елның җәендә, Якын һәм Урта Кабаннарның яр буйларын тикшереп чыккач, мин фәнгә билгеле булмаган биш яңа кушылдык таптым.

Беренчесе, шаулап-гөрләп, «хуш ис» аңкытып, Кабанга Академия театрының яңа бинасы тирәсендәрәк коя иде. Күлне сасытып, төзүчеләрнең теңкәсенә иң нык тигәне шул иде.

Бу кушылдыкны тикшерү күп вакыт алмады. Шаккаткыч маҗаралар да, хәтәр мизгелләр дә булмады. Исе генә менә... Җилгә каршы яктан барырга тырышып, ташкын инде шактый тирән чокыр ярырга өлгергән калку ярга мендем. Комсомольский урамындагы сасы баткаклыкны кичтем (ә бит бу яр буе архитекторларның рәсемнәрендә нинди матур булып күренә иде!). Аркылы Насыйри урамы буйлап киттем. (Сүз уңаеннан: урамның исеме «Поп. Насыйри» дип язылган иде; шәһәр башкарма комитетына шалтыраткач, язуны алыштырдылар). Сасы елга башын мин... Мәрҗани мәчете янынннан эзләп таптым. Ул канализация коллекторыннан чаптырып агып тора. Чокыры әштер-өштер генә киртәләп куелган.

Киртә тирәсендә ләчтит сатып утырган агайлар соравыма бик те-

ләп җавап бирде. «Чишмә» инде бер ел чамасы ага икән. Шалтыратмаган, язмаган җирләре калмаган. Туганнан туган энесе Мәскәүдә яши торган ниндидер Фатыйма атлы сатучы хатын «Чаян»га җибәреләсе хатка имза да җыеп йөргән, ди. Әбекәйләрнең берсе өч айлап элек чокыр янына «Водоканал» дип язылган ябык машина килеп туктаганын да күреп калган. Машинадан төксе кыяфәтле, кырынмаган өч ир төшкән. Тәмәке тартып, таптанып, чокырга төкергәләп бераз торганнар да китеп барганнар...

Сууткәргечләр һәм канализация хуҗалыгы идарәсендә эшләр гадәти тәртип белән бара иде: язу машинкалары тыкылдый, телефоннар чылтырый. Коридор идәнендә, аркаларын стенага терәп, иренеп кенә тәмәке пыскытып, берничә ир-ат утыра. Алар яныннан, биек үкчәле туфлиләре белән тек-тек басып, кәгазь өемнәре тотып, буялган тырнаклы кызыйлар үтеп китә. Башлык, әлбәттә инде, кайдадыр киңәшмәдә, урынбасары — ялда. Ярты сәгатьләп көтеп утыргач, баш инженер Дамил Җиһаншин кабинетына эләгә алдым. Дамил Дәүләтович мине дикъкать белән тыңлады. Бары бер урында гына: «Бер ел ук юктыр ла, арттырырга яраталар инде бездә»,— дип куйды. Яңалык ачмыйм, димәк. Соравыма җавап урынына, кыенлыклар турында сөйләп китте: акча аз, техника юк, эш хакы бәләкәй, берәү дә атлыгып тормый, янәсе. Шулай да ул, сүзен түгәрәкләп: «Төзәтербез... Борчыласыгыз юк. Проект төзелгән. Акча бүленгән. Якын арада коллекторга ремонт тәгалләнәчәк»,— диде.

Белмәгән кеше өчен канцелярия теле үзе бер табышмак. Шуңа күрә мин «якын арада»ны ничек аңларга икәнен ачыклый төшүләрен үтендем. Гади телгә күчергәндә, бу — бер ай эчендә, күп булса, ай ярымда, була икән. Җитәкче иптәшнең авызыннан шул сүз чыгу белән, «дусларча килешү» тәкъдим иттем: шушы срок үткәнче үземнең «ачышым» турында берни дә язмыйм. Әгәр инде... Ул чагында үпкәләштән булмасын. Редакция белән килешеп куелган. Дамил Дәүләтович, елмаеп, кулын сузды. Елмаюы гына шактый чытык килеп чыкты...

Укучы чамалаганча, бер айдан да, ай ярымнан да Мәрҗани мәчете янында, намазга йөрүчеләр интекмәсен дипме, бер рәхмәт яугырысы «инеш» аша салып куйган басманы искә алмаганда, берниндн үзгәреш тә булмады.

Тагын ай ярым үткәч кенә (минем материал, инде кабул ителеп, редакциядә чират кына көтә иде), чыбыксыз телефон кеше ышанмаслык хәбәр китерде: мәчет янындагы «чишмә» акмас булган. Шунда ук әлеге урынга ашыктым. Чыннан да, асфальттагы яңа «ямаулык»тан гайре, үзем ачкан «яңа кушылдык»ның эзе дә калмаган иде. Гаҗәп: аварияне бетерү өчен бер атна вакыт җиткәч, Кабанны ел дәвамында нәҗес суы белән агулау ни пычагыма кирәк булды икән?

Икенче кушылдык Кабанга каршы яктан коя. «Динамо» су станциясенең такта идәне астыннан үтеп, яңгыр суы юлының бетон улагыннан агып төшә ул. Бу кушылдыкның очына чыгуы җиңел булмады. Монда да махсус телдә «хозфекаль» дип йөртелгән су акканлыгы, беренче карауга, дөресрәге, беренче сулышка ук сизелеп тора иде. Тик каян агып килә ул? Канализация суы яңгыр юлына, гадәттә, канализация челтәрендә авария булгач кына эләгә. Кабан тирәсендәге бөтен урамнарны йөреп чыктым — берннинди «чыганак» тапмадым.

«Динамо» станциясендә эшләүчеләр соравыма каршы йөз чытып, кул гына селтәделәр:

— Монда гел шулай инде, ага да ага. Бәлкем, ун, бәлкем, егерме елдыр, кем белгән аны... Ничек инде: исебез китми? Шалтыраттык та, яздык та...

«Водоканал»дагы дежур диспетчер җаваплылыктан катгый рәвештә баш тартты:

— Без түгел. Ул районда безнең тулы тәртип... Әйе, элек иске кол-

лектордан аккалый иде. Соңгы вакытта бер зар да ишетелми...

— Әмма сасы су каян да булса ага лабаса!

— Яңгыр суы юлыннан дисезме? Бәлкем, кайдадыр бәдрәфне яки юынтык чокырын юдырып киткәндер. Ә бәлкем, әле берәр завод-фәлән мыштым гына канализация суын агызып ятадыр?.. Чистарту трестына мөрәҗәгать итеп карагыз!

Шәһәрне чистарту трестында минем белән сөйләшеп тә тормадылар. Санэпидстанциягә мөрәҗәгать итәргә туры килде. Коммуналь бүлек мөдире Мария Алексеевна Калашникова яңгыр суы гына түгелдер дигән шигемне уртаклашты. Әмма «Водоканал»ны да хаклы дип тапты: соңгы вакытта шикаятьләр, чыннан да, кими башлаган, урамнарның санитар хәле дә яхшырган. Гафу үтенде: эшем күп, берни белән дә ярдәм итә алмыйм. Шулай да, әйбәт кенә киңәш бирде: кыш житсә, астан чыгып торган пар буенча пычрату чыганагын табып булачак икән.

...Һәм менә сүрән, болытлы декабрь иртәсендә серле кушылдык буйлап барам. Икеләнми-нитми атлыйм, чөнки су асты инешен каплап торган плитәләр урыны-урыны белән кузгатылган, тимер рәшәткәләрдән генә түгел, ярыклардан да пар һәм... ис бөркелә. Свердлов һәм Айдинов урамнары кисешкән җирдә ул аеруча көчле.

Уңга борылып, ис тәмам беткәнче барам. Кире борылып кайтам, һәрбер ишегалдына кереп чыгам. Ниһаять, канализация хезмәткәрләре уратып алган, авария булган җиргә юлыгам.

Отбой чүкече дөпелди, насос эшли. Пычрак телогрейка кигән, шәлләрен кашларына ук төшереп бәйләгән апаларның кулында — лом. Чокыр өстендә басып торучы төксе генә ир кешегә, баш дип белеп, сак кына сүз кушам: Кабанга «Динамо» станциясе янында агып төшә торган су асты елгасы шушында башланмыймы?

— Ә сезне кем дип белик?

Аңлатам.

— Юк,— ди агай,— теләр-теләмәс кенә.— Моннан башланмый.

Безнең сөйләшкәнгә майланып беткән спецовка кигән яшь кенә моторчы егет тә колак салып тора. Сүзнең ни турында барганын белгәч, рәхәтләнеп сүзгә кушыла:

— Кабанга акмый, тагын кая аксын? Тик «Динамо» турысында түгел, Вахитов күпере янында... Бу иске коллекторның көче җитми аның. Соңгы ун-унбиш елда гына да Кабан буенда квартал-квартал күп катлы йортлар салынды. Барысы да шул бер коллекторга тоташтырыла.

— Мин Кабаннан ук килдем. Ярты көн йөрим, бер генә авария урыны да күрмәдем.

Егеткәй белән абзый мәгънәле генә карашып алалар. Абзый, «ни булса булыр!» дигән сыман, кул селтәп алды да:

— Ярты куйсаң, серне чишәм,— диде.

Шаяртуга бормакчы булам. Әмма агай шаяртырга уйламый да — сүзнең кызыгы беткәнгә санап, арт белән борыла. Егет исә, күз кысып алды да, юеш җиргә йомычка белән схема сыза башлады:

— Менә сезгә канализация коллекторы. Ике метр ярым тирәнлектә. Ә менә яңгыр суы юлы. Ул өстән, тротуар астыннан ук үтә. Янәшә баралар, әмма тоташмыйлар: коллектор агынтыларны чистарту корылмаларына куа, яңгыр суы Кабанга ага. Коллектор, төп-төзек булган хәлдә дә, зур агымны үткәреп бетерә алмый. Әмма дә ләкин аның төзек вакыты да булмый әле, гел тыгыла... Нигәме? Чөнки, проект буенча, ул яртылаш кына тутырылырга тиеш, ә без аны шыплап тутырабыз. Агынтылар, канализация капкачларыннан ташып, күлдәвекләр хасил итә, урам буйлап ага. Пычрак, сасы. Халык жалу арты жалу сырлый. Бу хәлдән гарык булган начальствобыз, беләсезме, ни уйлап тапты? Коллектор астан яңгыр суы юлы белән тоташтырылды. Хәзер агынтыларның бер өлеше Кабанга ага...

Шуннан соң ни булдымы? Шәһәр башкарма комитетында да, санэпидстанциядә дә мин сөйләгәннәргә бик житди карадылар. Әнәсеннән җебенә кадәр тикшерергә, очына чыгарга вәгъдә иттеләр. Миннән исә фаш итүләр белән ашыкмауны, шау-шу куптармауны сорадылар.

Чыннан да, телефон көн саен диярлек яңа хәбәр җиткереп торды. Егетнең сөйләгәннәре тулысынча расланган. Санитария нормаларын тупас бозу бер ай эчендә төзәтелгән. Гаеплеләр каты җәзага тартылган. Дөрес, аларның фамилияләрен миңа әйтмәделәр. Тик фамилиядәмени хикмәт — көннәрнең берендә «Динамо» станциясе астыннан үткән агым да юкка чыкты. Әйтерсең, бөтенләй булмаган да! «А. Айдинов» тукталышында сасы ис килми башлады. Бактың исә, булган канализация челтәре белән дә, яңа магистраль коллектор төзүгә миллионлаган сум тотмыйча да (элек мәсьәлә нәкъ менә шул нәрсәгә килеп терәлә иде) шакшыны күлгә агызмаска мөмкин икән. Моның өчен Спартак, Луковский, Свердлов урамнарындагы коллекторларга әледән-әле профилактик чистарту гына үткәреп торырга кирәк булган.

Берничә айдан бу искитмәле уңганлыкның да сере ачылды. Шәһәрнең чисталыгын һәм төзеклеген тикшерү өчен Мәскәүдән югары комиссия көтелгән булган икән. Ул елны Казан төзеклек буенча Россия шәһәрләре арасында беренче урынны алды. (Дөресен әйткәндә, Казаннан чистарак калаларны да күрергә туры килгәләде миңа).

Өченче, дүртенче һ. б. «кушылдыклар»ның да үз чишмә башлары бар иде. Киңәшмәләр үткәрелде, планнар төзелде һәм расланды, чаралар билгеләнде. Кемнедер «мунча керттеләр», кемнедер эштән сөрделәр. Әммә... койрыгын алса — башы, башын алса, койрыгы ябыша дигәндәй, бер агынтыны юк итеп өлгермиләр, ул икенче бер урында бәреп чыга, бер торбаны ямыйлар гына — икенчесе шартлый.

Елгачылар больницасы территориясендәге канализация коллекторында булган зур аварияне, әле бетерү өчен түгел, кем бетерергә тиешлеген ачыклау өчен генә дә елдан артык вакыт кирәк булды! «Водоканал», коллекторның бу өлеше елга порты балансында, дип тәкрарлады. Порт исә, ремонтны мех берләшмәсе ясарга тиеш, дип саный иде. Монысы тагын «Водоканал»га шудырмакчы булды. Чынлыкта, «Водоканал» ремонтларга тиеш булып чыкты да. Ләкин шул вакыт эчендә Кабанга күпме сасы су акты?!

Бер тапкыр шулай исәпсез-хисапсыз киңәшмәләрнең берсендә шәһәр канализация хезмәте башлыгы белән рәттән, шагыйрь әйтмешли, «туры килде минем урындык». Җитәкче иптәш, карашын читкә төбәп, төксе генә сөйләп китте:

— Менә сез язасыз, чыгышлар ясыйсыз, тәнкыйтьлисез. Игелек эшлим дип уйлыйсыз инде. Ә бит, төптәнрәк тикшереп карасаң, сез эшкә комачаулыйсыз гына. Нигәме? Хәзер аңлатам. Менә сез санэпидстанция китерттегез, чебеннән фил ясадыгыз. Хуш, бәхәсләшмим, фактлар дөрес. Әмма бер без генә алай эшләмибез ләбаса... Сезнең чыгыштан соң безне призлы урыннан мәхрүм иттеләр, бөтен персоналның премиясен кистеләр... Бездә күпме алалар дип уйлыйсыз?.. Белмисез шул, хикмәт тә шунда. Халык эш хакының премияләр исәбенә бараз адәм рәтенә керүенә күнеккән иде инде. Премиясез аларны монда аркан белән дә тотып булмый. Нәҗестә казыну рәхәт мәллә? Болай да кеше җитми — тагын уннарча кеше дәррәү гариза тотып килде...

1980 елның 17 маенда Казан шәһәр Советы башкарма комитеты «Кабан күлен пычратуларны булдырмау чаралары турында» карар кабул итте. Үзтәнкыйтьле, гаепле кешеләрне атап күрсәткән, кем кайчан нәрсә эшләргә тиешлеген төгәл билгеләгән үткен һәм дөрес карар иде бу. Башкарма комитетка турыдан-туры буйсынган идарәләргә кагылышлы ике генә пунктны китерәм:

...Сууткәргеч-канализация хуҗалыгының производство идарәсе башлыгы вазифаларын башкаручы ип. Артюнов Г. А.га 1980 елның

1 августыннан пычрак агынтыларны Кабан күленә агызуны туктатырга.

...Башкарма комитетның төзекләндерү идарәсе начальнигы ип. Цышевский Г. М.га 1980-81 елларда яңгыр суларын Кабанга агызу алдыннан тондыру өчен махсус бассейннар проектын эшләргә һәм 1982 елда аларны төзүне тәэмин итәргә...

Алты елдан соң, 1986 елның көзендә шундый ук яңа карар кирәк булды, бу юлы — ТАССР Министрлар Советыныкы. Анда элекке карарның үтәлмәгәнлеге ап-ачык итеп әйтелгән иде.

«Элек Кабанда балык күп иде, акчарлаклар оча, балалар су керә иде. Хәзер ни булды? Күбекле дулкыннар да кер уу порошогы агарткан ярлар гына.

Кайчандыр Кабаннан җәйге челләдә дә саф җил исә иде. Хәзер тончыктыргыч сабын исе, черек исе, күкертле водород исе килә».

Равил Хәсәнов, Казан. 1980 ел.

«Кичә, 1980 елның 11 августында, унынчы яртыда Вахитов исемендәге химкомбинаттан Кабанга куе ак сыекча агыза башладылар. Банкага алдым — кер уа торган порошок. Бу хәл кичке тугызга кадәр дәвам итте. Балыкны агулап бетергәннәр иде, инде бака да калмады. Әлеге порошоктан су башта агара, аннары деген кебек кап-кара була, ә һава — противогаз киярлек. Мондый башбаштаклыкка кайчан чик куелыр икән?»

А. И. Кирьянов, Комсомольская урамы, 31/2нче йорт.

«Кайчандыр соклангыч күл булган Кабанның сасы сазга әйләнеп баруы белән кайчангача килешеп яшәрбез икән? Күлгә күпме пычрак агызырга була? Шәһәр властьлары кая карый?»

Л. С. Хәбибуллина, Казан.

«Болай яшәргә ярамый бүтән. Форточканы ачар хәл юк, ачмасаң, һава җитми. Иртән йокыдан мунчада ис тидергән сыман торасың. Берни дә эшләп булмый микәнни соң?»

18 имза куелган күмәк хаттан.

Мин берничә хаттан гына өзек китердем. Ә аларның исәбе-хисабы юк. Казан шәһәр Советы башкарма комитетында Кабанны пычрату турындагы хатларны махсус папкаларга тегеп баралар. Соңгы елларда гына да калын-калын өч папка тупланган.

Моңа тагын матбугаттагы чыгышларны да өстәргә кирәк. Миндәге тулы булмаган мәгълүматларга караганда да, 1971 елдан 1988 елга кадәр җирле һәм үзәк матбугат, радио-телевидение Кабан һәм Болак мәсьәләләре турында 58 мәртәбә чыгыш ясаган.

Кая гына язылмасын, газета редакцияләренәме, яки абруйлы үзәк органнаргамы — хатлар барыбер, ахыр исәптә, шәһәр Советы башкарма комитетына килеп керә.

Мине бу эшнең гади күзгә күренмәгән тәртибе кызыксындырды. Менә хат килде, газетада мәкалә басылып чыкты, ди. Шуннан соң ни була? Канцелярия эше остасы көлеп кенә куяр: хат килгән икән, димәк, аңа, тиешле вакыт эчендә, җавап язарга кирәк. Аннары инде ник шунда дөньяның асты өскә килми.

Хатлар төрлечә языла. Җаваплар исә әзер калыпка салынган. Хәер, ике төрле калып бар. Беренчесе, кыскарагы — аерым кешегә җибәрү өчен. Икенчесе, киңрәге, редакцияләргә җавап язганда файдаланыла. Әйдәгез, башкарма комитет председателе урынбасары А. Александров имзасы белән 1970 елдан башлап җибәрелеп торган җавапларга күз йөртеп чыгыйк.

Беренче өлештә фактларның дөрес булуы әйтелә. Гәрчә томанлырак төстә һәм беркадәр киметелеп булса да: «Кабанга пычрак агынты-

лар элэгүнең аерым очраклары булгалады...» Дикъкать итегез: *«аерым очраклары»*. Бу — агынтылар көннәр буена коеп торган чак турында! Арырак, көр күңел белән «мондый, һич тә ярамый торган пычратуларга» чик куелачагы искәрелә, сроклар күрсәтелә, газета чыгышына җавап йөзеннән күреләчәк конкрет чаралар санала. Әйтик, «Совет районыннан Идел буе районына бара торган яңа канализация коллекторы төзелә, ул 1971 елда файдалануга тапшырылу белән, Жданов-Свердлов-Луковский-Спартак урамнары төбәгендә эшләп килгән канализациядәге аварияле ситуацияләр һәм Кабанга канализация агынтылары элэгү очраклары бетәчәк».

«Күпсанлы чистарту корылмалары төзелә, алар агымдагы бишьеллыкта сафка басачак. Шәһәрнең үсү перспективасын күздә тотып, өч яңа магистраль коллектор салына. Әлеге коллекторларның аеруча мөһим участоклары 1972 елда сафка кертеләчәк. Бу исә хәлне тамырдан яхшыртачак».

Шулай итеп, әлеге документка ышансак, Кабанда хәл инде 1972 елда ук «тамырдан яхшырырга» тиеш иде. Ә ул начарланганнан-начарлана барды. Нигә? Совет районыннан Идел буе районына баручы коллектор санап үтелгән урамнардагы авария ситуациясенә, чынлыкта, берничек тә тәэсир итмәде һәм итә дә алмый иде — әнә шуңа! «Шәһәрнең үсү перспективасын күздә тотып» өч магистраль коллектор һәм шулай ук Кабан тирәсендә «күпсанлы чистарту корылмалары» төзү турында асылда сүз генә йөрде.

1973 елның январеннан башлап хатларның калыбы үзгәрә. Беренче өлеше элеккечә кала, әзерләнгән һәм кабул ителгән чаралар бүлегенә исә яңалык керә: «1974 елда «Горки» коллекторы, шулай ук промышленность предприятиеләренең канализация һәм йомык су әйләнеше системалары төзелү тәгәлләнгәч (Кабандагы хәлне тамырдан үзгәртергә тиеш булган элекке коллекторлар турында ләм-мим!), Кабан күленә пычрак су агызу тукталачак».

Ай бу кәгазь дигәннәре тылсымлы көчкә ия булса икән! Әмма... 1974 ел да узып китте, пычрак инешләр көчәя генә барды. Моннан нинди нәтиҗә ясалырга тиеш? Дөрес уйлыйсыз, тач шулай: яңа калып әзерләргә кирәк. Бу юлы А. Александров саграк кылана һәм агынтыларны бөтенләй туктату өчен ераграк срок билгели: 1980 ел.

Кайчандыр Хуҗа Насретдин, башын кискәгә куеп, егерме ел эчендә ишәк дигән малны да укырга өйрәтергә ризалаша. Башының муенда калачагына шикләнми ул: вәгъдәләшкән вакыт үткәнче, йә ишәк, йә хан, яисә үзе теге дөньяга китеп барачак бит.

Нәкъ шулай! 1980 елда әлеге шома хатларны иҗат итеп утыручының күзенә булса да карыйм әле, ичмасам дип, шәһәр башкарма комитетына килсәм, Александров иптәш анда эшләми икән инде. Аны алыштырган Я. Ишбулатов үткәндәге эшләр өчен җавап бирә алмыйм, бигайбә дигәндәй, кулларын гына җәйде.

Күлне пычрату «эшенә» турыдан-туры шәһәр башкарма комитетына буйсынган коммуналь хезмәтләр дә өлеш кертте. Бер кызык хәл истә калган. Киңәшмәләрнең берсендә сууткәргечләр-канализация хезмәте башлыгы ип. Арутюновка, «кискен рәвештә киметербез», «юл куймабыз», «чара күрербез» кебек чираттагы «ышандырулар»ына җавап йөзеннән, минә мондый сорау бирделәр:

— Әйтегез әле, Кабан булмаса, нишләр идегез соң сез?

Башлык аптырашта калды:

— Ничек инде, Кабан булмаса-а-а?!— дип сузды ул. Аннары төшенде.— Вакытлы трасса сузарга, өстәмә насослар куярга туры килер иде. Чистарту корылмасына кудырган булыр идек.

Кемдер бераү шунда әйтә куйды:

— Ә сез шулай итегез дә! Күл барын онытыгыз!

Ә бит, баксаң, эчке сулыклары булган башка шәһәрләрдә нәкъ

шулай эшлиләр. Безгә дә нигә Кабанны, әйтик, су стадионы дип санап, аңа су стадионына тиешле кадер-хөрмәтне күрсәтмәскә?! Хәер, хәзер башкача мөмкин дә түгел инде, хәзер бөтен Казанның сәламәтлеге Кабанның саулыгына бәйле.

Бәхеткә каршы, эш шома җаваплар белән генә чикләнмәде. Күлнең ихлас һәм фидакарь дуслары табылды, алар, шикаятьләр, матбугатта чыгыш ясаулар белән генә чикләнмичә, зур һәм мөһим эш башкардылар — мәсьәләне тамырдан хәл итү өчен җирлек әзерләделәр.

80 нче елларда В. В. Нечкинаның тикшеренүләрен университетның табигатьне саклау кафедрасы аспиранты Н. Минһажева дәвам иттерде. Ул күл суына меңнәрчә тапкыр анализ ясады, күлләрнең экологик системасын комплекслы өйрәнү үткәрде һәм аның язмышын хәл итү өчен фәнни база булдырды. Бу эшне ул кафедра мөдире Ю. С. Котов җитәкчелегендә алып барды. Бөтенроссия табигатьне саклау җәмгыятенең Татарстан советы президиумы да (председатель урынбасары Р. С. Левахина) турыдан-туры бу эшкә катнашты. Җәмгыятьнең коллектив әгъзалары, өлкән класс укучылары, университет, химия-технология һәм төзү институтлары студентларыннан торган табигатьне яклау буенча яшьләр группалары аеруча мактауга лаек. Бу группаларга канализация һәм су белән тәэмин итү буенча танылган белгеч — Әнвәр Якупович Абдюшев җитәкчелек итте.

Шәһәр санэпидстанциясе хезмәткәрләре М. А. Калашникова белән С. А. Яни, балык сагы инспекторы Р. В. Мәрданов, казанлылар С. Ш. Абдюшев, И. Никитина, И. М. Николаев, күлне саклау буенча рейдлар, постлар һәм башка чараларда катнашкан башка күп кенә кешеләр хөрмәт белән искә алынуга лаек.

Җәмәгатьчелек тарафыннан күтәрелгән проблемаларга, әйтелгән фикерләргә шәһәрнең архитекторлары Ү. Алпаров, Р. Дустиев, шәһәр Советы башкарма комитеты председателе Р. Идиятуллин һәм тагын күп кенә җитәкчеләр колак салалар, күңелләренә якын аладар иде.

## 13

Кешенең зур ясалма сулыклар, чып-чын диңгезләр хасил иткәне бар. Әмма тарих үле сулыкларга яңадан тормыш өрү очракларын белми әле. Ә менә 80 нче елларда Кабан белән нәкъ шундый хәл булды.

Бик тә гади-гадәти — комиссия төзүдән башланып китте бу эш. Хәер, комиссиясе гадиләрдән түгел иде. Биологлар, медиклар һәм санитария хезмәткәрләреннән тыш аңа реаль власть ияләре дә кертелде. Комиссиягә җитәкчелек Казан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе урынбасары Ю. М. Погореловка йөкләнде. Гыйльми секретарь итеп университетның табигатьне саклау кафедрасы мөдире, биология фәннәре кандидаты Ю. С. Котов билгеләнде.

Үз гомеремдә миңа күп кенә комиссияләрнең әгъзасы булырга язса эшен күзәтергә туры килгәне бар. Җаваплылык бөтен кешегә дә тигез бүленә торган һәм, димәк, конкрет берәүгә дә төшми торган, бюрократик гакылның иң югары казанышы булган бу оештырылмалар гадәттә әллә ни майтара алмый. Кемдер әкертен генә кыймылдый, актлар төзелә, документлар теркәлә, беркетмәләр языла...

Әмма бу юлы башкачарак булды. Инде төзелгән чакта ук комиссиягә хәлнең торышын өйрәнү һәм «тиешле җиргә» хәбәр итү генә түгел, хәлне төзәтү бурычы да куелды. Конкрет вакыт эчендә — Г. Камал исемендәге театрның яңа бинасы ачылуга, ягъни 1985 ел башына кадәр. (Соңыннан бу срок 1986 елның азагына күчерелде.)

Менә шуңа да комиссиянең эшчәнлек нәтиҗәләре, ул эшнең торышы белән танышып анык бер фикергә килгәнче үк, күренә башлады. Табигатьне саклау белән лаборант кыз шөгыльләнү — бер нәрсә ул.

Заводка партиянең шәһәр комитеты секретаре яки бүтән зур җитәкче килеп, план үтәлешеннән дә алда Кабанга агызыла торган суның күләме һәм чисталык дәрәҗәсе белән кызыксынуы исә бөтенләй башкача кабул ителә. Директор мәсьәләнең уеннан узганлыгын җитәкче иптәшнең тавышыннан ук чамалап ала...

1981 елның маенда комиссия хөкүмәткә тиешенчә дәлилләнгән, экономик яктан нигезләнгән документ тапшырды. Бу документтан күлне бары ясалма юл белән — кеше катышлыгы белән генә коткарып булганлыгы күренә. Комиссиянең тәкъдимнәре шуннан гыйбарәт:

1. Күлгә һәртөрле пычрак су агызуларны кичекмәстән туктатырга.
2. Ясалма агым булдырырга.
3. Күл төбен шәпләп чистартырга.
4. Суны аэрацияләргә (һава өрдерергә).
5. Ярларны төзекләндерергә һәм яшелләндерергә.
6. Яңгыр һәм кар суларын махсус коллекторларга җыеп канализация челтәренә кудырырга.
7. Күлдән су алу күләмен чикләргә.
8. Күлнең тереклек дөньясын тергезергә.

Асылда бу — коры тәкъдимнәр генә булмыйча, комиссия үзе үк тормышка ашырырга тиешле эш планы иде инде.

Чираттагы гадәттән тыш адым директорлар советы төзүдән гыйбарәт булды. Кабан буенда урнашкан, күпме еллар күлне тончыктырып килгән предприятиеләрнең җитәкчеләренә бу юлы аны коткару бурычы йөкләнде.

Бер директор: төрле-төрле 37 советта әгъза булып торам, һәр утырышта катнаша башласам, миңа 74 сәгатьле тәүлек кирәк булачак, дигән иде. Әмма бу совет атна саен үткәрелеп, анда бөтен директорларның да катнашуы мәҗбүри иде! Хәер, акча бирү кебек нәрсәне директордан башка кем дә булса хәл итә аламы соң әле? Сүз дә бит ниндидер мең сумнар турында түгел, миллионнар турында барды. Мәсьәләнең чын-чынлап шулай куелуына кайберәүләр башта ышанып та җитмәде: сез нәрсә, иптәшләр, шаяртасыз мәллә? Моңа кем юл куйсын! План бар, смета бар. Сметадан тыш сукыр бер тиен дә тота алмыйбыз... Финанс ревизияләре, халык контроле белән ни эшләргә кушасыз тагын? Ирекле көннән башны төрмәгә тыгар хәл юк, янәсе.

— Ә уннарча ел буена күлгә теләсә ни агызырга ярый идеме соң?— аларның авызын әнә шулай томаладылар.— Күз яше күк чиста суны бушлай тотарга ярый идеме? Табигатьтән алган бурычны түләргә вакыт. Чигенер урын юк — күл һәлакәткә килеп җитте.

Бөтен вагын-төяген сөйләп укучының башын катырасым килми. Төрлесе булды. Берәүләр, кызгандырырга теләп, мескенгә сабышты, икенчеләре һәр мең сум акча өчен җан талашты. Инстанцияләр буйлап та йөрделәр, өстәлгә эштән китү турында гариза атып та карадылар. Тик, беркайда да теләктәшлек тапмагач, аз-азлап янчыкларын чишә башладылар. Шулай итеп, җыя торгач, 20 миллион тупланды.

Әмма директорларны акча каерып өчен генә җыймыйлар. Чынлап торып тотынгач, һәрбер предприятиедә дә диярлек, пычрану үзенчәлегенә бәйле рәвештә, үз чистарту системаларын эшләү, берәр төрле әмәл табу мөмкин булып чыкты. Бер предприятиегә тондыру буасы да җитә, икенчесендә зарарлы агынтыларны нейтральләштерү кирәк, өченчесендә гади, әмма ышанычлы фильтрлар куеп була икән. Рационализаторлар да күп кенә отышлы чаралар тәкъдим итте.

Шәһәр һәм республика җитәкчеләренең ярдәмен тоя башлагач, санитария хезмәтләренә дә җан керде. Бер кат чистартмыйча торып алар агынтыларны хәтта шәһәр канализациясенә дә кабул итми башладылар. Һәрбер соңгы чик концентрацияне үтү очрагы «ЧП»га әйләнделә, шәһәр башкарма комитеты председателе кабинетында яки хәтта партиянең шәһәр комитеты бюросында тикшерелә иде.

Нәтиҗәдә, 1981 елның беренче яртысында күлгә агулы су агызу күләме өч тапкыр кимеде. 1980 елда Якын һәм Урта Кабанга төрле яктан 18 сасы «кушылдык» койса (дөрес, аларның өчесе «рәсми түгел» — минем картада гына билгеләнгән), 1981 ел җәендә аларның нибары алтысы гына торып калды. Иң гаҗәбе шул: комиссия эшләгән чакта М. Вахитов исемендәге химкомбинатта ник бер авария агызуы булсын! Әллә технология дисциплинасын төгәл үтәү нәтиҗәсе, әллә очраклылык кына булган инде. Һәрхәлдә, директор А. М. Рәхмәтуллин шундый бер агызу өчен дә директор урындыгыннан гына түгел, партия билетыннан да колак кагарга туры киләчәге турында шәп кенә кисәтелгән иде.

Комиссиянең таләбе буенча 1981 елда Кабанның аргы башындагы насослар тулы көченә җибәрелде. Күкертле водород белән агуланган су урынына, сулы горизонтлар аша, чиста агымсу керә башлады. Анализлар кислородка туенган катлауның аз-азлап тернәкләнә баруын күрсәтте. Ботан бугазы аша саф су Якын Кабанга да кертелде. Әмма монда ләм тыгылган сулы горизонтларны терелтү мөмкин булып чыкмады. Күл төбен шәп кенә чистартып алырга кирәк иде.

1981—1982 еллар кышында ничәмә-ничә еллар эчендә беренче тапкыр Кабанда боз катты. Соргылт, куыклы, тотрыксыз боз иде бу.

Язын ис гадәттәгедән азрак килде, тиздән анысы да бетте диярлек. Әлбәттә, күлдә җан әсәре юк иде әле. Шулай да, үлчәү тәлинкәсе тирбәлеп куйды инде. Казанлыларның күпчелеге бу үзгәреш хакында берни дә белми иде әле. Якын-тирәдә яшәүчеләр исә шундук чамалап алды: шикаятьләр кимеде.

1982-1983 елларда агынтыларны бетерү, Иделгә су кудыру һәм күл төбен чистартырга әзерлек эшләре дәвам итте. Күмәк тырышлык белән бик тиз арада 16 миллион сумлык проект та эшләп алынды. Юкка баш ватып тормыйча, илленче елларда инде сыналган һәм бик тә отышлы чыккан ысулны кулланырга — земснаряд белән чистартырга булдылар. Проектчыларны бүтән нәрсә борчый иде: миллионнарча тонна агулы ләмне кая куясы?

Шактый гына эзләнгәч-тикшеренгәч, Утар ягындагы ташландык җиргә кудырырга булдылар. Шәһәрдән ерак булуы әйбәт иде, әмма 13-15 километр артык ерак түгелме? Хәтта Волга — Дон каналын төзегәндә дә кудыру ераклыгы тугыз километрдан артмаган... Кыен хәлдән пульпаның (балчык белән су кушылмасы) басымын тиешле дәрәҗәдә тотачак арадаш насос станцияләре ярдәмендә чыгарырга булдылар.

Вакыт кыса иде. Театрның яңа бинасы ачылуга өч еллап кына калып бара. Җитмәсе, ачу тантанасы театрның сиксән еллыгы белән туры килә. Мәскәүдән, союздаш һәм автономияле республикалардан мәгтәбәр кунаклар чакырылган. Республиканың йөз аклыгы җитди сынау алдында калган.

Казан заказы буенча Цимлянск судомеханика заводында житештерүчәнлеге сәгатькә 250 куб метр булган куәтле земснаряд ясыйлар. Аны 1983 елның апрелендә «Спартак» берләшмәсе янында суга төшерделәр. Шул ук вакытта пульпа үткәргеч салу буенча шактый катлаулы һәм күп хезмәт сорый торган эшләр дә алып барылды. Менә җитәкчелек итү һәм төрле оешмаларның тырышлыгын координацияләү өчен башкарма комитет председателе җитәкчелегендәге шәһәр штабы булдырылды.

Шундый ерак арага пульпаүткәргеч салу өчен күпме торба кирәк. Ә алар СССР Госпланы разнарядкасы буенча бирелә. Нишләргә? Планнарга төзәтмә кертеп, Кабан өчен «берничә тамчы» бүлеп биргәннәрен берничә ел көтеп утырыргамы? Еллар түгел, минуты кадерле. Урында «эзләп табарга» кирәк иде. Бу четерекле эшне шәһәрнең инженерлык сагын эксплуатацияләү идарәсе башлыгы Иван Степанович Аксеновка һәм шул ук идарәнең баш инженеры Илдар Сәләхович Шәехсаттаровка йөкләделәр. Менә шулар инде бөтен Казанны бетереп, әле металл ватыклары өемендә, әле предприятиеләр ишегалдында күгәреп ятканны

табып, төрле диаметрдагы шактый гына торба тупладылар.

Төпкә «Трансгидромеханизация» трестының 480 нче төзелеш идарәсе җигелде. Эшне тизләтә төшү өчен аңа «Татнефтепроводстрой» трестының кайбер идарәләре дә ярдәм итте. Шәһәрнең инженерлык саклануы идарәсе, «Татспецстрой», «Казгражданпроект» трестлары һ. б. оешмаларның бүлекчәләре һәм аерым белгечләре дә тартылды. Төп эш көчен һәм белгечләрне Кабан тирәсендәге предприятиеләр бирергә тиеш иде. Скептиклар юравы буенча, мондый таркаулык эзерлек эшләренең генә дә 10—15 елга сузылуына китерәчәк иде. Гыйбрәтле мисалы күз алдында: «Гидроспецстрой» трестының Казан төзелеш идарәсе сигез ел эчендә Болакның нибары биштән бер өлешен генә реставрацияли алды. Анысын да проекттан тайпылгалап кына әле.

Ләкин шәһәр штабы пульпаүткәргеч төзелешен үз кулына алды. Штабта һәрбер эш көне кыска оператив киңәшмәдән башланып китте. Анда конкрет сораулар куелды: электриклар җитмиме? Кайчанга һәм ничә кеше кирәк? Шунда ук штаб членнарының берсенә шәһәр предприятиеләреннән тиешле санда белгеч табу йөкләнә. Элемтәчеләр җитмиме? Шәһәр элемтә идарәсенә шалтыратып, күпмедер вакытка кеше җибәрү турында килешәләр. Моның ише мәсьәләләр сәгать саен диярлек чыгып тора. Әмма алар сәгате-минуты белән хәл ителә. Ул гына да түгел, мондый өзеклекләр кабат тумасын өчен тиешле чаралар күрелә иде.

Пульпаүткәргечне театр бинасыннан танк училищесына кадәр Н. Николаев җитәкчелек иткән монтажчы слесарьлар бригадасы сузды. Баштагы биш километр ике ай ярым эчендә салынып бетте. Арырак аны В. Гребнев җитәкчелегендәге комплекслы бригада дәвам иттерде («Татнефтепроводстрой»ның 6 нчы идарәсе). Сазламыклы иң катлаулы урын туры килде аларга. Әмма зур тәҗрибә һәм көчле омтылыш эшне тиз арада менә дигән итеп башкарып чыгарырга мөмкинлек бирде.

Ярты ел дигәндә, унөч километрлы пульпаүткәргеч әзер иде инде. Арадаш дүрт насос станциясендә дә эш төгәлләнде.

Туфрак өемнәре белән читләнгән илле гектарлы мәйданны — ләм «склады»н әзерләргә кирәк иде әле. Агулы ләм җир асты суына үтеп кермәсен өчен комнан махсус «түшәк» юдырдылар. Штаб М. Галиуллин җитәкчелегендәге 348 нче земснаряд экипажының бу эшне гаять тиз башкаруын билгеләп үтте. Участок һәркайсы берәр гектарлы 48 тондыргычка бүленеп, алар бер-берсеннән бишәр метрлы валлар белән аерып куелды (ләм әнә шул калынлыкта юдыртылырга тиеш иде). Саклык йөзеннән, участок тагын бер махсус дамба белән уратып алынды.

Кабан тирәсендәге бер генә предприятие дә «өлешсез» калмады. Эш өч смена буена — көне-төне барды. Берәүне дә үгетлисе юк. Күлне коткарырга кирәк — һәркемне шул уй ашыктырды-җилкендерде.

Һәм менә 1983 елның 4 ноябрендә земснаряд машинисты Виктор Иванович Соловьев пульттагы тумблерларны күчерә, кнопкаларга баса башлады. Егерме метрлы рам, калтырангалап, әкрен генә суга күмелде. Тагын бер кнопкага баскач, рам очындагы кашыклы фреза хәрәкәткә килде. Торбаның дерелдәвеннән, ком бөртекләре ышкылган тавыштан аңладым: пульпа агыла башлады. Тик тиешле җиргә барып җитәрме ул?

Ялыктыргыч минутлар үтә. Ниһаять, телефон шалтырады. Трубканы бригадир В. Савельев ала.

— Пульпа унөченче километрга килеп җитте! Тизлекне арттыра аласыз.

Ул көздә земснаряд бер ай чамасы гына эшләп калды. Язын якын тирәдә яшәгән кешеләр, өмет һәм курку белән, кат-кат испәнделәр — сасы ис килми иде. Күпме гомергә беренче тапкыр!

Күл боздан арыну белән, земснаряд кабат эшли башлады һәм җәй буе туктамады. Кабан әйтерсең лә күкрәк тутырып сулыш алып куйды. Эссе көннәрдә аннан инде сасыган күкәй исе түгел, саф бер салкынлык бәреп тора башлады. Кабанга карап сокланып була иде инде. Үтә күрен-

мәле яшькелт суда күтәрү краннары, театр бинасының ак мәрмәр диварлары көзгедәгедәй чагыла... Бераздан яр буйларында камыш үсеп китте, күрән җете яшел төс алды. Очлы яфрак, җикән кебек күп еллар күренмәгән үләннәр дә баш калкытты. Шул елның июнендә күл өстендә беренче акчарлакларны күрдем. 1984 елның 14 июнендә беренче балыкчыга юлыктым. Театр янындагы бетон парапеттан тезләре сыдырылып беткән арык аякларын асылындырып утырган бу малай бик тә җитди кыяфәт белән калкавычка текәлгән иде. «Чиртмидер бит?» дигән аптыраулы соравыма җавап төсендә горур рәвештә консерв банкасына ишарә итте ул. Банкада, узышып-куышып, ике елгыр җилембалык йөзә иде! Бу баланы кочаклап үбә яздым.

Пычрану дәрәҗәсе 3,5—4 баллга төште, ягъни ике тапкыр кимеде һәм кимүендә дәвам итте. Земснаряд та тәүлек саен биш мең тонна чамасы сасы ләм боткасы суырып ала торды. Күз алдына китерегез әле: көн саен биш тонналы мең самосвал дигән сүз бит бу!

Бер тапкыр шулай земснаряд машинисты Виктор Иванович Соловьев белән сөйләшеп киттем. Якын Кабан төбендәге ләмнең күләме галимнәр исәпләгәннән күп өлеш артык булырга тиеш, диде ул. (Ахыр исәптә шулай булып чыкты да). Сүз иярә сүз китеп, ханнар хәзинәсе турында да сөйләштек. Виктор Иванович минем хикәяткә бик җитди карады, галимнәрнең күлне өйрәнү өчен шундый форсаттан файдалана алмый калуларына офтанып та куйды. Бер тапкыр земснаряд «тончыгып алган» икән: Гражданнар сугышы заманыннан калган маузер тыгылган. Очраклы рәвештә генә, әлбәттә; мондый зурлыктагы әйберләрне земснаряд гадәттә сизми дә йотып җибәрә.

Виктор Иванович әйтүенчә, тоткыч җайланмалы махсус рәшәткә куйсаң (шунда ук кәгазьдә сызып күрсәтте — гап-гади нәрсә) — шактый «ганимәт» җыярга мөмкин буласы икән. Хәзинә кадәресен үк әйтеп булмый, ә менә төрле савыт-саба, чүлмәк ватыклары, балык тоту әсбаплары кебек нәрсәләр өзелеп тормаячак. Күлнең төбе ташлы түгел, димәк, каты әйберләрнең һәркайсы диярлек археологлар өчен кызыклы булырга мөмкин....

1984 елдан башлап, күлнең хәле яхшыруга бәйле рәвештә, театр төзелеше дә тизләнеп китте. Аның тирәсендәге яр буен төзү аеруча кызу темп белән алып барылды. Бу эш «Казгражданпроект» институты проекты буенча башкарыла (авторлары — Ю. В. Гребнев, А. Я. Осокина, Р. Н. Җәлалетдинов). Күп хезмәт салуны сорый торган, чутсыз тимербетон йөта торган шактый кыйбатлы проект бу (бер як яр буен төзүгә генә дә алты миллион сум акча тотылсын әле!). Аның караві, мәңге тузмаслык итеп эшләнә.

Театр бинасы күлнең йөзек кашына әйләнде. Шәһәрнең күренекле урыны булып бәлешмәлекләргә дә теркәлеп өлгерде инде. Ул, бәлкем, тарихка да даны сүнмәс-сүрелмәс Кабан буе театры булып кереп калыр.

## 14

Болак шул хәлендә калган килеш Кабанны гына чистарту — кан тамырларын холестерин томалаган килеш йөрәкне дәвалау белән бер. Җитмешенче еллар башында бер очында Казан суыннан, икенче очында Кабаннан өзеп калдырылган Болак (ләм утыра торгач, аның төбе Кабанның су өсте биеклегеннән дә 1-1,5 метрга биегәя) сасы су җыелган озынча бер чокырга әйләнде. Санэпидстанция: Болак куркынычлы инфекция чыганагы булып тора, дигән нәтиҗә ясады. Аның черен барган суында һәм лайлалы ләмендә табигатьтә очрый торган чир таратучы бактерияләрнең бөтенесен дә тапканнар, имеш.

Болак мәсьәләсе ул елларда шәһәр Советы сессияләренең барысында да диярлек тикшерелеп торды. Бер-бер артлы проблемалы мәкалә

ләр, корреспонденцияләр басылды, фельетончылар. Болак турында язып, тапкырлыкларын чарлады. Хезмәт ияләреннән хатлар, шикаятьләр өзелмәде.

Ниһаять, кирәкле акча бүлеп бирелде. Тиз арада проект дигәнен эшләп ташлаганнар (авторларын ачыклау мөмкин эш булып чыкмады). Житмешенче еллар урталарында «Болак» операциясе башланып та китте.

Болайрак булды бу. Яр буйлап әрҗәле самосваллар чиратка баскан. Чылбырлары шалтор-шолтыр килүче, ачы төтенгә уралган куәтле экскаватор, гайрәтле селтәнеп, берничә куб сыйдырышлы чүмечен ләмгә батыра. Тик... сасы сыеклык чүмеч тешләре арасыннан агып бетә, чүмечнең мыегы гына чыланып кала. Суны куәтле насослар белән дә суыртып карадылар. Бусы да барып чыкмады, күчлерәк суырткан саен, сулы горизонтлар аша, яңа сыек ләм күбрәк керә торды. Болак Куйбышев сусаклагычыннан йөз метрлап кына арада бит. Ләмне суы белән чумырып алырдай чүмеч тә җайлап карадылар. Тик ул самосвал әрҗәсендәге ярыклардан акты.

Җыелган халык төрлечә теш агартты:

— Я, кем самосвал белән су ташый инде?!

— Тагарак белән ташысаң, тизрәк булыр иде!

— Земснаряд кирәк, егетләр! Иң кулае, иң арзанлысы шул...

Тик халык фикеренә колак салучы булмады. Экскаваторны күпергә куеп карадылар. Һәм ул, элегрәк ваткан яр буе рәшәткәләренә өстәп, күпернең таш култыксасын селтәп атты. Болак төбе анда ныграк дип, экскаваторны Казан суы ягыннан төшерергә булдылар. Тик бу иләмсез нәмәрсә шундук бата башлады. Әлеге сәер операция, асылда, шуның белән тәгәлләнде. Вакытның һәм акчаның калган өлеше экскаваторны «батырларча коткару»га сарыф ителде.

Хәер, бу юкны бушка авыштыруның да бер файдасы тиде: Болакны һәлакәттән «ура» кычкырып кына коткарып булмаячагы, техник яктан дөрес, төпле фәнни мөнәсәбәт кирәклеге ачыкланды.

Шәһәр житәкчеләре Ленинградның каналлар чистарту буенча зур тәҗрибә туплаган «Ленгипрогор» институтына мөрәҗәгать итәләр. Институт вәкилләре, Казанга килеп, эшнең торышы белән танышалар һәм... Әллә үз белдекләре белән, әллә кемнеңдер сүзенә колак салып, мәсьәләне «хирургик юл белән» хәл кылу вариантын тәкъдим итәләр. Болакны... күмеп, бик шәп автомагистраль саласың да, вәссәлам!

Беренче булып иҗат әһелләре каршы чыкты. Алар инешнең тарихи әһәмиятен аңлатырга тырыштылар: Болак ярлары Володя Ульяновны күреп белә, Толстой һәм Горький, Тукай һәм Такташ, Лобачевский һәм Бутлеров, Җәлил һәм Сәйдәшев монда ял итеп йөрергә яраткан. Болак турында күпме легенда, риваять бар, аңа багышлап шигырьләр язылган, җырлар чыгарылган. Болак шәһәр йөзендәге бер төсмер генә, әмма нәкъ менә ул Казанның тарихи үзәгенә мөкәммәллек бирә.

Архитекторлар исә сул һәм уң Болак урамнарының күп гасырлар дәвамында яр буе урамнары булып формалашуына һәм бу аларның «төскыяфәтләрендә» дә чагылуга дикъкать итәргә өндәделәр. Шактые үзләре дә архитектура һәйкәлләренә әйләнгән күперләрне кая куясың тагын?

Гидрологлар һәм шәһәрнең инженерлык саклануы вәкилләре Болак — шәһәрнең бизәге генә түгел икәнен искә төшерделәр. Ул элек-электән артык җир асты суларын суырып-җыеп торган, бу вазифаны әле хәзер дә үти. Болакның стадион янындагы очында урнашкан насос станциясе ел саен меңнәрчә тонна су суыртып чыгара бит. Болакны күмү белән, Куйбышев сусаклагычы кысып-этеп торган җир асты сулары якын-тирәдәге йортларның подвалларын басачак. Сусаклагычның су өсте биеклеге — диңгез өсте биеклегеннән 53 метрда, Казанның уйсулыкта урнашкан өлеше исә күбесенчә 50-52 метрда гына булуын истән чыгарырга һич ярамый.

Проектка хәтта ГАИ вәкилләре дә каршы иде. Аларның фикеренчә, транспорт агымын шәһәрнең үзәк өлеше аша үткәрү кулай булмаячак. Болай да хәттин ашкан шау-шу арта, һава пычрана. Әйләнеч юллар эзләвең хәерлерәк...

Шау-шулы тикшерүдән соң авторлар күпчелек тавыш белән кире кагылган проектны яңадан эшләргә булдылар һәм күпмедер вакыттан аның беркадәр үзгәртелгән вариантын тәкъдим иттеләр. Бусы да Болакны «күмә» иде. Тик, гидрологлар сүзен истә тотып, бу юлы төптә дренаж торбалары калдырылачак, ягъни Болак торба эченә яшереләчәк. ГАИ вәкилләре фикерен истә тотып, юл урынына бакча булдырырга тәкъдим ителә иде.

Бәхәс яңабаштан кызды. Бу вариант кайберәүләргә шул ягы белән ошады: ул проблеманы бөтенләй хәл итәргә мөмкинлек бирә, шәһәр сасы ис һәм инфекция чыганагыннан арынып кына калмыйча, өстәмә «яшел үпкә» дә ала. Шәһәр Советына хат арты хат юллап, якын-тирәдә яшәүчеләр дә кызган табага май өстәде: күмсәгез күмегез, томаласагыз томалагыз, сасысыннан һәм шакшысыннан гына коткара күрегез!

Болакның язмышы кыл өстендә калды.

Ләкин гидрологлар бу юлы да катгый рәвештә: «Юк!»— диделәр. Болак шәһәрнең уйсу өлешендә, шуңа күрә яңгыр һәм кар сулары шунда агып төшә. Язгы якта яки көчле яңгырдан соң проекттагы бакчаны 30—40 сантиметр биеклектәге су каплап алачак. Ул гына да түгел әле, дренаж системасы салып калдыру проектның бәясен арттырачак. Файдасы, ышанычлылыгы ачык каналныкыннан азрак булса да, үзе кыйбаткарак төшәчәк. Шул ук чыгымнар исәбенә, шәпләп чистартып һәм төзекләндереп, Болакны саклап калуың хәерле.

Экологик тигезлекне саклау зарурлыгы да исәпкә алына. Ул вакытта Кабанны агым сулы итү буенча берничә проект эшләнгән иде инде, аларның барысы да Болактан файдалануны күздә тота. Проектларның берсе менә мондый. Дамбадагы үткәрүчәнлеге махсус «калкан»нар белән үзгәртелә торган ерым аша су Куйбышев сусаклагычыннан биеклеге шул чама булган Югары Кабанга кертелә. Аннан ул махсус суташлагыч аша Монастырь бугазына, аның аша Урта Кабанга керә, шул рәвешле, Ботан бугазы һәм Якын Кабан аша үтеп, Болакка ага, насос станциясе суны Казан елгасына, ягъни кабат сусаклагычка кудыра.

Бу проект, аз чыгым тоткан хәлдә, бөтен системаны юдырырга мөмкинлек бирә. Һәм әле, күлләрнең хәленә карап, иң әйбәт режимда юдырып була. Тик моның өчен, күргәнегезчә, Болакның исән-аман булуы кирәк...

Менә шуларның барысын да бизмәнгә салып карагач, ленинградлыларның проектын кире кактылар.

Болакны реконструкцияләүнең бүтән проектлары да була. Берсе, әйтик, ярларны гына түгел, каналның төбен дә бетонлауны күздә тота. Болакны чистартуны нык җиңеләйтәчәк бу, әмма кыйбатка төшәчәк. Ник дисәң, төпне бетонлау ГЭС котлованын төзегәндәге кебек катлаулы шартларда алып барылачак, аерым участокларны шпунтлар белән аерырга, корытканчы суын суыртырга, бихисап бетон тотарга туры киләчәк. Ә файдасы ташка үлчим. Хәтта зыянлы да булачак әле: махсус калдырылган тишекләр тиз арада ләм белән томаланып, Болакның дренажлау сәләте юкка чыгачак.

Күп төрле экспертизалардан соң, ниһаять, «Казгражданпроект» институтының проекты кабул ителде. Ул менә нилэр күздә тота: авыш туфрак яр текә бетон стена белән алыштырыла. Стена читеннән, элек авыш яр булган җирдән, шәһәр өчен үтә кирәкле коммуникацияләр: җылылык трассасы, сүүткәргеч, магистраль канализация коллекторы уза. Яңгыр-кар сулары өчен махсус тондыргычлар төзелә. Болак, суның уртача тирәнлеге ике метрдан ким булмаган хәлдә, су өсте биеклеге Кабанныкы белән тигезләшерлек итеп тирәнәйтелә. Чистартканнан соң төпкә чуерташ һәм

эре бөртекле ком җәелә, бу исә дренажлау сәләтен тулысынча саклап калачак, ләм һәм пычрак аска саркып торачак.

Проект сиксәненче еллар башында тормышка ашырыла башлады. Бу эшне «Гидроспецстрой» трестының Казан төзү участогы алып бара (участок башлыгы — ТАССРның атказанган төзүчесе Виктор Афанасьевич Васильев). Беренче һәм соңгы торыклар реконструкцияләнде инде. Эш җиренә җиткереп, бөтен шартын китереп башкарыла. Яр читләп сигезәр метр тирәнлеккә сигез тонналы субайлар сугыла. Субайларны аксылсоргылт профильләнгән бетон белән тышлыйлар. Бер уңайдан күпер нигезләре дә ремонтлана.

Шулаен шулай... Әмма эш ифрат акрын бара. Сигез елда Болакның нибары биштән бер өлеше генә реконструкцияләнде, анда да әле — тирәнәйтелмәде, төпкә чуерташ, ком түшәлмәде. (Монысы ае-көне мәгълүм булмаган киләчәккә калдырылган). Болай барганда эшне тәгәлләү өчен тагын утыз елдан артык вакыт кирәк булачак.

Хәер, кайберәүләр фикеренчә, эшнең шулай сузылуы хәерле. Вертикаль бетон күрексез, элекке яшел авыш ярларны саклап калырга кирәк, ди алар. Күпме дефицит тимер-бетон материал кирәк булачак дип, дәгъваларын экономик яктан да нигезлиләр. Борчый торган башка нәрсәләр дә җитәрлек. Проекттан читкә китүләр күп. Әйтик, Болакны шунда да тирәнәйтмәсәң, кайчан тирәнәйтәсең? Утыз-кырык елдан соң, нигә эшләмәдегез дип сорар кеше дә табылмаячак. Юк, моны нәкъ менә хәзер, кул астында куәтле техника барында, акча «үзләштерелеп» бетмәгән чакта башкарырга кирәк. Минемчә, шәһәр башкарма комитеты эшне, проекттагы бөтен күрсәтмәләр җиренә җиткереп үтәлсә генә, кабул итәргә тиеш.

Янгыр суы өчен тондыргычлар да төзелми.

Проект Болакның тарихи бер өлешенә әверелгән яр буе тирәкләрен саклап калдыруны күздә тоткан иде. Аларны эшкә керешкәнче үк кисеп ташладылар. Бер очтан, менә дигән юкә аллеяларын да харап иттеләр.

Хәзер Болакның биштән дүрт өлеше балчык белән күмелгән, тирәнлеге бер метрдан артмый. Экологларның кисәтүенә дә карамастан, Болак Кабан белән киңлеге һәм тирәнлеге нибары бер метрлы бетон улак аша гына тоташып тора. Агым хасил итәр өчен бу бик аз. Проекттан читкә китүләр өчен кем җавап бирәчәк? Эшнең сыйфатын ничек яхшыртырга? Темпны ничек арттырырга? Бу сорауларны Казан шәһәр Советы башкарма комитетына юлларга туры килә.

## 15

Кеше белән бергә җир йөзендә уй-фикер дә барлыкка килгән. Нәкъ менә фикер йөртү сәләте кешене табигатьнең падишаһы, җирдә булган һәрнәрсәнең иң камил үрнәге итә. Ләкин кеше белән бергә җирдә чүп дигән нәрсә дә пәйда булды. Табигатьнең бөтен буыннары да миллионнарча еллар дәвамында бер-берсенә гаять дәрәҗәдә җайлашкан-көйләнгән табигый әйләнешенә сыя алмаган беренче җан иясе — кеше.

Табигатьнең сыгылмалылыгы, үз-үзен көйләү сәләте никадәр соклангыч булмасын, техник цивилизациянең хәзерге этабында табигать үз көче белән генә пычрактан арына, биосфераны тотрыклы хәлдә тота алмый инде. Шундый зарурият, мәсәлән, Байкал һәм Ладога күлләре янындагы целлюлоза-кәгазь комбинатларын ябу мәсьәләсен алга куйды. Бу гыйбрәтле ачы тәҗрибә табигать белән алыш-бирештә бүгенге көн файдасын гына күздә тоткан исәп-хисапка таянып эш итәргә ярамаганлыгын бик тә ачык күрсәтә. Ахыр исәптә бу табигатьнең дә, кешенең дә харап булуына китерә. Аларны бер-берсенә каршы куярга ярамый, чөнки кеше — табигатьнең үсеше нәтиҗәсе генә түгел, аның аерылгысыз бер өлеше дә әле ул.

Кабан күле Казан халкы өчен генә түгел, бөтен Идел артериясе

өчен дә куркыныч тудыра. Моны һич истән чыгарырга тиеш түгелбез. Хәер, эш истә тоту, аңлауга гына да терәлмәгән. Предприятиеләрдә, мәсәлән, һәркемнең табигатьне пычратуның зарарын яхшы аңлавына ышанасың. Шуңа да карамастан, пычрата торалар... Бурыч, күрәсең, экологик аңлылыкны әхлак нормасына, үз-үзеңне тоту кагыйдәсенә әйләндерүдән гыйбарәттер.

Кабанны коткарып калу өчен бүген нәрсә эшләргә кирәк?

Кабан комиссиясе тәкъдимнәрендә бу бурычлар бик тә төгәл тәгъбир ителгән. Аларның иң мөһимнәрен кабат искә төшерик.

Беренче чираттагы бурыч — бөтен төр агынтыларны да бетерү. ТАССР Министрлар Советы карарында моның иң соңгы катгый срогы итеп 1990 ел билгеләнгән. Кайчандыр бу бик ерак ара булып күренә иде, инде менә килеп тә җиткән дияргә була. 1970 елдан башлап бер-бер артлы билгеләнә һәм өзелә барган сроклар кебек, монысы да өзелерме?

Булган агынтыларны туктату белән бергә, яңаларын булдырмау да зарури. Әмма синтетик каучук производство берләшмәсе хәзерге вакытта реконструкцияләнеп ята. Проектка караганда, заводның житештерүчәнлеге алдагы елларда бермә-бер артырга тиеш. Күлгә ага торган агулары, һавага оча торган дәһшәтле төтеннәре дә бермә-бер артмасмы?

Шул уңайдан тагын бер сорау туа: реконструкциягә дип бирелгән уннарча миллион сум акчаны башкача тотып булмый идемени? Хәзер Ереван шәһәрендә урнашкан химия заводларын ябып, аларны башка урынга күчерү мәсьәләсе килеп басты. Ни өчен соң без, казанлылар, калабызның нәкъ үзәгендә борынгы изге күл буенда салынып яткан искиткеч зарарлы химик производствога битараф карыйбыз? Аны башка җирдә дә салып булыр иде бит...

Бездә мохитны саклау турында Закон бар. Законны бозучы исә, кеше үтерәме, күлне тончыктырамы, казна милкенә кул сузамы, халык байлыгы булган чиста су ресурсларын юк итәме — барыбер җинаятьче ул. Без исә еллар буенча аларны оялтмакчы яки үгетләмәкче булабыз, күп дигәндә, табигатькә китерелгән зыянны һичничек капламый торган символик штрафлар белән «куркытабыз».

Кабан төбен чистарту дәвам итә. 1987 елның азагына ярты миллион тоннадан артык ләм чыгарылды. Хәзер эш иң кыен урыннарга — Вахитов күпере, Ботан бугазы һәм тимер юл күпере тирәләренә җитеп бара.

Кабан комиссиясе, яңгыр суы коллекторлары, тондыргычлар төзү, төптәге катламнарга һава өрдерүне дә кертеп, эшне комплекслы алып барырга тәкъдим итә. Әмма коллекторлар һәм тондыргычлар төзүнең проектлаштыру стадиясен үтә алганы юк әле. Һаман бәхәсләшәләр: аерым, резервуар тондыргычлар төзергәме (сүз уңаеннан, шактый кыйммәткә төшәләр, туктаусыз карап-көйләп тору сорала, өстәвенә, нәтиҗәлелеге дә чамалы гына) яисә бөтен күл системасына берне — шәһәр чистарту корылмалары кебекнеме? Пай кертү тәртибендә, Кабан буендагы предприятиеләр исәбенә төзегәндә бу эш реаль күренә.

Суга һава өрдерү системасы да гаять нәтиҗәле булачак. Казан компрессор заводында компрессорларның бер өлеше эшләнде инде. Кайбер галимнәр бу система үзе генә дә проблеманы тулаем хәл кылырга мөмкинлек бирәчәк дип исәпли: окисьлашу процесслары уннарча тапкыр тизләнәчәк бит. Күл асылда күпмедер микъдарда промышленность һәм хуҗалык агынтыларын да эшкәртергә сәләтле мөстәкыйль чистарту корылмасына әйләнәчәк. Системаның бер генә кимчелеге бар: эксплуатацияләү кыйммәткә төшә, болай да житми торган электр энергиясе гаять күп тотыла. Димәк, төрле-төрле вариантларны сынап карарга, иң отышлысын сайлап алырга кирәк.

Кабанны коткаруга бүлеп бирелгән акчаның төп өлешен хәзер ярны төзекләндерү чыгымнары йотып бара. Зур-зур төзелеш оешмалары, куәтле техника җәлеп ителгән. Театр урнашкан урыннан алып, Кабан яр буйлары танымаслык булып үзгәрә бара.

Шәһәрне үстерүнең перспектив планында күлнең төньяк-көнчыгыш яры буйлап метро линиясе салу күздә тотыла. Буш җирләр, чүплекләр, тузып беткән бер катлы йортлардан торган кварталлар монда линияне иң арзанлы ачык ысул белән салырга мөмкинлек бирә. Бу төзелеш шәһәрнең әлеге аеруча шыксыз, ташландык өлешен төзекләндерер, матурлар дип ышаныйк.

Экономистлар исәпләвенчә, күлләр, бугазлар һәм алар тирәсендәге мәйданнарны тулысынча реконструкцияләү, дамбаларны рәтләү һәм төпне чистарту, суга һава өрдерү һәм чистарту корылмалары салуны да кертеп, йөз миллион сумнарга төшәргә тиеш. Шәһәрнең моннан гайре дә кечектергесез проблемалары бихисап икәнен уйласаң, кыйбатрак тоела. Ләкин экологлар табигатьне саклауда акча «кысу»ның тагын да кыйбаткарак төшәчәген әйтәләр. Сүз кешеләрнең сәламәтлеге турында бара бит. Аллергия, тире авырулары, онкологик чирләр, тын юллары ялкынсынуларының артканнан-арта баруы, күп кенә галимнәрнең фикеренчә, асылда мохит пычрану нәтиҗәсе булып тора. Димәк, бирелгән акчаны тота белергә, максатларны һәм аларга ирешү эзлеклелеген дөрес билгеләргә кирәк.

Шушы максаттан чыгып, шәһәрнең берләштерелгән экология хезмәте булдырыла. Аңа экологлар да, биологлар, медиклар, психологлар, архитекторлар, философлар да җәлеп ителә. Әлбәттә, язучылар да читтә калмас.

Университетның теоретик кибернетика кафедрасында Кабан күленең электрон-хисаплау моделе эшләнгән. Электрон-хисаплау машинасы, теге яки бу тискәре фактор калган тәкъдирдә, күлнең ничек үзгәрүен һәм аларны нинди эзлеклелектә бетерә барырга кирәклеген шактый төгәл исәпләргә һәм тагын күптөрле сорауларга анык җавап алырга мөмкинлек бирәчәк.

Бу «акыллы» модельнең авторы — математика фәннәре кандидаты Юрий Валентинович Голунков. Аның белән очрашып, берничә сорау бирәм.

— Юрий Валентинович, югары математик белеме булган гади диспетчерлар электрон-хисаплау машинасын тыңлата алырлармы? Сез аларның һәркайсы янында басып тормассыз бит инде.

— Булдырырлар дип уйлыйм. Бик гади модель бу. Бер-ике дәрестән соң өлкән класс укучылары да эш итә алачак. Аннан, модель операторны үзе өйрәтә, теге яки бу очракта нишләргә кирәклеген әйтеп тора бит ул. Модельнең асыл максаты да шул — экологик хаталарны булдырмый калу.

— Бик тә кыйммәтле «уен» түгелме бу? Шаукымга ияреп, кыйбатлы машиналар, программа сатып алып та, аларны эшсез тоткан предприятиеләр бар.

— Исрафчыллык турында әйтәсезме? Ә ул нәрсә хисаплау машинасына бәйләнмәгән бит. Хаталар кыйммәткәрәк төшә. Экономик яктан гына түгел, экология җәһәтеннән дә,— машинаны куллану отышлы.

— Аны бүген үк практикада кулланып булмыймы соң?

— Юк. Моның өчен алдан кайбер шартлар үтәлергә тиеш. Иң әүвәл, контроль хезмәте булдырырга кирәк. Машинага күлнең хәле турында мәгълүмат биреп торучы санитар-контроль постлар кирәк. Икенчедән, суның сыйфатына тәэсир итәрлек нәрсәләр — агым хасил итү, су кудыру, һава өрдерү системалары һ. б. булдырылырга тиеш. Бу модель кирәкмәс җирдән күлгә һава өрдереп, энергияне әрәм-шәрәм итмәс өчен, күлгә тәэсир итүнең иң отышлы вариантын табып, иң уңайлы режим тоту өчен иҗат ителде.

— Шартларның иге-чиге юк. Ирексездән болай дип уйлап куясың: ничек соң әле күл, боларның берсен дә белмәгән килеш, меңнәрчә еллар буена экологик тигезлекне саклап килә алган? Пычрак су агызудан баш тартып, җәрәхәтләрен төзәтүне күлнең үзенә тапшыру дөрес булмасмы?

— Дөресен дөрес тә ул, тик әрәмәлекләрне,камышлыкларны күлгә кайтарып бирә алмыйсыз бит. Бүтән бер аварияга дә юл куелмас дип тә әйтеп бетереп булмый әле. Модель күлнең нәкъ менә хәзерге цивилизациянең гигант басымы астында яшәүгә бәйле реаль шартларны күздә тотып төзелгән.

Сүз уңаеннан, әлеге модель, экология җәһәтеннән караганда, бетон ярның файдасы гаять аз булуын күрсәтә. Суны камыш, күрән, тал куагы үскән сөзәк яр бик шәп чистарта икән. Күл камышы, әйтик, пестицидлар, фенол һәм авыр металл кушылмаларын (шул исәптән, терекөмешне дә) һәм нефть продуктларын суырып ала икән (концентрациясе һәм микъдарына карап, әлбәттә). Кызык: мондый матдәләрнең сабакта һәм яфрактагы концентрациясе судагыдан ун мең өлеш күбрәк була ала икән.

Боларның бөтенесен дә исәпкә алып, университетның табигатьне саклау кафедрасы Кабан күлләре системасын республика күләмендәге табигать истәлеге итү турында закон проекты эшләде һәм аны хөкүмәт органнары каравына кертте. Проектта күл тирәсендәге буш урыннарда 50-100 метр киңлектәге яшел зоналар булдыру каралган. Мондый зонада ни дә булса төзү тыела, ул бары ял итү, балык тоту өчен генә файдаланылачак. Проект суны чистарту гына түгел, күлнең балык хәзинәсен яңарту эшләрен дә күздә тота. Мөмкин эшме бу?

Берничә ел элек Оренбургтагы дусларым мине соклангыч бер күлгә алып бардылар. Җете яшел зирек, тал куакларына, камышка күмелеп утырган зәңгәр күл өстендә кара болыт булып киек кошлар бөтерелә.

Күлнең Оренбург газ эшкәртү заводы агынтыларыннан хасил булганлыгын белгәч, исем китте. Хикмәте гади икән үзе: баштан ук табигатьне мөмкин кадәр саклауны максат иткәннәр монда. Чистарту корылмалары дирекциянең дә, җәмәгать оешмаларының да күз уңында. Иң яңа сепараторлар кулланалар, агулы катнашмаларны нейтральләштерүнең иң шәп әмәлләрен эзлиләр, кислород өрдерү һәм биологик чистарту кулланалар.

Мондый мисаллар тагын да бар. Идел дельтасындагы Зур Лиман дигән ясалма сулык турында газеталар күп язды. Лиман асылда Волжский шәһәре чистарту корылмалары тезмәсендәге соңгы буынны тәшкил итә. Ике йөз мең кешеле кала һәм зур-зур нефть-химия предприятиеләре суларын шунда агызалар. Ләкин — бары химик, механик һәм биологик чистарту үткәннән соң гына.

Зур Лиман түбән Иделнең балыкка һәм киеккә бай табигый лиманнары арасында да аерылып тора. Балык монда хәттин ашкан, аккошлар, челәннәр йөзеп йөри, башка төрле кошлар көтүләре белән оя кора.

Мин, әлбәттә, Кабан күлләре тирәсенә дә яңадан көтү-көтү кабан дуңгызлары әйләнеп кайтыр дип өметләнмим. Ләкин кешенең үзе харап иткән соклангыч, гаҗәеп табигый сулыкны тормышка, табигатькә кабат кайтарып бирми калдырырга хакы юк...

Бу әсәрне язып йөргәндә барыннан да элек ханнар хәзинәсе кызыксындырган кешеләр белән күп тапкырлар очрашырга туры килде. Мине урамда барган җирдән туктаталар, өйгә шалтыраталар.

— Шулай да Кабан төбендә хәзинә бармы, юкмы?

Алдарак язганнарга өстәп ни әйтим икән? Бәлкем бардыр, ә бәлкем юктыр да. Табышмак чишелмәгән килеш кала. Эзләргә атлыгып торучылар да аз түгел. «Конкрет нәрсә эшли алабыз? Нидән башлыйк?» — дип сорайлар алар. Инициатив группа төзүдән башларга киңәктер, минемчә. Яшьләр группасы була ала ул. Бәлкем, студентлар группасыдыр. Легендалар, риваятьләр җиле кагылган тарихи табышмакның җавабын яшьләр эзләми кем эзләсен ди?

Шулай да фараз ителгән хәзинә тирәсендәге шау-шуның төп нәрсәне каплап китүен теләмәс идем мин. Бәһаләп бетергесез иң зур хәзинә — Кабан үзе, аның көмеш суы, зәбәрҗәт яры, сихәтле кислород белән мөлдерәмә тулы фирүзә һавасы икәнен онытмыйк әле!

## ӘДӘБИ МИРАС

# МӘҖМУГЫ-Л-ХИКӘЯТ

## Патша кияве «Җәбраил» маҗаралары



Хәбәрләрне сөйләүчеләр һәм әсәрләрне күчерүчеләр болай бәян кылдылар: бер шәһәрдә балта остасы һәм тукучы бар иде. Икесе дә үз эшенә шулкадәр оста иделәр — ул заманда аларга тиңнәр юк иде.

Бәхетсезлеккә каршы, икесе дә бер үк хатынга гашыйк булдылар, әмма һәр икесе бер-берсенең бу хәленнән хәбәрдар түгел иде. Әлеге хатын матурлык иясе иде, бик күркәм иде. Күңеле белән балта остасына күбрәк тартыла иде. Ләкин тукучының көче, кыюлыгы балта остасыныкына караганда артыграк иде: вакыт-вакыт бу хатынны көч белән куркытыр һәм хатын, чарасыздан, аның белән булыр иде.

Шушы рәвешчә беркадәр вакыт үтте. Тукучы, бөтен осталыгын эшкә җигеп, әлеге хатын өчен шундый бер күлмәк тукыды ки, ул күлмәкнең итәге һәм якасы тәмам тоташ иде, бер генә җөе дә юк иде. Ул күлмәкне бөтен шәһәрдә күрсәтеп йөрделәр, һичкемнең мондый күлмәк тукырга кодрәте җитмәде һәм барысы да тукучыны бик мактадылар.

Балта остасы бу күлмәкне күрде, ачуы килде. «Тукучының бу хатын белән гыйшкы бар икән»,— дип уйлады һәм әлеге уен хатынга да белдерде. Хатын балта остасын бик якын итә иде, аулак җирдә утырганда әйтте:

— Белеп тор һәм аң бул: синең бер бөртек чәчең дә миңа тукучының башыннан газизрәк. Мин, янавыннан куркып кына, аның белән ирексездән сөйләшеп утырам, аның күңел кайтаргыч гәүдәсен күрүгә, кургашындай эримен һәм яфрактай калтырыймын,— диде. Балта остасы җавап бирде:

— Әгәр аңа күңелең ятмаса, мин сине ул явыздан коткарам,— диде. Хатын әйтте:

— Син теләсәң, мин аны исертеп һәлак итәм,— диде. Балта остасы әйтте:

— Ул эш синең өчен мәшәкатьле булыр. Мине чынлап дус итсәң, мин тукучыны шундый хәйлә белән юк итәм — галәмдә һич кеше аның эзен тапмас,— диде.

Балта остасы тукучы янына барды. Әйтте:

— И туган! Ул күлмәкне шундый сыйфатта тукыгансың, бөтен тукучыларның борынына чиртеп, үзләрен бер капчыкка тыгып куйдың. Мин дә шулай, бөтен һөнәремне күрсәтеп, башка балта осталарын аста калдырсам иде,— диде. Тукучы әйтте:

— Мөбарәк булсын, әгәр миңа хаҗәтең төшсә, мин сиңа ярдәм итәм.

Балта остасы такталар әзерләде, бөтен кодрәтен һәм осталыгын биреп, бер сандык ясады. Тәмам булгач, тукучы янына барды:

— Агачтан бер нәрсә ясадым, һичкемнең андыйны күргәне юк. Миңа ярдәм итсәң һәм минем белән сахрага барсаң икән. Таулы җир булмасын,

Ахыры. Башы 9 санда.

тип-тигез дала булсын. Бу тылсымны кулланып, сынап карыйк, аннан соң балта осталарына белдерербез,— диде.

Тукучы риза булды.

Шәһәр читендә бер тигез дала бар иде, сандыкны шунда алып килделәр. Балта остасы сандыкның авызын ачты, аннан соң тукучыга әйтте:

— Киемнәреңне салып, бу сандыкка кер, ә мин сандыкның житешмәгән җирләрен күрим,— диде. Тукучы, киемнәрен салып, ялангач булып, сандыкка кереп утырды.

Сандыкның эчендә ике чөй бар иде, берсе — уңда, берсе — сул ягында. Уңдагысын борса — сандык күккә менәр, сулдагысын борса җиргә төшәр иде. Балта остасы беркатлы тукучыга уңдагы чөйне күрсәтте һәм әйтте:

— Монысын бор! — диде.

Тукучы, мескен, уң кулы белән борды — сандык, кош кебек, һавага күтәрелде. Тукучы күпме борса, шуның кадәр биегрәк күтәрелер иде. Шулай итеп, балта остасының күзеннән дә югалды.

Сандыкның тәрәзәләре бар иде, тукучы түбәнгә карады: җиһанда нинди төзек һәм җимерек урыннар булса — һәммәсен күрде. Күңеленнән әйтте:

— Аһ! Балта остасы мине бәлагә дучар иткән икән!..— диде. Шулкадәр курыкты, йөрәге ярылырдай булды. Ниһаять, сул яктагы чөйне борды, сандык түбәнәя башлады, җиргә якын килеп, бер утрауга төште. Тукучы сандыктан чыкты, бераз йөрде, бу нинди урын икәнен белмәс иде, тирә-юне су иде. Һәр тарафка йөреп, төрле җимешләрдән авыз итте. Көтмәгәндә күрде: диңгез читендә ике-өч кеше йөри иде. Барып сәлам бирде, алар җавап кайтардылар. Һәм әйттеләр:

— Син ни кеше һәм бу җирдә ни эшең бар?

Тукучы әйтте:

— Мин ерактан килгән кеше, юлымнан адаштым, миңа коры җиргә юл күрсәтегез әле? — диде. Тегеләре:

— Бу — Гомман диңгезе, ә без — энҗе эзләүчеләр. Сиңа бу утраудан чыгарга кирәктер. Бу диңгезнең уң тарафында шәһәр бар, үзеңне анда җиткер,— диделәр. Тукучы үз-үзенә әйтте:

— Әгәр сандыкны монда куеп, җәяү барсам — куркам, һәлак булырмын. Яхшысы шул булыр: сандыкка керим, бөтен серләрен белим, чөйне борып, һавага очып, бу утраудан чыгыйм,— дип сандыкка утырып, чөйне боргалап, һавага күтәрелде. Өскә күтәрелгәч, аска карады, еракта бер зур шәһәр күрде. Сулдагы чөйне боргалап, шул шәһәрдән ерак булмаган бер урынга төште. Сандыктан чыкты, бер мәһабәт сарай күрде, сарайның капкасы тимердән ясалган иде. Карап-карап торды — һич кеше күрмәде. «Бу нинди җир икән? Бу сарай турында кайдан хәбәр белешим икән?» — дип, хәйран булып, гаҗәпләнеп, як-ягына караныр иде. Ниһаять, шунда нәрсәләр төзәтеп ятучы бер кешене күрде. Барып сәлам бирде:

— Бу сарай кемнеке? — дип сорады. Тегесе әйтте:

— Син читтән килгән кешеме әллә? — диде. Тукучы:

— Әйе, читтән килдем, бертуганымны югалттым, шуны эзләп йөрим,— диде. Ул кеше әйтте:

— Бу сарайны Гомман патшасы салдырган иде. Аның сәбәбе шул: патшаның бер чибәр кызы бар, аның кебек зат бөтен дөньяда юк диләр, туганнан бирле аны һичкемгә күрсәткәннәре юк. Бары тик патша үзе генә килеп, кызының йөзен күреп китә,— диде.

Тукучы, бу сүзләрне ишеткәннән соң, яшеренгән җиренә кире кайтты, кич булганчы сабыр итте. Менә кич җитте, якты дөнья кара дию төсле караңгы булды. Тукучы халыкның татлы йокы вакытында сандыкка керде һәм, чөйне боргалап, сарай түбәсенә төште. Сандыктан чыкты, сарай эченә төшеп, кыз бүлмәсенә керде, аны кочагына алып, шикәр кебек иреннәреннән үбә башлады. Кыз кинәт уянды, үзен ят бер ир кочагында күрде, куркып кычкырды:

— Син ни кеше, ни өчен мондый әшәке хәрәкәтләр кыласың?

Аның авазына даясе[1] уянды, ут яндырып өйне яктыртты. Күрделәр: бер ялангач кеше басып тора. Әйттеләр:

— Син кем, нинди кеше буласың!

Тукучы әйтте:

— Мин — Җәбраил булам, мине аллаһы тәгалә җибәрде. Күкнең жи-

---

[1] Дая — сөт анасы

денче катында бу чибәрне миңа багышлап никахладылар һәм мине кияү итеп җибәрделәр,— диде. Дая белән кыз аның сүзенә ышандылар, үз-үзләренә әйттеләр:

— Бу сарайга кош та очып керә алмас, өйнең ишекләре тимер чыбыклар һәм йозаклар белән бикләнгән. Сарайга шушы ялангач хәлдә Җәбраилдән башка беркем дә үтеп керә алмас иде,— диделәр. Кыз әйтте:

— Мөбарәк булсын, аллаһы тәбарәкә вә тәгалә мине сиңа тиң кылып тора икән, миңа да, атама да моңа шөкер итәргә, тиешлесен үтәргә кирәк булыр,— диде. Шулай итеп, чибәр кыз тукучыга буен куйды, тукучы теләгенең ачкычы белән аның кызлык йозагын ачты.

Күрәсең, кызның атасына бер мөһим эш төште, бер ай буе сарайга килмәде. Тукучы, һәр көн кич белән килеп, таңга кадәр кыз янында булды, иртә белән генә китә иде. Кыз йөккә узды.

Көннәрдән бер көнне кызның атасы сарайга килде. Кызы янына керде, кызын элеккеге хәлендә күрмәде. Даясеннан сорады:

— Моңа нәрсә булды? — диде. Дая булып үткән хәлләрне сөйләп бирде, әйтте:

— Аллаһы тәгалә, синең кызыңны Җәбраилгә никахлап, сиңа кияү җибәргән. Һәр төнне Җәбраил килә, таң атканчы кызыңның күңелен күреп, иртә белән китә.

Патша бу сүзләргә чиктән тыш гаҗәпләнде, вәзиренә әйтте:

— Кеше ышанмаслык ни эш икән бу? — диде. Сарайның тирә-юнен, як-ягын яхшылап карадылар — һичбер җирдә кеше эзен күрмәделәр, гаҗиз булдылар. Патша үз-үзенә әйтте:

— Бу һич булмаган эшләрдәндер. Шушы кадәр бикләр белән ныгытылган сарайга ничек юл табарга мөмкин? Мин бу төндә сарайны саклыйм, шаять, баш бутагыч бу вакыйгалар серен белермен,— дип, коралланып, кылычын кулында тотып сакта торды.

Төн уртасында, гадәтенчә, сандыкка утырган тукучы сарай өстенә төште. Сандыкның түбәгә төшкән авазы шаһның колагына ишетелде һәм ул кинәт һушыннан китеп егылды. Аннары акылына килде, кызы янына ашыкты. Аның янында тәмам ялангач хәлдә утырган тукучыны күреп:

— Хуш килдең, аллаһы тәгаләнең якыны, фәрештәләрнең башлыгы! — дип, күзләреннән яшь агызып, аягына егылды. Кыз әйтте:

— И Җәбраил! Бу — минем атам,— диде. Тукучы мөбарәк кулы белән шаһның башын-йөзен сыйпады, маңгаеннан үпте. Патша аның аяк-кулын үбеп, тагын аягына егылыр һәм эченнән горурланып: «Кем уйлаган, Җәбраил минем киявем булыр дип! Бу — минем өчен бәхет!..» дип уйлар, аллага шөкер итәр, мактау сүзләрен укыр иде. Ахырда өенә кайтып, йокларга ятты.

Тукучы, кыз кочагына кереп, күңеленә рәхәт тапты. Таң якынлашканда, кызны йокыда калдырып, түбәгә чыкты, сандыкка кереп, үзенең яшеренгән җиренә очып китте.

Кыз уянды, тукучының үз яныннан киткәнен белде. Торып, атасы янына барды. Атасы уянды, сарай түбәсенә чыкты. Нәкъ шул вакытта күктә йолдыз атылды. Шаһ ул йолдызны күреп:

— Алланың ишеге ачылып, Җәбраил югары китеп бара,— диде. Шунда ук йөзен җиргә куеп, догалар кылды. «Җәбраилнең киявем икәне чынлап та дөрес икән»,— дип уйлады һәм, югарыдан төшеп, кызына әйтте:

— Зинһар, Җәбраилнең хезмәтенә һәрвакыт әзер бул, мөмкинлегең җиткән кадәрле җаена тор. Мин кайтып, аңа лаек төрле-төрле әйберләр һәм яхшы киемнәр хәзерләп җибәрәм,— диде. Кыз әйтте:

— Инде кырык көн Җәбраил өебезгә килеп йөри, бу вакыт эчендә бер тамчы су һәм бер кисәк азык капканы юк,— диде.

Таң аткач, патша сарайдан чыкты, капкаларны бикләп, шәһәренә кайтып китте. Шунда ук берничә букча затлы кием, күп төрле азык-төлек хәзерләп, кызына җибәрде. Әйтте:

— Бу бүләкләрне Җәбраил киявемә бирсен, тагын да хезмәт итәрмен,— диде.

Ә бу төнне тукучы, Гомман шаһының үз сараена очып барып, түбәсенә төште. Төнлекләрдән карап йөрде, сарай эчен күзәтте. Йөри торгач, бер бүлмәдә падишаһны күрде. Ул вәзире һәм өч-дүрт түрәсе белән утыра иде. Беркатлы падишаһ вәзире һәм түрәләренә кияве турында хикәятен сөйли

иде. Падишаһның якыннарыннан берсе акыллырак иде, патшаның бу хикаятенә каршы төшеп әйтте:

— И падишаһ! Бу бер дә урынсыз эш инде: синең кебек атаклы һәм акыллы патша мондый буш хыялга бирелгән икән. Ул кеше сихерче булырга тиеш, сихер һәм әфсен белән үзен шундый хәлдә күрсәтеп, шул әфсеннәр белән синең башыңа хурлык салыр,— диде. Патшаның бу сүзгә ачуы килде, кырыслык белән әйтте:

— Әгәр үз күзем белән күрмәсәм, синең сүзең дөрес булыр иде. Мин аны ачыктан-ачык күрдем, Җәбраил килде һәм китте, киткәндә артыннан карап калдым, ул киткәндә күкнең ишекләре ачылып торды,— диде. Әмма, патша бу турыда күпме генә дәлилләр китермәсен, теге әдәм үз сүзеннән кайтмады. Шул вакыт тукучы төнлеккә кулы белән сукты һәм, кирпечләр алып, шаһның, вәзир һәм түрәләрнең өстенә ташлады. Бер кирпеч, теге туры сүзле әдәмнең башына төшеп, берничә җирендә җәрәхәт ясады. Шаһ, вәзир һәм түрәләр бу хәлне күреп, өйнең түшәме ишелә дип уйлап, өйдән чыгып качтылар. Патша аларга әйтте:

— Күрдегезме инде Җәбраилнең могҗизасын! — диде. Һәммәсе гаҗәпкә калдылар һәм өйләренә таралыштылар.

Тукучы сандыкка кереп утырды, кыз сараена очып барды. Кыз янына кереп, әйтте:

— Синең атаң минем турыда вәзире һәм ярдәмчеләренә сөйләде. Ләкин бер ярдәмчесе моңа каршы төште, ышанмады. Ходай тәгалә аңа газап итү өчен, Газраилне җибәрде. Ачуы килеп, һәммәсен, һәлак итмәкче иде. Әмма мин, җир үбеп, алладан шәфкать сорадым һәм атаң хөрмәте өчен аларны үлемнән алып калдым,— диде, үткән вакыйгаларны сөйләде.

Ә патша, йокыдан уянгач, вәзир һәм ярдәмчеләрен җыйды:

— Торыгыз, Җәбраилгә барып, үтенечләребезне белдерәбез һәм аннан безгә булышлык итүен сорыйбыз,— диде. Һәммәсе кызның сараена бардылар. Патша ишеккә килеп, бикләрен, йозакларын күрсәтте:

— Яхшы карагыз: бу сарайга кош та очып керерлек түгел,— диде. Сарайның нык бикләнгән булуын күреп, барысы да хәйран калдылар. Кыз атасын күрде, янына төшеп, аяк-кулын үпте, атасына әйтте:

— И атам, җаным! Җәбраилнең хәлен башыннан ахырынача бу кешеләргә әйт, ишетсеннәр. Кичә сездә үткән вакыйганы син сөйләми тор, ул вакыйганы мин сөйләп бирим,— диде. Патша:

— Сөйлә, ул ни вакыйга? — диде.

Кыз кичә аларда булып узган бөтен вакыйгаларны — ходай тәгаләнең Газраилне җибәргәнен, Җәбраилнең аларны йолып калуын һәм бер туры сүзле әдәмнең яраланганын — һәммәсен сөйләп бирде. Патша һәм аның белән килгән кешеләр, бу хәлләрне ишетеп, һәммәсе гаҗәпкә калдылар һәм әйттеләр:

— Һич шик юк, ул — Җәбраил,— диделәр. Кызының аягына төштеләр:

— Безгә ярдәм ит һәм Җәбраилгә әйт: күңелен хуш тотсын, моннан соң без аңа каршы сүз әйтмәбез,— диделәр. Әмма әлеге яраланган адәм күңеленнән генә әйтте: «Әгәр аллаһы тәгалә мине бу усаллыгым өчен гафу итмәсә дә һәм тәмугка салып ачуын алса да, мин һичбер вакыт Җәбраил патша кызы белән якынлык кылучы икән дип уйламам. Бу уйнашчы кеше үзен әфсен һәм сихер белән «Җәбраилмен» дип әйтер»,— диде.

Аннан соң патша ярдәмчеләре белән шәһәргә кайтып китте, һәрвакыт яңадан-яңа бүләкләр җибәреп, «Җәбраил»нең күңелен күрер иде.

Тукучы, һәр төн килеп, кыз белән таңга кадәр күңел ачып, тиешле вакытта кайтып китә иде. Һәм һәр кичне аның өчен яхшы-яхшы матур киемнәр, төрле-төрле тәмле ризыклар хәзерләнгән була иде. Ул шул ризыкларның һәрберсеннән берәр кисәк яшереп алып, сандыкка салып, үзе белән алып китеп, туйганчы сыйлана иде. Шулай итеп шактый вакыт үтте. Кыз бу арада ай кебек матур йөзле бер ир бала тапты.

Әмма алга таба вакыйгалар үзгәреп китте. Атасы бу кызны, кече яшеннән үк, бер патша улына багышлаган иде. Ул падишаһ, вакыты җиткәч, кызны сорап илчеләр җибәрде. Бу падишаһ аңа мондый җавап юллады:

— Минем кызымны ходай тәгалә Җәбраилгә никахлаган. Һәр төнне күктән Җәбраил иңеп, кызым белән бергә булып китә. Һәм бу сәгатьтә минем кызымның улы дөньяга килде.

Патшаның бу хәбәрен ишетеп, аны ахмакка һәм тилегә санадылар. Ачулары чыгып, күп итеп гаскәр җыеп, Гомманга таба чыгып киттеләр. Чиксез гаскәр белән килеп, Гомман шәһәрен көтмәгәндә камап алдылар.

Гомман падишаһының түзеп торырлыгы калмыйча, ныгытма эченә

кереп бикләнде, гаҗиз һәм чарасыз булып, кызына язу җибәрде: «Җәбраилгә әйт, әгәр миңа булышмаса, минем бөтен байлыгым җилгә китәр», дип язды. Кыз бу хәлне тукучыга белдерде. Тукучы әйтте:

— Бу кичә сабыр ит, мин барып аллаһы тәгалә хәзрәтләренә белдерәм, илбасарларга газап җибәрсен,— диде.

Таң атты. Тукучы үз эшенә китте: ул көн кичкә кадәр таш җыеп, сандыкка тутырды. Төн уртасында сандыкка кереп, һавага күтәрелеп, дошман падишаһының чатыры өстенә барып, таш яудырды. Шул вакыт патша уянды, күрде: күктән таш ява. Көтмәгәндә бер таш падишаһның башына тиде, башын ярды. Гаскәр курыкты, чатырларын, тирмәләрен ташлап качты. Ә тукучы, аларның артларыннан куа барып, зур-зур ташлар белән атыр иде.

Иртәгесен Гомман падишаһы дошман гаскәренең качып баруын күрде, һөҗүм итеп, артларына төште, кайсын үтереп, кайсын әсир алды. Гомман падишаһы, бу зур җиңүнең сәбәбе Җәбраил икәнен исендә тотып, өенә кайтмыйча, сугыш кырыннан турыдан-туры кызының сараена юнәлде. Төнлә тукучы килде. Падишаһ аның аягына йөз куеп, күп рәхмәтләр укыды. Аннан соң өенә кайтып китте.

Тукучы патша кызына боерды:

— Миңа хәлвә, көлчә һәм кош ите хәзерләп бир, мин аларны аллаһы тәгаләгә рәхмәт йөзеннән, кош-кортка бирәм,— диде. Кыз ул әйткәнне эшләде, тукучы әлеге ризыкларны үзе яшеренгән тау куышына куеп, көндез туйганчы ашар иде, ә патша кызы белән төнлә күңел ачканда, үзен Җәбраил итеп күрсәтеп:

— Миндә ашау хаҗәте юк! — дияр иде.

«Җәбраил»нең даны дөньяга таралды. Ләкин теге чакта җиңелгән падишаһ һич тә тынычлана алмас иде һәм җиңелү ачысы күңеленнән бер дә китмәс иде. Ул яңадан хәзинә ишеген ачты, кара халыкка төрле нигъмәтләр өләштерде, яңадан чиксез гаскәр җыеп, Гомманга юнәлде. Һәр җирне басып алып, талар һәм үтерер иде. Бу хәбәр Гомман шаһына җитте, каты гаҗизлектә калды. Яңадан тукучыга мөрәҗәгать итте. Кыз тукучының аягына егылды, ялварды. Тукучы әйтте:

— Сабыр итегез, ходай ни кушса, шул булыр,— диде.

Ул кичне бу сүз белән күңелләрен юатып, кайтарып җибәрде. Таң вакытында тау куышына барды, сандыкны анда куеп, шәһәргә китте. Анда бераз кара май алып, аны мамык белән аралаштырды һәм утлы күмер алды. Төннең яртысында сандыкка кереп, дошман гаскәренә таба очты, дошман падишаһы ята торган зур чатыр өстенә килде. Утны майлы мамыкка төртеп, чатыр өстенә атты. Утны күргәч, барысы да курыктылар, урыннарыннан кубып, йөгерешә башладылар. Ходай тәгалә аларга ут яудыра дип уйладылар. Бөтен кирәк-яракларын, юл әйберләрен, чатырларын, тирмәләрен ташлап качтылар. Гомман падишаһы шатланып, гаскәре белән килеп, тукучының хезмәтенә йөз куйды.

Тукучы, кыз янына килеп, үткән хәлләрне сөйләп, канәгатьлек белән янында йоклады. Иртә белән тау куышына кайтты. Ни күрсен, сандыкта ялгыш бер кисәк утлы күмер калып, сандык янып беткән, көл булган иде. Бичара тукучының үзен Җәбраил эмингә охшатып йөрүе дә шулай тәмам янып беткән, ул инде гади кеше булып калган дигән сүз иде бу. Тукучы бик озак кайгырып, уйланып утырды, аннары Гомман шәһәренә юнәлде.

Тукучылыктан башка һич һөнәр белми иде, ниһаять, тукучыларның кибет ишегенә җитте. Үз-үзенә әйтте: «Борынгыдан ук акыллы кешеләр әйткәннәр: һөнәрен яхшы белгән адәм тук булыр, үз кәсебендә булган адәм хуп булыр. Әгәр мин үз кәсебемдә мәшгуль булсам, миңа шуннан да яхшы чара юктыр, үз көнемне үзем күрермен»,— дип, бу уйда булды. Тукучыларның башлыгына барып сәлам бирде, әйтте:

— Мин читтән килгән кеше. Бу һөнәрне мин яхшы беләм. Әгәр боерсаң, эшемне күрсәтәм һәм нәрсә бирсәң, шуны алырга риза булам,— диде. Оста әйтте:

— Бик яхшы. Эшеңдә бул,— диде.

Патша кызы ул кичә һәм көндез «Җәбраил килер» дип күз тотар иде — килмәде. Моннан соң бер ай үтте — килмәде. Кыз, каты кайгыга төшеп, елый башлады, чөнки ул тукучыны ярата иде. Ниһаять, бу хәбәр аның атасына да барып иреште, төрле шөбһәле уйлар уйлап, кызы янына килде. Хәлен сорашты, әйтте:

— Алла язмасын, синең тарафтан лаек булмаган бер хәрәкәт ясалган булса кирәк. Җәбраилнең синнән күңеле кайткан ахры,— диде. Кыз:

— Мин һичкайчан Җәбраилнең хәтерен калдырырлык нәрсә эшләгәнем юк,— диде. Гомман падишаһы халыкка хәер һәм сәдакалар өләште һәм дәрвишләргә күп нигъмәтләр чәчте. Кызның ул сарайдан тәмам гайрәте кайтты, шәһәргә йөз тотып, атасының сараена килде.

Тукучының юкка чыгуы турындагы хәбәр галәмгә җәелде. Гомман шаһының дошманнары кузгалыша һәм хәрәкәт итә башладылар. Үтерелгән шаһның туганнары, гаскәр җыеп, Гомман шәһәренә юнәлделәр. Гомман мәлиге халыкка ныгытма эченә кереп бикләнергә боерды, кызын үз сараена озатты.

Кыз юлга чыкты. Юлда барганда тукучы хезмәт итә торган остаханәгә күзе төште. Көймәле зур арбаларның тавышы тукучының да колагына керде, остаханәдән чыгып, бу тамашаны карап тора башлады. Кинәт кызның күзе тукучыга төште, аны таныды, атының тезгенен тартып туктатты. «Әнә шул адәмне китерегез» дип, ике-өч хезмәтчене җибәрде. Үзе шунда ук кире борылып кайтты, атасына бу турыда мәгълүм итте. Атасы, ике кеше җибәреп, тукучыны үз янына алдырды. Аны күреп, әйтте:

— Син Җәбраил түгелме?

Тукучы:

— Әйе, мин — Җәбраил,— диде. Шаһ:

— Синең белән ни хәлләр булды? — дип сорады. Тукучы:

— Ул кичне синең дошманнарыңа ут яудырган һәм барысын һәлак иткән идем, шул сәбәптән аллаһы тәгалә миңа газап кылды, канатларымны яндырды, мине тукучылыкка багышлады,— диде. Гомман мәлиге аңа зур ихтирам күрсәтте, кыз да тукучының аягына төшеп, түбәнчелек итте. Гомман мәлиге әйтте:

— Инде бар, хатының һәм улың белән хуш бул, аллаһы тәгалә яңадан сиңа рәхмәтен салып, әүвәлге хәлеңә кайтарганчы тыныч кына яшә,— диде. Тукучыга падишаһлар гына кия торган киемнәр китереп бирделәр һәм ул падишаһ кызы белән күңел ачуларга, кәеф-сафа коруларга мәшгуль булды.

Күп тә үтми дошман шәһәрне камап алды, киң дөньяны тар итте. Гомман мәлиге, гаскәрен җыеп, капкаларны бикләп, ныгытма эчендә утырды. Бер көн гаскәрнең бөтен башлыкларын чакыртты, боерды:

— Бу кичә гаскәр белән чыгып, кисәк кенә һөҗүм итеп, дошман явына курку салыгыз,— диде. Тукучыга да әйттеләр:

— Син дә гаскәр белән бергә чык. Ходай тәгалә сиңа ачуланган булса да, синдә бәрәкәт күп, шуңа күрә без сине бергә алып барабыз, синең изгелегең безгә уңыш китерер,— диделәр. Тукучы кара кайгыга төште, үзүзенә әйтте: «Минем гомеремдә дә атка атланганым юк, инде нишләрмен? Шуннан да яхшысы булмас: берәр сылтау табып акланыйм, шуннан соң миннән баш тартырлар». Падишаһның бик атаклы бер аты бар иде, исемен Баднам диярләр иде. Андый ат дөньяда юк иде, әгәр падишаһка дошманга каршы барырга туры килсә, шул атка атланып барыр иде, шуңа гына ышаныр иде. Тукучы падишаһка:

— Син миңа сугышка барырга боерасың. Тик син миңа үзем теләгән атны бир,— диде. Падишаһ:

— Кайсы ат кирәк булса, шуны ал,— диде. Тукучы күңеленнән: «Падишаһның атын сорыйм, шаять, бирмәс, шуның белән котылырмын»,— дип уйлады. Әйтте:

— Миңа синең атың кирәк,— диде. Ләкин падишаһ:

— Синең өчен бернәрсәне дә кызганмыйм,— дип, атын бирде. Тукучы, атны күреп, каты гаҗиз булды, тапкан сылтавы бернигә дә ярамады. Үзүзенә әйтте: «Бу сәгать бәлагә төштем, инде бу юлы җан коткара алмам»,— диде. «Падишаһлар кия торган яхшы җилән, алтын билбау һәм кыйммәтле кораллар бирегез. Аннан соң, атка мендереп, капкадан чыгарып җибәрегез. Шуннан соң мин Хозыр пәйгамбәрне булышчылыкка, Ильяс пәйгамбәрне ярдәмгә алып килəм, дип әйтим. Шул сылтау белән җанымны коткарырмын»,— дип уйлады.

Мәлик боерды, тукучы үзе сораган бөтен нәрсәне алдына китерделәр, киемнәрне кигезеп, коралларны тагып, ат өстенә утырттылар, ныклап бер кеттеләр һәм капкадан төн уртасында чыгарып җибәрделәр.

Тукучы шәһәрдән чыкты. Барыр юлы дошман гаскәренә туры килде.

Атына камчы белән сукты, тагын да берне катырак орган иде, ат бик кызу чабып китте. Тукучы куркуыннан: «Ля илаһи илля аллаһи!» дип кычкыра башлады. Дошман падишаһының чатыры янында бер агач бар иде. Ул агач инде бик борынгы заманнардан бирле үсеп утыра, төбе һәм үзәге черегән иде. Тукучы, җан куркуыннан, ул агачка тотынып калырга теләде. Ә аты шул агач кәүсәсенә килеп бәрелде һәм аны тамырыннан кузгатып, падишаһ чатыры өстенә аударып җибәрде. Агач каты тавыш белән чатыр өстенә килеп төште, падишаһ һәм аның күп гаскәр башлыклары агач астында калып үлделәр. Ат, дулап китеп, гаскәр урнашкан җирдә шулкадәр каты чабып йөрде, чатырларны таптап, һәммәсен тар-мар китерде. Тукучы җан куркуыннан тетрәп: «Мин — Җәбраил!» дип әледән-әле кычкыра иде. Моны ишеткән һәм падишаһларының үлемен белгән гаскәр халкы ул караңгы төндә тәмам куркуга төште, коралларын һәм бөтен җиһазларын ташлап качты.

Таң атканда күрделәр: дошман гаскәреннән бер атлы калмаган, бар нәрсәне ташлап качып баралар. Гомман падишаһы артларыннан төшеп, кайсын әсир алып, дошманның байлыгын, малын һәм нигъмәтен җыеп шәһәргә әйләнеп кайтты. Тукучыны эзләп карадылар, тапмадылар. Даладан, таулардан эзләделәр, ахырдан бер тирән чокыр эчендә таптылар. Ат ияренә бәйләнгән хәлдә, һушсыз булып ята, аты ул чокырга төшеп үлгән. Тукучыны ат сыртыннан алып, йөзенә гөл суы чәчеп, һушына китерделәр. Гомман мәлиге аның йөзен-күзен үбеп, Ходайга шөкерләр кылды. Тукучы бераз куәт алып, йөзен шаһка борып, әйтте:

— И мәшһүр падишаһ, и данлыклы падишаһ! Мин Җәбраил түгелмен, мин — тукучы булам,— дип, булып үткән хәлләрен башыннан ахырынача тәмам сөйләп бирде. Аннан соң әйтте:

— Әгәр миңа риза булсагыз, Ходай хакы өчен мине моннан артык хурлык белән һәлак итмәгез, һәм үземнең шул фәкыйрь хәлемдә калдырыгыз,— диде. Гомман падишаһы тукучының хәлләрен тәмам ишеткәч, болай уйлады: «Бу кеше күп егетлек күрсәтте һәм ничә тапкыр минем дошманнарымны һәлак итте. Кызым да аны ярата, аннан баласы да бар, аннан соң аның исеме дә дөньяга җәелгән, данлы исеме аркасында һич кеше миңа дошман була алмас. Әгәр аның тукучы икәнен белсәләр, барысы да мине хурлап көләрләр һәм дошманнарым да батыраер». Шулай уйлап, падишаһ аның күңелен күрергә тырышты. Әйтте:

— Хатының һәм улың белән хуш бул һәм бу яшерен сүзләрне һичкемгә әйтмә һәм һәрвакыт Җәбраил кыяфәтендә бул,— диде, тукучыны элекке гадәте буенча кыз янына, сарайга җибәрде.

Тукучы Гомман падишаһы кызы белән кичә һәм көндез күңел ачып, рәхәтлек белән гомер кичерер иде. Кайвакыт болай кабатларга ярата иде:

Яманлыкны күп кылса да яман,
Син кеше күңелен кылма азар [1],
Кыл дуска һәм дошманга яхшылык,
Шул вакыт яман булыр хур вә зар.

## Диңгезче Әбелфәварис хикәяте

Хәбәрләрне тапшыручылар хикәяттә шулай сөйләделәр:

Басра шәһәрендә бер кеше бар иде, нигъмәт иясе һәм мөхтәрәм кеше иде, исемен диңгезче Әбелфәварис дип атап әйтерләр иде. Һинд диңгезендә ул йөрмәгән һәм күрмәгән бер карыш җир дә калмагандыр. Бер көн ул диңгезчеләр белән диңгез ярында утырыр иде. Кинәт каяндыр бер карт килеп чыкты, бер көймә алдына килеп, боларның яннарында торды. Сүзгә катышты, әйтте:

— Әй, осталар! Алты айга көймә биреп торыр кешегез булырмы? Күпме теләсә — шулкадәр түлим,— диди. Әбелфәварис:

— Мең динар бирсәң, мин риза,— диде. Карт әйтте:

— Ярый, кабул итәм,— диде, мең динар кызыл алтын санап бирде. Өч көннән килергә сүз беркетте, өенә кайтып китте.

Диңгезче, алтынны алып, йорт кирәк-яракларын һәм үз мәшәкатьләрен

[1] Азарлау — хурлау, гаепләү

кайгыртты, калганын гаиләсенә васыять итте. Вәгъдәләшкән көнгә диңгез читенә килде. Шул ук вакытта карт та килеп җитте. Бер кара голәме[1], егерме йөк тукымасы бар икән. Әбелфәварисны күргәч, хуплады, шунда ук йөкләрне көймәгә төяделәр. Өчәүләшеп юлга чыктылар. Карт юнәлешне күрсәтеп барды. Диңгезче көймәне ул күрсәткән тарафка алып барды. Йөзделәр, бер утрауга җиттеләр, көймәне бәйләделәр, капчыкларны бушаттылар, аларны голәм җилкәсенә күтәреп алып китте. Бер тау итәгенә җиттеләр. Күрделәр: тау итәге коелар белән тулган. Карт бер кое янына килде, диңгезчегә әйтте:

— Әй кыю адәм! Бел: мин бер сәүдәгәр идем, бу утрауда җәүһәр табып тордым. Сиңа мең динар кызыл алтын бирүнең сәбәбе шул иде. Инде минә монда килдек, әгәр аңласаң, миңа һәм сиңа күп файда булыр. Бу коеларда капчыкларыбызны энҗе белән тутырырбыз, тәмам булганнан соң китәрбез. Өебезгә кайткач, яртысын син алырсың, яртысын мин алырмын. Коега төш, анда кәрзинне тутыр, мин моннан алып торырмын. Бу байлык сиңа да, миңа да үлгәнче җитәр,— диде. Әбелфәварис ул-бу әйтмәде, коега төште, кәрзинне тутырды. Карт югары тартып алды, күрде: энҗе бик вак икән. Әйтте:

— Кил, бире чык, күр: бу энҗе эшкә ярамас,— диде. Диңгезче өскә чыкты, карады, аннан соң башка коега төште, кәрзинне эре энҗеләр белән тутырды. Энҗене шул кадәр алдылар — кәрзиннәр, капчыклар һәммәсе тулды. Шунда диңгезче күрде: карт аны тартып чыгарырга бау төшерми. Әйтте:

— Их карт! Мине дә чыгар,— диде. Карт әйтте:

— Урының яхшы, шунда тор,— диде. Диңгезче озак ялварды, әмма файдасы булмады. Шуннан соң әйтте:

— Миңа тигән өлеш сиңа булыр, чыгар гына,— диде. Карт әйтте:

— Әй, тиле! Сине чыгарсам, миннән өлешеңне дә, үчеңне дә алачаксың. Иң яхшысы — шунда ят, сүзем өзелде,— диде. Диңгезче ант эчте:

— Валлаһи, сиңа тимәм, коткар гына,— диде. Карт әйтте:

— Тәҗрибә өчен генә агуны авызыма салмам,— диде, китеп барды.

Диңгезче үз хәленең аяныч икәнен күрде, карттан өмет өзде, үксеп елады. Мөнәҗәтләр әйтеп, өч көн коеда ятты. Аннан соң кое төбе буйлап китте. Күрде, кеше сөякләре ята. Әйтте:

— Миннән башка кешеләр дә бу бәлагә юлыккан икән,— диде.

Шулай йөргәндә бер тишеккә юлыкты. Аягы суга тиде, суга төште, су иңенә кадәр җитте. Татып карады: су тозлы икән. Шуннан белде: бу диңгезгә чыгу юлы булса кирәк. Су юлы буйлап китте, диңгезгә килеп чыкты, аннан ярга күтәрелде. Ходайга шөкер итте. Коега барды, карады: карт белән голәм киткәннәр. Кыен хәлдә калды. «Шаять, берәр көймә күрермен»,— дип, яр читенә барды. Кинәт бер олы кораб күренде. Диңгезче кул болгап, ярдәм сорады. Ул корабтан көймә төшерделәр, килеп, Әбелфәварисны корабка алдылар. Әйттеләр:

— Һай, монда нишләп йөрисең?

Әбелфәварис җавап бирде:

— Корабым батты, мин ярга йөзеп чыктым,— диде.

Аннан ул кораб белән ун көн бардылар, коры җир күренмәде. Әбелфәварискә әйттеләр:

— Дүрт-биш көн инде корабыбыз, артка тарткан кебек, кире китә, хәлебез нидер, белмибез,— диделәр.

Кинәт манара кебек бер тау күренде, үзе күзгә кебек шома. Нинди тау икәнен белмәделәр, «Бу ни гаҗәп?»— диделәр. Күрделәр: кораб шул күзге сыман кыяга таба китәр. Әбелфәварис әйтте:

— Һәммәбез һәлак булырбыз!— диде.— Атамнан бу җирнең сыйфатын ишеткән идем. Атам миңа: «Бер упкындыр, анда төшкән һичкем котыла алмас»,— дип әйтә торган иде. Халыкның барчасы Әбелфәварискә әйтте:

— Чарасын белсәң, син белерсең, безне коткар?!

Әбелфәварис әйтте:

— Булган барлык бауларны алыгыз. Корабыбыз кыяга якын баргач, аркан атып чыгарбыз. Суда һәлак булганчы, корыда булырбыз,— диде. Һәммәсе дә бу фикерне яхшы дип тапты, Әбелфәварис ни боерса, шуны эшләделәр. Бу чара уңышлы чыкты, аркан бер агачка эләкте. Әбелфәварис

[1] Голәм — хезмәтче малай

ярга беренче булып чыкты. Бер яшел гөмбәз күрде, шунда таба барды. Күрде: шактый биек корыч багана тора. Аңа бер зур барабан асылган һәм такта беркетелгән. Ул тактага болай дип язылган: «Әй бу җиргә килүче! Бел һәм аң бул: мин Искәндәр Зөлкарнәйн дигән кеше, бу җиһанны гизеп, шушы упкынга очрадым. Моның афәтен күргәч, хәкимнәргә боердым: «Бу афәттән котылу өчен бер тылсым ясагыз»,— дидем. Әфлатун хәким: «Мин бер-бер чара кылам»,— дип, шушы багананы ясады. Ничек гамәлгә китүе будыр: алтын чылбыр белән асылган барабанга таяк белән өч тапкыр каккач, упкын эчендә кергәннәр котылу юлына чыгар, ләкин барабанны каккан кеше монда калыр». Әбелфәварис бу язуны укыды, кораб белән килгән җәмәгатькә дә хәбәр бирде. Халык арасында үкереп елау башланды, гарасат көне кебек булды. Бер-берләреннән ризалык теләшеп, өметсезлеккә бирелеп утырдылар. Бераздан соң үзара сөйләштеләр:

— Барыбыз да үлгәнче, ялгыз бер кеше үлсә — ни булыр?

Ахырда, елашып, Әбелфәвариска әйттеләр:

— Кил, безгә чара янә синнән булыр, әгәр булмаса, һәммәбез монда һәлак булабыз,— диделәр. Ә Әбелфәварис аңлы кеше иде. Эченнән генә уйлады: «Шул хәтле адәм һәлак була, янә мин дә исән калачак түгелмен. Инде чара шул булыр: мин ялгыз калып, бу кадәр халык котылыр булса, кыямәт көн, шаять, әҗерен буш итмәс». Халыкка әйтте:

— Мин бу эшне эшлим, әмма миңа үз ризалыгыгыз белән ни бирерсез?— диде. Әйттеләр:

— Ни теләсәң дә ал, җаныбызны гына коткар!— дип, йөзләрен җиргә куйдылар. Әбелфәварис әйтте:

— Монда торган корабның эче тулы мал. Шуның яртысы — сезгә һәм яртысы миңа булсын. Моннан котылгач, Басрага барып, минем өлешемне йортыма, гаиләмә бирегез. Минем башыма ни язган булса, шуны күрермен,— диде. Барчасы ант эчтеләр, кабул иттеләр. Әбелфәварис ярга кире чыкты, таяк белән барабанга бер тапкыр сукты. Шул арада кораб ике-өч ук атымы кадәр ара кире китте. Өч мәртәбә оргач, Хакның кодрәте белән, кораб инде упкын чигенә чыкты. Вәгъдәгә тугрылыклы булып, Басрага кайтып, Әбелфәварисның өлешен, килешкәнчә, йортына тапшырдылар.

Ә бу тарафта мескен Әбелфәварис ярда ятты, йоклады. Торды, юынды, намаз кылды. Аннан соң, кыяга кош кебек ябышып, мең бәла-михнәт белән тау өстенә чыкты. Күрде: сусыз һәм үлән-куаксыз бер сахра. Әмма каяндыр куйлар чыкканын күрде. Шунда китте, анда баргач, бер болын күрде, болын эчендә куй көтүе йөри иде. Әбелфәварис шатланды. Карады, күрде: бер тау кебек олы гәүдәле егет куйлар көтә, кәҗә тиресеннән кием кигән. Әбелфәварис ул егеткә сәлам бирде. Көтүче аның сәламен алды:

— Хуш килдең!— диде, сорады:

— Син кайдан һәм ни кеше син? Монда ни эзлисең?

Әбелфәварис башыннан кичкәннәрнең бөтенесен сөйләп бирде. Көтүче көлде, әйтте:

— Шөкер ит, ул бәла упкыныннан котылдың,— диде.— Кайгырма, мин сине кеше яши торган бер урынга ирештерәм.

Бер чынаяк сөт һәм бераз икмәк бирде. Әбелфәварис ашады, аннан көтүче әйтте:

— Өйгә кайтабыз, ял итәрбез,— диде. Диңгезче белән көтүче өйгә киттеләр. Бер тау төбенә җиткәч, егет куыш ишеген каплап торган ташны алды, Әбелфәварисны эчкә төртеп кертте, аннары тишекне янә таш белән каплап куйды. Диңгезче куыш эче буйлап китте, бер ачык җиргә чыкты. Бакчалар һәм басулар күрде, җимеш агачлары чиксез күп иде. Тау эчендәге бер мәгарәдә бүлмәләр уелган, ләкин һичкем күренми. Бер бүлмәгә керде, анда ун ялангач кеше утыра, шулкадәр симергәннәр — күзләре күрмәс булган. Әбелфәварисны күреп, еладылар, сорадылар:

— Ни кеше син, монда ни эзлисең?— диделәр. Әбелфәварис хәлен сөйләп бирде. Тагын да әйтте:

— Ул егет мине кунак итте,— диде.

Әйттеләр:

— И бичара! Ул егет — кеше ашаучы, көтүче рәвешендә йөрер, очраган кешене китерер, монда ташлар, симертер, суеп ашар. Без һәммәбез сәүдәгәрләр идек, каршы җил безне монда ташлады, моның кулына төшеп, бу хәлгә дучар булып утырырбыз,— диделәр. Әбелфәварис бу сүзләрне ишетте исә, бөтен тәне дерелди башлады, җанына ут ябышты, кайгылы-хәсрәтле утырды.

Бераздан соң көтүче килде, киемен салды, мәгарәдән чыкты. Яшелчә җимеш китерде. Әбелфәвариска бирде:

— Бар, юлдашларың белән бергә аша! — диде. Аннан көтүче эчкә керде, иң симез токтыннарның берсен алып китте, учакта кыздырып ашады. Аннан соң бер чиләк шәраб эчте. Тамагы туеп, йоклады. Әбелфәварис әйтте:

— Мин үзем монда һәлак булырмын, әмма котылу өчен бер-бер хәрәкәт кирәктер,— диде. «Аh» итте, елады. Юлдашлары әйтте:

— Ах, бер хәрәкәт ясасаң икән? Шаять, Хак рас китерер иде,— диделәр. Әбелфәварис торды, ике очлы тимер таяк тапты, утта кыздырды. Бик каты кызганнан соң, икесен дә көтүченең күзләренә басты, аны тәмам сукыр итте. Көтүче торды. Әбелфәварисны куа башлады. Болай гына тота алмагач, тиз генә капкага барды, утырды. Куйларны бер урынга җыйды, аркаларыннан сыйпап, берәм-берәм чыгара башлады. Әбелфәварис шунда ук бер куйны суеп, тиресен салдырып киде. Куй кебек булып, капкадан үтәргә уйлады. Ләкин көтүченең кулы бу хәйләне тойды, ныгытып тотты, куй тиресе аның кулында калды, ә диңгезче чыгып качты. Көтүче аның артыннан куа китте. Әбелфәварис күрде: котылырга мөмкин түгел. Диңгезгә ташланды, йөзә башлады. Көтүче бүтән чара тапмады, диңгез ярында утырды, шактый утыргач, кире китте. Әбелфәварис яңадан ярга чыкты, көтүчедән куркып, күз күргән якка таба китте.

Көтүче, диңгезчедән өмет өзеп, сарайга барды, андагы җәмәгатьләрне тапмады. Аңлады: барысы да качканнар. Анннары куйларын эзләп барды, аларны да тапмады. Ачуыннан диңгезгә сикерде, һәлак булды.

Әбелфәварис өч көннән соң бер тау итәгенә җитте. Бер болынлык күрде. Анда бер кеше җир сөрә иде. Барды, сәлам бирде. Ул кеше җавап кайтарды:

— Хуш килдең! — диде. Кунак итеп, икмәк һәм су бирде, хәлен сорады. Әбелфәварис үзенең хәлен хикәят итте. Карт көлде, әйтте:

— Көтүче бик нык куркыткан икән, ярый әйбәт кенә котылгансың. Хәзер инде тыныч бул, хәвеф юктыр,— диде.— Бер тау өстендә зур авыл бар, өем андадыр, кунак булырсың,— диде.

Авыл халкы Әбелфәварисны «Хуш килдең»,— дип, сәламләп каршы алды.

Өйгә керттеләр, яхшы ризыклар китереп ашаттылар. Аннан карт әйтте:

— Аргансың, ят, тынычлап ял ит,— диде. Үзенә ияртеп, җир астындагы бер куышка алып керде. Әбелфәварис эчкә керде, күрде: егермеләп кеше утыра, алар моны күреп елаштылар. Әйттеләр:

— Әй сукыр бәхет! Бу кеше ашаучының тозагына ничек төштең? — диделәр. Әбелфәварис үз хәлен сөйләде. Болар әйтте:

— Без сәүдәгәрләр идек. Ходайның казасы безне монда ташлады. Һәммәсе монда кеше ашаучылар. Кулына кергәнне көндез эшләтер, төнгә монда куяр. Симергәннәрне тотып ашар,— диделәр. Бу сүзләрне ишетеп, Әбелфәварис бик кайгырды, тәненә калтырау төште, аллага ялварды:

— И йөрәк серләрен белүче! Синсез котылу, бәладән чыгу юктыр. Үтенечемне өметсез калдырма,— дип, мөнәҗәт әйтте.

Таң аткач, карт килде, ишекне ачты, боларны үз эшләренә җибәрде. Диңгезчегә әйтте:

— Син нинди эш беләсең? — диде. Диңгезче әйтте:

— Өй хезмәтен беләм,— диде. Карт аны өй эшенә куйды.

Диңгезче кичә-көндез хезмәт итте, су китерде, аш пешерде, өйне себерде. Картның хатыны моны күрде, бик күңеле булды. Икенче көнне хатын иренә әйтте:

— Моны миңа багышла, өй хезмәте өчен тотармын,— диде. Ире моның үтенечен кабул итте. «Ярар», диде. Әбелфәвариска карчык шатлык хәбәрен әйтте, диңгезче моңа рәхмәт укыды.

Бер көн картка бер кеше килде:

— Фәлән көтүче үлде,— дип хәбәр бирде. Карчык:

— Бу кеше ышанычлы күренә,— дип, Әбелфәварисны сарык көтәргә җибәрде.

Диңгезче далада сарык көтәр иде, ихлас күңел белән күзәтер иде. Даланың ике башында сакчылар бар иде. Диңгезче бер сакчы белән танышты, бер чара булыр дип, бер көнне куйларны сакчы ихатасына куып китерде, сөт сауды.

— Ризык пешер, ашыйбыз,— диде. Бу эш сакчыга ошады. Диңгезче бу эшне гадәт итте, ул өйгә кыю рәвештә килеп-китеп йөри башлады. Бервакыт тау куышында бал тапты, алды, сакчы өенә китерде. Сакчы әйтте:

— Каян алдың, барып белим, күбрәк алып кайтыйм,— диде. Юлдаш булып киттеләр. Юлда кулай туры килде, диңгезче сакчыны үтерде. Бу юньсез урыннан китте, диңгез ярына барып чыкты. Күрде: бер зур кораб килә, эче тулы халык. Әбелфәварисны күреп, корабка алдылар, хәлен сорадылар. Ул хәлен-хикәятен сөйләде, гаҗәпләнделәр.

Бер ай диңгездә йөреп, ахырда сау-сәламәт килеш ярга чыктылар. Корабның капитаны Әбелфәварисны Басрага озатты.

Менә өенә кайтты, күрде: өй халкы матәм тоткан. Әбелфәварисны күргәч, шат булып, матәм киемнәрен салып, шатлыктан елашып күрештеләр. Әбелфәварис бик шөкерләр итеп, хода юлына күп корбан багышлады. Күп алтын һәм энҗе-көмешне фәкыйрь-мескеннәргә бүләк итте, янә баштан кичкәннәрен сөйләде, халык хәйран калды. Шул рәвешле берникадәр вакыт өендә торды.

Беркөн шулай күңел ачып, диңгез читендә, халык арасында утыра иде. Шул вакыт әлеге дә баягы — хикәят башында телгә алынган карт килеп чыкты. Яңадан, элеккечә көймә һәм диңгезче таләп итте. Әбелфәварис утырган җиреннән торды, килде, әйтте:

— Мең динар бир, мин барам!— диде. Әлеге карт шунда ук кабул итте, сөйләшенгән мең динарны санап бирде. Шулай ук, әүвәлге кебек, очрашу вакытын билгеләде. Әбелфәварис күңелендә әйтте: «Миңа әле юлга чыгу вакыты җитмәгән, ләкин бу әшәке, мәрхәмәтсез карттан мөселманнар үчен алмый калдырмам»,— диде.

Вәгъдәләшкән көнгә диңгез ярына килде. Явыз карт көтеп тора иде, көймәгә менде. Шулай ук, теге кара голәм белән өчесе бергә юлдаш булып, өч ай дигәндә шул утрауга чыктылар. Карт максатына җитте, сөенде. Әбелфәварисны коелар янына алып барды. Коега җиткәч, диңгезчегә әйтте:

— Бу коега төш, монда бик күп энҗе бар, яртысын син алырсың, яртысын миңа бирерсең,— диде. Диңгезче әйтте:

— Әй карт! Минем бу җиргә килгәнем юк, хәл ничек икәнен белмим, әүвәл син төш, бераз чыгар, ничек эшлисен күрим, аннан мин төшәрмен,— диде. Карт:

— Минем бу гомеремдә бер кырмысканы да рәнҗеткәнем юк, сиңа зыян тидермәм,— диде. Диңгезче әйтте:

— Зыянсыз, тыныч кеше булуыңа иманым мең тапкыр камил, әмма файдасын-табышын күрмәгән килеш ул эшкә керешмим,— диде. Карт гаҗиз булды, нишләсен: теләсә-теләмәсә дә, үзе коега төште. Бер кәрзин энҗе тутырды, әйтте:

— Тарт!

Диңгезче кәрзинне тартып чыгарды. Карт әйтте:

— Күр, монда ни газап булсын!— диде.— Мин чыгам, син төш,— диде. Диңгезче әйтте:

— Күрдем, сүзең дөрес икән, син инде бүген эшлә, иртәгә мин төшәм, бик күп энҗе чыгарырмын,— диде. Карт:

— Ни чара итим?! Тозагына төштем,— диде. Шул кадәр күп энҗе чыгарды — чамасын тәңре генә белер. Капчыклар тулды, Әбелфәварис аларны көймәгә салды, кара голәмне дә шунда утыртты. Карт әйтте:

— Инде мине чыгар,— диде. Диңгезче әйтте:

— Монда чыгып нишләрсең? Анда тор!— диде. Карт ялварды, әйтте:

— Әй туган! Мөселманлык хакы өчен мине тартып чыгар!— диде. Әбелфәварис әйтте:

— Әй яман эт! Үзеңә төшкән авырлыкны күрәсең, башкалар зәхмәтен күрмисең, ни өчен күрмисең?! Әй яман фигыльле! Беләсеңме: мин диңгезче Әбелфәварис буламын. Әй хәрамзадә! Мине бәлагә дучар иткәндә сукыр идеңме әллә? Исеңдәме: «Агуны тәҗрибә өчен генә авызыма салмам», дип, минем ялынганыма рәхим-шәфкать итмичә, бауны кистең. Инде үз башыңа төште, алдыңдагы сөякләрне күрәсеңме — сине шуларның гөнаһысы тотты!

Карт елый-елый ялынды, әмма файда булмады, кое төбендә калды.

Шулай, гөнаһ кылмаса — газап тапмас иде. Һәркемнең кылганы алдына килмичә калмас, яманлык итеп яхшылык көтү — булмас эш.

Әбелфәварис бер олы ташны китерде, коеның авызын каплап куйды.

Энҗе-мәрҗән белән тулы көймә янына килде. Голәм сорады:
— Хуҗам кайда? — диде. Диңгезче әйтте:
— Диңгез эчендә,— диде. Голәм, диңгезгә карыйм дип, аска иелде. Диңгезче аны суга төртеп төшерде, кайтыр юлга чыкты.
Өч айда Басрага җитеп, бу хәзинәне өенә илтте. Җәмәгатьләре күреп, сөенделәр. Ахыры хәерле булды, бу хикәятне ядкарь итеп калдырдылар.

## Алтын бәһасенә торган зирәклек

Хәбәрләрне сөйләүчеләр һәм әсәрләрне күчерүчеләр шундый риваять сөйләделәр:
Нишапур шәһәрендә Ләввахә атлы укымышлы бер хуҗа бар иде. Һәртөрле һөнәрләр белән бизәүле иде. Бервакыт аңа Хиҗазга сәфәргә китәргә туры килде. Хәзерләнде, кирәк-яракларын алып, юлга чыкты. Хиҗазга баручылар белән бергә китте. Багдадка якынлашканда юлбасарлар Ләввахәнең юлын кистеләр, янчыгындагы йөз алтмыш динар алтынын алдылар, ялангач калдырдылар, гаҗиз-мескен итеп ташладылар. Ләввахә бер тиен акчасыз калып, җанын сөйрәп, Багдадка килде, оятыннан өч көн бер почмакта, аулакта яшерен ятты.
Бу хәлендә күрде: тик утырып һәм әдәп саклап эш бармас. «Хәрәкәттә — бәрәкәт» дип, торды, базарга барды. Бер кешегә әйтте:
— Авыр хәлгә очрадым, миңа ярдәм ит, бу шәһәрдә берәр юмарт кеше булса, аңа йөз орам, шаять, миңа бераз тукланып торырлык нәрсә бирер иде,— диде.— Начар нияттән әйтмим моны, хаҗга китәсем бар,— диде. Ул кеше әйтте:
— Безнең шәһәребездә мөлкәтле, бай бер кеше бар, мөгътәбәр кеше, исеме Бәшәр. Аның алдына барган һәркем максатына ирешә, янына барып, хаҗәтеңне белдер,— диде.
Ләввахә торды, хуҗа Бәшәрнең сараена барды, рөхсәт белән сарайга керде. Үз хәлен аңлатып бирде. Ләкин хуҗа Бәшәр ул вакытта башка нәрсә белән мәшгуль иде, шуңа күрә әйтте:
— Иа кардәш! Иртәгә килерсең, гафу ит, таңда хәлеңне күреп, эшеңне кайгыртырмын,— диде. Ләввахә бу урынсыз җавабтан көлде, үз гозерен түбәнчелекле кичектерүгә рәнҗеде, күңеленнән әйтте: «Бу нинди юмартлык булсын?!» — диде. Аннан уйлады: «Кайгысы бар кеше коръәнгә баксын, коръәнне укыса, кайгы-хәсрәте бетә, дип әйткәннәр. Мин дә шулай итим»,— диде.
Барды, мәчеткә керде, коръән битен ачты, көйләп укуга мәшгуль булды. Кинәт бер аятькә күзе төште. Анда: «Ләввахатүн ли-л-Бәшәр галәйһә тисгату гашәр» («Ләввахәгә Бәшәрдән унтугыз тиешле») дип язылган иде.
Шунда ук торды, коръәнне җиңенә яшерде, мөхаззыйрга[1] барды. Әйтте:
— Читтән килгән кешемен, теләкләремне үти алмыйм, бер мөселманда унтугыз динарым бар иде, бирми, шуны алып бирсәгез иде? — диде.
Мөхаззыйр барды, хуҗа Бәшәрне казыйга китерде. Казый аңа хөрмәт күрсәтте, әйтте:
— Ни булды, безгә хөрмәт күрсәтеп килүегезнең сәбәбе ни? — диде. Хуҗа Бәшәр әйтте:
— Мөхаззыйрыгыз килде, хезмәткә чакырды.
Казый мөхаззыйрга карады:
— Ни вакыйга? — диде. Мөхаззыйр әйтте:
— Менә бу читтән килгән егет әйтте: «Алымым — шул кешедә»,— диде. Аның сүзе белән китердем.
Казый Ләввахәгә әйтте:
— Алымың кемдә?
Ул әйтте:
— Шушы хуҗададыр,— диде. Казый әйтте:
— Күпме? Телгә алырлыкмы?
Ләввахә:
— Әй дөньяның хөкемчесе! Яшең озын булсын, бу кешедә унтугыз динарым бар,— диде. Казый хуҗа Бәшәрдән сорады:
— Син ни диярсең? — диде. Хуҗа Бәшәр:
— Хәбәрем юк,— диде. Казый хәйран калды, чөнки бу кеше мең динар булса да, ялган әйтмәс, кире какмас иде. Ләввахәгә әйтте:

[1] Мөхаззыйр — нотариус

— Каршы якны кире кагырлык таныклыгың, шаһитең бармы?
Ләвваха әйтте:
— Монда ул, хәзер күрсәтәм,— диде. Җиңеннән коръәнне чыгарды, әйтте:
— Атам миңа Ләвваха дип исем биргән, бу хуҗаның аты Бәшәрдер, хак тәгалә боерган болай дип: «Ләввахатүн ли-л-Бәшәр галәйһә тисгату гашәр».
Казый көлде, хуҗа Бәшәргә әйтте:
— Бу — үткен егет икән, синең моңа унтугыз динар бирәсең бар имеш, кил, бир!— диде. Хуҗа Бәшәр:
— Гәрчә юк булса да, сез әйткәч — бирәм,— диде. Үлчәү тартты, китерде, унтугыз динарны Ләввахагә бирде. Ләвваха алтынны алды, китәргә теләде. Казый Ләввахәнең кулыннан алды, үз бүлмәсенә алып керде, әйтте:
— Бу ни? Килдең, дәлилсез-нисез унтугыз динар алдың, дәлилеңнең исбат булуы кирәк түгел, хәзер үк син аңа кире кайтарып бир, таңредән курыкмыйча, корьән аятен пычраттың, кяфер булдың, вәләкин читтән килгән мескен булганың өчен, үтенечеңне сакладым, тимәдем. Инде алтынны хаксыз алгансың икән, кире алам, иясенә бирәм, мәгәр тәүбә итәрсең, берәр төрле күркәм эш күрсәтерсең, юкса кулымнан котылмассың,— диде.
Ләвваха әйтте:
— Миннән нинди күрекле эш таләп итәсең?— диде. Казый:
— Менә бу эшне кыл,— диде һәм кыздырылган тавык китерде. Әйтте:
— Бу тавыкны без биш кешегә һәм ике голәмгә[1] бүлә алсаң, егерме динар бирәм. Әгәр өлешләрне тигез итмәсәң, алтынны кулыңнан алам, чөнки син ялган нәрсә белән мөселманнардан мал алырга телисең,— диде. Ләвваха күрде: казый үзе, аның хатыны, ике улы һәм ике голәме аяк өсте торалар. Пәке чыгарды, тавыкның башын кисте — казый алдына куйды. Муенын кисте — хатын алдына куйды. Канатларын кисте — ике угланның алдына куйды, ике аягын кисте — ике голәмгә бирде. Калганын үзенең алдына куйды, эшен тәмам итте. Казый әйтте:
— Бу нинди бүлү!? Моның ни нигезе бар? Башын эт тә ашамас, янә калган өлешләрен бүлү ни сәбәп белән булды? Бу кыздырылган тавык синеке булдымы?!— диде. Ләвваха әйтте:
— Бүленеш бик дөрес, һич кимчелек юктыр,— диде.
Казый әйтте:
— Ничек?
Ләвваха әйтте:
— Бу шәһәрнең хуҗасы, башлыгы — син, шуның өчен башын сиңа бирдем. Тагын галәм халкына шул мәгълүм: ирләрнең шөһрәтле, атаклы булуы һәм югары күтәрелүе хатыннарның яхшылыгы беләндер. Шуның өчен муенын хатынга куйдым. Янә угланнар — ата кешенең канатларыдыр, шуның өчен канатларын угланнар алдына куйдым. Янә аякларын голәмнәргә бирдем, шуның өчен: алар, аяк булып, син боерган җиргә синең өчен чабып барырлар. Ә мин инде бер ярлы, бәхетсез, сөрелеп йөрүче, кулсыз һәм аяксыз, башсыз һәм милексез. Шуңа күрә дә башсыз-муенсыз һәм канатсыз гәүдәне, үз алдыма куйдым,— диде. Казый моны ишетте исә, инсафка килде, бүленешне хуп күрде, егерме динарны Ләввахагә бирде. Әйтте:
— Иртәгә тагын килерсең, тагын бер мәсьәлә бар, җавап бирсәң, алтын алырсың, йә һәммә акчаңны кире бирерсең,— диде.
Икенче көнне аш өстәлендә дүрт тавык ята иде. Казый аларны Ләввахәнең алдына куйды, әйтте:
— Моны да өлешләргә бүл, дөрес бүлсәң, кырык динар тагын бирермен, дөрес бүлмәсәң, электән никадәр алтының булса — шуны алырмын,— диде.— Аннан янә чыбык белән суктырырмын,— диде. Ләвваха карады, күрде: алдында биш кеше, хезмәтче малайлар монда түгел. Бер тавыкны казый белән аның хатыны алдына куйды. Бер тавыкны — ике углан алдына, ике тавыкны үз алдына куйды. Казыйның йөзе караңгыланды, әйтте:
— Һай, бу ни мәгънә: без икешәр кеше булып та, берне генә бирәсең, ә үзеңә икене аласың?— диде. Ләвваха әйтте:
— Әгәр шулай әйтәсең икән, үзең туры юл күрсәтәсең булып чыга, чынлап та шулай,— диде. Казый:
— Сөйлә, нинди буш, мәгънәсез сүзләр әйтерсең икән?— диде. Ләвваха әйтте:
— Син, хатының һәм тавык — барлыгы ничә була?
Казый әйтте:

[1] Голәм — хезмәтче малай

— Өч.
— Янә ике углың белән бер тавык ничә була?
— Өч була.
— Янә минем белән ике тавык ничә була?
— Өч,— диде казый. Ләввахә әйтте
— Мин хисапны дөрес әйттем, монда нинди ялгышлык бар?
Казый кыен хәлдә калды, кырык динарны чыгарып бирде. Янә әйтте:
— Иртән килерсең, өченче тапкыр ничек үтәрсең — күрербез,— диде.
Икенче көнне казый сиксән динарны янчыктан чыгарды, алга куйды, әйтте:
— Һай! Әгәр тиешенчә бүлеп бирсәң, алтынны тулысы белән алырсың, әгәр дөрес булмаса, бөтен алтыныңны алырмын, сине алтын хәсрәте белән рәнҗешле итәрмен,— диде. Ләввахә:
— Ярар, и үткен фикерле, акыллы казый!— диде.
Казый җиде йомырканы Ләввахә алдына куйды.
— Әй, акыл иясе, бу җиде йомырканы без биш кешегә бүлеп бир, һәрберебез риза булырлык шарты белән тигезләп бүл,— диде.
Ләввахә берсен алды да казый алдына куйды. Өч йомырка алды, хатын алдына куйды. Берне үз алдына һәм икене ике углан алдына куйды. Казый болай бүленешне күргәч, җанына ут төште, кычкырды, әйтте:
— Һай! Бу кылганыңның сәбәбе-нигезе ни: безгә берәрне бирәсең, ә хатынга өчне бирәсең, моның ни акылга сыешлыгы бар?— диде. Ләввахә әйтте:
— Башта хисапны күрерсең, кирәксә тагын бер хисаплarбыз,— диде.
Казый әйтте:
— Әйт, ни урынсыз сүз сөйләрсең, тыңлыйк,— диде. Ләввахә әйтте:
— Һәрберебезнең икешәр йомыркасы бардыр, өчәр иттек. Хатынның берсе дә юк — аңа да өчне бирдек, аның да өчәү булды,— диде.
Казый гаҗиз калды, җиңелде. Әйтте:
— Тор, моннан югал. Алтыныңны далада юлбасарга бирдең, бу вакыт монда килдең, Багдад шәһәрендә безне талыйсың һәм малыбызны аласың. Бөтен дөньяның ганимәте минеке булса, аны да алдап алырсың, мине бурычлы итәрсең. Яхшылык ит: янә сиксән динарны да ал да, тизрәк юлыңда бул,— диде.
Ләввахә, җиңү яулауга ирешеп, урамга чыкты, табыш-алтыннарны күрде: йөз алтмыш динарга бер генә динар тулмый калган.
Инде бу хикәятнең файдасы шулдыр: җитезлек һәм зирәклек алтын бәһасенә торыр, ул сәфәрдә һәм читтә йөргәндә кешегә һәрвакыт кирәк. Ә фәкыйрьлектә бигрәк тә кирәк икән.

## Өч егет хикәяте һәм патша кызының тәүбәсе

Хикәятчеләр шундый хикәят сөйләделәр:
Үткән заманда бер карт белән өч егет юлдаш булып бардылар. Аларның казасы белән, бер сахрага җиттеләр. Һәр дүртесе арып-талып, шулкадәр згыйфь, гаҗиз булдылар — йөрергә көчләре, хәлләре калмады.
Шулчак егетләрнең берсе сахрада гаҗәеп бер сарай күреп алды. Ул сарайның башы күккә җиткән, ишекләре агым суга караган. Юлдашлар берберсенә әйттеләр:
— Тырышып-тырмашып, үзебезне ул сарайга җиткерә алсак, шаять, берәр кеше булып, безгә ашамлык-эчемлек бирер, туйдырыр иде, бераз ял итәр идек,— диделәр. Булдыра алганча тырышып карадылар, әмма тагын да алга барырлык көчләре юк иде. Бер сәгать утырдылар, янә кузгалып киттеләр. Сарайга кадәр өч-дүрт ук атымы ара калган иде. Һәр дүртесе хәлсезләнеп егылдылар. Аннан соң кузгалдылар, картка әйттеләр:
— Әй озак еллар яшәгән карт! Әйдә, һәркайсыбыз үз башыннан кичкән берәр гаҗәеп вакыйга-хикәят сөйлик, кайсыбызның хикәясе яхшырак, матуррак — шуны сарайга күтәреп илтәбез. Һәммәсе дә:
— Яхшы булыр!— дип килештеләр. Аннан соң егетләрнең берсе әйтте:
— Исфаһан вилаятендә Әбү Дәләф дигән олы дәрәҗәле бер кеше бар иде. Мин, ике муг [1] кешесе белән шәрик [2] булып, бервакыт аның хезмәтендә

[1] Муг — утка табынучы, зәрдүш динен тотучы
[2] Шәрик — компаньон

торган идем. Шулвакыт бер нәрсә күрдем. Бик гаҗәп һәм сирәк була торган хәл, сезгә сөйлим, файдасы булыр, күңелләрегезне бу дөньяга багламассыз,— диде. Юлдашлары:

— Сөйлә,— диделәр. Егет сөйләде:

— Ул авылның яртысына гына Әбү Дәләф хуҗа иде. Икенче яртысы — ике муг кулында. Ә Әбү Дәләф кичә-көндез шул фикердә иде: ул авылның яртысын муглардан берәр хәйлә белән сатып алмакчы иде. Әмма ул муглар үз өлешләрен һичбер сәбәп белән дә сатмаслар иде.

Бер көн Әбү Дәләф аудан кайтып килә иде. Муглар аны, кадер-хөрмәт күрсәтеп, өйләренә алдырдылар, чиксез кунак иттеләр. Әбү Дәләф, күпме вакытлар инде, авылның яртысы өчен утыз мең кызыл алтын бирмәкче иде, әмма муглар риза булмаслар иде. Мугларның берсе сары киемле иде. Әбү Дәләф күрде — бармагына якут ташлы затлы йөзек кигән икән. Сары күлмәктән кайтарылган нурлар, йөзек ташына төшеп, ул таш гаҗәеп һәм сокландыргыч булып күренде. Әбү Дәләф, хәйран калып, аңа карар иде. Бу муг Әбү Дәләфнең уен аңлады. Шундук, йөзекне бармагыннан чыгарып, Әбү Дәләфнең алдына куйды. Әбү Дәләф йөзекне алды, карады, әйтте:

— Бик матур икән, әмма моның өстенә язылган язу гына бераз зыян китерә,— диде. Ул муг әйтте:

— Әй әмир! Зинһар, андый уй белән күңелеңә шик салма, бу язу йөз-мең йөзектән яхшырак,— диде. Бу йөзеккә чиста уй-фикер язып куелган, мәгънәсе болай: «Әгәр бөтен дөнья падишаһларын үз фәрманыбызда тотсак — ахыры ни? Барча дөнья малын тәмам үзеңә җыйсаң — ахыры ни? Һәммә дәүләтләрне үзебезнеке итсәк — ахыры ни?» Ягъни ахырда һични калмас, юк булыр.

Әбү Дәләф моны ишетте, каты әсәрләнеп, ачы күз яшьләре белән елады. Үзе һаман кабатлар иде: «Ахыры ни?» Һәм үз нәфесенә әйтер иде: «Әгәр бу авылның тәмамы минеке булса — ахыры ни?» Аннан соң үзе үк көйләп әйтеп бирде:

Дөньяны морадыңча уарсың — ахыры ни?  
Гомер китабың укып чыгарсың — ахыры ни?  
Бу җиһанда йөз ел тереклек сөрсәң,  
Тагын да йөз ел торсаң — ахыры ни?!

Әбү Дәләф, шушы сүзләрне әйтеп, авылның икенче яртысын — үз өлешен дә мугларга багышлады. Аннан кайтып китте. Тереклеге беткәнче, гомерен гыйбадәттә үткәрде, бу түбән дөньяны ташлады һәм күңелен ахирәт эшләренә беркетте.

Шушы хикәясен тәмам иткәч, егет әйтте:

— Әй юлдашларым! Бу хикәятнең файдасы шул булыр: дөнья вафасыздыр. Әгәр көнчыгыштан көнбатышкача алтын-көмеш җыйсак — ахырда ни булыр?!

Бу гыйбрәтле хикәят юлдашларына хуш килде, егетне мактадылар. Янә бер егет әйтте:

— Минем дә башымнан кичкән вакыйгам бар, сөйлим, сезгә янә бер файда булсын. Әмма шул шарт белән: ишеткәннән соң, ходай хакы өчен, кабул кылыгыз, кешеләрнең йөз пәрдәсен ертмагыз һәм һич тә көнчелек итмәгез. Көнчелек — бик зур афәт ул,— диде. Юлдашлары әйттеләр:

— Сөйлә! Ничек икән?

Егет сөйләде:

— Ул вакытта мин әле мыек кына чыгарып килгән яшь егет идем. Йөзем күркәм, буй-сыным күңелгә ятышлы иде. Шатланып, горурланып, җиңел һәм матур атлап йөрер идем. Бер көн, алланың казасына каршы, шәһәр читендәге сахрага чыккан идем. Бер инешкә килеп җиттем. Ул инеш Хәҗҗаҗ исемле бер залимнең җәйге сарае яныннан гына ага иде. Киемнәремне салдым, суга кердем. Алланың казасы һәм хөкеме шулай булган икән: Хәҗҗаҗның бер кәнизәге бар иде. Чиксез матурлык иясе, яшь һәм саф иде. Ул кәнизәкнең күз карашы кинәт миңа төште, күңеле белән миңа гашыйк булды. Уйнап кына миңа алма белән атты. Алманы алдым, югары карадым, алманың иясен күрдем: тулган айдай балкып тора. Ул гүзәл сынлыга гашыйк һәм кол булдым, күңел дәртем белән аңа омтылдым. Ул назлы кәнизәк татлы тел белән сүзгә керешә һәм миннән исемемне, билгеләремне сорашты. Мин атым-юлымны әйттем. Аның гыйшкыннан эчем янар-көяр иде. Өч көн хәл-әхвәлем шул рәвешчә үтте. Ахырда ул кәнизәк, үзенең эч серен әйтеп, бер хезмәтчесен миңа җибәрде. Мин бер аулак җир хәзерләп куйдым. Ул гүзәл һәрвакыт килеп җитәр иде. Байтак вакытлар шулай үтте.

Беркөн Хәҗҗаҗ үзенең берничә әмире һәм вәзире белән утыра иде.

Падишаһларның әңгәмә корып утырган вакытларында сөйләнә торган һәртөрле сүзләр сөйләшерләр иде. Хәҗҗаҗ әйтте:

— Барча ризыклардан кайсы ризык яхшырак һәм тәмлерәк икән?

Вәзирләрдән берсе әйтте:

— Мин кечкенә кошларны шикәр, чикләвек, канәфер, шәраб һәм май яккан ипи ашатып симертәм, шулар итеннән яхшырак һәм тәмлерәк ризык булмый,— диде.

Хәҗҗаҗ бу сүздән гаҗәпкә калды. Ә вәзир өенә кайтты, шул рәвешчә симерткән берничә кошы бар иде, аларны кыздырып һәм эчләрен якут-җәүһәрләр белән тутырып, Хәҗҗаҗга җибәрде. Хәҗҗаҗ теге ай йөзле кәнизәкне бик ошата иде, ул кошларның берсен үзенә алды, калганын кәнизәккә җибәрде. Ә кәнизәк исә аларны миңа җибәрде. Минем бер дустым бар иде, аны чакырдым, кыздырылган кошларны бергә ашарга тәкъдим иттем. Дустым килде, ул кошларны аның алдына куйдым, эчләрен ярып, андагы кыйммәтле җәүһәрләрне күрдем. Шундук ул дустымның көнчелеге кузгалды, хөсет чылбырын тибрәтте. Урыныннан торды, ул тәгамны ашамады, Хәҗҗаҗга барып, хәлне аңа әйтте. Хәҗҗаҗ каты ачуланды, чөнки ул кәнизәкне бик якын дусты итеп тота иде һәм башка кәнизәкләргә баш итеп куйган иде. Әмма башта бу сүзгә һич ышанмады. Шундук вәзир артыннан кеше җибәрде:

— Ул кошларның корсакларына ни салган идең?— дип сорады.

Вәзир:

— Якут-җәүһәрләр белән хәзерләгән идем,— дип җавап кайтарды.

Хәҗҗаҗ, кеше җибәреп, кәнизәкне һәм мине чакыртты. Кәнизәккә карады, әйтте:

— Әй мәлгунь! Мин синең хакыңда ниләр генә кылмаган идем, инде син кылган эш шуның хакымы?— диде. Кәнизәк җавап бирде:

— Әй җир йөзенең хөкемдары! Мине бу яман хәрәкәтем өчен шелтәләмә, мине ике нәрсә әсир итте: берсе — тәкъдир, алланың хөкеме миңа шулай булган икән; икенчесе — гыйшык тәэсир итеп, күңелемне ныклыктан һәм ихтыярымнан чыгарып, мине зиндан михнәтенә һәм богауга дучар итте,— диде. Хәҗҗаҗ әйтте:

— Әй бозык! Минем ачуымнан курыкмадыңмы? Синең түбән җаныңны җилгә бирәм, юкка чыгарам бит!

Кәнизәк әйтте:

— Әй атаклы хөкемдар! Гашыйк абруй югалту һәм татлы җан турында уйламас, бу эшкә аяк баскан көннән бирле, мин башымны югалтканмын, синең ачуың хакында кайчан уйлыйм ди?!

Хәҗҗаҗ, җавап таба алмыйча, гаҗиз калды. Миңа карады, әйтте:

— Син кайдан килдең?

Мин әйттем:

— Бу шәһәрнекемен.

Әйтте:

— Мине танымадыңмы, канэчкеч икәнлегемне белмәдеңме, миңа шундый яманлык эшләргә ничек батырчылык кылдың?!

Мин, тереклегемнән өмет өзеп, әйттем:

— Әй әмир! Гомерең озын булсын. Синең канэчкеч һәм залим икәнеңне ишетеп белә идем. Әмма мин гашыйк булдым, җанымнан кулымны юдым, бу хәтәр эшкә аяк бастым, максатым шул иде, ә инде башым бетә икән — хөкем синеке.

Хәҗҗаҗ бераз миңа карап торды, аннан соң кәнизәк белән минем арада йөргән хезмәтчегә карады, әйтте:

— Син ни өчен риза булдың, сиңа ышаныч күрсәткән идем?

Хезмәтче әйтте:

— Әй бәхет иясе хөкемдар! Мине алтын-көмеш юлдан чыгарды, галәмдә алтын-көмеш юлдан чыгармаган кем бар?— диде.

Хәҗҗаҗ, башын аска иеп, бераз вакыт уйланып торды. Аннан соң башын күтәрде, әйтте:

— Бу төр кыен эшләр галәмдә күп булыр, әмма һәр өчесе дөрес сөйләгән өчен гафу иттем,— диде, кәнизәкнең кулыннан тотып, мең динар белән миңа багышлады. Әлеге хезмәтчене дә азат итте. Ә көнчелектән миңа яла яккан оятсыз дустыма әйтте:

— Әй хәрамзадә! Бу егет синең хакыңда кешелеклелек күрсәткән, ул кошларны һәм җәүһәрләрне сиңа биргән һәм серен сиңа әйткән. Нинди шайтан сине бу эшкә китерде, ике мөселманның йөз пәрдәләрен ертып һәм

серләрен фаш итеп, ачып, тагын өч мөселманның канын түкмәкче идеңме?! — диде. Шундук боерды: тегене аягыннан дарга асып, ташлар белән атып үтерделәр.

Кем дә кем агай-энесенә, дустына яки ярына көнчелек чылбырын тирбәтеп яла якса, җәзасы һәм өлешенә тигәне шул булыр.

Бу вакыйгага инде бер ел үтте, ул кәнизәк вафат булды. Ә мин, аның кайгысыннан тынычлыгымны югалтып, башымны калдырып, сөрелеп йөримен.

Бу кызганыч хикәят егетнең юлдашларына хуш килде. Инде өченче егеткә әйттеләр:

— Хәзер чират синеке, син дә башыңнан кичкән берәр вакыйгаңны сөйлә,— диделәр. Ул егет әйтте:

— Минем вакыйгам шул булыр:

Мин шәһәребезнең олы нәселдән булган затларыннан идем. Ләкин алдакчы, тотрыксыз язмыш миннән йөз чөерде, тормышым, көн күрмешем үзгәрде, гаиләм зур булды. Шул көнгә төштем — бер көнлек ашар ризыгым калмады. Анам, хатыным һәм өйдәге ике балам — барчасы миңа бердәнбер туендыручы итеп карарлар иде. Бик каты кайгыга чумдым, чөнки өч көн һәм өч төн инде балаларыма ашатырга бер кисәк ипи дә юк иде. Оятымнан үз хәлемне кешегә әйтмәс һәм кешедән һични сорамас идем, күршеләремнән дә сер итеп саклар идем. Миңа әйттеләр:

— Тор, Бәрмәкиләр [1] җәмгыятенә бар, хәл-әхвәлеңне аларга мәгълүм ит, шаять, алланың тәкъдире шулай туры килеп, синең эшеңә аларның мәрхәмәтле карашы һәм ярдәме булыр.

Мин тордым, гаилә әһелләремне алып, Багдад шәһәренә йөз тоттым.

Менә, Багдад шәһәренә килеп җиттек. Кая барырга да белмәдем, гаҗиз булдым, чөнки бу вакытка кадәр Багдадны күргәнем юк иде. Шәһәр капкасыннан кергәч үк, янында бер мәчет күрдем, гаиләмне шунда калдырдым. Үзем, кайгы-хәсрәткә чумып, алга таба киттем, мәгәр берәр җирдән хәер табармын дип, базарга чыктым. Ләкин, оялганлыктан, һичкемнән дә берни сорый алмадым. Мәхрүм һәм хәсрәтле булып, гаиләмә әйләнеп кайтмакчы идем. Кинәт, алланың әмере белән, бер төркем кешеләр күрдем. Өсләрендә — матур, чиста киемнәр, яхшы атларга атланып, мәгърүр һәм купшы рәвештә киләләр. Мин эчемнән генә: һич шик юк, бу кешеләр берәр җиргә кунак булып бара торганнардыр. Мин дә ияреп барыйм, шаять, балаларыма берәр кисәк икмәк яки ризык калдыклары алып кайтырмын,— дип уйладым, шул уй белән аларга ияրдем.

Бер биек сарайның ишек төбенә килеп җиттек. Ул сарайның түбәсе күккә ашкан, ишегенә кәрәз сыман челтәр пәрдә эленгән. Эчкә кердем, анда исә һәр дүрт якка утыргычлар куелган, һәрберсе тәхет сыман, җәүһәрләр белән бизәлгән. Килгән кешеләрнең барчасы шул утыргычларга барып утырдылар. Шунда ук җәүһәрләр белән бизәлгән тагын бер алтын урындык чыгарып куйдылар һәм тулган ай кебек бер егетне шул урындыкка утырттылар, аның сөйләгәнен тыңладылар. Ул егет сүзен тәмам иткәч, сарай эченнән хезмәтчеләр чыга башлады. Алар мәҗлестә булган һәр кешенең алдына алтын тулы берәр табак куеп киттеләр. Мин, тартынып һәм уңайсызланып, табакка карарга да кыймас идем. Андагы кешеләргә карадым: һәрберсе, табаклардагы алтыннарны алып, кесәләренә һәм куеннарына салдылар. Ә мин, куркуымнан һәм берни белмәгәнлектән, табакка кул сузмас идем. Хезмәтчеләрнең берсе миңа әйтте:

— Әй шәех! Ни өчен табактагы алтынны алмыйсың? — диде. Мин алтынны алдым, шатланып, ишеккә таба киттем. Шулчак:

— Әй шәех, кая барасың? — дигән бер аваз килде. Мин шикләндем. «Алтынны миннән кайтарып алмагайлары» дигән уй белән сарай ишегенә җиттем. Теге алтын урындыкта утырган егет янында тагын бер егет бар иде. Мине күрделәр, ачык йөз күрсәттеләр, сорадылар:

— Кайсы шәһәрдән син? Бу шәһәргә ничек төштең, читтән килгән кеше күренәсең? — диделәр. Мин әхвәлемне сөйләп бирдем. Әйттеләр:

— Син монда гаиләң белән Бәрмәкиләр өчен килдеңмени?

— Әйе,— дидем. Әйттеләр:

— Син бу җирдә туктал, синең өчен Бәрмәкиләрне белешербез, аннан соң сине аларга хезмәткә җибәрербез, алар сине максатыңа җиткерерләр.

[1] Бәрмәкиләр — иранлыларда атаклы нәсел. Габбасилар хәлифәлеге заманында (VIII—IX гасырлар) алар сарайда иң югары дәүләт урыннарында торганнар.

Аннан соң ул егетләрнең берсе миңа әйтте:

— Гаиләң кайда калды?

Мин әйттем:

— Мәчеттә калдылар,— дидем. Боердылар, тәм-том һәм ашамлык китерттеләр. Миңа әйттеләр:

— Бу тәгамне аша, без янә килербез,— диделәр.

Мәнә кич җитте. Егетләрнең берсе мине алырга килде һәм бер сарайның ишек төбенә китерде. Әйтте:

— Бу сарай — Бәрмәкиләрнеке. Кер, мин дә керермен, сине кайгыртырга, тәрбияләргә кушармын,— диде. Мин ишектән кердем, шундый бер сарай күрдем ки — җәннәт кебек бизәлгән, төрле-төрле келәмнәр, төрле төстәге пласлар түшәлгән, затлы пәрдәләр эленгән. Ул сарайның уртасына җиттем һәм шунда балаларымны күрдем: яхшы киемнәр киеп басып торалар. Ялгыш күрәм дип, хыялый булдым. Баягы егет килеп керде, әйтте:

— Әй ир-егет! Бу сарай барлык нигъмәтләре белән синеке һәм минеке булыр. Бу сарайда ике елга җитәрлек ашау-эчү әйберләре, кирәкле һәм яраклы нәрсәләр — һәммәсе дә бар. Һәм сезгә тагын уң кәнизәк, мең кызыл динар, ике авылның керемен багышлыйм, айлык һәм еллык хезмәт хакы бирәм. Башка кирәкле, тиешле нәрсәләрне безнең бер ышанычлы кешебез һич кимчелексез җиткереп торыр,— диде.— Инде бел, әй егет, без — Бәрмәкиләр булабыз, син безгә сыену урыны эзләп килгәнсең икән, без сиңа тиешле ярдәм күрсәтербез.

Мин бу кадәр юмартлык һәм ягымлылык күргәч, егетнең аягына төштем, исемен белдем: Яхъя Бәрмәки икән. Ул мине сарайда калдырды, үзе китте.

Мин янә сарайга кердем, гаиләмне күрдем, якут-җәүһәрләргә чумганнар, төрле-төрле киемнәр кигәннәр, төрле нигъмәтләр каршына утырганнар, яннарында ун кәнизәк хезмәт итеп тора. Мин бик тә шат булдым. Шактый вакытлар анда яшәп, авыллардан кергән малны алып, кирәгемчә тотар идем.

Ахырда ялгыш фикергә биреләдем. Беркөн күңелемдә тәкәбберлек һәм мин-минлек ялкыны күтәрелде. Әйттем:

— Бу көн минем кебек кем бар?!— дидем. Бу уем аллаһы тәгаләнең күңеленә хуш килмәде, казасын салды. Ул заманның падишаһы Бәрмәкиләрнең барысын да җавапка тарттырды. Һәммә мал һәм милекләре китте, мин дә хәерчелектә калдым, балаларымның кайсысы үлде, кайсысы фәкыйрьлеккә төште. Ә мин исә сезнең белән шушы рәвешчә сөрелеп йөрергә мәҗбүр булдым. Инде бу баштан үткәннәремнең сезгә файдасы шул: зинһар өчен, мин-минлек, тәкәбберлек кылмагыз, югыйсә, бәхетсезлек килер, соңы начар булыр.

Бу хикәят юлдашларына хуш килде. Аннан соң картка карадылар, әйттеләр:

— Әй озак еллар яшәгән карт! Без башыбыздан кичкәннәрне сөйләдек, син дә бәян ит,— диделәр. Карт әйтте:

— Мин башымнан кичкән һичбер вакыйга белмим,— диде, төрле-төрле ант эчте. Егетләр әйтте:

— Әгәр хикәятеңне сөйләмәсәң, ничек шарт куйган һәм вәгъдәләшкән булсак, шуны үтисең.

Карт чарасыз калды, күңелсезләнде, һич җавап әйтә алмады. Боларны бер-бер артлы күтәреп, арып-талып, сахрадагы шул биек сарайга җиткерде.

Бу җәйге сарайда падишаһ кызы яши иде, заманaның чибәре, шул чорның бердәнбере иде. Аны, даясе һәм берничә кәнизәге белән бергә, чит-ят кешенең күзе төшмәсен дип, оҗмах бакчасына охшаган шушы сарайга китергәннәр иде. Кыскасы, бу көн әлеге кыз сарай тәрәзәсеннән карап утыра иде. Кинәт күзе сахрага төште, картның җилкәсенә чиратлашып атланып килүче егетләрне күрде. Ул карт, аларның һәрберсен аркасына йөкләп, егыла-тора атлап, мең мәшәкать белән бу сарайның ишегенә җиткерер иде. Кызның бу хәлгә эче пошты, бер хезмәтчесен җибәреп, юлчыларны чакыртты. Кыз әлеге егетләргә әйтте:

— Әй залимнәр, вай кеше рәнҗетүчеләр! Минем атамның шәһәрендә хаклык хөкем сөрә, монда бүре белән куй бер арыктан су эчәләр. Ә сез, куәтле һәм таза өч егет, бер зәгыйфь, хәлсез картның җилкәсенә менгәнсез. Мин шушы сәгатьтә үк бу мескеннең хакын һәм үчен сездән алам, башкаларга гыйбрәт булсын!— диде. Егетләр әйттеләр:

— Әй мәликә! Гомерегез озын булсын, без картка һич золым кылмадык, чөнки бу карт белән безнең арабызда шундый ант һәм шартыбыз бар иде: һәркайсыбыз берәр хикәят, ягъни башыбыздан кичкән берәр вакыйга сөйлибез,

кемнең вакыйгасы гаҗәбрәк булса, аны кеше яши торган урынга күтәреп җиткерәбез, дип сүз куешкан идек. Инде сезгә мәгълүм булсын: без, вәгъдәбезгә тугрылыклы булып, һәркайсыбыз бер хикәят, баштан үткән бер вакыйга сөйләдек, бу карт сөйләмәде. Арабызда булган шарт һәм килешенү буенча гамәл кылдык, золым кылмадык.

Кыз карттан сорады. Карт әйтте:

— Әйе, дөрес әйтәләр,— диде. Кыз әйтте:

— Син ни өчен хикәятеңне сөйләмәдең?

Карт әйтте:

— Хәтеремдә юк,— диде. Кыз әйтте:

— Шушы яшькә җитеп, башыңнан һичбер вакыйга үтмәдемени?

Карт әйтте:

— Үтмәде,— диде. Кыз гаҗәпкә калды, янә картка әйтте:

— Яшең ничәгә җитте?

Карт әйтте:

— Җитмешкә,— диде. Кыз әйтте:

— Минем башым унҗидегә җитте, шул унҗиде ел эчендә мең төрле әхвәл-вакыйга башымнан кичте. «Җитмеш ел эчендә башымнан һичбер вакыйга үтмәде» диюең — дөньяның бер гаҗәбедер.

Карт әйтте:

— Әйе, нәкъ шулай,— диде. Кыз егетләргә әйтте:

— Әгәр мин үз башымнан үткәннәрне бу бичара карт хакы өчен сөйләсәм, ярармы?— диде.

Егетләр әйттеләр:

— Хөкем — сезнекедер.

Кыз сүз башлады, сөйләде:

— Мин унөч яшемдә идем. Беркөн базар уртасыннан үтеп бара идем, бер тегүченең улын күрдем, остаханәдә нәрсәдер тегеп утыра. Күрүем белән, аңа чын күңелдән гашыйк булдым. Шулкадәр тәэсирләндем: аякларым хәлсезләнде, остаханәдән атлап чыгарлык көчем калмады. Берничә кәнизәк һәм хезмәтче янымда иде, базарда рисвай булам дип, йөз хәйлә белән үземне тыйдым.

Өемә кайттым, әмма әүвәлге тынычлыгым югалган иде инде. Гыйшык уты көннән-көн газаплап, күңелем ялкыннары күкрәгем учагыннан чыгып, баш миемә үрләп, намус-оятымны, сабыр-түземлегемне көйдерде; ахырда, алла белән ант итәм, сөягемә кадәр җитте. Тәкатьсез булып, серемне сөт анама әйттем. Даям әйтте:

— Моңа чара булыр, син әле бик яшь, гыйшык тотуны белергә иртәрәк,— диде, мине күп үгетләде, шелтәләде. Мин даямнең сүзен колагыма да элмәдем.

Кыскасы, бер хезмәтчегә тегүче егетнең билгеләрен әйттем, аны алып килергә куштым. Егет килде. Мин, аның зифа буй-сынын күргәч, һушымнан китә язып, мең хәйлә белән үземне туктаттым. Төрле төстәге парчаларны алдына куеп, әйттем:

— Берничә күлмәклек кис!— дидем. Шуны үтенгән булып, сылтау таптым. Ул — яхшы холыклы, әдәпле егет — оялып һәм тарсынып кына, парчаларны кисте, эшеннән бушагач, китәргә теләде. Мин әйттем:

— Безнең гадәт һәм йолабыз шундый: кем дә кем безнең сарайга килсә, ризыктан авыз итмичә китмәс,— дидем, алдына ризык китертеп куйдым. Ул, башын аска иеп, әдәпле кыяфәт белән ашамлыктан авыз итә башлады. Мин, итне үз кулым белән кисеп, алдына куяр идем. Ул егет, минем бу тыйнаксыз хәрәкәтләремне күреп, башын күтәреп, «ләхәүлә»сен укыр иде. Өй аулак иде. Егетне үземә таба тартып, кочаклап, шикәр иреннәреннән үптем. Ул—диндар һәм тыйнак егет—минем бу әдәпсез эшләремне күргәч, әйтте:

— Әй, ай йөзле хур кызы! Мондый яман хәрәкәтләр кыласың, ходайдан курыкмыйсыңмы? Ул, серләрне һәм бөтен яшерен нәрсәләрне белүче, күреп тора бит!— диде. Минем ачуым килде, куркытам дип, егеткә пычак белән селтәндем. Казага каршы, пычак аның бугазына тиде. Егет шунда ук егылды, җан бирде. Бу фаҗигале вакыйганы күргәч, эчемдә ут кабынды, тәтене тамагымнан чыкты. Хәйран булып, борчылып, шунда ук даямне чакырдым, вакыйганы белдердем. Даям әйтте:

— Мин сиңа «Мондый мәгънәсез, ялган фикерне кылма, ансат кына кулга кермәс, соңыннан үкенү файда китермәс», димәдемме? Инде ул эшне кылдың, гөнаһсыз бер егетнең канын түктең, өстеңә олы гөнаһ алдың,— диде. Мин әйттем:

— Әй миһербанлы даям! Бу ачулануың, шелтәләвең урынлы түгел, бер чара кылсаң икән, югыйсә, сер ачылмагае,— дидем. Ахырда шуны яхшы дип таптык: үтерелгән егет яткан бүлмәне бикләп, йозаклап куйдык. Ачкычын үземә алдым.

Төн җитте, халык йоклады. Ул мескеннең гәүдәсен бер паласка чорнадык, сарайның бер почмагына ташлыйбыз дип йөрдек, ләкин ташлый алмадык, чөнки сарайның һәр ягы сакчылар белән тулы иде. Шулай итеп, гәүдәне бүлмәдә калдырырга туры килде. Ходайның казасына ризалык бирдек.

Шулай шактый вакыт үтте. Каравылчылар сизенә башладылар. Һәркайсын бер-бер хәйлә белән тынычландырыр идек.

Атамның сараенда, каравылчылар арасында кара тәнле бер мәсхәрә, исәр сыманрак кол бар иде. Исеме Макбиләк иде. Һәркем аннан көлеп, мәсхәрә итеп, аның муенына бер сугып китәр иде. Ахырда шуны яхшы күрдек: Макбиләкне чакырдык, алдына илле кызыл динар куйдык, әйттек:

— Бу кызыл динар сиңа булсын. Бу паласны бер җиргә яшереп куй, һичкем тоймасын, әмма шул шарт белән: бу паласны ачып карамыйсың,— дидек. Макбиләк явыз, бу алтыннарны күргәч, әйтте:

— Әгәр ул паласның эчендә ни икәнен белсәм, илтеп яшерермен,— диде. Без әйттек:

— Синең анда ни эшең бар?

Макбиләк әйтте:

— Бу паласның эчендә ни икәнен белмичә, яшермәм.

Даям белән күпме генә үгетләсәк тә, һич файда булмады. Бәхәс, тарткалашу күп булды, чиктән ашты. Чарасыздан паласны ачтык, үлекне күрсәттек. Макбиләк әйтте:

— Миңа әйтегез, бу үлек кем, вакыйгасы ничек?

Мин гаҗиз һәм кайгылы булдым, вакыйганы сөйләп бирергә туры килде. Ул хәрамзадә кара кол, бу сүзне ишеткәч, йөзен миңа борды, әйтте:

— Әгәр теләсәң, бу вакыйга, бу фаҗига һәм бу серләр яшерен калсын дисәң, шул кирәк: син, миңа буеңны биреп, куеныма керсәң — һәммәсен булдырырмын. Юк исә — мин һичкайчан бу эшкә аягымны атламам, ә бәлки сереңне ачармын,— диде. Аннан бу сүзне ишеттем исә — якты дөнья күземә караңгы булып күренде. Мин әйттем:

— Әй надан Макбиләк! Мин падишаһның саф һәм намуслы кызымын, миңа мондый пычрак, әшәке сүзләр әйтмә!

Ул кара кол миңа шундук җавап бирде:

— Ул тегүче егет белән гыйшык уены уйнаганда гафифә түгел идең, инде бу сәгать изге һәм чиста булып кыланасың.

Мин әйттем:

— Мондый буш, мәгънәсез сүзләрне ташла, башыңнан чыгар, сине дөньялыкта бай итәм, ризалатам,— дидем. Ул әйтте:

— Әгәр бөтен дөньяның малын бирсәң дә, минем морадымны бирмичә, файда булмас,— диде. Мин каты кайгыга төштем. Атама рисвай булуымнан куркыр идем. Макбиләк исә һәрдаим килеп янар иде, кире кагып сүз әйтү һич файда бирмәс иде. Ахыры, ходайның казасына ризалык биреп, ул начар эшне кабул кылдым... Ул хәрамзадә, морадына ирешеп, паласны илтеп яшерде. Мин бер кайгыдан котылдым. Әмма теге кара йөзле бәндә мине үз иркенә шулкадәр буйсындырды ки — кайчан теләсә, шунда миннән теләгәнен алып китәр иде. Мин, гарьлектән һәм ризасызлыктан интексәм дә, атамнан куркып, һич сүз әйтә алмас идем. Шактый вакыт шул рәвешчә үтте.

Алланың казасына каршы, бервакыт атам гаскәре белән ауга китте. Бер төркем сакчыларны сараебызның капка төбендә каравылга куйды. Мәгәр бер кичә сакчылар каравыл йортының ишек төбендә торырлар иде. Макбиләк аларның арасында күңел ачар иде. Ул сакчылар бу кичә үз хатыннарын да алып килеп тамаша кылырлар, күңел ачарлар иде. Һәм дә Макбиләк наданның муенына орып, әйттеләр:

— Син дә хатыныңны китер,— дип, аны мәсхәрә итеп көлделәр. Макбиләк әйтте:

— Сез мине мәсхәрә итәсез, мине түбәнсетәсез, әгәр мин мәгъшукамны сезгә күрсәтсәм, валлаһи дип әйтәм, барыгызның да үте сытылыр!

Сакчылар әйтте:

— Синең мәгъшукаң кем соң?

Ул хәрамзадә, исереклегеннән үзен-үзе белештермичә, әйтте:

— Сезнең падишаһыгызның кызы ул!

Барчасы көлеп, мәсхәрә итеп, тавышландылар:

— Моннан соң, бу көннән соң, мондый мәгънәсез сүзне сөйләмә, безнең башыбызны ярырсың,— диделәр. Макбиләк әйтте:

— Әгәр ышанмасагыз, шушы сәгать барып, алып килеп, сезнең яныгызда утыртам,— диде. Сакчылар көлде:

— Ходай хакы өчен, әгәр дәгъвавң рас икән — күрсәт!

Макбиләк шундук урыныннан кубып, оятсыз рәвештә минем яныма килеп керде. Мин әйттем:

— Бу тиешсез вакытта ни эшләп йөрисең?— дидем. Ул әйтте:

— Шул кирәк: хәзер үк тор, минем белән сакчылар арасына барып, күңел ачуга катыш. Анда барысы да хатыннарын китергәннәр.

Мин әйттем:

— Әй Макбиләк, син яман хәрәкәт кыласың, мондый эшәке эшне һәм сүзне ташла,— дидем, ничә мәртәбә каршы әйтеп карадым. Әмма тәэсир итмәде. Чарасыздан тордым, хәзинәмә кереп, бераз агу алып, ул юлбасар белән сакчылар янына бардым. Сакчылар мине күрделәр, урыннарыннан кубып, әдәпле кыяфәт белән тордылар. Мин алар янына барып утырдым. Әйттем:

— Мин бу кичә сезнең белән мәҗлестәш булам, ләкин шул шарт белән: сакый [1] мин булсам икән,— дидем. Алар әйттеләр:

— Хөкем — сезнекедер.

Макбиләк һәр мизгелдә кулын муеныма салып үбәр иде. Сакчылар, мәсхәрәнең мондый хәрәкәтләреннән гаҗәпләнеп, хәйранга калырлар иде. Мин шәраб касәләрен алдым, һәркемгә агу салып бирер идем, эчеп егылырлар иде.

Шулай итеп, барысы да егылды. Мин пычак алдым, әүвәл кара йөз Макбиләкнең башын кистем, сакчыларның корсакларын ярдым, хатыннарын да һәлак иттем. Эшләрен тәмам кылып, сарайга кереп йокладым.

Таң атты исә:

— Падишаһның каравыл йортындагы сакчыларын үтереп киткәннәр!— дигән тавыш купты. Шулай итеп, бу бәлане шул чара белән кире кайтардым.

Берникадәр вакыт үтте. Мине бер падишаһның углы кияүгә сорады. Атам бирергә булды. Туй кирәк-яракларын хәстәрли башладылар. Минем эчемә янә ут төште. Даямне чакырдым, әйттем:

— Әй миһербанлы даям! Минем ни өчен борчылуым сиңа ачык, шуңа бер чара яки хәйлә кылсаң икән, мин киявем алдында әүвәлге кичтә оят һәм уңайсызлыктан котылсам икән?— дидем.

Даям әйтте:

— Әй ай йөзлем! Мин бу хакта сиңа караганда йөз-мең тапкыр кайгылырак, хәсрәтлерәк булып торам. Әмма һич төрле юл һәм чара табарга аң җитми, — диде. Даямнән моны ишеткәч, каты кайгыга чумдым. Ахырда оста куллы бер рәссам чакырттым һәм каршыма утырттым. Каш-күземне, буй-сынымны тәмам күрсәттем һәм әйттем:

— Әй оста һөнәрле рәссам! Сурәтемне төшереп һәм тасвир кылып ал, шул сурәттәге берәр кәнизәкне, ничек кенә кыйммәт бәһале булса да, эзләп тап. Миңа шундый охшаган булсын — заманаының акыллылары һәм бу чорның зиһенлеләре дә аны — миннән, мине аннан аерып ала алмасын. Һәм бу серне һичкемгә белдермә. Мин сиңа гомерең буена җитәрлек байлык бирермен,— дидем. Рәссам әйтте:

— Фәрманыңны кабул кылдым, җаным-күңлем белән бу юлда тырышлык куярмын,— диде.

Берникадәр вакыттан соң ул бер чибәр кәнизәк алып кайтты. Һичкем аны — миннән, мине аннан аера алмаслык иде. Мин чиксез шат, хуш күңелле һәм бәхетле булдым. Ул кәнизәкне чакырдым, әйттем:

— Бел һәм аң бул: мин сине шулкадәр зур бәягә сатып алдым, бу кадәр юмартлык һәм хөрмәт күрсәттем. Болар һәммәсе шул бер кичә өчен, аннан соң сине бу ике-өч көн эчендә берничә мең динар биреп азат итәрмен. Кемне күңелең сөйсә, шуңа никах кылып бирермен. Әмма минем бер хаҗәтем бар, аны кабул кылсаң икән,— дидем. Сиңа хаҗәтем шул: мин сиңа хәбәр иткән вакытта киявемнең кочагына кереп ятарсың, максатын синнән алыр, күңелен күрер. Аннан соң, торып, үз урыныңа китәрсең. Киявем янына инде мин барырмын.

Кәнизәк әйтте:

---

[1] Сакый — шәраб өләшүче

— Әй маһруй, хөкем синекедер, мин ул эшне эшләрмен, син кушканны үтәрмен,— диде. Кәнизәкнең бу сүзенә күңелем булып, йөзен һәм күзен үптем һәм сабыр иттем.

Ниһаять, мине киявем янына илттеләр, бүлмәсенә кердем. Киявем исерек иде, минут саен уянуын көтәр идем, кәнизәкне шунда янәшәдә генә яткырган идем. Киявем уянды, тиз генә тордым, кәнизәкне уятып, куенына салдым. Киявем, кәнизәккә кул озатып, теләге гәүһәрен аның әнже кабырчыгына куйды, морадын тәмам кылып, янә йокыга китте. Мин әйттем:

— Әй кәнизәк! Үз урыныңа бар!

Тугрылыксыз кәнизәк җавап бирде:

— Бу ир — минем киявем, аллаһы тәгалә аны миңа насыйп итте,— диде. Ул вәгъдәсен бозган кәнизәккә кат-кат әйтеп карадым — файдасы булмады, кулын киявемнең муенына салып, катырак кочаклар иде. Мин, каты куркып һәм өметсезлеккә бирелеп, ул урыннан торып киттем. «Киявем йокыдан уянмагае, бу серне белмәгәе» дип, чарасыздан аш бүлмәсе ягына чыктым. Ашханә эченә утын тутырганнар иде, ул утынга ут төртеп җибәрдем, аш бүлмәсен бөтенләй ут чолгап алды. Ул бүлмә киявем белән кәнизәк яткан өйгә тоташ иде, ут аның түшәменә дә үрләде. Халык кычкырыша, шаушу килә башлады, киявем йокыдан уянды, утның ялкыннарын күрде, качып, түбә өстенә чыкты. Мин артыннан бардым, күрдем: кәнизәк янында тора. Киявем хәмер һәм йокы исереклегендә иде, хезмәткәрләргә кычкырды:

— Тизрәк су китерегез, утны сүндерегез!— диде. Мин, шул шау-шудан файдаланып, киявем белән кәнизәкнең арасына кердем. Ул каһәр суккыры кәнизәкне ут эченә төртеп төшердем. Шулай итеп, мин ул каты бәлаләрдән котылдым.

Инде минем бу гыйбрәтле хикәятемнең сезгә берничә файдасы булыр. Берсе шул: һәркем, һәр кеше ходайдан курыксын, күзен һәм тәмам әгъзаларын яман эшләрдән сакласын, аңсыздан гыйшык утына дучар булса, сабыр итсен. Әгәр сабыр кылмаса, минем кебек рисвай булыр. Икенчесе шул: һәркем үз чигеннән тышка аяк басмасын, бары-югыннан канәгать була белсен. Әгәр шулай канәгать итмәсә, сакчы Макбиләк кебек һәлак булыр. Өченчесе шул: һәркем кешенең яхшылыгын белсен, исендә тотсын, вәгъдәсендә һәм сүзендә нык торсын. Әгәр шулай булмаса, тугрылыксыз кәнизәк кебек башын югалтыр.

Карт һәм юлдаш егетләргә бу кызның башыннан кичкәннәре бик гаҗәп булды, күңелләренә хуш килде, барысы да хикәятне һәм кызны мактадылар, афәрин әйттеләр.

## Җәйсур хикәяте

Хикәятчеләр шундый риваять китерделәр:

Борынгы заманда бер олы падишаһ бар иде. Мәмләкәтенең озынлыгы — киңлеге чиктән тыш иде. Җәйсур исемле бер углы бар иде, шул углын гаять якын күрер, гаять сөяр иде, зирәк, белемле һәм дә һөнәрле итеп тәрбияләр иде.

Шулай бервакыт шаһзадә ауга чыкты. Гаскәр тукталган урыннан аерылып китте, адашты. Даланы гизеп йөрде, юл күрсәтерлек бер кеше дә булмады. Ачлык михнәтен күп кичерде, ахырда бер ят җиргә килеп чыкты.

Күрде: бер манарага кеше башларын асып куйганнар. Кешеләрдән сорады:

— Нәрсә бу?— диде.

Әйттеләр:

— Симхар шаһның шахматны оста уйнаучы бер кызы бар, гаять чибәр. Бөтен дөньяның шаһзадәләре килеп, шахмат уйнап җиңелә, кыз башларын отып ала, монда аса,— диделәр. Шаһзадә моны ишеткәч әйтте:

— Мин дә шахмат уйный беләм, үземне сынап карасам ни булыр? Йә башымны югалтам, йә тагын бер баш алам,— диде. Шул уй белән солтанның вәзире янына барды. Әйтте:

— Солтанның шахматка оста кызы бар икән, аның белән көрәшсәм икән,— диде. Вәзир әйтте:

— Әйе, бик чибәр кыз, ләкин шуны белдерәсем килә: һушсыз итеп,

башыңны алыр. Бу теләктән кире чиген, бу — башкарып чыгарлык эш түгел,— диде. Шаһзадә әйтте:

— Барыбер уйнармын. Шаһка белдерегез!— диде.

Бу хәбәрне ишеткәч, шаһ кызы шатланды, әйтте:

— Канга сусап торам, яхшы булды, килсен!— диде.

Килешенеп, мәҗлес җыйналды. Алланың ярдәме белән, Җәйсур җиңүче булды. Әмма кыз, үзенең матурлыгы белән горурланып, Җәйсурга кырын карады. Солтан кызын күп тапкырлар үгетләде:

— Инде никадәр ярамас эш эшләдең, булачагы булды, иткәнең явыз эштер, ояттан башка ни файда?— диде.— Әгәр Җәйсурның дәреслегенә шикләнсәң, аны тикшереп карыйсың килсә, берничә йөк мал бирим, сәүдәгәр рәвеше белән барсын, нәрсә дә булса эшләсен, керем алып китерсен,— диде. Кыз бу сүзне ишеткәч:

— Ярар. Җәйсурдан сорагыз, бу эшкә риза булса, берничә йөк мал бирегез, барсын, эшне бетереп кайтсын,— диде. Җәйсурга әйттеләр исә, риза булды. Кыз әйтте:

— Бу төлке кулыннан котылу юк икән,— диде. Тагын да вәзиргә яшерен сүз әйтте:

— Моны бер хәтәр җиргә озат, бүтән килмәсен, анда олаксын,— диде.

Җиде йөк кыйммәтле гуд агачы төяделәр. Җәйсурга йөк хайваннары белән идарә итүне тапшырдылар, «Фәлән шәһәргә илт, анда сатып алучы күп»,— диделәр.

Мәгәр ул шәһәрдә өч хәйләкәр, алдакчы, үткен бар иде. Вәзирнең Җәйсурны анда озатуының максаты да шул иде: мал анда югалыр, Җәйсур оттырыр, шаһ кызы үз иркендә калыр дип өметләнде.

Җәйсур, байлыкны алып, шул шәһәргә китте. Ничәмә тукталышларны үтә-үтә, барасы җиренә якынлашты.

Әлеге шәһәрдәге өч хәйләкәр кеше, җиде йөк кыйммәтле гуд агачы килүен ишетүгә үк, үзара сүз беркеттеләр, байлыкны алдап алырга уйладылар. Аларның берсе — тире иләүче, икенчесе — орлык һәм ашлык белән сәүдә итүче, өченчесе сыер башларын сатучы иде. Берсен, алдап алу өчен, Җәйсурның каршына җибәрделәр. Шәһәр алдында бер тау бар иде, анда кәрван килеп кунар иде. Ул кеше шунда барып торды. Анда гудка охшаган агачлар бар иде, шуларны күп итеп янына җыйды.

Шул вакыт Җәйсур килеп җитте, сәлам бирде. Әлеге кеше сәламне алды. Җәйсур әйтте:

— Әй туган! Товарымның бәһасе күпме булыр?— диде. Теге:

— Яхшы булса, йөген биш-алты бакырга алырлар,— диде. Җәйсур гаҗәпләнде:

— Ни сөйлисең?— диде.

— Ни ишетсәң — шуны. Бу шәһәрдә гуд агачын утынга гына ягалар. Менә шуны ягып утыруымны күрмисеңмени?— диде әлеге алдакчы.

Җәйсур әйтте:

— Мин боларны шәһәргә илтеп сатмакчы идем,— диде. Алдакчы әйтте:

— Шунда бушат, ни дип шәһәргә илтәсең, мин монда юлдашларым килеп җиткәнче яндыра торыйм,— диде. Янә әйтте:

— Бу утынны калдырсаң, шәһәргә баргач бер баш бирермен үзеңә,— диде.

Җәйсур китеп барды, тагын бер алдакчыга юлыкты. Ул да шул рәвешчә алдады. Аңа да ике йөкне бушатты. Алдакчы әйтте:

— Мин тире иләүчемен. Яныма килсәң, бер киемлек тире бирермен,— диде.

Аннан соң Җәйсур тагын бер алдакчыга юлыкты. Ул да, тегеләр кебек, өч йөкне бушаттырды. Әйтте:

— Мин — орлыкчымын. Килсәң, бер капчык орлык бирермен,— диде.

Җәйсур, тәмам малсыз калып, шәһәргә килеп керде. Аңа бер карчык очрады, карчыкның бер күзе генә күрә иде. Җәйсурның кушагына кыстырган гуд ботагыннан бер чыбык күрде. «Мөхәммәткә салават» дип, чыбыкны алды, күзенә сөртте. Ике күзе дә күрә башлады. Хакка шөкер итеп, Җәйсурның аягына төште. Җәйсур сорады:

— Ни булды?— диде. Карчык әйтте:

— Гуд чыбыгы белән сөрттем исә — күзем ачылды. Тагын бармы агачың?— диде. Җәйсур әйтте:

— Әй ана! Иөгемнең һәммәсе гуд иде, әле генә монда мине алдадылар, агачны кулымнан гел бушка алдылар, ни эшлим?— диде. Карчык:

— Әй углым! Синнән игелек күрдем, хезмәтчеңмен, кил, өемдә кун, качырларыңа да урын табылыр,— диде. Янә әйтте:

— Сине алдаганнар. Фәлән җирдә бер мунча бар, аның янында бер кечкенә бүлмә бар, караңгы төшкәч, шуның түбәсенә чык, кырына барып ят, колак тот, ни сүз кичсә — тыңла, шаять, дәртеңә бер дәрман булыр,— диде.— Гудның бу җирдә бәһасе үз авырлыгындагы саф алтындыр,— диде.— Бу кадәр алтынны әрәм җибәрү ярамас,— диде. Җәйсур әйтте:

— Әй ана! Алар кемнәр булыр?— диде. Карчык әйтте:

— Әй углым! Бу шәһәрдә алдакчы һәм хәйләкәр халык күп, аларның башлыклары да бар. Кич булгач һәрберсе килер, башлыкларына шикаятен белдерер. Ул аларга җавап бирер, аны истә тотарга боерыр. Яхшы эшләде исә, изге дога кылыр. Әгәр кешене алдый алмаса: аны өйрәтер, кирәкле очракта аның тиешле җавабы булыр,— диде.

Җәйсур кичен карчык әйткән җиргә барды. Түбә өстенә чыкты, шыпырт кына колак салып ятты.

Беренче булып тире иләүче килде. Җир үпте, карт алдында баш куйды. Карт сукыр иде, тире иләүчене капшады. «Хуш килдеңме?»— диде. Тире иләүче әйтте:

— Бу көн юлга чыккан идем. Бер тилегә очрадым, ике мең торырлык гуд агачын алдым,— диде.

Карт әйтте.

— Сатучы ни әйтте, син ни бирәм дидең?— диде. Тегесе әйтте:

— Бер киемлек тире бирәм, дидем.

Карт әйтте:

— Яхшы булмаган, ачык һәм төгәл әйтергә кирәк иде. Әгәр сатучы ул тирене синең җилкәңнән алырга теләсә, син нәрсә әйтерсең?— диде.

Тире иләүче әйтте:

— Әй сөекле шәех! Куй, ул кеше бер надандыр, андый сүзне әйтә алмас, ул ни белсен?!— диде. Карт әйтте:

— Ярар, мин сиңа әйттем, хәзер бул,— диде.

Аннан соң баш-аяк сатучы килде. Картның кулын-аягын үпте. Ярдәм итүен теләде, әйтте:

— Әй шәех! Ике йөк гуд агачы кулга төшердем,— диде. Карт әйтте:

— Алдапмы, йә сатып алыпмы?— диде. Ул әйтте:

— Бер баш бирергә булдым,— диде.

Карт әйтте:

— Ачык әйтү кирәк иде. Иртәгә килеп, синең үз башыңны сораса, ни диярсең?

Баш-аяк сатучы әйтте:

— Бу сүзне белер кеше түгел ул,— диде.

Аннан орлыкчы килде. Ул да кул үпте. Өч йөк гуд турында сөенеч хәбәрен белдерде. Карт әйтте:

— Акчага килешепме, яки бирәр нәрсә бирепме?— диде. Ул әйтте:

— Шәһәргә килсәң, бер капчык орлык алырсың,— дидем. Карт әйтте:

— Әгәр ул ир орлыгы сораса, нишләрсең?— диде. Орлыкчы әйтте:

— Аны белер кеше түгел ул,— диде.

Җәйсур боларны хәтеренә беркетте, өенә кайтты, маҗараны сөйләде. Карчык әйтте:

— Күзең ачылды, эшеңне күрү артыннан йөр,— диде.

Таң атты. Җәйсур базарга керде. Баш сата торган кибеткә килде, күрде: сатучы баш-аякны очсыз бәягә сатып утыра. Сәлам бирде. Сатучы әйтте:

— Бу башларның кайсын телисең — шунысын ал!

Җәйсур әйтте.

— Бу баш белән мин нәрсә эшлим? Миңа синең башың кирәк,— диде. Янә әйтте:

— Һай, күзеңне ач, мине шахматчы Җәйсур диярләр, мин — шаһзадә, мин синең турыда үз шәһәремдә ишеткән идем, теләгем сине сүзеңнән эләктерүдә иде. Бу шәһәрне синең яманлыгыңнан коткарам, ике йөк гудны бер башка бирдем, юкса ике йөк гудны бер башка бирер идемме?!— диде.

Аннан тире иләүчегә барды. Җилкәсеннән тиресен телеп алырга сорады. Аннан соң орлыкчыга барды, бер капчык ир орлыгын сорады. Ул көнне әлеге алдакчыларны артык рәнҗетмәде, өенә кайтты.

Ә алдакчылар, кич булгач, шәехләре янына бардылар, «Коткар!» — диделәр. Шәех әйтте:

— Сезгә ул кеше гуд агачын юкка гына бирмәс, дип әйтмәдемме?— диде. Тегеләр әйттеләр:

— Әй солтаныбыз! Без ялгыштык. Инде безгә берәр чара кирәк!— диделәр. Шәех әйтте:

— Чара шул булыр: шахматчы Җәйсурны риза-бәхил итү кирәк,— диде.

Иртән тордылар, шаһзадәне эзләп таптылар, йөз-мең гафу үтенделәр, кунак иттеләр һәм малын тулысы белән кайтардылар, шактый бүләкләр кушып бирделәр.

Җәйсурны күп маллар белән озаттылар, әмма шәһәрдән чыкканда алдакчылардан сакланырга куштылар. Җәйсур рәхмәтләр әйтте, бу хәлне карчыкка сөйләде. Карчык әйтте:

— Киткән вакытыңда качырларыңның дагасын тискәре дагалат. Артыңа төшкән алдакчылар «һаман да чыкмаган икән» дип уйлар, кире борылыр. Син, Хак уң китерсә, эшеңне сәламәтлек белән башкарып, кайтып китәрсең,— диде.

Җәйсур карчыкка афәрин укыды. Аллага тапшырып, юлга чыкты. Исән-саулык белән тукталышларны, торак урыннарын үтеп, Симхар шаһның хезмәтенә сәламәт һәм табышлы булып кайтып җитте.

Симхар мәлик кызына әйтте:

— Без аны бу эшне башкара алмас, дип уйлаган идек. Инде мондый сурәттә күренгәч, дөресен, тиешлесен эшләү кирәктер,— диде.— Каршы килердәй бүтән сылтавыбыз калмады,— диде.

Кыз дөреслек белән ризалык бирде. Мәлик боерды, туй ясатты, шәһәрне, сарайларны бизәтеп, кызны бизәндереп-ясандырып, Җәйсурның куенына салды.

Шаһзадә, мәлик янында шактый көннәр булып, аннан соң Симхар шаһтан рөхсәт алып, ата-анасының бусагасына таба йөз тотты. Мәлик хәзинәсен ачты, алтын-көмеш, энҗе-җәүһәрләр, якут-зөбәрҗәтләрне кызының юлына исраф итте. Гарәп голәмнәре, һинд кәнизәкләре, гарәп атлары һәм чиксез гаскәр белән, кадер-хөрмәт күрсәтеп озатты.

Шаһзадә, үз шәһәренә якынлашкач, кеше җибәрде. Падишаһ ишетеп, шәһәр халкын каршы алырга чыгарды, шәһәрне бизәп, гыйззәт һәм хөрмәт белән үз сараена төшерде. Улын тәхеткә утыртты. Шаһзадә гадел хөкемгә кул озатып, халык белән бергә булып, юмартлык һәм киң күңеллелеккә йөз тотты, күп заманнар падишаһлыкта булды.

Инде, һәркем белсен: һөнәрнең һәммәсе һөнәрдер, аны яхшыга-яманга бүлү ярамас — Җәйсурның бу мәртәбәгә, олы дәрәҗәгә ирешүе һөнәр белү нәтиҗәсендә мөмкин булды.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Бәхәс дәвам итә: «Заман һәм шигырь»*

**Мансур Вәлиев**

## НИ ӨЧЕН БОРЧЫЛАБЫЗ?

### Барысы да бергә бәйләнгән...

Безнең шигърият проблемаларыбыз, хәтта саф әдәбиятныкы гына булып күренгән мәсьәләләребез дә яшәү һәм тормыш мәсьәләләре белән бик тә тыгыз бәйләнгән. Бүгенге шигърияттә безне борчыган байтак кына уй-фикерләрнең тамыр очы олы тормышка, реаль чынбарлыкка килеп ялгана.

Шуңа күрә журналыбыз битләрендә бара торган дискуссиядә без бүгенге поэзиянең үзен генә алып, аның мәсьәләләрен тормыш проблемалары белән бәйләмичә сүз йөртсәк, аңгәмәләребез шактый ук бер яклы булыр. Аларның ышандыру көче дә кимер.

Аннан соң, безнең бәхәсебезнең уртак темасы да «Заман һәм шигырь» дип куелган бит әле. Димәк, шуннан чыгып караганда да, шигъриятебез эченә кереп киткәнчегә кадәр, безгә башта үз заманыбыз турында уйланып алу кирәк. Аның аеруча күзгә ташланган кайбер сыйфатларын, тенденцияләрен ныграк аңларга тырышу кирәк. Ул сыйфат һәм тенденцияләрнең заманыбыз кешеләренә, чордашларыбызга ни рәвешле тәэсир итүен төшенергә тырышырга кирәк.

Биредә, әлбәттә, ул проблемаларның барысына да тукталу, һәммәсен күз уңыннан үткәрү мөмкин түгел. Чөнки «Егерменче гасыр» дигән ул проблема — кешелекнең гаять тә үзенчәлекле һәм принципиаль үзгә сыйфатларга ия булган, гаять уникаль бер чоры буларак дистәләгән том фәнни хезмәтләр таләп итә.

Ә хәзергә без, сөйләшүнең, бәхәснең төп үзәнен истән чыгармыйча гына, тормышыбызның шигърияткә аеруча кагыла торган кайбер яклары, кайбер сыйфатлары турында уйланып алыйк.

### Зур-зур сәбәпләр...

Бүгенге тормышыбызда шигъриятнең «сәламәтлегенә» көчле йогынты ясаучы нинди мөһим факторлар бар соң?

Соңгы елларда татар совет поэзиясенең генә түгел, ә гомумән дөнья поэзиясенең торышына тәэсир иткән иң зур факторларның берсе — шәһәрләшү процессы.

Бу процессның безнең тормышыбызны нык үзгәрткәнен барыбыз да бик яхшы беләбез. Чыннан да шәһәрләшү күренеше (фәнни телдә ул «урбанизация» дип йөртелә) бик күпләрнең яшәвен бөтәнчә итте. Хәзер инде безнең Татарстан халкының гына да, гомер-гомергә җирдә яшәгән халыкның да, 70 проценттан күбрәге шәһәрләрдә көн күрә.

Шәһәр тормышы. Шәһәрчә яшәү. Бүгенге кеше өчен ул нәрсә дигән сүз соң?

Торгынлык елларында без тормышыбызның уңай яклары турында шактый күп сөйләштек. Хәтта әйбәт якны арттыра төшеп тә сөйләштек, кабартыбрак та, ыспайлап, бизәп тә. Ә хәзер чынбарлыгыбызның кешегә тискәре тәэсир ясаучы яклары турында сүз алып барырга вакыт түгел микән? Бүген шул турыда күбрәк уйлану

бергә-бергә фикер йөртү кыләчәктә кеше өчен тагын да начаррак булачак кайбер тенденцияләрне йөгәнләргә ярдәм итмәсме? Хәзерге ачыктан-ачык сөйләшү һәм үзгәртеп кору дәверендә мондый мөмкинлектән без һичшиксез файдаланырга тиеш бит!

Шулай итеп, шәһәрләшү процессының бүгенге кеше яшәешенә нинди тискәре йогынтысы күзәтелә соң?

Барыбыз да белеп, сизеп тора: шәһәр тормышы ул — табигать баласы булып яралган, шулай үскән һәм миллионнарча еллар дәвамында табигать эчендә яшәгән Кеше дигән затның кинәт кенә бөтенләй икенче төрле сферага — үзенә капма-каршы булган әйберләр, күренешләр мохитенә — барып керүе дигән сүз. Ягъни аның тимер-томыр, калын-калын ташлар һәм зарарлы газлар мохитенә күчүе дигән сүз. Тоташы белән әнә шундый әйберләрдән диярлек кенә торган тирәлектә кешенең тормыш корып җибәрергә маташуы дигән сүз.

Хәзер инде бу күренеш маташу гына булып калмады, ә зур процесс төсен алды. Кайчандыр ямь-яшел булган Җир шарын хәтта кайчак таштан, тимердән, сасы газдан торган гигант шәһәрләр чолганышында гына итеп тә күзаллап куясың курка-курка...

Әйе, бер генә якны күбрәк кайгыртып, бары тик уңайлык турында гына уйлап, кеше әнә шундый сәер тормыш корды. Гаять тә киң мәйданда, бихисап күп җирне асфальт һәм тимер-томыр белән каплый-каплый, төзеде ул үзе уйлап чыгарган бу яңа төр тормышны.

Яңача булган, табигатькә каршы булган ул тормышны коруын корды кеше. Ләкин бит һәр нәрсәнең чын кыйммәте чагыштырып караганда гына беленә. Әйберләрне дә, күренешләрне дә без чагыштырып карарга, шуннан соң гына нәтиҗә чыгарырга өйрәнгән.

Әйдәгез, биредә дә шул әйбәт алымны кулланыйк. Чагыштырып карыйк. Ягъни шәһәр җирендәге яшәүне табигать эчендәге яшәү белән янәшә куеп карыйк.

Авыл җирендә туып-үскән кешегә инде моны сөйләп тә торасы юк кебек. Табигать бит ул — урман һәм болыннарыбыздагы әйтеп кенә бетерү мөмкин булмаган чиксез ямь, тиңе булмаган гүзәллек, иң камил шигърият! Табигать бит ул — кешенең эченә исткиткеч шифа булып бөркелеп керүче хуш исләр, тәмле исләр! Ул бит — кошлар авазы белән дә, әкрен искән җилдә лепердәшеп утыручы яфраклар көе белән дә кешенең җанына агылучы үтә нәфис бер моң! Ул — елга һәм күлләребездәге бүтәнчә кабатлана алмастай ләззәт, бу бәхетне бер мәртәбә үзе кичергән кеше инде шуннан соң һичкайчан оныта алмастай бәхет!

Гомумән, табигатьнең кайсы гына күренешен алма, кайсы гына мизгеленә тукталма — аның һәммәсе дә кешене сәламәт һәм матур итеп үстерүгә булыша. Шулай тәрбияли, кешене һәр яктан ныгыта, чыныктыра. Табигать һәм кеше турында күбрәк уйланган саен, без хәзер сирәк искә ала башлаган бер хакыйкатьнең дөреслегенә ныграк ышана барасың. Ул хакыйкать түбәндәгедән гыйбарәт. Кеше — үзенең Табигать дип исемләнгән анасы карынындагы мәңгелек бала икән! Әнә шул карынны ул беркайчан да ташлап чыкмаска тиеш икән! Үзен Анасы белән бәйләгән киндек җебен һичкайчан өзмәскә тиеш икән ул!

Шушы урында яшүсмерләр холкы турында да уйланып аласы килә. Үзенә бераз көч кергәнен сизү белән, нәрсәдер майтара алганын аңлау белән, ниләр генә кылана башламый яшүсмер кеше?! Гомумән, ул кыланмаган нәрсә калмый дөньяда!

Моңарчы кешелек җәмгыяте дә әнә шуңа якын психологик халәт кичерде. Үз кулында фәннең һәм техниканың гаять зур көчен тою — аны ниләр генә кыландырмады?! Кешелек — әлеге яшүсмер малай кебек — алдын һәм артын, нәтиҗәсен, ахырын уйлап тормыйча, әллә ниләр майтарып ташлады...

Шәһәрнең кешегә ничек тәэсир итүен тулысынча аңлый алсак — безнең чәчләребез үрә тормас иде микән?! Хәер, чамалап кына без аны бераз төшенәбез дә бугай инде. Чөнки гыйбрәтле хәлләр адым саен диярлек очрап тора... Күптән түгел күргән бер күренеш минем үземнең күз алдымнан һич кенә дә китми.

Җәйге эссе көн иде. Казан шәһәренең бөтен транспорт өчен диярлек иң үзәк юлы булган Декабристлар урамындагы тукталышта, эсседән әлсери-әлсери, тәтенгә һәм газга буыла-буыла трамвай көтәм. Шактый гына көткәч, ниһаять, дөбер-шатыр шалтырап мин көткән трамвай да килеп туктады. Көчле кояштан, тавыштан инде нишләргә белмичә тәмам ярсыган халык ташкыны белән бергә мин дә эчкә үттем. Инде кузгалып киттек, тынычланып кына барырбыз дигән идек — мөмкинме соң?! Трамвай утыргычлары уртасындагы тар коридорга кертеп куелган кечкенә арба бар иде, шундагы яшь бала бөтен көченә акырып, гасабиланып җылый башлады. Күрәсең инде ул без кергәнче дә шактый тавышланган — кырыендагы әнисе нишләргә белмичәрәк аптырап тора, халыкның йөз-кыяфәтендә дә үтә борчылу.

Һәркемнең тынычлыгын ала торган бу күренешкә карап барган саен башка күңелсез уйлар күбрәк килә иде.

Мескен, бу бәләкәй җан иясе, нәселендәге меңләгән еллар буена аккан күзәнәкләр дәшүе буенча табигатькә чыгам дип туган бит инде. Ә аны, табигать баласын, үтергеч тимер ташкыны уртасына китереп кертканнәр! Чын, туп-туры мәгънәсендә тимер ташкыны бит бу! Әнә, янәшәдә генә әллә ничә рәт булып, үкерә-үкерә зур машиналар, тау хәтле тракторлар бара. Алар арасындагы тимер юлда тагын тимер трамвай! Ул да галәмәт тавыш чыгарып — шатыр-шотыр бара! Ә трамвай эчендә инде янә тимер кыса — арба. Боларның һәммәсе бит — бу кечкенә җан иясенә каршы! Һәммәсе аны нык борчый, изә һәм ботарлый бит!

Үсә, олыгая барган саен без тимер ташкыны арасында әлеге бала сыман еламаска, ул кадәр үк әрнемәскә тырыша башлыйбыз. Әкренләп түзәргә өйрәнәбез, чыдарга өйрәнәбез. Ләкин аңа карап кына, безнең ташлама ясавыбызга карап кына, бу конфликтның асылы алышынмый шул! Бу зур каршылык тирә-юнебездә яшәп кала, һәр даим безгә тәэсир ясавын дәвам итә.

Табигатьтә исә бөтен хәрәкәт һәм үзгәрешләр инде озак дәверләр буена сыналып беткән, уңайлы рәвеше табылган юлдан бара. Анда һәммәсе ипле бер җай белән бара.

Авыл кешесен генә алыйк. Ул мал асрый, кош-корт тота. Материаль якны — кеше җилкәсендә яшәмәүне әле бөтенләй искә алмаганда да, аның яшәвендә никадәр дереслек?! Аныңча яшәү — ул кыска гына итеп әйткәндә — табигать белән бергә зур гаилә булып яшәү дигән сүз! Мал-туар һәм кош-корт исәбенә кешенең аралашу сферасы, яшәү мохите зурая, гаиләсе ишәю дигән сүз. Әлеге мал-туар да, барча кош-корт та — болар һәммәсе кеше белән бер гаилә сыман яши бит алар. Бер гаилә. Димәк, кеше никадәр күп яктан ала үзе өчен кыйммәтле тәҗрибәне, акылны, сабакны!

Ә яшь буын, кечкенә кеше?! Аның өчен мондый шартның никадәр кадерле икәнен аңлатып кына бетереп була микән? Яшәүнең гаять тә күп төрле һәм нечкә мөнәсәбәтләре үзенә актив кагыла торган, әкрен-әкрен тәэсир итә торган бу мохит эчендә кечкенә кеше бит нихәтле әхлакый сабак — яшәү тәҗрибәсе, гармоник тәрбия ала!

Ә шәһәр баласы мондый олы бәхеттән мәхрүм. Кызганыч дәрәҗәдә мәхрүм! Аңа бит, әлеге катлы-катлы тимер ташкыны эчендә барган сабыйга булган кебек, гомере буена диярлек каты, кискен, тупас көчләр тәэсир итеп тора. Аңа бик озак дәверләр әнә шундый йогынты ясала!

Җирдән нык аерылып, таш пулатларның сигезенче-унынчы катларына менеп кунаклаган безнең шәһәр фатирларыбызда бит малай кешегә бөтенләй эш, шөгыль дә юк. Кызлар әле кухняда, әнисе тирәсендә, үзләренә эш табалар. Бу аларның киләчәк юлы, төп яшәү стихиясе белән тәңгәл килә, шуның белән яраша. Ә киләчәктә ир-ат булырга тиешле кеше — малай кеше — йә нәрсә эшләсен инде ул һәр яктан чикләнгән таш стеналар арасында?! Ә бит егет кешегә бөтенләй бүтән төрле яшәү, бүтән төрле — актив стихия кирәк!

Әнә шундый шартлар булмаганга күрә, без яшьләребезнең бүгенге бозыклыкларын күрәбез. Шәһәрдә кеше тормышының чүп урынына да куелмау очраклары адым саен диярлек. Соңгы вакытта исә үтереш белән тәгалләнә торган урам сугышлары да ешайды...

Боларның һәммәсе — үзебез оештырган шәһәр тормышы җимешләре. Болар — безнең зур күләмдә уйлап эш итмәвебез, зур ялгышларыбыз нәтиҗәсе.

Шулай итеп, без югарыда күрсәтеп үткән хәлләр барысы да тормышыбыз гармониясен (ягъни шигъриятне дип уйлыйк) җимерү буенча шактый кирәкмәгән эш башкардылар, җәмгыятькә зыян салдылар. Әдәбият ягыннан чыгып караганда, бу төбәкнең күренекле вәкилләре авызыннан инде байтактан сөйләнеп йөргән сүзнең дереслеге тагын да бер мәртәбә расланды соңгы елларда. «Шагыйрьләр авылда туа, ә шәһәрдә үлә» дигән сүзнең...

Егерменче гасырга хас булган икенче зур үзенчәлек — фән һәм техника революциясе дә, кеше өчен бик зур уңайлыклар тудыруга карамастан, яшәеш гармониясен бозуга шулай ук байтак кына өлеш кертте. Заманыбыз кешесе бары тик салкын исәп белән генә, башны гына эшләтү, акыл белән генә күп нәрсәгә ирешергә өйрәнеп шуңа күнегеп китте. Шул рәвешчә генә яшәүгә ияләште. Фәннең һәм техниканың көннән-көн киңрәк масштабларда җәелып килгән казанышлары акылның һәм салкын исәпнең абруен тагын да күтәрде.

Шулай итеп фән безнең тормышның төп героена әйләнде. Кеше тулысы белән диярлек шуларга бәйле була башлады, хәзер ул алардан башка яшәүне күз алдына китерә дә алмый. Баштарак күреп үткәнебезчә, кечкенәдән үк нечкә мөнәсәбәтләр арасында тәрбияләнмәгән, аларны тоярга һәм аңларга өйрәнмәгән кешедә болар бер

яклылыкны тагын да көчәйттеләр. Дөньяның һәм халык яшәешенең хисси һәм әхлакый ягы бөтенләй игътибардан ук читтә кала башлады.

Яшәешне шактый гадиләштереп аңлау, кешене исә автомат роботларга якынлаштырып карау көчәйде. Парадоксаль шундый бер хәл дә килеп туды: эшләр болай барса, үзе уйлап тапкан робот белән кеше арасында бөтенләй аерма да калмаска мөмкин икән бит! Хисси һәм әхлакый якны искә алмый яшәгәндә, менә шул үтә кызык һәм кызганыч хәлгә дә бик якын кала икән бит!

Бүгенге яшәү гармониясе, ягъни шигърият бозылуга зур гына сәбәпче булган әле тагын бер көч бар. Анысын да карап үтик.

Илебездә озак еллар буе дәвам иткән торгынлык чоры һәм шәхес культы еллары кешеләр эчендәге, бигрәк тә миллионлаган гади халыктагы фикер һәм хис хәрәкәтенә һич кенә дә ярдәм итмәде. Киресенчә, ул елларда гади халыктан чыккан һәр тойгы административ бюрократик аппарат тарафыннан зур дошманлык белән каршы алынды. Һәр хәрәкәтнең алгы сафында бара торган хискә, эмоциягә ул елларда бик еш киртә куелды.

Ул елларның бик күп ачы җимешләреннән берсен искә төшерик. Торгынлык чорында бюрократ начальниклар авызыннан дөньяга бик тә тискәре төсмерле «самодеятельность — үзешчәнлек» дигән сүз туды. Нинди дә булса тәкъдим, кызыклы фикер әйткән гади кешеләргә, халкыбызның улларына һәм кызларына әнә шундый күңел төшергеч сүз әйтелде. Ягъни администратор үзеннән узып фикер йөрткән, димәк, аңа өстәмә мәшәкать тудырган берәүне дә яратмады, күрәлмәде.

Шулай итеп безнең чордашларыбыз ихласлыктан уттан курыккандай курка башладылар. Ә ихласлыктан шигърияткә дә ерак калмый бит инде! Ихласлыктан шигърияткә бер генә адым ара бит! Димәк, торгынлык елларында югарыда карап үтелгән бөтен сыйфатлар белән бергә ихласлыкка урын да киму — шигъриятне кысучы тимер богауны тагын да ныгыткан дигән сүз!

Чынбарлыкның үзендә поэзиянең үсүенә комачаулаучы әнә шундый зур-зур сәбәпләр яши. Соңгы елларда без шигъриятнең торышыннан ризасызлык белдерәбез икән — иң элек әнә шулар хакында истән чыгарырга тиеш түгелбез!

## Үзебездән торганнары....

Әйе, әйе — сәбәпләрнең үзебезгә бәйлеләре, бары тик үзебезнең оештыру эшебездән генә торганнары да байтак. Әгәр дә бүген без татар совет поэзиясенең халык күз алдында абруен тагын да күтәрергә телибез икән, ул чагында әлеге сәбәпләр хакында да һәм аларны бетергән тәкъдирдә безгә ачылачак мөмкинлекләр турында да ныклап уйланырга тиешбез.

Барыннан да элек шуны әйтергә кирәк: безнең балаларыбызга кече яшьтән ук житәрлек дәрәҗәдә һәм системалы итеп, ә бик күп урыннарда хәтта бөтенләй ук шигъри тәрбия бирелми. Бәләкәй кешенең җанын, күңелен тәрбияли һәм матурлап үстерә торган әнә шул бик зур мөмкинлек файдаланылмый кала. Ә бит безнең үзебезне үстергән әниләребез кечтән йокларга ятканда халкыбызның мавыктыргыч әкиятләрен сөйлиләр, көндезләрен төрле-төрле җырларын җырлыйлар, такмакларын әйтәләр иде. Гаять күп яклы шигъри тәрбия бара иде. Хәзер, безнең чорда, ныклап уйлап карасак — мондый әниләр күпме икән соң? Без бөтен эшне балалар бакчаларына һәм мәктәпләргә ышанып тапшырдык та тапшыруын, ә бит балалар бакчасында безнең шигъриятебез бөтенләй дә кулланылмый, мәктәпләрнең дә бик күбесендә андый эш бармый.

Шулай булгач, без бик тә көткән әлеге шигъри тәрбия кечкенә кешегә каян һәм ничек, ни рәвешле килеп керергә тиеш икән соң? Илаһи юл белән күктән төшәргә тиешме ул?! Ә бит балалар бакчалары, аеруча мәктәпләр, бүгенге көндә шигъри тәрбия буенча бик тә зур эш эшли алырлар иде.

Алтмышынчы елларда үзем укыган Барҗы урта мәктәбе (Әгерҗе районы) искә төшә. Анда даими рәвештә дип әйтерлек шигырь язучылар арасында ярышлар үткәрелә иде. Әдәби викториналар бик еш була иде. Мәктәптә укучыларның үзләре тарафыннан гына берничә стена газетасы чыгарылды. Ә аларның берсе — «Яшь каләм» исемлесе — бары тик әдәби газета гына иде! Шулай ук драматург Юныс абый Әминев җитәкләгән әдәби түгәрәк тә эшли иде бездә.

Болар бүгенге һәрбер мәктәп укучыларының кулыннан килә торган эшләр бит инде. Моның өчен бары тик... Бары тик теләк кенә кирәк! Һәм дәртләнеп, шушы эшне яратып йөрүче берәү кирәк. Әнә шундый канатлы җан кирәк!

Ә югары уку йортларын тәмамлап мәктәпләргә килүче яшьләребез нигә соң әнә шундый матур-матур эшләрне башлап йөрмиләр? Беренче башлап оештырмыйлар? Әллә соң институтларыбызның үзләрендә дә андый эшләр бик үк гөрләп бармый микән? Болай дип уйларга да нигез юк түгел. Чөнки, белүебезчә, әлегә аларда актив иҗади мохит бик үк күренми. Шулай икән — институтларыбызның тәрбия җимешләре булган студентлардан актив шәхесләр ничек тусын ди инде!

Шуларга ук тоташып килүче тагын бер мөһим сәбәп: без әле булган, басылып чыккан әйбәт кенә шигырьләребезнең дә халкыбыз тарафыннан яхшы үзләштерелүенә ирешә алмыйбыз. Менә дигән шигъри әсәрләр китапларда яисә журнал битләрендә дөнья күрә тора. Аларны укыган хәтле шигырь сөюче укый, укымаганы исә укымый — һәм шуның белән бу процесс тәгәлләнә дә! Ә бит яхшы шигырьләрнең халык өчен эшләгән эшләре алай гына бетәргә тиеш түгел! Чөнки анда, талантлы шигъри әсәрдә, халыкның, тормышның бик тә зур рухи энергиясе тупланган була.

Менә мисал өчен бер очракны алыйк. Чорыбызның атаклы шагыйре, әйтик, Гамил Афзалның бер бик шәп шигыре басылып чыкты ди. Без, аның каләмдәшләре һәм күп санлы укучылар, әлеге шигырьгә салынган тирән һәм актуаль эчтәлекне ул шигырь басылып чыккан көннәрдә үк ачып бирергә тиешбез. Ул эчтәлекне ачу процессында бүгенге тормышның әсәрдә чагылган проблемаларын уңай якка хәл итү турында да уйланырга тиешбез. Әле бит Г. Афзал әсәрләре эчтәлек ягыннан катлы-катлы була, аларны тиз генә сүтеп бетерү — тиз генә төбенә төшеп җитү мөмкин булмый.

Шуның өстенә әле тагын талантлы шагыйрь тапкан сүз энҗеләрен аерым-аерым алып карарга да кирәк. Аларны да бар кыйммәтендә аңлау сорала.

Кыскасы, кайбер шәп шигырьнең эчтәлеге романнарга тиң була. Аны хәтта сөйләп бетерү дә кыен! Ә киң катлау укучыларга шигъри тәрбия бирү максатында популяр басмаларда бу эш эшләнергә тиеш иде.

Ләкин безнең көндәлек матбугат моны эшләми. Анда-санда күренгән рецензияләр дә ул таләпкә җавап бирә алмый. Менә шушы урында инде без тагын бер мөһим сәбәпкә килеп җитәбез.

Шигырьләребезне, гомумән барлык кызыклы һәм игътибарга лаеклы әсәрләребезне укучы күз алдында тиешенчә анализлап, шул нигездә эстетик һәм шигъри тәрбия эше алып бара алмавыбызга — безнең әдәби матбугатыбыз бик аз булу сәбәпче. Аның җитәрлек булмавы, басылу өчен мәйданның бик аз булуы. Аз дигәндә атналык әдәби газета булмау бу эшкә бик комачаулый.

Шул ук мәңге сүгелә торган әдәби тәнкыйть фикеренең пассив булуы да — әлеге сәбәп нәтиҗәсе. Чөнки бүген басылып чыккан кызыклы әсәргә иртәгә яисә бер-ике көн эчендә халык фикере дөнья күрмәгәч — ул әсәр әкренләп онытыла. Аның кайнарлыгы бетә, эчтәлеге тоныклана. Ул тудырган рухи дулкынлану басыла, сүрелә. Көчле иҗтимагый яңгырашка лаеклы күпме әсәрләр шулай акрынлап сүнә, сүрелә бездә!

Менә каян туа бездә сүлпәнлек! Менә каян килеп чыга бүгенге әдипләребезнең пассивлыгы! Һәм укучыларның шигъриятькә җитәрлек дәрәҗәдә, без көткән дәрәҗәдә кызыксыну белән карамавы!

Мисал өчен Тукайлар, Әмирханнар чорын искә төшерик. Алар ни өчен шундый, без сокланырдай зур һәм актив шәхесләр булып формалашканнар? Чөнки ул вакыттагы гаять күп санлы матбугат органнары тирәсендә кайнар һәм иҗади атмосфера булган! Әдипләр, шагыйрьләр әнә шул кайнар халәттә — көрәш халәтендә яшәгәннәр.

Ә соң бүген тормышыбызда андый көрәшләр беттемени?

Юк, безнең заманда — яшәешебезне өр-яңадан үзгәртеп кору чорында — иҗтимагый һәм социаль көрәшләр һич тә бетә алмый. Безнең үзебезгә генә матбугатыбызның ролен күтәрү, аның чынбарлыкка тәэсирен көчәйтү турында конкретрак уйланырга кирәк! Һәм тиешле чарасын күрергә! Югыйсә, без каләм ияләре, илебездә җиде миллион булган татар халкын әхлакый тәрбияләү буенча әлегә бик тә аз эшлибез! Һич тә заман таләп иткән дәрәҗәдә түгел. Шигъри тәрбия турында инде әйткән дә юк!

## Эш алдыннан киңәшү

Халкыбызның «Киңәшле эш таркалмас» дигән бик акыллы мәкале бар. Журналыбыз битләрендә инде бер елга якын бара торган бу сөйләшүне дә беренче чиратта әнә шул ноктадан карап кабул итәсең.

Р. Мостафин белән В. Нуруллинның бәхәсне башлап җибәргән әңгәмәләрендә бүгенге шигъриятнең шактый гына «авырткан урыннары» ачыклана. Алар бигрәк тә китапның басылу һәм халык арасында таралу якларына нык тукталалар. Тәнкыйтьче белән нашир сүзне күбрәк шул хакта куерта.

Әйе, алар кузгаткан бу мәсьәләләр — эшнең практик ягы дигән сүз. Бүгенге көндә безнең игътибардан һич кенә дә читтә калмаска тиеш ул проблемалар.

Чыннан да, китапларны басу эше дә, шулай ук аларны халыкка тарату, сату эше дә заман таләп иткәнчә куелган дип әйтә алмыйбыз әле без бүген. Ни өчен заманча түгел соң?

Чөнки тагын бик тә кызык хәл — китапны басучыга да, сатучыга да, китапның ничек таралуы мөһим түгел кебек килеп чыга! Бу тармакта эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү китапның күпме таралуына бәйләнмәгән. Алар барысы да билгеле бер окладта утыралар.

Ә бит чынлап караганда бер дә алай булырга тиеш түгел! Башка күп кенә илләрдәге кебек, китапны язган өчен дә, аны баскан һәм саткан өчен дә түләү — табышка бәйле булырга тиеш! Әнә шул табышның билгеле бер проценты түләнергә тиеш һәр хезмәткәргә, һәр авторга.

«Шигырь китабы табыш бирерме?»— дип шик белдерүчеләр булыр.

Әйе, болай эшләгәндә халыкка кирәкмәгән буш шигырь җыентыклары саны нык кимиячәк. Ә яхшылары ничек булыр? Аларга да дөньяга чыгу авырлашмасмы?

Тарихка борылып карыйк. Без бүген тәнкыйтьләгән капиталистик тормыш шартларында Тукайлар елына 2-3 әр китап бастырып чыгара алган икән, безнең гуманистик холыклы социализмда эш аннан начар була алмый! Без эшебезне тиешенчә оештырып җибәрә алсак, яхшы шигырь китабы өчен унар меңләгән тираж да туплый алабыз. Җиде миллионлы татар халкы өчен ун мең дигән сан бер дә күп түгел ул!

Шулай ук китапны бастыру һәм сату эшләренә шигъри зәвыклы кешеләрне куя алсак, халыкка иң-иң кирәкле китапларны гына бастырып чыгара алсак — таралу эшенең дә бик уңышлы барачагына һич шикләнмәскә мөмкин. Элек-электән үк безнең авылдан-авылга йөреп китап сатучыларыбыз булган. Фидакарь җанлы мондый затлар бүген дә килеп чыгачак бит алар! Бары тик бу изге эшне зур масштабта кузгатып җибәрү генә кирәк! Тик бу эшкә хәзерге хәлдәге сыман битараф кешеләр генә алынмасын! Татар телен бөтенләй белмичә дә, татар китабын алмасыннар иде дип, үзе янына килгән кешене куып җибәргәндәй читкә этәреп утыручы хәзерге безнең манекен-сатучыларыбыз гына алынмасын бу эшкә! Сату эше хәзергедән дә начар була алмый! Берничек тә хәзергедән начар була алмый ул!

«Заман һәм шигырь» дигән бәхәсне башлаган беренче әңгәмәдән мин үзем әнә шул фикерләрне тотып алдым. Бүгенге шигърият өчен чыннан да җитди әһәмияткә ия мәсьәләләр алар.

Шагыйрь Марс Шабаевның икенче санда басылган «Төшсез чикләвекләр» исемле усал һәм принципиаль мәкаләсе белән дә килешми мөмкин түгел. Бу язманың төп мәгънәсе шигърияттәге чүп-чар белән көрәшне көчәйтергә чакыру дип аңлашыла. Чынлап та, хәзер безнең илебездә бөтен кеше дә диярлек укый-яза белә. Бик күпләрнең теле дә шома гына — ак кәгазь буйлап аларның каләмнәре бик җитез чаба. Сүз арты сүзне, җөмлә арты җөмләне тезеп кенә тора... Әнә шулай итеп шигырь булырга ашыккан бихисап такмаклар, шома язмалар туа тора. Ә иң мөһиме алар авторның күңелен басу һәм таныш-белеш арасында укып юану өчен генә язылмый бит әле — почта белән яисә «аякланып» шундук Казан ягына юл ала, төрле-төрле басмаларда үзләренә урын таләп итә...

Әйе, биредә һәвәскәрләр турында сүз барганы ачык. Ләкин менә алар язган бик күп санлы шигырьләрне нишләтү мәсьәләсендә төрле карашлар яши. Берәүләр (Р. Мостафин да андый караш белдергән иде) һәвәскәрләр өчен аерым басма булдырырга кирәк, ди. Әлбәттә, аларның үз хисапларына яши торган. Икенчеләр исә мондый төр иҗатчыларга бөтенләй диярлек игътибар итмәү ягында — янәсе «алар белән алышбиреш итәсе юк, кемнең кем икәне ап-ачык ярылып ята!»

Ныклап уйлап караганда мондый карашларның икесе дә дөрес түгел. Чөнки һәвәскәрләр өчен аерым басма — ул кирәкмәгән өстәмә мәшәкать кенә. Шулай ук ул типографияләр проблемасын тагын да үткенәйтәчәк. Яхшы поэзия әсәрләре язмышына шактый ук тәэсир итәчәк. Байтак кына буталыш та китереп чыгару ихтималы юк түгел андый басмаларның. Түбән зәвыклы язмалар белән чын шигърият әсәрләре укучыга бер төслерәк тәкъдим ителәчәк бит!

Ә һәвәскәрләргә бөтенләй игътибар итмәскә дигән карашның дөрес түгеллеге инде ап-ачык. Чөнки сәләтле шагыйрьләрнең каян һәм кайчан киләсен беркем дә алдан әйтә алмый бит! Андыйлар үзешчәннәр арасыннан да килеп чыгарга мөмкин.

Хәтта олы яшьтәгеләр арасыннан да! Мондый ихтималны безгә һич тә кире кагарга ярамый. Без халык байлыгы — талант, сәләт белән эш итәбез.

Нинди юл гына кала соң бу мәсьәләдә?

Башлап язучы авторларга карата һәм аларның әсәрләрен бастыру буенча хәзер яшәп килгән тәртип нигездә дөрес дип уйлыйм мин. Бары тик аның, ул системаның әйбәт эшләвен генә тәэмин итәргә кирәк. Фикерне ачыклабрак аңлатып китик.

Күп кенә районнарда әдәби иҗат берләшмәләре уңышлы гына эшләп килә. Без бик күп кенә мәсьәләләрне чишкәндә, хәл итәргә тырышканда, әнә шул берләшмәләрнең әһәмиятен уйлап җиткермибез. Аларның — билгеле яхшы эшләгән тәкъдирдә — культура тормышы өчен әһәмияте шактый зур бит. Әгәр дә теге яки бу төбәктә әдәби берләшмә яхшы эшли икән: анда талантлы яшьләр югалып калмаячак диган сүз. Алар әкрен-әкрен берләшмә эшенә тартылып, беренче иҗади чыныгу алачаклар, район газетасы дигән матбугатта басылу бәхетенә ирешәчәкләр — үз әсәрләрен район газетасында сигезәр-унар мең экземпляр бастырып, әнә шуның кадәр укучыга җиткерәчәкләр. Без һәвәскәр авторлар дип атаган менә бу контингент өчен район газеталары менә дигән матбугат органы бит инде! Ә язылган әсәрләрне тикшергәндә инде биредә Татарстан Язучылар союзыннан билгеләнгән консультантлар-шефлар юнәлеш бирергә тиеш. Алар белән элемтә ныклы булырга тиеш! Болар инде барысы да билгеле әйберләр һәм кайчандыр эшләнгән дә нәрсәләр. Тик менә соңгы вакытта моңа игътибар кими төште кебек. Ә бит болай булырга тиеш түгел!

Шул ук тиражлар хакында уйлана башласак та, урыннардагы әдәби берләшмәләргә килеп төртелербез. Алар район җирендә культура тормышын активлаштырсалар (мисал өчен Түбән Камадагы «Җидегән чишмә» берләшмәсе кебек!) биредәге халыкның китапларга мөнәсәбәте яхшы якка бик нык үзгәрәчәк. Халык безнең китапларны чын-чынлап күңел ризыгы итеп даими рәвештә куллана башлаячак. Халык актив рәвештә әнә шундый ризыкка сусый башлаячак!

Күрәсезме, район җирендәге әдәби берләшмәләрнең эшен активлаштыру аша без үзебез өчен мөһим булган ничә проблеманы берьюлы чишә алабыз. Әдәби консультантлар, районнарга билгеләнгән шеф язучылар яхшы эшләсә — теге яки бу район матбугатында үсеп чыккан талантка республика күләмендә күренү дә чагыштырмача авыр булмаячак. Һәрхәлдә, ул — әгәр дә талант дәрәҗәсе шуңа лаек икән — әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарына эләгәчәк.

Тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин үзенең 4 санда басылган мәкаләсендә шулай ук бик мөһим нәрсәләр кузгата. Аның хәзерге поэмалар турында борчылып уйлануы миңа бигрәк тә якын тоелды. Чынлап та, бүген безнең поэмалар өлкәсендә һуш китәрдәй хәл бит. Илебезнең материаль тармагында килеп чыгып, торгынлык елларында аеруча калку күренгән гигантомания чире безнең поэзиядә нәкъ менә поэмалар рәвешендә яши. Коеп куйган гигантомания бу! Ягъни язган кешенең бары тик күләм зурлыгына гына омтылуы, шуңа гына ирешергә теләве!

Мондый зур күләмле көпшәк поэмаларны кайбер шагыйрьләр фәлсәфи поэма дип акларга тырышалар. Аларга җавап итеп иң беренче шуны әйтәсе килә: язган әсәр укылмый икән, аның бернинди фәлсәфәсе дә керми инде укучыга. Ул фәлсәфә укучыдан читтә кала, һавада асылынып кала!

Икенчедән, сәнгать әсәре һәм бигрәк тә поэмалар, һәртөрле фәлсәфәне бары тик эрегән хәлдә генә — ягъни җанлы образлар яшәешенә органик рәвештә әверелгән халәттә генә кабул итә. Әсәрнең бер һәм тулаем яшәеше булып әйләнә алган тәкъдирдә генә! Ә безнең соңгы вакытта бер-бер артлы басылып торган «фәлсәфи поэмалар»ыбызда зур поэтик эчтәлек юк.

Мондый озын һәм көпшәк, буталчык поэмалар белән очрашкач, сюжетлы поэмаларны бик тә сагынасың! Күңелгә тирән үтеп керә торган поэмаларны юксынасың.

Ә бит поэмалар хакында сүз барганда иң элек шуны истән чыгармаска кирәк: биредә гади укучыга иң якын була алган жанр турында сүз. Ягъни лиро-эпик жанр хакында бара. Мавыктыргыч вакыйгалары, кызыклы сюжетлары белән үзенә тартып, шигъриятнең эчкәрерәк серләренә алып керәп китәрдәй төр бит ул — поэма. Әдәбиятның бик күп нечкә хәйләләрен, серләрен үзенә туплаган, әнә шуңа күрә дә кайчандыр халыкка бик тә якын булган әсәрләр бит алар — поэмалар!

Димәк, шигъриятнең тулаем абруен күтәрү, аның көчен арттыру турында чынчыннан уйларга теләсәк, без иң элек һәм бик тә җитди төстә поэмалар жанрын кайгыртырга тиеш! Шигъри телдәге повестьлар, хикәяләр төрен! Алар безнең күп санлы укучыларыбызны мавыктыра алсыннар! Чын-чынлап әсәрләндерә алсыннар! Менә шул чагында без поэма жанрының уңышы хакында сөйләшә алырбыз!

Мавыгып укырдай сюжетлы һәм тирән эчтәлеккә ия поэма күрергә зар булган

шигырь сөючеләргә «Татарстан яшьләре» күптән түгел бер зур бүләк ясады. Газетаның 1988 елгы 27 март санында яшь шагыйрь Рәниф Шәриповның «Фатыйма мәхәббәте» исемле поэмасы басылып чыкты.

*Каян алып нинди сүзләр белән генә*
*Ясыйм икән Фатыймакай сурәтеңне.*
*Каләм алып кәгаземә кагылырга*
*Куркып торам Фатыймакай, күрәсеңме.*

*Ничек кенә таушалган сүз, ялган белән*
*Кагылмаска синең матур исемеңә.*
*Сүз күп бездә, тик күбесе ясалма моң,*
*Чүп кичереш, буш хыяллар ише генә.*

Әнә шундый бик тә ихлас хис-кичерешләр белән башлап китә яшь автор үзенең поэмасын. Һәм менә шушы без укыган беренче строфаларда ук аның үзенең дә гаять дулкынланган, тәэсирләнгән, алдагы вакыйгалар белән чын мәгънәсендә әсәрләнгән күңеле сизелеп тора. Шуңа күрә поэманың «Фатыйма мәхәббәте» дигән исемен укып инде шактый гына ымсынган кеше беренче строфалар аша тагын да ныграк рухлана төшә. Якындагы вакыйгаларның дулкыннары инде аны үзенә суырып ук диярлек ала. Бүтән аерыла алмаслык итеп!

Ә алда торган вакыйгалар гаять драматик. Алай гына да түгел — хәтта трагик...

Менә шушы соңгы җөмләне язып куйдым да, алга таба узып китә алмыйча, шунда тукталып калдым. Чөнки драматик, трагик вакыйгалар дигән сүзләр һич кенә дә үзләреннән җибәрмиләр. Чөнки менә шушы урында безнең бүгенге шигърият өчен бик тә мөһим мәгънәләр ята. Уйланасы мәсьәләләр, киңәшәсе нәрсәләр ята.

Без озак еллар буена тормышыбыз ал да гөл дип сөйләп килдек. Хәтта әле еш кына очракларда шулай дип уйладык та. Кызганычка каршы... Ә чынлыкта, менә хәзер күзебезне ныграк ачып карагачтын, әйләнә-тирәбездә нәрсә күрәбез соң?

Хәл ителүне көтеп яткан бик тә күп мәсьәләләр күрәбез без үзебезнең әйләнә-тирәдә. Социаль, әхлакый, шәхси мәсьәләләр... Һәм аларның бик күбесе тирәсендә көрәш бара. Аларның бик күбесе төрле-төрле бәрелешләр төене булып тора.

Ә замандаш кешеләребезнең шәхси тормышларында никадәр катлаулы хәлләр! Капма-каршы холык-характерлар бер-берсенә килеп бәреләләр, янсә утлар чыгарлык итеп ышкылып үтә... Ә бүгенге гаиләләрдә сабак һәм гыйбрәт алырлык нинди генә хәлләр юк?! Ир белән хатын мөнәсәбәтләре хәзер ничек кенә үзгәреп бетмәде инде?! Ата белән бала, ана белән бала мөнәсәбәтләре... Ә һаман күбәя баручы ятим балалар? Бернинди тәрбия күрмичә өрлек хәтле гәүдә үстергән яшүсмерләр?

Кайсын гына алсак та, бетмәс-төкәнмәс гыйбрәт, уйлану чыганагы була ала болар. Ә безнең соңгы еллар шигъриятендә ни дәрәҗәдә чагылды соң алар? Әнә шул гыйбрәтле хәлләр, күренешләр безнең шигърияттә бөтенләй диярлек күренмәде бит!

Безнең шагыйрьләрнең күбесе һаман да шул вак-төяк чагыштырулар эзләп, ә алар табыла калганда шуларны төрле яктан әйләндерә-әйләндерә карап, тикшереп мавыктылар. Үз күңелләреннән төрле кызыклы төсмерләр, нюанслар эзләделәр. Икенче берләре исә уйлап чыгарулар белән мавыктылар.

Ә яшь шагыйрь Р. Шәриповның поэмасында тасвирланган трагик хәлләргә килгәндә, алар шуннан гыйбарәт. Киләчәктә перспективасы юк дигән исәпкә керү аркасында бик тә кечерәеп калган бәләкәй генә авылда Фатыйманың ире Салих каты авырып китә. Аны тиз арада больницага илтергә кирәк! Көч-хәл белән арба табып, карт алашаны тәртә арасына кертә дә, Фатыйма юлга чыга. Илтеп җиткерергә, ничек тә булса өлгерергә! Поэманың менә шул өлеше ир хатыны Фатыйманың олы җанын гаять тә тирәннән ача. Иренең гомерен саклап калу — Фатыйма өчен бердәнбер зур максат!

Тик ара якын түгел шул... Аты да бик карт аның... Ә Фатыйма һаман куа. Чөнки вакыты бик тә аз! Каты чиргә ирек бирмәскә кирәк!

Тормышта гел дә диярлек шулай була бит ул — эшләр бер артка китә башласа, төрле яклап начараерга тотына. Чыдап кына тор! Фатыйманы да юлында сынау арты сынау сагалый. Аның карт аты юлга егыла, ә Фатыймага инде бүтән чара юк — арбаны ул үзе... тарта башлый!

*Изге могҗиза бу! Илһам, сакла юк-бар сүздән!*
*Фатыйма бит бөтенләйгә туктар тиздән...*
*Шифаханә баскычына йөген салыр,*
*Ишек шакыр, башын күтәрми тын калыр.*
*Ишек ачык. Кемгә монда ярдәм кирәк?*
*Ә Фатыйма һаман шакый: тизрәк! тизрәк!*
*Соңгы тамчы көчен алган бер ишарә —*
*Салихына төртеп күрсәткән бичара.*

*Һәм тынычлап ятып калган, изрәгән дә,*
*Йөрәгенең туктаганын сизмәгән дә...*

Поэманың ахыры һич тә мажор ноталарда төгәлләнми. Исән калган ир берничә көн узу белән, шул ук арбага утыртып үзенә... яңа хатын алып кайта! Шулай... бу тормышта һәркем үзенчә яши шул!

Әсәр уйландыра. Нык уйландыра... Күптән укылса да — истән чыкмый.

## Кемгә нәрсә кирәк?

Шактый озак дәвам иткән торгынлык елларында безнең күңел дөньяларыбыз һәм уйлау-фикерләү рәвешләребез дә нык кына үзгәргән икән. Без илебезгә Бөек Октябрь социалистик революциясе алып килгән, егерменче елларда җәмгыятебездә киң канат җәйгән актив яшәү рухын байтак кына дәрәҗәдә онытканбыз икән. Чын тормышның, чын яшәешнең үзенә хас булмаган ниндидер ясалма һәм үсешкә комачаулаучы шартлылыклар кануны буенча яши башлаганбыз без. Хәтта шундый яшәешкә тәмам күнегә үк башлаганбыз.

Артта калырга тиешле, хәзер без алар тоткынлыгыннан чыгып китәргә тиешле бу тәртипләр, мондый рух бигрәк тә соңгы елларда — илдә революцион яңарыш җәелгәндә — нык сизелә. Аеруча күзгә ташлана. Әдәбият өлкәсендә бигрәк тә.

Әдәбиятның халык өчен яшәве, укучылар өчен язылуы бәхәссез хакыйкать. Халык үзенең иң талантлы улларын тәрбияләп үстереп, әдәбият дөньясына кертеп җибәрә дә, шуннан соң инде алардан әйбәт-әйбәт әсәрләр көтә башлый. Үз күңелендә булганны, яшәеш тудырганны оста итеп, тәэсирле итеп әйтеп бирүче дип саный бит язучыны халык. Бик гади генә итеп әйткәндә әдәбият белән халык арасындагы бәйләнеш әнә шундый ул.

Әйе, бу кадәресенә беркем дә каршы килмидер. Бусы, әйтеп узганыбызча, инде аксиома хәлендәге хакыйкать...

Шуннан соң инде алга таба китик. Рас әдәбият халык өчен языла икән, аның өчен дип яши икән, һәм җәмгыятькә нәкъ менә шул хезмәтне күрсәткәне өчен аннан материаль һәм рухи ярдәм ала икән — шулай булгач халыкның, укучыларның да язучы иҗаты хакында үз фикерләрен әйтергә хокукы бар бит! Теге яки бу әсәрнең үзенә ничек тәэсир итүен, ошавын яисә ошамавын әйтергә һәм язып чыгарга хакы бар.

Мөгаен, бусы белән дә бәхәсләшүче табылмас дип уйлыйм. Чөнки монысы да абсолют дәрәҗәдәге, барыбыз да таный торган дөреслек. Балки бирегә әнә шулай диеп язганнан соң, бүтән фикерләргә дә күчәргә мөмкин булыр иде. Ләкин әлеге дә баягы без озак еллар кичергән торгынлык еллары шактый үзгәрткән икән кайберәүләрнең фикерләү рәвешен. Чөнки без әле яңа гына бәхәссез хакыйкать дип карап киткән кануинны бозарга маташулар шактый еш очрый. Әдәбият һәм аның проблемалары хакында ачыктан-ачык сөйләшүне тыярга, аны кирәксез һәм хәтта зыянлы нәрсә итеп күрсәтергә теләүчеләр бар.

Соңгы елларда укучылар шигърият мәсьәләләре хакында борчылып редакцияләргә хатлар яза башлагач, әдәбиятның бу тармагы турында сөйләшү чыннан да өлгергән икәне ачыклангач — ике төрле мөнәсәбәтләр бәрелеше бигрәк тә күзгә ташлана башлады.

Нинди мөнәсәбәтләр соң алар?

Соңгы еллар тормышының үзендә, әдәби җәмәгатьчелектә һәм матбугатта шактый еш чагыла, еш очрый торган бу ике төрле карашка тулырак тукталып үтик.

Беренче караш. Бу караш тарафдарлары болай дип саныйлар. Әйе, бүгенге көндә безнең поэзиябезнең дә һәм гомумән ил күләмендәге поэзиянең дә байтак кына җитди кимчелекләре бар. Ул кимчелекләрнең байтагы торгынлык чоры һәм аның чагылышлары белән нык бәйләнгән. Бөтен яшәү рәвешебез белән бәйләнгән. Шуңа күрә хәзер ул кимчелекләр хакында ачыктан-ачык сөйләшү, аларны игътибар үзәгенә чыгарып кую һәм төзәтү өчен, алардан тиз арада арыну өчен көрәшергә кирәк. Чөнки яшәп килгән теге яки бу кимчелекне атап әйтмичә, тәртеп күрсәтмичә — аннан котылып булмый. Мөмкин түгел. Әнә шундый изге ният белән бу караш тарафдарлары төрле җыелышларда һәм матбугатта үзләре күргән кимчелекләрне әйтеп чыгалар, ул җитешсезлекләрдән тизрәк котылыйк, диләр.

Икенче караш. Мондый фикердә торучылар асылда әдәбиятның һәм бигрәк тә шигъриятнең чын хәлен ачыктан-ачык сөйләшүгә каршы төшәләр. Бигрәк тә аның кимчелекләрен күрсәтү кирәк түгел диган сыман фикер үткәрәләр. Мондый мөнәсәбәтнең хәзерге яңарыш чорында шактый гаҗәп тоелуы мөмкин. Чөнки үсеш-

кә бары тик кимчелекләрдән котылу аркылы гына ирешеп була бит. Бүген яшәүче кимчелекләр алар алга таба бару юлындагы киртә, өскә таба күтәрелүче кош өчен авыр таш бит.

Шагыйрь Әхмәт Рәшитов бәхәстә катнашып үзенең мәкаләсен (5 сан) тулысы белән менә шушы икенче фикерне — ялгыш карашны раслауга багышлады. Шуңа күрә аның ялгышларын берәм-берәм һәм тәртибе белән карап барыйк.

Мәкаләсенең иң беренче бүлеген автор «Урап кайтыйк әле үткәннәрдән» дип исемли һәм үткән чорлар тормышына мөрәҗәгать итеп, аннан А. С. Пушкин мисалын ала. Бу шагыйрьне сирәк туа торган даһи дип санау мәсьәләсендә без биредә, әлбәттә, автор белән бәхәсләшмибез. Әмма менә шул даһиның язганнары турында аның замандашлары үз фикерләрен белдерә ала идеме, юкмы? Безнең Ә. Рәшитов кистереп «юк!» дип әйтә. А. С. Пушкин талантын мактап, аның әсәрләренең кыйммәтен аңлатып, күпләгән замандашлары яратып укырдай зур-зур тәнкыйть әсәрләре язган В. Г. Белинский шагыйрьнең кайбер шигырьләре уңаеннан усал фикерләр әйткәч,— бу безнең Ә. Рәшитовка ошамый. Шагыйрьне үтерүчеләргә булышты тәнкыйтьче дип яза ул.

Ярый, алайса киресеннән чыгып карыйк, Ә. Рәшитов сүзе дөрес дип карыйк. Алай булган очракта безнең тәнкыйть һәр шагыйрьгә, ә инде зур талантка бигрәк тә, ләббәйкә генә диеп торырга тиеш булып чыга бит?! Дөресен әйтмичә генә! Мәнә бу карашны безнең илдә шәхес культы һәм торгынлык чоры тудырган караш димичә ни дисең?! Шул елларның иң типик җимеше бит инде бу! Ягъни, нинди дә булса сәләткә ия булган берәү бөтенләй халык һәм җәмәгатьчелек күзәтүеннән азат. Халык аның теге яки бу сыйфатлары хакында, бигрәк тә йомшак яклары турында авыз да ача алмаска тиеш!

А. С. Пушкин белән В. Г. Белинский арасына кереп, безнең Ә. Рәшитов бөекләргә бары тик сукыр рәвештә иярергә яратуын гына ачты түгелме?! Ә бөекләр үзләре бит теге яки бу кеше турында, аның иҗаты турында ни уйласалар — шуны әйтеп, шуны язып яшәгәннәр! Әнә шуңа күрә алар бөек булып үскәннәр дә! Үз күңелләрен шартлы кысалар эчендә тотмаганга күрә! Ә. Рәшитов тәкъдим иткән рухи кыса кысып тормаган аларның яшәвен һәм аларның иҗатын! Менә бит хикмәт нәрсәдә! Ә без (Ә. Рәшитов карашы моңа бик ачык мисал) мондый кысаларга бик тә иялəнгән, хәтта артыгы белән иялəнгән икәнбез! Илленче еллар тәэсире дими ни дисең инде моны!

Шулай итеп, тормыш һәм яшәеш хәрәкәтен нинди генә булса да кысага тыгарга маташу үсешкә зыян китерә. Яшәүдә бары тик хәрәкәт һәм көрәш закончалыклары гына идарә итәргә тиеш! Әнә шулар гына үсешкә һәм яңа биеклекләргә китерә. Күп еллар буена расланган фәлсәфә әнә шул хакыйкатькә инандыра.

Үзенең язмасын «Шигърият һәм тәнкыйть» дип исемләсә дә, чынлыкта Ә. Рәшитов поэзияне тәнкыйтьтән читтә калдыруга чакыра. Мәсәлән, ул рецензияләрне бары тик шагыйрьләр үзләре генә нык аңлап, тирән тоеп язалар ди. Әйе, андый шагыйрьләр дә бар, башка жанрларда да андый иҗатчылар бар. Ләкин шул ук вакытта без бит монысын да бик яхшы беләбез. Соңгы елларда язучылар һәм шул исәптән шагыйрьләр арасында да «Син — миңа, мин — сиңа» принцибы буенча эш итүчеләр шактый күбәеп китте. Җыелышларда алар доклад сөйләсә, барысын да мактап кына бара, әйтерсең инде бездә бер генә кимчелек тә калмаган! Матбугатта алар мәкалә яисә рецензия белән чыгыш ясаса — шулай ук гел мәдхия генә! Ә. Рәшитов нәкъ менә шуларны чын тәнкыйть дип атый. Гел мактап кына һәм өстән генә рецензияләр язучы Ә. Габиди кебекләрне ул үрнәк итеп куя. Алар әйткән тәнкыйтьне дә шифалы дару кебек кабул итәсең, ди автор.

Әйе, бу тип «тәнкыйтьчеләр»не бик яхшы беләбез без! Тоташ мәдхия укыганнан соң, алар форма өчен генә бер-ике вак житешсезлек тә күрсәткән була. Янәсе, менә болар да бар, аларны һичшиксез төзәтергә кирәк. Ә чынлыкта ул житешсезлек әсәр өчен төп кимчелек булмый, андыйлар әсәр язмышын хәл итми торган була. Әсәрне бар иткән яисә аны юк иткән төп моментлар андый «тәнкыйтьтә» билгеле инде әйләнеп узыла. Уртакул һәм буш әсәрләр язып бастыручының йөрәгенә мондый «тәнкыйть», әлбәттә, май булып ята.

Шигъриятнең безнең әдәбиятта иң борынгы һәм иң көчле тармак булуын бүген беркем дә шик астына алмый. Ул бәхәссез хакыйкать. Ләкин кайчагында матбугатта принципиаль мәкалә басылганнан соң «шигъриятка кизәнү» дигән сүзләр ишетелеп ала. Андый сүзләр артында зур гына хәйлә ята.

Иң башта, гомумән, тәнкыйтькә эләккән кешенең үз-үзен ничек якларга теләвенә күз салыйк. Әдәбиятта гына түгел, теләсә нинди бүтән тармакны алыйк. Кем тарафыннандыр тәнкыйть утына дучар булган кеше үзен яклау өчен иң элек тәнкыйтьләүченең үзенә нинди дә булса берәр гаеп тагарга тырышыр. Аның үзенең бер-бер

кимчелеген табып, игътибарны шуңа таба юнәлтергә тырышыр. Ягъни, «иң әйбәт саклану чарасы — үзең һөҗүм башлау» дигән тактика белән хәрәкәт итү була инде бу! Нәкъ Суворовча!

Шулай итеп, мондый очракта тәнкыйть утына эләккән кеше күрсәтелгән җитешсезлекне бетерү турында түгел, ә судан коры чыгу хакында уйлана, шуның чарасын күрә башлый.

Әйләнә-тирәдәгеләр менә шушы хәйләне вакытында аңлап ала алмасалар, тәнкыйтьләүче белән тәнкыйтьләнүче арасында үзара гаепләшү генә бу дигән уй да туарга мөмкин. Яшәп килгән кимчелекләрне, беренче башлап сүз әйткән тәнкыйтьләүче күрсәткән җитешсезлекләрне бетерү чаралары күрелмәскә дә мөмкин. Ә таза, рухи яктан сәламәт коллектив булганда, әлбәттә, кемнең нәрсә өчен көрәшкәне бик тә ачык күренеп тора ул...

Безнең әдәби җәмәгатьчелек катнашында узган җыелышларда да чыгыш ясаучылардан бары тик шагыйрьләрнең үзләренең генә безнең поэзияне бер дә кимчелексез дип санаулары, булган кимчелекләрне реаль рәвештә күрергә теләмәүләре — әйбәт, эшлекле киләчәк файдасына сөйләми.

## Кыялар һәм үзәннәр...

Һич уйламаганда кыялар турында да бәхәс килеп чыкты бит әле. Журналның узган ел дөнья күргән саннарының берсендәге (8 сан) мәкаләдә мин Равил Фәйзуллинның шигыре белән Сафуан Муллагалиевнең әсәрен чагыштырган идем. Беренче шагыйрьнең «Аһ, бу тау юклыклар, кыя юклыклар...» шигыре белән икенчесенең «Теләмәдем кыяларга бер кош булып ояларга» дигән әсәрен. Бу ике шигырьнең төп фәлсәфәсе шушы без атап үткән юлларга нигездә сыеп беткән, шуңа күрә бәхәснең асылы укучыга да ачык аңлаешлы.

Эш шунда, шигырь турындагы бәхәс барышында Рахмай Хисмәтуллин сүз алып (быелгы 6 сан) бу очракта Р. Фәйзуллин сүзенә ныграк ышануын, аның фәлсәфәсе белән килешүен белдерде. С. Муллагалиевнең шигырен исә көпшәк әсәр дип кенә тамгалап үтте.

Чыннан да, фикер алышыр өчен кызыклы гына очрак. Әйдәгез, бу ике шигырьнең башка ягына кагылып тормастан — аларның төп фикерләре, төп фәлсәфәләре хакында сөйләшеп алыйк. Аларның кайсысы тормышчанрак эчтәлеккә ия? Кайсында яшәү фәлсәфәсе ныграк һәм тулырак чагыла?

Иң элек берсен кире кагып, икенчесен генә расларга тырышу булмасын өчен, икесенең дә уңай ягын, дөрес ягын табарга тырышыйк. Әйе, «аһ, бу кыя юклыклар, тау юклыклар...» фәлсәфәсе безгә яхшы аңлашыла — кешеләрне сыный торган ситуацияләргә кытлык сизү, шуларны юксыну, чын ирләрчә яшәргә бик нык ымсыну дип кабул итәргә кирәк бу шигъри юлларны. Шулай ук ныклык, кыюлык, каһарманлык символы дип тә аңлый алабыз без кыяларны. Һәрхәлдә, шагыйрь Р. Фәйзуллинның төп идеясе әнә шул тирәгә яшеренгән. Нәтиҗә ясаган кебегрәк әйтсәк, бу күбрәк очракта яшьлеккә хас халәт. Каядыр, нәрсәгәдер ашкыну, омтылу халәте. Бик үк ачык, анык булмаса да — каядыр, нәрсәгәдер ирешәсе, күтәреләсе, менәсе килү...

Инде икенче шагыйрь Сафуан Муллагалиевнең «Нәрсәм калган кыяларда...» дип үзәннәрне мактаган шигыренә килик. Биредә нинди реаль эчтәлек ята икән?

Биредә иң элек үзәннәрнең төп үзлеген — аларда яшәү, тормыш баруын, дәвам итүен әйтеп китәргә кирәк. Менә бу сыйфат: тормышны барлыкка китерү һәм дәвам иттерү бер генә төрле шигъри чара белән генә дә, бер генә төрле матур омтылыш белән генә дә алмаштырыла алмый торган асыл һәм бердәнбер сыйфат! Хәтта ки әле бөтен табигать, галәм өчен уникаль дәрәҗәдә бөек булган бердәнбер халәт бу! Тормыш китереп чыгару һәм аны дәвам иттерү!

С. Муллагалиев үзенең тормыш тәҗрибәсеннән чыгып әнә шул бөек фәлсәфәгә ирешкән һәм аны шигырендә гади генә итеп, әмма ихлас һәм тәэсирле итеп әйтеп биргән. Дөнья күреп, туган җирен сагынып, җирсеп кайткан һәм туган туфракның ни икәнен бик яхшы аңлаган кешеләр акылы чагыла монда. Биредә ирексездән диярлек мәрхүм шагыйребез Сибгат ага Хәкимнең: «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» дигән юллары искә төшә. Кыскасы, реаль эчтәлек — мәгънә тирәнлеге ягыннан караганда «үзәннәр» ягының җиңүе көн кебек ачык. Тормыш үзе, яшәү үзе әнә шул ямь-яшел гүзәллеккә төренгән үзәннәр ягында! Тормыш үзе әнә шуларны яклый.

Ярый, ә егетлек, кыюлык мәгънәсендәге кыя образы белән нишлибез соң? Бәлки бу яктан караганда «кыя» дигән чакыру дөресрәктер?

Тормышта һәрвакыт батырлыкка урын бар. Бу сүзләрне Максим Горький әйт-

кән. Шулай булгач, без әле нигә батырлык, кыюлыкны гел кыялар төбәге белән генә бәйлибез? Үзебезнең як үзәннәрендә туып үскән Җәлилләр кыядан киммени? Алар үзләрендә туган ягыбызның бөтен матурлыгын һәм ныклыгын чагылдырмадымыни?!

Тау ягы — кыялар иле халыкларының кырысрак холкын мактый биредә Р. Фәйзуллин дисәк — моңа да бик иярәсе килми. Чөнки андый холыклы кешенең ил башына менеп утырып халыкка ниләр күрсәткәнен без бүген бик яхшы беләбез. Шуңа күрә бу мәгънәдә дә «кыя» образы безнең күңелне яулый алмый. Юк, алмый! Кешелек матурлыгына ия, кече күңелле һәм тирән рухи дөньялы шәхесләрне — үзләрендә эчке һәм тышкы гармония чәчәк аткан шәхесләрне — үзрәк күрә, якынрак күрә безнең халкыбыз!

Язмабызның ахырында кыялар һәм үзәннәр хакында сүз кузгатуның тагын бер максаты бар иде.

Билгеле булганча, без — татар интеллигентлары, үзебездән читтә булган темалар турында бик тә теләп сүз куертабыз. Үзебез катнашып хәл итә алмастай проблемалар — әйтерсең лә безнең өчен җан азыгы! Шул кадәр дә мавыгып һәм озак вакыт биреп тикшерәбез без андый ерак проблемаларны! Гаҗәпкә калырлык!

Аерым алганда бүгенге поэзиядә дә андый чир бар. Шигъриятне каяндыр читтән, ерактан, бүтән тормыштан — бүтән җирлектән эзләү көчле. Шуңа күрә безнең поэзиядә диңгезләр дә, таулар да, йолдыз җилләре дә — буа буарлык!

Тик менә бүген безнең каршыга килеп баскан чынбарлык иҗат кешесенә язган вакытта теманы һәм мәсьәләне үзенең басып торган җирлегеннән алырга куша. Иҗатны җиргә төшәргә чакыра. Җир кешесе янына килергә куша. Аның — гади кешенең — йөрәген аңларга, тоярга чакыра! Чөнки безнең чор ул конкрет кешене һәм аның җирлеген ныгыту чоры.

Шуңа күрә без язмабызның ахырында тагын бер мәртәбә Сибгат Хәкимнең акыллы юлларын кабатларга мәҗбүр булабыз... «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...»

Әйе, бу кырлар, бу үзәннәрдә — безнең татар халкыбыз яши!

Безнең дә яшәү һәм иҗат итү җирлегебез әнә шунда!

## Роберт Миңнуллин

# НӘРСӘ БУЛДЫ БЕЗГӘ?

Нәрсә булды безгә? Нәрсә булды безнең шигъриятебезгә? Ни өчен аның тирәсендә шулкадәр шау-шу, бәхәс купты? Данлыклы поэзиябез үзенең позицияләрен чыннан да югалттымы соң әллә? Бәлки, бәлки... Хәзерге көндә — иң зарур чакта гына ни өчен шигырьнең кирәге калмады? Югыйсә, нәкъ менә бүген шигъри сүз элеккедән көчлерәк яңгырый ала түгелме соң? Әлбәттә, әлбәттә...

Гомумән, шигырьгә кем бәя бирергә тиеш соң әле? Тәнкыйтьчеләрме? Наширләрме? Шагыйрьләр үзләреме? Әллә инде укучылармы? Кайсыларына ышанырга? Хакыйкать кем ягында? Ә бит шигъри тормыш яшәвен дәвам итә: шагыйрьләр яза тора, укучылар укый тора, тәнкыйтьчеләр тәнкыйтьли тора... Барысы да тәртиптә шикелле. Ләкин, ләкин...

Һәр шагыйрь үзенчә ачыла. Кемнедер тәнкыйть ача. Кемнедер — укучылар. Кемнедер — аксакаллар. Кемнедер — вакыт галиҗәнапләре...

Әхсән Баяновның 60 еллык юбилее кичәсе әле дә күз алдымда. Матур сүзләр дә күп әйтелде анда. Талантлы язучы, шагыйрь, драматург, тәнкыйтьче икәнлеге дә искә алынды. Ләкин иң истә калганы — шагыйрь Ренат Харис чыгышы булды. Ул Әхсән Баяновны күкләргә күтәреп тә мактамады, әллә нинди төче-төче юбилей котлаулары да әйтмәде. Ул юбилярның шигырьләрен генә укыды. Кулына эләккән очраклы бер китабыннан. «Җәй — яшел кош» исемле. 1976 елны басылып чыккан. Бер шигырь яңгырады. Ике, өч... Зал башта аптырабрак калды, сискәнебрәк киткәндәй булды. Ахырдан бөтен зал шаулатып кул чапты. Шигырьләре кырыс, усал, гадел иде Әхсән Баяновның. Җитмәсә, Р. Харис үзе укыган һәрбер шигырьнең язылган елын әйтеп барды. Ул шигырьләрнең барысы да торгынлык чорының чәчәк аткан елларында

язылган булып чыкты. Шуңа күрәдерме, алар аеруча көчле яңгырадылар ул көнне. Янымда утыручы язучы кичә беткәндә колагыма пышылдады: «Әхсән Баянны, ниһаять, аңладым мин»,— диде ул, дулкынлануын яшерә алмыйча.

Әхсән Баяновның зур шагыйрь булуын, аның юбилей көннәрендә, ниһаять, тәнкыйтьчеләр дә аңладылар булса кирәк. Мәсәлән, Татарстан радиосыннан барган бер русча тапшыру истә калган. Анда тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин белән шагыйрь Николай Беляев, Мәскәүдә «Советский писатель» нәшриятында чыккан «Другой земли нет» исемле шигырьләр китабыннан соң, Ә. Баяновны шагыйрь буларак өр-яңадан ачулары турында сөйләделәр. Р. Мостафин аны Р. Гамзатов, К. Кулиев, Д. Кугультинов белән дә чагыштырып сөйләде әле хәтта. Ә бит ничә еллар буе тәнкыйть Әхсән Баяновны шагыйрь буларак күрмәмешкә салышып килде. «Соң булса да уң булсын» дими ни дисең инде бу очракта.

Торгынлык чоры... Ә бит ул елларда Әхсән Баянов язган. Туфан, Хәким, Арслан язган. Г. Афзал, Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин язган. Кырык беренче елгылар язган. Юк, безнең шигърият үз позицияләреннән чигенмәде. Чөнки шигъриятебез зур, шагыйрьләре зур. Мин монда әле төп көчләрне күз алдында тотам. Шигъриятебезнең намусы алар иҗаты белән үлчәнә. Шигъриятебез алар иңенә таяна.

Шулай да соңгы елларда шагыйрьләр иҗатына бәя бирүдә шактый буталчыклыклар килеп чыкты. Объективлык кимеде. Мактала торган гына шагыйрьләр барлыкка килде. Алар талантлы шагыйрьләр. Алар калын-калын китаплар чыгаралар. Алар турында озын-озын рецензияләр, мәкаләләр, иҗат портретлары языла. Алар турында һәркем ашыга-ашыга үз фикерен әйтеп калырга тырыша. Тәнкыйтьчеләр генә дә түгел, хәтта прозаиклар да, драматурглар да читтә калмый. Әйтик, заманында Р. Фәйзуллин турында сүз әйтми калуниндидер бер кимчелек булып санала иде. Шуңа күрә үзләренең яңа поэзияне «аңлауларын» тизрәк күрсәтеп калырга теләүчеләр кирәктә дә, кирәкмәгәндә дә шагыйрьне мактадылар.

Тәнкыйть мәкаләләрендәге төрле обоймаларга «беркетелгән» шагыйрьләр төркеме пәйда булды. Алар әлеге исемлектән бер дә төшеп калмыйлар, искә алынып кына торалар, онытылмыйлар. Ләкин аларның үз гомерләрендә бер генә тапкыр мактау да, тәнкыйть тә ишеткәннәре юк.

Һәр чактагыча, тәнкыйть өчен яратылган шагыйрьләр дә табылды. Алар, гадәттә, тәнкыйтьчеләрнең яраткан шагыйрьләре. Чөнки аларның иҗатыннан мәкаләләр өчен кирәк булган кире мисалларны теләгәнчә табарга мөмкин.

Тагын бер төркем шагыйрьләр бар. Алары сиздерми генә, тавышсыз-тынсыз гына китап чыгару ягын карыйлар. Һәм чыгаралар да. Ләкин ул китапларны тәнкыйтьчеләр белмиләр дә, күрмиләр дә. Укучылар да беләдер дип уйламыйм. Аларның шагыйрьлекләре беркемгә дә билгеле түгел диярлек. Аларны фәкать редакцияләрдә, нәшриятта, литфондта, Язучылар союзы бухгалтериясендә һәм шулай ук пропаганда бюросында беләләр булыр. Андыйлар Казанда да, Чаллыда да, Әлмәттә дә тыныч кына яшәп яталар.

Шигъриятебездә графоман дәрәҗәсендәге шигырь язучылар да җитәрлек әле. Алары куркынычрак та. Бу хакта М. Шабаев бик дөрес әйтеп китте. Алар соңгы вакытта артканнан-арта гына бара. Алар коточкыч күп язалар, шагыйрьдән шагыйрьгә йөриләр, шигырьләрен бер укыталар, ике укыталар, өч укыталар, киңәшләр алалар, төзәттерәләр, эшләттерәләр, ямыйлар, ремонтлыйлар. Аннары шул шигырьләрен иҗат секцияләренә алып киләләр. Анда аларны өч-дүрт, дүрт-биш шагыйрь яңадан укып чыга, киңәшләрен бирә. Шуннан соң ул шигырьләр газета-журнал редакцияләренә килеп эләгә. Төзәтелеп, редакцияләнеп кайберләре дөнья да күрә. Еллар уза, әлеге шигырьләр җыела тора. Кулъязма нәшриятка тәкъдим ителә, рецензияләнә, редакцияләнә, кереш сүз языла. Һәм, ниһаять, әлеге шигъри язмалар аерым китап булып басылып та чыга. Китапның тышында, билгеле инде, әлеге әсәрләрне беренче тапкыр язган һәм аларны еллар буе күтәреп йөргән кешенең исем-фамилиясе тора. Гәрчә анда, әгәр дә гадел булыйк дисәк, тагын бер ун исем-фамилияне бик рәхәтләнеп куярга булыр иде. Чөнки әлеге китапка күп шагыйрьләрнең бик зур хезмәте кергән бит. Ә авторның үз хезмәте бөтенләй диярлек калмаган. Хәер, андый авторлар үзләренең «соавторларына» бурычлы булып калмыйлардыр. Чөнки алар шигырь язарга оста булмасалар да, башка һөнәрләргә оста булучан. Шуңа күрә дә тора-бара алар китапларны коеп кына куя башлыйлар. Билгеле инде, союзга да керми калмыйлар. Моннан соң сөйләшеп кара инде син алар белән! Шунысы аянычлы, минем бу мәкаләне укыганда ул «шагыйрьләрнең» берсе дә «кара әле, минем турыда язган бит бу» димәячәк, хәтта башына да китермәячәк. Ләкин аларны барыбыз да белә. Тик дәшмибез генә. Ничек дәшик инде. Без алардан үзебез шагыйрьләр әвәләдек түгелме соң?

Аннары шунысы да бар әле. Алар, сукыр чебен кебек, тәнкыйть мәкаләләренә дә килеп керәләр, талантлы, зур шагыйрьләр белән беррәттән, алар хакында да сүз

әйтелә, китапларына сүз башлары языла, хәтта үзәк матбугатка да тәкъдим ителә башлый, шаулатып иҗат кичәләре уздырыла. Менә шуннан соң инде кайбер тәнкыйтьчеләрнең компетентлыгына бераз шик уянып куя. Тәнкыйтьнең бүгенге көндәге иң зур кимчелеге дә шигърият белән мөтәшигърияткә бутаудадыр, мөгаен.

Шигъри тәнкыйтьтәге аңлашылмаучылыкларның берсе талантлы шагыйребез Рәшит Әхмәтҗанов белән булды. Ләкин аңа ни өчендер беркемнең дә игътибар иткәне юк. Әйтерсең лә, шулай булырга тиеш. Ә бит ул бүгенге көндә танылган шагыйрь, моннан утыз еллар элек поэзиягә килгән шагыйрь. Аның беренче шигырьләре 1961 елда ук Марс Шабаев, Саҗидә Сөләйманова, Энҗе Мөэминова кебек өлкән буын шагыйрьләр белән «Яз күрке» исемле яшь шагыйрьләр китабында дөнья күрде. Аннары үзенең аерым китабын чыгарды. Ләкин бераздан ни өчендер тәнкыйть тарафыннан Р. Фәйзуллиннар буынына кертеп йөртелә башлады. Соңрак аның шигырьләре Т. Камалиев, Ш. Маннапов белән бергә «Адымнар» исемле җыентыкта чыкты. Соңга табан аның исеме Зөлфәт, М. Әгъләмов, К. Сибгатуллиннар белән бергә күренде. Бу елларда ул безнең буын шагыйрьләре рәтендә саналып йөртелә. Тәнкыйтьчеләр Рәшит Әхмәтҗановны татар шигъриятенең «мәңгелек яшь шагыйре» ясамакчылар, ахры.

Эдуард Мостафинны да талантсыз шагыйрь дияргә берәүнең дә теле бармас. Аның талантлы шагыйрь булуы бәхәссездер. Шулаен шулай, ләкин талантлы шагыйрьгә мөнәсәбәт тә башкача булырга тиештер бит. Ләкин аңа карата безнең тарафтан, йомшак кына итеп әйткәндә, талантсыз мөнәсәбәт, игътибарсызлык, битарафлык хөкем сөрә. Беренчедән, китаплары еллар буе ята-ята гына, бик авырлык белән генә чыга. Икенчедән, СССР Язучылар союзына әле булса кабул ителмәгән. Өченчедән, аның исеме дә, шигырьләре дә Татарстан китап нәшриятында чыгып килүче «Татар поэзиясе антологиясе»нә кертелмәгән. Моны ничек аңларга? Бәлки, шигырьләре начардыр? Әгәр ул критерийдан чыгып карасаң, Эдуардтан начаррак шигырьләр язучы бернichә дистә шагыйрьне дә әлеге антологиядән төшереп калдырырга кирәк иде. Әллә инде «башка» сәбәп өченме? Алай икән, шул «башка» сәбәп өчен, әгәр гадел булыйк дисәк, тагын бик күп, бик күп шагыйрьләребезне антологиягә кертми калдырырга иде. Шулай да ни өчен бер Эдуард Мостафин гына керми калган соң анда? Сәбәбе нидә? Хәзер беркем белми, беркемгә кирәкми... Ләкин ничек кенә булмасын, шагыйрь Эдуард Мостафинның «Татар поэзиясе антологиясе»нә керми калуы барыбызның да — Язучылар союзы идарәсенең дә, поэзия секциясенең дә, нәшриятның да, антологияне төзүчеләрнең дә намусында кала. Торгынлык чорындагы социаль гаделсезлекнең «матур» бер үрнәге бу. Башка кабатланмаска тиеш үрнәк!

Тәнкыйтьчеләр шагыйрьләрнең иҗатларын тикшергәндә бүлгәләргә, йә булмаса төрле төркемнәргә аерырга яраталар. Әйтик, шактый гына еллар шагыйрьләребез дулкыннарга бүленеп йөртелде. Мин үзем, мәсәлән, бишенче дулкын вәкиле идем. Бүлгәләүләр шагыйрьләрнең әдәбиятка килү вакытлары белән дә, нинди дер бер темага язуларына карап та эшләнде. Үзләренең зәвыкларына туры китереп тә бүлгәләп карадылар. Ләкин бу бүлүләр, төркемнәр, обоймалар субъективлыкка китерә торган алым булып чыкты. Талантлы шагыйрьләребез, бер чыбыкка тезеп куйгач, төссезләнеп, бер-берсенә охшап калдылар. Тәнкыйтьчеләрнең кайберләре шуны онытып җибәрделәр бугай: лирик шагыйрьләрнең дә, әгәр талантлы булса, һәркайсы үзләренчә яза. Фәлсәфи шагыйрьләр дә шулай ук. Аннары лирик шагыйрьләр дә фәлсәфи шигырьләр иҗат итәргә мөмкин түгелме соң әле.

Һәрхәлдә, мәкалә саен Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Гатауллин, Г. Рәхим дип тезеп китү укучыларны туйдыргандыр. Әлеге шагыйрьләрнең үзләренә дә ошамыйдыр бу чылбырдай тезелеп гомер итүләре. Алар миңа хәзер Р. Фәйзуллинрхарисргатауллингрәхим дигән бер шагыйрь булып тоела башлады. Ләкин бит аларның һәрберсе үзенчә, шигърияткә алып килгән яңалыклары да үзләренчә, туган телгә булган мөнәсәбәтләре дә үзләренчә. Бер-берләренә һич кенә дә охшамаган шагыйрьләр. Берберсенә тагылып йөрергә лаек түгел дип уйлыйм мин аларны.

Әгәр дә тәнкыйтьчеләребез шагыйрьләргә һәрвакыт объектив бәя биреп барсалар, аларны вакытында күрә белсәләр, әйбәт, талантлы шагыйрьләрнең кадерен белсәләр, төрле уңайсыз хәлләр килеп тә чыкмас иде, бәлки. Ә алар җитәрлек була тора. Рәхим итәсез, шундый хәлләргә бер мисал: күптән түгел Мәскәүнең «Современник» нәшриятында «Середина земли родной» исемле яшь шагыйрьләр китабы басылып чыкты. Анда безнең Татарстаннан Р. Зәйдуллин, Л. Зөлкарнәев, Г. Моратов, Р. Шәрипов, Л. Лерон, Н. Акмалов кебек яшь буын шагыйрьләребезнең шигырьләре тупланган. Шулар арасына кем килеп кергән дип уйлыйсыз? Фәнис Яруллин. Танылган татар шагыйре. Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Быел «Шигырь китапханәсе» сериясендә сайланмаларын чыгарган почти классик шагыйрь. Әйтәсе дә түгел, шагыйрьнең 50 еллык юбилеена менә дигән «бүләк». Мәскәү нәшриятларында Фәнис Яруллинның кем икәнен белмиләрме? Белергә тиешләр! Әгәр дә бел-

миләр икән инде, монда без дә гаепле. Күрсәтә белмибез, димәк.

Әгәр дә безнең шагыйрьләребезне илебез күләмендә яхшы белсәләр, һич югында, аз-маз булса да алар турында хәбәрдар булсалар, СССР Язучылар съезды трибунасыннан сөекле шагыйребез Хәсән Туфанны, әле үзе исән чакта ук, «Хасан Туран» дип мәсхәрәләмәсләр иде. Ярар, Х. Туфан рус телендә яңгырамасын да ди. Аның шигырьләре рус теленә аз тәрҗемә ителгән, Мәскәүдә чыккан китаплары да берничә генә. Белмәүләре бер дә гаҗәп түгел кебек. Ләкин үзәк газетада («Социалистическая индустрия», 15 апрель, 1988 ел) ике бөек шагыйребезне — Габдулла Тукай белән Муса Җәлилне берләштереп, аларның икесен бер итеп «Джалиль Итукай» дип язуларын, нинди дер моңа кадәр билгеле булмаган шагыйрь исеме «иҗат» итүләрен берничек тә аңлап булмый. Димәк, Җәлил белән Тукайны да тиешенчә белмиләр булып чыга. Кайберәүләр өчен бу гадәти хәреф хаталары гына булып тоелырга мөмкин. Ләкин, кызганычыбызга, хәреф хаталары гына түгел, тирәнгәрәк киткән хаталар шул болар.

Әле менә искә төште. Берничә ел элек рус мәктәбендә укыган, ләкин татарчасы бик тә әйбәт бер егет белән сөйләшү булган иде.

— Үзебезнең кайсы шагыйрьләрне беләсең соң?— дип сорадым егеттән.

— Хәсән Тукайдан башка берәүне дә белмим шул,— дип җавап кайтарды ул, үзенең татар әдәбиятыннан аз булса да хәбәрдар булуына горурланып.

Анекдот кебегрәк яңгырый, шулай бит? Кемгәдер көлке дә тоелырга мөмкин әле. Ләкин ул чагында бер генә дә көләсе килмәгән иде минем.

Шигърияткә нидер булды шул. Соңгы вакытта аның абруе төште. Дөресрәге, шигърият үзе, нигездә, үзгәрмәде, шигъриятькә мөнәсәбәт үзгәрде. Язучылар союзында да, нәшриятта да, редакцияләрдә дә, тәнкыйтьчеләр даирәсендә дә. Шигырь күпләр өчен кирәксез, файдасыз бер жанрга әйләнә башлады. Шигырь китаплары моңа кадәр мөмкин кадәр кыяфәтсезрәк чыгарылды. Рәсемсез, саргылт кәгазьдә, шигырь юллары шыплап тутырылган булыр. Һәм, әлбәттә, иң түбән тираж белән. Хәтта газета-журналларыбыз да «акчаны күп ашый» дип, шигырьләрне азрак бирергә тырыша. Кайсыдыр бер мәкаләдә сәер бер фикер дә яңгырап китте. Янәсе, шагыйрьләр шигырьләрен акча өчен генә язалар. Күп язган шагыйрь — начар шагыйрь. Аз язса, әйбәт булып чыга инде. Ул чагында иң әйбәт шагыйрь бездә Мәхмүт Газизов булырга тиеш. Чөнки аның унбиш ел инде шигырь язганы юк. Ләкин «акча өчен яза» дигән ярлык тагу талантлы шагыйрьне рәнҗетә торган әйбер. Безнең шартларда шигырь белән тамак туйдырып булмаганны бөтен кеше беләдер, мөгаен. Шуңа күрә дә шагыйрьләребезнең бөтенесе дә диярлек казна эшендә эшләргә мәҗбүр. Ул гына да түгел, күп шагыйрьләр күптән инде башка төшемлерәк жанрларга күчешеп беттеләр. Күпләр өчен шигърият икенчел жанрга әйләнеп бара шикелле. Хисам Камалов — романнар яза. Илдар Юзеев — танылган драматург. Әхсән Баянов — романнар, повестьлар, драмалар авторы булып танылды. Шәүкәт Галиев балалар әдәбияты дилбегәсен үз кулына алды. Гәрәй Рәхим — прозаик та, драматург та. Рөстәм Мингалим дә драматург булып китте. Марсель Галиев — прозаик, драматург. Разил Вәлиев — прозаик. Рашат Низамиев — прозаик. Күрәсез, шагыйрьләр югалып кала торганнардан түгел, алар акчаның кайсы жанрдан күпме тамганын яхшы чамалыйлар. Төшемле жанр шигырь түгел шул. Ә инде «саф» шагыйрьләр бармак белән генә санарлык калып бара. Җиңел түгел шул шагыйрь шулпасы!

Бездә бик күп талантлы шагыйрьләр еллар дәвамында тәнкыйтьчеләр игътибарыннан читтә кала килә. Югарыда мин аларның кайберләре турында әйтеп уздым инде. Ә менә җитмешенче еллар башында поэзиягә килгән шагыйрьләргә тәнкыйть әле, гомумән, тотынмаган. Дөрес, унбиш-егерме ел дәвамында безнең буынны да кыр казлары кебек бер чылбырга тезеп йөрттеләр йөртүен. Әмма аерым рецензияләрне исәпкә алмаганда, ни Марсель Галиев турында, ни Зиннур Мансуров турында, ни Фәннур Сафин турында әлегә бер җитди сүз дә әйтелгәне юк. Шулай ук Нурия Измайлова, Госман Садә, Харрас Әюпов, Рашат Низамиев та күптән инде тәнкыйтьчеләр фикеренә лаек китаплар бастырып чыгардылар. Хикмәт нидә соң? Югыйсә, шагыйрьләр бар, китаплар бар, иҗатлар бар, ә тәнкыйтьчеләр фикере юк. Шигъриятттә үзен тапкан, үз сүзен әйткән, татар шигъриятен үзенчәлекле иҗатлары белән баеткан буын. Аларны шигъриятттән барыбер алып ташлап булмый. Шуңа күрә тулы бер буынны күрмәмешкә салышу гаделлек түгел, минемчә. Аннары шунысы кызык, безнең буынның зур бер төркем тәнкыйтьчеләре дә бар. Аларга безне аңлавы җиңелрәк тә булырга тиеш. Ләкин алар да дәшми... әлегә.

Нәрсә булды соң әле безгә, егетләр? Шигърияткә булган бу битарафлык каян килә? Нигә буталышып беттек? Югыйсә, шигъри хуҗалыгыбызны тәртипкә китерер өчен күп тә кирәкми бит. Берничә шарт та җитә. Шагыйрьләр яхшы шигырь язса, нәшрият яхшы китаплар чыгарса, тәнкыйтьчеләр яхшы тәнкыйть мәкаләләре язса,— бар да яхшы булачак!

Библио-графия

# ФИКЕР КАТЛАМНАРЫ

**Галиев Ш. Илһамым-мәхәббәтем. Лирик язмалар. Казан, 1986.**

Шәүкәт Галиевнең «Илһамым-мәхәббәтем» китабын мин кулыма кызыксыну белән алдым. Иң әүвәл аның тышкы ягы — әсәрләрнең чәчмә формада язылуы ымсындырды. Шагыйрьләрнең, хәтта бик киң танылганнарының да, бәгъзе бер ихтыяҗ белән прозага күчүләре, алар каләменә хас булганча, мул хисле матур-матур чәчмә әсәр иҗат итүләре табигый күренеш, әлбәттә. Прозабызның ничектер төссезләнеп, сүлпәнәеп барган хәзерге мәлендә аңа Шәүкәт Галиев кебек талантларның килүе, яңа сулыш өрүе әдәбиятыбыз өчен мөһим табыш, зур отыш булыр иде.

Ләкин бу китабында Ш. Галиев чәчмә рәвештә язса да, барыбер шагыйрь булып калган икән. Монда аның соңгы утыз ел эчендә теркәп барган лирик язмалары туплап бирелгән. Ягъни ул — уй-фикерләр китабы. Анда күтәрелгән мәсьәләләр гаҗәп күп төрле, масштабы биниһая киң. Яшәеш, дөньяны тану дәверендә фикер иясе күңеленә ни-нәрсәләр кагылып узса, шуларның һәммәсе дә җыентыкта урын алган. Автор аларны аерым-аерым ояларга җыеп бирә: «Илһамым-мәхәббәтем», «Хисләр әлифбасы», «Ил яктысы», «Вакыт һәм гомер тәүлеге», «Туган җир. Табигать сәхифәләре». Бу бүлекләр үз эчләрендә тагын бик күп бүлекчәләргә бүленә, җыйнак-җыйнак фикерләр, күзәтүләр китерелә. Бу хасияте белән алар күпмедер дәрәҗәдә К. Насыйриның «Фәвакиһел-җөләсә» китабын да, Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре»н дә хәтерләтәләр.

Фикерләр арасында, билгеле, авторга иң якын, иң газизләре — шагыйрьнең яшәешен, хәятын тәшкил иткәннәре — әдәбият һәм сәнгать хакындагылары. Ул аларның иҗтимагый, рухи тормыштагы урыны, тәэсир көче, бу мөмкинлекләрнең ни дәрәҗәдә файдаланылуы хакында уйлана. Еш кына әдәбиятның өстән-өстән йөзүен, тормышның асылына төшенеп җитмәвен күрсәтә, үз иҗатыннан да моңа мисаллар китерә. Самолет кырда чүп утый дип, илленче елларда, әле бу эшнең үзен дә күрмәгән чагында, сокланып шигырьләр яза торган булган шагыйрь. Хәзер исә ул химикатларның чүпне генә утамавын, тирә-юньдәге барча тереклек ияләренә, кош-кортка, балыкка зыян салуын да күрә башлаган.

Шагыйрь әдәбиятның еш кына инерция буенча баруына, аерым темалар тирәсендә генә бөтерелүенә игътибар итә, язучыга үтә таныш булган тормышның, тәҗрибә, уйтойгыларның читтә кала бирүен искәртә.

Автор әсәрләребезнең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсенә текәлеп карый. Аның күзәтүенчә, кайбер әдәби әсәрләрнең сырт сөяге булмый. Моның сәбәбен ул кеше күңелен, психологиясен тирән тоймауда, шуны образлы рәвештә әйтеп бирә белмәүдә күрә. Рәтле телең, җитди темаң, мавыктыргыч сюжетың, анык характерларың булмаган килеш заман турында роман бинасын төзергә тырышуны ул саман кирпеченнән унбишәр катлы йорт салып азаплануга тиңли.

Аны урта кул әсәрләрнең күпләп языла торуы, шуларның мактала килүе хафаландыра, борчуга сала. Автор моның чыганагын эзли. Әйтик, ни өчен бер тәнкыйтьче кызып-кызып уртакул шагыйрьне яклый? Чөнки ул үзе уртакул тәнкыйтьче икән. Моның белән ул үз дәрәҗәсен расламакчы була.

Күренә ки, бу фикерләрнең нигезендә иҗатка карата зур таләпчәнлек, әдәбиятны олылау, тормыштагы актив позицияне раслау ята, сүз сәнгатенең нормаль үсеше хакында кайгырту чагыла. Китапта гомумән яшәеш, аның асыл сыйфатлары, закончалыклары хакында җитди караш уздырыла. Бик сирәк очракларда гына эзлеклелек чуалып киткәндәй була. Әйтик, авыр елларда әдәбият, сәнгать тормышны бизәп күрсәтергә тырышкан, ди автор. Тормышлар рәтләнгәч исә, авыр чаклар кырыслыгын чагылдырырга омтылу сизелә. Әдәбиятыбыз тарихында андый хәлләр дә күренеп калгалады, әлбәттә. Ләкин шулай да моны табигый күренеш, закончалык дип аңлату дөреслеккә туры килеп бетми. Асылда ул әдәбиятның билгеле бер атмосферада пассивлаша төшүен, үткен мәсьәләләрдән читләшүен, күрәш дәрте сүрелүен генә раслый.

Бу язмалардан без шагыйрьнең иҗат психологиясен, язу, хис-фикерне тышкы дөньяга чыгару, образга күчерү дәрте бе-

лән канатланган чактагы үзенчәлекле халәтен ачык итеп күз алдына китерәбез. Художникка илһам килүен автор илаһи бер кодрәт уянуына тиңли. Аныңча, илһам — ул сәламәт кешенең сау рухы канатланган чагы: күңел мөлдерәмә яктылык белән тула, тамырларда кан урынына кайнар нур ага, тәндә дәрт-дәрман ташып тора, ни эшләсәң дә җырлап кына бара, авыр тоелган, җанга тигән мәсьәлә дә ансат кына хәл ителә.

Ләкин моның белән автор иҗат эшен һич тә җиңеләйтеп аңлатмый, илһам — үзеннән-үзе, шагыйрь тырышлыгыннан башка эшли дигән беркатлы фикер үткәрми. Әлеге халәтне, иҗат дәртен ул тырыш хезмәт, өзлексез уйлану, эзләнү нәтиҗәсе дип бәяли. Күңел кагына, күңел — күкләрдә, ди ул. Әмма бу хәлгә җитәр өчен җир тырнап шактый үрмәләргә кирәк: канатлар күктән төшми, канатларны җирдә үстерәсең.

Автор монда иҗатның шагыйрь үзе генә тойган серләре белән уртаклаша, әсәрнең ничек итеп күңелдә бөреләнүен, ак кәгазьгә төшүен яктырта. Һәр шигырьнең үзең генә белгән көе була, ди ул. Еш кына көйләп язасың да, дөресрәге, күңелдә яңгыраган көйне сүзгә күчерәсең. Аңлашыла ки, моның өчен шагыйрьдән хис моңын, барометр кебек, бик сизгер тоя белү сорала.

Ш. Галиев әдәби әсәрдә конкрет картинаның, образлы сурәтнең куәтле эстетик йогынтысын басым ясап күрсәтә. «Мең кеше үлде!» дигән гомуми сүзгә караганда, тасвирлап бирелгән бер үлем ныграк тетрәтә дип раслый ул.

Язмалардан аңлашылуынча, шигырь язу вакытында уй һәм тойгыларның урыннары, шагыйрь аңында, күңелендә кайсының алга планда, кайсының арттарак торуы да әһәмиятле икән. Иң яхшысы — уй һәм хис бердәмлеге белән бергә туган шигырь. Ул рәхәт языла, анда бөтенлек, гармония була. Әүвәл фикерне теркәп, соңыннан шуңа тиң хис өрү читенрәк. Киресе дә булырга мөмкин. Башта күңелдә хис ярала. Әле шуның мәгънәсен аңлатырдай фикер ачык төсмерләнми тора. Ул шулай кабатланмыйча, мәгънәви анык кыяфәт алмыйча, югалып та калырга мөмкин. Ләкин, шуңа да карамастан, автор күп кенә хәлләрдә шигырь язу өчен беренче этәргеч булып тойгы хезмәт итүен раслый. Шагыйрь хисен уйга күчереп яза, ди ул икенче бер урында. Ягъни дәртләнеп иҗат итү, әйбәт әсәр тудыру өчен хис һәм фикер бердәмлеге шарт булуын тагын бер кат искәртеп уза.

Автор монда гадилеккә килү юлын да яктырта. Каләм тибрәтә башлаган мәлдә ул куышы, томанлы итеп яза торган булган. Мәгънәгә дә артык игътибар итмәгән, өстән-өстән йөзә биргән — сүзләр генә ялтырасын. Шигырь шулай булырга тиеш дип инанган ул. Тик байтак еллар тырыша торгач, ул кешечә, гади итеп язарга өйрәнә, гадилек гүзәллегенә ирешә. Шуңа күрә ул гадилек дәрәҗәсенә күтәрелүне сәләт, тәҗрибә нәтиҗәсе итеп, сәнгатьнең, матурлыкның бик мөһим серенә төшенү билгесе итеп карый.

Ш. Галиев сәнгать тармаклары: җыр, бию, мәзәк турындагы фикерләрен дә теркәп узган, аларның табигатенә хас сыйфатларны билгеләгән. Мәзәк жанры, аның әйтүенчә, кылыч белән ярышуны хәтерләтә, анда тизлек, һөҗүм хәлиткеч роль уйный. Салмак сөйләгәндә исә мәзәкнең пары чыгып, сүнеп, суынып бетә. Бу мәгънәдә һәр мәзәк — үз ритмы, сулыш-тыны булган җыйнак спектакль ул.

Мәзәк жанрының асылы турында зур-зур мәкалә дә язарга мөмкин булыр иде. Ә Ш. Галиев аның мөһим билгеләрен икеөч җөмлә белән әйтеп биргән.

Бу язмалар арасында без чын мәзәкчел ситуацияләрне дә очратабыз. Шундыйларның берсе, мәсәлән, баланың елга өстендәге катламы күреп соклануы, матурлыгын салават күперенә тиңләве. Шундыйрак күренешне Ш. Галиев бер шигырендә дә сурәтләгән иде. Димәк, автор аны башта шушы язмаларында теркәп куйган, аннары шигырь калыбына салган. Бирелә шулай ук легендага тартым рисалә, сабак булырдай үкенечле хәлләр, драматик, фаҗигале күренешләр дә тасвирлана.

Бездә әле иҗат процессын, художникның лабораториясен эчке яктан яктырткан хезмәтләр аз языла, иҗатның серләре, сүз остасының бай тәҗрибәсе күп очракта дөньяга чыкмыйча, уртак хәзинәгә әйләнмичә кала. Бу җәһәттән Ш. Галиев китабын тәүге җитди тәҗрибә дип карарга була. Ул әсәр язуның нәрсә икәнен, үзенчәлекләрен, нечкәлекләрен укучыга төшендереп бирә. Без монда шагыйрьнең эстетик карашлары турында мәгълүмат алабыз, җанга газиз туган тел турындагы фикерләре белән танышабыз.

Калган бүлекләр асылда фәлсәфи планда язылганнар. Икенче бүлектә, мәсәлән, кешенең хисләре, уйлары, мәгълүматлылык, фикер йөртү, акыллылык, зирәклек, күңел дөньясы, хакыйкать, характер һәм башкалар хакында сүз бара, боларның мәгънәсе ачып бирелә. Аныңча, җитәкче зирәк булганда, бер акыл йөзгә тапкырлана — күрсәтмәләрен йөз кеше тормышка ашыра. Юлбашчы зирәк булганда, бер акыл миллионга тапкырлана. Үкенечкә каршы, ялгышлар да шул ук дәрәҗәдә тапкырлана.

Кешене кеше итүдә автор күркәм рухи, әхлакый сыйфатларны бик югары бәяли. Ата-анасының баласына калдырган мирасын — эшчәнлек һәм тыңгысызлыкны, намус һәм вөҗданны ул бар байлык, мөлкәтләрдән дә өстенрәк куя. Балалар дөнья-

сы китапта аерым бүлек билән тора. Автор эш тәме, яме, ләззәте турында тирән мәгънәле фикерләр әйтә, эшкә һәм эш турында сөйләнүгә мөнәсәбәтнең төрлечә булуын күрсәтә. Эшләдем, дәшмәдем, ди берәү әйтә, ошатмадылар, пассив диделәр. Инде сөйлим дә сөйлим, эшләргә вакыт юк. Мактыйлар, актив!— диләр.

Язмалардан күренүенчә, тыйнаклыкка һәм әрсезлеккә мөнәсәбәт тә бер генә төрле булып чыкмый икән. Автор күзәтүенчә, тыйнаклык мактала килә, куләгәдә кала килә. Әрсезлек әрләнә бирә, эшен эшли тора, түрдән төшми тора.

Китапта яшьлек, мәхәббәт, гаилә мөнәсәбәтләре хакында гыйбрәтле фикерләр әйтелә, төрле ситуацияләр китерелә. Бер ир аерылырга ниятләп йөргән. Судка кәгазьләр әзерләгән, әйберләрне бүләргә исемлек төзеп куйган. Кәтмәгәндә, бөтенесен дә калдырып, үзе үлеп киткән.

— Шулкадәр аерыласың килгән иде... Менә, аерылдың инде...— дип җылый икән хатыны, әрнү катыш үпкә белән.

Язмыш, шулай итеп, үзенчә аера, үзенчә бүлә.

Автор сугыш һәм җир иминлеге турында борчылып уйлана, игътибарын акыл үсешенең бүгенге логикасызлыкларына юнәлдерә. Әйтик, ерткычка атар өчен мылтыкны ядрә белән коралар. Кешегә ату өчен атом бомбасы әзерләп куелган. Адәм баласы шул хәтле зур ерткыч булып чыгамыни? Автор әнә шундый сорауга җавап эзли.

«Кызыл китап» бүлеге табигать турында сөйли, андагы гармонияне, зирәклекне аңлата, кеше акылының, гамәлләренең табигатькә йогынтысын күрсәтә. Кеше, мәсәлән, тиз йөрешле машиналар ясый, әмма һәр машина мең кеше азыгын — кислородны ашый. Машиналар күбәя, җан иясе сулый торган һава азая. Бу хәл кешелек алдына тагын да җитдирәк, кискенрәк проблема китереп куя. Мондый шартларда кеше әлеге кислород чыганагын күп тапкырлар ишәйтү, һәр буш яткан җирдә калын урман үстерү хәстәрен күрергә тиеш иде кебек. Ләкин чынлыкта гел алай булып бетми. Әйтик, адәми затлар яңа ел бәйрәмен бәйрәм итәргә йөргәндә, миллионлаган, дистәләгән миллион зифа, сылу чыршылар, үзләренә үлем якынлашуны сизеп, кан калтырап торалар. Чөнки ул көннәрдә аларны хисапсыз кыру башлана, борынгы таш курчакка табынучылар, мәҗүсиләр дәверендәге кебек, алар символ хакына корбан ителәләр. Инде атна-ун көн үтүгә боларның кирәкләре бетә, илнең бөтен урам-тыкрыклары корыган чыршы белән тула. Корбан йоласы аек акылдан көчлерәк булып чыга, әнә шундый табигатькә, яшәешкә хилаф хәлләр шагыйрь күңелендә аптырау, гаҗәпсенү хисләре уята. Әдип раславынча, безнең әле бик гади күренешләрнең дә мәгънәсенә төшенеп җиткәнебез юк. Үзебез өчен нәрсәнең файдалы, нәрсәнең зарарлы икәнлегенә дә хисап биреп бетермибез. Автор күтәргән күп кенә мәсьәләләр, минемчә, бүген үк хәл итүне, эшкә керешүне көтәләр.

Биредә мин аңлы рәвештә җыентыкта күтәрелгән проблемаларның аеруча үткенnәренә тукталдым, аларны калкурак итеп күрсәтергә тырыштым. Ләкин, моңа карап, китапта гел күңел әрнетердәй мәсьәләләр җыелган икән дип фараз кылырга ярамый. Аның күп өлеше якты, ягымлы нурлардан тукылган, чынбарлыкның тирән хикмәтләрен ачып бирә торган нәтиҗәләрдән тора. Шул ук вакытта ул ваемсыз хозурлану, тук канәгатьлек җимеше генә дә түгел.

Фәлсәфи язмалар — безнең әдәбият өчен тансык жанр. Уйлану, фикер йөртү күләмле әсәрләрдә дә аз чагыла. Әллә нигә бер очраштырып куйгаласа да, сайлыгы, беркатлылыгы аркасында, примитив була, хаталар китә. Мондый хәл бигрәк тә урта-кул әсәрләргә хас. Бу китаптагы уйланулар исә җиһанны тирәнрәк аңларга, нәтиҗәләр ясарга булышалар. Яшәешкә актив мөнәсәбәт әнә шунда күренә.

Китапта фикерләрне бер-берсенә ялгап, тоташтан үстерә бару, өзлексез агым булдыру бурычы куелмаган. Мәгънәле, җыйнак җөмләләр күпмедер дәрәҗәдә шигъри парчаларны хәтерләтәләр. Кыскалык авторга тормышның киң иңнәргә, җыентыкны күп сыйдырышлы итәргә булышкан.

Дәлилләү, иллюстрацияләү дә юк. Мәкаль, әйтемнәр кебек, бу язмалар үзләренең эчке энергиясе, кодрәте хисабына яшиләр. Бу көчне аларга мәгънә тирәнлеге, фикер тапкырлыгы, ыспай, килешле итеп әйтә белү осталыгы бирә, иллюстрациягә, исбатлауга ихтыяҗ калмый.

Язмаларның һәммәсе дә, лирик әсәрләр кебек, композицион бөтен, төгәл итеп оештырылганнар. Күп очракта фикерләр билгеле бер фонда, бәгъзе күренешләр янәшәсендә киләләр. Шуңа күрә монда янәшәлек, контрастлык, антитеза әһәмиятле роль уйный. Фикерләргә параллель яки контраст итеп, я тормыш күренешләре, тарихи вакыйгалар, я тапкыр, канатлы гыйбарәләр килә, ахырдан мәгънәле нәтиҗә ясап куела. Әнә шулар һәр парчага төгәллек, бөтенлек төсмере бирәләр, аларны шигъри строфага якынайталар. Гомумән, монда күп нәрсә лирика һәм башка җыйнак жанрлар законы буенча иҗат ителгән. Китапта гыйльми концепцияләр генә түгел, шигъри караш та хәтсез урын ала.

Ш. Галиев төгәл тел белән эш итә. Китапта нинди дә булса артык яки урынсыз сүзне очратмыйсың. Бер җирдә автор: «ат уйнаткан сыман сүз уйнатырга

яратам», ди. Моны без аның шигырьләрендә дә күрә киләбез. Сүз уйнатулар бу язмаларга поэтик яңгыраш өстиләр. Үзенчәлекле метафора, чагыштырулар белән бергә автор омофон, оксюмороннарны да чит итми, җаена туры китереп, ипле итеп рифмаларны да кушып җибәрә. Шуңа күрә фәлсәфи-абстракт идеяләр укучы аңына җиңел-мәшәкатьсез барып җитәләр, предметлы, җанлы булып күз алдына килеп басалар.

Нәтиҗә шул: бу китап талантлы лирик шагыйрьнең бер үк вакытта олы фикер иясе дә булуын, кеше күңелендә күпме җәүһәрләр саклануын күрсәтә. Бу язмалар илдә башланган үзгәрешләргә кадәр теркәлгәннәр. Ләкин шуңа да карамастан, бүген һич тә үзләренең кыйммәтләрен җуймаганнар, гаҗәеп актуаль яңгырыйлар, хәзерге хәрәкәткә, үзгәртеп кору эшенә актив катнашып киләләр. Китапның күп кенә битләрендә без үзгәртеп кору идеяләренә аваздаш фикерләр белән очрашабыз. Алгарак карап язылганнары да бар. Шул ук вакытта аларның әле бу китапка кермичә калганнары да аз түгелдер. Заман атмосферасы әдип күңелендә яңа хисләр, яңа уйлар уяткан булуы ихтимал. Алары белән яңа китапта очрашырбыз дигән өмет бар.

Автор үзе бу язмаларны сүтеп ташлаган сәгать детальләренә тиңләштерә, шуларны җыеп, бер бөтен итсәң, безнең дәверне күрсәтердәй әсәр килеп чыгар иде, ди. Әнә шул җыю шөгылен дә, тоташ сюжетлы, киң сулышлы әсәр язу эшен дә Ш. Галиевның үзенә йөклисе килә. Әлеге фикерләре, кеше характерлары, психологик күзәтүләре, тасвирлау осталыгы белән Ш. Галиев мена дигән проза әсәрләре иҗат итә алыр иде. Шул юлда аңа уңыш һәм илһам телисе килә.

**Фәрит ХАТИПОВ,**
филология фәннәре докторы,
профессор.

# *Бер сорауга — бер җавап*

— Гомәр ага! Сез алдагы елларда «Казан утлары»нда нинди әсәр белән катнашырга уйлыйсыз?

**Гомәр Бәширов,** Татарстанның халык язучысы:

— Хәзерге заман яшьләренең кайберләрендә халыкның тарихына ихтирам һәм игътибар җитеп бетмәве сизелгәләп куя. Алар, мәсәлән, «Үткән заман кешеләреннән нәрсә көтәсең? Аларның культуралары шактый ук түбән булган бит» дигән кебегрәк фикер йөртәләр. Бактың исә, үзе шул ук борынгы кешеләр чыгарган сокландыргыч җырлар белән күңелен ача, моннан 800 ел элек язылган «Йосыф китабы»н укып хәйран кала, Сак-Сок бәетеннән гыйбрәт ала. Әле җитмәсә, үз фикерен куәтләү өчен, иң ышанычлы дәлил итеп, ике сүзнең берендә бабайлар әйтеп калдырган табышмакны, мәкальне, тапкыр сүзне искә төшерә.

Киләсе елда «Казан утлары»на тәкъдим ителәчәк яңа әсәремдә мин әнә шулайрак уйлаучы сай карашлы кешеләр белән бәхәскә керәм. «Үзе ярлы булса да күңеле бай» диләр бит. Мин бу әсәремдә революциянең беренче елларында яшәп, хәзер инде ветеран дигән хөрмәтле исем йөртүче бай күңелле, батыр йөрәкле, фидакарь җанлы шәхесләр хакында язам. Димәк, аларның дәртле яшьлек еллары, легендаларга әйләнерлек кайнар мәхәббәте, яңа тормышны аякка бастыру, менә хәзерге муллыкка, байлыкка нигез ташлары салу өчен көнен-төнен белмичә, җаннарын да аямыйча көрәшүләре хакында булачак ул әсәр.


Бу әсәремне язганда замандашым Әхмәт Ерикәй җыры гел исемдә булды. Ул онытылмас бер аһәң булып күңелем түрендә моңландырып торды:

*Яшьлегемә кире кайтыр идем,*
*Кире кайта торган юл булса...*

дигән иде ул. Әмма әдәби иҗат кешесенең бәхете шундадыр ки, аның өчен яшьлегенә кире кайту юлы бикләнмәгән. Әдип кеше әгәр бик теләсә, яшьлегенә кире кайтып, анда яңадан бер мәртәбә яшәп кала, әгәр таланты яисә сәләте җитәрлек икән, нәфис сүз ярдәмендә, әдәби образлар аша аны башкалар күңеленә дә тәэсир итәрлек дәрәҗәгә менгерә.

Мин хәзер нәкъ әнә шундый бер үк вакытта бәхетле һәм газаплы көннәр кичерәм.

# Уфада культурабыз истәлекләре



**«Госмания» мәдрәсәсе урнашкан бина**

Г. Тукай урамы, 39 нчы йорт.

*А. Тимергалина рәсеме.*

# «ГОСМАНИЯ» МӘДРӘСӘСЕ

«Галия», «Госмания», «Хакимия», «Хәсәния»... Уфадагы атаклы татар мәдрәсәләре. Октябрь революциясе алды елларында бу дүрт мәдрәсәдә генә дә алты йөзгә якын шәкерт белем алган. Алар арасында «Галия»дән кала иң мәшһүре — «Госмания». XIX йөзнең икенче яртысында ачылган бу мәдрәсә 1906 елда яңа бинага күчә (хәзерге Тукай урамы, 39 нчы йорт). Ул бинаны Уфаның зур байларыннан Госманов мәдрәсә өчен махсус рәвештә төзетә. Шуңа күрә аны «Госмания» дип атаганнар. 1916 елда мәдрәсәгә капиталь ремонт ясала. Бу чорда инде мәдрәсә заманча җиһазлана: ике кешелек парталар, мөгаллимнәр өчен кафедра эшләтелә, гомуми лекцияләр өчен махсус зал да булдырыла. Шәкертләргә торак өчен ике катлы агач йорт сатып алына.

Мәктәп-мәгариф өлкәсендәге яңалыклар «Госмания»не дә читләтеп үтмәгән, әлбәттә. Гасыр башында ук монда, ислам дине нигезләреннән тыш, дөньяви фәннәр дә укытыла башлый. Шәкертләр география, тарих, физика, математика, ботаника, химия, геометрия һәм алгебрадан, татар, гарәп, төрек, рус телләре һәм әдәбиятларыннан дәрес тыңлыйлар. Хокук фәннәре буенча да лекцияләр укыла. Мәдрәсәнең китапханәсенә керсәң дә шундый ук хәл: төрле фәннәрдән дәреслекләр, кулланмалар белән бергә татар, рус һәм дөнья әдәбияты классикларының әсәрләрен дә укырга мөмкин булган анда.

Октябрь революциясе алды елларында мәдрәсәдә үз заманы өчен абруйлы мөгаллимнәр коллективы туплана. Физикадан Г. Шнаси, математикадан Г. Хәбиров, ботаникадан Г. Фәхретдинов, гарәп теленнән Ә. Әсәдуллин, татар теле һәм әдәбиятыннан К. Кәриб һәм башка мөгаллимнәр дәрес бирә. Күренекле татар язучысы һәм галиме Риза Фәхретдинев тә берара мәдрәсәдә дәресләр алып барган.

1916 елда мәдрәсәнең уставы һәм программасы булдырыла. Анда башка татар мәдрәсәләрендә күренмәгән яңалыклар да карала. Мәсәлән, һәр елны мәдрәсәнең алты еллык курсын тәмам иткән шәкертләрдән сәләтлерәк 2-3 кешене яңадан мәдрәсәдә калдыру күздә тотылган. Бу шәкертләр мәдрәсә хозурында берәр фән белән ныклап шөгыльләнергә һәм белгечлек алырга, соңыннан сайлаган фәннәре буенча китап язып, аны аерым комиссия тарафыннан тикшертергә тиеш булганнар. Икенче төрле әйткәндә, алар зур мәдрәсәләрдә укыту хокукы алу өчен диссертация ысулы белән имтихан тапшырганнар. Заман таләпләренә ярашлы мондый яңалыкларның күбесе тормышка ашмаган.

«Госмания» шәкертләре әдәбият, сәнгать һәм музыка белән дә кызыксыналар. 1901 елның 27 гыйнварында ук шәкертләр үзләре язган дүрт пәрдәле бер пьеса буенча спектакль куялар. «Госмания» мәдрәсәсе шәкерте, соңыннан үзе дә берничә пьеса авторы булган Гыйлаҗ Гумирский театр белән кызыксынып китүе турында болай дип искә алган: «Бервакыт кичен мәдрәсәгә Мәҗит Гафури килеп утырды. Без, шәкертләр, гадәттәгечә, аны әйләндереп алдык. Сүз күбрәк театр, артистлар, театр китаплары турында барды. Ул безне шул чакта ук драматург булып танылган Галиәсгар Камал, талантлы татар артисты Габдулла Кариевларның иҗаты белән таныштырды. Мин аңа кадәр, яшеренеп кенә, «Сәйяр» труппасының бер-ике спектаклен караган идем. М. Гафури белән әңгәмәдән соң, ныклап артист булырга карар иттем. Мәдрәсәдә миңа фикердәш кешеләр дә табылды. Җыелып сөйләштек тә, Г. Камалның «Беренче театр»ы буенча репетиция ясый башладык. Төп рольне мин алдым. Тәүге спектакль бик уңышлы үтте. Безне дәртләндереп җибәрде».

Мәдрәсәдә спектакльләрдән тыш әдәби-музыкаль кичәләр дә үткәрелгән. 1916 елда узган бер бәйрәмдә мәдрәсәдә кызлар кыллы оркестры чыгыш ясый. «Госмания» шәкертләре шәһәрнең башка мәдрәсәләрендә уздырылган кичәләргә, театрларга да теләп йөргәннәр. Өлкән язучыбыз Риза ага Ишморат «Госмания»дә укыган вакытында «Галия» мәдрәсәсенә әдәби кичәгә баруын, анда бик яшьли фаҗигале төстә һәлак булган көрәшче шагыйрь Шамун Фидаи белән танышуын искә ала.

Октябрь революциясеннән соң да шактый вакыт эшләп килгән «Госмания» мәдрәсәсе соңыннан татар мәктәбе итеп үзгәртелә. Егерменче еллар башында аңа «Хөсәен Ямашев» исеме бирелә. Хәзер әлеге бинада педагогия институтының халык мәгарифе хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү факультеты урнашкан.

*Х. Гобәйдуллин һәм Җ. Миңнуллин тексты.*

# ТӘТЕШ

Халык телендә сакланып калган риваятьләргә караганда, шәһре Болгар тар-мар ителгәннән соң, аннан күчеп китүчеләрнең бер өлеше Тәтешне нигезлиләр. Риваятьтә хикәят ителгәнчә, аның исеме монда элек яшәгән Тәтеш исемле бабага мөнәсәбәтле рәвештә бирелгән. Шәһәрнең төньяк юнәлешендә, соңыннан руслар төзегән Троицкий дип аталган монастырь урынында әлеге бабаның йорты урнашкан булган. Чиркәү төзегәндә берничә зиннәтле каберлек табылган. Шул каберлекләрнең берсе өстенә куелган кабер ташында, П. Семенов язуына караганда, 1283 елда үлгән болгар кешесе турында мәгълүмат булган. Шулай ук бу урыннан акча хәзинәсе, төрле бизәнү әйберләре, җиз тәңкәле бил каешлары һәм башка матди культура ядкарьләре табылган. Археологик мәгълүматларга караганда, шәһәрлек җирлегендә (археологик әдәбиятта ул икенче Тәтеш шәһәрлеге дип атала) барлыгы өч культура катламы ачыкланган. Аларның өстә ята торганы, тирәнлеге 15 сантиметр булганы — рус катламы, барлыкка килү чоры — XVI—XX йөзләр. Икенче катламның калынлыгы шулай ук 15 сантиметрлар тирәсе, ул XIII-XIV йөзләргә, ягъни болгар чорларына карый. Бу катламнан әйбәт итеп яндырылган, балчыктан ясалган 118 савыт-саба калдыгы, Үзбәк хан чорына, ягъни 1330-1340 елларга мөнәсәбәтле акчалар, 4-5 сантиметр калынлыктагы кирпеч ватыклары, төтен үткәрә торган балчык торба калдыклары, тимер китмәннәр, балык тота торган кармаклар, сыер, сарык, балык сөякләре һәм башка әйберләр табылган. Өченче катламның калынлыгы 115 сантиметр чамасы. Бу катламдагы балчык төсе нәкъ болгар чорыныкы кебек, ләкин монда табылган матди культура калдыклары бортасларга мөнәсәбәтле итеп каралган. Әлеге төбәктә тагын X-XI йөзләргә мөнәсәбәтле энҗе бөртеге табылган. Шундый энҗе бөртекләре моннан тыш, археологик казынулар күрсәтүенчә, Идел суының уң ягында, хәзерге Мордва АССР җирләренә кадәр, ягъни элек бортаслар яшәгән урыннардагы каберлекләрдән дә табылган. Халыкта Бетле Тау дип йөртелә торган тау янында тагын бортасларга мөнәсәбәтле булган һәм фәндә беренче Тәтеш шәһәрлеге дип аталган шәһәрлек тә өйрәнелгән. Шунысы игътибарга лаек, археологик яктан тикшерелгән икенче Тәтеш шәһәрлегенең аскы катламын, ягъни башлангыч ноктасын X-XIII йөзләрдә яшәгән бортас авылы хәрабәләре тәшкил иткән. Анда XIII-XIV йөзләрдә болгар һәм бортаслар аралашып яшәгәннәр һәм бу авыл тора-бара болгар шәһәренә әверелгән. Күршедәге бортас шәһәрлеге, ягъни беренче Тәтеш, яшәүдән туктаган. Татарстанның Тау ягы һәм Кама аръягы районнарында бортас этнонимына мөнәсәбәтле авыл, күл һәм тау атамалары сакланып калуы археологлар карашын ныгыта. Болгарларга күрше булып яшәгән һәм төрки телдә сөйләшкән бортаслар да татар халкының формалашуында катнашканнар. Төрки мифологиядә һәм татар халкында да киң таралган легенда-риваятьләрдә Алып батырның бертуган улларыннан Болгар исемлесе Болгар шәһәрен, ә Бортас — Бортас шәһәрен нигезләве хәбәр ителә.

Шәһәрлекнең төньяк өлешендә табылган болгар чорына мөнәсәбәтле матди культура әйберләренең байтак булуына караганда, элек аның мәйданы шактый зур булган.

Тәтеш географик яктан бик уңай урынга, көнчыгыш яктан Иделгә килеп төшә торган биек текә калкулыкка утырган. Шәһәрнең көньяк һәм көнбатыш юнәлештәге кырыйларыннан зур чокыр үткән. Крепостьның көньягына таба сузылган биеклектә, күрәсең, шәһәр бистәсе урнашкан булгандыр.

Шәһәрдә сәүдә, һөнәрчелек, культура үскән. Гыйлем учаклары — мәдрәсәләр булган. Тирә-юньдәге җирләрдә халык иген иккән, елга-сулардан балык тоткан һәм башка һөнәрләр белән дә шөгыльләнгән.

Тәтеш бер феодаль үзәк булып, шул тирәдәге җирләр аның кул астына оешкан булса кирәк. Н. К. Калинин фикеренә караганда, болгар чорларында ук хәзерге Тәтеш урынында, Идел суының уң ягыннан шәһре Болгарга чыга торган турыда, каравыл посты итеп шәһәр торгызылган булырга мөмкин.

1552 елда Казан ханлыгы җирләре Рус дәүләте составына кертелгәннән соң, элек шәһәр булган нәкъ шушы урынга йомышлы кешеләр, нигездә руслар, китереп утыртыла. Хәзерге шәһәрнең оешуы XVI йөзнең икенче яртысына карый. Ул хәрби-административ характердагы ныгытма һәм колонизация үзәге буларак барлыкка килә (1892 елда, губерна статистика комитеты мәгълүматларына караганда, Тәтештә яшәгән 4729 кешенең бары 226 сы гына татарлар булган). Аны яңа нигезләгән русларның төп вазифасы җирле халыкны буйсындырып тору һәм рус дәүләте чикләрен саклау була. Шәһәр белән гаскәр башлыгы (воевода) җитәкчелек итә.

XVI йөзнең 70 нче елларында Тәтеш койма белән әйләндереп алынган кечкенә генә шәһәрчек рәвешен алган. Койма эчендә йомышлы халыкның аз санлы йортлары, воевода торагы һәм чиркәү урнашкан. XVII йөзнең 30-40 елларында Тәтеш шәһәренең мәйданы шактый зурая. 1638 елда, Иранга сәяхәткә баруы вакытында, Адам Олеарий 18 август көнне Идел өстеннән Тәтешне күрә һәм аның турында истәлекләрен калдыра. «Төш вакытында без Казаннан 120 чакрым ераклыкта тау өстенә һәм тау битенә урнашкан Тәтешне күрдек»,— дип яза һәм аның күренешен дә бирә. Олеарий тасвирлаган Тәтеш шәһәре күренеше безгә билгеле рәсемнәрнең иң борынгысы буларак әһәмияткә ия. Тәтешнең йортлары төрле урыннарга (тау башына, тау битенә, Идел яры буендагы тау астына) сибелеп утырган. Шәһәрнең тау башындагы ныгытмаларыннан башка тагын тау битеннән түбәнгә, Иделгә таба сузылып төшә торган бистәне әйләндереп алган агач диварлары һәм дүрткырлы манарасы булган. А. Олеарий язуына караганда, Тәтеш халкы балыкчылык белән шөгыльләнгән һәм ашлык белән сәүдә иткән, чөнки ул сәүдә өчен уңайлы зур елга — Идел ярына урнашкан.

XVII йөз урталарында Тәтеш хәрби әһәмиятен югалта. Аны 1648 елда төзелгән Сембер (хәзерге Ульяновск) шәһәре алыштыра. XVIII йөз башыннан Тәтеш яңадан оештырылган Казан губернасы составына керә. Пугачев восстаниесеннән соң патша хөкүмәте, Идел буенда үзенең йогынтысын көчәйтү максатыннан чыгып, башында генерал-губернатор торган Казан наместничествосы оештыра. Казан губернасы унөч өязгә бүленә һәм Тәтештә өяз шәһәрендә була торган дәүләт учреждениеләре ачыла.

Тәтеш шәһәренең XVIII йөз ахырына, XIX йөзнең беренче елларына (1804 елдан да соң түгел) караган планы мәгълүм. Аннан күренгәнчә, шәһәрдә таштан салынган чиркәү, тоз амбарлары, кабаклар, ипи кибете, базар урыннары, тимерче алачыклары, дәүләт учреждениеләре, зират һәм башка урыннар бар. Шәһәр төньяктан көньякка таба сузылган. Кечерәк чокырлар белән ул зурлыгы ягыннан тигез булмаган өч кисәккә бүленә. Төньяктагы кечкенә өлеше түгәрәк формасын алып тора. Урта кисәктән ул параллель рәвештә урнашкан ике кечерәк чокыр белән аерыла. Шәһәрнең иң зур урта өлеше көньякта урнашкан өченче кисәгеннән шулай ук чокырлар белән бүленгән.

Тәтеш катлаулы үсеш юлы узган. Башта ул борынгы авыл, аннан соң болгар шәһәре, вакытлар үткәч, Рус дәүләтенең чиген саклаучы һәм өяз шәһәре буларак үсеш алган.

Хәзерге вакытта Татарстанның бер район үзәге булган Тәтеш үсеп килә торган шәһәрләрнең берсе. Янында пристань дә бар. Тәтеш районы авылларының җирләре кара туфраклы һәм уңдырышлы. Республикабыз экономикасын үстерүдә Тәтеш районы хезмәт ияләре дә үзләреннән лаеклы өлеш кертергә омтылалар.

**Фирдәүс ГАРИПОВА,**
филология фәннәре кандидаты

## УКУЧЫ СҮЗЕ

«Иртеш таңнары» романын («Казан утлары» №№ 1, 2, 3. 1988 ел) тирән ләззәт белән укыдым. Әсәрнең дөнья күрүе Себер татарлары тормышында зур вакыйга булды.

Роман геройлары аша якташларым — туган авылым Саускан кешеләренең язмышлары белән очраштым: аларның көнкүреше, тарихы, төрле йолалары безнең күңелгә бик якын. Инде романның икенче кисәген түземсезлек белән көтәбез.

**Тукай Сөечев.** *Төмән өлкәсе, Тобол районы.*

Безнең авылда «Казан утлары» кулдан-кулга йөри. «Иртеш таңнары»н һәркем зур кызыксыну белән укый. Хәтта Кави бабай да чират көтә. Аңа 78 яшь. Авылда укучылар конференциясен уздырырга җыенабыз.

**Газиз Әхмәтов, Шакирҗан Ибраһимов.**
*Төмән өлкәсе, Кукрәнде авылы.*

Мөхәммәт Уразаев образы аерым бер җылылык белән бирелгән. Сәрвәрне, Шамилне, Мәүлияне, Йомабикәне җәлләп күземнән яшь килде. Әсәр тормышның төрле яклары эченә алган. Һәммәсе дә ышандыра, шатландыра, көйдерә. Романның дәвамын көтәм.

**Миңнура Камалова.**
*Башкортстан АССР, Нефтекамск шәһәре.*

Үзебезнең Себер халкы тормышы яктыртылганга күрә күңелебезгә бик якындыр, мөгаен. Гаять зур кызыксыну белән укыдык. Әйтемнәре, җырлары да безнең якныкы. «Иртеш таңнары»н иң яхшы әсәрләр белән янәшә куярга була. Роман басылган журналыбызны укый-укый теткәләп бетерделәр. Барнаул шәһәрендә яшәүче туганнарыбыз үтенеп сораганлыктан аларга озаттык. Әсәрне эшкәртүче һәм бастырып чыгаручы редакция хезмәткәрләренә бик зур рәхмәт!

**Зиннур, Зафирә Бекшеневлар.**
*Тобол шәһәре.*

Якуб Зәнкиевнең «Иртеш таңнары» романын укыгач, артык хисләнүдәнме, әллә әсәрнең авторы өчен куанычтанмы — «Казан утлары» журналы редакциясенә хат язмыйча булдыра алмадым.

Мин үзем утыз сигез ел мәктәп директоры булып эшләдем. Туган телне саклап калу юнәлешендә капма-каршы фикерле кешеләр белән көрәшеп яшәдем. Шул телгә тел тидерүчеләр, аны тырнаучылар шактый очрады. Шөкер, менә демократия, үзгәреш чоры бу өлкәдә ниндидер өметләр уятты. Бу уңайдан шуны әйтәсем килә: моннан ике-өч дистә еллар элегрәк, мәктәпләрдә бу телне укытмасак та ярар, яки башка фәннәр арасында аның әһәмияте шул кадәрле генә диеп кимсетеп караучылар булды. Хәтта дәрес расписаниеләрен төзегәндә рус телен ана теле, ана телен татар теле дип язылганнары да очрады.

Туган телебезнең матурлыгын, ягымлы-йомшаклыгын, күңелләрне тетрәндерерлек көчлелеген шул роман расламыймыни инде?!

Соңгы ике-өч дистә елларда, татарлар татарлыгыннан качып, үз телендә сөйләшүне гарьлеккә санаучылар артты. Бу турыда уйласам, минем җаным өши. Никадәрле гарип кешеләр — үз теленең тәмен-ямен белмәүче туң күчәннәр артты.

Без үзебез менә инде утыз сигез ел «Казан утлары»н алабыз. Һәр номеры безнең өйгә үзе бер бәйрәм булып керә.

Быелгы саннары тагын да кадерле, алар әлеге роман белән башланды бит.

Безнең бурыч, булдыра алганча, әсәрне халык арасында киңрәк тарату. Әсәр буенча китап укучылар конференциясе үткәрергә җыенабыз.

**Х. Хәбибуллин.**
*Түбән өлкәсе, Акъяр авылы.*

Хөрмәтле «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре!

Ерак Сахалиннан сезгә сәламнәр һәм изге теләкләр юллыйбыз. Сезнең журналда шәхес культы елларында һәлак ителгән кешеләр тормышын сурәтләгән роман басылды («Тайгак кичү», «Казан утлары» № 4, 5, 6, 1988 ел). Бу әсәрдә минем иремнең әтисе — Рияз Йосыф улы Алкин турында шактый күп язылган. Иремнең үз әтисе турында күбрәк беләсе килә. Ул әтисе кулга алынгач, 1938 елда туган. Әтисен күреп белми.

Алкиннарның өч балалары булган. Олы кызлары Резеда Казанда яши, пенсиядә. Икенче уллары Разит Татарстанның Балтач районында физика-математика укыта. Ирем Роберт — хәрби кеше. Әниебез (минем каенанам) Хәтирә Хөсәеновна исән-сау. Аңа хәзер 82 яшь.

Сезгә рәхмәт хисләре белән,

**Е. И. Алкина.**
*Көньяк-Сахалинск шәһәре.*

И. Салаховның «Тайгак кичү» романын тетрәнеп укыйбыз. Без, утызынчы елларда туган кешеләр, бик күпләрнең бер гаепсезгә һәлак ителгәнлекләрен ишетеп, белеп үстек. Ләкин бу кадәр дә җәзалау, кырылыш булган дип уйламый идек әле.

Мине бер нәрсә борчый: кайда соң ул гаепсез кешеләрне җәзалаучылар, кыйнап, этләрдән талатып үтерүчеләр? Алар персональ пенсия алып, иң затлы квартираларда яшәп ятмыйлармы икән? Болар да үз җәзасын алсыннар иде. Шунсыз җаным тынычланмаячак. Бу хатымны елый-елый язам.

**Нәзирә Галимова,** пенсионерка.
*Чаллы шәһәре.*

Безнең гаилә «Казан утлары» журналын күптәннән яратып укый. Әниебез аны гомер буе укыды. Соңгы елларда язучыларыбыз көнүзәк темаларны күтәрәләр. Һәр әсәрне ахыргача укып чыгасың. И. Салаховның «Тайгак кичү» романын заман рухына туры килгән, кешеләр көткән әсәр дип әйтер идем. Аны авыл халкы бик тиз укып чыгып, үзара фикер алышырга да өлгерде. Безгә бигрәк тә кадерле булды бу әсәр. Анда әтиебез Алкин Рияз турында язылган. Бу турыда әниебез елый-елый укыды. Ул бүгенге көндә Казанда тора. Әнине эти белән күрештермәгәннәр. Суд та булмаган. Әтинең шуннан соңгы язмышы безгә төгәл билгеле түгел иде.

**Разит Алкин, укытучы.**
*ТАССР, Балтач районы, Чутай авылы.*

Батулланың «Юл өстендә зәңгәр чәчәк» әсәре («Казан утлары» № 4, 5, 1988 ел) күңелгә кереп калды. Үзем дә сугыш алдыннан туган кеше. Әсәрдә барысы да дөрес сурәтләнгән дисәм килә. Бала чакларны искә төшергән бу әсәрне укыганда күңел тула. Ач вакытлар, күргән михнәтләр, халык өчен авыр чаклар... Ятим балаларына бер уч арыш алган өчен ун елга төрмәгә ябылган кешеләрне дә беләм.

Яшьләр өчен гыйбрәтле әсәр язган язучыга рәхмәтләремне юллыйм.

**Хәкимулла Базыров.**
*Түбән шәһәре.*

«Юл буенда зәңгәр чәчәк» повестын яратып укыдым. Хатын-кызлар язмышын уйландырырлык итеп язган. Укый-укый бер нәрсәгә ачык төшенәсең: кеше кылган һәр явызлыкның сәбәбе бар икән бит. Ул сәбәпләрнең серенә төшенү өчен тормышны гына күзәтергә кирәк. Аларны булдырмый калу яки алдан кисәтү өчен без күп нәрсәләр эшли алабыз. Әйдәгез, яшәвебез мәгънәлерәк булсын.

**Габделхак Фатыйхов.**
*Удмуртия АССР, Воткинск шәһәре.*

Журналны кулга алу белән иң элек аның тиражы күпме икән дип карыйм. Аз-азлап булса да арта тора. Ана телебезнең көч-куәтен саклый, яклый алсак, тагын артачак бит.

Безнең гаилә М. Хәсәновның «Язгы аҗаган», Я. Занкиевнең «Иртеш таңнары» романнарын бик җентекләп укып чыкты. Туган телнең көч-куәте әнә шундый әсәрләрдә күренә инде.

Ф. Латыйповның «Татарстан читекләре» дигән очеркын укып куандык та, хафаландык та. Читекләрне матур итеп, сыйфатлы һәм мул итеп эшләп чыгаруга каршы корылган киртәләрне (алар әле бар икән) җимерәсе иде. Безнең Оренбург якларында, Казан читеге киясе иде, дип өметләнеп яшәүче хатын-кызлар аз түгел.

**Т. Әбдрәшитов.**
*Оренбург шәһәре.*

Безгә дә ата-бабаларыбыздан калган архитектура истәлекләрен реставрацияләү өчен аерым фонд булдырып, счет ачарга кирәк. Борынгы Болгар истәлекләренә «җан өреп», кеше күзенә күрсәтерлек итсәң, яки Казанда булган борынгы биналарны реставрацияләсәң, начар булмас иде. Казанда булып кайткан кешеләр бу мәсьәләдә башкалабызны бик мактамыйлар. Халкыбызның йөз аклыгы булыр дәрәҗәдә аны матурлыйсы иде. Рухи байлыкларыбызны барлап, яшьләрне шулар җирлегендә тәрбияләү бурычы безнең өстә тора. Юкса, алар таралган, сибелгән, кайберләре югалган һәм югалып баралар. Бу минем генә уйларым түгел. Гади балта остасының гамьле уйлары сезгә дә ят түгелдер шәт. Журнал әнә шул мәсьәләләрне дә күтәреп чыксын. Бик вакыт инде.

**Хәбир Габдуллин.**
*Оренбург өлкәсе, Октябрь авылы.*

«Казан утлары» журналының быелгы 3 нче санында Клара Булатованың «Югалтмаска!» исемле шигыре басылды. Шифалы шигырь ул: йомылган күзләрне ача, йокыга талган күңелне, фикерләрне уята. Мең рәхмәт ул шагыйрәгә! Халкыбызның шундый талантлы хатын-кызлары булуы куандыра. Шигырь үзгәртеп коруның чынлап та революцион булуын ачып бирә. Бу илаһи дулкыннан шагыйрә үзенә илһам алсын, иҗат уңышлары ишәйсен.

**Ф. Сәйфуллин,** медицина фәннәре докторы
*Ташкент шәһәре.*

Хөрмәтле вә кыйммәтле туганнарым!

Мин олы яшьтәге кеше инде. Журналыгызны укып барам, анда басылган әсәрләр белән рухланып үзем дә шигырьләр язам.

Биредә үзешчән сәнгать түгәрәге оештырдым. Эшне алып бару шактый авырга туры килә. Милләттәшләрнең күбесе үз телебезне белми яки начар белә. Татарча тапшыруларны Мәскәү күрсәтсә генә карый алабыз. Торгынлык елларында «эше хәләл, үзе хәрәм» диебрәк карамаган булсалар, бәлки безнең шәһәрдә дә татарча ансамбльләр оешыр, үзешчән сәнгать түгәрәкләре барлыкка килер иде. Эшче кешенең тормышы белән бергә күңеле, рухи дөньясы да матурланырга тиеш. Шунсыз үзгәреп, яхшырып булмас.

**Халидә Хөснетдинова.**
*Үзбәкстан ССР, Әндиҗан шәһәре.*

Халкыбыз кайларда гына яшәми. Алар арасында хезмәт батырлары, чын хезмәт кешеләре исәпсез-хисапсыз.

Магнитогорск мартеннарына, Чиләбе трактор заводына, Донбасс һәм Кузбасс шахталарына нигез салуда халкыбыз уллары зур тырышлык куйган. Хәзер дә алар төп хезмәт кешеләреннән санала. Нигә менә шул кешеләр янына язучылар, шагыйрьләр, артистлар онытканда бер генә килеп китәләр. Нигә алар турында әдәби әсәрләр язылмый. Әдәбият-сәнгать, алар хезмәте бергә кушылса, халкыбыз горурлыгы булырлык әсәрләр туар иде.

**Хәмит Дияров.**
*Чиләбе шәһәре.*

«Казан утлары»н көтеп алам. Анда басылган әсәрләрне укыгач, үземне Татарстанда, туган авылымда итеп хис итәм. Марсель Зариповның журналның 2 санында басылган «Тагын карабодай турында» дигән очеркын укып чыккач, тирән уйларга баттым, җаным кузгалды. Авылда яшәгән кеше белә: ничәмә-ничә еллар карабодайны санга сукмыйча яшибез, шулай итә-итә карабодай эзләп таба алмый торган малга әйләнде. Хәзер кайбер яшьләр аның исемен дә, нәрсә икәнен дә белмиләр. Халык хөрмәт иткән бу кыйммәтле ашлык менә шушы хәлдә калды.

Марсель Зариповка зур рәхмәт. Ул шундый аңлаешлы итеп, исбат итеп карабодайның кыйммәтен күрсәтеп бирә. Карабодайны күбрәк игүнең файдасы турында ышандырырлык итеп сөйли. Марсель Зарипов өндәвенә игенчеләр гамьсезлек күрсәтмәстер.

**Кашшаф Юнысов.**
*Таҗикстан ССР, Кайраккум шәһәре.*

Журналда «Татарстан — туган төбәгем» рубрикасын ачу — редакциянең бик акыллы, кирәкле эше булды.

«Зөя буе йолдызлары» дигән мәкаләне кат-кат укыдым. Мин үзем бу төбәктән булмасам да озак елларга сузылган хезмәтем, гаилә тормышым буенча ул яклар миңа бик таныш, бик якын. Татарстан районнарында, күп кенә авылларда булырга, төрле кешеләргә, катлаулы вакыйгаларга очрарга туры килде. Әмма Зөя буеның табигать матурлыгы, кешеләрдәге әдәп-гадәтләрнең матурлыгы, тормыш- көнкүрешләрендәге пөхтәлек, чисталык, эшлеклелек миндә гомер буена якты эзләр калдырды.

Мәкаләдәге һәрбер кеше зур шәхес, иҗтимагый һәм политик тормышта җуелмас эз калдырган кешеләр. Мисал өчен революционер Вәли Шәфигуллин яки галим Җамал Вәлидине генә алсак та, алар фәнни һәм тарихи өйрәнүне көтеп яткан гаять зур шәхесләр.

Кайбер теләкләремне дә әйтәсем килә.

Халык артисткасы Галия Кайбицкая — йолдыз. Бик дөрес. Аның агасы җырчы һәм мәгърифәтче Камил Мотыйгый да йолдызлар арасында урын алырга хаклы кеше. Кара көннәрдә күп кыйналды. Гаделсезлеккә түзә алмады, 1941 елда үз-үзенә кул салды.

Йолдызларны тәрбияләгән укытучылар, партия әшлекләләре дә бар бит әле. З. Рәмиев, М. Гайнуллин, Я. Насибуллин һ. б. Башта укытучы, аннан 25 ел буена партия эшлеклесе булып танылган Фатих Адаматов та бу очеркта урын алырга тиеш иде. Шушы кадәр бай материалны район үзәгендә музей итеп формалаштыру турында уйларга кирәк.

**Җамал Вәзиева,** хезмәт ветераны.
*Казан шәһәре.*

Журналның быелгы 3 нче санында Сәгыйть Хафизовның «Үзеңне тап, шагыйрь!» дигән мәкаләсен укыгач, үземнең фикеремне язарга булдым.

Автор Р. Миңнуллинның Сөн елгасын үзенеке итүен, Башкортстандагы бу инешкә Мамадыш егете З. Мансуров та барып чума дип, авторны иҗат этикасын бозуда гаепли, аңа үз инешен табарга киңәш итә.

Бу уңайдан мин шуны әйтер идем: Сөн елгасы Башкортстанның Бакалы районыннан башланып, Татарстанның Актаныш районы Чуракай авылы аша Татарстан

җиреннән ага. Минем үземнең бу елгада (ул инеш кенә түгел) су коенганым бар. Аның өчен Башкортстанга баруның кирәге юк.

Татарстанның Мамадыш районында Югары Сөн, Кече Сөн, Түбән Сөн дигән авыллар бар. Бу авылларның исеме үзләре урнашкан шул исемдәге елгачыклар белән дә бәйле. Сәгыйть Хафизов үзенең мәкаләсендәге ялгыш сүзне төзәтсен иде.

**Габделхак Хафизов.**
*Азнакай районы.*

Журналны мин хәреф таный башлаганнан бирле укып үстем. Аның әле «Совет әдәбияты» исемендә бик ябык-нәзек чагы, кытыршы кәгазьгә басылып чыккан еллары бар иде. Шул еллардагы бер истәлекне һич онытa алмыйм.

Күрше малае Фәсихулла, минем кебек үк ата-анасыз үсүче ташбаш, кайдадыр казынып йөреп, кылыч табып алган. Кылыч тимгел-тимгел яшелләнеп күгәргән инде. Безнең Алпар авылы аша гражданнар сугышы елларында ак чехлар да, кызыллар да узган. Кылыч шулардан калган булырга тиеш, диде безгә Югары оч карты Мәталли бабай.

Ул кылычны без Чирмешән буена алып төшеп, ком белән ышкый-ышкый ялтыраганчы чистарттык. Шул кылычны әбиләр тегеп биргән киндер ыштан бөрмәсенә, күрше белән алмаш-тилмәш тагып, бөтен авылны әйләнеп чыгабыз. Малайларның күзләре кыза! Бигрәк тә укытучы Заһитов абый малае Роберт безгә чат ябышты. «Миңа бирегез дә, бирегез» дип арттан калмый.

— Сездә китаплар күп. Китаплар китерсәң, бирербез,— дибез тегеңәр.

— Күпме китерим соң?— ди теге.

Күршем Фәсихулла җиңе белән борын астын ышкый-сөртә бераз нәрсәдер исәпләп-чутлап торды да:

— Ун «Совет әдәбияты» китерсәң, кылычны бирәбез,— диде. Роберт бик тә риза булып өенә чапты. Көтәбез. Килми дә килми теге. Караңгы төште. Бермәлне, килеп керде бу безнең ызба алдына. Безнең әзли. Куены тулы — китап! Сигез данә «Совет әдәбияты» журналын алып килгән бу.

Сатулашып тормадык инде — бирдек кылычны. И шул ук кичне, ай яктысында ук, тотындык журналларны укырга. Рәхәте, шатлыгы — ат биргесез! Дөньяда тиңе булмаган хәзинәбез бар сыман тоябыз үзебезне малайлар арасында.

Аннары инде ул журнал безнең избачка килә башлады. Без аны дүрт күз белән көтеп алабыз.

Миңа биш-алты ел Себер, Кемерово якларында яшәргә туры килде. Мин анда да якташлардан журналны эзләп таба идем. Кави Нәҗминең «Язгы җилләр», Гомәр Бәшировның «Намус» романы, Габдрахман Әпсәләмовның сугыш хәлләрен язган хикәяләре, повестьлары, романнары, Шәрәф Мөдәррис шигырьләре минем күңелгә әнә шул чактан ук сеңеп калды.

Хәзер инде «Казан утлары»ның һәр санын диярлек укып барам. Миннән соң малай укый, аннары — кече кыз.

Журналга теләкләрем дә бар. Нигә безнең атаклы елгалар, күлләр, төрле исемдәге чишмәләр, аланнар, болыннар, таулар, үрләр турында ешрак, матуррак итеп, җанга ятышлы итеп язмаска? Һаман да гражданнар сугышы, Ватан сугышы турында укыйсы килә. Узган сугышта да татарның зур-зур командирлары булган бит. Алар турында күбрәк беләсе килә.

Журналның «Елмаеп та, көлеп тә» дигән битләре бик сирәк күренә. Минемчә, усал да түгел ул. Әллә кемнәрне тәрҗемә итеп маташалар. Үзебезнеке, татарныкы әз чыга. Мине, әнә, кайбер татар егетләренең эштә адәм рәтле эшләмичә, азып-тузып йөрүләре, бай хатыннар әзләүләре, шәфкатьсез сугышулары бик борчый. Нигә шундыйларны журнал аша да ныграк пешермәскә? Яки өлкәннәр теле белән аларга үгет-нәсихәт, гыйбрәт бирмәскә?

Журналның мәртәбәле булуы — безгә дә сөенеч. Дусыңның шатлыгы, синең дә — куанычың, диләр бит. Ихлас күңелдән уңышлар телим мин журналга.

**Фәргать Шакиров.**
*Чаллы шәһәре.*

## Безне дә онытмагыз!

Мин журналны күптән укып киләм, чөнки әти-әниләрем үк татар һәм башкорт телләрендә газета-журналлар алдыралар иде.

Безнең Чиләбедә татар китапханәсе дә бар, әмма анда укучылар саны елның елында кими бара. 350 меңнән артык татар һәм башкорт яшәгән өлкәдә милли тел укытыла торган мәктәпләр бармак белән санарлык кына булгач, ул укучылар каян килсен инде...

Этнография, тел, культура турындагы материалларны канәгатьлек белән укып барам. Бигрәк тә татар халкының килеп чыгуына кагылышлы материаллар кызыклы. халыкның (Казан татарларының гына дип әйтмим) тормыш-көнкүреше, теле, культурасы да кызыксындыра.

Журналның һәр санында диярлек партия райкомнарының беренче секретарьларына сүз бирелү куанычлы күренеш. Минем уемча, Татарстаннан еракта яшәгән укучылар республиканың байтак районнары турында инде бай мәгълүмат алгандыр. Чыннан да, бу рубриканы укыганда гүя Татарстанның төрле төбәкләре буйлап сәяхәт итәсең. Ә иң мөһиме, бу мәкаләләрнең тәрбияви әһәмияте дә бар: алар туган якка, үз халкыңа мәхәббәт тәрбияли. Зур рәхмәт сезгә моның өчен!

Ләкин бит илнең башка регионнарында яшәүче татарлар турындагы язмаларны Татарстан һәм Башкортстан кешеләре — «Казан утлары»ның төп укучылары да яратып укыйдыр. «Казан утлары»ның яктысы үз ягында яшәүчеләр өчен генә булырга тиеш дип уйламыйм мин.

Чыннан да, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләремнең иҗтимагый-политик тормышын күз уңында тотучы башка матбугат үзәге юк бит. Бу җәһәттән, Пенза өлкәсенең Әләзән авылы Волгоград ягындагы һәм Финляндиядә яшәүче татарлар турындагы язмаларны иң кызыклылары дип саныйм. Себердәге һәм Мещера ягындагы телдәш һәм кандаш туганнарыбызның ничек көн итүе, Әстерхан һәм Ставрополь татарларының ничек яшәве турында укыр идек. Кытай һәм Румыниядәге, Польша һәм Болгариядәге генә түгел, Тамбов өлкәсендәге татарлар да игътибардан читтә кала бит. Шундый материаллар күбрәк басылсын иде.

Мин ел саен диярлек Үзбәкстандагы туганнарыма барам. Менә кайтуым гына әле. Минем белән бер купеда Пермьнән бер ир белән хатын барды. Милләтләре татар. Безнең халыкның шул бит, кем, кайдан дип сөйләшү китте. Гаҗәпләнүемә каршы дип әйтимме, кызганыч димме, әңгәмәдәшләрем Курган өлкәсендә буын-буыннан татарлар һәм башкортлар яшәвен белми икән. Чыннан да, әйтик, Красноярск краенда яки Иркутск өлкәсендә яшәүче татарлар турында без нәрсә беләбез соң? Берни дә! Бәлки «Казан утлары» битләрендә шундый мәкаләләр бирергә кирәктер? Бәлки, иң яхшысы, союз күләмендәге яңа журнал булдырыргадыр? Ул «Казан утлары» яки «Агыйдел»гә көндәш түгел, ә өстәмә булсын ди. Чыннан да, «башка» татарлар кайдадыр яши, эшли, ач-ялангач түгел икән, тагын нәрсә кирәк, дип карарга күнегелгән. Еламыйлар бит, ә еламаган балага ими бирмиләр...

Менә күптән түгел генә Курган өлкәсендәге Сафакүл районында чыга торган «Трудовая слава» газетасын укыдым. Анда газетаның үз хәбәрчесе Мәүләвиловның, минем уемча, кызык кына мәкаләсе бар. Автор район халкының 80 процентган күбрәген тәшкил иткән татар-башкорт халкының рухи өлкәдәге проблемалары турында яза. Һәр юлы йөрәк әрнеп язылган. Районда 4 кенә мәктәптә милли тел укыталар. Балалар туган телне генә түгел, рус телен дә начар беләләр. Җыр-биюләр онытылган (сеңелем яши торган Учалы районында уеннарыбызны күреп сөенәм әле). Җирле радиодан татарча сүз бик сирәк яңгырый. Кыскасы, проблемалар бик күп.

Гафу итегез, сезгә дә зур үпкәм бар. Кырым татарларының «Ленин байрагы» газетасын үрнәк итеп куясым килә. Анда «Без СССРда яшибез» дигән рубрикада илнең төрле якларындагы милләттәшләре турында язып торалар. Ә алар кая гына таралмаган. Яшәгән һәр өлкәләрендә диярлек тапшырулар алып барыла, балаларын туган телгә өйрәтәләр. Үз телләренә, культураларына ничек сак карыйлар алар! Чыннан да, бу патриотизм. Ә бездә ничек? Татар теле укытучысының балаларны туган тел дәресенә йөртү өчен нинди «педагогик» алымнар куллануын Чаллыда эшләгән вакытымнан хәтерлим әле. Балалар үз телләрен өйрәнергә теләми. Бу бит әле Татарстанның үзендә. Ә инде халкыбызның башка төбәкләрдәге төркемнәре, бөтен милли-рухи тормышларыннан мәхрүм ителеп, алмашка берни дә алмаган кешеләр турында нәрсә әйтәсең!

Чиләбедә яшәүчеләр «бәхетлерәк» әле: үз китапханәләре бар, өч үзешчән сәнгать коллективы эшли, ара-тирә Уфа һәм Казан тапшыруларын карыйбыз, «тере» артист-

ларны күрәбез. Төмән өлкәсендәге Аромашево яки Курган өлкәсендәге Сафакүл районы татарларына бу да тәтеми бит. Тик безгә дә болар гына җитми, канәгатьләндерми.

Менә нәрсә борчый һәм хәтта гаҗәпләндерә. Без Алма-Атадан тапшыруларны рәхәтләнеп тыңлый алабыз, ә Казан яки Уфа белән хәл бөтенләй башка. Юньләп ишетелми. Омск һәм Иркутск өлкәләрендәге татарлар гомумән берни ишетә алмыйлар. Казах Алтайдан Иделгә, Алай тауларыннан Төмәнгә кадәр туган телендәге тапшыруларны тыңлый. Татарга исә бу юк! Мәскәү яки Казаннан бөтен илгә ишетелерлек итеп тапшырулар алып барырга әллә кайчан вакыт инде. Немецлар тыңлый бит!

Шушы елның 19 январенда Мәскәү радиосыннан «Ярты төннән соң» дигән музыкаль тапшыру яңгырады. Җырларның исемнәре әйтелмәде. Халык җырларын менә дигән итеп башкаручы Габдулла абый Рәхимкулов баянга кушылып бер җыр җырлады. Һәм мин радиодан бу җырның исемен сорап белмәкче булдым. Тик әле дә җавап юк. Казанга да язып караган идем, юк белән баш катыру дип карадылар, ахрысы.

Үз телен белмәгән, укырга-язарга өйрәнмәгән, җырларыбызны тыңларга яратмаган бөтен-бөтен буыннар үсте, борын-борыннан килгән милли җырлы-биюле уеннарыбыз онытылып бара. Алар Татарстанның үзендә дә онытылды бугай инде. Күпме югалттык, кулдан ычкындырдык, әрәм иттек. Киләчәк буыннар моны гафу итмәсләрдер.

Т. С. Мальцевка рәхмәт! Курган телевидениесе аша ул чыгыш ясаганнан соң эти-әниләрем туып-үскән Сафакүл районында (4 мәктәптә генә!) туган тел укыта башладылар.

КПСС Үзәк Комитетының милли мәсьәләгә багышлап үткәреләчәк Пленумы кайбер проблемаларны хәл итәр дип ышанасы килә.

Мин ни өчендер сезнең журналга, аның укучыларына, авторларына зур өмет баглыйм. «Казан утлары» бу өлкәдә башлап йөрер дип уйлыйм.

Ә теләкләр шундый: татар халкы яшәгән һәр төбәктә туган телдәге тапшыруларны тыңлау мөмкинлеге булсын, китаплар һәм пластинкалар сатылсын, җыелып яшәгән урыннарда үз телеңне укытсыннар һ. б.

Сезнең журнал — үзәктә. Артык хисләнеп киткән булсам, гафу итәрсез, дип уйлыйм. Бөтен гарәп илләре өчен Мисыр ничек булса, безгә дә Татарстан шулай баш мие һәм йөрәк кебек.

Башта ук гафу үтенәм: бу хатымны бастырып чыгарыр өчен дип язмадым. Ул бигрәк тә йөрәк әрнүенең бер авазы кебек. Туган телемдә яза алмавым бик кызганыч. Тукай: «Күп яттык без мәдрәсәдә, аңламадык бер нәрсә дә».— диган, безгә мәдрәсәсе дә эләкмәде шул.

Әти-әниләремә рәхмәт, гәрчә руслар арасында үссәк тә, гаиләдә телне кадерсезләмәгәннәр.

Язучыларыбыз КПСС Үзәк Комитеты Пленумына ничек хәзерләнә, Татарстан вәкилләре анда нинди тәкъдимнәр белән бара, журнал бу юнәлештә нәрсәләр эшли ала — менә шул хакта беләсе килә.

**Фатыйх Шәфиков.**
*Чиләбе шәһәре.*



# Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку-язу

## Икенче дәрес

Узган санда журнал укучыларга гарәп хәрефләренә нигезләнгән иске татар әлифбасы тәкъдим ителгән иде. Күренә ки, иске татар язуы белән хәзерге графика арасында бик зур аерма бар. Болар: күп хәрефлелек, вариантлылык һәм күп авазлылык. Бу хәл, үз чиратында, укырга-язарга өйрәнү процессында зур кыенлыклар тудыра, өйрәнүчедән түземлелек һәм тырышлык таләп итә. Иске татар язуы уңнан сулга таба языла һәм шул тәртиптә укыла. Китап-журналларны уку тәртибе дә башкача, ягъни хәзерге уку-язу системасына күнеккән кеше күзлегеннән караганда, китап яки журнал «кире яктан, соңгы битләреннән» укыла башлый, димәк, текстлар да шул тәртиптә языла. Иске язуыбызның бик күп үзенчәлекләре бар. Бу дәрестә сүз хәреф нигезләре турында барыр. Беренче дәрестә тәкъдим ителгән алфавиттан күренгәнчә, иске татар язуында хәрефләр өч-дүрт төрле рәвештә языла: аерым, сүз башында, уртада һәм ахырда. Мондый төрлелекнең нигезендә иске татар язуының басмадан да бигрәк кулъязма өчен ныграк җайлаштырылуы ята. Бу хәл иске язуны өйрәнгәндә, бигрәк тә башлангыч чорда зур кыенлыклар тудыра. Шуның өстенә бу язу системасында баш һәм юл хәрефләре дигән төшенчә дә юк. Гарәп хәрефләрен график-фонетик алым белән үзләштерү уңай нәтиҗәләр бирә. Бу дәрестә бирелгән таблица (ул профессор Миркасыйм Госманов тарафыннан эшләнгән) әнә шул алым нигезендә төзелгән. Таблицада хәрефләр төп өлешләренең (нигезләренең) язылыш охшашлыгы буенча төркемләнгән. Аларны шартлыча «хәреф нигезләре» дип атарга мөмкин. Әмма таблицада хәреф нигезләренең исемнәре традиция буенча «шәкел» дип бирелде: би-шәкел, нун-шәкел һ. б. Алга таба да хәреф нигезләрен атау өчен шушы гыйбарә кулланылачак. Шулай итеп, иске татар язуында барлыгы 18 хәреф шәкеле кулланыла. Хәрефләрне тизрәк истә калдыру өчен иң беренче чиратта әнә шул хәреф шәкелләрен игътибар белән өйрәнергә кирәк. Мәсәлән, таблицада тәртип буенча икенче позициядә торучы би-шәкелне алып карыйк. Бу шәкел иске татар алфавитындагы дүрт хәрефне «ясауда» катнашкан: б — ب , т — ت , с (сь) — ث , п — پ . Ә хәзер тәртип буенча уңдүртенче позициядә торучы кәф-шәкелгә игътибар итик. Классик гарәп алфавитында нечкә к авазын белдерүче ک хәрефе нигезендә иске татар язуында, гарәп телендә булмаган авазларны белдерер өчен, ике яңа хәреф барлыкка килгән: нечкә г — گ һәм ң — ڭ ، ڭ .

График-фонетик алымга нигезләнеп төзелгән бу таблица иске язуыбыздагы хәреф шәкеленең өстенә һәм астына куела торган нокталарның язудагы мөһим вазифасын тагын да ачыграк итеп күрсәтергә ярдәм итә. Иске алфавиттагы күп кенә хәрефләр бер-берсеннән нокталарның кайда куелуы белән аерылалар. Шуңа күрә нокталарның иске язуыбызда өстәмә билге — галәмәт кенә түгел, ә бәлки хәрефнең төп элементларын тәшкил итүен онытмаска кирәк. Тәкъдим ителгән таблицаның «Асыл гарәп алфавитында» дип аталган графасында хәрефләрне бер-берсеннән аеру өчен өтер куелды. Иске татар язуында өтерне, сызык асты хәрефләре белән бутамау өчен, өскә каратып куйганнар.

Мәгълүм ки, яңа алфавитны үзләштергәндә укырга гына түгел, бәлки дөрес язарга да өйрәнергә кирәк, ягъни уку-язу эшләре бер үк вакытта алып барылырга тиеш. Иске татар язуында хәрефләрнең язылышы, аларның үзара кушылуы турында кыскача мәгълүматлар журналның киләсе санында биреләчәк.

| ФАРСЫ һӘМ ТӨРКИ ӨСТӘМӘЛӘР | АСЫЛ ГАРӘП АЛФАВИТЫНДА | ПОЗИЦИЯДӘГЕ РӘВЕШЛӘР: БАШТА, УРТАДА, АЗАКТА | НИГЕЗЕ ШӘКЕЛ | ХӘРЕФ ШӘКЕЛЛӘРЕ | ТӘРТИП БУЕНЧА |
|---|---|---|---|---|---|
| | ا، آ | آ ـا ا | ا | ӘЛИФ ШӘКЕЛЕ | 1 |
| پ (п) | ب، ت، ث | ٮـ ـٮـ ـٮ | ٮ | БИ-ШӘКЕЛ | 2 |
| | ن | ٮـ ـٮـ ـں | ں | НУН-ШӘКЕЛ | 3 |
| | ی | ٮـ ـٮـ ـی | ی | ЙАЙ-ШӘКЕЛ | 4 |
| چ (ч) | ج، ح، خ | حـ ـحـ ـح | ح | ҖИМ-ШӘКЕЛ | 5 |
| | ع، غ | عـ ـعـ ـع | ع | ГАЙН-ШӘКЕЛ | 6 |
| ژ (ж) | ر، ز | ر ـر ر | ر | РӘ-ШӘКЕЛ | 7 |
| | د، ذ | د ـد د | د | ДАЛЬ-ШӘКЕЛ | 8 |
| | س، ش | سـ ـسـ ـس | س | СИН-ШӘКЕЛ | 9 |
| | ص، ض | صـ ـصـ ـص | ص | СЪАД-ШӘКЕЛ | 10 |
| | ط، ظ | ط ـط ـط | ط | ТЫЙ-ШӘКЕЛ | 11 |
| ۋ (w) | و | و ـو ـو | و | УАУ-ШӘКЕЛ | 12 |
| | ق | قـ ـقـ ـق | ٯ | КАФ-ШӘКЕЛ | 13 |
| گ (гь)، نگ، ڭ (ң) | ک | کـ ـکـ ـک ك | ک ك | КӘФ-ШӘКЕЛ | 14 |
| | ل | لـ ـلـ ـل | ل | ЛӘМ-ШӘКЕЛ | 15 |
| ڤ (w) | ف | فـ ـفـ ـف | ڡ | ФИ-ШӘКЕЛ | 16 |
| | م | مـ ـمـ ـم | م | МИМ-ШӘКЕЛ | 17 |
| ه، ە (ә) | ه | هـ ـهـ ـه ه | ه ە | һИ-ШӘКЕЛ | 18 |

## Язу үрнәкләре

آ ا ا بـ ـبـ ب پـ ـپـ پ تـ ـتـ ـت ت

ثـ ـثـ ث جـ ـجـ ج چـ ـچـ چ حـ ـحـ ح

ح خـ ـخـ خ د ـد ذ ـذ ر ـر ز ـز ژ ـژ سـ ـسـ

ـس س شـ ـشـ ش صـ ـصـ ص ـص ضـ ـضـ ض

ط ـطـ ظ ـظـ عـ ـعـ ع ـع غـ ـغـ غ ـغ فـ ـفـ ف ـف قـ ـقـ

ـق ق کـ ـکـ ک ـک گـ ـگـ گ ـگ ڭـ ـڭ لـ ـلـ ـل

ل مـ ـمـ م ـم نـ ـنـ ن ـن هـ ـهـ ـه ه ئه ـه و

ۋ ـو و یـ ی ی لا ـلا

## Укыгыз һәм күчереп языгыз

آز آق آل آر آس آش آغا آزا آلا آنا

آتا آپا آچا آرپا آراتا آلما آرقان بابا باز باغانا

بارماق باتقاق تابا تاتار تازارا تالاق تارماق جاناش

جای چاباتا چاتان چاتناغان چارلاق دار دان داستان

ساپ ساز ساق ساران ساباقتاش سایلانا سالماق

شامان شاه صاف فاش فال قاداق قازاق قاناغان

قاراساق قابارتما قازان قالفاق کادر کازارما لاف لایلا

لاقان لاشمان لاباسا لامپا لاپاس مارس ماقتانا مای

مالای ناز نارات واق واز یاز یاق یالغان یالاغای

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ЧИТ ИЛЛӘРДӘ









Гомәр Бәширов. Намус. Роман. Немец телендә. О. Браун тәрҗемәсе. Берлин, 1954. 2-басмасы 1955 елда нәшер ителә. 344 бит.

Шул ук әсәр һинд телендә. Судхир Кумар Махтур тәрҗемәсе. Ташкент, «Прогресс» нәшрияты филиалы, 1981. 424 бит. Тиражы 5000.

Шул ук әсәр кытай телендә. Ши Чжепунь тәрҗемәсе. Шанхай, «Хосин», 1952. Романның яңа басмалары 1953 (ике мәртәбә), 1957 елларда чыгарыла. 422 бит.

Гомәр Бәширов. Туган ягым — яшел бишек. Повесть. Венгр телендә. Тәрҗемәчесе Дьюла Фюзеши. Будапешт, «Европа», 1982. 575 бит. Тиражы 5500.

Әмирхан Еники. Әйтелмәгән васыять. Хикәяләр. Венгр телендә. Будапешт. «Европа», 1986. 191 бит. Тиражы 3000. Җыентыкка «Кем җырлады», «Ялгызлык», «Тәнге тамчылар», «Бер сүз», «Әйтелмәгән васыять», «Җиз кыңгырау» әсәрләре авторның «Юлчы» җыентыгыннан Адягасы Клара һәм Баскы Имре тарафыннан тәрҗемә ителгән. Китапта авторның тормышы һәм иҗаты турында Адягасы Клараның белешмәсе дә бирелә.

Әмирхан Еники. Җиз кыңгырау. Хикәяләр. Гарәп телендә. Ташкент, «Радуга» нәшриятының филиалы, 1984. 200 бит. Тиражы 3770. Авторның «Юлчы» җыентыгыннан унбер хикәя сайлап алып тәрҗемә ителгән.



## Нурихан Фәттахка 60 яшь

Нурихан Фәттах (Нурихан Садрилмән улы Фәттахов) 1928 елның 25 октябрендә Башкорстан АССРның Яңавыл районындагы Күчтавыл дип аталган татар авылында туган. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган.

1944 елда «Совет әдәбияты» журналында аның беренче шигырьләре, ә 1948 елда күмәк җыентыкта беренче проза әсәре дөнья күрә. Ә 1955 елда язучы үзенең «Сезнеңчә ничек?» исемле романын тәмамлый. 1962 елда «Бала күңеле далада» исемле романын яза. «Мөдир Саҗидә» повесте Н. Фәттахны татар прозасына үзенчәлекле шигъри бер төс, аһәң алып килгән каләм остасы итеп таныта.

Алтмышынчы еллардан башлап язучы үзенең төп игътибарын тарихи жанрга юнәлтә. Язучы археологик экспедицияләргә кушылып, борынгы Болгар хәрабәләрен казуда катнаша, сәяхәтләр ясый. Әдипнең «Ител суы ака торур» (1970), «Сызгыра торган уклар» (1977) романнары һәм «Кол Гали» (1973) трагедиясе, «Ерак гасырлар авазы» (1976), «Фест дисбесенең сере» (1986) исемле хезмәтләре — әнә шул күп еллык эзләнүләр нәтиҗәсе.

Әдәбиятны үстерүдәге хезмәтләре өчен Н. Фәттахка 1978 елда РСФСРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде.

Нурихан Фәттах — Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редколлегиясе әгъзасы.



## Салисә Гәрәевага 50 яшь

Шагыйрә Салисә Гәрәй кызы Гәрәева 1938 елның 6 ноябрендә Татарстан АССРның Минзәлә районы Тулбай авылында туган. 1962 нче елдан ул Урал-да — Чиләбе шәһәрендә яши, эшли, иҗат итә.

Салисә Гәрәеваның шигырьләре башта республикабыз көндәлек матбугатында дөнья күрде, аннары татар һәм рус телләрендә басылган күмәк җыентыкларда урын алды.

1979 нчы елда «Уралым» исемле мостәкыйль китабы басылып чыкты, быел исә аның иҗатын шактый калку күрсәткән «Тау сукмагы» исемле җыентыгы дөнья күрде.

Салисә Гәрәева — 1982 нче елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярларны кайнар котлыйлар, аларга сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телиләр.

# *Культура тормышы көндәлеге*

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан Язучылар союзының 18 августта узган ачык партия җыелышы авылга шефлык ярдәме күрсәтү, үзгәртеп кору проблемаларын яктырту һәм аларны тормышка үткәрүдә язучылар алдында торган бурычларга багышланды. Очерк һәм публицистика секциясе җитәкчесе М. Зарипов докладыннан соң, әлеге мәсьәлә буенча фикер алышуларда язучылар Р. Төхфәтуллин, Г. Ахунов, С. Сабиров, М. Хәбибуллин, Ә. Галиев, М. Галиев, Р. Кәрами, шагыйрьләр М. Хөсәен, Г. Рәхим, Ә. Гадел һ. б. катнашты.

## ГЫЙЛЬМИ КОНФЕРЕНЦИЯ

24—25 майда Казанда «XIX гасырның икенче яртысы — XX гасыр башларында Россия халыкларының прогрессив иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер юнәлешләрен өйрәнүнең методологик проблемалары» темасына фәнни конференция булып узды. Аны СССР Фәннәр академиясе каршындагы Иҗтимагый фикер тарихы фәнни советы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм СССР Фәннәр академиясенең Философия институты оештырды.

Конференция эшендә Мәскәү, Ташкент һәм РСФСРның кайбер автономияле республикаларыннан килгән галимнәр катнашты.

## АРХЕОГРАФИК ТАБЫШЛАР

Быел июль аенда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының тарихчы-археографлары ике төркемгә бүленеп илебезнең төрле төбәкләрендә тикшеренү эшләре белән шөгыльләнделәр. Тарих фәннәре докторы, профессор М. Госманов җитәкчелегендәге белгечләр Красноярск шәһәрендә һәм крайдагы авылларда булды. Тикшерүләр нәтиҗәсендә эпиграфика өлкәсендә кызыклы күренешләр ачыкланды, бу якларга 1910—1912 елларда Столыпин реформасы дәверендә күчеп килгән татар авылларының хәзерге географиясе, саны ачыкланды.

Бер үк вакытта шул татар авылларында университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары доцент Ш. Садретдинов җитәкчелегендә фольклор практикасы үттеләр. Бу төбәкне өйрәнү КДУ студентлары тарафыннан киләчәктә дә дәвам иттереләчәк.

Тарих фәннәре кандидаты И. Гыйләҗев җитәкчелегендәге икенче төркем Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь районы авылларында эшләде. Аның эшендә журналның тәнкыйть һәм фән бүлеге өлкән редакторы Җ. Миңнуллин да катнашты. Тикшеренүчеләр татар, гарәп һәм фарсы телләрендә язылган йөзгә якын кулъязма һәм документаль чыганак таптылар. Алар арасында болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», XIV йөз татар әдәбиятының күренекле ядкарьләреннән Хөсам Кятибнең «Җөмҗөмә Солтан» дастаны, урта гасыр татар прозасының күренекле әсәре «Каһарман катыйл» китабының XVIII гасыр күчермәсе, Ә. Каргалый әсәрләре бар. Арада төрекчә һәм кытайча язылган таныклык грамоталары да очрый. Алар бу як сәүдәгәрләренең элгәреге эшчәнлегенә, аларның төрле илләр белән тыгыз элемтәсенә ишарәли.

## РӘШИТ ВАҺАПОВ МУЗЕЕ

Рәшит Ваһаповның туган авылы Актукта (Горький өлкәсе) җырчыга багышланган музей ачылды. Авыл клубының бер бүлмәсендә сөекле җырчыбызның шәхси әйберләре, төрле еллардагы концерт афишалары, диплом күчермәләре, фоторәсемнәре тупланган. Шушы ук бүлмәдә Р. Ваһаповның туган йорты макеты куелган.

Музей ачылган көнне Рәшит Ваһаповка багышланган кичә булды. Кичәгә Казаннан сәнгать осталары З. Сәхәбиева, Р. Курамшин, Ә. Яһудин, С. Алиев, җырчының тормыш иптәше Зәйтүнә ханым, улы Зөфәр, Мәскәүдән сеңлесе Халидә ханым һәм башка туганнары килгән иде.

## КАЮМ НАСЫЙРИ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ

Татарстан Халык мәгарифе министрлыгы коллегиясе һәм РСФСР Педагогия җәмгыятенең Татарстан бүлеге президиумы Каюм Насыйри премиясе булдыру турында карар кабул итте. Бу премия халык мәгарифен үстерү эшенә лаеклы өлеш керткән иң яхшы укытучыларга, мәгариф работникларына, фәнни хезмәткәрләргә биреләчәк.

Премия бирүнең положениесе эшләнде, әлеге бүләккә тәкъдим ителгән эшләрне карау һәм бәяләү буенча комиссия составы расланды.

Каюм Насыйри премиясе тәрбия һәм укыту өлкәсендәге яңа хезмәтләр, татар мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбиятын укытуда алдынгы педагогик тәҗрибә туплау һәм аны тормышка ашыру, республикада халык мәга-

рифен үстерүгә зур өлеш керткән өчен бирелә.

Премиягә шәхси хезмәтләр белән бергә, педагогик советлар, җәмәгать оешмалары, галимнәр һәм методистлар рекомендациясе белән коллектив хезмәтләр дә кабул ителә.

Премия һәр елны укытучылар көнендә биреләчәк.

## «ТУГАН ТЕЛ» ҖӘМГЫЯТЕ

Ульяновск шәһәрендә татар әдәбияты һәм сәнгатен пропагандалау юнәлешендә эшләүче «Туган тел» дигән яңа җәмгыять оешты. Энтузиастлар Наил Минеев һәм Айрат Ибраһимов башлангычы белән төзелгән җәмгыять Чкалов исемендәге культура сараенда эшләп килүче «Чулпан» ансамбле белән берлектә, Габдулла Тукайга багышланган кичә үткәрде инде. Әлеге оешма Бөтенроссия культура фондының Ульяновск өлкә бүлегендә рәсми рәвештә аерым секция итеп расланды.

## ЮГАРЫ БҮЛӘК

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Татарстан АССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, СССР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 15 август Указы нигезендә, Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет культурасы өлкәсендәге хезмәтләре һәм күп еллар буена нәтиҗәле эшләгәне өчен язучы Мөсәгыйть Хәбибуллинга, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 22 июль Указы нигезендә, «РСФСРның атказанган культура хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Равил Шәрәфиев совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен РСФСР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 1 июнь Указы нигезендә, «РСФСРның халык артисты» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Татарстан АССР Верховный Советының 1988 ел, 16 июнь Указы нигезендә совет сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен:

— шагыйрә Гөлшат Зәйнашевага «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе»;

— Татар дәүләт драма һәм комедия театры директоры Роберт Әбелмамбетовка «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы»;

— Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең әдәби-музыкаль лекторий җырчысы Рәшит Гобәйдуллинга «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының әдәби бүлеге мөдире Рәмзия Такташка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 12 август Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Роберт Батуллин, шагыйрь Шамил Маннапов, язучы Фатих Хөсни Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 20 июнь Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнделәр.

Озак еллар нәтиҗәле әдәби һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен язучы Шамил Бикчурин, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1988 ел, 29 июнь Указы нигезендә, РСФСР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

# ӨЙ ЭЧЕГЕЗ — ГӨЛБАКЧА...

Өе нурлының — йөзе нурлы, ди халык. Бу сүзләргә тирән мәгънә салынган. Чыннан да, өй эченең бизәлешендә кешенең яшәү рәвеше, көнкүреше, рухи тормышы чагыла. Ул гына да түгел, өй бизәү сәнгате халык культурасының аерылгысыз бер өлеше булып тора һәм аның тамырлары ерак-ерак гасырларга — борынгы болгар чорларына ук барып тоташа.

Кеше һәрчак янәшәсендә, әйләнә-тирәсендә үз рухына, үз зәвыгына, үз идеалларына туры килердәй әйберләр булуын теләгән. Шуңа күрә дә өй бизәүдә кулланылган һәрнәрсә халык тарихын, аның милли үзенчәлеген, дөньяга карашын, дини ышануларын, әхлак кануннарын, эстетик зәвыгын калку чагылдыра.

Халык сәнгате тудырган җәүһәрләрне без, гадәттә, аерым-аерым карыйбыз. Музей залларында да алар шулай аерым-аерым куелган. Ә бит аларның күбесе үзара бик тыгыз бәйләнештә, бер-берсен тулыландырып, бер-берсенең мәгънә төсмерен арттыра. Мөгаен, әнә шундый сәнгать җәүһәрләрен үзара янәшә куеп, бер тирәлектә күзаллаганда гына без аларның рухи кыйммәтен, дөньяви мәртәбәсен чын-чынлап аңлый һәм тоя алабыздыр. Өй эче бизәлешен чагылдырган күренеш — нәкъ менә шундый тирәлек — бик күп сәнгать җәүһәрләрен үзара җыеп, туплап, берләштереп торучы гаҗәеп бер тирәлек ул! Монда инде чигелгән сөлгеләр дә, бизәкле чаршаулар да, тукылган паласлар да, челтәрле пәрдәләр дә, сандык төпләреннән алынган намазлыклар да, өй түренә яки ишек өстенә эленгән шәмаилләр дә — һәммәсе һәм һәммәсе дә бербөтен сурәт булып әверелә. Бер сүз белән генә әйткәндә, өй эчен бизәү халыкның рухи тормышына, көнкүрешенә аеруча тыгыз бәйләнгән һәм монда кул эше сәнгатенең барча төрләре тупланган.

XVI гасырда, Казан ханлыгы алынгач, татар халкының көнкүрешендә һәм, әлбәттә, өй бизәү сәнгатендә дә кискен бер үзгәреш пәйда була. Моңа шәһәрләрнең җимерелүе, татар халкының читкә сөрелүе яки көченеп китүе, халык тормышының гомуми «авыллашуы» сәбәп була.

Авыл өе. Бура-йорт. Өй бизәү сәнгате нәкъ менә шушы бура-йорт белән тыгыз бәйләнгән. Дүрт почмаклы яки алты почмаклы өй. Ап-ак мич. Кече як һәм олы як. Олы якны хуҗалар гадәттә кунак өе итеп тота. Әлбәттә, кунак өенең бизәлешенә аеруча зур игътибар бирелә. Мондагы җиһазлар аеруча җыйнак һәм пөхтә итеп урнаштырыла. Агач сәке, өстәл, урындыклар, зур сандык — гадәти генә булган шушы җиһазларны тукылган һәм чигелгән әйберләр гөлбакча итеп бизи.

Өй бизәү турында сөйләгәндә, әлбәттә, татар халкының барлык этник төркемнәре сәнгатен дә күзалдында тотарга кирәк. Аларның һәркайсында үзенчәлекле сыйфатлар, үзенчәлекле күренешләр бар.

Ә без бүген борынгы Болгар чорында ук ислам дөньясының бай культурасын үзләштергән, тарих юллары аша үз төсмерен саклап узган һәм Казан татарларында сакланып калган өй бизәү сәнгате турында сүз алып бардык. Әлеге сәнгатьнең җуелмас төсмерләрен Татарстан авылларында хәзер дә еш очратырга мөмкин. Андый өйләргә керсәң, чынлап та: «Өй эчегез гөлбакча икән!» дип әйтәсе килә.

**Л. КОРОБЦОВА,**
Татарстан сынлы сәнгать
музее хезмәткәре.

**А. СИНИЦЫН** фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Татарстан китап нәшрияты.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотосы.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1989 ЕЛДА

Газиз Кашапов. **«Убырут»**

...Август аеның караңгы төне. Коеп яңгыр ява. Урманда ялгыз башы яшәп ятучы Мәүләви Риянов хуҗасы күренмәс, әмма нәрсәсе беләндер үзенә бик тә таныш Тавыш ишетә. Әлеге кырыс Тавыш Мәүләвигә, инде картаеп җиткән кешегә, аның узган тормышы, төрле урыннарда эшләгән чакларында кешеләргә кылган кансызлыклары турында исенә төшерә. Үлем бусагасына якынайган көннәрдә булса да үзе төрлечә җәберләгән һәм кимсеткән кешеләрдән бәхиллек соравын таләп итә. Озакламый Мәүләви үзенең вөҗданы белән сөйләшүен аңлый. Шулай итеп, каһарманның гомер йомгагы бик табигый рәвештә сүтелә башлый. Ул берәүне шикаять ярдәмендә «халык дошманы»на чыгарып юк итә, сугышка бармыйча калу җаен таба, ирләре сугышка киткән хатын-кызларны төрле кыен шартларга куя һәм үз корбаны итә...

Баштагы мәлне Мәүләви, элекке хәйләкәрлеген җигеп, вөҗдан таләбеннән качып котылмакчы була. Ләкин Тавыштан качып котылу мөмкин түгел, ул тамчы да калмыйча хуҗасын эзәрлекләп йөри. Чын күңелдән үк булмаса да, кайберәүләр алдында бәхиллек сорарга туры килә. Әмма Мәүләви Рияновның күңелендә чын йөрәктән чыккан омтылыш юк, алар мәҗбүри һәм киеренке. Ниһаять, кайнап торган тормыш фонында Мәүләви Риянов үз хәленең мөшкеллеген аңлый...

*«Убырут» дигән бу повесть, 1983 елда ук язылып, «Казан утлары» редакциясенә тапшырылган иде, әмма торгынлык чорының салкын сулышын җиңә алмыйча, ул авторга кайтарып бирелде. Яңарыш җиле белән рухланган журнал әсәрне автордан кабат соратып алды...*

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210




# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)